# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2000



# YAZUÇILARIBIZ ÇİT İLLƏRDƏ




Şagırlər (suldan uņga) **Robert Minnullin**, **Renat Xaris**, **Rawil Fəyzullin** Gete həm Şiller watanı—Veymar şəhərendə. *Germaniya.*



Tatarstannıņ xalıq yazuçısı **Ayaz Ğıyləcef** Tərkiədə uzdırılgan Aqsaqallar qorıltaında. *İstanbul. Oktəber, 1999.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2000

3

(929)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рөстәм МИНГАЛИМ. Кичер, Аллам! *Шигырьләр* ..... 5
Вахит ИМАМОВ. Утлы дала. *Тарихи роман* ..... 11
Салисә ГӘРӘЕВА. Алмагачтан алма төште... *Шигырьләр* ..... 95
Иллус ГЫЙЛӘҖЕВ. Иң зур куаныч. *Шигырьләр* ..... 99
Нурулла ГАРИФ. Мин сезнең арада яшәдем. *Эссе* ..... 103
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Татарга да бәйрәм килми калмас. *Шигырьләр* ..... 127
Рәшит ШИҺАП. Мәхәббәт көче. *Шигырьләр* ..... 129

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Фатих ӘМИРХАН. Милләт тәрәккъый иттерү ..... 131

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәрит ХАТИПОВ. Якты җирлектәге һәлакәт ..... 137
Ләйлә МИНҺАҖЕВА. Хаталар да булмаса ..... 142

**МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫ**

Фәрит ГАЛИМУЛЛИН «Ислам императоры» — Рәшит Казый ..... 145

**ҖИҢҮНЕҢ 55 ЕЛЛЫГЫНА**

Зәет МӘҖИТОВ. Йөрәк аша узды сугыш ..... 150

**СӘНГАТЬ**

Мәгъсүм ГӘРӘЕВ. Балетның шигъри тылсымы ..... 161

**ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА**

Фәрит БӘШИР. Онытылган әдип Касыйм Биккол ..... 172

**ХӘТЕР**

Лирон ХӘМИДУЛЛИН. Үз кыйбласын тапкан шәхес ..... 178

**ФАТИХ КӘРИМИНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ**

Мәсгуд ГАЙНЕТДИН. Яңа мәдәниятыбызның «баш конструкторы» ..... 182

**KİTAP KÜZƏTÜ**

Tənzilə ARSLANOVA. Quraү moņı qaүta ..... 186
Укучы сүзе ..... 187
Иҗтимагый мәдәни тормышыбыздан ..... 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: окончание романа В. ИМАМОВА «Огненная степь»; эссе Н. ГАРИФ «Я жил среди вас»; стихи Р. МИНГАЛИМА, С. ГАРАЕВОЙ, И. ГИЛЯЗОВА, Ф. АБДРАХИМ, Р. ШИГАПОВА.
«Из сокровищницы татарских рассказов»: рассказ Ф. АМИРХАНА. «На пути обновления нации».
«На конкурс рецензий»: статьи Ф. ХАТИПОВА «Трагедия на светлой основе»; Л. МИНГАЗОВОЙ «Если бы ошибок не было...»
«Память»: статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА «Исламский император - Рашит кази».
«К 55 - летию победы»: З. МАЗИТОВ «Война прошла через сердца».
«Искусство»: статья М. ГАРАЕВА о знаменитом артисте балета Лондонского театра «Ковент-Гарден» И. Мухамедове.
«К истории литературы»: Ф. БАШИРОВ. «Забытый писатель Касим Биккол».
«Память»: статья Л. ХАМИДУЛЛИНА об известном писателе Х. Сарьяне.
«К 130 - летию Ф. Карими»: статья М. ГАЙНУТДИНОВА «Главный конструктор новой культуры».
«Книжное обозрение»: статья Т. АРСЛАНОВОЙ «И возвращается мелодия курая...»
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Татарская красавица» - работа художника М. Саттарова; писатель Б. Камалов.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": the finishing V. IMAMOV'S novel «The fiery steppe», N. GARIF'S story «I was living among you»; verses of R. MINGALIM, S. GARAEVA, I. GILAZOV, F. ABDRAHIM, R. SHIGAPOV.
"From the treasury of Tatar stories": F. AMIRKHAN'S story «On the way of new science».
"literary criticism"; F. HATIPOV'S article «The tragedy on the light basis», L. MINGAZOVA'S article «If we haven't mistakes...»
"Memory": F. GALIMULLIN'S article «The Islamic emperor - Rashit cazi».
"Commemorating the 55 th anniversary of victory": Z. MAZITOV «The war passed over the our hearts».
"Art": M. GARAEV'S article about the famous ballet artist of London theater I. Muhamedov.
"History of literature"; F. BASHIROV «The forgotten writer Casim Bikkol».
"Memory": L. HAMIDULLINA'S article about the famous writer H. Saryan.
"Commemorating the 130 th anniversary of F. Karimi": M. GAINUTDINOV'S article «The main designer of the new culture».
"Book review": T. ARSLANOVA'S article «And kurai melody eturns...»
Humour - satire.
The diary of social and cultural life.
In our covers: «Tatar beautiful woman» artist M. Sattarov, writer B. Kamalov.


★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.02.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8653 Заказ Э-83
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2


© «Казан утлары», 2000 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Рөстәм Мингалим

СҮЗЛӘРЕБЕЗ

### Кичер, Аллам!

Татарчалап сөйлим,
и бер Ходам,
син бит татарча да беләсең.
Инде сизгәнсеңдер Кешелеккә
Син җибәргән акыл кермәсен...
Фикер сикереше булды аз-маз,
ачык җирләр ...бераз капланды.
Зур өметең генә акланмады,
ботын чабып шайтан шатланды.
Көкне бүлә кеше, сугыш-суеш,
комың җитми җирдә комсызга.
Ил өстенә илләр ут ыргыта,
җәһәннәмең булып Җир кыза.
Хәтер җуеп бара бу Кешелек,
Адәм белән Хәува онытылган.
Эттән туган кебек бериш нәсел,
бериш нәсел—
әйтик, дуңгыздан.
Пәйгамбәрләр—
алдан сизгәннәрдер,
качканнардыр шуңа биредән.
Оят бер эш кебек миңа бүген
хәтта шигырь язып йөрү дә...
Ике тиен бирсәң—дин алалар,
өч тиенгә аны саталар.
Бер-ике сүз әйтим урысча да:
Җирдә хаким хәзер Сатана.
Кеше чыкмый пока колларыннан,
тавык сыман алар, баш—этәч!
Авызын төясеңме—акыл белән
сүз дә колак аша кермәгәч?!

... Үзең генә аңлап,
кичер, Аллам,
мин пышылдап сорыйм, Син ишет:
—Каты башкаена Кешелекнең
«уйыйк мәллә тагын бер тишек?!»

*1999.*

## Кай тарафтан, кем нәселе бу җаннар?

Нәҗес чукыр карга булып сандугач—
ни кылырсың, тәкъдиреңдә шул булгач?
Кушып тәкъдир, мин дә аз-маз эчкән чак,
«тарих мең дә тугыз йөз»не кичкән чак.

... Олы юлда минем арттан җиттеләр,
янәшәмнән шап-шып атлап киттеләр.
Калмыйлар да калдырмыйлар мине дә,
туган диләр, юлдаш диләр, дус диләр.
Кай тарафтан, кем нәселе бу җаннар?
Тукайны да белмиләр, чукынганнар!
Минем эчкә сызылып кына шик үтә,
ни әйтсәң дә башта затлы түбәтәй.
Костюм яңа, акча да бар кесәдә,
таласалар, әгәр «чишен» дисәләр?
Уйга килгән—килде бермәл алдыма,
болар минем түбәтәйне алдылар.
Сатып аны, эчтеләр—исерделәр,
үземә дә бер йөз грамм бирделәр.
Туган диләр, юлдаш диләр, сал моны!
Аннан, диләр, салырсың костюмыңны?!
Олы юлда бик кыен шул ялгызга,
мондый мәлдә иман булмый явызда.
Күзләрендә уйный минем киләчәк,
чишендерә болар—чишендерәчәк.
Мөртәтләргә җиңел генә бирелмәм,
салдырырлар костюм белән тиремне!
Сөяксез дә йөрәксез калдырырлар—
әмма болар кулы җитмәс рухым бар!
Исән-имин рухым әйтер берчакны:
—Йә, егетләр, өзик исәп-хисапны!

Ишеткән бар, ил малы илдә калмас,
кайтарырлар—ир малы ирдә калмас:
гаҗәпләнеп ул көнне тарих күрер,
минем рухым боларны чишендерер.

*1997.*

## Гариза

Күп тыңладым акыллылар сүзен,
авызларын гына үбәсе!
Яшим хәзер хатынымны тыңлап,
күптән кирәк булган, күрәсең.

Бу нәтиҗәм—алтмышымны узгач,
изге Тукай туган бу айда...
... Язам хәзер,
хатын әйтеп тора,
мин гариза язам Ходайга.
Бер Ходаем!
Бар кылдың ла үзең,
һәммәбезне Үзең карыйсың:
кара инде ошбу гаризамны,
өч үтенеч анда—барысы.
Беренчедән,
сәнгать нисбәтеннән,
тәмам ашты татар биеккә:
һәркем—яза,
ясый,
уйный,
җырлый,
ну күрсәттек инде биеп тә!
Һәрберебез Тукай бүләгенә—
зур исемгә лаек, валлаһи.
Бу исемне тагарга дип уйлыйм
бар татарга—уптым илаһи.
Искәрт, Ходай, түрәләргә моны,
берәм-берәм безне ваклыйлар.
... Икенчедән, сәясәткә күчеп,
Сиңа тагын мотлак серем бар.
Ирек балы—кайный бит Казанда,
шактый усал булды күәсе.
Киртлә, Аллам, Мәскәү колагына:
мөстәкыйльлек бирә күрмәсен!
Шуны бирсә—халкым бүләк яулап
һәм кәнәфи бүлеп... үләчәк.
Ярый Мәскәү пока моны белми,
әгәр белсә—тиз үк бирәчәк.
Өлгерәчәк тиз үк арабызда
мәркәзебез башын кыючы...
... Хөр мәмләкәт—
истәлек ул безгә:
узганнардан туфрак
бер учлык.

Бүгенебез—сәнгатебез кебек!
Тик әз генә йөрәк ачына:
Казан бакчалары—эт бәдрәфе,
язын шулар кардан арчыла.

Этләргә салым салырлар да
баетырлар әле казнаны...
һәм өченче—соңгы үтенечем,
сабыр-сабыр, хатын!
Язамын!
Үзем хәзер җәннәтеңне көтәм,
бер аягым гарше катында.
Бир исәнлек, Ходай, кызларыма,
татарларым вә урысларыма,
вә глауный—
минем хатынга?

*1998.*

## Ялгызлар моңы

Ак кар асларында ялгыз куян,
җилләр җиргә түшәп кар сырган.
Ялгызларга гына юлдаш моң бу,
ялгыз тавыш кирәк бу җырга:
язган безгә ялгыз булырга.

Без җилләргә ялгыз кермәс идек,
туры килде ялгыз калырга.
Ялгыз тавыш кирәк әй бу җырга,
ялгыз тавыш кирәк бу җырга:
язган безгә ялгыз булырга.

Ялгызларга гына юлдаш моң бу,
ялгыз тавыш җитә бу җырга:
безгә язган җирнең өстендә дә,
астында да ялгыз булырга...
... Язган безгә ялгыз булырга.

*1994.*

## Тыныч төн

Тыныч төн бу, җәйге төн бу авылда,
кое тора урам уты алдында.
Җанга ничек тынгы килсен ди хәзер,
җанга ничек тынгы килсен ди хәзер?!
Үсеп җиткән ак күлмәкле кыз бала
чылдыр-чылдыр
су ала.

Йөрәгемдә тау ватарлык көчем бар,
таңда торып юл чыгасы эшем бар.
Ялгыз китү җиңел түгел бит инде,
ялгыз китү җиңел түгел бит инде.
Үсеп җиткән ак күлмәкле кыз бала
чылдыр-чылдыр
су ала.

Тыныч төн бу, җәйге төн бу авылда,
болай соңлап ник инде су алырга?
Алган суы күңел утын сүндермәс,
дәрьялар да күңел утын сүндермәс!
Ак күлмәкле, кара кашлы кыз бала
чылдыр-чылдыр
су ала.

*1972.*

## Елмай әле

Ниләр булды үзеңә,
ике кара күзеңә?
Мә кульяулык, сөрт яшеңне,
сөйлә серең үземә.

Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә?

Йөзең түгәрәк кенә,
үзең күбәләк кенә.
Керик әле бакчаларга,
йөрик бергәләп кенә.

Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә?

Гөл биреп юатыйммы,
биримме сабырлыгым?
Буйларыңа туры килми
уйларың авырлыгы.

Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә?

Акыллым, гөл генәм,
елмай инде бер генә?

*1992.*

## Гөл күзләре мөлдерәмә

*Фасил Әхмәткә*

Уйнадың да—тулды моңнар,
тулды күңелләремә.
Күңелемне күмде гөлләр...
Нур иңде гөлләремә!

Гөл күзләре мөлдерәмә,
ник чылана таң нуры?
Әллә кояшлы кайгым бу,
әллә шатлык яңгыры?

Көйләреңне каян алдың,
нинди тылсым беләсең?
Сандугачлар мәктәбендә
укыдыңмы әллә син?

Гөл күзләре мөлдерәмә,
ник чылана таң нуры?
Әллә кояшлы кайгым бу,
әллә шатлык яңгыры?

Моңнарыңда җиргә кайта
җирдән киткән әнкәем.
Ак чыбылдык эчләрендә
алмалы бишеккәем...

Гөл күзләре мөлдерәмә,
ник чылана таң нуры?
Әллә кояшлы кайгым бу,
әллә шатлык яңгыры?

*1994.*

## Алмалык

Сиңа дигән сүзләрем күп иде,
һаман шуны сөйли алмадым.
Таңнарым да, кичләрем дә шуңа
бигрәк моңсу килә алланып.

Безнең сүзләр,
сөйләшмичә калган безнең сүзләр—
сыгылыплар төшкән алмалык.

Бар иде шул икәү сөйләшәсе,
син үзең дә аны аңладың.
Чиксез галәм сыйган бу заманга
без янәшә сыя алмадык.

Безнең сүзләр,
сөйләшмичә калган безнең сүзләр—
сыгылыплар төшкән алмалык.

Сөйләшәсе һаман алда сыман,
алдады бит тормыш, алдады.
Бер сөйләшеп—йөз аңлашыр идек,
без сөйләшер вакыт калмады.

Сүзләребез,
сөйләшмичә сүнгән сүзләребез—
сыгылыплар төшкән алмалык...

*1995.*

## Чәчмә әсәрләр

# Вахит Имамов

# УТЛЫ ДАЛА

ТАРИХИ РОМАН

## Ундүртенче бәйләм

### 1

Тимучин унсигезенче яше белән барган чакта Балдак-Далага кайтып Байшонкар-Ясүгәй туграсы астында яши башлаган кыятлылар, нирунлылар саны кабат ике меңгә житкән иде инде. Әүвәл кыятлылар кача-поса һәм берән-сәрән генә өстәлеп торса, соңрак инде йөзәр-йөзәр тирмә булып та Тимучин канаты астына кайтып сыендылар. Болар күбесенчә Тимучинның агалары Дәритай, Тайчу, Канун кул астыннан качып кайткан ирләр һәм һәркайсының тиң анлатмасы бер чамарак иде:

—Агаларың безне нә дошман һөҗүменнән саклый алмый, нә яңа җәйләү йә ганимәт таба белми. Алар ауга кабиләдәге җәмгы ирне ияртеп чыксалар да, атылган җәнлекләрнең тиресен дә, сынын да фәкать яраннары белән бүлешәләр, безгә тоягы илә колагы гына кала. Берәр чин бәгенең буралкы ат көтүен эләктерсәк тә, безгә аты түгел, тышаулыгы та тәтеми. Синең атаң Ясүгәй баһадир андый бирән түгел, ул соңгы җамаяк дөгесен дә тигез бүлешә иде. Атаңдагы гаделлек күчми калмагандыр, шуңа өметләнеп синең янына кайттык.

Шул зар, шундый сүзләр аша Тимучинга акыл белән сабак бирүләрен кабиләдәге ирләр үзләре, бәлки, сизмәгәндер дә. Әмма Тимучин аларның һәрбер фикерен күнел сандыгына бикләп барды. Тора-бара абруй-дәрәҗәсен күтәрү өчен ул инде хәйлә һәм хыянәт кебек адымнарны ясаудан да бик үк тартынмады.

Бервакытны ауга чыккач, юлда кыятлылар чаган татарларының сәүдә кәрванына тап булдылар. Тартарлар төнгелеккә туктап, арбалардан ыстан төзеп ята, уртасында кул-аяклары пута-чылбырларга богауланган йөзәрләгән коллар тезелеп тора, ә кәрванны ышыклап килгән сакчыларның саны биш-алты дистәдән артык түгел иде. Кул астында утыз-кырык чамасы гына җайдак булса да, Тимучин шул төндә үк һөҗүмгә ташланырга ният итте. Аның әмере буенча кыятлылар әүвәл чаптарларын якындагы сырт артына илтеп яшерделәр. Төн уртасы узып киткәч кенә, алар ыстанның әйләнә-тирәсе буйлап сибелеште. Һәркем өчен бурыч билгеләнгән, алар хәзер яшь баһадирның соңгы әмерен генә көтеп ята иде.

Арбаларын яннарына яткырып, араларына киез бәйләгән тоташ

---

Ахыры. Башы—журналның 1,2 саннарында.

чылбыр аша ыстан эченә, иң беренче булып, Тимучин үзе үтте. Бавырчы белән Җәлмә аның артыннан калмый шуышалар, болар өчесе тиң тешләренә хәнҗәр кысып капкан, кулларына кылыч тоткан иде. Богауланган колларны ыстан уртасына тезеп салсалар да, татарлар унар адым саен икешәр сакчы куйган булып чыкты. Ләкин инде сакчыларның күбесе җебегәннәр, күкрәкләре өстенә килеп терәлгән ияк тирәсеннән мышнаган һәм пуфылдаган тавыш кына ишетелә. Тимучин, Бавырчы, Җәлмә сакчыларның һәммәсен тиң чәнчеп чыктылар да, богауланган колларны уята башладылар. Колларның күбесе ни булганын аңлый иде, ахры, ым кагып пышылдап рәхмәт белдерүне кирәк санадылар.

—Тәшәккер-әдәрем, тәшәккер-әдәрем.

Тимучин әле иреннәренә бармак тидереп, әле йодрык селтәп тегеләрнең авызларын томаларга мәҗбүр булды. Хәер, коллар үзләре дә һәр мизгелнең алтын бәһасе икәнлеген бик тиз чамалады, ашыга-кабалана аларның һәркайсы иптәшләрен пута-богаулардан арындыра башлады, кулларында сакчылардан калган корал пәйда булды. Хәзер инде ыстанның тышкы ягында яткан кыятлылар өчен шартлы фәрман бирәсе генә калган иде. Тимучин якында гына пыскып азапланган бер кисәүне кулына эләктерде дә, аны күккә чөйде. Шул минутта ук кыятлылар арбалар чылбыры янында йокымсырап утырган торгаклар өстенә карчыгадай очып ябырылды...

Татарлар коллыгыннан котылган әсирләрне кат-кат санап чыккач, аларның биш йөзгә якын булуы ачыкланды. Күбесе Иссык-күл һәм Сәйхун тирәсендә сәүдәгәрләр ятьмәсенә эләккән уйгыр, казакъ, угыз ирләре икән. Тимучинның әсирләргә төбәп дәшкән сүзләре бер үк вакытта шома да, кармаклы-элмәкле дә булып яңгырады.

—Төрки илә магул бер ананың игезәк улларыдыр. Без, магуллар, сезне чин бирәннәре кулына барып керәчәк коллыктан азат иттек. Хәзер сез ирекле, туган ыруларыгызга кайтып китсәгез дә һичбер тоткарлык юк. Мәгәр уйланыгыз. Татар сәүдәгәрләре алып киткән чакта сезнең берегез өчен дә ул ырудашларыгыз акча түләмәгән, сезне коткармаган. Кайтып житү бәхетенә ирешсәгез, сез аларны гафу итәрсезме?—Җавап көтеп Тимучин тын торды, һичкем эндәшмәде.

—Аннары кайтып житә алуыгыз да бик икеле. Менә, күрәм, Онон буена килепирешкәнче һәммәгез дә коры сөяккә калган. Сездә бүген үк юлга чыгарлык җегәр дә юк, аннары юлда янә берәр сәүдәгәр йә бинең колына әверелү хәвефе көтеп тора. Шуңа күрә мин сезне үз кабиләм учагы янына чакырам. Һәммәгезгә кәләш табылыр, казан уртак булыр.

Кыят мәргәннәренең күбесе уйгыр, казакъ, угыз ырулары яшәгән якка алып китә торган көнбатыш юл тирәли, тезелешеп баскан, карашлары кырыс, аткылары усал—әсирләрнең Тимучин тарафыннан әйтеп бетерелмәгән әмергә буйсынмыйча чарасы юк иде. Алар балаларын җуйган кыр казлары сыман тавышсыз-тынсыз гына, җепкә тезелешеп, Балдак-Дала ягына атладылар. Ялга дип тукталган беренче төн үткәч тә, тан атканда, кыят җайдаклары әсирләр чылбыры каршына өч казакъ иренең җеназаларын һәм биш-алты ук китереп ташлады. Тимучинның аңлатма-кисәтүе бу юлы да кыска, коры булды.

—Ошбу бичараларны минем мәргәннәрем уйгыр даласы ягыннан табып алып кайтты. Алар туган якларына кайтмакчы булып юлга чыкканнар да, аймык тозагына барып юлыкканнар. Җирдә аунаган ошбу аймык укларын минем мәргәннәрем бичараларның тәненнән суырып алган...

Ялга тукталган икенче төндә әсирләрнең һәммәсе диярлек гел йокысыз чыкты. Ә таң аткач Тимучин инде яна, кыргый адымы белән мингерәтте.

Саф каршында әүвәл дәү күн капчык тоткан Тимучин пәйда булды, аннары Җәлмә белән Бавырчы куллары артка каерып бәйләнгән Билгүтайны чыгарып бастырдылар. Билгүтай һични төшенми, аптыраган иде,

күрәсен. Ул аяклары белән типкәләп тә, симез, дәү гәүдәсе белән ыргылып та каршы торып маташты. Ул арада Тимучин инде кулларына тоткан капчык авызын ачты, бер сүз эндәшмәде. Менә, капчык эченнән чыккан ак кеш тиреләре, алтын кысага утыртылган көзге, көмеш очлым, шәмдәл, мәрҗән ташлы нәни айбалта, йөзек-беләзекләр... һәммәсе дә җир өстенә очты. Ин ахырдан гына Тимучин алтын путалар белән бизәп ясалган нәни тартма чыгарды. Келәсен ачты да, аны баш өстендә селтәп-селтәп алды. Тимучин каршындагы хәтфә үлән өстен сөт шикелле ап-ак энҗе бөртекләре каплап китте. Телгә килеп сүз башлагач инде Тимучинның тавышы җан өшеткеч салкын һәм хәтта аяусыз да булып яңгырады.

—Яуда табылган малны тигез бүлешү магулларның төп кануны иде. Билгүтай аны бозган. Менә, моннан ике көн элек чаган татарларыннан талап алынган нигъмәтнең төп өлешен ул үзенә яшереп калдырган. Минем бораддәрем булуга карамастан Билгүтай ошбу караклык өчен илле камчы илә җәзаланачак. Ул яшереп җыйган ошбу мәрҗәннәрне исә һәммә иргә, әйе, әйе, һәммә иргә бүлеп бирәчәкмез...

Аркасында бер исән җире дә калмаганга күрә йөзтүбән капланып һәм яман ыңгырашып яткан Билгүтай янына Тимучин төнлә генә керде. Акланып та, гафу үтенеп тә маташмады, кыска гына итеп күңелендәге уен ачып салды.

—Җан бирер алдыннан атай-мәрхүм шундый васыять әйткән: «Магулларны юкка чыгудан бер тугра астына, бер йодрык булып туплану гына коткарачак». Мин ошбу вазифаны үз өстемә алам. Ә олуг гамәл бәрабәренә юлга чыккан чакта кителгән теш, канаган тез илә ваклан-мыйлар. Җиңү яулау өчен һәрбер чара кулай, чөнки җиңүчене хөкемгә тартмыйлар. Ошбу хакка түз вә миңа ачуланма, Билгүтай...

«Тимучин каты куллы, коры, мәгәр гадел, юлы гел унудан»,— дигән хәбәрләр акрын-акрын гына бөтен Онон, Аргын, Далай-Нур, Керу-лен буйларына җәелгән магул кабиләләренә тарала торды. Балдак-Дала үзәненә кайтып сыенучылар саны да хәзер инде айлап түгел, көнләп арта иде.

## 2

Елан елы башланып унсигез яшь тулгач, Тимучин энекәшләре Билгүтай белән Хасарны да, мәңге аерылу белмәс яраннары Бавырчы белән Җәлмәне дә үзенең тирмәсенә чакырттырып алды.

—Миңа кыятлыларның тулы хокуклы баһадиры булырга да вакыт,— дип башлаган Тимучинның тәүге сүзләрен барчасы тын сәерсенә төшеп кабул иткән иде. Хуҗаның беркадәр көттереп тезгән алдагы гыйбарәсен ишеткәч, авызлары ук ерылды.

—Күпмегә кадәр миңа хатынсыз вә ятаксыз интегергә була? Анда Бөртек-сылу да, шаять, мине көтеп тилмерәдер. Юлга җыеныгыз, калым хәстәрләгез. Бүләкләрне алгач, Дәй чәчән эреп китәрлек булсын...

Кыятлылар юл буе уйнап-көлеп барды. Дәй чәчән дә кияү кәрванын күптән көткән икән. Шулай да ул Тимучинны таный алмыйча, байтак вакыт гаҗәпләнеп торды. Кияү егете үзенең кабиләдәшләренә бер дә охшамаган. Буе тегеләрдән бер баш калку, гәүдәгә нык таза, маңгае киң. Кыятлылар кара-кучкыл булса, Тимучинның чәчләре куе-җирән төстә. Яңакларында сакал бөртекләре дә юк, фәкать борын астында гына сирәк-мирәк мыек төртеп тора. Аның каравы егетнең күзләре ут бөрки, ихтыяр һәм гайрәт чалымнары бөтен торышында ярылып ята.

Конгыратлар җәйләвендә атна буе туй иткәннән соң гына, кыятлылар кайтыр юлга җыена башлады. Арбалар өстенә сандык-сандык бирнә чыгарып тезгәч, карт Дәй чәчән тирмә эченнән якалары, изү, җиң очлары энҗе-мәрҗән бөртекләре белән каймаланган гаҗәеп затлы тунны

кулларына күтәреп чыкты. Картның куллары һәм тәне калтырана, күзләре дә бераз дымлы иде. Сүзләрен дә көттерә-көттерә, ялындырып тезде.

—Ошбу кара төлке тунын тугыз санә элгәре безгә чиннәр каханы бүләк иткән иде. Буир-Нур күле эргәсеннән сезне куган, синең атай-агаларыңны галиб кылган өчен... Инде атаең юк, урыны җәннәттә булсын... Магул илә татар ырулары арасында да дошманлык вә нәфрәт бетеп бара, Ходай Тәгалә шаһит, киленнәр алышамыз... Ике арадагы низаг тәмам юкка чыксын, ике ыру киләчәктә гомер бакый дустанә вә имин хәят илә мәгыйшәт кылсын иде... Аналары миңа гел угыл китерде. Бөртек бикә берданбер кызым булып үсте, аерып җибәрү авыр. Аның кадерен бел, берүк сакла...

Кайткан чакта уен-көлке тагын да мул булды. Иң чиста сулы чишмәләрдә чайкап юган сыман алсу һәм саф йөзле, карлыгач канатыдай кыйгач кашлы, чем-кара толымнарын инбашына салган Бөртек бикә, чыннан да, фәрештәләр назы астында иркәләнеп үскән шикелле күз алгысыз чибәр һәм Тимучин аны кочып кайтуы белән үк бик бәхетле иде. Онон елгасын кичкән чакта аларга биш-алты арбадан хасил бер кәрван очрады. Бәхет-гыйшык хисеннән исергән, туарылган Тимучин шулар каршында иләсләнеп-һаваланып кычкырып җибәрүдән дә тайчынмады.

—Ясүгәй баһадир угылы, кыятлылар хуҗасы Тимучин конгыратлар бәге Дәй чәчәннең кызын алып кайта! Тимучин хәзер үзе дә тулы хокуклы баһадир. Әй, сез, аң булыгыз!

Каршы очраган кәрван арбаларында тугра да юк, аларның кайсы ыру, нинди кабиләдән булуларын чамалавы читен, ә ияр өстенә менгән бер җайдакның карашы ут бөркегән сыман көйдереп һәм усал яна иде. Тимучин арбасына терәлеп узган чакта нәкъ шул телгә килде:

—Вакыт житкән икән, вакыт җиткән. Мотлака, аң булырмыз.

«Вакыт» сүзенә нишләп басым ясый, нәрсә хакында кисәтү ул?— моны искәреп торучы кеше табылмады. Ничек сәлам-фәлән бирми очрашсалар, шулай саубуллашмый-нитми аерылыштылар. Ә Балдак-Далага кайтып керүгә, Тимучин үзенең тирмәләренең бер өлешен Бүрехан тавы итәгенә күчереп кую турында әмер бирде. Шул көнне үк яшь баһадирның тирмәләрен киртәләрдән корылган ыстан уратып алды, төнгелеккә аның тирәсенә дистәләгән торгак сакка басты. Кәләш күреп күзе томаланган яшь баһадир һавалана, шаша һәм үз куллары белән үзенә тозак коруын да абайламый иде.

Беренче төндә үк, таң атканда, аның шушы кияү ыстанына өч йөз җайдаклы нөгәр бәреп керде. Аны мәркет бәге Чилунның бертуган энекәше Карасу житәкләгән һәм ул моннан унтугыз ел элек Ясүгәй тарафыннан рәнжетелгән абыйсы өчен үч алырга сусап килгән иде.

Кияү ыстаны өстенә ингән хәвефне, иң беренче булып, Айлун әкәнең колчурасы Гайшә сизеп алды. Чәче-башы тузган шул Гайшә кереп төрткәли башлагач Тимучин һичбер нәрсә аңышмыйча торды.

—Йорт-ниргәнә этләр ябырылды. Тор, хуҗам, тор!

Тимучин этләр өргән аваз ишетмәкче булып колак салган иде. Тышкы яктан атлар пошкырган, ир-ат сүгенгән, агач сынган, ул да түгел, инде ачыргаланып-илереп кычкырган хатын-кыз тавышлары бәреп-бәреп керде. Шик юк, Бүрехан итәгенә дошман һөҗүм иткән, ыстан тирәсендә шулар белән торгаклар арасында орыш бара иде. Тимучин сикереп торды, кулларына хәнҗәр, кылычын алды. Бер минут эчендә зиһененнән йөз төрле уй сикергәләп узды.

Бүреханнан Балдак-Дала ерак, ярдәмнең тиз килеп житә алуы бик икеле. Җитмәсә, Балдак-Далага дошман һөҗүме хакында, йә, кем хәбәр итсен? Нигә, нигә диеп кабиләсеннән читкә аерылды ул? Татарның: «Аерылганны аю ашар»,—дигән гыйбарәсенең кайтавазы шушы микәнни соң? Аннары, аерым кияү ыстаны кордырып та Тимучин үзе берни отмады бит әле. «Сезнең якта әле туй булмады, кушылырга иртә», дигән булып Бөртек бикә, барыбер, аерым тирмә кордырды, кичә шунда ятты.

Анын сылуы, анын карлыгачы хәзер кайда икән?

Тимучинның соравын сизгән сыман шул минутта тыштан Бөртек бикәнең ачыргаланып кычкырган тавышы ишетелде:

—Тимучин, Тимучин!.. Әни, жаныкаем!

Яшь баһадир тирмә ишегенә таба ярсу болан сыман сикерде дә, киез читен бер-илле ачуга ук капылт сыны катты. Ыстан эче йөзәрләгән жайдак белән тулган, кулларында канга манчылып беткән кылычлар ялт-йолт итә. Әгәр күзләренә күренсән, болар сине шул минутта кавын сыман телеп ташлаячак.

Тимучин күзенең угы белән Бөртек бикәне дә бик тиз эзләп тапты. Аны бастырыктай озын буйлы, корык гәүдәле, әзмәвердәй бер ир инбашына салган. Бөртек бикә, бичара, аяклары белән тибенгәндәй итә, тырмаша һәм тешли, ләкин имән кәүсәсе шикелле нык куллардан барыбер арына алмый. Житмәсә, «бастырык» пәһлеван ихахайлап көлеп аны һаман мыскыллавын, ярсытуын белә.

—Чылгыр, Чылгыр! Син Тимучин кәләшенең үзен эләктергәнсең. Мәгәр мин ошбу тотык чәчбине Ясүгәй-тинтәк шикелле үземә кәләш итеп алып олыламыйм. Мин аны сина, колчурама, хатынлыкка бирәм. Жегәрең житкәнче тапала шуны, әйдә.

Бүрехан тавынын итәген ат шикелле кешнәп көлгән тавыш күмеп китте. Мондый мәсхәрә Тимучин өчен тырнак астына шырпы кадап жәзалаудан кайтыш түгел иде. Ул әле генә «бастырык» пәһлеванга эндәшкән тавыш иясен эзләп тапты һәм яр читенә сөйрәп чыгарылган балык сыман авызын ачты да катты. Ияр өстендә әтәч сыман кукыраеп утырган бу бәндә Тимучинга Онон елгасын кичкән чакта очраган ут карашлы жайдак һәм инде һичбер шик юк—ул мәркет бәгенең бик тә якын бер туганы иде. Тау итәген ярып янәдән дә шушы кешенең әмере яңгырады:

—Тимучины кайда соң әле монын, кыят батыры кайда? Мина шуны тотып китерегез. Жигән тиешле энекәш дип тормыйм, мин ул кияү егетенең тиресен үз кулларым илә тотып туныйм!

Карасунын «жигән энекәш» дигән булып төрттерүе, үзенчә, Тимучинны «Ясүгәй дәвамы түгел, Чилу бәктән яралган бала», дип мыскыл итү иде. Тимучин каны кызышудан ядрә сыман шартларга житешсә дә, үзенең көчсезлеген аңлаудан тешләрен шыгырдата-шыгырдата барыбер дә түзде. Ә бераздан берничә жайдакның жиргә сикереп төшүен күреп алгач, Тимучин тирмәнең түр ягына ыргылды да, ак киезне хәнжәре белән телеп, ачыклык аша куаклыклар эченә кереп качты. Әмма аны мәркетләр дә шәйләп өлгерде. Карасунын ажгырып кычкырган усал тавышы колакларны гүя изеп-сызып узды.

—Барчагыз да Тимучинның артыннан ташланыгыз! Тиз арада тотып китермисез икән, һәммәгезне суям!

Өч йөзгә якын жайдак бүре тавышыннан өркегән сарык көтүе сыман бердәм рәвештә алга ыргылды. Хәленең үтә мөшкел икәнлеген Тимучин, әлбәттә, бик шәп аңлый иде, ул, селәүсен шикелле тиз-тиз сикергәләп, Бүрехан өстенә менеп китте. Атлар эре-эре ташлардан хасил тау сырты буенча менә алмаганга күрә мәркетләр баһадирдан шактый калыштылар. Ул арада Тимучин инде Бүрехан тавының икенче як итәгенә тәгәрәп төште дә, әллә бурсык, әллә бүе өереннән бушаган зур бер өн эченә кереп чумды. Мәркет жайдаклары тау сырты буенча әрле-бирле сугылып әллә ничаклы вакыт үткәрделәр, әмма Тимучинның эзен тапмадылар.

Яшь баһадир кабат Бүрехан тау итәгенә әйләнеп кайткан чакта кияү ыстанынннан күмер генә калган, анда Айлун әкә, Бөртек кенә түгел, хәтта, Гайшә дә юк, мәркетләр аларның һәммәсен тотыклыкка алып киткән иде. Тимучинның күзләреннән ике яшь бөртеге сытылып чыкты. Ләкин аларны Кук-Тәңрегә күрсәтү дә олы гөнаһ иде. Тимучин яңакларын кискен хәрәкәтләр белән тиз-тиз сөртеп алды. Теш арасыннан усал ысылдаган сүзләр сытылып чыкты:

—Юк, сындыра алмассыз мине! Ясүгәй угылы тантана итәчәк көннәр килер, килер әле!!!

### 3

Мәркетләрнең мәсхәрәсе өчен үч кайтармау, бигрәк тә Айлун әкә белән Бөртек сылуны тотыклар хәлендә калдыру һич ярамый, ачуны эчкә йотарга маташу яки чара күрмәү дошманнар тарафыннан бер янакка сукканда икенчесен куеп тору кебек жебегәнлек булып кабул ителер иде. Әмма Байшонкар-Ясүгәй туграсы янына тупланган кыятлылар саны биш мең ирдән артмый. Мондый вак-төяк көч белән мәркетләр өстенә бару үгез мөгезен сындырырга җыенган чебен өеренә тиң. Кыят кабиләсенең, Байшонкар нәселенең дан-шөһрәтен саклап калу өчен нишләргә соң инде, нишләргә?

Тимучин атна-ун көн буе фәкать шушы хакта гына баш ватты, ашау-эчүдән, йокыдан мәхрүм калды. Баһадирның хәле яман читен һәм мондый тозактан чыгуның әмәле дә һич табылмый иде. Шулчакны Балдак-Далага, гел дә көтмәгәндә, Бавырчының атасы Нагу-Баян кунакка килеп төште. Ашын ашаган, яшен яшәгән ак сакаллы картның киңәш-унашы да төпле-ипле чыкты.

—Менә син, балакай, «әллә инде тайжутларны, чатҗиратларны, һич тә югы гамужә аганнар Дәритай, Тайчу, Канунны үзенә ярдәмгә дәшеп караргамы», дисең. Инде уйлан. Бервакытны сиңа хыянәт кылып, үзеңне япа-ялгыз көе ташлап киткән бәкләр хәзер син өстеңгә чыксын вә көчәйсен өчен ярдәм итәрләрме? Юк, мантыйкка сыймый бу. Аннары, аннары ярдәмгә эндәшү, димәк ки, баш июнең икенче ягы да бар бит. Син теше-йоны коелып, эче суырылган хәлсез бүреләр каршына барып тезләнәсеңме дә, әллә инде гайрәт чәчеп торган арысланга барып сыенасыңмы?

—Биш-алты өтек бүре эргәсенә барып йөз суы түккәнче, сыңар арыслан янына иңеп ялвару отышлырак инде анысы, моңа шигем юктыр. Мәгәр ярдәм өмет итәрдәй арысланны каян табасы соң?

—Әйдә, инде ошбу арыслан хакында да без баш ватып карыйк. Хәтерем ялгышмаса, моннан тугыз санә элгәре, маймыл елында бугай, гирәйләр ыруының башлыгы Тугърул хан да кара татарларга каршы яуга кергән иде. Сонра ул яуда татарлар өстен чыкты, ә без хансыз вә дүңгәләк кеби таралышкан-сибелгән ыру булып калдык, син беләсең булыр. Ие, менә шул яу барышында Тугърул хан да катнашты. Җиенлылар аны Керулен буена кысрыклап тукмый башлаганда синең атаң Ясүгәй батыр аңа ярдәмгә килде вә Тугърулны үлем элмәгеннән коткарып калды. Шул яудан соң Тугърул хан Ясүгәйне үзенең гомерлек борадәре, дип игълан итте. Хәтта, алар беләкләрен кисеп кан да алыштылар.

Тимучинның карашында энҗе кар бөртекләре өстендә уйнаклаган кояш нурларына охшаш якты чаткылар ялтырап алды, сулышы капты.

—Син Тугърул хан эргәсенә барып тезлән, дисең инде алайса. Шулаймы, Нагу-Баян би?

—Тезләнгәннең башына төкерүләре дә ихтимал. Юк, тезләнмә. Ин-иң затлы бүләкләреңне ал да, әйдә, юлга җыен. Әгәр ошбу арыслан сине иш итә икән, теше-йоны коелган теге бүреләр үзләре үк синең хозурыңа йөгереп килер.

### 4

Гирәй-кираитлар ыруының би һәм батырлары кыятлылар кәрванын Тулы елга ярына килеп каршыласа да, Тугърул хан үзе яшь баһадирны кабул итәргә бик үк ашыкмады. Яраннары ханның көтмәгәндә сырхаулап китүен сәбәп иткән булды, ә Тимучинның күнелен корт кимерде. Аптырагач, бер би аша өлкән ханбикәгә кызыл якут ташлы беләзек озаттырды. Төнге күке пышылдавы тәэсир итте бугай, икенче

танда Тимучинны ханнын кече сараена чакырттылар.

Тугърул инде мыек-сакаллары чалара башлаган, юан, дәү корсаклы ямьсез бер ир иде. Ул Тимучинны тәхетеннән төшеп, кочагына кысып каршылады. Эреләнмәде, Тимучин да иелеп анын җин очларын үпте, тәхет янында утырган ханбикәне дә бил бөгеп һәм олылап сәламләде. Һәр ике як хәл-әхвәл сорашкан булдылар. Ләкин уртада бер дә җылылык юк, әнгәмә дигәннәре һич ябышмый иде. Тимучин ым какты һәм залга үзе белән алып килгән бүләкләрне кертергә кушты. Бавырчы белән Җәлмә күтәргән тәпсиләр өстендәге алтын кысалы көзге, мәрҗән ташлы айбалта һәм кеш тиреләрен күргәч, ханбикәнең йөзе яктырды, тик Тугърул хан карашында гына тәгәрәп төшү чаткылары бик үк сизелмәде. Ул арада залга инде Хасар белән Билгутай да керде. Алар кулларына Дәй чәчәннен бердәнбер кызына бирнә итеп биргән затлы тунын тоткан, кара төлке тиресенә беркетелгән энҗә бөртекләре залга үтеп кергән кояш нурларында язгы боз кыйпылчыкларыдай сихри, ымсындыргыч булып җемелдиләр иде. Тунны күрүгә үк Тугърул хан алтын тәхетеннән сикереп торды, Тимучинны янә кысып-кысып кочагына алды.

—Олыладын, картаймыш көнемдә дә күнелемне күрден, рәхмәт борадәрем.

Тәхеткә барып утыргач, Тугърул затлы тунны тез өстенә салды да, ханбикәнен колагына иелеп болай пышылдады.

—Ошбу бүләк чин каханы кулыннан җаухуриларга гына бирелә торган олуг бер билгедер. Ә җаухури—ул бөтен төрки-магул даласында Ван-хан, ягъни чин каханынын вәзире, дигән дәрәҗә йөртүчедән кала икенче зат булыр.

Зал уртасында Тимучин телгә килде. Яшь баһадир башын берникадәр иеп сөйләсә дә, аһәңе кыю һәм нык иде.

—Кайчандыр син минем атам Ясүгәй баһадирны үзеннен гомерлек борадәрен, дип атагансын, канын алышкансын. Атам инде вафат, анын канын алып ошбу җиһанда без өч угыл калдык. О, Тугърул хан! Мәнгелеккә күчкән атам хакына дип син мине угылын итеп кабул кылсан вә үз канатын астына алсан иде?!

Тимучиннын кайнар сүзләреннән сон дулкынланган Тугърул хан бармак битләре белән күз яшьләрен сөртте, тавышы да калтыранып чыкты.

—Әйе, әйе. Ясүгәйне оныту мөмкинме сон?! Син угылым, син угылым минем, Тимучин!

## 5

Нагу-Баян фаразлаган сүзләр, чыннан да, рас килде. Тугърул ханнын унбиш мең җайдаклы гаҗәеп зур чирү бирүен ишетүгә үк Тимучин янына чатҗиратлар төмәне дә килеп кушылды. Чатҗиратлар гирәй-кираитлар белән берлек төзеп яши, яу юлына чыккан төмәнне кабилә баһадиры үзе алып килгән икән. Ә ул кабилә башлыгы дигәннәре моржага керсә, Тимучин аны артыннан да бик җинел таный торган Җәмуга булып чыкты. Балачакта аерылуны белмәс бу ике дус хәзер инде бөтен чирүләре каршында кочаклашып күрештеләр. Озакка сузмыйча шул көнне үк бер-берсен борадәрләр, диеп аташтылар, гомергә аркадашлар, җан дуслар булырга антлар беркеттеләр.

Мәркет ыруынын җәйләүләре дошман күтми иде. Гирәй, чатҗират һәм кыятлыларнын утыз мең лек гаскәре аларны туздырып, сытып барды. Орхон елгасы ярына житкәч, баскынчы төмәннәр икегә бүленде. Җәмуга батыр үз төмәне белән Орхонны кичте дә Селенга ягына китте. Тимучин исә, егерме мен җайдаклы ике төмәнне алып, Байкүл буена юнәлде.

Юк-бар бәрелешләр үткәреп атна чамасы баргач, мәркет бәге Чилу һәм анын туганнары, яраннары яшәгән җәйләүләргә дә килеп ирештеләр. Чилу белән Карасу Тимучин явы турында, әлбәттә инде, күптән хәбәрдар

иде. Орхон тамагында алар аны ике төмән яугир һәм шулар алдына тоташ чәнечкедән хасил киртәләр чылбыры тезеп каршылады. Тимучин ул чәнечкеле киртәләрне абайлап өлгермәгән иде, бер төмәнне шундук яуга ташлап нык ялгышты. Җайдакларның беренче ташкыны шул чәнечкеле киртәләр аша үткәндә җәяләреннән сынар ук та очыра алмыйча капылт авып төште. Аяклары, күкрәкләре чәнечкеләр белән теткәләнеп беткән йөзләгән яу атлары тоякларын, авызлык һәм йөгәннәрен җиргә бәрә-бәрә, озак тартыштылар. Йөзәрләгән җайдаклар да дошман угыннан бигрәк яраланган һәм җан ачысы белән тартышкан чаптарларның тояклары эләгүдән тынып-тынып калды.

Мондый мәхшәрне күзәтеп торган җайдакларны яңа һөҗүмгә күтәрү, билгеле ки, чиксез авыр иде. Тимучин янына җыйналып меңбашлары озак киңәштеләр. Күп очракта сүзсез генә торган Билгүтай аларны бу юлы көтелмәгән тәкъдиме белән таң калдырды.

—Тимучин! Бер мең җайдак бирсәң, мин әнә теге тау башына менәм. Шуннан мәркетләр өстенә бүрәнәләр илә ташлар очырамыз.

Тимучин кул астындагы чирүдән бер мең җайдак аерылып китүне шәйләп калсалар да, мәркетләр аларның кай якка юнәлүен анламадылар. Ә бермәлне янда гына торган биек тау битендә йөзәрләгән җәяүле пәйда булды һәм шул минутта ук мәркет укчылары өстенә эре-эре ташлар, юан бүрәнәләр тәгәрәп төшә башлады. Орхон тамагында коточкыч зур гарасат кузгалгандай булды, сафлар буталышты, бар иңкүлек өстен ачыргаланып һәм ярсып кычкырышкан тавыш каплап китте. Тимучин инде үз янындагы җайдакларны да яуга ташлагач, мәркетләр әлләни зур каршылык та күрсәтеп маташмады. Болай да сафларын, нөгәрләрен югалтып бетергән мәркет укчылары, зур кыяга килеп бәрелгән дулкын сыман чәчерәп, төрле якка качты.

Бу Тимучинның иң әүвәлге зур җиңүе иде. Аның бик тә-бик тә тантана итәсе килде. Әмма әнисе Айлун әкә белән сөеклесе Бөртек кинәт аның күз алдына богауланган хәлдә килеп басты. Тимучин чытырдатып йодрыкларын төйнәде, энекәшләре Хасар белән Билгүтай ягына борылгач, яман усал кычкырып, боерыклар ыргытты:

—Әй, сез, борадәрләр! Камчы илә кыздырганны көтәсезме әллә? Чилу бәйнең артыннан ыргылыгыз да, инәкәйне һәм Бөртекне тизрәк коткарыгыз!

Ул арада дала түрендә, тау итәге буйлап таралган Чилу бәй җәйләвенең бер очында көчле янгын купкан, ә аяусыз җил исә очкын һәм төтенне төрле якка куалый һәм тузгыта иде. Берзаманны кара сөрем бөтен җәйләү өстен каплап алды, тирмә-утарлар гел күренмәс булды. Һәрбер мизгел саен тик бер исем Тимучинның чигәләрен сытып янгырады:

—Бөртек, Бөртек, Бөртек!..

Сагынудан, әрнү-газаплардан түземлеген җуйган Тимучин үз-үзен белештермичә, ярсып, кара айгырының касыгына типте. Хуҗасының дуамал кайнарлыгына иярләнгән айгыр, авыр пошкырып, ут һәм сөрем давылы эченә томырылды. Кара төтен туфанының үзәгенә барып кергәч, Тимучин берни күрми, аннан бер адым да калышмаска күнеккән Бавырчы белән Җәлмә дә күптән аны күздән җуйган иде. Төтен болытын ерып барган чакта Тимучин чаптарының күкрәгенә әле ис-акылын җуйган мәркетләр, әле өркү-өшәнүдән бәбәкләре акаеп чыккан иясез атлар килеп бәрелгәләде. Тимучин аларның берсен-бер шәйләмәде, эчтән, бәгырь түреннән үк суырылып чыккан сагынулы тавыш белән кычкыруын белде:

—Кайда син, Бөртек? Бөр-т-е-е-к!

Тау итәгенең өстенәрәк менгәч, күз алдын каплап киткән төтен пәрдәсе ачылгандай булды. Артыш, өрәңге, карагач куаклары арасында ниндидер биек арбалар төркемен, шулар тирәсендә кайнашучы шәүләләрне шәйләп алгач, Тимучин шул тарафка ыргылды. Анда мәркет бөгенен бертуган энекәше Карасу белән бастырыктай озын гәүдәле Чылгыр-пәһлеван киемнәре ертылып-өзгәләнеп беткән Бөртек бикәне путаларга

урап азаплана иде. Үзенә таба кылыч айкап һәм ажгырып очкан жайдакны күргә үк, Карасу бәк сөнге тотып каршы төшкән иде, әмма берничә мизгелдән соң ул инде тоташ теленеп чыккан канлы бугазы белән гырылдап, аяк астына ауды. Орышка дип корал хәстәрләмәгән Чылгыр-пәһлеван тегермән канатыдай иләмсез озын кулларын яман болгый-болгый карагач куаклары арасына ыргылды, һавада анын усал янап кисәткән тавышы гына асылынып калды.

—Бик тантана кылма, Тимучин. Синен белән киләчәктә орышларда күрешербез. Шулчакта кан косасын алда әле!

—Тимучин, Тимучин, баһадирым минем!—дип еламсырап чакырган тавыш ишетелде. Чәче-башы тузган, елый-елый шешенеп һәм ярсып беткән ярымшәрә Бөртек ике кулын югарыга чөйгән хәлдә аңа таба атлап килә иде. Зөфаф кичен дә татымый аерылышкан кияү белән кәләш бер-берсенен кайнар кочагына атылдылар.

## 6

Җиде-сигез ай чамасы үткәч, Бөртек угыл тапты. Балдак-Далага гирәйләрдән, чатжират, нируннардан йөзәр-йөзәр тирмә кунак килде. Чаптарлар бәйгесе уздырып, бил алышып, ауга йөреп бер ай буе туй иттеләр. Исеме «Жучи» дип тәгаенләнгән сабыйны телгә генә түгел, инде кулга алмаган бер кунак та калмады. Чатжиратлар, гирәйләр анын хөрмәтенә дип әллә никадәрле бүләк китерделәр. Тик Тимучин гына Бөртек бикә тирмәсенә атналар буена кереп карамады, кара көеп һәм урт чәйнәп йөрде. Сабый Жучи жирән Тимучинга бер дә охшамаган, дегет сыман кара чәчләре, корык кебек как һәм озынча гәүдәсе белән үк ул мәркетләрнен Чылгыр-пәһлеванына ныграк тарта иде.

—Жучины коеп куйган Дәй чәчән, диләр бит. Бабасы да арык тәнле, сагыз кеби кара кеше икән. Бөртек бикә киленне юкка табалама.

Айлун бикә шул рәвешчә юанып караса да, Тимучиннын йөзе яктырмады. Әле ярый Балдак-Даладагы бүтән артым анын күнелен дәртләндереп, үсендереп торды. Тимучиннын мәркетләр ыруына ясаган жиңүле походыннан сон Байшонкан-Ясүгәй туграсы янына кайтып сыену тапкан кыятлылар саны ун мен тирмәдән дә артып китте. Ләкин Мәнгелек Күк Тәнре һәм тәкъдир-сукбай яшь баһадир өчен мондый бәхетне дә күпсенгән булып чыкты.

Бәбәй туена кунакка килгән чакта Нагу-Баян карт аны, югыйсә, әллә ничә тапкыр кисәтеп үткән иде:

—Теге чакта япа-ялгыз калдырып сине ташлап киткән агаларын да, күрше ыру-кабиләләр дә кыятлыларнын көчәюеннән шүрли. Татарлар турында бер гыйбрәтле гыйбарәне ишеткәнен бармы? Теге жиһанга күчкәч жәһәннәмдә, имеш, җәмгы халыкларны да аерым-аерым казаннарга салып чыкканнар вә яннарына авыр гөрзи тоткан торгаклар бастырып куйганнар, ди. Кем казаннан чыгарга маташа икән, шундыйларнын башына сугып кире чумдыралар. Бер татарларны гына һичкем сакламый, ди. Газраилләре килеп, ошбу хәлгә гажәпләнгәч, торгаклар кул гына селтәгән. Боларны саклау кирәкми, әгәр берәр татар күтәрелә башлый икән, аны башкалары үзләре үк кире сөйрәп батыралар, имеш. Менә, бүген магул кабиләләре арасында да шундый ук хәл, батыр. Агаңнар да, мәрхүм Котул хан угыллары да синен гаярь юлбарыска әйләнүеңне һич теләми. Аеруча тайжутлардан сак бул. Иң беренче булып ташлап киткәннәре өчен алар синен үч алуыннан курка. Ерак арага чыкма, юлда ялгыз йөрмә.

—Бүредән курыкканнар гына урманга бармый ла ул. Ә мин хатыннар итәген саклап утыра торган нәселдән түгел,—дип Тимучин кул гына селтәде, Нагу-Баян сүзләренә илтифат итмәде.

Жучи туеннан сон байтак айлар узды, Тимучиннын күнелендәге төер таралмады. Ул һаман да Бөртек бикә тирмәсенен бусагасын сирәк

атлап керә, кыят ирләренең йөзләреннән дә гел кимсеткеч, мәсхәрәле караш кына эзли һәм менә шул, бәгырен туктаусыз кимерүче, яман корттан арынырга теләп, ауга йөрүләрне өстен күрә иде. Соңгысында да үзе белән җиде-сигез генә ирне алып, ул Соры-Айгыр үзәнлегенә таба сунарлыкка китте.

Аны биек, текә кыялар арасыннан шаулап аккан Кайнар чишмәгә килеп җиткәндәрәк капылт эләктерделәр. Әүвәл һаваны йомран сызгырган тавыш чыгарып очкан уклар ярып узды һәм Тимучинны озатып килүче җайдакларның һәммәсе тин иярләре өстенә бөгелеп төште. Көтелмәгән һөҗүмнән өне алынган кара айгыр кешнәп-дулап арткы аякларына күтәрелде, унга-сулга сикереп бәргәләнде. Әмма берничә мизгелдән соң ук инде Тимучинның гәүдәсен кылдан үргән аркан чорнап алды һәм кыят баһадиры өзәнгеләреннән суырылып җир өстенә очты.

Искә-анга килгән һәм аякларына сикереп баскан чакта аны инде дистәләгән укчы уратып алган, ә каршында исә кулларына зәһәр камчы тоткан Торгытай бәк ияр өстеннән генә көлеп тора иде.

—Нәрсә, бөтен магул тирмәләрен үз эргәнә туплап хан булырга жыендыңмы, имгәк?—дип, каһкаһәле, зәһәр тавыш белән кешнәп сорады ул.—Һавадагы бер көтү торнага йөгән кидерү хакында хыялланганчы, иң әүвәле, син кулыңдагы сыңар песнәккә—үз хатыныңа хуҗа булырга өйрән. Ул сиңа, азгын мәче кеби, мәркетләрдән бала ташымасын.

Торгытай бәк үзе ихахайлап көлде, ат көтүе сыман яман кешни-кешни укчылары аңа кушылдылар. Тимучин гомер буе үзе хакында «мәркет баласы, Чилу бәй малае», дигән мәсхәрәле төрттерүләрне ишетүгә инде күнеккән, ул андый гайбәтне мыек астыннан көлеп кенә үткәрә торган иде. Ә менә бу юлы Җучины да «мәркет баласы», дип мыскыл итү Тимучинның үтенә барып тиде. Ул селәүсен шикелле капылт сикерде дә, ярсып гыжлый-гыжлый Торгытайны ат өстеннән сөйрәп төшермәкче булды. Ләкин тайҗутлар бәге ияренә коеп куйган кебек нык утырды, ул гына да түгел, кулындагы зәһәр камчы белән Тимучинны унлы-сулы китереп яңаклый да башлады.

—Син бөтен тайҗут кабиләсен пыран-заран китерергә ант эчкән түгел идеңме соң, хөрәсән? Менә сиңа, менә! Болай гына да калдырмыйм. Мин сине колчурама әйләндереп, аякларымны юарга мәҗбүр итәм әле!

Тимучинны тайҗутлар кышлавына кадәр ат ияренә аркан белән тагып һәм камчылый-камчылый алып кайттылар. Тайҗутлар үзләренә иң якын кардәш булган уранхай кабиләсе белән кушылып яши, кышлауга дип корылган тирмә-алачыклары да хәзер бергә икән. Торгытай шул уранхай кабиләсенең иң оста бер тимерчесенә шапырынып дәште:

—Җирсүдәй! Ошбу кыят мүкләгенең тояклары тотмый. Дагалале шуны. Кабат үз җәйләвенә кайту турында хыяллана да алмаслык булсын.

Шул көнне үк Тимучинның кулларына богау салдылар, муенына арба тәгәрмәче кадәрле агач башмаклар кидерделәр. Тайҗутларның орчык хәтле генә малай-шалае да аңа әле таш ата, әле тибеп үтә, ул ашарга утырса җамаягын урлый, ә Тимучинда исә үч алу түгел, җавап кайтарырдай-сакланырдай да мөмкинлек юк иде. Олы бер кыят кабиләсенең данлыклы баһадиры Ясүгәй улы булган Тимучинның үз туганнары кулындагы кимсеткеч әсирлек, коллык көннәре шулай башланды.

## Унбишенче бәйләм

### 1

Соңгы берничә ай буена Андрей кенәзгә якын килмәле түгел, нинди йомыш, нинди гозер белән генә янына кермәсеннәнр, ул бәйдән ычкынган эт шикелле котырына, теләсә кемне ертык тун урынына

өзгәләп ташларга әзер иде. Бөек кенәзнең тиктомалдан да күкерт сыман кабынуын күргәч, баш воеводасы Борис Жидиславич та, кала кенәзләре һәм тиуннар да аның йортын әледән-әле урап кына үтә башлады. Шуннан соң Андрей кенәз күп вакытын чиркәүләрдә һәм үз сараендагы иконалар каршында озын-озак гыйбадәт кылып уздыра торганга әйләнде. Ләкин юк, көннәр буе сузылган гыйбадәтләрдән соң да ул җанына тынгы таба алмый, һәр хәтирә яки һәр яңалык аның бәгыренә шырпы сыман кадалуын дәвам итә иде.

Болгарлар өстенә зур яу белән барып инде икенче улы—Мистиславы да яман шешенүдән вафат булганнан соң, Андрей кенәз үзенең дә, хатынының да кайгысын җиңеләйтмәк ниятендә, Байгөл янына барып кергән иде. Байгөл аның кипшенеп, бөкшәеп беткән кыяфәтен дә, иртә чаларган чәчләрен дә күз чалымына китереп тормады. Андрей бусаганы атлап узуга ук, ул аның өстенә үз сабыйларын явыз тилгәннән саклаучы ана каз ярсулыгы белән очып кунды.

—Үз бүлмәләренә бикләнеп дуңгыз булганчы эчтен-эчтен дә, хәзер җылы сүз вә миһербанлык көткән мескен кыяфәтендә монда керденме, җәллад? Юхаланма, елан. Битлегеңне йөз кат алыштырсаң да, минем син җәлладны гафу итәсем юк. Атаң Юрий-кабәхәтнең минем газиз әткәемне агач ботагына асып үтерүен азсынгансың, туймас нәфесең һаман кан сораган икән. Син ике тапкыр минем Ватаныма яу оештырдың. Шул синең ач-әрвахлык походларыңда минем сөлектәй ике газиз балам шәһит китте. Мин газиз әткәем өчен дә, ул балаларым өчен дә сиңа соңгы сулышымача ләгънәт укыячакмын!

Хатынына үч итмәкче булып, Андрей кенәз үзенең төпчек улы Григорийны Байгөл кочагыннан йолкытып алдырды да, аны Владимир-Суздаль епископы Феодор-атакай янына озаттырды. Исәбенчә, ул гомер буе әнисе янында үскән, болгар һәм кыпчак телләрен әнәсеннән җебенә кадәр белгән Григорийга Феодор-атакай үгет-нәсихәте, аның үрнәге аша христианлык рухын индермәкче иде. Әмма кала кенәзләре һәм тиуннар бөтенләй дә көтелмәгән хәбәрләр китереп Андрей кенәзне өнсез калдырдылар.

—Син Киев каласыннан митрополит дәрәҗәсен йолкып алып, аны Феодор-атакайга бирергә, шул юл белән Владимирны урыс җирләренең тулы үзәге итәргә хыялланып йөрисең, бөек кенәз. Ә син монда урыс иле, бердәм дәүләт, дип җан атып йөргән бер вакытта Феодор-атакай авыллардан-авылларга кучә-кучә монахларны, инок һәм попларны талый. Алтын-көмешләрен яшергән чиркәүләрнең байтагында ул инде попларның күзләрен чокып, телләрен кисеп алуга кадәр барып җитте. Җитмәсә, ул атакай турында әле тагын яп-яшь малайларны үзе янына түшәккә ятарга мәҗбүр итә икән, дип тә сөйлиләр. Шулай булгач, синең Григорий төпчегең ул ерткыч епископ янында нинди эшкә генә өйрәнә алыр икән?..

Котырынган-шашкан Андрей Феодор-атакайның кул-аякларына богау салдырды да, аны Киев митрополиты янына озаттырды. Махсус хөкем карары буенча явыз Феодорның анда телен кисеп алганнар, күзләрен чокыганнар, уң кулын һәм тагын нәрсәсендер чабып өзгәннәр. Мондый хөкем-җәза турында ишетеп беркадәр тынычланса да, Андрей кенәз үзенең төпчеге Григорийны, барыбер дә, Боголюбовога кире кайтармады. Тынгы белмәс Бөек Новгород каласы бу вакытта янә баш күтәргән, моңа кадәр кенәз булып торган Рюрикны куып, ул инде ничәнче мәртәбә хуҗасыз көенчә һәм һичкемгә бил бирмичә яшәргә җыена иде. Андрей яңа кенәз итеп Новгородка Григорийны җибәреп карады. Ләкин бер ел кадәре дә вакыт үтмәгәндер, новгородлылар аның төпчек улын да Владимирга куып кайтарды.

Ул арада инде Киев каласыннан да судан алып утка сала торган хәбәр килеп җитте.

—Син гади кенәз дәрәҗәсендә калдырып киткән Глеб энекәшең вафат. Аның хакында кара халыкка «яман чирдән үлде», дигән ялган

житкерделәр. Ә чынында исә аны кала бояры Григорий Хотович суеп үтергән бит. Хәзер, әнә, Волынь, Галич, Дорогобуж, Новгород, Луцк кенәзләре Мстислав, Давид, Владимир, Рюрик, Роман бергә кушылганнар да, Киев каласын кулга төшергәннәр. Туганнары тарафыннан тәхеткә утыртылган Рюрикны да янә элеккечә «урыс җирләренең бөек кенәзе», дип игълан иткәннәр, ди...

Искиткеч хәбәрләр һаман агыла торды.

—Киев җирендә һичбер тынгылык юк. Хәзер анда Ростислав нәселе белән Олег оныклары тынышу белми үзара сугышалар. Галич кенәзе Ярославның вәхшилегенә бөтен Киев халкы ярсый, гасабилана, ди. Ул Анастасия атлы бер фәхишәгә гашыйк булган да, үз хатыны белән балаларын зинданга бикләп тота, көн саен җәзалый башлаган. Ярый әле беркөнне хезмәтчеләре ярдәм иткәннәр дә, Ярослав хатыны улын алып Польша җиренә качкан. Ярослав теге фәхишә Анастасия белән инде ачыктан-ачык типтерә, хезмәтчеләрен эт урынына кыйната, изә башлаган. Шуннан ары түземлеген җуйган Галич боярлары туфаннан да яман фетнә күтәргәннәр. Теге Анастасияне учак өстенә ташлап, яндырып үтергәннәр. Аннан янә Ростиславныкылар баш калкыткан. Алар синең энекәшең Ярополкны кулга төшергәннәр. Син сугыш уты кабызсаң, алар аны аманат итеп кулланмакчы икән...

Андрейны Чернигов кенәзе Святослав белән Олег нәселе яу походы оештырырга котырта башлады.

—Энекәшең дошман кулында. Үзеңнең намусыңны сакларга да алынмассыңмыни? Без бит яуга әзер. Фәрман гына юлла.

Андрей Ростислав нәселе белән ике арадагы низагны тыныч кына хәл итмәкче булды. Козьма ватагасы белән бергә килеп кушылган яңа сугышчылар арасында Михна-Кабан атлы элеккеге Киев пәһлеваны да бар иде. Андрей шуны чакыртып китерде дә, Ростиславныкыларга шундый сүзләр тапшырырга кушты:

—Киев өлкәсе минем биләмәм ул. Рюрик аны калдырып Смоленскига китсен. Фетнәне оештыруда төп гаепче булган Мстиславны исә урыс җирендә бөтенләй күрәсем килми. Анысы җаны теләгән якка чыгып качсын...

Ә Михна-Кабан Киев жиреннән бөтенләй адәм көлкесенә калып кайтты. Котырынган Мстислав аның чәч-сакалын кыркып бетергән, җитмәсә аның аша Андрей кенәз өстенә дә ушат-ушат пычрак түккән икән.

—Ул Ростиславныкыларның да кенәз икәнлекләрен онытып, безне малай-шалай итеп сөйләшмәкче була. Без аннан курыкмыйбыз, әйдә, яуга килсен. Аны да менә шулай кыркып җибәрербез...

Мондый мәсхәрәгә түзү гайре җебегәнлек, әмма җиденче дистәсе белән барган Андрейның инде походларга йөрердәй куәте юк иде. Ул үз янына төпчек энекәшләре Михаил һәм Всеволод белән әлегәчә эшсез-вазифасыз яткан Григорийны чакыртып алды. Күрсәтмә-боерыкларны да, картларга хас булганча, ашыкмыйча тезде.

—Бүген үк һәр тарафка—Суздальгә, Белоозерога, Новгородка, Муромга, Рязаньга чапкыннар җибәрегез. Мин үзем Полоцк, Туров, Гродно, Пинск, Смоленск калаларыннан дружиналар көтәм. Суздаль-Рязаньнардан полклар килгәнче үк юлга чыгу хәерле. Барча дружиналар соңыннан Чернигов кенәзе җирендә кушылырлар. Поход барышында гаскәрне минем бердәнбер улым һәм дәвамчым Григорий җитәкләр, аңа воеводам Борис Җидиславич ярдәм итәр. Гаскәрне икегә бүләргә туры килсә, аның икенче яртысын Чернигов кенәзе Святослав кулына тапшырырсыз. Ул походларга бик күп йөргән кеше, яуның рәтен белә. Киевны яуламыйча торып кире борылмагыз!..

Чернигов биләмәсе җирендә бергә кушылган чакта Андрей Боголюб яклы кенәзләрнең саны гына да егермедән арткан, ә алар кул астындагы барча гаскәр илле меңләп кылыч исәпләнә иде. Теләсә кайсы чит дәүләт өчен дә куркыныч көч булган мондый гаскәр турында ишетүгә үк, Киев

тәхетенә утырган Рюрик кенәз каланы ташлап китте. Андрей яклылар Киевка бер ук атмыйча да бәреп керде. Ләкин әле жиңү яуланмаган. Рюрик гаскәре Киевны калдырса да, аннан илле чакрымдагы Вышегород каласында ныгып урнашкан иде. Ана Белогород, Галич калаларыннан да берничә полк ярдәмгә килеп житкән, диделәр.

Илле мең кешелек гаскәргә өстәмәгә әле тагын киевлыларны, якын-тирәдәге угыз-бәрәндиләрне дә алып егермедән артык кенәз хәзер инде Вышегород өстенә ябырылды. Гаскәр белән әле Григорий, әле Андрейнын төпчек энекәше, унтугыз яшьлек Всеволод, әле сакал-мыегы чаларган Чернигов кенәзе Святослав командалык итте. Дружиналарны ничәмә-ничә тапкыр штурмга ташлап карадылар, бертөрле дә файдасы күренмәде. Рюрик яклылар ачлыктан, сусызлыктан жан бирергә риза, әмма аларның Андрей кенәз каршында тезләнергә, ирекләрен жуярга исәбе юк иде. Тугыз атнага сузылган камап торудан соң Андрей яклы егерме кенәз дә үз дружиналарын алып, туган биләмәләренә таралырга мәжбүр булды.

Җинелү тамгасы күтәреп кайткан төпчек улын Андрей кенәз ачы хурлану хисләренә күмелеп каршылады. Ләкин моны Григорийның үзенә сиздермәде, бар ачуын, гарьләнү-үкенүен эченә йотты да, күбрәк вакытын янә гыйбадәткә багышлап уздыра торганга әйләнде. Яшьлегендә ул төзергә хыялланган бердәм дәүләт әлегәчә юк һәм аның әле булган кадәресе дә, иске кафтан сыман, һәрбер жөе буенча шатыр-шотыр килеп умырыла, жимерелә иде. Андрей моны анлап-күреп торды, әмма бу хәвефне туктатырлык көч-чараны эзләп таба алмады.

Ә бер танда аның сараена киемнәре тәмам теткәләнгән, үзе шыр сөяккә калып, йөзеп куе сакал-мыек баскан Макар килеп керде. Иске воеводаның үлеме хакында хәбәр алгач, Андрей кенәз нәкъ ярты ел чамасы элек шушы Макарны ерак Нократ буендагы Колын-Хлынов кальгасына яна хужа итеп куган иде. Менә, борылып кайткан, димәк, эш пешмәгән. Нигә кире кайткан, нәрсә булган анда?

Хужаның соравын да көтмичә, гыжлый-гыжлый, Макар үзе сүз башлады:

—Анда яшәгән вотяклар, чирмеш, болгарлар янына Новгородтан качкан урыслар да барып кушылган. Безгә буйсынып, ясак түләп яшиселәре килмәгән. Беркөнне бергә берләшеп баш күтәргәннәр дә, кальга башлыгы булып торган Борис белән аның яраннарын суеп бетергәннәр. Безне дә көчле тозак корып каршы алдылар, минем бар отрядны диярлек кырып бетерделәр. Көч-хәл белән генә качып котыла алдык. Чирмеш урманнары эченә качкан идек, анда тагын вотяклар белән арлар куа башлады. Барча иптәшләрем һәлак булды. Әллә нинди сазлык-чытырманлыклар аша, ачка кыркыла-кыркыла кайтып життем. Хлыновлылар беркемгә дә буйсынмыйча, үзбаш булып яшәргә жыена. Менә шундый яман хәлләр, хужам.

«Иске буа сыман жимерелә, жимерелә дәүләт», дип күнеленнән генә янып сызланды да, Андрей Макарны эттән алып эткә сала-сала куып ук чыгарды. Ялгыз калгач, эчтән сыза-көя һаман да шул Хлынов турында уйлануын белде. Бер минутта зиһене кинәт яктыргандай булды.

Юк, чирмеш-вотяк түгел, ә болгарлар баш күтәргән анда. Шулар Хлыновны кулга төшереп янә Колын кальгасына әйләндергән. Ике тапкыр поход белән бардым, икесендә дә балаларымны үтереп, гаскәремне туздырып кайтардылар. Урыс кенәзлекләре оеша, берегә алмый, ә алар анда һаман жиңү тантана итә, үргә менә бара. Минем кулдан көч китә, моны башка кенәзләр дә күреп тора. Шуңа алар мина буйсынырга теләми. Әле үземнең коргаксыган агач хәленә төшмәвемне күрсәтергә кирәк. Моның өчен иң кулае—Болгар өстенә яна поход ясау. Әйе, яна поход! «Талау походы» дисәң, башка кенәзләр дә кушылмый калмаячак. Кабат тантана итәрлегем дә, янә ияр өстенә менәрлегем дә бик бар әле минем».

Поход турында фикер алышырга дип, Андрей үз янына Байгөлнен

энекәшләре Хәким белән Расүлне, аларның кияүләрен, Болгарга бетмәс үчле булган Хәмбәлне дәштерде. Ләкин Расүл атлы каенэнекәше Владимир каласыннан Боголюбового килеп тормаган, үз фикерен бер яраны аша гына әйтеп җибәргән:

—Элеккеге ике походында ике улыңны югалту аз булды микәнни? Юк инде, җизнәкәй. Минем каргаларга азык буласым килми. Аннары, үз илем өстенә кылыч күтәреп мәңге барасым юк!

Кайнешендәге мондый тәкәбберлекне, гыйсъянлыкны ишетеп, Андрей әүвәл авыз ачып бүкән сыман торды. Аннары күзләрен акайтты да үкереп үк җибәрде.

—Мин аны атасы кебек үк итеп дарга асачакмын, хәсисне!

Мәгарәдәй тынлык эчендә байтак вакыт сүзсез утырдылар. Андрей һәркайсына караш ташлап чыкты, ләкин Хәмбәл булып Хәмбәл дә походны яклап сыңар сүз дә әйтмәде. Аптырагач, Андрей кулын селтәп кенә, якыннарына таралырга кушты.

## 2

Андрей янына чакырылган ирләр шул кичтә үк Хәкимнең кияве Петр өенә җыелышты. Кенәзгә үчле булган, аңа теш кайраган боярһәм сәүдәгәрләр Владимир каласында инде байтак икән, Петр өстәле артына тезелгән ирләрне саный башлагач, алар егермедән дә артык булып чыкты. Алдан ук сүз беркеткән сыман, ирләрнең һәммәсе дә билләренә корал аскан иде. Әүвәл Андрей кенәз исемен искә алучы кеше булмады. Әмма хәмердән бушатылган стаканнар кунакларның телен тиз ачтырды.

—Андрей кенәз шаша. Җиденче дистәне ваклый бит инде, акылдан ычкына башлавы шулдыр,—дип, беренче булып, аны каланың иң абруйлы бояры Аверкий Ефрем телгә алган иде. Аның сүзләрен, өй хуҗасы буларак, Петр элеп китте.

—Кулыннан дәүләт ычкына, шуңа котыра ул. Оят түгелмени? «Олуг кенәз мин генә, Киев—вассал», дип башкаланы тез астына салмакчы иде дә, Ростиславныкылар аңа кукиш күрсәтте. Глебны үтереп, башкалага хуҗа булып кына калмадылар, ә Андрейның энесе Ярополкны бүгенгәчә әсир итеп тоталар. Төпчек улы Григорий башта Бөек Новгородтан колак каккан иде, аннары инде Вышегород янынннан да күтенә тибеп кайтардылар. Хәтта, шул ерак Нократтагы Хлынов булып Хлынов кальгасы да аңа баш бирергә теләми. Менә шуңа күрә яна поход оештырып, абруен кабат кайтарырга омтыла ул. Безнең җилкәгә утырып, җәннәтнең үзегенә барып кермәкче, ай-яй оста!

—Менә шиш аңа! Карт комганын учлап тик утырсын!—дип, бер дә көтмәгәндә, моңа кадәр ипле, тыныч сәүдәгәр булып танылган Хәким сикереп торды.—Ул карт тәренең, барыбер, бер походы да унмый. Болгар өстенә элек тә ике мәртәбә яу белән барып карады бит инде. Икесендә дә йоны өтелгән шәрә бүре сыман куып кайтардылар. Меңәрләгән сөлектәй ир шунда ятып калды. Инде без дә козгыннар өчен азык булыйкмыни?

Сәүдә остасы Геронтий урынынннан кубып сүз башлады:

—Яким-туган бик тә дөрес әйтә. Андрей кенәз походка чыга икән, тагын меңәрләгән кардәшләребезне югалтачакбыз, ә аларның ятим балаларын шул ук Андрей яраннары базарларда кол итеп сатачак. Ул Андрей явызга тагын да үзебезнең үк урыс җирләрен талаттырып, коргаксыттырып булмас.

—Үлем, үлем тиеш ул котырган эткә!—дип, биш-алты ир шундук йодрыкларын югарыга чөеп үкерде.

Янда сүзсез генә утырган Рәсүлгә таба ымлап, юлда кәрваннар йөртүче Иоким тезеп китте:

—Сез хак әйтәсез, туганнар. Безнең Андрей кенәзне барып суюдан

башка чарабыз юк. Әнә, ул бүген походка барудан баш тартканы өчен Рәсүл сәүдәгәрне асып үтерү белән яный. Каршы торуыбызны белеп ала икән, иртәгә безне дә шул ук язмыш көтә. Йә иртәгә ул безне дарга аса, йә без бүген үк аның үзен җәһәннәмгә олактырабыз. Андрей кенәз сараена һөҗүмне кичектерү үзебез өчен үк үлем. Юлга ашыгыйк, туганкайлар, юлга!

«Үлем» сүзе әйтелгән, ин куркыныч үр инде үтелгән иде. Тагын берәр йотым хәмер эчеп алгач, тынычланыбрак фикерләүгә күчтеләр. Алдан сүз беркетеп куйган шикелле бермәлне һәммәсенең дә карашы Хәмбәлгә текәлде. Ин усал фетнәче кыяфәтендә сорауны Петр бирде.

—Ә син нишләргә җыенасың, Анбал Ясин?—Рус жиренә качып килгәннән бирле Хәмбәл Хисамны Владимир сәүдәгәрләре шулай дип атап йөртә иде.—Син жебек таракан шикелле берәр ярыкка качып калырсыңмы, әллә безне кенәзгә үк барып сатарсыңмы? Син койрыгыңны сыртка салып төлкедәй качып китүгә дә, сынар адәмне түгел, бөтен халкыңны сатып йөрүгә дә күнеккән бит инде.

—Йә, син кем яклы?—дип, һәммәсе дә кылычларын ана таба төбәп жанвар кыргыйлыгы белән кычкырдылар.

Хәмбәл өшәнеп калды, урыныннан сикереп стенага елышты. Әмма ана якынаеп килгән кылыч очлары да, шашкан карашлар да чиксез үткен иде. Ул ачыргаланып, ярсып кычкыра-кычкыра акланырга гына мәҗбүр булды.

—Мин сезнең белән лә инде, сезнең белән, Алла коллары! Кенәз белән ике тапкыр Болгар өстенә кайтып карадым. Әмма икесендә дә яман алдады, мина тәхетемне кайтарып бирмәде ул. Күралмыйм мин аны, күралмыйм!

Шулчагында Владимир каласының капка сакчылары өчен жаваплы Гордей телгә килде.

—Кенәз өстенә барсак, аның безне коралланып каршы алуы бар бит. Димәк, аның коралларын алып яшерергә, шулай итеп аны ике кулсыз калдырырга кирәк. Ә Анбал—Андрей кенәзнең бик тә ышанычлы кешесе, аның казначысы. Әйтик, безнең беребезне дә төнлә кенәз сараена якын жибәрмиләр. Ә Анбалга һәрчакта юл ачык. Шулай булгач, әйдә, ул сарайга үтсен дә, Андрей кенәзнең кылычларын алып чыксын әле.

—Һе! Әгәр безне сатса?—дип, һәммәсе дә янә күмәк купты.—Берьялгызын анда жибәрсәк, бу ана ин кулай очрак бит.

—Сатмыйм, сатмыйм! Сез бармыйсыз икән, аны үзем суям!—дип, Хәмбәл янә шашты, ярсыды. Үзенең ипле, тыныч тавышы белән көтмәгәндә Хәким сәер генә итеп өстәп куйды.

—Сатмый, сата алмый ул, юкка кайгырмагыз. Сарайда безнең яклы тагын бер сугышчы бар. Анбал безне сата-нитә калса, шул сугышчы аның үзен суеп үтерәчәк.

Һәммәсе дә сорау тулы караш белән Хәкимгә төбәлделәр. Ә ул кулы белән ирләргә урыннарына утырырга ишарәләде.

—Ул кешенең исемен мин сезгә, әлбәттә, Анбал барында әйтмим. Әмма белеп торыгыз, ул бик тә ышанычлы кеше. Аның инде бу вакытка, хәтта, кылыч-хәнҗәрләрне урлап яки яшереп куйган булуы да мөмкин.

Шулай да ирләрнең Хәмбәлне үзләреннән ерак жибәрәселәре килмәде. Кыюлык өчен дип тагын берәр йотым хәмер дөнкеп куйдылар да, төн уртасы житкәндә һәммәсе бергәләп юлга кузгалдылар.

### 3

Егермедән артык гыйсъянчы жайдак Боголюбовога килеп житкән чакта төн дегет сыман кап-кара, күзгә төртсәләр дә беркем, берни күренмәслек иде. Шушы хәл аларга кыю, житез хәрәкәт кылырга ярдәм дә итеп куйды.

Сарай сакчыларының күбесе бу вакытта инде жиде бабасын онытып тирән йокыга талган, уяу дигәннәренең дә хәле аңкы-миңке иде. Фетнәчеләр йокыдагы сакчыларның һәммәсен диярлек тавыш-тынсыз гына суеп чыкты. Шулай да кайсыдыр бер саксызының кылыч кыны йокыдагы каравылчының тимер калканына бәрелеп яңгырады да, әнә шул тавыш икеме-өчме торгакны капылт сикәндерде.

—Әй, нәрсә шалтыратасыз, ни бар анда?—дип сакчылар кулларына кылычларын алып, фетнәчеләргә таба атлый башлаган иде дә, алары да, муеннарына кадалган хәнжәр яраларыннан авыр ыңгырашып, туфрак өстенә ауды. Диварлардан кенәз сараена кадәр булган ара инде ачык иде. Бояр Аверкий Ефрем һәммә фетнәчегә ишетелерлек итеп катгый әйтеп куйды:

—Бетте, туганкайлар. Артка юл бикләнде. Андрей түгел, шайтан үзе каршы килсә дә, чигенү юк инде.

Моны, әлбәттә, һәркем аңлый иде. Беренче кан коелды, фетнә башланды, хәзер инде берчакта да аларны гафу итүче табылмаячак иде. Шуны уйлый-уйлый гыйсъянчылар кылычларын тагын да ныграк кысты, кенәз сараена таба да гайрәтләнеп, сүзсез атладылар.

Сарай ишек төбендә сакчы-мазар юк, ни гаҗәп, хәтта, ишек булып ишек ачык иде. Аверкий бояр ымлавы буенча уннан артык фетнәче сарай тирәли таралып каравылга басты, биш-алты ир кылычларын яуга әзер тотып, эчкә атлады. Эчкә узганнар арасында Хәмбәл дә бар, аны әледән-әле кылыч очы белән төртә-төртә башка ирләр алга әйди иде. Шуңадырмы дәү гәүдәле Хәмбәл адым саен һаман ярсый төшеп, нәфрәтләнеп барды.

Фетнәчеләр коридорда да һичкем булмавына гаҗәпсенгән иде, әмма өч-дүрт адым алда карлыккан тавыш белән берәү телгә килде.

—Кем бар анда? Козьма, әллә син кайттыңмы?

Хәмбәл дә, Хәким һәм аның кияве Петр да тиз таныды. Тавыш иясе һаман да шул, хуҗасына тугры эт сыман бирелгән, Прокопий—җансакчы иде. Бу юлы да коридорга аркылы ятып, кенәзнең ишек төбен саклый икән, мескен. Ул аягына күтәрелеп өлгерсә дә, үзенең муенына килеп ябышкан аюдай Хәмбәлнең көченә каршы тора алмады. Ишек төбен саклаучы «эт» картайган һәм аның тәненнән гайрәт киткән иде шул инде. Ләкин соңгы минутында бер мизгелгә булса да катил кулыннан ычкынып ул, барыбер, коридорга сөрән салып алды.

—Кенәз! Ке-нәз!

Икенче мизгелдә исә Хәмбәл янә аны тимердәй кыскычлары белән китереп буды, бугаз кимерчәкләренең шытырдап сынганы яңгырап ишетелде. Ул арада инде Андрейның ятагы да нык шыгырдап алды.

—Кем ул анда?

Һәммә ирләр баш түбәләренә күсәк килеп төшкән сыман идәнгә тез чүктеләр. Тын алулар ишетелмәс булды. Ярый әле беренче булып Петр айный алды.

—Пр-ро-ко-пий.

Петрның тавышы төнге тынлыкта хәтәр яңгыраса да нык калтырап чыкты һәм моны Андрей кенәз тиз аерып өлгерде. Ишек аша дәшкән тавышы зәһәр усал иде.

—Юк, Прокопий түгел, Алдама, эт!

Фетнәчеләр искә-аңга килде. Яшеренеп, юхаланып маташуның файдасы юк иде. Котырынып бүлмә ишегенә тибә башладылар. Ләкин имән ишек такталары ныклы, калын, алар аннан-моннан гына тибүләргә һич бирешми иде. Бүлмә эчендә Андрей да мәлҗерәп тормады. Ул яшь, гайрәтле вакытындагы житезлек белән бүлмә түренә ыргылды, ашыга-кабалана мич буендагы стенаны тиз-тиз капшап чыкты. Бүрәнәләрдәге тимер элмәкләрнең барчасы да үз урынында, ә хәнжәре белән изге Бористан истәлек булып калган кадерле кылычыннан жилләр искән иде. Андрей авыр сыкрап куллары белән башын кочаклады.

—Ах, син, хыянәтче хатын!

Шул минутта имән ишек күгәненнән каерылып очты. Дәбер-шатыр килеп бүлмәгә ирләр атылып керде һәм икесе шундук Андрейның бугазына барып ябышты. Башкалары дөп-дөп китереп кенәзнең башын, сыртын, кабыргаларын төя башлады. Жиденче дистәсе белән барган, шактый кипшенә төшкән Андрейга яшьлектәге гайрәте-куәте кайтты диярсең. Авыр гыжласа да, әүвәл бер дошманын тез астына бөгеп салды, аннан икенчесен мич арасына селтәп очырды. Бүлмәгә кергән ирләр бишәүалтау, алар карангыда бер-берсен аермый иде, күрәсең. Арадан кайсыдыр берсе икенчесенә хәнҗәр белән кат-кат чәнчеп алды.

—Мин үзебезнеке лә. Архип, Архип бит мин,—дип, теге бичара яман ыңгырашып идәнгә аугач кына, һәммәсе дә акылына килде. Аларның күзләре карангылыкка ияләнә башлаган иде инде. Кылычларын, хәнҗәрләрен сузып, кенәз өстенә ябырылдылар. Хәнҗәр-кылыч очлары Андрейның гәүдәсен дистәләгән урыннан тишкәләде, сөякләренә кадалып чыкырдады. Кенәз инде канга батып беткән, ә үзе һаман аумый, мәгърур имән сыман селкенми дә аягүрә басып тора иде. Житмәсә, ул әле гыжылдаган, усал тавыш белән сөйләнә дә башлады.

—Минем нинди явызлыгым тиде сезгә? Нигә канымны коясыз? Мин сезнең һәммәгезгә дә икмәк ашатучы бит.

Тагын кемдер аңа хәнҗәр кадап алды. Андрей инде сүгенүгә күчте.

—Ходай Тәгалә минем өчен барыбер үч алачак. Ләгънәт, ләгънәт сезгә, хәшәрәтләр!

Фетнәчеләр ярсып-котырынып тагын берничә мәртәбә хәнҗәркылычларын Андрейның тәненә батырды. Кенәз, ниһаять, яман гыжлап идән өстенә ауды. Гыйсъянчылар аны дөмекте, дип уйлады, күрәсең. Читтә авыр ыңгырашып яткан Архипны кулларына күтәрделәр дә, ашыгакаударлана коридорга чыгып йөгерделәр.

—Бер-ике мизгел узуга ук Андрей аңга килде. Ах-вах килеп ыңгыраша-сызлана гына аякларына күтәрелде һәм бүлмәсеннән чыгып, икенче катка алып менә торган баскычка таба дөп-дөп атлап китте. Аның тавышы катилләрне янә тукталырга мәҗбүр итте. Ыргыла-бәрелә кабат кенәз бүлмәсенә әйләнеп кайттылар. Андрейны тапмагач һәммәсен дә хәвеф биләп алды.

—Инде дөмеккән сыман иде бит, кая киткән соң бу?

—Әгәр кенәзне качырсак, безнең башлар бетте.

—Нигә сөйләнеп торабыз соң? Әйдә, тизрәк эзлик.

Ниндидер шәм кисәге табып шуны кабыздылар. Идәндә кан таплары ярылып ята иде. Шулар эзеннән барып баскыч буена життеләр. Андрей кенәз баскыч басмалары астында посып утыра иде. Катилләрдән йөзен капламакчы булып ул уң кулын югары күтәрде. Ләкин шул минутта ук Петр яман селтәнде дә, шушы сынар кулны капылт чабып өзде. Андрейның инде куәте-җегәре гел калмаган иде.

—Җанымны синең кулларына тапшырам, йә, Ходаем!—дип авыр ыңгырашты да тынды.

Катилләр ул төнне сарайны ашыга-кабалана ташлап китсәләр дә, һичбер төрле чаң сугу, ыгы-зыгы булмагач, таң атуга янә бергә җыйналдылар. Алар нык кызмача, шуңа батыр иде. Әүвәл сарай эченә узып кенәз сандыгын эзләп таптылар. Андагы барча энҗе-мәрҗән, алтынкөмешне аерым бер арбага бушатып, Владимир каласына озаттылар. Аннары кенәзнең шәраб келәтенә үтеп, янә тантанага бирелделәр.

Кояш шактый гына югары күтәрелгәч кенәз сараена Козьма кайтып керде. Кичә аны Байгөл Боголюбоводан Владимирга җибәргән, ә таң атканда кала хәвефле хәбәр белән тулган иде инде. Башын түбән иеп, кайгыдан кара көеп кайткан хезмәтче сарай янында торучы кешеләрдән тик бер генә әйбер турында сорады:

—Кенәз кайда ята?

—Этләргә ризык булсын, дип катилләр аны яшелчә бакчасына

чыгарып ташлады. Янына барасы булма. Катилләр кенәзгә хәерхаһ кешенең үзен дә дөмектерәбез, дип, кат-кат янадылар.

Козьма ике дә уйлап тормады, төп-төз адымнар белән бакчага кереп китте. Туфрак-ләм белән укмашып беткән Андрейның җәсәде жирдә ауный, муенын-янакларын чебен сарган иде. Козьма аның каршына килеп тезләнүгә үк елый башлады.

—Их, газиз кенәзкәем! Элек көчле иденң, сизгер идең бит син. Ә бу юлы янына катилләр, җәлладлар килүен нишләп сизмәдең соң? Эх, нигә генә диеп кичә сине ташлап киттем икән?..

Берзаманны бакчага Хәмбәл килеп керде. Нурсыз да, мәгънәсез дә караш белән текәлеп озак карап торды. Козьма ничарадан бичара рәвештә шуңа сүз катты.

—Анбал, хәерсез җан! Хуҗабызның гәүдәсен берәр әйбер белән капларга иде бит. Келәмме, япмамы, тәрәзәдән шуның берсен ташла.

Хәмбәлнең җавабы күзләре сыман ук нурсыз, салкын чыкты.

—Без аны этләргә ташладык. Югал моннан!

—Ах, син, хайван!—дип, Козьма үзен-үзе белештермичә кычкырып ук җибәрде.—Кенәзне этләргәме? Ә син хәтерлисеңме соң, хәерсез? Аның алдына килеп тезләнгән чакта синең өстеңдә юньле кием дә юк, син шыр кылкадан гына хасил идең бит. Хәзер, әнә, син бәрхеткә төренгәнсен, ә кенәз шәрә ята. Этҗан булма. Бар, зинһар, ни булса да ташла.

Үткәнен, мескен чагын исенә төшерү Хәмбәлне сындырды. Ул тиздән Андрей кенәз җеназасы өстенә бер келәм белән юрган аламасы чыгарып ташлады. Шуларга төреп һәм иңбашына күтәреп Козьма мәетне бистә чиркәвенә илткән иде, катилләрнең үч алуыннан шүрләп анда да кертмәделәр. Ике көн, ике төн буена Козьма кичәге хаким гәүдәсен утын сараенда саклап чыкты. Ул арада катилләр кенәзнең каладагы сараен «чишендерергә» дип, Владимирга ук китеп барган, ә анда исә бөтен кала буенча Андрей туганнарының, боярларның йортларын тоташ талау башланган икән инде. Өченче көнне генә Андрейның җеназасын чиркәүгә кертеп табутка салдылар. Җиденче көндә кенәз мәетен Владимир каласына алып киттеләр дә, Изге Ана чиркәве зиратында, ниһаять, качып-посып җиргә иңдерделәр. Бөек кенәз кылган эшләрне искә алып сөйләүче һичкем табылмады.

## 4

Атна-ун көн үтте, ә катилләрне эзләүче, аларга кагылучы кеше һаман күренмәде. Гаҗәеп, коточкыч хәл: Владимир-Суздаль җирендә катилләр кайгысы түгел, кенәзлекне һәм Андрей мәрхүмнең барча туган-тумачасын тик бер генә хафа—тәхет чире генә биләп алган иде.

Бушап калган тәхеткә дәгъва кылучылар бик тиз һәм күп табылды. Владимир-Суздаль җирендә бөек кенәз булып күтәрелүгә Андрейның әлегәчә исән туганнары—Юрий Долгорук уллары—Святослав, Михаил, Всеволод кына түгел, бактың исә күптән вафат Мстислав һәм Ростиславтан калып, инде үсеп житкән, башка вак кала хуҗалары булып утырган Ярослав, Мстислав белән Ярополк та бик лаек икән бит. Биләмә боярлары, эре сәүдәгәрләр, воевода һәм тиуннар, алар гына да түгел, инде җыен эте-бете менә шушы исемнәр тирәсендә сүз куертты, ызгышты, тәпәләште, пычакка-пычак килде. Фәкать бер дәгъвачы, иң-иң канунлысы—Андрей кенәзнең исән калган бердәнбер улы, унҗиде яшьлек Григорийның исемен генә ялгыш та телгә алмадылар.

Тәхет тирәсендәге мәхшәргә, иң беренче булып, Владимир халкы үзе оеткы салды. Гәрчә кала халкы әле Юрий Долгорукның үз каршында ук тәхеткә аның иң төпчек уллары Михаил белән Всеволодны утыртырга ант иткән булса да, моннан егерме ел чамасы элек үк Андрейга юл куеп, вәгъдәсен беренче кат бозды. Шуннан соң инде хыянәткә юл ачылган

иде, Андрей вафатыннан соң да моннан бик житез файдаландылар. Рязань илчеләре коткысына бирелеп алар, иң әүвәл, Ростислав уллары булган Мстислав белән Ярополкны тәхеткә чакырып чапкыннар юллады. Тегеләр Мәскәүдә тукталып һәм «булачак» тәхетне юа-юа типтереп яткан чакта Владимир капкасы төбенә Андрейның энекәше Михаил килеп житте. Хәзер инде владимирлылар яна хыянәт юлына басты һәм Михаилны эчкә уздырды. Муромлылар белән рязаньлыларны ияртеп капка төбенә Мстислав һәм Ярополк килгәч, владимирлылар аларга баш иярга теләмәде. Ике арадагы кан коюлы сугыш жиде атна барды, илле көн (!) буена жир инрәп һәм янадан-яна мәетләр өеме белән сугарылып торды.

Ниһаять, илленче көндә Михаил акылына килде дә, тәхетенә, дөньясына төкереп, башка кенәзлеккә чыгып китте. Владимир тәхетенә Ярополк менде, Мстиславы Ростовка ризалашты. Әмма беркадәр вакыт узгач, владимирлыларны боярлар кубызына биеп утыручы Ярополк та туйдырды. Аның арт ягына тибеп, владимирлылар тәхеткә янә Михаилны дәште. Михаилның юлга чыгуын ишеткәч, Ростовтагы Мстислав әтәч сыман ярсып, ияр өстенә менде. Ике гаскәр Владимирдан биш чакрым ераклыкта канлы яуга керде. Владимирлылар моны кала диварлары өстеннән генә күзәттеләр. Тагын яна хыянәт әзерләнә: кем өстен чыга, калага шул керәчәк иде. Бу юлы Ходай үзе ярдәм итте бугай—Михаил жинде һәм тәхеткә узды.

Менә шуннан соң гына Владимирда, ниһаять, Андрей кенәзнең жанын кыючыларны искә төшерделәр. Яна хакимнең хөкеме аяусыз, карары корыч булды:

—Фетнәчеләр ягына авышып иренә хыянәт иткән Байгөл-Василисаны мичкәгә томалап күлгә ыргытырга!

—Кенәз куенында жылынып еланга әверелгән килмешәк Анбал Ясинны сарай капкасы каршында бер йөз ук атып теткәләп бетерергә!

—Фетнәдә катнашкан башка катилләрнең барысын да дар агачларына асып үтерергә!

Хөкем карары тормышка ашырылганнан соң, ни өчендер Андрейның бердәнбер улын бик тә, бик тә тырышып эзләделәр. Әмма Григорий печән кибәнендәге энә сыман юкка чыккан иде.

## Уналтынчы бәйләм

### 1

Андрей Боголюбның вафаты турында хәбәр алгач, Ибраһим хан әүвәл ни уйларга да белми аптырап калды. Урыс кенәзе никадәр генә явыз булмасын, мәгәр аның катилләр кулыннан жан бирүе—ул дошманына да теләми торган аяныч бер үлем һәм, кеше буларак, хәтта, кызгандыра да иде.

Аннары инде рус жиреннән шактый сәер хәбәрләр агыла башлады.

—Владимирда тәхет өчен үзара яу башланган. Андрейның энесе Михаилга каршы Мстислав илә Ярополк атлы жигәннәре пычакка-пычак килеп кан коешалар, ди. Ә ул Мстислав белән Ярополк Рязань кенәзенә кайнешләр тиеш, жизнәләре исә аларны котыртып-өстереп ята, корал, алайлар белән дә ярдәм итә икән.

Болары инде көндәш ил башлыгының күңеленә сары май булып ята торган хәбәрләр иде. Чөнки Ибраһим хан Владимир-Суздаль кенәзлегенең соңгы елларда нәсел үгезе сыман ныгый, көрәя баруын да, аның инде аранына гына сыймыйча, сикереп чыгып, чит-ятларны сөзә башлаячагын да тоеп-сизеп торды. Рязаньлыларның каршы чыгуы, алай гына да түгел, хәтта, инде күсәк күтәреп дөмбәсли башлавы Владимир кенәзлегенең хәлсезләнүенә китерәсен Ибраһим хан аңлый һәм мондый

ызгыш-талашны, әлбәттә, яклый гына иде. Мондый чакта аның әле көйсез ир белән хатын якалашканда койма ярыгына капланган күршеләр сыман гади күзәтүче генә булып каласы да килмәде, пыскый башлаган учакка ул үз куллары белән куз һәм дары өстәмәкче булды. Шул максат белән якын-тирәдәге бәк һәм тарханнарга ашыгыч фәрман куды.

—Артык вә кирәксез булган коралларны ни тиклем җыя аласыз, җәмгысын да Ага-Базар эргәсенә бик тиз китерегез.

Һичкемне кисәтми-нитмичә Ибраһим хан үзе юлга җыена башлады. Дистәгә якын корабка ашлык тутырттырды, хәзинәдән кадак-кадак алтын-көмеш, энҗе-мәрҗән алды. Инде һәммәсе дә әзер булып үзен озата барачак менлек белән яраннары ачыклангач кына бертуган энесе әмир Хәсәнне янына дәштереп алды.

—Рәзән кенәзе Глеб янына кунакка барамыз, юлга җыен.

Әмир Хәсән аяз көнне яңгыраган күк күкрәве сыман көтелмәгән һәм дорфа сорау бирде:

—Нием калган анда?

—Мин калган, мин—Бөек Болгар ханы.

—Ә-ә, Чатыртауга биргесез олуг байлык икән. Бармый булмас инде...

Ибраһим хан белән әмир Хәсән соңгы берничә ел буена шул рәвешчә чеметешеп яши. Әмир Хәсән әле малай-шалай, яшүсмер генә чагында бу кадәр үк телле түгел иде. Соңгы вакытларда, менә, гел азау тешен күрсәтә башлады, абыйсының бер генә фәрманын да күндәмлек һәм итәгать белән кабул иткәне юк. Ибраһим хан, әлбәттә, барысын да ишетеп, белеп тора. Әмир Хәсәнне ханның баш вәзире булган Мәрчура котырта. Егетләр яше белән генә барган әмир күнеленә хөсетлек, үч, мәкер орлыкларын чәчеп шул агулый. Билгеле, Ибраһим хан Мәрчураны инде күптән илдән куа да, дарга аса да алган булыр иде. Ләкин энекәшенең кешелеге, табигате сазда үскән усак үзәге сыман үзе черек икән, аңа йөгән кидерүче бәндә барыбер табылачак бит. Менә ни сәбәпле Ибраһим хан Хәсәнне Биләр каласында, тәхет эргәсендә калдырып китә алмый. Гәрчә аның белән бер корабта йөзеп, бер казаннан ашау күңелле булмаса да, җан тынычлыгы хакына ул энесен үзе белән ала.

Ә мәркәздә, әйдә, Сәлим идарә итә торсын. Ул унбиш яшендә, әлбәттә, малай-шалай гына әле. Мәгәр Ибраһим хан аның янында инде чал сакалга чумган сәрдәрен, меңәрләгән сынауларны узган тугры юлбарысны—Корнай батырны калдыра бит. Шулай булгач, аның улы Сәлим шаһзадә өчен пайтәхеттә хәвеф тумаячак. Хәвеф дигәннәренең юлда Ибраһим ханның үз алдына килеп басуы мөмкин. Чөнки Рязань кенәзлегенә ханның сак башлыгы булып Тургай, Корнай улы, бара. Ул да әле бик яшь, егермесе дә тулмаган. Әлеге поход—аңа ышанып тапшырылган иң беренче зур эш. Әмма Ибраһим ханның шушындый адымнарга бармый башка чарасы юк. Сәлим, Тургай ише яшьләрне дә, корыч кылыч хәзерләгәндәге сыман итеп, әле утка, әле суга тыгып чыныктырасы, сыныйсы, үстерәсе бар бит.

## 2

Йөкчеләр иңендәге капчыкларда тоташ ташкын булып агылган гәрәбәдәй ашлыкны, кораблардан чыгарылып Ука ярына тау-тау өелгән көбә, очлым, айбалта, сөңге, ятаганнарны күргәч, Рязань кенәзе Глеб шатлыгыннан чак-чак кына биеп җибәрмәде.

—Миңа корал-шайман кирәклеген каян белдең, күрше?—дип ул әледән-әле Ибраһим ханны иңнәреннән кочып алудан да тыелып калалмады, уйларын-ниятләрен дә капылт ачып салды.—Мин каенэнекәшләремнең берәрсен Владимир каласына утыртмыйча торып һич тыначак түгел. Андрей үзе һәм аның яклылар Владимир тәхетен егерме ел буена

имде инде. Житәр! Болай булгач, мин ул Андрей-этжаннын энекәшләре Михаил белән Всеволодның тетмәләрен тетәм!..

Ука ярына тезелеп үзен каршылаучы боярлар арасында инде күптән мәрхүм булган Бәрәж ханның улы Чилбир бәкне күргәч, Ибраһим хан имәнеп үк китте. «Атасы Бәрәж вафатыннан соң үк юкка чыккан иде, менә кайда сыену тапкан икән, кара син аны! Урыс икмәген ашап, кяфер көйләренә бии торгач кемгә әверелгәнсендер, анысын чамалармыз». Әмма боярлар белән куллар бирешә-бирешә күрешкән чакта чират ана житкәч, Ибраһим хан күнелендәге шикләрен Чилбир бәкнең үзенә һич тә сиздермәде.

—О-о, минем карендәш менә кайда икән бит, ә без сине югалттык,— диде дә, Ибраһим хан аны, хәтта, кочагына кысты һәм һич тә көтелмәгән сүзләр тезеп салды.—Сабы сынган балта сыман теләсә кайда аунап йөрмә инде син. Болгарың, халкың бар бит, туган өенә кайт.

Кенәз сараена кайткач, Глеб, каланың ин күренекле боярларын жыеп, олы кунак хөрмәтенә тәүге мәжлес ясады. Хан кадәр хан кунак булып гади кенәз йортына көн дә килми. Ибраһим ханның кунакка төшүе үзенә ялгыш кына тәтегән олы бәхет булуын Глеб нык чамалый һәм, әлбәттә, моны бөтен кенәзлекләргә, барча рус халкына белдертү өчен жаны-тәне белән кыбырсына иде.

Түрдәге өстәл янына килеп утыргач та, өстенә чәчәкле киң сарафан кигән, мангаена энже-мәржән белән бизәлгән кәккүш-калфак элгән аксыл чәчле кызны күреп Ибраһим ханның эченә ут йөгерде. Кызый шактый йомры гәүдәле, мул күкрәкле. Бит очлары пешкән алма сыман алсуланып тора. Кашлар карлыгач канаты шикелле тигез сызылып киткән. Озын, куе керфекләре арасында нәни йолдыз булып терекөмеш сыман елгыр, шаян күзләр елтырый.

Ханның төп юлйөртүчесе булып килгән һәм колакларын шомрайтып утырган сәүдәгәрләр башлыгы Иркәнәш би өстәл артындагы күз атыш уенын бик тиз сизде бугай, үзеннән аныклык кертүне кирәк тапты.

—Глеб кенәзнең өлкән кызы Вышелюба бу. Сазаган кыз булса да, бер яучыны да үзенә якын жибәрми, бик көрпәле, бер саплам да жылы сүз әйтә белми, диләр.

Ибраһим хан үзен беркадәр уңайсызрак хәлдә тойса да жавап бирми калмады.

—Жайдаклары жебегән туры килгәндер. Юньле жайдак булса, әллә нинди чыгымчы биягә дә авызлык кидерә белер иде...

Кунаклар шактый кызып уен-жыр башлагач, шушы Вышелюба гел Ибраһим хан каршына килеп кәс-кәс биеде, шул адымы белән зур кунакны шабыр тиргә салды. Ибраһим хан өстәл артыннан сикереп чыгып яшьләргә кушылудан чак тыелып утырды. Ул ханлыгына, дәрәжәсенә, гайбәтенә дә төкереп бирер иде. Аның кадакланган сыман итеп урынында үзенең яше, олылыгы тотты. Ибраһим гомер буе тәз һәм озын буйлы, чандыр гәүдәле, бакыр сыман, кояшта янган йөзле, чаларуны белмәс дегет чәчле булды. Шуңа күрә аның төгәл яшен чамалый алмыйча күпләр алданды. Ә ул хәзер алтынчы дистәне кырлап бара бит инде, әйтергә генә ансат...

Кунакны төрледән-төрле теләкләр юллый-юллый сыйлау дәвам иткәч, Вышелюба Ибраһим ханга шәраб белән мөлдерәмә тулы кубок китереп бирде. Шулчагында Ибраһим хан аның кулларына кагылды, башы әйләнеп китте. Кызның куллары песиле тал бөресе кебек йомшак, шома, үз гомерендә таш чыгарудан, кылыч селтәүдән, калалар төзүдән башканы белмәгән ханның мондый нәфислекне татыганы, күргәне юк иде. Мәжлес тәмамланып түшәккә егылгач та, Ибраһим хан төн буена шушы йомшак, назлы куллар белән саташып чыкты. Аның өчен жиһанда шул нәфис куллардан, кәккүш-калфак кигән мул имчәкле кыздан да кадерлерәк, затлырак байлык калмаган иде инде.

Икенче көнне түшәктән баш калкытырга да өлгерә алмадылар,

инде кенәз үзе кереп, табын артына дәште. Бу юлы Глеб туарылган, хәзер инде сый-нигъмәт татырга дип боярларны гына түгел, ә каланың иң бай сәүдәгәрләрен, һөнәр осталарын, дружинасындагы йөзбашларны—берсен-бер калдырмыйча кунакка алган иде. Ибраһим хан менә шунда, өч йөздән артык рязаньлы каршында, Глеб кенәзнең күнелен күрмәкче, хужа кешене зурламакчы булды. Өстәл артына инеп беркадәр утыргач та, ул үзенең урыныннан торып басты, бармак шартлатып кына махсус фәрман бирде. Шул минутта ук залга кулларына көмеш тәпсиләр тоткан сугышчылар керә башлады. Тәпсиләрнең берсендә көмеш тәнкәләр өеме ялтыраса, икенчесе алтын белән тулы, ә берсеннән-берсе мәһабәтрәк һәм сылурак сугышчылар чылбыры биек тау итәгендә бәреп чыккан чишмә суы сыман мәңге бетмәс шикелле тоела иде. Сугышчыларның кергән берсе тәпсиләрне Глеб кенәз өстәленә тезә барды һәм берзаманны, инде анысы тулгач, Ибраһим хан бүләкләре башка өстәлләргә дә күчә башлады. Шулай да, ниһаять, дусларда аяк ялына дип бирелә торган иң соңгы һәм иң татлы шәраб сурәтендә залга энҗе-мәрҗәннәр, якут асылташлар белән тулы берничә тәпси керде. Асылташларның күз явын алып елкылдавын күргәч, залдагы өч йөз кунакның һәркайсы авызларын ачып торып басты. Менә шулчагында инде Ибраһим хан үзе телгә килде:

—Рәзәнлеләр, хөрмәтле дустларым, күршеләрем минем! Без сезнең хозурга иң эчкерсез хисләр белән кунак булып килдек. Без сезнең белән ут күршеләр булып яшәсәк тә, үтә дә сирәк вә ни үкенеч, орыш мәйданында гына очрашамыз. Вәләкин ошбу җиһанда кияү-кәләш алмашып, кода-кодача булып, кунакларга барышып яшәү кулайрак булыр иде. Менә бит, күреп торасыз, улчагында бүләге дә мулдан, сый-нигъмәте дә татлы, затлы була. Шулай икән, әйдәгез, ошбу дөньяда туган-тумача, кода-кодача булып яшик. Ә сезгә бөтен урыс мәмләкәтенең тоткасы вә күчәре булып яшәргә язсын, амин!

Глеб кенәз әле залга кертелгән алтын-көмеш тәпсиләрне күргәч тә бизгәк тоткан сырхау шикелле дулкынлана-калтырый башлаган иде. Ибраһим ханның эчкерсез һәм кайнар булып яңгыраган мөрәҗәгатен дә ишеткәч, хужа кешенең күзләреннән инде яшь тамчылары ук бәреп чыкты. Ул яңа кымыз сыман уйнаклаган хисләрен тыеп кала алмыйча, атылып килеп, Ибраһим ханны кочагына кысты, сүзләрен дә бөтен залга ишетелерлек итеп әйтте:

—Ә нигә озакка сузарга да, үзебездән башламаска әле, Ибраһим хан? Әйдә, минем өлкән кызым Вышелюбаны син үзеңә хатынлыкка ал да, без туганнар һәм бер-беребезгә ныклы терәк булыйк.

Ибраһим хан сөенечтән бугазына килеп утырган төенне дә йота алмый торды. Ул Глеб кенәздән чиксез рәхмәт, кайнар вәгъдә сүзләрен дә көтә, күңелендә тышауларын өзеп качарга ашкынган тулпар шикелле ярсу хыял да бар, әмма хужа кеше нәкъ менә шул өмет-хыялкайны йөзләгән рязаньлылар каршында ярып салыр, дип һич гоманламый иде.

—Кызың безнең дингә күчәр микән, кенәз? Шундый шартым бар бит...—диде ул дулкынланып.

Глеб кенәз өчен бу колак ишетмәгән яңалык түгел иде, җавабын тиз тапты.

—Күчәр, күчәр, сезнең дингә дә күчәр. Озата килүчеләрең арасында муллаң да бар иде кебек. Шуны чакыр да, әйдә, кызны әфсенләсен.

Ә бераздан Глеб кенәз бөтен зал өстенә ярып салды.

—Минем яңа кияү өчен тост тәкъдим итәм! Ибраһим хан өчен!

### 3

Сыерлар атавына кайтып житкән чакта Ибраһим ханны болгар һәм биләрлеләрнең гаҗәеп зур флотилиясе каршы алды. Йөзәрләгән каек һәм көймәләр, әйтерсең лә, Иделнең билен буып алган,

ханның кайту юлын тоташ бикләгәннәр. Нәкъ уртада торган олы баркас сәхнәсенә Сәлим чыгып баскан. Бертуктамый җилфердәгән хан әләме астында көмеш көбәгә төренгән көе кукраеп торса да, елмаюдан җәелеп китәргә ымсынган авызын көч-хәл белән тыя. Ибраһим хан улының канәгать йөзенә караш ташлады да, ирексездән, күңеленнән генә, сүгенеп үк куйды. «Тәхет ташлап йөрүләрнең нинди хәвеф-каза тудырырга мөмкин икәнен белмисең шул әле син, шалпавыз! Әле ярый атаң тинтәк түгел, ул сине чукырдай җәмгы көндәшләрне үзе илә йөртә».

Ибраһим хан үзе баскан кораб сәхнәсеннән артка карап алды. Әнә, күмер сыман кара көеп чыккан әмир Хәсән уртын чәйни-чәйни ялгыз басып тора. Әнә, корабның икенче ягында Чилбир бәк үзенең улы Газины алдына кочып баскан. Чилбирның керфекләрен беркадәр кыса төшеп төбәлгән карашыннан ниндидер өметсезлек һәм шикләнү саркыла кебек. Ул юлга кузгалыр алдыннан Ибраһим хан янына үзе килде. Соравында ук икеләнү-шомлану чагыла иде.

—Син мине теге чакта уйнап, күңелне кытыклау өчен генә чакырдыңмы, әллә Болгар җиренә кайтырга чынлап торып рөхсәт итәсеңме?

Ибраһим хан аны-моны уйламый җавап бирде:

—Кайт, әлбәттә. Ихлас чакырам мин. Мәмләкәтемез иркен, ә син үги түгел. Гыйдайлыкта гомер кичерүче сыңар углына гына, мөгаен дә, җылы почмак табар.—Аннары өстәде:—Нур-Сувар каласы гомер бакый сезнең нәселнең биләмәсе булды. Атаң кеби гыйсъянлык яисә катиллек юлына басмыйсың икән, иншалла, ул биләмә тора-бара янә синеке булыр. Шаять, ризасыңдыр?

—Риза, риза... Рәхмәт!

Чилбир ул вакытта шул рәвешчә корабка ингән иде. Ә күңеле барыбер тыныч түгел, күрәсең. Әнә бит, хәзер карашындагы шикләнү хисләрен дә яшерә алмый, җитмәсә әле сабый улын да, оясын тилгәннән сакларга җыенган ата каз шикелле, ике кулы белән каплап баскан. Шулай, илдән аерылып чит табактан ашау, кыек юлда йөрү шөбһәле, сак кешегә әвереллдерә инде ул.

Ибраһим хан тагын бер мәртәбә Сәлим тарафына караш ташлады да йөрәге сызып куйды. «Көтүдәге айгыр шикелле, бүреләр тешеннән әлегә үзем саклыйм. Мәгәр көтмәгәндә мәңгелеккә күчсәм, ул әрсез бүреләр өеренннән ничек сакланырсың?..»

Каршы алучылар нәкъ Богылтау каршына килеп Идел буган иде. Ибраһим хан текә тау тирәли тезелеп киткән бүрәнә диварларга таба текәлде дә, бермәл уйга калып торды. Бу кальганы халык «Богылтау» дип тә, «Өчиле» дип тә йөртә. Хатирәләргә баксаң, ана Тимер Мөэмин хан моннан йөз дә җитмеш—йөз дә сиксән еллар элек нигез салган инде. Мәгәр юл унаенда бик тә җайлы булып утырганга күрә аны урысларның ушкуйлары да, яу гаскәрләре дә гел-гел талап торган. Әле, әнә, Болгарга ясаган беренче походы вакытында аны Андрей кенәз дә тоташ яндырып үтте. Менә шул сәбәпле бер дә мантый, ныгып китә алмый бу Богылтау дигәннәре. Ә мәмләкәт хуҗасының күзләре белән баксаң, бер генә дошманга да биргесез кальга—корыч калкан төзеп кую өчен менә дигән урын лабаса. Бер ягыннан аны Идел саклый, икенче яктан—инеш. Кальга артында әле тагын бер-бер артлы тезелешеп киткән дистәләп күлләр бар. Тавы биек, текә. Көнбатыш якта төбе күренмәс ерым. Дошман тигез яланнар, зәңгәр елга-күлләр уртасында түбәтәй шикелле калкып торган әлеге тауга якын килү өчен генә дә күпме интегәчәк, никадәр кан коячак? Гади кальга гына түгел, мәркәзнең үзен дә төзеп куярлык бит монда! Нишләп мона тикле ошбу төшне игътибарсызнисез калдырган ул?..

—Әйдә, Богылтауга таба борылыгыз, туй итәмез!—дип, Ибраһим хан оран салуга ук Идел өстендәге йөзәрләгән каек-көймә текә яр буена ябырылды. Абыстайдагы күңел көрлеге, шатлык әмир Хәсәннең үтен сытты бугай, аның майсыз арба күчәре шыгырдаган сыман сыкрап һәм

үртәлеп мыгырдаган тавышы ишетелде.

—Уен-муен түгел, картаеп беткән хан кяфер бичәсе алып кайта бит. Әйдә, кышкы утардан соң япан кырга чыгарылган язгы бозау кеби кушаяклап сикер, бие, шашын, бөек Болгар халкы! Иртәгә олуг хан синең үзенне дә кяфер ясап куймагае!

Уртларын шыгырдатырга мәҗбүр булса да, Ибраһим хан дәшми калды, түзде. Энекәше көнләшүдән тиресенә сыймый икән, ни хәл итмәк кирәк? Арттан өреп калучы һәрбер көчек саен тукталып, аңа таш ыргытып вакыт дигән алтынкайны юкка-барга сарыф итеп булмас...

Богылтау өстенә менгәч, Вышелюбаны житәкләгән көе Ибраһим хан бөтен тирә-юньне дикъкать белән янә карап чыкты, үтә канәгать калды. Алар кабат әйләнеп кайткан чакта текә яр өстенә иркен чатыр корылган, ханның яраннары хәзер учак тергезү, казан асу белән мәшгуль иде. Шулчагында хан чатыры янындагы алтын казаннарның берсен эләктереп, Вышелюба телгә килде.

—Хан табыны өчен су алырга үзем барыйм әле.

Сөенеченнән гүзәл җәйрән сыман сикергәләп йөргән ханбикәне барчасы да елмаеп һәм хуплап озата калды. Хан чатыры янына Богылтау кальгасының башлыгы булып торган Илтимер би дә чакырылган иде. Шул Ибраһим ханга бик тә сәер риваять тезеп салды.

—Ошбу тауда элек заманнарда явыз бер аждаһа яшәгән, еланнар мыжгып торган, диләр. Әүвәл шуларны, кура яндырып, моннан куганнар, ди. Аннары гына яңа кирмән төзү мәшәкатенә керешкәннәр. Тимер Мөэмин хан ошбу гамәлгә үзенең улы Нургали шаһзадәне тәгаенләгән булган. Мәгәренки шаһзадәнең үзеннән яшереп кенә аның яраннарына яшерен фәрман да түндергән. «Кирмән нигезенә корбан китерегез. Чишмә бәреп чыккан урынга тәүге инсан булып кем килә, шуны корбан итегез. Шунсыз ошбу кирмән күкрәп үсүгә мәңге ирешмәстер». Азатлар менә шушы инеш ягында, текә тау эргәсендә туфрак казыганнар. Чишмә бәреп чыккан. Вәләкин берзаманны, иң тәүге инсан булып, чишмә хозурына Нургали килеп житкән. Әлбәттә, азатлар шаһзадәне корбан кылырга үтә кызганганнар. Аның урынына бер этне корбан кылып, кирмән нигезенә индергәннәр. Шул хакта ханга хәбәр иткәч, ул яман дулаган да, шундый фараз әйткән: «Ошбу кирмән киләчәктә этләр кулына эләгәчәк икән».

Күңелсез риваятьтән соң, Ибраһим хан әсәренеп, агарынып калды, йөзеннән нур качты. Мәет озаткан шикелле, уйга чумып, озак утырдылар. Бераздан соң гына Илтимер би үзенең хикәятен очлап куйды.

—Байтак гомер үтте, мәгәренки кирмәннең этләр кулына калганы юк әле. Шөкер, бүгенгәчә аңа үземез хуҗамыз... Ә шаһзадәне халык һич тә онытмаган. Инеш эргәсендәге чишмәне ул әле булса Нургали чишмәсе, дип атап йөртә.

Шулчагында тау битеннән аста, инеш ярында Вышелюбаның ачыргаланып-инәлеп кычкырган тавышы ишетелде:

—Казан, казаным! Алтын казанкаем!

Хәвефләнеп һәммәсе дә чатырдан атылып чыкты. Вышелюба кулларын чәбәкли-чәбәкли инеш яры буенча сикергәләп йөри, үзе яшь аралаш гел тәкърарлый иде:

—Алтын казаным төпкә төшеп китте. Казан, казанкаем!

Ибраһим хан чын-чынлап, җаны-тәне белән өзгәләнгән Вышелюбаның сабый бала сыман сикергәләп йөрүенә мөкиббән китеп торды-торды да, бөтен Богылтау өстен яңгыратып көлә башлады.

—Мин сиңа тагын бер казан бирәм. Әйдә, анысын да су төбенә төшереп җибәр дә, янә бие әле.

Вышелюба иреннәрен турсайтты, чынлап үпкәләде. Ул үпкәләсә дә гүзәл, ә олыгайган хан шундый байлыкка ия булуы белән үк бик бәхетле иде.

... Икенче көнне песи баласы кебек иркәләнеп, тартылып-сузылып

кына кояш күтәрелде, ал тан атты. Азатлар, газиләр хакимне каршыларга дип сафка тезелгән чакта ханның өр-яңа фәрманы инде әзер иде:

—Богылтау кальгасы урынына ак ташларга төреп, яңа кирмән нигезләргә, кала тергезергә. Ошбу гамәл хакына бөтен Болгар мәмләкәтеннән мөһәндисләр илә бер мең тиклем ташчыларны, мигъмарларны, сәүдә осталарын чакырып китерергә. Кирмән-кала төзү вазифасы мәмләкәтемезнең олуг бәге—әмир Хәсән җәнабларына индерелә. Бер йөз азат белән әмир Хәсән бүгеннән үк Богылтауда кала.

## 4

Ап-ак юрганнарга төренгән Ибраһим хан сарайның икенче катындагы кече залда, ин-ин түрдә, түшәк өстендә ята. Тәрәзәләр артындагы бөтен җиһан да ап-ак. Тышта кыш уртасы; буран булса да якты. Ибраһим хан яктылыкка, җиһан аклыгына түзә алмый. Тәрәзәләрне инде күптән киез пәрдәләр белән томалаттырды. Шуңа күрә зал эчендә хәзер тонык карангылык, тынлык хөкем сөрә. Юкка-барга хан янына керүче, аны борчучы юк.

Менә инде биш-алты ай буена Ибраһим хан әллә нинди чирдән җәфа чигә. Дистәгә якын табиблар, өшкерүчеләр, имчеләр дә чакырып карады, әмма аның хасталык сәбәпләрен белүче, аңлата алучы юк. Ә Ибраһим ханның ничә айлар буе тамагыннан беркавым ризык үтми, кендектән аста ниндидер бер елан аның тәнен кисеп-кисеп талый. Хан инде бу вакыт эчендә су күрмәгән агач мичкә сыман тәмам кибеп, коргаксып калды. Тәне сөяк белән тиредән генә хасил, җегәр дигәне дә көнләп кими бара.

Ибраһим ханның хәзер төп шөгыле—уйлау. Ә уйларның тау чишмәсе кебек мәңге бетәсе юк. Төннәр буе йоклый алмый, сызланып яткан чакта Ибраһим хан хыялы аша бар җиһанны аркылыдан буйга йөреп чыга. Үзенә күрә, әллә кайларга керә, һәммәсен бизмәнгә салып үлчи, сыный, чамалый. Ә таң атты исә инде үз янына вәзирләрне, бәк һәм әмирләрне чакыртып төпченә, сораштыра, һәркайсының җелегенә үтә. Тегеләр бернәрсә дә яшерми, һәр тарафны энәсеннән җебенә тиклем, бәйнә-бәйнә сөйләп чыга кебек. Ләкин тегеләр күз алдыннан югалуга ханны янә яман корт талый башлый, икеләнү һәм шик күмеп китә. Яраннар бер генә эшне дә ханның үзе кебек җиренә җиткереп, җегенҗеккә китереп үтәмәгәндер булып тоела башлый.

Бүген дә, әнә, акрын гына ишек шыгырдады, ярыкта Мәрчураның балавыз сыннныкы шикелле саргылт, хиссез-хәрәкәтсез йөзе чагылды. Ибраһим ханның чырай сытардай куәте юк иде, шуңа күрә карашын читкә алды, керфекләрен йомды. Әйе, бу бәндәне Ибраһим хан күрә, күтәрә алмый. Әмма барыбер түзә. Чөнки Мәрчура кадәр үк күпне күргән, тәҗрибәле икенче бер ирне Болгар дәүләтеннән табу кыен. Ә карап торышка мокыт кына булып күренгән шушы Мәрчура-вәзир яшьлегендә Бохарада укыган, Чин җиренә барып килергә җитешкән, Болгар иленә кайткач, тәҗарәт эшенә керешеп, Киевта, Румда, Ләһстанда булган. Шушы үзе кетмер, үзе елгыр бәндәнен тагын Багдад хәлифәсе булып хәлифә янына кадәр барып кайтуын да искә алгач, янә ни өстәмәк кирәк? Кыскасы, ул бармаган, ул күрмәгән ил юк. Шуңа күрә кайсы мәмләкәттә ни генә булмасын, җилнең кай тарафка таба исәчәген, кем белән сату итү отышлы, кемгә аяк чалырга кирәк—Мәрчура вәзир һәммәсен дә алдан белеп тора, ялгышмый. Җитмәсә, аның әле болгарныкыларга да борыны бик сизгер. Кайсы кала ханнан хәреҗ яшерә, кайсы бәкне тәхет янынарак елыштырырга, кайсын аяк чалып егарга кирәк—Мәрчура вәзир мәмләкәт биләре белән шахмат тактасындагы сыннар шикелле уйный, бер генә вилаятъ хуҗасына да үсеп, азынып, көрәеп китәргә ирек бирми. Менә ни сәбәпле аңа тешен кысып түзә Ибраһим хан.

Мәрчура өч-дүрт төргәк кәгазь тотып кергән иде. Шуларга таба ияге белән ымлап сүз башлады:

—Богылтаудагы Казан кирмәненнән сәүдәгәрләр нөгәре кайтып төште. Әмир хәзрәтләре дивар тергезүне тәмамлаган, хәзер яна мәсжед төзү мәшәкатьләренә керешкән. Ташчыларга, мигъмарларга ризык житми икән. Шул нисбәттән икмәк вә куй сораган. Мин инде Сәмәрә бикә белән Сарычин тарханга фәрманнар юлладым. Сәмәрә бикә—он, ә Сарычин елкы көтүе китерергә тиеш.

Ибраһим ханның елан кабыгы сыман яргаланып беткән иреннәре арасыннан иске самавыр борынынннан саркыган су тамчылары кебек көттереп һәм сузылып кына берничә сүз савылды.

—Тагын... нинди хәбәрләр бар?

—Рәзән кенәзе Глеб бабаң тарафыннан ингән хәбәрләр гайре сәер. Дәште кыпчакта «Лачын Хисами» кушаматлы ниндидер яна сәрдәр табылган. Әрбәт-воеводаның вафатыннан файдаланып, шул сәрдәр Мәскәү кальгасын көлгә әйләндереп киткән. Әле Сүздәлгә тиклем үтеп, ошбу каланы да басып алырга ният иткән дә, мәгәр жегәре житмәгән. Ахыр чиктә, бистәләрен яндырып, кире чиккән.

Селкенердәй куәте булмаса да, Ибраһим хан түшәгеннән кузгалгандай итте. Эчкә баткан, бөрешкән яңаклары кура жиләге сыман тимгелтимгел булып кызарып чыкты. Гаҗәпләнүдән, хәлсезлектән көрмәкләнгән теле санаулы авазлар гына сытып чыгара алды.

—Ничек... урысларның... йөрәгенә тиклем үтә алган соң ул?.. «Лачын» ниндәй инсан?

Мәрчура күзләрен кагып бетерелмәгән кадак сыман тырпайтып тик торды, бераздан гына инбашларын сикерткәләп алды.

—Үзем дә аптырыйм, гыйззәтле хан. Кыпчакларның Тугълый ханнары бар иде. Янә дә килеп Күбәк, Кузай, Әнәкләре барлыгын да беләм. Көнчәкне аларга үзебез үстереп бирдек. Ә ошбу Лачын Хисами каян табылгандыр—һич төшенә алмыйм.

Мәрчураның мондый аңлатуы, житен сукканнан соң чәчелеп калган кибәк өеме сыман, Ибраһим ханга бөтенләй дә кирәк түгел иде. Аның янә йөзе сытылды. Вәзир үз хатасын төзәтергә ашыккандай тагын сөйләнә башлады.

—Мәгәр минем күнелемдә олуг шик бар, гыйззәтле хан. Ошбу сәрдәр урыс жирләренә бәгъзе каршылык-киртә белми үтеп керә. Аның алайлары юлларда елан кеби тавышсыз-тынсыз йөри. Урыс калаларын да ошбу сәрдәр әтәч сыман чукып кына ала. Уйлыймын ки, Лачын сәрдәр урысларның үз кулыннан качкан вә аларга үтә дә үчле инсан түгел микән?..

—Ачыкла...—диде Ибраһим хан, усал ысылдап.

Башын ия-ия Мәрчура чыгып киткәч, Ибраһим хан янә керпе энәләре сыман чәнечкеле уйлар эченә чумды. Ул кыпчак даласыннан күтәрелеп чыккан Лачын Хисами асылда кем икән соң? Кыпчакларда кабилә саен бер хан, алар хәтсез. Бер-берсенә баш ия дә, кушыла да белмиләр. Шул таркаулыкларыннан файдаланып, урыс кенәзләре аларны аерым-аерым көенчә чүкеп кенә тора. Урыс басымына һәм талавына түзмичә, инде чукынып, нәсаралар диненә күчкән кыпчакларны да байтак кына, диләр. Димәк ки, урыс баскынчылары аларны да бүлгәли, йота бара. Ләкин әнә шундый таркау, юаш кыпчаклар арасында Лачын Хисами атлы гаярь сәрдәр каян табылган соң? Аларда мөселманнарныкы шикелле Хисами атлы би яисә бәк хасил булу гайре сәер очрак. «Хисами»ның кушамат кына булуы да бик ихтимал. Аның ул Вүлдәмир кенәзләренә нинди бетмәс-төкәнмәс үче вә ачуы бар? Нигә Кияү-кала, Галич, Смоленск әтрафына бармый, нишләп һаман-һаман Вүлдәмир кенәзлегенен биләмәләренә генә каныга ул?..

Ибраһим хан гыйнвар бураннарына да биргесез уй-сораулар өермәсе эчендә изаланып озак ятты, әмма газап йомгагының очын барыбер таба

алмады. Берзаман ул яткан бүлмә ишегенең күгәннәрен иплә шыгырдатып, аның янына хатыны Вышелюба инде. Ул үзе белән бергә бүлмәгә яшьярымлык улы Алтынбәкне дә житәкләп кергән иде. Сабыенын салават күпере сыман көләч йөзен күрүрә үк Ибраһим ханның карашы да кояш нурларында тирбәлгән пәрәвез жепләре шикелле яктырып алды. Тегәрҗептәй нечкә иреннәре арасыннан кайнар хисләр сытылып-савылып чыкты:

—Улым, улыкаем!

Алтынбәк әтисенен суырылып, кибеп калган кыяфәтенә иялэнгән иде инде. Ул һич тә ятсынып тормыйча сикергәләп килде дә, Ибраһим ханның күкрәгенә ятты. Әти кеше арык, хәлсез бармаклары белән аның аксыл-сары чәчләрен аралады, капылт бәреп чыккан яшь элпәсе күзләрендә томан хасил итте. Янда гына хатынының ипле-назлы тавышы ишетелде.

—Ә без бүген Сәлим абый илә Чирмешән буена барып кайтырга да өлгердек әле, әттәсе. Сәлим абыйдан Алтынбәкне үз янына, ияргә алуын да бик үтенгән идек, тик ул тынламады. Бер ияргә ике шаһзадә сыймый торгандыр инде, күрәсең.

Вышелюба сабый бала сыман иреннәрен турсайтып, үпкәләгән тавыш белән сөйли, ул элеккечә үк дәртле, чибәр иде. Ибраһим хан аның йомшак кулларын эләктереп, аларны янагына кысты. Шушы ләззәттән исергән сыман онытылып ятты.

—Сәлим шаһзадәне мин алтын казан төшереп жибәргән инеш буендагы кальга тарафына барырга жыена, диләр. Үзе идарә итәчәк ил белән таныша тору минем улыма да комачауламас иде. Минем үзенә тагылырга маташуны Сәлим шаһзадә санга сукмас инде?..

Хатынының ошбу сүзләре Ибраһим ханны тормыш-яшәешнен асыл агымына кайтарды. Әйе, Вышелюба Биләргә килгәннән бирле әмир Сәлимне өнәмичә яши. Ул Алтынбәк туганнан соң фәкать аның киләчәге өчен генә янып көя. Ихтимал, ана кеше шулай кайгырып-өтәләнеп яшәргә тиештер дә. Мәгәр әмирләр, ханнар иңендә мәмләкәт саулыгы, тәхет иминлеге турындагы борчу-мәшәкатьләр дә бар бит әле. Ә бүген андый йөкне Алтынбәк-нарасый ничек итеп үз иненә алсын?

Шулай да Ибраһим хан сөекле хатынына аны юатырдай жылы жавап тапты.

—Мин әйтермен... Сәлим тынлар... Алтынбәкне алыр...

Вышелюба сарайдагы хезмәтчеләр, сәркатибләр арасында булган юк-бар турында сөйләп берникадәр вакыт утырды да, ничек кергән булса шул рәвешчә ипле генә басып, тиздән чыгып китте. Бүлмәдә янә мәгарәдәге кебек тынлык урнашты, бетмәс-төкәнмәс уйлар ташкыны Ибраһим ханны янә газаплы хисләр чоңгылы эченә суырып алды...

Сагыз кебек тартыла-сузыла чираттагы бер көн үтеп китте, жир өстенә карангылык инде. Түшәккә һич ашыкмый торган дәртсез хатын сыман көттереп-ялындырып кына күк йөзендә салкын ай калыкты. Бүлмә эченә ингән нурлар борын төртердәй жылы тән эзләде, таба алмады. Ибраһим ханның пыяладай катып калган ачык күзләрендә учак жылысы да, тормыш чаткысы да инде сүнгән иде.

## Унҗиденче бәйләм

### 1

Печән күбәләре кебек тезелеп киткән вак-вак таулар арасындагы инкүлек буенча озын, нечкә аркан сыман сузылып атлы гаскәр бара. Ятаган кылыч һәм садаклар билгә асылган, җәяләр индә, җайдаклар очларына ат ялы бәйләнгән сөңгеләрен генә күккә төбәп утыра. Ирләрнең килеш-кыяфәтләре игезәкләрнеке кебек бер үк төсле. Өсләрендә тимер боҗралардан үрелгән көбә күлмәк, аякларында юка

табанлы, җинел күн итекләр, иңнәрендә йә корычтан коелган, йә катлы-катлы күнне сагызга катырып ясаган ипле, түгәрәк калкан. Төрле җәнлек сурәтләре һәм бизәкләр белән нәкышьләнгән калканнары кебек үк кояш нурларында көмеш тәнкә яки дулкын өсләрендә сикергәләгән чабак балык сыман уйнаклап баручы очлымнары да үзгә. Аларның өске өлешен генә кәләпүш шикелле түгәрәк, әмма уртасы нык очлы корыч кәпәч каплаган. Ә шул кәпәчнең тирә-ягы буйлап җайдакларның муенына кадәр нәкъ көбәләрдәге шикелле үк тимер боҗралар дулкыны тезелеп төшкән. Һәм иң сәере—җайдакларның борыннарын сәгатьләрнен бәләкәй теле сыман кыска, очлы корыч калканчыклар каплап тора.

Игътибарсызрак карасаң, ирләрне дә бер-берсеннән аерып булмас төсле. Һәркайсында яңак сөякләре тәртеп торган җәенке йөз; кояшның эссе нурлары астында һәм ачы дала җилендә йөреп, төнге учак янында утырып бакыр төсенә кергән, кырысланган киң бит; дошманың ерактан ук күрү, сынап карау өчен яратылган кысык күзләр; иреннәрне генә түгел, иякне дә каплап ике якка салынып төшкән мыек чылгыйлары; янаклар буйлап анда-санда гына тәрткән сирәк сакал; һәм аеруча җәлеп иткән тараф—теләсә кайсы мизгелдә дошманың каршыларга йә булмаса аның өстенә ташланырга әзер торган һәрчак уяу караш.

Бу—бер гасыр буена рус кенәзлекләрен дер селкенеп яшәргә мәҗбүр иткән кыпчак гаскәре. Менә хәзер дә ул хуҗалар һич кәтмәгән яшерен юллар буйлап рус җирләренең үзәгенә—Владимир каласына төбәп бара.

Дошман җирен ук сыман ярып килүче гаскәрнең ин-иң очында, мөгез урынында—мәгъруր Григорий. Ул ияр өстендә коеп куйган сын шикелле утыра. Карашы күктә очкан бөркетнекедәй уяу, йөзе кырыс, җитди. Кайчакларда ул күзләрен йомып та баргалый. Андый минутларда сәрдәр йокымсырый, дип алдануың да бар. Григорий йокы белми. Күзләрен йомган чагында ул күңелендәге уйлар өермәсен калыпка салып ала.

Ул быел да, менә, алты-җиде мең кешелек гаскәр белән дошман өстенә бара. Гәрчә үзе шул Владимир каласында туып үссә дә, ул—Григорий өчен куралмас һәм дошман җир, моңа икеләнми. Әүвәл анда аның әтисен—бөек кенәзне суеп үтерделәр. Соңрак шул ук владимирлылар әлеге фаҗигада аның әнисен—Болгар кызын хыянәтче итте һәм агач мичкә эченә томалап гомерен кыйды. Шул катилләр үк аның үзен дә кенәз тәхетеннән мәхрүм итеп кенә калмадылар, яңа канга сусап, бөтен урыс җире буенча кон-тон эзләттеләр.

Григорий—сукбай хәзер. Мөгаен, ул үзенә оя, сыеныч тапмас гомерлек дүнгәләктер. Әүвәл Рязань җиренә качып анда Глеб кенәз канаты астында кон итмәкче иде. Әмма Глеб ике-өч тел белгән укымышлы, зирәк егетне, урыс җирендәге һәммә калага дәгъва-хокукы булган көндәшне, яуда курку белмәс һәм теләсә нинди зурлыктагы гаскәргә сәрдәр итеп куярдай баһадирны үз эргәсендә тотуның ни белән янавын бик тиз чамалады, күрәсең. Әллә каян гына ишетеп-белеп алды да, ул Григорийны «фәкать падишаһлар нәселеннән булган кешеләрне генә үземә яр итәм», дип, һаваланган гөрҗи шаһбикәсе Тамара янына кияү сыйфатында озатты. Ә алма пеш, авызга төш, дип кенә әзер тәхетне эләктерергә өметләнүче вак-төяк шаһзадәләр җиһанда бик күп булып чыкты. Аларның күбесен артына ут капкандай шаһбикә түшәгенә узарга омтылды һәм моңа ирешкән бере таң атканда гаип була барды. Патшабикә сәрдәре булып торган Әтрәк батыр белән бәйләнешкә кереп, әле ярый Григорий гөрҗи тозагыннан вакытында качты.

Менә, хәзер ике-өч ел инде ул кыпчаклар арасында. Чит кавем вәкиле, дип кимсетеп тормадылар, яудагы сәләтен, кыюлыгын күрүгә үк кыпчаклар аны түмәнбаш итеп куйды. Орышлардагы шул ук елгырлыгы, җитезлеге өчен кыпчаклар аңа «Лачын Хисами» кушаматы да такты.

Ул узган ел Мәскәү, Суздаль калаларына уңышлы поход кылды. Урыс җирендә аның Глеб кенәздән кала сөйләшердәй, таянырдай танышы юк иде. Әле походка кузгалганчы ук Григорий аның янына барды. Ә

тегенә исә шайтан үзе бажай иде, күрәсең, ул Григорийнын ниятен белүгә үк сукбай сәрдәрне кочагына алды.

—Мин үзем дә ул Владимирдагы Михаилга каршы яу алып барам бит. Иш янына куш, дигәндәй бер-беребезгә терәк, көч булырбыз. Мин турыдан гына анын өстенә барам. Ә син Угра елгасы буйлап күтәрел, юлың ачык булыр.

Глеб, чыннан да, үз сүзендә торды. Даладан алып Владимир кенәзлегенең чигенә килеп житкәнче кыпчаклар юлда бернинди тозак-киртә белми юырттылар. Өсләренә капылт килеп төшкән көчкә мәскәүлеләр каршы тора алмады. Кала урынында кисәү, кирпеч өемнәре генә утырып калды...

Быел да походка кузгалыр алдыннан Григорий-сәрдәр әүвәл Рязань кенәзе белән сүз беркетте. Жинүгә ышаныч арткач, тукъсубалылар бәге Әтрәк исеменнән төрле кабилә ханнары Бәнәк, Күбәк, Тугълый, Кузай, Әнәк, Көнчәк янына чапкыннар юллап карады. Исәбе барча кабилә ханнарын бер әләм астына туплау иде дә бит, юк шул, кыпчак юлбашчылары бу юлы да үзләренчә эрелек һәм мин-минлек күрсәттеләр. Алар гына түгел, хәтта, Григорий чакыру ташлаган болгарлар да отышлы походтан баш тартты. Чит гаскәр ярдәменә мохтажлыклары калмаган, исәп итсәләр, алар ялгыз көенчә дә Владимир кенәзлеген туздыра ала, имеш. Кыпчаклары да, болгарлары да сәер, юаш халык. Әнә, урыс, ичмаса, яу йөргәндә булса да йодрык сыман туплануны белә. Ә кыпчак, болгар һаман ата каз шикелле япа-ялгыз көе ысылдаган була. Өч-дүрт ата казны бер көтүгә туплап булмаган кебек, боларнын бәкләре, ханнары да япа-ялгыз көе чәбәләнә. Ярар, кушылмагыз соң! Дошман бер көтү тилгән булып өстегезгә килгәч, сез тәкәбберләргә дә акыл керер әле!

## 2

Әлбәттә, бу юлы да Владимир кенәзлегендә аларны көтүче юк иде. Григорий юлда очраган вак-төяк ике-өч дружинаны үгез сыман сытып үтте дә, бер кичтә кайчандыр үзе уйнап-үскән таш кальганы—Боголюб бистәсен камап алды. Монда аңа һәрбер сукмак, дивардагы барча ярык таныш. Ул кальганы нинди рәк көч, хәтта, кемнәр саклавын да чамалый. Максат итсә, ул кальганы килә-килешкә үк яулый ала иде. Әмма ул кыпчак жайдакларының утлы ук очыра башлавыннан, бистәдә янгын чыгудан курыкты. Хәзер инде никадәр генә чит-ят тоелмасын, ләкин әлеге бистә—ул уйнап-үскән оя, әтисе Андрей кенәз корган таш һәйкәл бит. Әтисенең, әнисенең сулышларын, тәннәре кайнарлыгын отып калган бу бистәне яндырып көл итәргә анын хокукы юк. Менә шуна күрә Григорий яу оранын һаман сузды, кыпчакларны һөҗүмгә ташламады.

Ә таң атканда анын эргәсенә Владимир каласыннан чапкын килеп житте.

—Глеб кенәз кала янында тора. Сине көтеп, һөҗүм башлый алмый. Сиңа әмере катгый. «Боголюб—вак бистә. Сиңа байлык та, дан да китерәчәк түгел. Тәхет—Владимирда, аны яулау төп эш. Чапкынга ияреп минем янга ук кебек оч!»

Глеб кенәзнен аны холоп хәленә куеп фәрман юллавы үтенә тисә дә, Григорий моңа игътибар итмәскә тырышты, түзде, белдермәде. Аны аеруча Глеб кенәзнен кыпчаклар холкын, дала яугирләренен гадәтләрен белмәү аптыратты. Кыпчаклар нинди дә булса кала яки бистә янында торганда майлы калжа күргән жанвар кебекләр бит. Шул калжаны эләктермичә торып алар урыннарыннан купмый.

—Кенәз каланы ялгыз көе генә штурмлап карасын. Әгәр яулый алса, даны да, байлыгы да берүзенә булыр,—диде дә, Григорий Рязань чапкынын шундук кире куды.

Бистәне, Григорий өйрәткәнчә, елга ягыннан килеп яуладылар. Кальга капкалары да ачылып гаскәр эчкә тулгач, кыпчаклар белән идарә итү мөмкин булмас эшкә әверелде. Дала жайдаклары һичнинди аралауны, тәртип дигәнне белми, алларында сәүдәгәр сараемы яки тимерче алачыгымы, әллә чиркәүме—һәрбер йортны тоташ рәвештә талап бара иде.

Һәммәсенә кул селтәп һәм төкереп, Григорий үзе үскән сарайга томырылды. Ичмаса, һичьюгы ул йоклаган түшәкләрне, ул үскән бүлмә һәм залларны исән калдырсалар, аның әти-әнисе җыйган зиннәтләрне пыран-заран китермәсәләр иде!

Ходайга мең шөкер, дала яугирләре әлегә сарай янына килеп өлгермәгән булып чыкты. Ишек төбендә ике-өч сакчы калдырды да, Григорий ашыгып-кабаланып сарай эченә чумды. Менә, ул уйный торган зал, ул ашаган өстәл. Бер карасаң, бары да элеккечә. Ләкин инде тәрәзә кашагаларына эленгән пәрдәләр дә, мич тирәсендәге савыт-саба, келәмтүшәк—тоташ яна икән. Хәтта, әнә, келәмнәргә асып куелган сугыш кораллары да яна.

Григорий шул кораллар тупламасы каршына килеп туктады да йөрәге-жаны учка килеп эләккән кош баласы сыман калтыранып һәм сулкылдап куйды. Йә, Хода! Сабы асылташлар белән бизәлгән әнә теге кылыч аның әтисенең ядкаре түгелме соң? Ул бит аны күз карасы кебек кадерләп кенә саклый, шушы кылычы турында күпме хатирәләр бәян итә иде!

Имеш, кайчандыр әлеге кылычка «Кызыл кояш» Владимирның улы Борис хужа булган. Ә Борис—Владимирның Болгар ханнары нәселеннән булган Бүзбикә атлы хатыны тапкан олан. Бүзбикә бөек кенәзнең иң яраткан хатыны булган һәм аңа нибары ике угыл тапкан. Бүзбикә үз балаларын укымышлы һәм зирәк итеп үстерә белгән. Шуңа күрә Владимир үзеннән соң Киев тәхетенә бөек кенәз итеп нәкъ менә болгар хатыны тапкан балаларны—йә Борисны, йә Глебны калдырмакчы булган. Мәгәр Владимирның икенче бер хатыныннан туган явыз Святополк әүвәл Борисны, аннан Глебны катил затлар яллап үтерткән.

Тукта, әллә нинди сәер хәл түгелме соң бу? Аның әтисе, Андрей кенәз, урыс белән кыпчак никахыннан туган бала иде. Борис атлы мәрхүм—анысы инде урыс белән болгар каны кушылудан туган. Шушы катнаш канлы Борисның кылычын катнаш канлы әтисе үзенә истәлек иткән. Һәм ни гажәп, Владимирдан килгән катилләр аның сараена бәреп кергән чакта Андрей кенәзнең истәлекле, кадерле бу кылычын болгар кызы, Григорийның әнисе Байгөл яшереп куйган булган, диделәр бит. Ошбу кылыч белән Борис та үзен саклый алмаган, әтисе Андрей кенәз дә аннан мәхрүм калган. Сыңар кылыч тирәсендә кайнаган нинди эзлеклелек соң бу, нинди тәкъдир? Бу кылычның «мин катнаш канлы түгел, бәлки чиста канлы кешеләрнең генә гомер сагына басам», дигән кинаясе-шарты түгелдер бит инде? Әллә ике милләт җимеше булган кешенең катил түгел, бәлки халыклар, мәмләкәтләр арасында илче булырга тиешлеге турында чакыру йә оранмы? Әллә соң бу кылыч үзенең Ватанын, илен югалткан да, яңа хуҗаларын шуңа сакламыйммы?..

Истәлекле кылычны кулларында тоткан көенчә, Григорий озак басып торды. Анын тәне буйлап урыс, кыпчак, болгар каны ага. Әлеге халыклар ия булган телләрнең дә һәркайсын белә ул. Әтисенең кадерле ядкаре булган әлеге кылыч белән ни хәл кылырга соң, үзе белән алыргамы, юкмы? Әгәр алса, сәер кылыч белән бәйле тәкъдир очы кая барып чыгар?..

## 3

Глеб кенәз кыпчакларны Колакча елгасы буендагы зур гына уйсулыкта ныклы тозак корып каршылады. Алмашка алынган һәрбер ат сыртына чүмәлә-чүмәлә ганимәт төягән кыпчак гаскәре юлда кайта-кайта

уяулыгын инде тәмам жуйган, газиз далалары аларны төнге юлчыны чакырган учак сыман тарта һәм кул сузымы гына калган арада алар һичнинди дә мәкер көтми иде. Рязань кенәзе корган тозакка да алар талчыбыктан үргән мурда эченә сикергән балык сыман үз сансызлыклары белән килеп керде. Яу йөреп эттәй яравайланган сугыш атлары кыбырсый һәм пошкыра башлаганда эш нык узган, икешәр катлы чылбыр булып тезелгән Рязань гаскәре аларны һәммә яктан чолгап алган иде.

—Туган-үскән кальганны яуладын да, урыс байлыгын тик бер үзен талап качарга жыендынмы, сатлык, әшәке жан?!—дип, уйсулык өстеннән әүвәл Глеб кенәзнең күк күкрәгәндәй усал тавышы янгырап үтте. Аннары инде кояш нурларына күмелгән биек тау борынында Глеб үзе дә пәйда булды. Ул йөзе-кыяфәте белән үк өшәндергеч, кансыз, ә очлым, көбә, дирбия көмешләрендә уйнаклаган нурлар аны, хәтта, дәһшәт, тылсым иясе дәрәжәсенә куеп чагылдыра иде.

—Син мина ярдәмгә килмәден, мине саттын, Лачын. Владимир каласы янында оттырып минем яугирләрем ганимәтсез калды. Синекеләр, күреп торам, Боголюбны кызганып һәм сайлап таламаган. Кыргыйларына житкер. Исән каласылары килсә, ганимәт төягән барча атларны чылбыр тышына куалап чыгарсыннар.

Рязань кенәзенең әрсезлегеннән бигрәк Григорий үзенең саксызлыгы, беркатлылыгы, ачыгавызлыгы өчен әрнеп жавап бирде:

—Эт авызыннан сөяк талап алырдай куәтең бар икән, әйдә, көчәнеп кара, юлбасар кенәз. Мәгәр дала бөркетләре мал бүлешү, юмартлыкны белми, шуны нык чамала!

Чолганышта калган кыпчак гаскәре умарта күче шикелле кайнап, тузгып алды. Беркадәр вакыт буена инкүлек эчендә өзәнге, йөгән тимерләренен чыңы, кыска-кыска әмерләр авазы янгырап торды. Аннары инде ярсу жайдаклар ике башта да сөнгедәй чөй ясап сафка тезелделәр. Григорий шундый бер чөйнен ин очына басты. Һавада кыпчакларнын бер-берсен яуга дәртләндергән гаярь аһәңе янгырап ишетелде.

—Тукъсуба!

—Бәлдүз, Сарыхан, Китән!..

Григорий Глеб кенәз басып торган тау борынына төбәп алга томырылды. Иһаһайлап, сызгырып, бүре тавышлары чыгарып улый-улый аңа кыпчаклар иярде. Менә, Григорий инде Рязань сугышчылары сафына бәреп керде. Анын яшендәй уйнаклаган кылычыннан качып котыла алмыйча ике якта ике яугир ауды. Икенче мизгелдә исә анын муенына авыр гөрзи төшеп гөрселдәде һәм һушсыз Григорийнын гәүдәсе тау итәге буйлап аска тәгәрәде...

Григорий күзләрен кабат ачканда жиһан инде төнге караңгылыкка чумган, ул үзе пыскып янган учак янында ята, каршына ике-өч сугышчы гына тезләнеп баскан иде.

—Яу ничек тәгәлләнде? Мин кайда?—дип телгә килгән сәрдәргә каршы жавапларны да кыска, анык кына итеп анлаттылар.

—Дошман чылбырын жинел өзеп чыктык. Мәгәр ганимәтнен яртысы дошман кулына төште.

—Гаскәр хәзер кайда?

—Кыпчаклар туган жирләренә кайтып китте.

—Мине ташлап киткәннәр инде алар, болай булгач.

Григорийга жавап бирүче табылмады. Сакчыларнын берсе урыныннан кубып учакка чабык-чөбек өстәде.

—Ә сез нишләп минем янда калдыгыз? Нигә качмадыгыз?

Бу юлы да сәрдәр сораулары жавапсыз көе калды. Аптырагач, Григорий тегеләрне күздән кичереп чыкты һәм төенне тиз чиште. Анын янында калучы сакчыларнын өчесе дә нинди дәр жәзадан качып кыпчак ханнарына, биләренә ялланган болгар яугирләре. Алар байлыкка-малга кызыкмый, үзләрен дә ни тегендә, ни монда сагынып көтүче юк.

Григорий сынар кулы белән бил каешын барлап алды, Боголюбтан

алып чыккан истәлекле кылыч үз урынында иде. Ул уйларга чумды. Нишләргә инде хәзер? Кыпчак сугышчылары аны ташлап качкан, димәк, хаҗәте дә шул дәрәҗәдә генә. Далага кайтып, анда үзен ташлап киткән өчен купмедер сугышчының гомерен кыйдыру аңа берни бирми. Ул анда, барыбер, артык кашык, кадерсез зат кына булып яшәячәк. Инде кая юл тотарга да, кем янына барып сыенырга? Кемгә булса да кирәкме соң ул, гомумән?

—Атлар әзер. Кай тарафка юл тотабыз, сәрдәр?—дип, аның уй-газапларын сизгәндәй, болгар качагының берсе сорап куйды. Кулын әтисеннән калган ядкарь кылыч өстенә салды да, Григорий берникадәр вакыт буе дәшми-тынмый ятты. Ул көннән-көн тутылана барып, сызландырып торган һәм ахыр чиктә барыбер борынлаган яман шеш сыман, ниһаять, ныклы бер карарга килгән иде инде. Шуны үзенә тугры калган сугышчылар җиткерде.

—Болгар җиренә. Болгарга.

## Унсигезенче бәйләм

### I

Егерме яшен яна гына тутырган Сәлим хан иркен, зур зал буйлап читлеккә ябылган юлбарыс шикелле әрле-бирле йөри, йөзеннән нур качкан, кашлары җимерек иде. Күгәннәре белән шыгырдап ишек ачылды да, кисәтми-нитмичә залга мәмләкәтнең баш сәете Мирхаҗи килеп керде. Аның да кәеф бик чамалы иде, күрәсең. Ул кулларын сүзсез генә хан тарафына сузды, аннары тәрәзә буендагы нәни мендәрләрнең берсе өстенә барып чүмәште дә, урам якка текәлеп тораташтай калды. Мәгарәдәй тынлыкта икесен дә, мөгаен, бер үк төрле уйлар газаплагандыр, ә шулай да, беренче булып, хакыйкать турында сәет сүз кузгатты.

—Мәмләкәт гайре сыйхау, яман хаста хәлендә бит, хания. Аны ничек савыктырырга, ни рәвешле аякка бастырырга җыенасың?

Сәлим хан чәчен-сакалын тоташ бәс сарган сәетне акыллырак сүз башлар, киңәш бирер, дип көткән иде. Сәетнең берниндп тәкъдимсез-нисез көенчә аның янына кереп, борчып йөрүе мин-минлегенә ярамады, хан әче как капкан шикелле йөзен усал сытты да, янә зал буйлап йөрене башлады.

—Ябай халык аяк сузар хәлдә. Ул, бичара, син җиткергән яңа салымнарга һич тә разый түгел,—дип, сәет тәрәзә төбеннән кабат аваз салды.

«Һе, син кереп әйтмәсәң белми идем, картлач!»—дип үз эченнән генә көрпәләнеп сүгенде дә, Сәлим хан элеккечә кыштырдавын белде. Зиһененә рәшәле томан шикелле ярсыз-киртәсез уйлар өерелеп килде.

Әйе, урамга чыгып гавамны тыңламаса да, Сәлим хан һәммәсен ишетеп-белеп тора. Соңгы айларда ул җиткергән өстәмә салымнар белән һөнәрчеләр дә, субашлар һәм чирмешләр дә һич канәгать түгел. Салымны ике мәртәбә күбрәк түли башлаган ар-чирмешләр аеруча нык сукрана. «Без ислам диненә күчмәгән, кара чирмеш булып йөргән чакта да шушы тиклем салым түли идек. Инде потчылар булудан туктадык, сезнең дингә күчтек, ә талавыгыз, барыбер, кимемәде. Әгәр нәсаралар диненә күчкән булсак, мөгаен дә, урыс кенәзләре безне бу тикле үк таламас иде әле». Чирмеш биләренең мондый янау-сыкрауларын Сәлим хан колагына байтак җиткерделәр. Хан үзе дә чамалый: урыс белән ике арада калкан булып торган ул эрҗә, чирмеш, мукшы, ар халыкларын рәнҗетмәскә, алар хозурындагы мөселманнар кавемен һаман саен ишәйтергә иде. Әмма иртәгәге көнгә ышанычы, бүген таянычы булмаган яшь хан ни кылсын

соң? Мәмләкәт казнасы тишек янчык сыман буп-буш. Төзелеш жененнән башканы белмәгән анын әтисе Ибраһим хан казнадагы бар байлыкны Богылтауда—Казан, Мәләкәс тавында Чаллы кирмәннәрен төзүгә тотып бетерде. Яна ханнын һөнәрчеләргә өстәмә салымнар житкерүен сылтау итеп сәүдәгәрләренә кадәр Болгар мәмләкәтеннән читкә чыгып качты. Сәүдәгәрләр бие Иркәнәшне чакырып сораштырдыңмы, тегенең авызында гел бер үк жыр:

—Син тамга салымын бермә-бер арттырдың. Өстәвенә, урысларга, садумнарга вә румнарга Идел буйлап йөрүне дә тыйдың. Шунын аркасында урыс белән гөржи дә Ага-Базарга килеп йөрмәс булды. Үрганечтән, Харәземнән, Бохарадан йөрүче кәрваннар саны бермә-бер кимеде. Шуңа бәйле нисбәттә, безнекеләр дә Тимер Капкага, кыпчак даласына, Үрганечкә йөреп сәүдә итүне үзләренә отышлырак, төшемлерәк саный башлады.

Шулай, хан яшь булгач тел яшереп торуны да артыксына хәзер бәк һәм биләр. Күпне сиздерәләр, тәрттерәләр, ләкин күңелләрендәге иң яшерен һәм иң тырнаган уйларын, барыбер дә, әйтеп бетермиләр. Ә аларнын һәркайсын эчтән зәһәр төтен сыман талап, әчеттереп торганы—ул тәхет мәсьәләсе бит. Илдә күпләр тәхеткә Сәлим хан менү белән риза-бәхил түгел. Байтак бәк һәм биләр бүген биш куллап тәхеткә анын агасын, Ибраһим ханның энекәше булган әмир Хәсәнне утыртып куяр иде. Баш вәзир булып йөргән Мәрчура да, Алабуга, Кашан, Жүкәтау һәм Кернәк бәкләре дә—һәммәсе әмир Хәсәнне күпкә өстен саный. Шуна күрә ул дүрт кала бәге арасыннан берсенең дә елдан артык инде яна хан күзенә килеп күренгәне, анын каршында тезен чүккәне юк. Ходай насыйп итсә, килер, килер ул бәхетле көн! Алабуга-Кернәк бәкләре генә түгел, чит-ят дошман юлбашчылары да Сәлим хан каршында тезен чүгәр әле!

Мәгәр әле менә бүген, шушындый авыр көндә, үзенә ышанычлы яраннар, таянырдай терәк табасы иде. Ә саный башласаң, алар бөтенләй дә юк бит. Икейөзле, бөтен эче-тышы мәкер, ялагайлану белән тулган Мәрчура вәзир. Ханнын иминлеге турында кайгыртудан бигрәк кыпчак даласын сагынып яшәүче ять-яшь Тургай сәрдәр. Ун яшен әле генә тутырган энекәше әмир Хажи һәм әле борын асты да кипмәгән Алтынбәк. «Рязаньга жибәр, әти-әнием янына кайтар», дип елый-елый үзегенә үткән Вышелюба. Әти исән чакта башлы-күзле булыйм, ул канәгать китсен, дип кенә кыпчак даласыннан алып кайткан, чынында исә бер кадере дә булмаган хатыны Рауза. Йә, шуларның кайсын үз итсен дә, кемгә таянсын соң? Анын әйләнә-тирәсендә эч серен уртаклашырлык та якыннары юк бит. Әнә, Мирхажи сәет тә анын янына гел-гел кереп йөргән була. Ә кыяфәте исә һәрвакытта чукрак яки телсез кешенеке сыман: карашы жылы, күзләре гел елмая, ә иреннәре-йөзе катып калган. Аңа ничек итеп серен чишмәк кирәк?..

—Нинди гозерең бар иде? Нигә кердең?—дип кычкырып Сәлим хан Мирхажи сәетне хыяллар болыты өстеннән жиргә сөйрәп төшерде. Сәет каушамады, тиз-тиз тезеп китте.

—Хәтсез көннәр-айлар буе арпа-солыдан мәхрүм кылынып шыр сөяккә калган ат кебек кипкән, коргаксыган синең күңелен, и, Сәлим хан. Бетмәс-төкәнмәс шик вә шөбһә корты талый булыр сине. Андый мәлдә гадел таждар булу гайре читен хәлдер. Күңел күзең сукыраймасын дисәң, син гавамга бер бак. Анда гавам елый. Ә бүген күз яше илә сыктаган гавамның иртәгә сиңа каршы кулына корал алуы да ихтимал бит.

—Әллә өркетмәкче буласың инде, сәет?—дип көрпәле хан үз-үзен көчләп елмаймакчы иде дә, кунакның аллагы сүзләре шундук куырып алды.

—Нишләп өркетим ди? Мәмләкәттә чуалыш-фетнә кубу мина түгел, әмир Хәсән өчен сөенеч бит. Фетнәләрнең ниндәе дә суны анын тегерменәнә генә коя булыр...

Баш сәет белән ханнын әңгәмәсен шулчак залга килеп кергән

каравылбаш өзде.

—Алабуга кирмәненнән чапкын килеп төште. Анда бәла—дошман килгән, хания.

Сәлим ханның йөзеннән мәкерле елмаю узды, әмма башкаларга, моны сиздермәде. Боздай салкын тавыш белән каравылбашка дәште:

—Чапкын керсен, үзе бәян итсен.

Ишектән өстенә ертык җилән кигән бер ир узды. Залның уртасына кадәр дә үтә алмады, тезләренә чүкте һәм ике кулын да алга сузып таш идән өстенә капланды. Чапкынның өсте-башы шау тузанга баткан, аркасын һәм инбашларын буй-буй тир каплаган, күренеп тора—ул чаптарларын юлда ару-талуны белми куган иде.

—Көтелмәгән бәла, вәли хан галиҗәнапләре.—Чапкын гыж-гыж килә-килә шулай сүз башлады.—Вилаятемезгә дошман бәреп керде. Мукшы урманнары тарафыннан. Чулман дәрьясы буйлап.

—Кемнәр алар? Көчләре ни тиклем?

—Тәүге орыш барышында ике адәмнәрен тотык итеп алдык. Олуг Наугырыт эргәсеннән үк төшкән ушкуй чирүе икән. Кяферләрнең саны биш меңнән кайтыш түгел.

Сәлим хан чапкын каршына килеп туктады да, кулларын ботларына шапылдатып алды.

—Биш мең адәм. Әле алары да азаматлар түгел, ә ушкуйлар. Шул чебен көтүе өчен ни бәбәгемә дип бөтен мәмләкәткә җәнҗал куптара бу Әхтәм имгәк?! Вакытында мәмләкәт чикләренә сак куймаган, йокыга бирәнләнеп бетле ушкуй нөгәрен дә борын төбенә тиклем уздырып җибәргән икән, кала саклауны да үзе кора белсен.

—Алабуга иң ерактагы вилаять булса да, ул олуг мәмләкәтемезнең бер өлеше, тере тәннең мөһим әгъзасы бит,—дип, Мирхаҗи сәет сүз кыстырган иде дә, Сәлим хан шундук өзде:

—Кала саклауны оештыра алмыйча мәмләкәткә зәүрат сала икән, мин ул Әхтәм-имгәкне дарга тотып асам!..

Фәлән йөз чакрым араны кара тиргә батып очкан чапкын тавышсыз-тынсыз гына мүкәләп залдан чыгып китте. Үзенең күз көеге генә булып торуын Мирхаҗи сәет тә бик чамалый иде, эрегән язгы кар суыдай ул да юкка чыкты.

## 2

Сәлим үлем белән янаса да, Әхтәм бәкне дарга асып торасы булмады, ул үзенең соңгы сәгатен канлы яуда тапты. Аның белән бергә мәгърур Алабуга кирмәне дә җимерелеп-янып, җир йөзеннән тәмам юкка чыкты. Сәлим хан ерак вилаятьтән килгән мондый хәбәрләргә тәүге көннәрдә бер дә ышанмады. Хәлне ачыклап кайту өчен шул тарафка үзенең хассә алай башлыгы Атбасарны куды. Әмма әлеге кыпчак баһадиры алып кайткан яңа хәбәрләр дә тоташ сагыш белән тулган иде:

—Алатау өстендәге бистә урынында кара күмер генә җәйрәп ята. Таш кирмәнне җимереп бетергәннәр. Аның урынында ялгыз казык сыман булып бердәнбер манара гына утырып калган. Кирмәннең соңгы азаматлары шунда кереп бикләнгән. Дүрт-биш көн буена тулгамада тотып та ушкуй нөгәре аны алалмаган. Ахырда «Шайтан каласы бу, сихерләнгән кала», дип, ушкуйлар аңа төкереп китеп барган...

Никадәр генә тугры җан булмасын, хассә алай башлыгы үзенең ханына бар хакыйкатьне дә сөйләп бетермәде. Ә хакыйкать гади халык күңелен сәмум җиле шикелле өтеп, көйдереп йөрде.

—Ушкуйлар чигенеп киткән чакта бөтен Алатау өстендә мәетләр өеме сарылып яткан булган. Безнең шәһит киткән борадәрләремезне атна буена кузгатучы, җирләүче табылмаган. Ахырда Иж аръягыннан арлар килеп кенә ул бичараларны гүргә индергән, ди...

Халык кимсетелгән һәм ярсыган иде. Бөтен ил өстендә ризасызлык, үпкә кара болыт сыман куерып йөрде. Моны, әлбәттә, Сәлим хан да сизә, тоя башлады, күнеленә шом инде, урамга чыкмас, халык күзенә чалынмас хакимгә әверелде. Бер иртәдә ул үз янына баш вәзире Мәрчураны дәшеп китерде.

—Хассә алайга алырдай ышанычлы яугирләрең бармы?

Мәрчура чәйнәп биргәнне көтеп торучы пошмас бәндә түгел иде инде, Сәлим хан ташлаган кинаяне ярты сүздән аңлады.

—Кыпчак даласыннан безгә Лачын Хисами кушаматлы бер баһадир килде. Асыл аты Григорий булыр. Вулдәмирдә олуг кенәз булып торган Әндринең углы. Атасын катилләр суеп харап иткәннән соң кыпчаклар эргәсенә чыгып качкан, шулар арасында сәрдәр булып йөргән.

Күзләрен йомды да Сәлим хан хатирәләр дәрьясына чумды. Тукта, тукта! Ошбу «Лачын» атын түшәктә хаста булып яткан әтисе Ибраһим хан да әллә ничә тапкыр телгә алган иде түгелме соң? Ул әлеге сәрдәр турында «урыс жиренә елан кеби үтеп Мәскәүгә ут төрткән, Суздальның да тирә-юнен көлгә әйләндергән», дип сөйләгән иде бугай. Сонрак шушы ук сәрдәр хакында Боголюбны алган, дигән хәбәр йөрде. Аннары аны суга төшкән балта кеби эзсез гаип булды, дигәннәр иде, бактың исә ул Болгар куенында икән. Нишләп бирегә килгән, максаты ни?

Сәлим хан күнелендәге уйларның берсен дә сиздермәде.

—Мин ул Хисами хакында бәгъзе фаразлар ишеткәләп торам. Аның әнкәсе кем?

—Безнең Кашан каласыннан чыккан Байгөл бикә, сәүдә эшенә маһир Кучкәй бинең кызы. Элегрәк елларда Кучкәй урыс жиренә китеп бистә нигезләгән, соңра шуның урынында синең гамужән Әрбәт Мәскәү атлы кала күтәреп куйды.

—Хисами хәзер кайда, ниләр кыра?

—Рәзән кенәзе Глебка каршы чыккан актыккы явында ошбу Хисами авыр имгәтелгән. Мәет дип санап, кыпчаклар аны шунда ташлап качкан. Хәзер ул Саклан бистәсендәге бер тимерче өендә яши. Инде савыкты бугай, аягына басты. Хужасы аның хакында мина көн дә житкереп тора.

—Ул Хисамины янына дәштереп ялла. Хассә алайга өстәмә йөзлек жыйсын. Лачынмы ул, әллә үләксә кошымы—моны киләчәк орышларда ачыклармыз...

Көннәр үтте. Икеләтә салым белән талауга түзмичә алачыкларын япкан һөнәрчеләр арасыннан үзенә йөзлек туплап, Григорий-Хисами да сарай сагына басты. Ә Сәлим ханны шик-шөбһә хисе һаман ташламады. Чөнки урам-базарларда ризасызлык, үпкә дулкыны учакка асылган сулы казан сыман һаман кайнып бирде. Ул да түгел, беркөнне хан янына сәүдәгәрләр башлыгы Иркәнәш би дә тузынып килеп керде.

—Ошбу урыс ушкуйларынын азынуына, талавына каршы берәр нинди киртә куелачакмы, ханиям, әллә юкмы? Әнә, Мөрем, Рәзән юлбасарларынын бер нөгәре Ука елгасы тамагында янә сәүдәгәрләремезнең дистәдән артык каекларын актык итекләренә, чүәкләренә, чапаннарына тиклем тоташ талап жибәргән. Исән кайткан мөһажирләр хәзер базарларда, урамнарда коткы таратып йөри. Көн-таң атса телләрендә бер сүз: «Мәмләкәттә кайчан хужа хасил булыр? Гавам хакында, дәүләт хакында кайгыртучы таждар табылырмы?»

Сәлим хан Иркәнәш бине уртларын чәйни-чәйни озатып жибәрде дә, котырынып-ярсып үз янына баш вәзир Мәрчураны чакыртып алды. Ханнын теле-сөйләме дә бисмилласыз иде.

—Кяфер ушкуйлары адым саен болгарларны талый. Ул эт жаннар каршында «ярхәмкалла» жырлап күпме утырырмыз? Чуан-хәшәраткә ирек бирсән, эт имчәге кеби, бөтен тәнне сарып ала бит ул. Ушкуйларнын умырткасын сындырырга, аларны Болгар мәмләте эргәсенә таба йөрүдән биздерергә кирәк. Бүген үк, ашыгыч рәвештә, Укалагы Калачык тарафына курсыбайнын бер мен газиен юлла. Ошбу гамәл генә дә житмәс. Рәзән

кенәзе Глеб янына да, Вулдәмирдәге олуг кенәз Всеволод эргәсенә дә махсус илчелек озатырга кирәк. Мин ул ачыгавызларның һәркайсына аерым-аерым шартнамәләр язып хәстәрләрмен. Ә син билен бөгә белмәс илчеләрне эзлә. Ул җен оялаган кяфер мәмләкәтендә берәр заман асыл хуҗа табылырмы да, алар тыгыну-нәфес белмәс ушкуй-юлбасарларына йөгән кидерерме? Әллә урыс кенәзләре ушкуйларның кул-аягын сугып сындыруны бездән көтә микән? Тапкан илчеләрең ике кенәз каршында да менә шундый мәкамьдә сөйләшә торган булсын...

Сәлим хан юллаган илчелек ике айдан соң кире әйләнеп кайтты. Урыс кенәзләре кайтарган җавап-гамәлләр, бер уйласаң, сөенерлек иде. Всеволод та, Глеб та Чулман буена һәм Идел ярына аерым-аерым нөгәрләр туплап озатканнар, ушкуйларның тамырын корытырга ант эчкәннәр икән. Сәлим ханның иңнәренә канат үскән кебек булды. Әмма ике-өч ай да вакыт үтмәгәндер, пайтәхеткә хәвеф тулы яна хәбәр инде һәм Болгар халкын кайнаган су шикелле янә өтеп алды.

—Чипсә тамагында, мәмләкәтемезнең үзәгенә кереп, ушкуйлар сәүдәгәрләремезнең янә бер кәрванын талаган. Сәүдәгәрләр илә аларның яраннарын, ташка бәйләп, суга батырганнар. Көймәләрнең, каекларның барчасын да җыеп, Мөрем ягына чыгып сыпыртканнар...

Сәлим хан яна-каба Владимир кенәзе Всеволод янына тагын бер илчелек юллады, аннан юлбасарларның койрыкларын кисүне кат-кат таләп итте. Махсус мөнадиләр, базарлардан-базарларга, бистәләрдән-бистәләргә күчеп, хан кылган гамәлләр хакында игълан итеп йөрде. Әмма мондый үгет-нәсихәтнең тәэсире генә бер дә сизелмәде. Халык илнең көчсезлеге, мескенлеге, тоташ хәвеф эчендә яшәү белән һич тә риза түгел, ул һаман учак өстендәге казан шикелле кайный.

Ә бер таңда Биләр урамнарын гаҗәеп һәм сәер хәбәр урап үтте:

—Урыс ушкуйларының яңа бер нөгәре Җукәтауга тиклем килеп житкән булган. Юлда әллә ничә бистәләрне, карьяларны талап өлгергәннәр. Мәгәр Шишмә елгасы тамагында төнлә ошбу ушкуй нөгәре өстенә билгесез бер алай һөҗүм кылган. Ушкуйларның күллесен диярлек кылычтан уздырганнар, бәгъзе кяфер генә качып котыла алган...

Бер ай чамасы вакыт узуга шушындый ук хәбәр янә кабатланды. Халык хәзер инде аны яшермичә, сөенеч алган сыман, дәртләнеп һәм ясканып, колактан-колакка тапшыра иде:

—Ханымыз йокласа да мәмләкәтемездә безне кяфер ушкуйларыннан яклаучы батыр табылган бит. Ул үз канаты астына бер алай микъдаре азамат туплаган да, шул нөгәр илә фәкать төнлә генә дошман өстенә һөҗүм кыла икән. Һөҗүмне ярканат, бөркет сымак гайре житез ясый, яуны кайнар вә бик тә кыска тота, ә таң атуга эзсез югала икән. Төнге бөркетләрнең һәммәсе дә йөзенә битлек кия, шул сәбәпле аларны соңыннан танучы-белүче юк, ди.

Әлеге сәер хәбәрләр, әлбәттә инде, Сәлим хан колагын да урап үтмәде. Ул хакимлек кылган мәмләкәттә, үзенең борын төбендә билгесез бер алай хасил булу, ябай халыкның алай башлыгын изге батырга санап куануы аның күңеленә хәвеф һәм шом салды. Әмир Хәсән тарафыннан ялланган көч булса, билгесез бу алайның хан гомерен кыюы яки пайтәхеттә түнтәреш әзерләп ятуы да бар бит. Шушы хәвеф чыбыркылавына түзмичә Сәлим хан төнге алай башлыгын ачыкларга әмерләп базарларга, бистәләргә бер төркем шымчылар юллады. Ләкин таҗ иясенең күңелен юатырлык җавап алып кайтучы табылмады.

## 3

Җиһан өстенә караңгы төн ингәч, каланың Шәрекъ капкасы тавышсыз гына ачылды да, ялан кырга өстенә кара башлык, кара җиләң кигән ялгыз җайдак чыкты. Ул чаптарын урыныннан

кисәк ыргылдырып, ике чакрым ара да узмагандыр. Чирмешән елгасы буендагы тирән бер ерымда сүрән генә янган учак яктысы чагылды. Жайдак чаптарын шул тарафка борды, ерым читенә житүгә иярennән төште. Ләкин яр өстеннән ерым эченә таба ике адым да атларга өлгермәде, анын каршында жир астыннан калыккан шикелле мәһабәт гәүдәле шәүлә пәйда булды, корыч тавышлы сорау ишетелде:

—Нинди йомыш йөртә?

—Үч вә галәбә.

—Үч вә жину,—дип аны кабатлады да, торгак булып торучы шәүлә инде ягымлырак тавыш белән телгә килде.

—Ә, син икәнсен ләбаса, Лачын батыр. Танымыйча торам, гафу итә күр.

Талгын тавыш белән төнге ялгыз жайдак та сүз катты:

—Галиәскәр, синме? Әссәламугаләйкүм, борадәр. Йөзбашларнын һәммәсе дә килеп життеләрме?

—Аллага шөкер, барчасы да монда. Сине көтәләр, Лачын батыр.

Чыбык-чабыкларны шытырдатып ерым төбенә төшкән төнге кунакны учак янындагы алты-жиде ир аягүрә басып каршылады.

Лачын батыр һәммәсе белән дә күрешеп, кул бирешеп чыкты, кайберләренә жылы сүз кушарга да онытмады.

—О, Шәмсетдин борадәр Болгар каласыннан ук килеп өлгергән бит. Юл читен булмагандыр, шаять? Ә азаматларын нихәл синен анда? Ушкуйлардан үч кайтаручы булып йөрүдән баш тартучы юкмы?

—Ушкуйлардан үч алырга атлыккан яугирләрнен саны үсә генә бара, Лачын батыр. Синен әләмен астына баскан ярканатлар саны өч йөздән дә артып китте инде.

—Сөенечле хәбәр. Һич тә начар түгел, борадәрем. Мәгәр арагызга шымчылар вә угырлар үтеп кермәсен өчен яна инсаннарны яу-орышта сынасагыз иде.

Учак тирәли тезелеп утырышкач, һәммәсе дә янә Лачын батырнын сүз башлавын көтте. Батыр күп сузмады.

—Корым-Чаллы тарафына озатылган торгаклардан хәбәр кайтып төште. Мәртүбә вилаяте аша, чирмеш карьяларын талый-талый, Чулманга таба ушкуйларнын яна нөгәре якынлашып килә. Шаять, аларны Нократ елгасы буенда каршыларбыз. Ходай ярдәме илә атнакич төнендә шул Нократ буендагы Кирмәнчек кальгасы янына тупланырбыз.

—Бик хуп, бик хуп,—дип, йөзбашларнын бер-икесе, очрашуны түгәрәкләнгәнгә санап, учак янында яткан камчыларын кулына алган иде. Лачын батыр сөйләменен сәер дәвамы һәммәсен дә кисәк сагаерга мәжбүр итте.

—Минем яныма көтелмәгән кунак килеп төште бит әле, борадәрләр. Шул хакта сезнен колакларга житкермичә башка чарам юктыр.

Каудар йөзбашлар камчыларын янә учак янына куйды, барчасынын да йөзенә кырыслык, уй инде.

—Казан кирмәненләге әмир Хәсән минем яныма бер мөһажир юллаган. Ул Муром, Рязань калаларына яу әзерли икән. «Үчне мәмләкәтемез эчендә яу кылып кына түгел, ә явыз бүренен үз өненә барып та кайтару бик фарыз. Шундый гамәл кылсак, ул бүреләр безнен көтүгә юлны тизрәк онытыр». Әмир Хәсән арадашчы аша менә шундый чакыру тапшырган. Вә әмир алаебыз белән безне яу чирүенә кушылырга дәшә.

Йөзбашлар утлы күмер йоткан сыман хәрәкәтсез, сүзсез утырды. Арада болгарлы Шәмсетдин генә йокысыннан уянгандай булды.

—Казан кирмәненләге әмир Хәсән синен Лачын батыр икәнлегенне ничек тәгаенләгән дә, анын чапкыны синен хозурына ни рәвешле үтеп кергән сон ул? Лачын батырнын асылда кем икәнен әле Биләр илә Болгарда да тәгаен белүче юк бит. Әмир Хәсән ничек синен эзенә төшкән?

Лачын батыр беркадәр көттереп жавап бирде.

—Бу хакта мин дә уйландым. Шигем вәзирдәдер. Мине ханнын

хассә алаена йөзбашы итеп Мәрчура үзе тәгаенләп куйды. Ушкуйлардан үч алырга чыккач, сарай тирәсеннән ике-өч көнгә югалып торуымны да ул, әлбәттә, белә, моңа шигем юктыр. Мәгәр ни өчендер бу хакта ул ханга да кереп әйтми, үземә дә һичбер сөаль бирми, киная дә кылмый.

—Мәрчура әмир Хәсән белән яшерен бәйләнештә тора, бу безгә сер түгел,—дип, ниһаять, Биләр каласының йөзбашлары да кабынды.— Алар үч алучылар алаен явыз гамәлдә кулланырга ният итми микән? Аларнын Сәлим ханга каршы түнтәреш оештыруы да ихтимал бит.

Лачын батыр йодрыгы белән тез башына усал сугып алды.

—Юк инде, андый явыз гамәл хакында хыялланалар икән, һич тә барып чыкмас! Безнең ният—ил-гавамны ушкуйлардан аралау, азат тормыш вә дә иминлектер. Муром, Рязань җиренә үч алырга бару белән мин бик разый. Мәгәр түнтәрештә, мәмләкәткә, падишаһка каршы яшертен вә явыз гамәлләрдә катнашу безнең мәсләк түгел.

## 4

Мең дә бер йөз дә сиксән өченче елның кышында Болгар нөгәре рус җиренә елан сыман һич тә сиздермичә килеп керде. Биш мен яугирдән торган җайдаклар гаскәренең башлыгы итеп әмир Хәсән үзенең сәрдәре Борһанны тәгаенләгән, әмма, асылда исә, юлга чыгуга ук чиру башына төнге «ярканатлар» батыры Лачын Хисами менеп баскан иде. Шул Хисами җайдакларны әллә нинди яшерен ерымнар, инкүлекләр, чокырлар аша алып бара белде, гаскәр һичбер каршылыккагынигә очрамыйча рус иленең бавырына тикле үтеп керде.

Бөек Владимир кенәзлегендә дошман һөҗүмен һичкем көтми, гомумән, рус иле зиһенен җуеп өстендәге киемнәрен тирә-якка аткан исерек сыман туарылып һәм ваемсыз бер хәлдә җәйрәп ята иде. Лачын Хисами һәм Борһан җайдаклары Муром каласын һичнинди каршылык күрмичә тоташ талап чыкты. Клязьма каласы, капкаларын бикләп, керпе сыман энәләрен кабарткан иде дә, Лачын Хисаминың ару-талу белмәс «ярканатлары» аңа төнлә бәреп керде һәм соңыннан кальга урынында көл калдырып китте.

Рязань каласының хакиме Глеб кенәз рус җирендә үз кесәсендә актарынган шикелле эш йөртүче сәрдәрнең кем булуын чамалады, ахры. Клязьма каласының язмышын ишетүгә үк ул якын-тирә авыллардан меңәрләгән олаучылар җыйды. Шулар яланнардан, ерымнардан кала янына кар-көрт ташыдылар. Шәһәр халкы шуны калыпка салып торды, су бөркеде. Нәтиҗәдә, Болгар гаскәре килеп житкән чакта, Рязань инде ике катлы боз дивары белән уратылган иде.

Атна-ун көн буе камалышта тоту, әле төнен, әле таңда һөҗүм итеп карау уңышлы нәтиҗәләргә китермәде. Болгарларның Муром, Клязьма калаларында җыйган ганимәтләре дә чиктән ашкан, аеруча Борһан җайдакларын яуга күтәрү симергән, маемлаган этне шып-шыр сөяк өстенә өсләтү кебек үк өметсез хәл иде. Лачын Хисами ахырда, Рязаньга кул селтәп, кире борылырга мәҗбүр булды.

Юньле хәбәр дә, юньсезе дә мәмләкәт эчендә яшендәй тиз йөри. Лачын Хисами үзе әле Казан кирмәненә дә кайтып элгәшмәгән иде, ә Биләр базарлары инде төрле гоманлаулар белән кайный башлады.

—Лачын батыр кяферләрнең дистәләгән кальгаларын алган, Вүлдәмир кенәзен сөннәткә утырткан, ди. Болгар җирендә мәмләкәтемезне вә гавамны яклауда аңа тиң батыр юктыр. Сәлим ханга Лачын батырны мәмләкәтнең баш сәрдәре итеп тәгаенләү лазим...

«Ярлы хыялы—бер капмак, би хыялы—бер чапмак», дип белми әйтмиләр шул. Лачын Хисаминың рус җиренә кылган уңышлы явы хакында хәбәр алуга ук Сәлим хан күнелен башка төр шом явыз корт шикелле кимерә башлады. Үз янына дәшеп ул моны баш вәзир Мәрчура колагына да ирештерде.

—Ошбу качак Хисами минем гамужәм әмир Хәсән белән тиктомалдан гына берегү кылмагандыр. Хисами, килмешәк, юхаланып куенга үткән елан сымак булды. Аны киләчәктә дә сарай эргәсендә асрап булмас. Фәрман язып хассә алайны ошбу еланнан бушат. Ул туплаган йөзлекне бүген үк куып тарат. Әгәренки ошбу угърыны яклап чыгучылар, ана кала капкаларын ачучылар табыла икән, андыйларны «Шайтан бугазы» зинданына ыргыту да кара халык өчен сабак булыр...

Төнге «ярканатлар» тарафыннан кат-кат кисәтелсә дә, Лачын Хисами, үз язмышын сынагандай, һич тә курыкмыйча Биләр урамнарына кайтып керде. Кала базарларын, бистәләрне дистәләгән шымчы айкап йөрде. Тик, ни гаҗәп,—һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр, гомумән, бөтен гавам авызына, әйтерсен, су капкан, Лачын батыр турында ишетүче-белүче кеше бөтенләй юк иде. Шулай да базар-урамнар яна хәбәрләрдән ара-тирә уянып-уянып алды:

—Лачын батырның нөгәре кичә төнлә ушкуйлар тозагыннан житмеш сәүдәгәрне йолып алган, диләр.

—Лачын батыр Кашан эргәсендә янә бер ушкуй кәрванын тар-мар иткән икән...

Ә яз үтеп җәй керүгә Бөек Болгар илен хәвефле яна хәбәр яшен сыман яндырып-көйдереп узды:

—Чулман, Чипса буйлап Болгар өстенә бихисап дошман төшә. Үткән кышта Лачын батыр кылган һөҗүм өчен Вүлдәмир кенәзе үзе болгарлардан үч алмакчы икән.

Мәмләкәт читендә торган тоткавыллар Сәлим ханга хәбәрләрне бәйнә-бәйнә кайтарып ирештерде.

—Урыс чирүен олуг кенәз Всеволод үзе житәкләп килә. Үзләренен алайлары белән Суздаль, Галич, Ростов, Чернигов, Переяславль, Смоленск, Новгород кенәзләре дә аның әләме астына килеп кушылган, ди. Киевтагы яп-яшь кенәз Изяслав та үзенен гамужәсе янына баскан. Мәгълүм хәлдер, Муром белән Рязань хакимнәре Владимир вә Глеб та Лачын Хисамидан үч алырга кыжрый. Глеб кенәз, дүрт улын да үзе белән алган. Всеволод кенәз шулай итеп үз канаты астына кырык меңнән артык яугир туплаган, Болгар өстенә мона тиклем күрелмәгән зур яу белән килә.

Чыннан да, бу Бөек Болгар әлегәчә күрмәгән олы бер яу иде. Ә үз гомерендә бер орыш та кичермәгән яшь Сәлим хан хәвефле хәбәрне алуга ук жылы мичкә куелган чүпрә сыман тәмам җебеп төште. Ул үзенең сараенда тимер читлек эченә эләккән тиен кебек әрле-бирле сугылды, ни әмир Хәсән, ни вилаять бәкләре һәм кала тарханнары янына чапкын юлламады. Сәлим хан, хәтта, баш вәзире Мәрчурага да өмет тотмый иде, шунлыктан һич югы аны булса да кинәш-унашка дип үз янына дәшеп карамады.

Ә ул арада Всеволод гаскәре инде һичнинди каршылык-киртә күрмичә Калачык, Чаллы, Кирмән кальгаларын сытып үтте, мәмләкәтнен үзәгенә керде.

Сәлим хан зиһенен жуйса да, халык уяу иде. Бер кичтә, карангы төшүгә, кемдер Мирхажи сәет йортының ишеген дөбердәтте. Сәет аны барып ачкач мондый пырдымсызлыктан бигрәк ишек катында Бәрәж мәчетенен имам-хатыйбы Госман хәзрәтне күреп гаҗәпсенде. Ә тегесе тын алырга да ирек калдырмады, шундук гозерен тезде:

—Мәмләкәтнен иминлеге хакында янучы-көюче ирләр Мөхәммәт-Бакырыя мәдрәсәсендә жыйналды. Мәмләкәт язмышы кыл өстендә, аларның һәрберсенә синең фикеренне ишетү тансык. Кичекмәстән, анык гамәл кылу өчен һәммәсе дә сине көтә булыр, сәет хәзрәт.

Кырт борылып кире кузгалганда Госман хәзрәт жилкәсе аша гына янә күз ташлады:

—Мәдрәсәнең капкасын узган чакта шартлы дәгъвәт—«Амин!» Кылган гамәлләребез Ходай Тәгаләнең шундый вакытына тәнгәл килсен, диеп аны шулай куштык...

Бакырыя мәдрәсәсенең дәрвишханәсенә килеп кергәч, Мирхажи сәет анда тезелешеп утырган ирләргә күз салды да кыенсыну хисе кичергәндәй булды. Зиһене аша ерак хәтирәләр йөгереп узды. «Кайчандыр минем дә шушылай яшерен фирка төзеп йөргән көннәрем бар иде бит. Ә хәзер мондагы яшьләрнең күбесен мин танымыйм да. Картаелган, каһәр, картаелган».

Келәм өстенә инеп дога кылгач, Мирхажи сәет бүлмәдәгеләрне янә күз уныннан бер кат кичереп чыкты. Түрдә Мәмле-Гомәр утыра, заманында дан вә шөһрәт алган шигырь остасы Сөләйман әл-Сувари углы, чыбык очырак булса да Мирхажига җигән тиеш кеше. Күрәсең, Мәмле-Гомәр җанында да, атасыныкына охшап, гыйсъянлык уты дөрләп янадыр, шул буйсыну калыпларын белмәү хисе аны яшерен фиркагә куалап китергәндер. Аның янәшәсендә кыпчак баһадиры Атбасар утыра, бер уйласаң, Сәлим хан таянган иң ышанычлы яраннарның берсе. Мәгәр юк икән шул. Хассә алай башлыгы да, менә, хан күзеннән яшереп җыелган фирка сафына баскан. Димәк ки, алай-болай булса, фетнә купса, ханны яклаучы юк. «Хәл-әхвәлең шактый дәрәҗәдә хөрти икән, Сәлим».

Мирхажи сәет карашын тәрәзә буена күчерде, каршында Рязань, Муром җирләрендә качаклыкта йөреп кайткан Чилбир бәкне шәйләп, бөтен тәне эсселе-суыклы булды. «Бәрәкалла! Болар инде Сәлим хан урынына яңа таждар да әзерләп куйганнар түгелме соң? Менә бит, ерак ара дип тормаган, Чилбир бәк Сувар каласыннан ук килеп җиткән. Болай булса, тәхет тирәсендә түнтәреш ясау да әлләни ерак йөрмәс».

Өстенә кара башлык, озын кара җилән кигән мәһабәт ирне күргәч, Мирхажи аның йөзендә ниндидер таныш чалымнар да тапкан кебек булды. Керфекләрен кыса төшеп бик озак күзләде, аптырагач башкаларга да күз йөгертеп чыкты, әмма бүтән берсен дә танымады.

Ниһаять, бүлмә түрендәге Мәмле-Гомәр дә Мирхажи сәетнең читен хәлен шәйләп алды бугай, сүз катты:

—Барчабызны да белеп бетермисең булыр, сәет хәзрәт, үзем таныштырыйм. Әнә ул, син гайре текәлеп күзәткән кара башлыклы ир, Лачын батыр булыр, гавам илә мәмләкәтебезне әлегәчә бердәнбер яклаучыдыр.

«Ә, менә нинди икәнсең бит син, билгесез вә сихри көч иясе!»—дигән хисләр кичерә-кичерә, Мирхажи янә лачын Хисаминың йөзенә багып алды, аның тарафыннан ягымлы караш күргәч, үзенең дә җаны гүя җылынып куйды. Ә Мәмле-Гомәр таныштыруын дәвам итте:

—Аның аръягында утыручы батыр—Сәмәрә бикәнең өлкән угланы Гази-Морат бәктер. Мәмләкәтебезгә дошман бәреп кергәч, дүрт меңгә тиклем азаматны алып, ул чакыруны да көтмичә үзе килеп җитте. Аның янәшәсендәге Гайсә, Латыйф, Гыйльман батырлар да Кашан, Кернәк, Тубылгытау калаларыннан берәр меңлек нөгәр алып килде. Шулай итеп, инде бүген үк мең яугирлек чирү пайтәхетебезне сакларга әзер тора. Мәгәр...—Мәмле-Гомәр беркадәр тын алды.—... Мәгәр пайтәхетне аңа тиклем безнең гамәлләргә аяк чалырдай бәгъзе хакимнәрдән арындыру фарыз.

Мәмле-Гомәр Мирхажи сәетнең уттай карашын очратты, ләкин каушамады.

—Әйе, син дөрес аңладың кебек, сәет хәзрәт. Безгә Сәлим ханны сарай эргәсеннән вакытлыча читкә этәрү лазим.

—Ошбу гамәл инкыйлаб, зур фетнә бит!—дип, Мирхажи сәет күкерттәй кабынса да, Мәмле-Гомәр каушамады.

—Сәлим хан яшь. Мәмләкәтебезгә дошман бәреп кергәч, көзге чеби сымак бәлтерәп төште. Ошбу көнгә тикле һични кылганы юк. Вә ниндидер отышлы гамәл кылуы да шикле. Чөнки ул әмир Хәсән атыннан да дер калтырап яши, һәр адымда шуның өрәген күрә. Сәлим хан иртәгә дә тәхет өстендә утырып кала икән, ана ярдәмгә атлыгучы көчләр булмаячак. Әтәчне бөркетләр, лачыннар өстеннән башлык итеп куясын

икән, тегеләре тавык кетәклегеннән дә биектәрәк очмый башлаячак, дигән рас сүз бар бит. Инде үзенә дә мәгълүм хәлдер, хәзрәт. Бүген безнен мәмләкәттәге гавам да, өске катламдагы бәк илә биләр дә икегә бүленеп яши. Бәгъзе өлеш Сәлим ханны яклый, икенчесе әмир Хәсән ягына аварга әзер тора. Өстебезгә дошман килгән чакта безгә аларнын һәр икесе артык. Әүвәл без мәмләкәтебезне дошман чиреүеннән азат итик, иминлекне саклыйк, ә тәхет казанында сонрак кайнашырбыз.

Мирхажи сәет «ә ошбу гыйсъян Мәмле-Гомәрнен акыл шәрифләре хак юлда бит», дип уйлап алды да, тамак кырып, үзе сорау бирде.

—Ә мин фәкыйрегездән ни таләп итәсез, нигә дәштегез?

—Без иртәгә Сәлим ханнан пайтәхетне ташлап китүен таләп итәчәкбез. Ошбу гамәл инкыйлаб та, түнтәреш тә түгел. Вакытлыча чигенеш кылу гына. Шулай итсәк, иртәгә үк пайтәхет сагына әмир Хәсән дә, Кашан, Кернәк, Мәртүбә бәкләре дә дәррәү килеп житәр. Дошман явыз, зур көч белән өстебезгә килә. Мәмләкәттәге барча көч вә алайларны бердәм йодрык итеп туплау фарыз. Без ният иткән ошбу гамәлләргә син дә үз фатиханны бирә күрсән иде, сәет хәзрәт.

Сәет уйга калды. Кайчандыр анын әтисе Давыт сәеттән дә «Илһун» фиркасен яшерен нигезләүче әжнәби Идрис хәзрәт, шагыйрь Сөләйман әл-Сувари, бакир хәзрәт, Корнай батыр, янә әллә нихәтле кешеләр фатиха сорады. Хәтта, Мирхажи үзе дә улчак этисеннән фатиха көтеп йөрде. Әмма Давыт сәет ниләндер нык шүрләде, фатиха бирмәде аларга. Ә сонынннан үзе фетнә башына басты, шунда катилләр анын гомерен кыйды. Менә, хәзер Мирхажи үзе дә нәкъ шундый ук хәлдә. Әгәр фатиха бирмәсә, ул гавамга, мәмләкәт иминлеген кайгыртучы батырларга каршы булачак. Ошбу батырлар, хәфиян фиркачеләр Сәлим ханга каршы фетнә кормаганмы? Бәрәж хан угылы булган Чилбир бәк тә ошбу тарафта, шаять, тиктомалдан гына утырмыйдыр. Мирхажи сәеткә оста фетнәчеләр корган пәрәвез оясына эләгү хәвефе янамый торгандыр бит? Сәлим ханны читкә тибәреп, тәхет тирәсендә канлы яу оештырырга тиеш түгел бит ул сәет кеше. Нинди гамәл кыласы сон ана, ничек хәл итәсе?

Мирхажи сәет бераздан тавышына корыч аһән өстәп дәште.

—Дилбегә вә йөгән алыштыру гына үшән атны ипкә-сапка кертми. Әгәр Сәлим ханны тәхетеннән алып анын урынына башка инсанны утыртырга ниятлисез икән, мәнге разый түгел. Ә инде мәмләкәт вә халык хакына дип пайтәхеттәге идарәне үз кулыгызга алырга жөрьәт итсәгез, һәммәгезгә хәер-фатиха миннән. Ният иткән изге гамәлләрегездә сезгә бердәмлек вә жинүләр насыйп әйләсә иде.

...Икенче көнне танда хан сараен менәрләгән инсан урап алды. Халык ташкыны куптарган тавыш-гауга кала диварларын дер селкетә, нииндидер көч кулланып бу ташкынны куарга, таратырга маташу учакка куыз ташлауга тин ялгыш гамәл иде.

—Биш кешедән хасил арадашчылар хан галижәнабләре хозурына узуны таләп итә,—дип хассә алай башлыгы Атбасар кереп әйткәч, Сәлим хан күркә сыман кабарынып һәм кукраеп маташмады, ризалыгын биреп, ияк какты.

Арадашчылар исеменнән таләпләрне Мәмле-Гомәр тезде:

—Үзенә кирәк кадәр хассә алай ал да, пайтәхетне калдыр. Сарай белән тәхет язмышына һич тә кысылмыйбыз. Болгар жиреннән дошманнарны кугач, әгәр мохтажлык туса, әмир вә бәкләр жыелып үзегез хәл кылырсыз. Мәгәр мәмләкәтне дошманнардан арчыгач пайтәхет юлы тәүге нисбәттә сина ачык булыр, мона икеләнмә...

Шәһәр халкында кузгалган дәрт һәм ялкын инде Мирхажи сәеткә дә килеп йоккан иде. Гавам белән бергә булырга омтылу хисеннән котыла алмаганга күрә, унике яшьлек углы Мөхәммәтгалине дә иярткеп, ул хан сарае каршындагы мәйдан эченә инде. Нәкъ менә шулчагында гади яугир сыман, иярләнгән чаптар өстенә менгән, ярымбөкерәйгән, өшәнеп һәм мескенләнеп калган Сәлим ханнын ачулы да, үпкәле дә

булган авыр карашы белән очрашты ул. Тәхетеннән тибәрелгән таждар үтеп барышлый ана сорау катты.

—Син пайтәхетне минем белән бергә ташламыйсыңмыни, сәет хәзрәт?

Мирхаҗи ныклы тавыш белән җавап бирде.

—Ханнар пайтәхеттән китә дә, кире аңа кайта ала бит ул, Сәлим углан. Ә сәет вә голәмә инсанга һәр вакытта ярлы халык хозурында булу отышлырак. Бигайбә, хан.

## 5

Балалары байтак булган өчен «Олы Оя» кушаматын алган һәм читят җиргә үз гомерендә тәүге тапкыр олуг поход белән чыккан Всеволодның төп максаты, әлбәттә, Биләр каласын—пайтәхетне яулау, шулай итеп бөтен Болгар илен тез чүктерү иде. Үз-үзен урыс хакимнәре арасында күрелмәгән данга күмү өчен ул сугышчан әләме астына дистәдән артык кенәзнең дружиналарын җыйды, әле урыс тарихы белмәгән күләмдә гаярь көч туплады. Урыс полклары Чулман буйлап Шишмә, Талкыш тамакларына кадәр булган араны тиз уздылар, шуннан соң гына кырык меңлек гаскәр походында четереклек туды. Болгарның яна башкаласы әллә кайда эчтә, шымчыларга, ертаулларга бөтенләй дә билгесез Чирмешән дигән елга буенда иде. Полкларга баркас-корабларны калдырып, җәяүле походка күчәргә туры килде. Яр өстеннән килгән җайдакларның саны унбиш меңнән артык түгел иде. Ләкин алары да, җәяүлеләр җаена яраклашып, ташбакадай хәрәкәтләнергә мәҗбүр булды.

Ярты көн буена туктаусыз атлый торгач, алларында Җүкәтау дигән кирмән калкып чыкты. Кала һәм аның янындагы бистәләр әлләни зур түгел, әмма имән бүрәнәләр белән катлы-катлы ныгытылган кирмән тез чүгәргә исәпләми иде. Всеволод килә-килешкә үк җәяүлеләр арасыннан җиде-сигез полкны, аларга өстәп өч-дүрт мең җайдакны һөҗүмгә ташлап карады. Кирмән диварлары баскынчыларны тоташ ук яңгыры очырып каршылады. Җитмәсә, җәяү атлый торгач полклардагы яугирләр дә нык йончыган, ярсу, ихтыяр, җиңүгә омтылыш хисләре сүнгән иде, күрәсең. Шуна күрә һөҗүм, орыш дигәннәре бик тә үшән чыкты. Ул арада инде, озак көттермичә, җир өстенә караңгылык иңде. Всеволод кенәз әмер биреп полкларны кире чигендерергә һәм япан кыр уртасында лагерь корып урнашырга мәҗбүр булды.

Ә төн уртасында Җүкәтау кирмәненә пайтәхеттән килгән чапкын үтеп керде. Үзе сүзгә саран, кыяфәте ярсу, усал. Таләбе дә каттый чыкты.

—Мине Уразай бәк хозурына илтеп җиткерегез. Йомышымны фәкать аңа гына ирештерәчәкмен.

Уразай бәк янына ингәннең соңында да чапкын сүзен кыска тотты:

—Пайтәхетне саклап кала алырдай көч-куәт бик санаулы гына. Барча вилаять бәкләре янына да, хәтта, инде кыпчак батырлары хозурына да чапкыннар җибәрелде. Ходай ярдәме илә алар, шаять, тиздән килеп житәр. Мәгәр ике генә тәүлек, өч кенә көн булса да син урыс алайларын үз кирмәнең эргәсенә бәйләп тотсаң иде, Уразай бәк. Пайтәхет башлыкларының, ябай халыкның сиңа булган гозер-үтенече шулдыр...

Икенче көн Җүктау тирәли барган тоташ орыш эчендә үтеп китте. Всеволод кенәз бу кирмәнне һаман көч, лаек киртә итеп исәпләми, шуңа күрә аның диварлары буена әле бер, әле икенче полкны уенга җибәргән шикелле генә озатып тора иде. Ләкин бер-бер артлы кабатланган һәр һөҗүм барышында урыс полклары ярга килеп бәрелгән дулкын сыман һаман-һаман арткы якка кайтарыла торды. Һәрбер һөҗүм һәлак булучылар һәм яралылар сафына яналарын өстәде.

Өченче таңда инде урыс яугирләре күнелендә ярсу, комар туды.Алар корбаннар, дивар тышындагы ерым эчендә калып изелгәннәр белән дә санлашып тормыйча кабат-кабат яуга күтәрелделәр. Вакыты-вакыты белән

баскынчылар болыты дивар өсләренә менеп житте, хәтта, кайчагында кирмән эчендә дә кыска-кыска гына орышлар булып алды. Әмма һәр очракта Жүкәтаулылар дошман көчен дивар өсләреннән әйләндереп атты. Баскынчылар сафында корбаннар саны һаман арта торды.

Карангылык инеп кабат лагерьга туплангач, кенәзләр һәм меңбашлар арасында ризасызлык, сукрану авазлары ишетелгәли башлады.

—Всеволод безне «пайтәхетнен үзен яулыйбыз, походка чыккан һәр сугышчы аннан кәрван-кәрван ганимәт туплап кайтыр», дигән коткы белән бирегә алып килде. Шулай булгач, без нигә дип ертык жилән дә эләкмәс хәерче бер кирмәнне камап ятабыз сон?

—Инде күпме туганнарыбыз яуда шәһит китте. Ә Всеволод үзенен корсагыннан да арыны күрә белми. Безгә бу кирмәнне калдырып йә пайтәхеткә юнәлергә, йә бөтенләй кире борылырга кирәк.

Хаким Всеволод башка кала кенәзләренен үзен ташлап китүеннән, гомумгаскәрнен кисәк таркала башлавыннан яман курка иде. Шуна күрә дүртенче тан атуга ук ул дружина башлыкларына яна фәрман бирде:

—Без Жүкәтау атамалы хәчтеруш бу кирмәнне кире кайткан чагында да таларга житешербез. Ә хәзер бөтен куәт белән алга, пайтәхеткә! Анда безне муллык һәм дан көтә.

## 6

Всеволод кенәз юкка гына үзенен сугышчыларын алтын таулар вәгъдә итеп комарлый, дәртләндерә, Биләр исә урыс дружиналары Жүкәтауны камап яткан арада имән диварлар артына байтак көчләр туплап куярга өлгергән иде инде. Мәмле-Гомәр чакыруы буенча пайтәхеткә, ин беренче булып, кашанлылар һәм суварлар килде. Алардан сон, бер тәүлек эчендә, имән диварлар артына сабакүлләр, чалматлылар, Зәй елгасы буендагы тәмтезлеләр, табынлылар инде. Мәртүбә вилаятендәге чирмеш белән арлар, Инсан бәкнен улы Көнгер кул астында булган башкорт жайдаклары Нокыш, Эстәрле буйларыннан Биләр диварлары янына килеп өлгерде. Беркадәр икеләндереп, көттереп булса да әмир Хәсән Казан кирмәнендәге үзенен курсыбаен Биләр тарафына юллады. Һәм, ин сонгы булып, кыпчак даласыннан да якты хәбәр килде.

—Биләр каласында үсеп киткән Көнчәк үзенен кул астындагы ун мен жайдак белән Болгар мәмләкәтенә ярдәмгә ашыга икән.

Пайтәхет эченә унар-унар менләгән гаскәр туплангач, башбаштаклык, мәхшәр булмасын дип, сәрдәр сайладылар. «Син мөремлеләр, рәзәнлеләр эргәсендә яшәп кайткан инсан, аларнын яу тәртибен дә яхшы беләсен булыр»,—дип кыстый-кыстый Чилбир бәкне гаскәр генә түгел, кала хакиме дәрәҗәсенә тикле күтәрделәр. Лачын Хисами таләбе буенча «Шайтан бугазы» зинданыннан анын өч йөз яугире чыгарылды һәм алар да кала сагына басты. Хәзер инде биләрлеләрнен күнел шәрифләре шактый түгәрәкләнде, кала урамнарына ышаныч һәм өмет нуры инде.

Всеволод кенәзнен исә күнел күзе генә түгел, хәтта, мангай күзе дә сукыр булып чыкты. Тинсез гаскәр жыеп иләсләнгән-һаваланган кенәз Биләр тарафына шымчыларын, ертаулларны да жибәреп карамады. Беркөнне урыс полклары кара тузан болыты куптарып Биләргә якынайды да, каладагыларнын күз алдында, япан кыр уртасында чатырлары, шалашлары белән лагерь корып куйды. Ә икенче танда инде Всеволод жайдак полкларнын һәммәсен дә һөҗүмгә ташлады. Баскынчылар сафы умарта күче шикелле кайнап тора, алар бихисап һәм куркыныч, кала диварларын төрле яктан сарып алган иде. Әмма инде пайтәхет тә ниндидер бер кеп-кечкенә Жүкәтау кирмәне түгел, ә кышкы өненнән чыккан ач, йолкыш аюны өстенә очлымын, көбәсен, калканнарын киеп, сөнге, садак, хәнҗәр һәм гөрзиләрен элеп каршылаган гаярь сунарчыга тин пәһлеван иде шул.

Биләр каласы да, нәкъ Жүкәтау шикелле үк, дошман сафын ук

яңгыры коеп каршылады. Көчле арбалетларга утыртылган кыска саплы сөнгеләр жайдакларны иярләреннән өзәңгеләре-ниләре белән суырып, йолкып атты. Житезлек һәм тәвәккәллек күрсәтеп шәһәр капкаларына якынайган урыс сугышчылары өстенә биек диварлардан кайнаган су һәм кайнар сумала акты. Беренче көнне үк Биләр диварлары буенда өч мең ир югалтып, баскынчылар кире чигенделәр.

Ә Чилбир бәк, канлы яудан соң тын алырга да ирек бирмичә, каладагы һәммә батырларны, менбашларны һәм биләрне үз янына дәшеп туплады да, әмер-фәрман тулы кыска нотык тотты.

—Дошманны кала диварлары эргәсенә якын жибәрү мәнфәгатькә ярашлы, муафыйк эш түгелдер. Өстәвенә кала әйләнәсендә диварларга терәлеп үк утырган йорт вә ихаталар бихисап. Дошманның диварларга да, шул йортларга да ут элүе мөмкин. Ошбу хәвефне булдырмый калу өчен диварлар тирәсендәге барча йортларны сүтәргә, кала белән бистәләр арасында махсус мәйдан хасил кылырга, ә мәйданга алып килә торган барча юллар, урамнар башына сүтелгән йортларның бүрәнәләреннән өстәмә дивар-калканнар төзеп куярга кирәк. Мин һәммә батыр вә бигә дә, аерым бистә сайлап, эш башларга боерам.

Меңбашлар һәм батырлар кала урамнары буйлап таралышкач кына, Чилбир бәк янына Лачын Хисами килеп мөрәжәгать итте:

—Үтә дә мактаулы вә отышлы гамәл хәстәрлисең, күнелем бик канәгать, афәрин, Чилбир бәк. Мәгәр син төнге «ярканатлар» алаен ошбу вазифадан азат кылсаң иде.

Чилбир бәкнең карашында усал очкын кабынды, сүзләре сытылып чыкты.

—Ә сез нинди югары катлам соң әле ул кадәрле?

—Юк, бернинди дә югары катлам түгел. Аерым өстенлекләр дә сорап аптыратмыйбыз. Без бүген төнлә диварлар аръягына чыгып Всеволод лагерына һөжүм ясарга карар кылдык. «Ярканатларга» яуга әзерләнергә вә тын алырга мөмкинлек бирү отышлы булачак.

Чилбир бәк берара уйга калып торды, аннары әйтте:

—Изге ниятең фәрештәләрнең амин, дигән чагына туры килә күрсен. Сиңа иминлек вә жиңү телим, Лачын батыр.

... Караңгы төн уртасында дала яклап билгесез жайдаклар алае өсләренә килеп ябырылгач, Всеволод лагерында коточкыч тәшвиш купты, әйтерсең лә, жиһан-жир чайкалды. «Душман! Душман!»—дип үкерә-үкерә урыс сугышчылары әле бер, әле икенче тарафка барып бәргәләнде. Аларның үкерү авазларын хәвефләнеп, иләсләнеп кешнәгән мeңәрләгән атлар тавышы күмеп китте. Өшәнгән, өреккән, тышау-йөгәннәрен өзгән аргамаклар бөтен лагерь буйлап чабулый башлады, аларның тояклары астында дисtәләгән ирләр аунап калды. Ә оясыннан аерылган кортлар күче сыман тузгыган, болганган, ис-акылын жуйган лагерь өстенә төрле яклап ук яңгыры һаман яуды, яуды, яуды...

Урыс лагерындагы һәр сугышчы таңны керфеген дә какмый каршылады. Озакка сузылган юлдан, авыр яудан, йокысыз үткән хәвефле төннән соң, әлбәттә, урыс яугирләре нык йончыган иде. Әмма мескен генә булып күренгән Жүкәтау кирмәнен дә яулый алмыйча ташлап китүләре, Болгар мәмләкәтенең пайтәхете янындагы тәүге штурмның уңышсызлыкка очравы, биләрлеләр оештырган төнге һөжүмнән соң купкан тәшвиш өчен хурлану хисләре урыс дружиналарын сыртына камчы эләккән чаптар шикелле ярсыта гына төште. Аеруча Киев каласыннан ук килгән яп-яшь хаким, Всеволодка жигән тиеш булган Изяслав кенәз чыгырыннан чыгып котырынды.

—Переяславльдәге бертуган абыем Игорь моның ише денсез басурманнарны ничек изәргә, сытарга кирәклекне күрсәтте бит инде.—Изяслав Игорьның кыпчакларга каршы ясаган походына һәм шул яу барышында Күбәк ханның әсир төшүенә ишарәли иде.—Әллә без Игорьдан кимме? Боларның да пайтәхетләре урынында көл генә калдырырга, ә ханнарын

ат койрыгына тагып урыс жиренә алып китәргә кирәк!

Всеволод әлеге жигәнен чиксез якын итә, шуңа күрә аның борнайлануына, көрпәләнүенә күзен йома иде. Бу юлы да Изяславның яскануына, адарынуына каршы тора алмады. Владимир, Суздаль, Ростов калаларыннан килгән җайдакларны аның әләме астына бастырды да яуга әмер бирде.

Тәкъдир дигәннәре Изяславка әүвәл хәерхаһлы булды. Ул төбәп кузгалган Кызыл-капу ягында Чилбир бәк фәрманы буенча йортлар сүтелсә дә, өстәмә дивар төзү эшләре төгәлләнеп житмәгән, кайбер һөнәрчеләр кача-поса гына әле һаман бүрәнәләр очлап, чокыр казып азаплана иде. Изяслав менә шул, әле төзелеп тә бетмәгән, өстәмә диварларны сытыпжимереп узды да, Кызыл-капу янына, һөнәрчеләрне сакларга дип чыккан жәяүле сугышчылар өстенә ябырылды. Саннары буенча ике йөзгә дә тулмаган биләрлеләр җайдакларга каршы тора алмады, һәммәсе диярлек кылыч йөзеннән кичеп жир өстенә ауды. Жиңү тантанасы белән иләсләнеп-шашып Изяслав хәзер инде Кызыл-капуга таба якынлашты. Ә бу вакытта капка күперләре яртылаш төшерелгән, бу тирәдә тоткавыллар бик аз, пайтәхеткә хәвеф яный иде.

Моны дивар өстендәге биләр, батырлар да тәгаен күреп торды. Ашыгыч чара күрмичә һич ярамый иде. Иң беренче булып, урыныннан кисәк ыргылып, Чилбир бәк кузгалды. Чаптары янына йөгереп барышлый ук кайнар әмерләре яңгырап ишетелде:

—Монысы урысларның ялган һөжүме генә булуы да ихтимал. Башка капуларны берүк ташламагыз. Каладагы барча халык дивар өстенә менсен.

Чилбир бәк атын камчылый-камчылый килеп житкән чакта Кызылкапу янында инде өч-дүрт йөзләп җайдак яуга ташланырга әзер тора иде. Алар арасында Лачын батырны, үзенең якташларын—суварлыларны да күргәч, Чилбир бәкнең күңеле үсенеп-очынып куйды. Тоткавыллар тарафына ташлаган әмере дә мәгърур, шанлы чыкты:

—Күперләрне төшерегез! Суварлылар, алга!

Беренче булып күпер өстеннән кырга, әлбәттә, Чилбир бәк үзе ыргылып чыкты. Аның иңбашына элгән алсу япмасы югары кайтарылып жилдә уйнаклый, шуңа күрә аргамагының ялына сыенып чапкан Чилбир бәк канатларын җәйгән дала бөркетен хәтерләтә иде.

Бер-берсенә дошман булган ике көч арасы күзгә күренеп кими башлады. Яшь, вәкарь Изяслав Чилбир бәккә каршы үзе чәчрәп чыкты. Биләрнең баш сәрдәре аңа таба кылыч тотып очса, Изяслав үзенең кулына авыр сөңге алды. Аннары инде ясалма мәйдан өстендә тимер чыңы гына яңгырап куйды. Икенче мизгелдә Чилбир бәк иярennән кубып жир өстенә очты. Авыр сөңге көбә аша үтеп аның касыгын ерып чыккан, сызлануларыннан ыңгыраша-ыңгыраша жирдә аунаса да, баш сәрдәр инде якты жиһан белән саубуллаша иде...

Дивар өстенә тезелгән биләрлеләр орыш азагын күреп «аһ» иттеләр, куркынудан йөзләрен капладылар. Ә яшь Изяслав кулларын күккә чөеп, яман кычкыра-кычкыра тантана итәргә тотынды. Ләкин вәкарьле, саксыз кенәзнең тантанасы озакка сузылмады. Лачын батыр очырган канатлы ук Изяславның муенына килеп кадалды һәм егермесе дә тулмаган япьяшь кенәз чаптарының ялллары өстенә бөгелеп төште.

## 7

Биләр каласы янында лагерь корып ятуның инде унынчы көне дәвам итә, әмма рус кенәзләре һәм меңбашлар үзләре дә моны пайтәхетне камалышта тоту, дип бәяли алмый иде. Аның каравы, төртмәрәк телле булган сугышчылар әлеге яуга кулай бәһане бик тиз уйлап тапты:

—Без күктән атып төшерелгән кыр үрдәге артыннан кереп сазлык уртасына баткан сунарчы хәленә калдык бугай инде. Ни сазлык безне

жибәрми, ни үрдәгебезне үрелеп алалмыйбыз.

Сугышчылар арасында купкан мондый коткылы, кадау сүзләрне, әлбәттә, Всеволод колагына да китереп ирештерделәр. Олуг кенәз моңа кул гына селтәде, чөнки үзенең аю өненә барып кергән сунарчы сыман мескен хәлдә калуын ул күптән аңлап өлгергән иде инде. Әлеге Болгарга каршы яу оештырган чакта ул ханның яшьлегеннән, тәхет тирәсендә туган низагълардан файдаланмакчы булып, җиңел җиңүгә өметләнгән иде. Әмма дошман басып керү Болгар халкын утка ташлаган мәгъдән шикелле укмаштырды, берләштерде генә. Хәтта, кыпчак кадәр кыпчак даласыннан болгарларга ярдәм килеп җитте. Ә Всеволод үзе һәркөн, һәртөн саен кабатланып торган яуларда ун меңнән артык сугышчысын югалтты, берни ота алмады.

Ләкин олуг кенәз өчен әллә кайдагы Смоленск, Переяславль, Чернигов калаларыннан килеп Болгар җирендә башын салган ун мең сугышчы түгел, ә үзенең яраткан җигәне, яшь Изяслав язмышы кызганычрак, кадерлерәк иде. Менә ничәнче көн инде аның карендәше әле уттай кызып, әле аңын җуеп газаплана. Всеволод көненә ничә мәртәбәләр аны әле саф, җиләс һавага чыгарттыра, әле чатыр эченә кертә. Вакыт тапкан саен янына килә, җигәненең газапларын күреп кайчак аңа үз җанын бирердәй хәлләргә керә.

Бүген дә ул, иртәдән бирле җиһандагы барча кайгыларын, хәвефләрне онытып, Изяслав җигәне янында изаланып йөрде. Өйлә вакыты якынлашкан чакта Новгород кенәзе Владимир кереп, аның колагына көтелмәгән яңалык пышылдады:

—Биләр капкасыннан сабый бала җитәкләгән бер карт чыкты. Кулына ак әләм күтәргән, бирегә таба килә.

Олуг кенәз гаҗәпләнеп куйды, дала уртасында утырган ялгыз өй тәрәзәсеннән җемелдәүче ут яктысы шикелле ымсындыргыч уйларны зиһен тәгәрмәче аша тиз-тиз әйләндерде. Солых тәкъдим итүче микән бу, әллә... әллә биләрлеләрдә инде оборона тотарлык, үзләрен якларлык җегәр-көч беткәнме? Алар да ач, инде ун көн буена кала диварыннан читкә чыга алмый бит. Бәлки, калада Всеволод сугышчылары өстенә яудырырлык сөнге белән ук та калмагандыр. Каланы саклаучылар арасында үзара низагъ кубып, дошман каршында тез чүгүне яклаучылар да табылуы мөмкин. Андый очракта әлеге арадашчы каршына катгый шартлар куймыйча, шәһәр капкаларын ачуны, сүзсез-шартсыз бирелүне таләп итмичә дә булмас.

—Барлык каравылчыларга фәрман җиткер, арадашчы-илчегә ата күрмәсеннәр. Аны бирегә үзең алып кил,—дип тиз-тиз генә әмер бирде дә, Всеволод өстенә көмеш җепләр белән чигелгән җиләнен киеп алды, сабына асылташлар тезелгән кылычын биленә такты.

Берникадәр вакыттан соң, олуг кенәз каршына Болгар дәүләтенең баш сәете Мирхаҗи килеп басты. Улы Мөхәммәтгалине кысып җитәкләгән, өстенә күз явын алырдай ап-ак күлмәк кигән, йөзе тыныч иде.

—Нинди шартларда бирелергә җыенасыз, сөйлә, илче,—дип олуг кенәзнең кәпрәеп эндәшүен ишеткәч, Мирхаҗи сәет көлемсерәп куйды.

—Без бирелергә дә җыенмыйбыз, мәмләкәтебез дәрәҗәсенә зыян китерердәй шартлар да булмаячак.

Олуг кенәзнең йөзе озак вакыт буе кояш нурлары астында яткан яшь бәрәңге сыман яшелләнеп чыкты, теле көрмәкләнде. Тау төшкәндә аякларын үрәчәгә терәп, дилбегәсен чорнап тарта-тарта гына юргасын тыя алган мескен олаучы шикелле, Всеволод та күкрәгендә кайнаган ярсу хисләрен көч-хәл белән басып, ниһаять, яңа соравын бирде:

—Син нинди вәкаләтләр, нинди максат белән чыктың соң, алайса?

—Мин Болгар мәмләкәтенең баш сәете, кенәз. Ягъни, Аллаһ колы, аның арадашчысы. Бәс, шулай икән, миңа ике дәүләт, аларның хакимнәре арасында илче булып йөрү дә язык гамәл түгел.

—Минем белүемчә, Биләрдә хан юк бит. Сез аны пайтәхеттән

куып чыгаргансыз. Өстәвенә, кала бәге булып калган сәрдәрегез дә вафат. Димәк, хакимегез, башлыгыгыз гел юк. Сез көтүчесез калган сарык көтүе сыман. Шулай булгач, син кем исеменнән генә сүз йөртә аласын соң, илче?

Всеволодның дошманына, көндәшенә очып куну түгел, бәлки затлы каурыйларын, муенындагы катлы-катлы бизләрне күрсәтү өчен генә ихатада кабарынып, борнайланып йөргән күркә шикелле кәпрәя башлавын анлады да, сәет каушамады.

—Ә син юкка гына сөенәсен, кенәз. Житмәсә, буранда адашып жил уңаена гына атлаучы юлаучы шикелле тирән хаталанасын. Мәмләкәтне ханнар сакламый, аны гавам яклый. Гавам зилзилә, туфандай ярсып куба икән, ул тәхетләрне дә әйләндереп ата, мәмләкәтен дә сонгы күлмәген салып нарасыен жил-янгырдан каплаган ана кебек саклый. Ә тәхеткә күтәрердәй, яна хаким яки яна сәрдәр итеп куярдай бәкләр вә батырлар теләсә кайсы дәүләттә дә һич бетәчәк түгел.

Всеволодның йөзе, карашы еллар буе чүпрәк, су күрмәгән тәрәзә пыялаларына охшап тоныкланды, күнеленә корт инде. Бу илче карт һичбер тарафта да боргаланмый сөйли, ачы хакыйкатьне ярып сала. Всеволодның үзенә дә Сәлим хан язмышы янап ятмый микән? Ул походка чакырганда Смоленск ирләренә дә, Новгородныкыларга, башкаларга да тау-тау ганимәтләр, жину һәм дан вәгъдә иткән булды. Пайтәхетләрен яулыйбыз, бөтен илне тезгә чүктерәбез, дип күпме күкрәк сукты. Ә асылда исә болгарларның бер генә каласын да яулый алмады, ун мен ир югалтты. Хәзер, әнә, кашанлылар, жүкәтаулылар, корым-чаллылылар бергә жыелып, Чулманда Всеволод калдырып киткән каек һәм корабларга һөжүм иткән, аларны саклаучы Белоозеро полкын тулысынча кырып салган, диләр. Моны ишеткәч лагерьдагы Рязань, Чернигов, Галич кенәзләре баш калкытты. «Булдыксыз Всеволодка ияреп йөрүнең нинди хажәте бар? Һаман бер төрле дә чара күрми икән, кайттык-киттек. Юлда мукшы йә ар аймакларын булса да талап чыгарбыз әле»,—дип, аларның коткы таратып, ризасызлык белдереп сөйләнгән сүзләрен олуг кенәз көн дә ишетеп тора. Ә шулар иртәгә Всеволод гаскәрен бөтенләй ташлап китсә? Йә түнтәреш оештырып аны олуг кенәзлектән алып атса? Болар өстенә, шул ук кенәзләрнең, жәллад яллап, анын гомерен үк кыюлары да бар бит. Димәк, Всеволодка нинди дә булса чара күрмичә, бәкегә төшкән йомычка сыман бер урында бөтерелү-таптанудан котылмыйча һич ярамый. Тибенмәгән тавык ач кала, ди. Ни хәл кыласы соң?

—Илче, син нинди тәкъдим индермәкче безгә?—дип телгә килгән Всеволодның соравы барыбер дә коры, ипсез чыкты.

—Гап-гадидер, кенәз. Пайтәхеткә тикле үтеп ун көн буе отышсыз яу кылуың яшь тавыклар янында әйләнгәләп йөргән карт, дәрмансыз әтәч таптануына гына охшап калды. Биләрнең тез чүгәсе, ә синең жинәсең юк. Гаскәрендәге Аллаһ колларының гомерен кызган. Кит син, кенәз.

Ачыну-көчсезлектән уртларын шыгырдатса да Всеволод күнелендә һаман өмет уты яна иде әле, шул соравын катты:

—Ә сез мина күпме ясак түләргә жыенасыз?

Мирхажи сәет кыя шикелле басып жавап тотты:

—Ясак түләү жинелүне, буйсынуны тану буладыр ул, кенәз. Ә Болгар мәмләкәтенең һичбер вакытта да үзен мескен яисә кол итеп таныйсы юк. Син бер генә тиен дә ясак өмет итмә.

—Мин ни пычагыма дип чигенергә тиеш соң алайса?

Всеволодның әлеге ярсу соравына да Мирхажи сәет жәйге янгырныкы сыман ипле, талгын тавыш белән жавап бирде:

—Гаскәренне саклап калу бәрабәренә, кенәз. Аллаһ колларын туган жирләренә исән-имин кайтарып житкерү өчен. Без сина Чулман дәрьясына тикле булган юлны ачачакбыз.

Олуг кенәз ваклана башлавын үзе дә тоймый калды:

—Ә кораблар? Сез мин Чулманда калдырып киткән каек белән

баркасларга кадәр тартып алгансыз бит.

—Аларын да бирербез. Тоткарлык ясаучы булмас.

Всеволод инде тагын нииндирәк отышлы-кулай таләп куярга белмичә йөди-үрсәләнә башлаган иде, шулчагында чатыр түрендәге пәрдә артында моңа кадәр һушсыз-хәрәкәтсез яткан Изяслав җигәненең тирән ыңгырашу авазы ишетелде. Олуг кенәз сикереп аягына басты, ә яралы Изяслав аны инде чакыра ук башлады.

—Аг-гай, аг-гай.

Всеволод яралы җигәнен каплап торган пәрдәне кисәк йолкып эчкә томырылды, түшәктә яткан Изяслав янына барып тезләнде.

—Ун көн буе өнсез-тынсыз яткач, ниһаять, анга килдең. Ходайның рәхмәте, савыгасыңмы әллә, туганкаем?

Изяслав эндәшмәде. Всеволод пәрдәне йолкып атканнан соң, бөтен чатыр эче ачылып калган һәм яралы яшь кенәз көтелмәгән кунакларга текәлеп ята иде. Иреннәрен авыр кыймылдатып шулар хакында сорады.

—Болар кемнәр, агай?

Всеволод ашыга-ашыга тезде:

—Илчеләр алар, илчеләр, туганкаем. Биләрдән килгәннәр. Тынычлык турында солых тәкъдим итәләр. Чулманга кадәр юлны ачмакчылар.

Изяслав карашын Мирхаҗи йөзеннән анын малаена күчерде.

—Ә монысы кем?

Агарынган, кипшенгән Изяславның кыяфәте бик кызганыч иде, Мирхаҗи да вакыт сузып тормый җавап бирде:

—Минем угылым бу. Аты Гали булыр.

—Гали,—дип акрын гына кабатлады да, Изяслав сыңар кулының бармаклары белән чакыргандай итте. Әтисе дә аркасыннан эткәч, Гали карышмады, Изяславның янына килеп басты. Көттереп кенә булса да яралы яшь кенәз янә телгә килде:

—Минем кылычым кайда? Аны шушы малайга бир, агай.

Сәер тәкъдим шактый аптыратса да, Всеволод түшәктән бер читтәрәк яткан авыр кылычны эләктерде, ашыгып-каударланып аны Галигә таба сузды. Ә Гали кулларын артка яшерде дә, шактый кыю төс-кыяфәт белән кисәк каршы төште.

—Ә ул миңа кирәкми. Мин гомеремдә дә кулыма кылыч тотачак түгел.

Ун-унике яшьләрдәге малайның чатылдатып рус телендә җавап бирүе дә, андагы кыюлык һәм имәндәй ныклык та һәр кенәзне капылт сискәндерде. Хәтта, чатыр уртасында торган Мирхаҗи дә улының тискәрелеге өчен нык сагая калды. Әмма тынлыкны янә яралы Изяслав өзде.

—Ә синең кулларың нәрсә тотачак соң?

—Каләм.

Мондый катгый, төгәл җаваптан соң байтак тын тордылар. Ахырда гыжылдый-гыжылдый Изяслав үзенең гозерен ирештерде:

—Син боларның тәкъдимен кабул ит, кенәз агам. Болгар җирен калдыр. Әйдә, илгә кайтыйк...

Изяслав тагын аңын җуйды. Яшь кенәзнең керфекләре бу юлы мәңгелеккә, кабат ачылмаска ябылган иде инде.

## 8

Рус гаскәре икенче танда ук урыныннан кубып, кайтыр юлга чыкты. Ләкин гаскәр сафында башбаштаклык, мәхшәр канат ярган, ганимәт, зиннәт талау өчен генә килеп кушылган аерым-аерым кала кенәзләре Всеволодка буйсынудан туктаган иде инде. Шулар юлда олуг кенәз әләме астыннан чыгып, якындагы вак-төяк кирмәннәргә, авылларга ташланды. Әллә ничә авыл һәм бистәләрне ялкын чорнады, йөзәрләгән болгарлылар урыс чаптарларының тояклары астында калды. Хатыннарны һәм яшь

кыз-кыркынны явыз баскынчылар үзләренә кәнизәклеккә алып китте.

Рус гаскәре кылган мондый мәсхәрә көне-сәгате белән пайтәхеткә килеп ишетелде һәм Биләрдә тупланган һәммә чиру мәмләкәтнең иминлеген саклау өчен яуга күтәрелде. Аеруча Биләргә сонарып килгән Көнчәк жайдакларын тотып тыешлы түгел, алар үчкә, канга, яуга сусый иде. Ата-анасын, уяулыкны оныткан һәм Болгар жире буйлап ярма сыман сибелгән-таралган баскынчыларны, беренче булып, шул кыпчаклар төмәне куып житте. Кече Чирмешән ярында кузгалган тәүге орышта ук алар Смоленск һәм Муром полкларын кырып салды. Елганың икенче ярыннан килгән Лачын Хисами яугирләре һәм башкорт жайдаклары Рязань полкларын пыран-заран китерде. Рус гаскәре шушы орышларда янә биш меннән артык сугышчысын югалтты, арбалардан һәм такта-бүрәнәдән ыстан кора-кора вак-төяк кала кенәзләре тагын Всеволод канаты астына басарга мәжбүр булды. Болгарлылар һаман аларны әтәч сыман сикереп-сикереп чукуын дәвам итте. Всеволод Новгород кенәзе Владимир кул астына байтак жайдак биреп, тулгаманы өзәргә тырышып карады. Ләкин әлеге һөжүм угы Лачын Хисами «Ярканатлары» саклаган арага туры килде. Лачын батыр Новгород кенәзе белән үзе бергә-бер орышка керде һәм шунда аның кулын чабып өзде. Урыс яугирләре янә арба-калканнар белән уратылган ыстан артына кереп качарга һәм Чулманга кадәр болгарлылар тулгамасында чигенергә мәжбүр булды.

Биләр тулысынча диярлек гаскәрсез һәм саксыз калган иде. Аның шушы көчсез халәтеннән Сәлим хан оста файдаланды. Ул үзенең хассә алаена өстәп, Тубылгытау кирмәненең жайдакларын алып килде дә, беркөнне һичкем көтмәгәндә пайтәхет урамнарына бәреп керде. Шул кичтә үк барча капкалар бикләнде, тоткавыл һәм шыгавыл нөгәрләре баш-аягы белән алышынды, халык йортларына, хәтта, базларына тикле кереп качты, шәһәрне тоташ хәсрәт, шом һәм хәвеф басты.

Тәхет турында янып көя-көя суга тилмергән сәхрә сыман коргаксыган Сәлим хан, әлбәттә инде, беренче эш итеп сараена ингән һәм үзенең бәхет, хыял куначасына менеп кунаклаган иде. Карангылык якынлаша-фәлән дип тормады, ул үз янына хассә алай башлыгы Атбасарны дәште.

—Елыйсы килгән бала атасының сакалын тартып уйный, ди. Фетнәгә ялкын элдергән Мәмле-Гомәр белән гыйсъянчы сәетне тап. Бәгъзесен дә зынжырларга урап минем алга китер.

Авызына кайнар аш капкан шикелле куырылса да, кыпчак баһадиры сүзләрен кистереп тезә-тезә каршы төшеп карады.

—Калага ингән мәлдә син бәгъзе инсанның да гомерен кыймаска, кан коймаска вәгъдә кылган идең, ханиям.

Ханның ядрә шартлаган сыман усал тавышы янгырап ишетелде.

—Мин дар агачы, аркан хәстәрлә, дип фәрман кылмадым бит әле. Вакыйгаларны ни пычагыма болай куалыйсың? Аннары ул гавам, пайтәхет диварлары аръягына кайтып төшәчәк биниһая чиру белән шаярырга да башыма тай типмәгән. Мин ул гыйсъян башлыкларын бүтән төрле жәзага тартып гавамга сабак бирәм.

Сәлим хан тәхетне кабат яуларга, дип походка чыккан чакта Атбасарга мәмләкәтнең баш сәрдәре урынын вәгъдә иткән иде. Беркатлы кыпчак баһадиры улчакта да аумакайлык күрсәтте һәм үзенең тәбедәге тычкан икәнлеген анламыйча хәзер дә күнде. Хассә алай газиләре Сәлим хан каршына әүвәл каеш арканнарга уралган Мәмле-Гомәрне, бераздан инде Мирхажи сәетне дә китереп бастырдылар. Ияр хужасы Сәлим хан иде шул, тезгенне ул тотты.

—Гавам—ул эт кеби, таждарларның йомшаклык күрсәтүен сизеп алдымы, хәзер өрә башлый, дигән гайре гыйбрәтле гыйбарә барлыгын бишектән бирле ишетеп үскән, мәгәр мона битараф калган идем. Инде авыз пеште. Кара халыкка уч төбен күрсәтү харам гамәл икән. Үземнең зиһенле шәкерт икәнлекне дә рас кылырга кирәк. Чөнки тинтәк хужа

гына үз йортында ике кат ут чыгара. Ә мин киләчәктә мондый хилаф эшкә—фетнә кубу, янгын чыгуларга—һич тә ирек бирмәм.

—Ике калҗа ризык кабып кына бәгъзе бүренең дә тәгамь тишеге туймый. Йоны ел саен коелса да, андый җанвар холкы үзгәреш белми бит ул,—дип, әүвәл Мәмле-Гомәр сүз әйтеп калырга ашыкты, аны Мирхаҗи да шундук эләктереп алды.

—Гавамдагы ризасызлык-нәфрәт һичбер вакытта да сыңар кисәү генә түгел, таҗдар. Аны йодрык, камчы белән төеп кенә һич сүндереп булмый. Ә камчы гына уйнатып утырган җайдакны бәгъзе ат та үз өстеннән чөеп ата. Сәясәтен-кәгъбәң элеккечә дәвам итә икән, фетнә-түнтәреш сукмагына аяк басучылар бик күп булыр әле.

Ярасына дары сипкән сыман ярсый гына төшкән Сәлим хан, аяк тибеп, шыгавылларына катгый әмер бирде.

—Ошбу гыйсъянчы мөртәтләрнең кул-аягына зынҗыр индерегез! Мәмле-Гомәр җимереп юк ителгән Алабуга калдыгы—Шайтан каласына илтеп тоткынлыкка ябылсын. Аны, өстәмә зынҗырлар тагып, манара диварларына бәйгә утыртсыннар. Ә Мирхаҗи ошбу көннән алып мәмләкәт сәете түгел. Эт симерсә, хуҗасын талый, диләр. Мондый кадер белмәс бәндә, әнә, бабасы көн күргән Болгар каласына олаксын да, шундагы Хәсән мәсҗедендә гади мөәзин булсын. Мәгәр аны зынҗырлардан коткарырга җөрьәт иткән сатлык гыйбад табылса, андый бәндәләрне үзем үк дарга асам.

... Биләр халкы усал җайдаклар тулгамасындагы ялгыз олауга утыртылган Мирхаҗи белән аның унике яшьлек Галиен кан елап, сыкрап озатты. Халык Мирхаҗины гаделлеге өчен бер яратса, Җәмигъ мәчет мөнбәреннән янгыраган моңлы тавышын көмеш чыңына тиңләп, үз артында аны «Нәкъкар» дип тә олпатлап йөртә иде. Ә сабый чактан бирле ана назын күрми үскән Гали болай да бик кызганыч иде, өстәвенә аңа Сәлим хан хөкеменең усал канаты да китереп суккач, тәхет иясенә ләгънәт яудыручылар саны аз булмады.

—Сәлим, йөзе кара, шәриф сәетемез илә ятим баланы рәнҗетеп, үзенә гөнаһ җыя. Тәхет дия-дия күзе сукырайды, вөҗданы коргаксыды микәнни соң ул залимнең?

—Таҗдар өчен вөҗдан—яшь егет түшәгенә салган әби сымак бит ул, аңа хаҗәт юктыр.

—Юкка, юкка гына азына, Сәлим хаким. Казанга ничек кычкырсаң, шулай җавап бирер. Мирхаҗи сәетемез дә, ул ятим Гали олан да ханга азау тешләрен күрсәтерләр әле...

Болгардагы Хәсән мәчетендә мөәзин вазифаларын башкаруга керешкәч, Мирхаҗи күзгә күренеп ябыкты һәм кипте. Шулай да тавышы һәм моңы көчле, аһәнле иде, «Нәкъкар» дигән аты монда да онытылмады. Ләкин көзге янгырлар башлангач, Мирхаҗи хәзрәтне яман суык бәрде. Аны йөткерү һәм ютәл чылбырга утыртылган эт шикелле һич калдырмый, һаман саен ныграк талый башлады. Хәзер инде аңа кул-аягы богауланган килеш Хәсән мәчетенең түгәрәк таш баскычлары буйлап көненә биш мәртәбә манара очына менү олы газап, авыр җәза иде. Беркөнне шул текә баскычлар буйлап кулына таяна-таяна үрмәләгән чакта Мирхаҗиның кисәк аягы таеп китте һәм ул, тимер зынҗырларын дөбер-шатыр китереп, таш идәнгә очты. Мәчет мөтәвәллиләре килеп җиткән чакта хәзрәтнең тәне суына башлаган иде инде. Кемдер теш арасыннан гына сытып пышылдады:

—Карт агачны күчереп утыртмыйлар бит ул, ай-һай, утырмыйлар...

Гали олан җиһанда дөм-ятимә калды.

## Унтугызынчы бәйләм

### 1

Тимучин өчен беренче айларда коллык тоташ газап, ут эчендә узды. Тайжутларның, уранхайларның бала-чагасына тикле аны үчекләп, типкәләп китүе бер хәл, Тимучинга әле кабилә бәге Торгытай да көнаралаш диярлек камчы сыдырып үтә, әмма иң яманы: шушы хаким ирешкән уңышлар турындагы һәрбер яңа хәбәр аңа ярасына тоз сипкәндәй тәэсир итә иде.

—Торгытай үзен Бүрежигәннән бирле тамыр җәйгән бөтен магул кабиләләренең юлбашчысы итеп игълан кылган. Ул элек Тимучин-тотык батыр булып торган кыят кабиләсен Керулен буеннан куган. Хәзер инде гомер-гомергә кыятлыларның бишеге саналган Онон ярларын да үз биләмәләренә кушарга җыена икән...

Тимучин үзенең көчсезлеген-мескенлеген аңлый һәм шушы чарасызлык аның җелегенә эчтән зәһәр елан сыман талый, суыра иде. Ул ничә еллар буена ялгыз яшәп, сусар-йомран аулап җанын саклап калды. Соңыннан инде, ниһаять, үз кул астына янә ун меңгә якын җайдак туплауга иреште, мәркет кабиләсен тар-мар итеп кайтты. Кыятлылар кабиләсе тау битеннән тәгәрәгән кар йомгагы сыман һаман зурая, һаман куәтләнә бара иде. Ләкин ачыгавызлык, саксызлык күрсәткән бәхетсез бер очрак Тимучинны, менә, кол итте дә, кыятлылар язмышын язгы боз кузгалып дәрья, ташкын уртасында калган бичара хәленә куйды. Тимучин үзе дә аларга һичбер ничек ярдәм итә алмый, тегеләр дә кайсы як ярга чыгарга белмичә йөдәп бәргәләнә. Дәрья уртасындагы бичара, ниһаять, бер як ярны сайлап, боздан-бозга сикерә башласа да, барыбер, ахыр чиктә чыланмыйча, егылмыйча калмый. Балдак-Далага җыелган кыятлылар да Тимучин коллыктан котылып кайтканчы, мөгаен дә, таралырлар, азаерлар инде. Билгүтай белән Хасар да, Бавырчы белән Җәлмә дә, шаять, алар өчен сизгер, маһир котүчеләр булып кала белмәс. Тимучин аларга һич югы берәр төрле хәбәр җиткерә алсын иде, ичмаса...

Әллә нинди антлар эчә-эчә ул бер сәүдәгәрне ялламакчы булган иде дә, теге икейөзле бәндә аны тайжут бәгенең үзенә барып сатты. Котырынып килгән Торгытай Тимучинны бөтен кабилә каршында ярсый-ярсый камчылап кына калмады, кул-аягына да агач башмаклар кидереп, аны җир астына чокып ясалган тирән баз эченә ыргыттырды. Көн яктысы һәм рәтле ризык күрмичә Тимучинның әллә ничаклы ай гомере шунда үтте. Сөзешкә ашкынган ярсу тәкә шикелле янадан-яңа яуларга атлыгып торучы Торгытайга берзаманны меңәрләгән нәүкәрләренә өләшерлек сугыш кораллары кирәк булган икән. Арба тәгәрмәчләрендәге, агач мичкәләрдәге кыршауларны салдырып та хәнҗәр белән ятаганнар ясауга керешкәннәр. Иртә таңнан кара төнгә хәтле эшләсәләр дә, осталар өлгерә алмый башлаган. Тимерче Җирсүдәй белән аның унбиш яшьлек улы Сүбүдәйгә ярдәм итәр өчен Тимучинны да баздан чыгардылар.

Сандал, мич күреге янында үзен бик коры тотса да, Җирсүдәй Тимучин өчен көтелмәгән хәзинә, алтыннарга биргесез остаз булып чыкты. Төнге ялга тукталган бер кичтә ул аны тәүге соравы белән үк утка салды.

—Менә сез, Торгытай белән икегез дә, яңа далалар, яңа елга-сулар яулыйбыз, дип азынасыз инде. Мәгәр дөньяда әле сезгә кадәр үк, элек заманнарда, ерак бабаң Аттила белән Искәндәр Зөлкәрнәен атлы олуг җиһангирлар булган бит. Әллә никадәр мәмләкәтләр, ярты җиһанны яулап та алар һичбер төрле уңышка ирешмәгән, төзегән дәүләтләре соңыннан керәч җамаяк шикелле чәлпәрәмә килгән, юкка чыккан. Сезнең берәрегез алар хакында ишетеп белә микән?

Тимучин өчен дә, унбиш яшьлек Сүбүдәй өчен дә әлеге исем иялере күктәге йолдызлар, диңгезләге балык кебек үк ерак һәм сәер

затлар иде, икесе тиң әсәренеп калды. Тимучин гына беркадәр тын торгач, ерак бабаларының исемнәрен санап китте.

—Бәртән, Кабул хан, Томавыл мәргән, Байшоңкар атлы бабаларым булганлыгын беләм. Алардан да алда Кыят, Көрән Бүре, Бүрежигән дигән бабаларым булган. Магул ыруына әнә шул, Бүрежигән атлы, бабам нигез салган, диләр. Ә Аттила миңа кайсы яктан килеп бабам тиеш?

—Син иң күп дигәндә дә моннан өч йөз, дүрт йөз еллар элек мәгыйшәт кылган бабаларыңның гына исемен санадың шул. Ә Аттила бабаң җиде-сигез йөз еллар элгәре үк гомер итеп, ошбу җиһанны кичкән. Искәндәр Зөлкәрнәен атлы җиһангир исә моннан мең дә биш йөз еллар элек үк яшәгән. Инсаният тарихы олуг дәрьялар кеби очсыз-кырыйсыз бит ул. Андагы вакыйгалардан сабак, гыйбрәт кенә ала белү кирәк.

—Атам, сөйлә, сөйлә. Аттила илә Искәндәрнең һәр икесе хакында да сөйлә,—дип, мич күреге ягыннан Сүбүдәй килеп, әтисенең җиннәренә тигәнәк сыман ябышты. Күзләрендә шайтан ут кабызды, диярсең, алар тоныкы кына янган күмерләр яктысында да ялык-йолык килеп тора иде.

—Ярар, сөйлим алайса, тыңлагыз,—диде дә, Җирсүдәй иреннәрен ялмап куйды.—Мәгәр миңа тарихны Искәндәр Зөлкәрнәен аты белән, элгәрерәк заманнардан башлап китү отышлырак булыр.

Тимучин белән Сүбүдәй, авызына керердәй булып, тимерче остага текәлеп утырдылар. Җирсүдәй акрын гына тарих төбенә күчте.

—Искәндәр—җитмеш дәрья, җитмеш дала аръягындагы Иллада атлы мәмләкәттән чыккан олуг җиһангирдыр. Әүвәл аның әтисе якын-тирәдәге дәүләтләргә каршы яу башлаган, барчасын да үзенә буйсындырган. Соңра инде ошбу эшне егерме яшьлек угылы Искәндәр дәвам иткән. Ул Тимер-Капка, Шам, Афина, Рум, Мисыр дигән җирләрнең һәммәсен басып алган...

—Һе, Торгытайның шәхси нөгәрендәге кишектин Сорхан-Шир дә шул Мисыр дигән илдән түгелме соң? Аны зәнҗи[1] илә гарәп катыш шул яклардан туганнары безнең сәүдәгәрләргә сатып җибәргән, диләр.

Сүбүдәйнең бүлдерүе ошамады бугай, «шулайдыр, шулайдыр», дип кенә җавап кайтарды да Җирсүдәй, янә үз эзенә төште.

—Нәфсе дигән нәгаләт авызлык вә йөгән белми бит ул. Искәндәр дә теге мәмләкәтләрне генә бик азсынган, хәзер инде бөтен җиһанга бугалак салмак булган. Ошбу ният илә безнең тарафка юнәлгән, угыз, казакъ, карлук, фарсы, уйгур җирләренең барысын басып алган. Аннары инде көньякка таба юнәлеп гарәп, индус җирләренә тиклем үтеп кергән. Мәгәр ошбу җиһангирның коры холкы, нәфес тыя белмәве, саранлыгы аның яраннарына, сәрдәрләренә бер дә ошамаган. Шулар астыртын түнтәреш хәзерләгәннәр, ошбу хыянәттә җиһангирның хатыны да катнашкан. Шул елан җамаякка салып аңа агу биргән. Ярты җиһанга бугалак ташлаган, мәгәр үз хатынын йөгәндә тота белмәгән Искәндәр Зөлкәрнәен менә шулай итеп утыз өч яшендә Мәңгелек Күк Тәңре хозурына күчкән. Ә аның вафатыннан соң угыллары, сәрдәрләре, яраннары арасында үзара сугыш купкан. Шулар Искәндәр бөртекләп, башаклап җыйган олуг мәмләкәтне ямаулыкка да ярамастай кырык төрле кисәкләргә бүлеп бетергәннәр. Соңрак инде Рум атлы ил куәт туплап чыккан да ул ямаулыкларны үз җиренә кушкан. Маһир, гаярь Искәндәр төзегән мәгъруր мәмләкәтнең эзе дә юк хәзер...

Әлеге минутларда алачыкның эче шундый тыныч, бер аһәң юк, мондый тынлык, хәтта, колакларда чыңлап тора иде. Аны һаман да шул яшь Сүбүдәй бүлде.

—Ә Аттила, атам? Магулларның ерак бабасы Аттила кайсы тарафларга яу йөргән дә, анда ни майтарган?

Җирсүдәй кыстатып тормады, тарих диңгезендә колач салып йөзәргә тотынды.

[1]Зәнҗи—негр.

—Аттила-жиһангир бер магулларның гына бабасы булмаган ул. Аңа сез белгән татар, мәркет, ангыт, найман, гирәй, уйгыр, карлук илә тагын әллә никадәрле ырулар буйсынып торган. Аларның җәмгысын да ул заманда бер исем белән генә атаганнар—һуннар. Менә шул һуннар җиде-сигез йөз еллар элгәре көнбатышка таба яуга киткән. Алар юлда угыз, казакъ, хәзәр, кыпчак, алан, сәрмәт вә тагын дистәләгән ыруларны басып алган, яугирләрен үз сафына кушкан. Сәйхун, Җәйхун, Җаек, Әтил, Тын шикелле олуг дәрьяларны кичкәч инде һуннар мадьяр, венгр, гот дигән халыкларны да пыран-заран китергән, олуг Рум мәмләкәтен дә тәмам тар-мар кылган. Мәгәр ярты җиһанга хуҗа булып алган Аттила-батырга да берзаманны Тәнре хозурына күчәргә вакыт килеп житкән. Ә җиһангирлар да, баһадирлар да гөмбә яки дала чәчәге түгел шул. Алар күче-күче белән дә, тутәл-тутәл булып та үсми. Һуннар арасында Аттилага алмаш табылмаган. Ул вафат булуга моның оланнары, яраннары, бәкләр арасында олы низагъ чыккан. Үзара яу йөри-йөри мондый көндәшләр берсен-берсе кырып бетергәннәр. Кайсы төмән безнең шушы Онон, Керулен тирәсенә кайтып егылган. Кайсылары шунда, бәхре Хәзәр, Әтил, Күбән, Тын дәрьяларына сыенып яшәп калган. Аттила-җиһангир бөртекләп җыйган олуг мәмләкәт тә санаулы еллар эчендә җимерелгән, сүнгән. Тарих җиһангирлардан менә шулай итеп тә үч кайтара икән...

Җирсүдәй сөйләгән һәрбер сүзне Тимучин ин куәтле янгыр суларын да үзенә йоткан чиллә туфрагы шикелле күнеленә сендереп барды. Искәндәр белән Аттила язмышлары өчен көенүдән эчендә янә янар учак кабынгандай булды. Сүбүдәйне дә, күрәсең, шушындый ук учак талагандыр инде, иреннәре арасыннан ялкынга тиң сүзләр бәреп чыкты:

—Искәндәр Зөлкәрнәен дә, Аттила да ярты гына җиһанны яулаганнар. Алар җиһанны тулысынча, актык дингезенә тикле яулап алган булса, соңыннан аларга каршы корал күтәрердәй, яуга кузгалырдай дошман калмас иде бит, эх!..

Берничә көннән соң халыклар, мәмләкәтләр хакында яңадан сүз купкач, Тимучин Җирсүдәйнең бер алдына, бер артына төшеп сораша-сораша җелегенә үтте.

—Син җиһанда бәхре Хәзәр бар, Сәйхун, Әтил, Һинд дәрьялары бар, дисең. Әллә нинди гарәп, фарсы, угыз, кыпчак, болгар халыкларын санап күрсәтәсең. Әйдә, аңлат миңа. Алар нинди җирләргә урнашкан да, кайсы тарафта соң?

Түземлегән җуйган Җирсүдәй аяк астында аунаган күмер кисәген кулына алды да, зур бер ак таш өстенә әллә никадәрле сурәт һәм сызыклар сызды. Аннары әле бер, әле икенче сурәткә күмер очы белән суга-суга, бик тәфсилләп һәммәсен аңлатты. Инде түзем йомгагының очын җуйгач кына түгәрәкләп куйды.

—Җиһанның актык чигенә барып ирешкәнче житмеш дала, житмеш дәрья, житмеш кыя-таулар кичәсе бар. Аны ошбу хәтирәдә генә аңлатуы ансат. Ә асыл җиһанны айкап чыгу өчен озын-озак гомер дә, зиннәт вә байлыклар да, өстәвенә әле тинсез җегәр кирәк...

Онон, Керулен буйларыннан бер якка да чыгып карамаган, язма хәрефнең сыңарын да аера белмәгән Тимучин өчен коллыктагы сабак-дәресләре әнә шулай дәвам итте.

## 2

Ничә ай, ничә ел гомере коллык газаплары эчендә узгандыр, Тимучин моны һичничек тә санап чыгара алмады. Ул инде күптән вакыт исәбен оныткан; читтән күзәткәндә, хәтта, үзенең мескен халәте белән ризалашкан да кебек тоела иде. Тимучиндагы ялган күндәмлек һәм гел-гел дәшми яшәү уранхайларга да тәэсир итте бугай. Аның аякларындагы агач башмакларны тимер чылбырларга алыштырдылар,

үзен тирән баздан һәм аерым читлектән чыгарып, такта сарайда тота башладылар. Муенына кидертелгән түгәрәк агач башмакларны салдырырга гына бирәү дә базмады. Ни әйтсәң дә, уранхайларның үз бәге юк, алар тайжутлар кабиләсенең башлыгы Торгытайга буйсынып яши һәм Тимучин кебек бер колчура өчен җил-давыл эләгүдән хәтәр шүрли иде.

Торгытай уранхайлар җәйләвенә бервакыт чиллә уртасында килеп төште. Такта сарайга бикләнгән булса да, Тимучинның җиләстә, күләгәдә бер дә газап чикмичә ятуы күнеленә хуш килмәде, әлбәттә.

—Сугым өчен симертергә ябылган тәкә түгелдер лә, нигә аны эшсез яткырасыз?—дип, Тимучинны күрә-күрешкә үк җенләнеп кычкыра башлады ул.—Янына бер каравылчы билгеләгез дә Татай тавына эшкә җибәрегез. Алачыкларда эшегез юньләп бармый. Бу имгәк шул таудан кәрҗин белән күмер ташып торсын. Эссе кояш астында акылга килер азрак.

Әнә шулай итеп, Тимучинның кулларына дәү бер адәм сыешлы кәрҗин тоттырдылар да, Торгытай күрсенгә, артына типкәли-типкәли, Татай тавына озаттылар. Аның янына сакка билгеләнгән бәндә Билгутай шикелле карсак һәм симез генә түгел, ә нәкъ аның кебек үк арты катыга тиде исә йокыга түнә торган пошмас бәндә булып чыкты. Тимучин әүвәл әле моңа бөтенләй дә игътибар итмичә күмер җыя иде. Ләкин бермәлне ул яңагына сугып йокыдан уятылган кешедәй капылт сискәнеп китте. Ауда йөргән сунарчы шикелле тирә-юньне ялт-йолт айкап чыкты. Татай тау итәге берән-сәрән үскән юкә, зирек, карама агачлары белән капланган, болар арасына качып котылырмын димә. Аның каравы, әнә, Онон ярлары буенча тоташ куаклыклар тезелеп киткән, байтак урыннарында җайдак кереп югалырдай булып камыш үсә. Муенга кидертелгән агач башмак бик сикергәләп йөгерергә дә,Ононга чумарга да ирек бирмәс-бирүен. Ләкин Балдак-Дала әлләни еракта түгел, кул сузымында гына бит. Ә анда Тимучинны олы эшләр көтә. Бу мәсхәрәле коллыкка күпме түзмәк кирәк? Нигә әле бәхетне сынап карамаска?

Ул үзенең уйларын кычкырып әйткән диярсең, борыны белән сызгыра-сызгыра йоклап утырган сакчы нәкъ шул мизгелдә күзләрен акайтып ачты да каршында җансыз багана сыман басып торган Тимучинга текәлде. Тоткынның муенына дәү агач башмаклар киертелгән. Ул бик тырышып сузса да, кулларын шул башмаклардан арырак уздыра алмый. Шуңа күрә мескен тоткынның сакчыга нинди дә булса зыян-зәүрәт китерә алуы бик тә шикле иде. Шуларны үлчәп сакчы тынычланды, күзләрен кабат йомды. Ә икенче мизгелдә инде Тимучин ажгырып килде дә, дәү башмакның тупас яны белән пошмас сакчының маңгаена орды. Утын пуләне кебек чирәмгә тәгәрәгән сакчы җан әсәре күрсәтми, ул бик тиз генә иска-аңга киләчәк түгел иде.

Тимучин булдыра алган кадәр сикергәләп-тузгып Онон буена очты. Юл таудан түбәнгә таба алып бара, йөгерү җиңел иде. Тимучин санаулы минутлар эчендә елга ярына төшеп житте, сунарчы угыннан качкан җанвар житезлеге белән куаклыклар эченә томырылды. Әмма тәүге очраган ике юан кәүсә үк аны күчәре баганалар арасына килеп кысылган арба шикелле шып туктаырга мәҗбүр итте. Тимучин муенындагы башмак-богжра кинлеге буенча шактый ук мул, аның белән теләсә кайсы сукмакка кереп качу мөмкин түгел иде. Тимучин янә Онон яры буйлап йөгерә башлады. Ул селкенгән саен агач башмак аның муен тиресен ныграк кисә барды. Кайнар тир белән кушылып яралар ачытты, Тимучин тәмам гыжлап чыкты. Ләкин качакка Балдак-Дала һаман кул сузымында гына булып тоела һәм ул тәненең, яраларының ай-ваена карамыйча янә йөгерә, ыргыла иде.

Мингерәтелгән сакчы байтак вакыттан соң гына аңына килгән, ахры. Качак артында тәүге җайдаклар шәүләсе пәйда булган чакта Онон өстенә томан, ә яр буйларындагы үзәнлекләргә кичке эңгер-меңгер яткан иде инде. Тимучин үз артыннан куа килүчеләрнең тояк тавышларын әле ерактан ук ишетеп өлгерде һәм су көзәне елгырлыгы белән Онон эченә

сикерде. Бу урында камышлар әлләни куе түгел, шулай да эчкә кергән саен алар Тимучинның артында биек койма булып калка иде.

Үзе качкан урынга килеп житкәнче үк Тимучин яр өстендә сүгенүчеләр арасыннан Торгытайның тавышын анык аерып алды.

—Ул хөрәсән әрлән дә, су көзәне дә түгел. Муенына башмак кигән килеш беркая да качып котыла алмас. Куып кына житим дә, тотыйм гына әле. Мин ул хөрәсәнне шул башмагы-ние белән бергә ат койрыгына тагып алып кайтам!

—Качыйм гына, котылыйм гына әле,—дип, Тимучин камышлар арасында ярсып пышылдады.—Каршыма эт шикелле шуышып килсәң дә, гафу итәсем юк.

Яр өстендәге тояк тавышлары ерагая башлады. Тимучинның тәне буйлап кайнар рәхәтлек йөгерде. Ләкин көтмәгәндә яр ягыннан су чупылдый башлады, камыш сабаклары кыштырдады. Тимучин бөтен тәне белән куырылды, су төбенә чумарга маташкандай итте. Әмма икенче мизгелдә үк инде үзенең мәңге батмас бөке хәлендә икәнлеген аңлап өлгерде дә, ачынудан бүредәй улап жибәрә язды.

Менә, Тимучин качкан куе камыш сабаклары урталай аерылды да, түгәрәк эченә әүвәл саллы, дәү сөңгенең угы килеп керде. Аннары инде сөңгенең иләмсез зур гәүдәле, кара-кучкыл тәнле хужасы пәйда булды. Тимучин бу минутта агач башмагы белән су эченә яткан һәм бөжра өстендә аның башы гына күренеп тора иде. Шулай аскы яктан караганга, ахры, кичке әңгер-меңгердә бот тиңентен генә су эчендә торган кешенең буй-сыны Тимучинга бөтенләй коточкыч пәһлеван булып күренде. Биленә уралган кызгылт чүпрәктән кала аның өстендә бер генә кием дә юк. Якякта нәни мендәр сыман кабарып чыккан күкрәкләре, дөя кебек юан беләкләре ул аз гына кыймылдады исә, уйнаклап ала иде. Бу пәһлеван ыргыткан сөңге гади кешене генә түгел, ә меньяшәр имәнне дә үтәдәнүтәли ярып чыгар сыман.

Тимучин таныды аны. Дошман Торгытайның кишектиннәре, ягъни шәхси сакчылары арасыннан иң гайрәтлесе һәм иң тугры дип исәпләнүче пәһлеван Сорхан-Шир иде бу. Ул мондагы төбәк кешесе түгел, Мисыр дигән илдән. Бурыч түләр рәтләре булмагач, аны туганнары әле үзе сабый чагында ук чин сәүдәгәрләренә сатып жибәргәннәр. Шулар аша, менә, Торгытай кулына килеп эләккән. Моның бастырык юанлыгы сөңгесеннән качып котылып булмас шул.

Тимучин аягүрә күтәрелә башлаган иде дә, Сорхан-Шир шып туктатты.

—Менә шушылай, жәйрән мөгезедәй сыну-бөгелүне белми торган булганың өчен сөймиләр дә инде сине тайжутлар, баһадир. Торгытай сине һаман жиңүгә, һаман берләшүгә йөз тотканың өчен яратмый. Ә син бирешмә, шундый булып кала күр, зинһар.

Тимучин шаккатты. Бу минутта күк йөзе убылып жиргә төшсә дә, бәлки, ул бу кадәр аптырамас иде. Ә монда әллә кайдагы чит мәмләкәттән килгән, моңа кадәр дәшмәс шәүлә генә булып исәпләнгән гап-гади бер кишектин бөтен магул ыруларының тормышына бәя, Тимучинга исә кинәш бирә.

—Син шушында гына утыр, баһадир, беркая да китмә. Мин сине беркемгә дә сатмыйм. Ә төнлә көт. Ярдәм итми калмам.

Көтмәгәндә ничек пәйда булса, Сорхан-Шир шулай юкка чыкты. Тавышы янәдән төн уртасы узгач кына ишетелде бугай.

—Әй, баһадир. Хәвеф-хәтәр үтте, инде чыксаң да була.

Кул-аяклары тәмам оеганлыктан Тимучин кымшана да алмый утыра иде. Сорхан-Шир янә дәште.

—Баһадир, дим! Таң озак көттермәс, жәһәт кымшан.

Ниһаять, урыныннан кубып, Тимучин яр буена чыкты. Анда сынар Сорхан-Шир урынына тагын ике шәүлә күреп шомлана ук калды. «Әй, үзе сатлык мал урынына йөргән кеше сине сатмыйммы соң?»—дигән

хәвефле уй зиһенен телеп узды. Әмма яннарына килеп житкәч, шәүләләрнен кемлеген таныды да, тораташтай булды.

—Без хәзер синең богауларыңны салдырабыз. Суккан чакта авыртмыйча калмас, түз, акырма,—дип телгә килгән кешеләрнең берсе аның коллыктагы остазы Жирсудәй, ә кулына авыр чүкеч-кискечләр тотып торучы икенче юлдаш исә тимерченең улы яшь Сүбүдәй иде.

Шактый матавыклансалар да, богауларны житез салдырдылар. Үзенең тимер кыршаулары белән шалтырап, берзаманны башмак-божра да яр астына чумды. Очар кош шикелле жиңеләеп калган Тимучин әле һаман урыныннан кымшанмыйча утыра иде. Аны Жирсудәй тыкырдата башлады:

—Таң сызыла түгелме инде? Әйдә, ашык. Торгытай көттермәс ул.

Тимучин күтәрелгәч, Сорхан-Шир сәер тәкъдим әйтеп салды:

—Минем Торгытай ише комсыз бәрәнгә түгел, ә асыл баһадирга хезмәт итәсем килә. Мине үзең белән ал син, баһадир?

Тимучинның ни әйтергә дә белми торуын күргәч, янә өстәп куйды.

—Торгытай куып житсә, минем сиңа кирәк булуым бар.

Тимучинның үзеннән бер башка калкурак пәһлеванны кысып кочакламыйча чарасы юк иде. Янда Сүбүдәй телгә килде.

—Мин беләм, магулларны бергә туплау өчен син әле бик күп яуларга керәчәксең, Тимучин. Минем дә сугышасым, жиңүләргә ирешәсем килә. Үзең белән ал син мине, әйдә.

Сүбүдәйнең тәмамлавы булды, аның жилкәсендә йодрыкларын яман болгый-болгый Жирсудәй тезеп китте.

—Сугышырмын мин сиңа, малай актыгы! Атай-анайдан сорап тору юк, ни юк. Чыкмакчы да таймакчы. Китми генә тор әле. Алачыкта эшлә, чүкеч селтә, эшкә өйрән башта. Ә кылыч болгарга, сөңге очырырга син болай да маһир.

Жирсудәй сүзләрен Тимучин елмаеп тыңлады. Ә жавабы таждарларныкы шикелле искитмәле вәкарь, коры яңгырады.

—Сорхан-Шир—берьялгызы. Аның монда иле дә, халкы да юк. Аны менә шуның өчен генә үзем белән алам. Ә син магул, Сүбүдәй. Синең артыңда меңәрләгән тирмәләрне берләштергән уранхайлар тора. Магулларга хәзер сынарлар түгел, ә меңәрләп берләшер вакыт житте. Әгәр син дә магул халкын бергә туплыйм дисәң, әнә шул меңнәрне ияртеп килә бел, дускаем. Шул чагында без синең белән мәңге аерылмабыз.

## 3

Туган нигезе Балдак-Дала үзәнлегенә кайтып кергәч, Тимучин ачуыннан шартларга житешеп котырынды, шашты. Тимучин югында Айлун әкә тырышлыгы белән Билгүтай кыятлыларның баһадиры, дип игълан ителгән, ә яңа хужа исә абыйсы еллар буена жыйган көчкуәтне пыран-заран китереп бетергән икән. Ак-караны күрми тузынган Тимучин тарафыннан иң төртмәле, иң әрнеткеч сүзләр, әлбәттә инде, беренче чиратта Билгүтайга эләкте.

—Мин Торгытай тырнагына барып эләккәнче Байшоңкар әләме астына унөч меңгә якын тирмә жыйган идем. Еллар буе каннар савасава, берәмтекләп жыелган унөч мең тирмә! Син шуны аңлыйсыңмы, бирән?! Ә мин котылып кайтуга исә Балдак-Далада нибары ике мең ярым тирмә утырып калган. Тфү, имгәк!..

Һавада йодрык селтәүнең файдасы юк иде, Тимучин Бөртек бикә тирмәсенә бикләнеп күңеленә юаныч табарга омтылды. Магуллар өчен Борте бикәгә әверелгән Бөртек ул коллыкта чакта яңа угыл тапкан, исемен Чагатай дип тәгаен иткән икән. Чагатай хәзер инде теттереп йөгереп йөри. Атасына охшап буйга калку, чәче жирән төстә. Тимучин көннәр буе шуның белән юанды, ә уйлары, күңеле, барыбер, гел еракта йөрде.

Тимучинның исән-сау әйләнеп кайтуын ишеткәч Онон, Керулен

тирәсендә генә йөргән кыятлылар янә Балдак-Далага инеп тупланә башладылар. Баһадир кеше өчен сөенеч, әлбәттә. Әмма Тимучин бер тамчы да канәгатьлек хисе кичерми. Ул үз кул астына берьюлы һәм бик күп көч туплау турында хыяллана, тик мона ирешүнен юлларын-чарасын эзләп таба алмый интегә иде.

Җитмәсә, сонгы көннәрдә анын күнеленә яна бер корт төште. Тимучин коллыкта яткан көннәрдә татарларнын жыен, әбрибуир, конгырат, дөрбән кабиләләре тагын да көрәйгән, алар үзләренә хәтта Мәгъсүм Султый атлы хан да сайлап куйганнар икән. Шул Мәгъсүм Султый кара татарларның вак-төяк чируләрен бергә туплап, зур гаскәр төзегән дә, көньяктагы далаларга төшеп, чиннәрнен байтак авыл-калаларын талап кайткан. Татарлар инде моннан утыз ел элек Буир-Нур күле буенда Котул хан житәкчелегендәге магуллар чирүен тар-мар иткәннән бирле жинелү белми яши. Чиннәр алардан үч алырга тели икән дә бит теләвен. Мәгәр алар арасында оста сәрдәрләрнен мәнге булганы юк. Алар яу йөрү тәртибен дә юньләп белми торган халык. Тимучин аларга барып ялланыр иде дә, ләкин үз кул астындагы ике-өч мен ир белән генә ни кырасын? Ә татарлардан үч алырга кирәк. Буир-Нур янында жинелгән өчен дә, әтисе Ясүгәй баһадирнын үлеме өчен дә. Монысы—һичшиксез. Аннары, Тимучинга яуда үзен маһир сәрдәр итеп таныту да нык отышлы адым. Бу ана магул кабиләләре арасында абруй казану, аларны үз әләме астына туплау өчен кирәк.

Әнә шул рәвешчә бик озак баш ватканнан сон, Тимучин үзенен балачак дусты Жәмуга янына жыенып юлга чыкты. Өстәвенә, мәркетләргә каршы оештырылган яу барышында алар бер-берсен туганнар дип тә аташканнар, хәтта, моны каннары белән дә беркеткәннәр иде.

Чатжиратлар бәге Жәмуга аны колач жәеп, сөенеп каршы алды.

—Ничә еллар буе күрешкән юк, сагынылган, дустым,—диде ул, хисләрен яшермичә.—Синен Торгытай зинданында коллыкта ятуын турында да ишеттем-ишетүен. Мәгәр тайжутлар белән уранхайлардагы көч утыз меннән артык тирмә исәпләнә бит. Ә минем кул астындагы жайдаклар саны унбиш мен тирәсе генә. Шулай икән, кыйналасы килгән ишәк сыман күсәккә барып ышкынып буламыни?

«Эх, минем унбиш мен жайдагым булсын иде әле! Мин анын белән Торгытайны гына түгел, бөтен магул кабиләләрен тез чүктерер идем»,—дип ачынып-көенеп уйлады Тимучин, әмма үзенен көчсезлеген, хәтта, туганы саналган Жәмугага да сиздермәде. Дала да, яу да көчсезләрне сөйми. Ә Тимучинга Жәмуганы ничек тә ризалатып, унбиш мен жайдагы-ние белән бер әләм астына кушарга кирәк иде.

—Магулларнын барча чирү вә кабиләләрен бер йодрык итеп тупларга вакыт житте, Жәмуга борадәрем,—Тимучин үзенен үгет-тәкъдимнәрен шулай дип башлады.—Татарлар да, найманнар, гирәйләр вә башка халыклар да, әнә, бер тугра астына тупланып, бер гаилә булып яши. Һәркайсынын ханы да, бердәм гаскәре дә бар. Ә магуллар көтүчесен югалткан куй өере сыман, Далай-Нур илә Онон арасындагы бөтен дала буйлап сибелешкән. Кабилә бәкләренен, нойоннарнын һәркайсы аерым гына көн итәргә жыена, уртак юлбашчыга баш иясе килми. Шуна күрә безне әле татарлар, әле мәркетләр аерым-аерым көе кыйнап китә. Житте, борадәрем! Безгә янә Кабул хан, Котул хан заманнарын кайтарырга, берләшергә вакыт.

Магулларны бер әләм астына туплау, күмәк хан булдыру турындагы фикерләр Жәмуга өчен дә чит-ят түгел икән, ул тиз ризалашты. Көз кергәндә Балдак-Дала үзәнлегенә жыелырга, дип сүз беркеттеләр.

Шуннан сон, Тимучин янә күптәнге «фәрештәсе»—гирәй-кираитлар хужасы Тугърул хан янына юнәлде. Ни гажәп, Тугърул хан аны онытмаган гына түгел, хәтта, көткән икән.

—Син бит минем атаулы борадәрем Ясүгәй улы. Әле тоткынлыкка кадәр үк, япь-яшь көе, син кыят-нируннарны бер учак, бер казан тирәсенә

туплау уе илә көеп йөргән иден. Мөгаен, хәзер дә ул уеннан кире кайтмассындыр?

—Юк, юк, атай. Кыятларны, нируннарны бер тугра эргәсенә туплау ниятеннән кире кайтасым юк. Бу бит синең борадәрең—Ясүгәй атамның да олуг васыяте,—дип, яна-пешә Тимучин Тугърул ханның салпы ягына салам кыстырырга ашыкты.

Тимучин икейөзлеләнде. Тугърул хан—чит ыру хакиме, анын каршында «мин кыятлылар, нируннарны гына түгел, ә бөтен магул кабиләләрен бергә туплау турында хыялланам»,—дип, күнелне ачып салу һич ярамый иде. Әнә шул мәсләктән чыгып, Тимучин үзен бөтенләй дә көчсез, тулаем рәнҗетелгән баһадир итеп кенә танытырга булды.

—Кыятларны, нируннарны үз тирмәм янына кабат кайтару өчен миңа үземне булдыклы сәрдәр, эшләре гел унучан баһадир итеп таныту кирәк, атай. Ә моны нинди дә булса зур җинүгә ирешмичә раслау һич тә мөмкин түгел. Бүген кул астымдагы чирүнең көче санаулы гына. Мин синең ярдәменә мохтаж, атай.

—Син кайсы дошманыңа каршы яуга чыкмак буласың соң, углым? Торгытайдан үч алырга ниятлисеңме, ничек?

—Юк, олуг хан. Эшләремне башта ук магулга магулны чәкәләштерүдән башласам, алар мактаулы да булмас һәм шәхсән минем үземә дә абруй өстәмәстер. Минем Торгытайдан кала да үч аласы дошманнарым бар бит. Синең атаулы борадәрең—атам Ясүгәй өчен. Моннан байтак еллар элек Буир-Нур буенда магуллар кичергән әче мәсхәрә өчен.

Буир-Нур күле буенда утыз ел элек булып узган соңгы зур яуда үзенең гаскәре белән бергә Тугърул хан да катнашкан һәм ул да татарлар тарафыннан ачы җиңелү хурлыгын татыган иде. Тимучин моны яхшы белсә дә, «магуллар» дигән сүз янына гирәйләрне кушып сөйләмәде. Ә шулай да Тугърул ханның мин-минлеген уятуга барыбер иреште ул.

—Син кара татарларны дөмбәсләргә исәплисең, димәк. Бик хуп. Аларның да арт сабагын укытырга вакыт. Мәгәр син һәм мин кушкан көчләр генә житеп бетәрме соң? Җыенлыларның бер үзендә генә дә житмеш менләп тирмә исәпләнә, син шуны онытма.

—Юк, онытмыйм, атай. Монда килгәнче мин инде чатҗиратлар башлыгы Җәмуга чәчән белән дә сүз беркеттем. Ул унбиш мең жайдаклы чирү туплап килә. Аннары мин чиннәрнен безнең чиктәге хакиме Чен-Сян белән дә килешергә җыенам. Кара татарларның ханы Мәгъсүм Султый аларның төньяктагы авыл-калаларын җимереп, талап кайтты. Моның өчен, билгеле ки, чиннәр татарларга бик нык ачулы. Бергә яу оештыру турындагы минем тәкъдимемне алар, шаять, сөенеп кабул итәр.

«Ә син әрекмән шикелле беркатлы түгел икәнсең бит, кыят баһадиры,—дип уйланды Тугърул хан.—Бер дә туп-турыдан чин хакиме янына төбәп китмәгәнсең. Буш кулны эт тә яламый, моны беләсең икән...»

—Чиннәрнең ул олуг вәзире Чен-Сян янына мин дә барам!

Тугърул ханның мондый белдерүе Тимучинны бер дә аптыратмады, ул күндәм кыяфәттә башын түбән иде.

—Сез Җәмуга белән гаскәрегезне кайда тупларга булдыгыз инде?

—Балдак-Далада, олуг хан. Шулай кулай булыр.

«Ох, остасың, баһадир!—дип, Тугърул хан янә көнләшеп уйлады.—Балдак-Дала икән, димәк, синең әләмең астына җыелган, син туплаган гаскәр була инде ул. Мәгәр хан башым белән сиңа буйсынып йөрергә мин җүләрме әллә? Юк, мин түгел, ә менә син үзең минем кубызыма биергә тиеш.»

Әмма Тугърул хан күнелендәге уйларын Тимучинга сиздермәде.

—Балдак-Даланы билгеләп дөрес эшләгәнсең. Бу сиңа абруеңны күтәрергә дә, кыятлыларны янә үз канатың астына туплауда да, шаять, ярдәм итәр. Унбиш мең жайдагымны алып, мин дә шунда килермен. Казаныңны асып, кунакларыңны каршы алырга әзерлән, баһадир.

## 4

Һәммәсе Тимучин үзе ниятләгәннән дә уңышлырак килеп чыкты. Кыят баһадирының магулларны берләшергә өндәгән чакыруы, яу походы турындагы хәбәр Аргын, Буир-Нур, Керулен буйларындагы иң ерак җәйләүләргә дә барып житкән, күрәсең. Тимучин Тугърул хан яныннан әйләнеп кайтканнан соң атна-ун көн дә вакыт үтмәгәндер, Балдак-Далага әллә кайдагы җөрҗән, мангыт, исут, урут кабиләләреннән йөзәр-йөзәр тирмәле олаулар агыла башлады. Кыятлылар белән нируннарны әйтеп торасы да юк. Тимучин коллыкта чагында аларны Котул хан уллары үз җәйләүләренә юмалап чакырган булса, хәзер һәммәсе диярлек янә Балдак-Дала ягына ава барды. Үзәнлектә тормыш кабат элеккечә ургый-кайный һәм, әлбәттә, мондый янарыш баһадирга канәгатьлек китерә иде.

Шулай да Тимучинга иң зур сөенеч өстәгән кеше яшь Сүбүдәй булды. Чөнки кыят баһадиры аны бөтенләй дә көтми һәм, гомумән, аның килү мөмкинлеген күз алдына да һич китерми иде. Шунадырмы беркөн таңда аның тирмәсенә җансакчылар башлыгы Сорхан-Шир кереп: «Уранхайлар килде!»—дигән гайре сәер хәбәр салгач, Тимучин бәреләсугыла тышка атылып чыкты. Күктән иңгәндәй булып тоелган җайдаклар нөгәре аны тирмә каршында тигез сафларга тезелеп көтә иде.

Тимучин сафларга күз йөгертеп чыгуга хәйран калды. Җайдакларның һәммәсе дә вак-вак тәңкәләрдән тезелгән тимер көбәләргә төренгән, яннарында кылыч, сөңге, хәнҗәр. Боларның хәтта ияр өзәңгеләренә тикле гел бер төрле. Сүз дә юк, боларны нөгәргә үткен күзле, таләпчән кул туплаган. Кем булыр бу? Дошман Торгытай кул астыннан кыятлар ягына боларны нинди кушйөрәкле батыр алып чыккан?

Менә, саф башында торган чем-кара аргамак өстеннән мәһабәт гәүдәле бер яугир сикереп төште дә, Тимучин каршына килеп башын түбән иде.

—Син магулларны ялгызак көе түгел, ә үз артыңнан башкаларны да ияртеп килсә генә кабул итәм, дигән идең. Менә, жиде йөз уранхай җайдагын үз әләмең астына каршыла, баһадир.

—Сү-бү-дәй, жан дускаем!—дип кычкырып җибәрде дә, Тимучин уранхай кунагын кочагына состы.

Тирмә эченә узып йомшак киләм өстендә урын алгач кына, Тимучин Сүбүдәйнең килеш-кыяфәтенә игътибар итте. Яңаклары беркадәр суырылып калса да, Сүбүдәй буйга тагын да үсә төшкән. Тимер көбә, киң күн каеш астында чиксез гайрәт белән ташучы гәүдә-сын ятуы күзгә бәрелеп тора. Егетнең карашында тәвәккәллек, ныклык. Моның куллары һәм ихтыяры ялгышуны, жиңелүне белмәс төсле.

—Ул тиклем охшаш корал вә киемнәрне каян тупладың син?—дип сорап куйды Тимучин. Сүбүдәй ирен читләре белән көлемсерәп куйды.

—Торгытайдан чәлдем. Ул аларны үзенең шәхси гвардиясенә—кишектиннәренә дип хәзерләткән иде. Ә Торгытайга хуш килгән шайман бөтен магул баһадиры өчен дә харам түгелдер бит.

Тимучин эсселе-суыклы булып китте. Ул үзенең бөтен магул кабиләләренең юлбашчысы булырга хыялланувы хакында һичкемгә әйткәне, моны сиздергәне юк. Ә уналты-унҗиде яшьлек Сүбүдәйнең—гади тимерче улының шул яшерен хыялны үтәдән-үтәли күреп торуы аны кыенсындыра да, гаҗәпләндерә дә иде.

—Нөгәреңне минем шәхси кишектиннәрем итеп куярга ризамы син?—диде Тимучин, аңа яратып карады.

Яшь егетнең төпле җавабы янә сокландырды.

—Килә-килешкә үк иң җаваплы бурычны йөкләү, ягъни утка салу уранхайлар өчен дә мәртәбә вә олы сынау булыр. Чит кабилә яугирләрен шәхси сакка кую синең үз туганнарыңа, үз хыянәтчеләреңә дә юлны бикләр. Син белеп эш итәсең, мин риза, баһадир...

Төрле кабиләләрдән килеп Балдак-Далада тирмә коручылар саны әнә шул рәвешчә көн дә арта торды. Күзгә кергәндә үзәнлеккә инде сигез меңнән артык тирмә тупланган һәм Тимучинның хәзер башка сәрдәрләр белән дә күкрәк киереп сөйләшерлек нигезе бар иде. Шулай да Балдак-Далага чатҗиратлар белән гирәй-кираитлар килеп житкәч, юлбашчылар арасында бәхәс-фәлән кубып тормады. Үзеннән-үзе аңлашылган төсле Тугърул хан баш сәрдәр булып кыйлана башлады. Ә тыныч үзәнлектә хаким булу белән яу кырындагы баш сәрдәрлекнең аермасы бик зур икәнлеген яхшы белгәнгә күрә, Тимучин белән Җәмуга әлегә бернинди дә ризасызлык-мазар сиздермәделәр.

Чин министры Чен-Сян янына Тугърул хан белән Тимучин бик тиз барып кайтты. Чиннәр элеккечә үк сугыш-орышларга йөз тотып яшәми һәм татарлар белән булачак яуга да алар нибары биш мең кешелек кенә чирү бирәчәк иде. Кәҗәсе түгел, мәзәге дигәндәй, Балдак-Далада якынча кырык мең җайдаклы гаскәр көткәнгә күрә сәрдәрләр моңа әлләни игътибар итмәделәр. Шәрекъ дөньясындагы иң мәгърур дәүләтнең татарларга каршы яуда катнашуы үзе үк зур мәртәбә һәм Тугърул хан белән Тимучин шуңа да бик канәгать иде.

Тайҗутлардан кала магулларның барча кабиләләреннән дә вәкилләр туплаган, шуларга гирәй-караитлар, чиннәр кушылган кырык биш мең кешелек гаскәр сентябрь азакларында юлга чыкты. Җиһанда әбиләр чуагы канат җәйгән, көннәр яңгырсыз һәм кояшлы иде. Әле бу, әле теге якта җайдакларны биек-биек таулар, олы бер гасырлык гомер кичергән аксакаллар сыман, тыныч кына күзәтеп һәм озатып кала. Сирәк-мирәк булса да тау битләрендә аксыл-сары чәч толымнарын иңбашына таратып салган моңсу кыз бала шикелле күзгә каен очрый. Гөнаһсыз кыз бала кебек үк сафлыгын җуймаган дала буйлап һәрбер узгынчыны да чалып егарга ымсынгандай итеп кылганнар йөгерә. Табигатьнең яу түгел, туй күтәрер чагы. Ә татар даласына, менә, кан һәм үлем бөркиячәк дәһшәт якынлаша.

Татарлар гирәй-магулларны бу кадәр үк көч-куәт туплап килер дип һич көтмәгән, күрәсең. Әлләни зур булмаган Үлҗә елгасы буенда аларны татарларның нибары егерме биш-утыз мең кешелек кенә гаскәре каршы алды. Гаскәр нигездә дүрбән кабиләсе җайдакларыннан тора һәм сәрдәрләре дә шушы ук кабилә хакиме Мәгъсүм Сүлтый иде.

Татарларның сан ягыннан шактый гына оттыруын күреп, Тугърул хан орышны бик кыска һәм бик кайнар итеп үткәрергә ниятләде.

—Татарларда безгә каршы торырлык көч юк. Меңлекләрне, алайларны запаска калдырып тормыйбыз. Черки болыты сыман бердәм ябырылабыз да, бар гаскәрләрен тоташтан сытып үтәбез,—диде ул, яу кырына күз ташлап беренче нәтиҗәләрне чыгаргач та.

Җәмуга бәк тә яуга сусый иде, ахры, каршы сүз катмады. Тугърул хан үз әләмен селтәп әмер биргүгә үк гирәй-магуллар өч тарафтан килеп татар гаскәре өстенә ябырылды.

Орыш, чыннан да, коточкыч дәһшәтле һәм аяусыз барды. Атлар кешнәгән, кешеләр ачыргаланып кычкырган авазлардан елганың ике як яры да инрәп тора, кылыч, сөңге орышыннан ике якта да сугышчылар йөзәрләп һәм меңәрләп ава иде. Татарлар төрле яктан уратып алынсалар да, әле агач түмәре шикелле нык торалар. Гирәй-магулларның һөҗүм угы аларның тыгыз сафлары эченә бер генә яктан да ярып керә алмый.

Тимучин әле орыш эченә кермичә читтән генә күзәтеп тора иде. Әлбәттә, ул күбрәк үзенең кыятлылар, нирунлылар орышына игътибар итте һәм күзәткән саен гаҗәпсенә барды. Аның меңлекләре башкаларныкы сыман татарлар белән йөзгә-йөз килеп орышмый, читтән карасаң, алар дошман гаскәренә сынар канатлары белән кагылып-орынып кына үтә.

Менә, кыятлылар дала ягында озын чылбыр булып тезелә дә, шушы чылбыр ук шикелле төбәлеп дошман өстенә оча. Әмма кыятлыларның берсе дә дошман белән орышка кереп тормый, кырмыска оясыдай кайнап

торган татарлар өстенә ике-өч ук ата яки җинел сөнгесен селтәп очыра да, һичнинди тукталыш-фәлән белмичә ары чабып уза. Бер сугышчы икенчесен, бер менлекне янасы алыштыра, дошман өстенә яуган ук һәм сөнге янгыры һич тә туктап тормый. Кыятлы җайдаклар арасында һичкем зыян күрми, ә татар сугышчыларынын сафы һаман кими, һаман кими бара. Әйтерсен, Үлҗә буендагы инкүлек өстендә ниндидер галәмәт зур тәгәрмәч әйләнә дә, шул тәгәрмәч үзенен күзгә күренмәс кыршаулары, пычаклары белән дошман сафын телгәләп, кисеп бара.

Тимучин дала ягында җайдакларны чылбырга тезеп торучы менбашларнын берсенә төбәлде дә, тимер очлым, тимер битлек астына яшеренгән сугышчыда Сүбүдәйне танып, гаҗәпсенә калды. «Менә, унҗиде яше дә тулмаган егет, диген син моны. Ташкын, дулкын сыман сафларны гел алыштырып торып орышу алымын каян белеп алган да, кай арада кыятлыларны шуна өйрәткән ул? Эх, Сүбүдәй кебек мондый оста юлбашчылар магуллар арасында күбрәк булсын иде!..» Тимучиннын хәзер үк очып барып Сүбүдәйне кысып кочасы килде. Әмма Үлҗә елгасы буенда аяусыз яу бара, ә сәрдәр кешегә хис күрсәтү артык сыйфат иде.

Татарларнын юлбашчысы Мәгъсүм Султый бөтенләй үк беркатлы һәм яуга ис-акылын югалтып ташлана борган дуамал түгел икән. Гирәймагуллар белән орыш артык кискенләшкәч, ул яшел әләмен як-якка җилфердәтеп ниндидер сигнал бирде һәм берничә минуттан сон эрелевәклы куаклыклар белән капланган биек үр артында да татарларнын яшерен чирүе калкып чыкты. Чама белән биш мен җайдактан торган әлеге чирү яман сызгырып-улап магул сугышчылары өстенә килә башлады. Ул якта Җәмуга бәк яугирләре орыш алып бара һәм алар инде шактый гына алҗыган иде. Ә инде ике ут уртасында да калгач чатҗиратлар бик тиз бирешә башлады. Ул да түгел, чатҗиратлар сафында беренче җебегәннәр һәм хыянәтчеләр күренде. Җайдакларынын яу кырын ташлап кача башлавын күргәч, Җәмуга котырынып-ярсып әле бер, әле икенче тарафка ыргылып карады.

—Куркакларнын барысын тин үзем кылычтан үткәрәм! Бер адым да артка чигенмәскә! Алга, яуга, фәкать алга гына!

Юк, кабилә башлыгынын янаулары, чакырулары да әлләни зур файда китермәде. Ике яктан китереп кысылган чатҗиратлар сафы әле анда, әле монда өзелеп, тетелеп чыкты. Җәмуга үзе дә инде сәрдәр булуын бөтенләй оныткан һәм гади сугышчы сыман дәү кылычын унлысуллы селтәп орышуны гына белә иде.

Тимучинга да үз янындагы барча кишектиннәрен алып яуга ташланырга туры килде. Кыятлылар орышкан якта татарларнын сафы яртылаш сирәгәйгән, шуна күрә аларны ерып бару шактый җинел иде. Үзенен уранхай сугышчылары белән ярдәмгә Сүбүдәй-менбаш та килеп җиткәч, татарларны изеп-сытып бару тагын да җинеләйде. Берзаманны Тимучин үзенен татарлар хакиме Мәгъсүм Султый белән йөзгә-йөз килеп басуын хәтта абайламый-тоймыйча да калды.

Татарлар да, магуллар да беркадәр артка чигеп, орыш мәйданын кинәйткәннәр бугай. Тимучин моны күз карашы белән күрмәде, тәне белән тойды. Ә игътибары исә хәзер тулысынча дошманы тарафына гына юнәлтелгән һәм Тимучиннын чигенергә яки сынатырга исәбе юк иде.

Тимучин мондый шәхси алыш барышында пәрәвез ятьмәсе корып үз корбанын көткән үрмәкүч сыман читтә генә качып-посып йөрүне дә, тавык басарга чамалаган әтәч төсле яны белән хәрәкәт итүне дә башта ук артык күрде. Орыш икән, орыш, качышлы уйнап булмый.

Татарлар хакиме Мәгъсүм Султый да нәкъ шундый ук фикердә иде бугай. Менә, ул да Тимучинга таба йөзе белән борылып басты, ике ара күзгә күренеп кими башлады. Кылычлар өскә күтәрелде, тәүге чынлау авазы янгырап алды. Ә аннары инде ул чынлау авазлары һаман-һаман саен ешая гына башлады, ана ирләр гыжлаган, атлар пошкырган тавышлар кушылды.

Ә бәхет дигәннәре бүген магул батыры ягында булып чыкты. Кайсыдыр мәртәбә кылыч болгаганда Мәгъсүм Султый кулын ашыгыбрак төшерде һәм шул мизгелдә үк Тимучинның яшендәй ятаганы әлеге кулны нәкъ терсәк турыннан җиргә кыеп төшерде. Тирә-юньдәге татарлар ни булганын аңлап өлгергәндә кисек кул хуҗасы инде үзе дә муенына чабылган кылычтан җир өстенә авып төшкән иде.

—Тимучин татар хакимен җинде!

—Татарлар сәрдәрсез калды!

—Байшонкар, Бәртән, Томавыл!—дип кайдадыр артта магуллар илереп һәм шашып кычкырдылар.

Юлбашчының үлеме ике кулсыз итте, күрәсең, татарлар тиз арада бирешә башлады. Бермәлне алар сафында мәхшәр купты, һәммәсе тиң Үлҗә яры буйлап качарга тотынды. Боларны хәзер сафка-нөгәргә туплау бөтенләй мөмкин түгел, ә магуллар шуннан аркаланып качакларны кылыч белән дә, сөңгеләр белән дә телә, турый, тетә генә иде. Магуллар татарларны шул рәвешчә дүрт-биш чакрым буе эзәрлекләп барды. Ахырда исә татарлардан нибары өч-дүрт мең чамасы җайдак кына качып котыла алды.

Татар ыстанында ганимәт байтак иде, магуллар ызгыша-талаша шуны бүлештеләр. Бавырчымы, Җәлмәме—кайсыдыр—Тимучин каршына да чиста көмештән ясалган сабыйлар бишеге белән алтын җеп кушып чигелгән юрган китереп салды. Тимучин боларга игътибар бирмичә генә утыра иде, бермәлне аның каршына дүрт-биш яшьлек сабый малайны житәкләп китерделәр. Елый-елый шешенеп беткән бала парча, кеш тиреләре белән бизәлгән киемнәргә төренгән, билендәге каешының аелы, кулындагы нәни беләзек—һәммәсе саф алтыннан. Бу малайның кайсыдыр бәк яки күренекле би баласы булуына шикләнерлек түгел.

Тимучин аның каршына килеп чүгәләде, бармак очлары белән янакларын, күз төпләрен ипләп сөрткәләде.

—Син кайсы кабиләдән буласың?—дип йомшак кына итеп сораша да башлады:

—Дөрбәннеке,—диде малай, бик көттереп кенә.

—Ә кем малае син?

—Әтинеке.

—Ал-лай,—диде Тимучин, аптыраудан колак артын кашып.—Ә исемең ничек?

—Шаһи Котыгъ.

Табылдык баланы Тимучин янына алып килгән йөзбаш өстәп куйды:

—Кара Бүке табып алган чакта бу малай нindидер кәгазь актарып утырган. Бүке сынап караган, шушы орчык чаклы малай актыгы укый белә икән.

Тимучин беркадәр вакыт кына уйга чумып торды да, үзеннән мәңге аерылмас Сорхан-Ширгә таба борылып әмер бирде:

—Малайны үзең белән ал. Кайткач аны Айлун бикә карап үстерер...

Утыз ел буе буйсынып һәм посып яшәүдән соң, ниһаять, олы җиңү яулаган магуллар җыенып Балдак-Дала үзәнлегенә кайткан чакта Тимучин сирәк кенә булса да табылдык Шаһи Котыгъны үзенең тезләре өстенә дә алгалады. Гәрчә ул ошбу сабыйның киләчәктә үзе төзиячәк иксез-чиксез империядә иң укымышлы галим һәм дәүләтнең баш казые булачагын, бүген әлбәттә белми иде әле...

## 5

Үлҗә елгасы буенда яуланган зур җиңү турындагы хәбәр магул кабиләләре яшәгән дала-җәйләүләр буйлап яшендәй тиз таралды. Көчле кешенең куены һәрчак ымсындыргыч була, Далбак-Далага килеп төпләнүчеләрнең саны да хәзер көнләп түгел, сәгатьләп арта

барды. Тугърул хан белән Җәмуга чәчән кайтып киткәнче үк үзәнлектәге тирмәләр саны ун мен чиген үткән иде. Ә кыш кергәндә алар янә унөч менгә житте. Әллә нинди дымсу һавалы, янгырлы-бозлы булып башланып киткән бу кыш буралкы, куй көтүләрен исән-сау чыгарырга бер дә өмет бирми, Тимучинга кабилә иминлеге турында кайгыртудан тыш әле әнә шул мал-туар бөтенлеге хакында да баш ватарга кирәк иде.

Җәмуга кышлау вакытында Тимучинны үз янына кунакка чакырып киткән иде. Озын-озак уйлап тормыйча Тимучин үзенен кул астындагы барча тирмә, мал-туарлар белән Җәмуга хужа булган кышлауга күченергә карар кылды. Унөч мен тирмәне ерак күчешкә хәзерләү, әлбәттә инде, бик матавыклы, четерекле эш иде, зур-зур арбаларны тутыра-тутыра байтак чиләнделәр. Шулай да барча мәрәкә-мәшәкать артта калды, тәвәккәлләп юлга кузгалдылар.

Әмма кыят-нирунлыларга юлда исән-имин, хәвеф-хәтәрсез генә барырга насыйп булмады. Тайҗутлар башлыгы Торгытай үз кулыннан качкан бәкне онытмаган һәм янә көч, абруй җыя башлаган, Үлҗә буенда җину яулаган Тимучиннан үч алырга кулай очрак кына көтеп йөргән икән. Сүбүдәй белән килгән уранхай җайдаклары арасында берәр сатлыкҗан булганмы, әллә Торгытай үзе юллаган шымчылар бик оста күзәткәнме—монысы дөм-карангы. Ләкин Торгытай Тимучиннын көчсез, мәшәкатьле һәм дала уртасында үскән ялгыз агач шикелле сак-ышыксыз чагын оста сайлый белде.

Торгытай үзе белән тайҗут, уранхай, исутлардан хасил утыз мен җайдаклы гаскәр алып килә иде. Төрле якка юлланган ертауллар Тимучинга моны бик тиз хәбәр итте. Махсус ыстаннар корып торыр өчен вакыт гаять кысан булганга күрә Тимучин җирле унайлыкларны гына файдаланырга карар кылды. Якында гына җайдаклар мәнге үтеп керә алмастай куе чытырманлык белән капланган тау итәге сузылып киткән иде.

—Безнен өчен әнә шул куаклыклар берьяк калкан булыр,—дип анлатты Тимучин үзенен якыннарына.—Ә икенче ягына арбалардан ике катлы озын чылбыр тезәрбез.

Сүбүдәй, Бавырчы, Җәлмә, Билгутай, Хасар—һәммәсе зур елгырлык белән саклану ыстаны оештырып йөрде. Юка кар катламы каплаган инкүлектә беркадәр ыгы-зыгы купса да, ул, әүвәл бүредән өркеп таралган, аннары җәһәт кенә янә мәгърур тәкә тирәсенә килеп тупланган куй көтүе сыман, юлбашчылар тырышлыгы белән тиз арада корыч ихтыярлы хәрби ыстан рәвешен алды. Берзаманны инде инкүлек өстендә әле Сүбүдәй, әле Җәлмә яки Бавырчынын катгый әмерләре генә янгырап торды.

—Әгъли, Апач, Турсык менлекләре! Әнә теге ерым буена сузылып урнашыгыз. Тышкы якка киезле арбаларны тезегез, ә йөк тутырганнары икенче катка калсын. Арбаларнын һәммәсе дә сүтелгән тирмәләр белән үзара тоташтырылган булсын.

—Әбләй, Елан, Шадай! Сезнен менлекләргә урын менә бу тау яклап. Тулгама коруга ук барча мал-туарны әнә теге ерым эченә кертеп яшерәсез. Кулына корал тотардай һәммә кеше арбалар чылбыры артында урын алсын. Ә ирләрегезне шушы тау битенә китереп бастырыгыз...

Ярты сәгать чамасы вакыт узганда инде инкүлектә баш-башлары куе чытырманлыкка барып терәлгән ыстан барлыкка килгән, тәртәләрен югары күтәреп бәйләгән бөркәвечле биек арбалардан, болай да мул итеп тутырылган йөк өстенә тиз арада корып куелган күчмә тирмәләрдән хасил ике катлы бу чылбыр үзенен ныклыгы, тыгызлыгы белән һич тә имән кирмәннәрдән кайтыш түгел иде. Буралкы, куй көтүләренен һәммәсен дә ыстан уртасындагы озын ерым эченә яшерделәр. Кулларына җинел аткылар, авыр җәяләр тоткан хатыннар, карт-коры, яшь-җилкенчәк арбалар чылбыры артында урын алды. Ә һәр сафка йөзәр-йөзәр булып баскан унөч мен җайдак чытырманлы тау итәгенә килеп тезелде дә, Тимучин әмерен көтә башлады. Баһадир фәрман бирсә, боларнын һәркайсы утка керергә дә, яу кырында башын салырга да шиксез әзер иде.

Торгытай нойон озак көттермәде. Ул Тимучинның көчен күптән беләдер, ә үзе белән утыз менлә гаскәр алып килгәнгә күрә масаюлы, борнай гына түгел, ваемсыз да иде. Кыят-нирунлылар корган ыстан янына житкәч, Торгытай аны ныклап күздән дә кичереп тормады, беренче төмәнен шундук һөҗүмгә ташлады. Бишәр-бишәр йөз булып тезелгән ун мең жайдак, әлбәттә, үзенең кыяфәте-көче белән үк дәһшәт бөркеп тора һәм коточкыч ташкын сыман килгән әлеге өермә үз юлында очраган һәрнәрсәне йомычка кебек сытып кына үтәр төсле иде.

Әмма мондый өермә-һөҗүмнәр кыят-нирунлылар өчен һич тә яңалык түгел иде, алар бу ташкынны да жил-давылга мәңге бирешмәс мәгърур имән сыман горур каршы алды. Тайжутлар төмәне Тимучин ыстанын канатларын җәйгән бөркет даладагы ялгыз төлкене каплаган шикелле тулаем уратып алса һәм туктаусыз ут янгыры коеп торса да, кыятлылар моннан бөтенләй дә диярлек зыян күрми, ә һөҗүмчеләрнең үз сафы исә бозлы янгыр чүкегән суган кыяклары сыман һаман егыла, һаман сирәкләнә бара иде.

Ярты сәгать буе уклар янгыры алышып торганнан соң, бернинди дә уңышка ирешмичә, тайжутлар төмәне кире борылып китте. Торгытай тәүге уңышсызлык, тәүге корбаннар белән исәпләшеп, баш ватып тормады, һөҗүмгә яңа төмәнен ыргытты. Бу юлы ун мең жайдакның яртысы кулларына башы тимер ыргаклы дәү сөңгеләр тоткан һәм Торгытай исәбе буенча алар әнә шул сөңгеләре белән арбалар-тирмәләр чылбырын өстерәп таратырга, өзгәләп ташларга тиеш иде.

Ләкин бу төмәннең ажгырып һөҗүмгә ташлануы да таш кыяга бәрелеп кире чәчелгән дингез дулкынына гына охшап калды. Тайжутларны һәр очракта умарта күче шикелле гүелдәп-гөжләп очкан ук вә сөңгеләр болыты каршылый һәм жайдаклар керпе сыман энәләрен кабарткан күчмә ыстан диварларына һич кенә дә якыная алмый иде. Өстәвенә Тимучин да хәзер яу барышында һәммәсен тәкъдиргә тапшырып һәм кул кушырып утыра яки бер яңагына сукканда икенчесен куя торган пошмас, үшән сәрдәр түгел иде шул инде. Һөҗүмнән соң тайжутларның көтүчесен югалткан куй көтүе төсле вак-вак төркемнәргә таралып бетүен күргә үк, Тимучин арбалар чылбырында «капкалар» ачарга боерды да, биш мең жайдакны шундук яланга ташлады. Тайжутлар кыятлылардан мондый елгырлык, кушйөрәклек көтми, чөнки алар бик ваемсыз иде. Ә кыят-нирунлылар ике арадагы бушлыкны селәүсен житезлеге белән очып узды да, тайжутлар өстенә ябырылды. Тайжутлар искә-анга килеп сафка тезелгәндә кыятлылар аларның инде ике меңнән артык жайдагын кырып салган һәм янә арбалар чылбыры артына кереп яшеренгән иде инде.

Торгытай шушындый хурлыклы кыйналудан да сабак алмады, ул тагын котырынып-ярсып жайдаклар ташкынын янадан-яна штурмга куды. Ә ташкын исә һәр һөҗүм барышында ким дигәндә бишәр йөз жайдагын югалтып һаман саен артка тәгәрәде. Инкүлеккә кичке энгер-менгер төшә башлаганда мондый берьяклы кыйнаудан һәм чолганышта торудан, ниһаять, Тимучин үзе дә туйды бугай. Берзаманны ыстан эчен тәвәккәл әмер авазлары ярып узды:

—Сулъяк баштагы арбаларны алып юл ачыгыз. Җәлмә, Хасар, Әбләй күремнәреннән кала барча меңлек тә кырга чыгыгыз да, унар катлы чылбыр булып шунда тезелегез. Чигенгән яки яу кырын ташлап качкан бер генә сугышчыны да гафу кылмыйм. Һәр сугышчы өчен—унлык, ә жебегәнлек күрсәткән унлык өчен йөзлек җавап бирә. Тәнре безнең яклы, без жинәргә тиеш. Барча магул ыруының бердәмлеге, бөтенлеге хакына алга, кыятлылар!

Тайжут сугышчылары орышта алжаудан бигрәк, Торгытай-сәрдәрләренең булдыксызлыгын күреп тә, чалырга салынган малныкы шикелле чарасызлык тойгысын кичереп тә инде сынган иде. Эре-эре шөпшәләр күче кебек яман гөжләп һәм үкереп килгән кыят-нирунлылар ташкынына алар тиешенчә каршы тора алмады. Яуны Тимучин сәрдәр үзе әйдәп

килә, ә аннан үрнәк алып канатланган кыятлылар, талпан сыман, дошманнарына теше-тырнагы белән ябышып сугыша иде. Аргамаклар ярсып кешнәгән, яралылар ачыргаланып кычкырган авазлар, тимер көбә, өзәнге-йөгән, кылыч-сөңге чыны дала өстендә берәр сәгать чамасы гына яңгырап торды. Ә аннары инде әлегә бөтенләй дә көтелмәгән хәбәр аяз көнне яңгыраган күк күкрәве сыман сафларны, даланы сискәндереп узды:

—Уранхайлар, уранхайлар кача!

Тимучин корт чаккан шикелле сискәнеп, кылыч селтәүдән туктады, кыятлылар сафына караш ташлады. Тәнрегә мең шөкер, Сүбүдәй батыр да, аның кишектиннәре дә—һәммәсе урынында, алар кылыч, сөңге, гөрзиләрен усал болгый-болгый орыша иде. Тимучин да янә орыш эченә ташланмакчы булды, ләкин өлгермәде. Тайжутлар ягыннан очырылган бер ук аның ияре астындагы аргамакның күкрәгенә килеп кадалды. Тимучин кисәк янга ауган ат гәүдәсе астында калудан көчкә котылып өлгерде. Ул сикереп аякларына гына баскан иде, кайсыдыр дошманы сөңге очы белән аның муенын берьяктан ярып узды. Күз аллары кисәк караңгыланган баһадирны кемдер бик җинел күтәреп яна ияр өстенә атландырды. Шул ук кеше, йөгәненнән сөйрәп, аның аргамагын орыш кырыннан читкә дә алып чыкты бугай. Тимучин боларны хәтерләп калырга өлгермәде, ул бөтен даланы тутырып кычкырган кыятлыларның тантана авазларыннан айнып китте.

—Исутлар, тайжутлар да кача башлады!

—Әнә, әнә, тайжут бәге Торгытай үзе дә кача!

Әйе, чыннан да, тайжутларда инде арысланнар шикелле ярсып орышкан кыят-нирун сугышчыларына каршы торырдай көч калмаган, алар идәнгә чәчелгән борчак сыман төрле якка сибелешеп яу кырыннан читкә элдертә иде.

—Миңа Торгытайны, Торгытайны тотып китерегез! Аны качырмагыз!

Үз-үзенә яман каты кычкырып әйткән шикелле тоелса да, әлеге әмерне биргән чакта Тимучинның тавышы гыжылдап кына чыкты. Шулай да ишеттеләр.

—Торгытайны качырмагыз! Торгытай артыннан!—дип, чылбыр буйлап әллә ничә кеше кабатлады да, йөзәрләгән җайдак тайжут бәге эзеннән томырылды.

Торгытайны нигездә яраннары—меңбашлары, бай сәүдәгәрләр, туган-тумачасы саклап бара иде. Кыятлылар әнә шул көенчә, һәммәсен берьюлы кулга төшерделәр. Кылыч-хәнҗәрләре йолкып алынган тайжут бәген дәү Сорхан-Шир Тимучинның аяклары очына китереп атты. Тимучин инде иярдән йомшак урындыкка күчеп утырган, кан күп югалтудан башы әйләнә, тәнендә жеп өзәрлек тә куәте юк иде. Шулай да ул дошманына һич тә көтелмәгән сорау белән мөрәҗәгать итте:

—Дөньяда иң татлы, иң баллы әйбер нәрсә ул, Торгытай, шуны беләсеңме?

Якын-тирәдәгеләрнең генә түгел, хәтта тайжут бәгенең карашына да гаҗәпләнү, аптырау чаткылары бәреп чыкты, ул бер сүз эндәшмәде. Аның өчен җавапны Тимучин үзе бирде:

—Дошманыңның каны, Торгытай, дошманыңның каны. Шуны онытма син... Хәер, моны ятлау сиңа артык инде... Сорхан-Шир!

Каршысында Мисыр пәһлеваны пәйда булгач, Тимучин кул гына изәде.

—Минем күз алдымда булмасын, читкә алып кит моны!

Ә Сорхан-Шир элеккеге хуҗасын әллә кая алып китеп йөрмәде бугай. Бер дилбегә озынлыгындагы арада ниндидер ыгы-зыгы тавышлары булып алды да, алар капылт тынды. Шуның артыннан ук Тимучинга Бавырчы сорау бирде:

—Без тайжутларның меңбашларыннан, вак-төяк бәкләрдән, батырлардан торган житмеш сигез аксөяген кулга эләктердек. Аларны нишләтәбез?

Тимучин бу юлы авыр гыжылдап, туктый-туктый гына җавап кайтара алды:

—Без магулларның бөтен кабиләләрен дә бергә берләштерү өчен олы юлга чыктык... Ә безне Торгытай оештырган эт өере таламакчы булды... Котырган этләрне кызганып тормыйлар... Безне алда яна яулар көтә... Башкаларга сабак булыр... Башкаларга сабак...

Тимучин аңын югалтты. Әмма аның хөкемен аңлап өлгергәннәр иде инде. Кыятлылар кылычларын кыннан чыгарды. Дала өстендә бер минут чамасы янә әҗәл биеп алды һәм җитмеш сигез гәүдә башсыз көенчә җир өстенә ауды.

Тимучин кемдер аның ярасыннан кан суырган чакта кабат аңга килде. Аның өстенә иелеп баскан кеше тугры Җәлмә икән. Шул ук Җәлмә аның ярасын ачыган сөт белән юды, үзенә әйрән бирде. Беркадәрле хәл кергәндәй булгач, Тимучинны җылы юрганга төреп яткырдылар. Янында кишектиннәр җитәрлек, инде онытылса, йокыга талса да була иде.

Шулвакытны аның янына бөтенләй дә таныш түгел япь-яшь егет килде. Чәче-кашы кап-кара, карашында шайтан биеп тора сыман. Гәүдәгә нык, кул-беләкләр таза.

—Мин исут кабиләсеннән, исемем Жиргүдай,—диде ул.—Тайҗутларның чирүендә идем. Яу барышында синең атыңны ул мин атып алдым. Җәяне күтәрсәм, үзеңне дә чүки ала идем.

Жигүдай тукталды, ниндидер хөкем көтте. Тимучин һичбер төрле хисен сиздермәде.

—Әгәр син мине әнә тегеләр шикелле үтерергә кушсаң, җир өстендә уч төбе кадәр генә чирәм кан белән пычраныр,—дип дәвам итте Жиргүдай үзе тәвәккәллек белән.—Ә инде исән калдырасың һәм үз гаскәрең сафына аласың икән, мин синең өчен дәрьяларны туктатырмын, кыялар җимерермен.

Ниһаять Тимучин да телгә килде һәм үз хөкемен җиткерде.

—Явыз кеше бүтәннәрнең җанын кыйганы яки угрылык кылганы хакында соңыннан чит-ятларга әйтми, моны яшереп йөртә. Ә син җәя күтәрүеңне миннән яшермәдең. Димәк, сиңа киләчәктә дә ышанырга була. Мин сине бүген үк унбашы итеп куям. Әйдә, минем кишектинем булып кал син.

Моны гына азсынды, күрәсең, Тимучин беркадәр уйланып ятты һәм соңыннан өстәп куйды:

—Ә лякабең моннан ары «Җәбә» булыр синең. Җәбә, ягъни ук. Кулың ялгышуны белми, син моңа бик лаек.

Егет канәгать елмаеп башын түбән иде. Соңыннан Чыңгызхан армиясендәге иң атаклы сәрдәрләрнең берсенә әвереләчәк, халкын данга күмәчәк Җәбә-нойонның хәрби юл тарихына нигез ташы әнә шулай салынды.

## Егерменче бәйләм

### 1

Ел артыннан еллар аккан сулар кебек уза торды. Мирхаҗи хәзрәт вафатыннан соң да ун кыш, ун җәй үтеп китте инде. Җиһанда унөч яше тулар-тулмаста дөмә-ятим калган Мөхәммәтгали ул гомер эчендә Болгар каласындагы икенче сыйныф мәдрәсәне дә, Биләрдәге «Мөхәммәт-Бакырыя» атлы югары мәдрәсәне дә тәмамлап өлгерде.

Мәдрәсәдә алар өч дус—Сәлим ханның бертуган энекәше әмир Хаҗи, Мәрчура вәзирнең хатыныннан туган төпчек улы Кылыч һәм әле бабасы Кормаш би акчасына, әле вакыф хисабына белем алган Мөхәммәт-

гали бергә укыдылар. Хәер, Мөхәммәтгали әмир Хажи белән Кылыч кына түгел, ә олы бер сыйныф өчен дә ымсындыргач, жылы учак шикеллерәк булды. Тыныч күл өстенә төшкән таштан таралган дулкыннар сыман Мөхәммәтгалидән дә тирә-якка жылылык бөркелеп тора һәм ул соңгы телем икмәген дә бүлешә торган беркатлылыгы, юмартлыгы белән һәммәсен дә үзенә тарта иде.

Мөхәммәтгали әтисе турындагы авыр хатирәләрне үз-үзе белән качышлы уйнаган кебек күпме генә онытырга тырышып яшәмәсен, әмма алар, барыбер, ана карынындагы яралгы сабый сыман әледән-әле уянып-тибеп ала, сискәндерә иде. Күнеләндә Сәлим ханга карата булган тирән рәнжү хисен чит кешеләр алдында сиздермәсә дә, Мөхәммәтгали бик еш кына уйчан, монсу кыяфәткә керә торган булды. Әтисе Мирхажи хәзрәтне сагынуданмы, дөмә-ятимлектәнме, мәдрәсәдә укыган тәүге елларында ук аңа шигырь-газәл язу чире йокты. Мөхәммәтгали язган шигырьләрен, эчке күлмәге сыман, чит-ят күздән хәтәр генә яшереп йөртсә дә, алар тора-бара, барыбер, шәкертләр кулына барып эләгә һәм, ни гажәп, сабакташларында күбрәк соклану, якты көнләшү тойгылары гына уята торган иде.

—Безнең Гали догадан шигырьне өстен күрә.

—Галинең шигырь юлларын фәрештәләр өшкерә, күрәсең. Язган бер газәле бисмиллалы, намазлыклы була.

Олуг мәдрәсәдә Мөхәммәтгали турында күбесенчә шундый сүзләр йөрде. Әмир Хажи да, барыннан да элек, аның нәкъ менә шул һәвәслеген якын итә иде бугай. Ничәмә-ничә ел дәвамында ул Мөхәммәтгали белән әле жиһан вә жәмгыять, әле галим-голәмә вә шагыйрьләр дөньясы турында әңгәмә-бәхәс куертырга ярата торган булды, сабакташының шигырьләрен тыңлап истирәхәт кичте. Алар «Мөхәммәт-Бакырыя»дан соң әле тагын Бохара, Үргәнеч югары мәдрәсәләренә барып та белем алу турында хыяллана иделәр.

Әмма вәкарь лачын белән мескен былбылларга бер үк иркенлектә-биеклектә очу язмаган шул. Әмир Хажи мәдрәсәне тәмамлауга ук Сәлим хан аны Болгар каласына олугбәк итеп озатты. Икенче дус—Кылыч Бәрәж мәчетендә имам-хатыйб булды. Мөхәммәтгалине генә күз чалымына китереп караучы да юк, ул һаман даладагы кылган сабагы сыман яклаучы-сыз, ялгыз һәм кадерсез иде.

Шулай да туктаусыз сыктап-елап торучы көзге яңгыр сыман гомернең дә берзаманны шифалы ялы да, якты кояшы да барыбер була икән. Мәдрәсәдәге дәрвишләр бүлмәсеннән кай тарафка чыгарга, кая барып бәрелергә белмичә йөдәгән Мөхәммәтгали янына беркөнне һич тә көтелмәгән чапкын килде.

—Богылтаудагы Казан кирмәненнән мин, әмир Хәсән юллады,— дигән аның тәүге сүзләрен ишеткәч, Мөхәммәтгали әле ни уйларга да белми тора иде. Чапкын авызыннан яна исем яңгырагач кына, ана сөенеч инде.

—Ирмәш хәзрәт белән әмир Хәсән сине олуг кунак итеп үз хозурларына дәшә.

Ирмәш хәзрәт. Аның мәрхүм әтисе Мирхажиның тугры мөриде булган, остазына терәк-юлдаш рәвешендә Таш-билбауны, Агыйдел, Дим, Сакмар, Жаек аръягындагы әллә ничаклы жәйләүләрне, кышлауларны бергә кичкән кеше. Әмир Хәсән хозурында, Казан кирмәнендә ул хәзер баш мөхтәсиб. Мөхәммәтгали аның турында әледән-әле һаман ишетеп тора. Ләкин инде байтак еллар буе үзен күргәне юк. Ә менә бит, ул ялгыз Мөхәммәтгалине дә, димәк, үзенең мәрхүм остазын да онытмаган икән.

Мөхәммәтгалине шашкын туфан сыман горурлык, тантана өермәсе капылт чолгап алды һәм ул сөенеченнән тышка бәреп чыгуыннан да бик үк тартынмады.

—И-и, Ирмәш хәзрәт чакыргач бармыйммы соң, мин һичшиксез барам!..

Биләр-Казан арасында табигать гел күзне иркәләп, күңелне кытыклап торганга күрә жайдаклар әледән-әле туктап ял итә-итә, юлны ашыкмыйча гына үттеләр. Казан дигәннәре кирмән генә түгел, хәзер инде шактый җәелеп үскән олы кала булып чыкты. Имән диварлар белән катлап-катлап ныгытылган кирмән үзе Богылтау һәм Елантау дип аталган ике тау өркәчен тоташтырып утыра. Кирмәнгә Акбикүл атамалы бистә кушылып киткән. Казансу белән Кабан күлен тоташтырган чип-чиста сулы Болак тирәли дә йортлар тезелешкән. Казансу аръягындагы тау битендә дә бер бистә бар, анда осталар яши, исеме Бишбалта икән.

Ирмәш хәзрәт, әлбәттә инде, Мөхәммәтгалине ихлас күңелдән сөенеп каршылады, мулдан бәреп чыккан күз яшьләрен яшерүне дә кирәк санамады. Мәрхүм остазын искә алган чакта аның өчен горурланып дәште:

—Эт ялмаудан елга каралмый ул, угылым. Элгәрерәк елларда Бәрәҗ хан акылын җуя-җуя шашкан иде, Сәлим хан да кимен куймады. Мәгәр «Кол» ләкабен алган Давыт бабаң да, Мирхаҗи атаң да гади халык күңелендә шәриф җаннар, хөрмәтле сәетләр буларак яшәп калды. Ярабби, Ходаем, синең дә исемен-калебен аларныкы төсле озын гомерле булырга насыйп әйләсә иде.

Әмир Хәсән сараена кунак булып баргач та, әңгәмә җебе бер тирәдәрәк йөрде.

—Арба астыннан чапкан эт «йөкне мин тартам», дип кукрая-кукрая уйлап бара икән. Мина җигән тиеш булган Сәлим хан да үзен җиһанның тоткасы, теге чакта пайтәхетне Всеволод Зур-Оя явыннан коткарып калган оста сәрдәр итеп саный бугай. Мәгәр улчак мәмләкәтне Сәлим-хөсет түгел, киресенчә, Мәмле-Гомәр белән Мирхаҗи атаң кузгаткан кара гавам яклап калды бит. Ә Сәлимгә алар ирешкән шөһрәт тә, алар яулаган җиңү дә ярамады. Тотты да, әнә шул кушаяклап чапкан хөсетлек нисбәтендә Мәмле-Гомәр белән атан-мәрхүм кеби ике изге җанның гомерен кыйды.

Ап-ак сакаллары, чәче белән шанлы галим-голәмәне хәтерләткән әмир Хәсәннең тирән үкенү аша, гаять моңсу итеп тезгән әлеге сүзләрен ара-тирә Ирмәш хәзрәт тә сипләп-калыплап барды.

—Нинди усал аккош та үз йомыркасын ватмый. Ни тикле генә үчле вә хөсет җанлы булмасын, мәгәр Сәлим хан да Мәмле-Гомәр белән Мирхаҗи хәзрәт кеби ике әүлиягә, ике әгъзам затка каршы кул күтәрергә тиеш түгел иде. Нә үкенеч, пеләш башка чал инмәгән кеби таҗдарларның җаны гел саңгырау гына була шул ул.

—Кайгырма, хафаланма, Гали-борадәр. Гайре кара төннең дә таңы атмый калмас. Хәтта кычытканны да кырау сугар чаклар барыбер килә бит ул,—дип әмир Хәсән Мөхәммәтгалинең иңеннән кага-кага сүзен очлап куйды.—Ә Казанда, минем олуг йортта, әйдә, үзеңне хуҗа итеп той да, ялын-сыен да күр, яңадан-яңа газәлләр дә тудыр.

Ләкин Мөхәммәтгалигә Казанда кунак рәвешендә истирәхәт кенә кичерергә дә, шигырь-газәлләр иҗат итеп күңел бушатырга да насыйп булмады. Ташчы-мигъмарлар Болак буендагы Ташаяк мәйданында яңа мәчет төзеп бетергәннәр, аны дога укып, бисмиллалап ачу тантанасы көтелә икән.

—Син Мөхәммәт пәйгамбәремезнең лаек оныгы. Яңа мәсҗет нигезенә изге дога кылу кеби олуг гамәл әүвәл синең өлеш,—дип, олылап-кыстап кунак егетне шуңа чакырдылар.

Биек, куш манаралары, иркен гыйбадәт заллары, нәкышьле мөнбәрләре белән яңа мәчет сокландыргыч, гүзәл иде. Тантанадан соң анар, алморт, йөзем, чия, кымыз белән бизәлгән табын янына кереп утыргач, Мөхәммәтгалигә мәчетне нигезләгән оста-мигъмарның үзен дә күрсәттеләр.

—Мәсҗедемезнең мөһәндисе дә, мосаннифы да[1] менә шушы Даир

[1]Мөһәндис һәм мосанниф—инженер һәм автор.

атлы оста була инде. Моннан утыз ел элгәре Әндри кенәз мәмләкәтемезгә каршы кылган тәүге зур яудан соң ул урысларның Вулдәмир каласында олуг нәсарә кәлисәсен нигезләүче булды. Хәзер инде ул каламыздагы зәркарьләр[1] вә мигъмарлар бие...

Шул атнада Даир оста Ирмәш хәзрәт белән Мөхәммәтгалине үз өенә кунакка дәшеп алды. Гүзәл, тыныч Кабан күленең камышлы ярына терәлеп утырган һәм хуҗаның үзе кебек үк аксыл-саргылт түбәле, шадра янак-диварлы, байтак елларны инәнә салганлыктан беркадәр җиргә чүгә төшкән таш йорт иде бу. Әмма эчкә ингәч, диварлары якты, бүлмәләре иркен, җылы икән. Инде кашларына тикле чал йөгергән, сөян таягын үзенең аерылмас юлдашы иткән Даир оста сүзен Мөхәммәтгалинең әтисе турындагы хатирәләрдән башлады:

—Мин Мирхаҗи хәзрәт илә ахирәт вә якын бораддәрләр булалмадым, купайту кирәкмәстер. Мәгәр аны Биләр, Болгар калаларында булган вакытларымда бик еш кына күреп тора идем. Ул берничә тел белүче укымышлылыгы өстенә гаделлек, хаклык вә азат тормыш бәрабәренә чакыру ташлаган шәриф сәет булганлыгы өчен дә мул шөһрәт казанды. Иллә мәгәр үтмәс балтаны үткен тел илә генә кайрап буламыни? Сәлим хан да ишетергә теләмәде аның кайгы-уен. Шуна күрә Мирхаҗи хәзрәтне ул, кул-аягын зынҗырлатып, пайтәхеттән куды. Мәгәр юкка. Саф чишмәгә илтә торган юллар һәрвакытта такыр кала бит ул. Иншалла, Мирхаҗи хәзрәт салган сукмакка аяк басучылар киләчәктә дә бик аз булмас әле.

Әтисе турында һәр йортта җылы, якты хатирәләр генә ишетү, әлбәттә, Мөхәммәтгалигә сөенеч һәм горурлык хисләре генә китерә иде. Даир оста йортында да ул вакыты-вакыты белән әле иннәренә канат үскәндәй очынып, әле монсуланып утырды. Шунадырмы дастархан өстенә бәлеш, гөбәдия, каклаган каз, кымыз, чия-карлыган кебек сый-нигъмәт инә башлагач та базга ябылган кешедәй үз алдына йомылып утырды һәм берзаманны Ирмәш хәзрәт тиз-тиз итеп терсәге белән төрткәләп алгач кына айнып киткәндәй булды.

Дастарханның бер як читенә, аякларын ипле генә бөкләп, озын, яшел күлмәкле, ап-ак алъяпкычлы бер кыз килеп утырган. Озын, нәфис бармакларын нәзакәтле сузып, ул җиз самавыр борыныннан бизәкле чынаякларга чәй агыза. Яулык читләре белән пөхтә капланган йөзен аска таба игән, чынаякларны дастархан тирәли тараткан чакта гына кунакларга керфек сирпеп ала. Аннан шылт иткән тавыш та ишетелми, үзен үтә тыныч, ипле, хәтта самими, садә тота.

Мөхәммәтгали башкаларга сиздермичә генә гел күз атып утырды...

Сый-нигъмәттән соң чыгып, өй артындагы агачлар күләгәсендә урын алгач кына, Даир оста аның турында берничә сүз әйтүне кирәк тапты.

—Зәрия атлы бердәнбер кызым ул минем. Әнисе аны тапкан чагында ук ошбу дөньядан китеп барган иде. Зәрия гел япа-ялгызы үсте. Ул минем багалмам да, канатым да булды. Яна җәмагать вә хезмәтчеләр алып маташмагач, Зәрия чит-ят белән бик аз аралашты.

Калган өстәмәне юлда кайткан чакта Ирмәш хәзрәт тезле.

—Зәрия сеңел гел Даир мигъмар белән юлда йөреп үсте. Пайтәхеткә барып йортлар төзиме, Кернәк яки Үбәк каласында мәсҗет саламы, Даир би һичбер вакыт аны үзеннән калдырмады. Ихтимал, шул нисбәттәндер, Зәрия сеңел чит-ят инсан белән уртак тел тапмады. Менә хәзер инде сазаган кыз булып бара. Ә бактың исә, ул баланың күнеле фәрештәләр үпкән ап-ак чишмә кеби.

Мөхәммәтгали инде Ирмәш хәзрәтнең тел төбен дә, киная сен дә тоемлый башлаган иде, җавап итеп бер сүз эндәшмәде. Ә Ирмәш хәзрәт һаман саен акрын гына игәүләвен белде.

—Ялгыз кеше тормышы болытлы көн шикеллерәк бит инде ул. Үз

[1]Зәркарьләр—һөнәр осталары, ювелирлар.

әнигә кереп качкан яралы бүре сымак ошбу җиһанда япа-ялгыз көе яшәп буламыни? Синең якын борадәрең дә, сердәшчең-терәгең дә юк. Ирнең вәзире—хатын ләбасә. Сонармыйча башлы-күзле булу синең өчен аерата отышлы гамәл сыман саналыр иде. Бирәм дисә колына, чыгарып куяр юлына, ди. Синең өчен андый кулай форсат тагын кайчан туа әле?

—Өйләнү—камыт кию түгелме соң?—дип, шаяртуга борып маташса да, Мөхәммәтгали күңелендә дә уй һәм исәп-хисап учагы барыбер ут алды. Читән казыксыз булмый, кеше кешесез тормый, дигән бәхәссез гыйбарәне ул да йөз кат, мең кат ишетеп үсте ләбаса. Әйе, ул да иркә-наз, жылы куен һәм жылы түшәк күрмичә байтак гомер кичте. Янында күңел бушатырдай киңәшчесе, ныклы терәк, сагынып кайтырдай жылы оя пәйда булса, ихтимал, аның хәят юлын да якты, назлы кояш яктыртып торыр иде. Аннары... аннары корыган агач кәүсәсе шикелле шыр-ялангач, шыр-хәерче бәндәнең аны мәңге аерылмас кара күләгә сыман эзәрлекләп йөргән сырхавы да бар бит. Мөхәммәтгали байбичә балалары арасындагы кәләшләргә йөз тотып, алар өчен тау-тау калым хәстәрләү кебек гайре чит-ят гамәл турында хыяллана, андый ярлар белән тормыш коруны күз чалымына китерә аламыни?

Башлы-күзле булу турындагы уйлар Мөхәммәтгалине тирән упкын төбен күрергә омтылу сыман инде ымсындыра да башлады, әмма шул ук вакытта икеләндерә дә иде әле. Шуны сизгән кебек, Ирмәш хәзрәт дилбегәсен кага-суга кызулата төште. Ул беркөнне Мөхәммәтгалине алдан кисәтми-нитмичә Даир оста белән кызы Зәрияне кунакка дәшеп алды. Тәбикмәк булып җәелергә дә әзер кеше сыман, тегеләрнең бер алдына, бер артына төште. Ә кунакларны озатып калуга янә Мөхәммәтгалине төрле яктан килеп игәүләде.

—Күп сайланган кияүгә пеләш кәләш эләгә ул, бик беләсең килсә. Зәрия сенелне сылулар рәтенә куймыйсың, шул сәбәптән үзенә тиң санамыйча кыйланган буласыңдыр инде, мөртәт. Мәгәр кәләшнең йөзеннән кашыклап су эчмиләр. Чибәрлек-сылулык туйда гына кирәк. Ә гомер итә башлагач, йөзе сылу түгел, киресенчә, йөрәге вә мәхәббәте кайнар җәмәгать сөйкемлерәк тә, кадерлерәк тә була бит ул. Син өрәк сыман япа-ялгыз каңгырап йөрмәкче буласыңдыр инде. Юкса, Зәрия сенелдәй фәрештәдән йөз чөермәс идең...

Янгыр тамчылап тамса да зур күлләрне тутыра, дигән хакыйкать тора-бара, барыбер, үзенекен итте. Янә ике-өч мәртәбә кунакка барышканнан соң, ниһаять, Мөхәммәтгали сынды. Икенче таңда ук Даир оста йортына яучылар юлладылар. Шул атнада Ирмәш хәзрәт йортында никах тантанасы да, тыйнак кына мәжлес тә булып узды.

## 2

Берәр айдан соң Мөхәммәтгали Болгар каласына төбәп юлга чыкты. Иксез-чиксез булган мәмләкәттә аның таянырдай башка кешесе юк, бар өмете әмир Хажи иде. Ходайның рәхмәте, сабакташы аны тибәрмәде, зур сөенеч белән үз ышыгына алды.

—Хәсән мәсжете атаң Мирхажи хәзрәт вафатыннан бирле ятим көе тора. Әйдә, хужа булып ал да, жан керт син шуңарга. Киләчәктә күз күрер. Иншалла, шәһре Болгарның мөхтәсибенә тиклем үсеп житү дә синең өчен гайре ят булмаган бер гамәлдер.

Халык күңелендә фәкать изге жаннар гына булып сакланган Кол-Давыт һәм Мирхажи сәетләр дәвамчысы Мөхәммәгалинең имам-хатыйб итеп билгеләнүе үзе үк болгарлылар өчен озак еллар буе тынчып яткан буаны ерып жибәрү сыманрак тәэсир ясады бугай. Беренче атналарда ук Хәсән мәчетенә намазга йөрүчеләр саны арта башлады, мәдрәсәдәге һәм мөтәвәллияттәге эшләр тернәкләнеп китте. Нәзарәт һәм дәрвиш бүлмәләрендә мөнәзара-гапь корырга, яңа имам-хатыйб каршында күңел

бушатырга, аның авызыннан якты, өметле сүз ишетергә атлыгучылар да бик аз түгел иде. Ләкин мондый әңгәмә-бушанулар ешрак кабатланган саен болгарлыларның кайгы-зары һаман-һаман бер үк эзгә кайтып кала торган булды.

—Соңгы елларда нә урыслар, нә бәгъзе дошман тарафыннан яу белән килүчеләр дә юк ләбаса. Ә Сәлим хан игенче вә төзүчеләрдән салым җыю күләмен һич киметми. Мәмләкәттәге һөнәрчелек белән сәүдәгәрлек чоңгылга төшеп бара.

—Кара эткә ак йон үсмәс, дигәннәре растыр инде. Ябай халык турында уйлау ханиянең ике ятып бер төшенә керми. Ул гавамны көнтөн талауны гына белә. Бер сарыктан тирене ике кат тунамакчы. Ә гавамның авызын ачса, үпкәсе күренеп тора.

—Нык кыздырган казандагы су да, кайнап чыкса, бермәл түгелә бит ул. Гавамның да түземлеге күптин корыды инде. Ханиянең дә комсызлыгы үзенә җәза-бола булып кайтмагае...

Мөхәммәтгали ялгыз калгач, эчтән сыза башлады, торган саен ачыныбрак уйларга мәҗбүр булды. Күңелендә йөрткән кайгы-зарын халык юкка гына аның колагына китереп ирештерми, заманында Давыт һәм Мирхаҗи сәетләр иңендә таяныч тапкан кебек бүген алар, әлбәттә, инде Мөхәммәтгали тарафыннан яклау көтә иде. Асылдан торып баксаң, мөгаен, ул изгеләр рәтендә саналучы бабасы белән әтисе башлаган гаделлек вә азатлык өчен көрәш-яуны дәвам итәргә тиеш бер инсандыр. Ләкин Мөхәммәгали җиһанда буш келәт йозагы шикелле япа-ялгызы бит. Аның мөридләре-фәлән генә түгел, хәтта, сере-ниятләре сыярдай сердәше, фикердәше дә юк. Ә ул берьялгызы гына баш күтәрсә, ни генә кырсын да, ни генә майтарсын? Ялгыз йөрәк ялкыны белән генә өй дә җылынмый бит ул.

Мөхәммәтгали ерakka түгелми-чәчелмичә дошманы Сәлим хан ыстанын да күз алдыннан кичереп чыгарга мәҗбүр булды. Сәлим ханны тәхет иминлеге турында баш ватмыйча ваемсызланып, кул кушырып утыра, дип һич бәяләп булмый. Моннан унбер ел элек күтәрелгән халык фетнәсеннән соң ул мәмләкәттәге байтак кала бәкләрен, сарай тирәсендәге яраннарын яңартып чыгарга өлгерде. Курку һәм буйсыну белмәс Сәмәрә бикәдән туган Гази-Морат хәзер мәмләкәтнең башсәрдәре булып исәпләнә. Элеккеге сәрдәр Тургай баһадир Саксин каласына тархан итеп озатылган, диләр. Сувар каласында бәк урынын мәрхүм Чилбирнең угылы Гази-Бәрәҗ алган. Никадәрле генә дәһшәт бөркемәсен, хәтта, шул «ярканатлар» башлыгы, килмешәк Лачын Хисами да ахыр чиктә сарай курчагына әверелгән бугай. Сәлим хан Кернәк каласына бәк итеп озатканнан соң Хисаминың тын алганы да ишетелми, диләр. Имеш, хан әле баш вәзирен дә алыштырмакчы булган, аның урынына Хәзәр дингезе буендагы Хаҗитархан кирмәненнән Дәүләтьяр атлы бәкне чакырган да икән. Мәгәр фәлән кулдан үткән фахишә шикелле елгыр, оста Мәрчура хан күңеленә юл тапкан да, купмас кыя булып һаман үз урынында калган. Байбичә катламы турында имеш-мимешләр ил буйлап күп йөри. Сарай тирәсенәрәк үтеп аларны ачыкласаң артык булмас иде дә бит. Ләкин хан сарае—оҗмах ишеге кебек, Мөхәммәтгалигә аннан үтү мөмкин гамәл түгел.

Көз житеп, шырпы сыман кыска, өтек көннәр, аккош муенындай озын-озак кичләр тезелеп киткәч, Мөхәммәтгали бабасы, әтисе әйдәкләп кузгаткан фетнәләр турында торган саен ешрак уйлана башлады. Кол-Давыт белән Мирхаҗи сәет тә Алланың кашка тәкәләре булмаганнар бит инде. Бүтәннәр өчен яши белмәгән—үзе өчен дә яши алмый ла ул. Бер белән сукмак салганчы, күп белән бергә адаш, диләрме әле? Аның ата-бабасы да әнә шул гади халык, кара гавам хакында янып-көеп фетнә ялкынын кабызган. Байбичә катлам арасында соңыннан аларны гыйсъянчылар, тәхеткә омтылган хөсет жаннар итеп телгә алучылар да аз булмады. Ләкин нахак сүз—агымсу, ә хакыйкать елга төбендәге ком катламы кебек. Сулар агып китә, ә алтындай ком барыбер кала бит ул. Кол-Давыт белән

Мирхажи сәетне дә инде ничә еллар буе гади халык фәкать изге җаннар итеп кенә искә ала, сагына. Ә Мөхәммәтгали тәнендә шул юлбашчылар, гыйсъянчылар канын йөрткән дәвамчы ләбаса!

Анын күнеленә кереп кунаклаган әнә шундый уйлар ярык көймә эченә саркылган су сыман торган саен аза, кимерә барды. Җир өстенә беренче кар явып үткән көнне Мөхәммәтгали инде түзмәде, үз алдына килеп монзар түккән дүрт-биш ирне дәрвишләр бүлмәсендәге чәйгә алып калды. Мәдрәсә шәкертләре йөгереп керткән самавырның чәе ирен өтәрдәй кайнар, Мөхәммәтгали хәзрәтнең тел очыннан сибелгән сүзләр исә аннан да кайнаррак иде.

—Сәлим хания үзен ил тоткасы, мәмләкәтне сөйрәп баручы, дип уйлап хаталана бугай. Ә арбаны камчы түгел, асылда исә ат, ягъни кара гавам тарта бит. Хания шуны аңларга теләми, ул халыкны рәхимсез талауны гына белә. Гавам-атның ничә еллар буе солы күргәне юк, аның сырты-җилкәсендә һаман камчы уйный. Ябай халыкның түзем коелары күптән корыды, миңа калса, аны язгы ташкын кеби кузгату, уяту өчен күп көч кирәк түгел.

«Мин дөрес сөйлимме?»—дигән кыяфәт белән Мөхәммәтгали самавыр тирәли тезелгән ирләрне күздән кичереп чыкты. Ирләр моны шундук аңлады, күрәсең, кайсы ияк кагып, кайсы сүз катып имам-хатыйб фикерен җөпләргә ашыкты:

—Дөрес, Гали хәзрәт, түземлекләремез күптән коргаксыды.

—Болай да тәндә чак чыкмаган җан гына калды бит инде. Ханның талавына күпме түзмәк кирәк?

Аһәндәш фикерләр белән илһамланган Мөхәммәтгали әңгәмәне тагын мөгезеннән эләктереп алды:

—Сыңар учак ягып ил җылытып булмый. Безгә дә бәгъзе-бәгъзе тарафларда—Болгарда, Суварда, Кернәктә, Саксинда, пайтәхетнең үзендә—кыскасы, һәммә җирдә Сәлим хан идарәсе белән ризасызлык, гаделлек хакына көрәш утын кабызырга кирәк. Мин үтә дә күп уйландым. Гаделлек белән азатлык өчен ихтилал явына кузгалуны яшерен фирка төзүдән башламыйча булмый. Анын шартлы исемен гүзәл яз хәбәрчесе—карлыгач-лар белән тәгаенләрмез. «Карлыгачлар». Җылы, якты исем бит. Ә хәзергә фиркамезнең нигезе ошбу мәсҗет булыр. Иманым камил, без салган сукмак эзенә күпләр аяк басар. Әйдә, ихтилалчылар сафына яңа яугирләр-не бергә-бергә туплый башлыйк, тугры җаннар булыйк, борадәрләр...

Ирләр гаделлек, хакыйкать хакына баш салырга да әзер икәнлекләре турында антлар эчкәч кенә таралышты. Болгар дәүләте эчендә әнә шул рәвешчә янә яңа ялкын купты. Ни гаҗәп, мондый хәвефле эшкә ут тергезүче Мөхәммәтгалинең үзен һичнинди үкенү, икеләнү тойгылары биләп йөдәтмәде. Киресенчә, күк капусы ачылып фәрештәләр «ләббәйкә» әйтте диярсең, шушы кичтән соң анын күнеле яңа гына юып чыгарылган йорт шикелле чистарынып, бушанып калган иде.

## 3

Вакыйгалар агышы «Карлыгачлар»га үз сафларына биш йөздән дә артыграк көрәшче тупларга ирек калдырмады. Күз карасыдай саклаган соңгы бөртек орлыкларын талап китүгә түзмичә, яз көне Мәртүбә вилаятендә ар, мукшы һәм чирмешләр баш күтәрде. Аларның карчыгадай елгыр җайдакларыннан төзелгән бер чиру, адәм генә түгел, боланнар да кереп адашырдай карурманнар аша сиздермичә үтеп, Корым-Чаллы каласын яндырып китте. Балта осталарын, һөнәрчеләрне туплаган икенче нөгәр дә ул арада тик ятмаган икән. Монысы Кара-Идел буена ук килеп, Килдеш атамалы яңа кирмән төзи башлаган. Димәк, чик сызыгын шушы елгада билгеләп, ар-чирмешләр Болгар мәмләкәтеннән аерылмакчы булган.

Билгеле инде, шәхсән Сәлим, хан үзе дә, бәкләр, биләр һәм тарханнар да дәүләт жимерелү-таркалуга «ләббәйкә» дип торачак түгел иде. Сәлим ханның шыпырт кына сызгыруы да житте, Биләр, Болгар, Сувар, Үбәк, Кашан, Жүкәтау, Ашлы, Чаллы, Кернәк—кыскасы, һәммә кала алайлары «ә» дигәнче Казан кирмәне янына жыелдылар. Бу кадәр көч әле моржа тәтенен дә татып өлгермәгән Килдеш кирмәнен жир белән тигезләп кенә калмады, бер уңайдан эржә, мукшы аймакларын да туздырып, талап узды. Ар-чирмеш халкының янә тез чүкмичә һәм Сәлим ханга тугры булырга ант китермичә чарасы юк иде.

Болгар мәмләкәте эчендә купкан әлеге буза-фетнә турындагы хәбәр шул арада урыс жиренә дә барып житкән. Бөек Болгар инде алты-жиде ел буе күрше ушкуйларыннан һәм комсыз чирүләрдән талау-бимазалау күрмичә генә, тыныч яши иде. Ләкин йоны коелса да, бүренең холкы-бирәнлеге үзгәрәмени соң ул? Кала алайлары Мәртүбә вилаятен туздырып йөргән чакта Болгар мәмләкәтенә Чулман яклап янә Новгород, Галич, Муром ушкуйлары бәреп керде. Юлларында каршы торырдай житди көч булмагач, алар тиз арада Ага-Базарга кадәр үк килеп житте. Болгар каласы керпе сыман бөгәрләнде, капкалар бикләнде, диварлар өстендә, манараларда яше-карты, күбрәк һөнәрчеләр урын алды. Бөтен мәмләкәт хәвеф-шомга чумды.

Ил эчендә дошман чирүе еландай шуышып йөрсә дә, пайтәхеттә түнтәреш ясау, инде анысы барып чыкмый икән, һич югы Сәлим ханга сабак бирү, аны акылга утырту өчен кулай чак иде бу. Яшерен фирка башлыгы Мөхәммәтгали моны бик тиз аңлап өлгерде һәм Болгардагы «карлыгачларына» кыска-кыска күрсәтмәләр биреп калдырды да, үзе пайтәхеткә таба ашыгып юлга чыкты.

Биләр каласында да яшерен фиркачеләрдән хасил төркем инде нигезләнгән, ләкин ул әле һаман әйдәүчесез, житәкчесез иде. Бу урында фәкать аны гына күрергә зур өметләр баглап, Мөхәммәтгали үзенең сабакташы, яшьлек дусты Кылыч янына китте. Озак күрешми торганнан соң очрашу олы шатлык иде, күрәсең. Кылыч аны кочагын жәеп каршылады. Мөхәммәтгали хәл-әхвәл сорашып торырга да ара калдырмады, килүенең максатын шундук ачып салды:

—Сәлим хан күзенә ак-караны күрми азына, гади халыкны талаудан гайре һичбер гамәл белми. Мәдрәсәләр, шәригать, сәүдә, төзүчеләр турында кайгыртып аның инде унбиш-уналты сәнә буе аркылыны буйга алып салганы да юк. Болгарны андый томана вә бирән таждардан азат итү өчен бик тә уңай форсат килеп чыкты. Сәлим ханны тәхеттән чәнчелдереп төшерергә вакыт!

Кылыч, әлбәттә, һични аңлый алмый һәм ул Мөхәммәтгалинең тиз-тиз тезгән кыргый сүзләреннән соң, хәтта, коелып төшкән иде. Сабакташы сулыш алган арада ул ике-өч сорау гына биреп калырга өлгерде:

—Тукта, Гали, тыр-тыр килмә әле. Сәлим ханны ниндәй көч, ниндәй куәт илә чәнчелдермәкче буласың да, аның урынына кемне куймакчысың? Лаек алмаш булмаса, сиңа эт тә иярәчәк түгел.

—Ходайга мең шөкер, бар ул андый алмаш,—дип, Мөхәммәтгали янә ялкындай кабынды.—Безнең белән укыган әмир Хажи менә дигән хан булырдай инсан. Син үзең дә яхшы беләсең бит. Әмир Хажи галим-галәмәне дә, газәл осталарын да сөя. Чичән-галимнәрне сөйгән бәндә вак вә керле жанлы булмый. Өстәвенә, ул болай да гаделлекле, чиста. Ул тәхеткә менсә, игенче вә һөнәрчеләрдән икеләтә-өчләтә салым талауны шундук туктатачак. Мона минем иманым мең-мең тапкыр камил.

Кылычның карашында ниндидер зәһәр ут чагылды.

—Сине әмир Хажи котыртып жибәрдеме, әллә мондый тайгак юлны үзең сайладыңмы?

Мөхәммәтгалине ачу-ярсулы хис биләп алды бугай, тавышы калтыранып, өзек-өзек чыкты:

—Нишләп Хажи котыртсын? Минем моның ише юлда йөргәнлекне

әмир сабакташ үзе белми дә бит. Мин Сәлим ханны алыштыру гамәленә күздән үк ябыштым. Кышкы айлар эчендә шушы ниятне хуплаган биш йөз кешелек фирка төзеп куйдым. Алар түнтәреш башларга чакыру гына көтә. Без кузгалсак, артыбыздан меңнәр иярәчәк. Мона икеләнмим.

Күзләрен майландырып, Кылыч төпченергә тотынды:

—Ә сез кайчан кузгалырга җыенасыз инде? Шартлы чакыру дигәнең нидән хасил?

Мөхәммәтгали элеккечә ялкынланып тезүен дәвам итте:

—Болгарда Хәсән мәсҗетендә калганнар белән сүз беркеттек. Алар Сувар, Җүкәтау, Тубылгытау, Кашан кеби калаларга чапкын юллаячак. Атнакичтә һәммәмез дә монда җыеламыз. Шул ук төндә хания сараена бәреп керергә ният. Сәлим ханны кулга төшерә алсак, әмир Хаҗи артыннан ашыгыч төстә чапкын җибәрәчәкмез.

Кылыч хәзер инде керфекләрен кыса төшеп,сынаган сыман дәште:

—Каудар гамәлгә иблис катыша бит. Син вакыйга-хәлләрне чамадан тыш куаламыйсыңмы, Гали борадәрем?

—Олуг гамәл кылырга тәвәккәлләгән инсан юлдагы чокыр-чакыр саен туктап тын алмастыр. Йодрык төйнәгәнсең икән, суга да бел. Гаделлек өчен көрәштә чигенергә һич тә ярамый. Күнеле пакъ инсан өстендәге күлмәген дә гел янартып тора. Тәхет иясе исә күлмәк кенә түгел. Гаделлек вә миһербанлык кеби шәриф хисләрне белмәгән Сәлим ханны инде күптән алыштырырга, чаң сугарга вакыт.

Шуннан ары Кылыч үзенең сабакташын үгетләп яки аның фикерләренә каршы төшеп маташмады, суга салган камыш сыман тынды. Аерылышыр алдыннан соңгы сүзләрен Мөхәммәтгали кырт кистереп әйтте:

—Атнакичтә синең Бәрәҗ мәсҗете манарасыннан ястү намазына дәшкән азан тавышын фиркачылар өчен шартлы чакыру булыр. Азаныңны бөтен калага ишетелерлек итеп әйт. Сарай мәйданына барча инсан җыелырлык булсын. Ә ил төкерсә, күл булмыйча калмас. Иншалла, без җинәрмез!..

## 4

Мөхәммәтгалине төнлә белән килеп кулга алдылар. Ул алдагы көндә фетнә хәстәрләре белән йөгереп йөри-йөри эт булып арыган һәм үзенең фиркасендәге бер «карлыгач» йортына сагыздай карангылык ингәч кенә кайтып ауган иде. Курсыбай газиләре типкәләп уяткан чакта ул әүвәл әле берни аңламый торды. Ә тегеләр аның кулларына элмәк салдылар да, пайтәхетнең иң әшәке «Шайтан бугазы» дип аталган зинданына илтеп ыргыттылар. Таң атканда зиндан читлекләре инде йөзәрләгән «карлыгачлар» белән шыплап тулды.

Мөхәммәтгали зинданның башкалардан аерым, имән бүрәнәләр белән ныгытылган кысан читлегендә тотыла иде. Ләкин зиндан сакчылары да тоташ залимнәрдән генә тормый икән, алар арасында гыйсъянчы хәзрәткә хәерхаһ кешеләр табылмый калмады. «Карлыгачлар»ның тоткын ителүе турындагы хәбәрне шулар хәзрәт колагына китереп ирештерде. Бичара «карлыгачлары» өчен сызлану-көюдән Мөхәммәтгали зиндан идәненә сыгылып төште. Әлбәттә, ул үзен ханга кем сатканын инде күптән аңлап алган һәм кабынырга да өлгермәгән учакның харап булуына фәкать үзен генә гаепләп битәрләнә, өзгәләнә иде. Ышанычсыз кешедән исеп үткән җил яхшы, ди. Хыянәтче Кылыч каршында мунчага кергән килен шикелле бөтенләй чишенеп ташлап ул үзе, мокыт, гайре ялгышты шул. Акыллы кеше уйлап бетергәнче, Икейөзле вә хыянәтче бәндә өчәр кабат тешли. Менә, сабакташы, дусты саналып йөргән сатлык Кылыч та аны елан сымак чакты. Мөхәммәтгали үзе җәллад балтасы астына ятарга яки дар агачына менәргә дә әзер, ичмаса, «карлыгачлар»ны җәзамихнәтләрдән йолып калырга насыйп булса иде.

Зинданның зәһәрдән-зәһәр камчылар, тимер кыскычлар, шөшле-

безләр белән шыплап тутырылган таш бер бүлмәсенә кара төн уртасында Сәлим хан үзе килде. Мөхәммәтгали белән икесен шул бүлмәдә япаялгыз көе калдырдылар. Тәүге сүзне, әлбәттә, таждар үзе катты:

—Әҗәле житкән карга бөркет илә шаярыр, ди. Элгәре елларда тинтәк бабаң илә атаң фетнә кузгатып әҗәл тапкан иде. Син мертәткә ни житмәде инде?

Кул-аякларына зынжыр салынса да, Мөхәммәтгали башын текә тотып сөйләште:

—Бичара бәндә тәненә килеп кадалган талпан туену-чик белмәс, канны үзе бүкәй тикле булып, шартлаганчы суырыр. Син дә әнә шул талпаннан бер дә кайтыш түгел. Мәгәр, Ходайга мең шөкер, гади халык сарык көтүе кеби дәшми генә түзми. Бүген ялы булса да, һичшиксез, ул тездә яшәүдән чирканган мәгърур баһадирдыр. Иншалла, ул да савыгыр вә бирән таждарны үз сыртыннан чәнчелдерми калмас.

Сәлим хан күкрәгендә ачу-ярсу давылы кузгалды, күрәсең, тавышы калтыранып чыга башлады:

—Син юкка гына көндез йолдыз күрергә ниятлисең, кабих. Синдәй этләр өргәннән генә күк йөзендә Ай да, йолдызлар да сүнми. Бер саламга ут капса, бөтен кибәнең яна. Син дә яшерен фирка нигезләп, янгынга тиң фетнә-түнтәреш куптарырга җыенгансың. Мәгәр сиңа шайтан уты белән хозурлану бәхетләре һич тәтемәс! Еланның койрыгын түгел, башын өзәләр ул. Мин дә әүвәл син ата гыйсъянчыны җәллад балтасы астына озатам, аннары инде бөтен мөриденне дарга тотып асам!

Соңгы сүзләр куырып алды, ахры. Мөхәммәтгали кәфенлек кебек агарынды, шулай да мескенләнү-түбәнсенүне белми җавап бирде:

—Мин фиркагә ялган вәгъдә биреп яки көчләп керткән гөнаһсыз инсаннарның нинди гаебе бар? Аларның берсе дә үзен кан вә гөнаһ белән таплап өлгермәде. Бер гаепсезне асканчы, ун гаеплене акла, дип өйрәтә түгелме соң безне Коръән хәдисләре? Шулай икән, насыйп иткән җәза-казаны да мин ялгыз көе кичерергә тиеш.

Мөхәммәтгалинең йомшак ягын Сәлим хан, әлбәттә инде, бик тиз тоеп өлгерде һәм кансыз җәллад сыман һаман саен шул ялы төшкә тоз салды:

—Күсәк күтәреп килгән дошманыңны бүрек салып сәламлиләрмени? Ю-у-у-к, хәзрәт-хәшәрәт! Бүрене кызганган тинтәк хуҗа сарыксыз кала ул. Киләчәк елларга да олуг сабак булсын. Мин биш йөз угырны да дарга озаттырам! Биш йөзен дә!

Әче каһкаһә, усал тантана белән яңгыраган кыргый тавыштан соң, Мөхәммәтгали әүвәл сынып төште, сүзләре ярымпышылдаган сыман ишетелде.

—Эт намазы ишетелсә, күктән ит явар иде, дигәннәре хактыр инде. Хан колагы мәрмәр дивар кеби, аны борчак атып йә ялварып кына һич тә тишеп булмый. Мәгәр...—Мөхәммәтгалинең тавышы кинәт затлы корыч сыман яңгырап-зыңлап китте.—Мәгәр елгаларны ансат буып була, ә халыкның авызын томалап булмый бит ул, сукыр хания!..

Мөхәммәтгалигә алга таба сүз әйтергә ирек куймадылар. Сәлим хан ниндидер күзгә күренмәс җепне тартып әмер бирде, күрәсең. Таш зинданга әзмәвердәй өч-дүрт җәллад юлбарыс сыман ыргылып керде дә, шуларның кылый күзлесе Мөхәммәтгалинең муенына күсәк белән орды.Мәхбүс хәзрәт шул мизгелдә упкын төбенә очса да, барыбер, иреннәре арасыннан бер сүз яңгырап калды:

—Сукыр хания!

## 5

Ничәнчедер көннән соң биш йөз «карлыгач»ны чыбыркылап куа-куа Биләр читендәге уйсулыкка чыгарып бастырдылар. Уйсулык төрле яктан курсыбай газиләре белән уратып алынган һәм шушында

ук, икенче як ярда, зынҗырларга уратылган тагын өч мең кешелек яңа бер тоткыннар төркеме үзенә хөкем-җәза көтеп тора иде. Килешкилбәтләренә күз ташлагач әлләни баш ватарлык җирлек тә калмады. Болар—болгарлар кулына әсирлеккә төшкән урыс ушкуйлары, Мәртүбә вилаятеннән кайтып өлгергән Гази-Морат гаскәре аларның исерек нөгәрен Ага-Базар инкүлегендә тар-мар иткән икән. Әсирлеккә эләккән өч меңнән артык ушкуйны шушы үзәнлеккә куып китергәннәр дә, хәзер инде аларны Сәлим хан, сәрдәр Гази-Морат, кала бәкләре Лачын Хисами, Гази-Бәрәҗ, Турай белән Уразай батырлар үзара бүлешергә тиеш икән. Бу кадәресе янәдан, уйсулык читендә Сәлим хан үзе пәйда булганнан соң гына ачыкланды.

Ул яраннары, вәзирләре белән яланга Шәрекъ капкасы аша килеп чыкты. Ияр астындагы алмачуар айгырның инде күптән дала, ирек күргәне юк иде, ахры. Күтәртмә күпер өстеннән дөңгердәп чыгуга ук яшь айгыр әле уңга-сулга ыргылып, әле алгы аякларын сикертеп уйнаклады. Сәлим хан, әлбәттә, ат күрмәгән кеше түгел иде. Алмачуар айгырына тузынырга ирек бирсә дә, ул ияр дә коеп куйган сын шикелле селкенмичә дә утырды, йөзендә канәгать елмаю чаткылары гына балкып торды.

Хан өстенә алтын җепләр белән нәкышьләп чигелгән озын җилән кигән. Билендә ике уч белән дә каплап бетермәслек алтын аел куелган киң һәм затлы каеш. Баш түбәсенә мәрҗән ташлар, нәфис каурыйлар белән бизәлгән ап-ак чалма элгән. Төс-кыяфәтенә карагач шик-фәлән юк, ханның кәефе бүген күктәге йолдызны эләктергән кешенеке сыман күтәренке, дөньясы түгәрәк иде.

Башта ул газиләр чылбырыннан бер як читтә җыелып үзен көткән сәрдәрне, кала бәкләрен күз чалымына да китереп тормыйча әсир ушкуйлар төркеме янына юыртып үтте. Әле һаман да сикереп уйнаклаган айгырны тезгенен тартып баса төшкәч, әлләни озак сузмады, борнайланып тегеләргә дәште:

—Чит мәмләкәт авыл-калаларын таларга, җимерергә килгәнегез өчен сезне үлем җәзасы көтә. Билгеле, һичбер угрыгызның да күңелендә ошбу юнәлештә икеләнү юктыр. Шулай да әгәренки вәли таҗдар түбәнчелек илә шәфкатьлелек күрсәтеп үлем җәзасыннан азат итсә, киләчәктә аның тугры коллары булырга ризамы сез?

Сөенечләреннән дәрьядагы дулкыннар шикелле уйнаклый башлаган төркемдәге әсирләр берсен-берсе уздырып кычкырышты:

—Риза, риза, хания! Без, һичшиксез, риза!

Сәлим хан хәзер инде иярендә вәкарь сикергәләп гыйсъянчы «карлыгачлар» төркеме янына юнәлде. Милләттәшләренең каршына килеп баскач, байтак вакыт буе эндәшмәде. Беркадәр кысыла төшкән керфекләре арасыннан мәсхәрәле, каһкаһәле караш ташлый-ташлый һаман утта яндырды тегеләрне, һаман газаплады.

—Ә сез фетнәчеләргә гомер бүләк кылсам, сез минем хәерхаһлыгымны кабул итәр идегез микән?—дип, ниһаять, каһкаһәле тавыш белән Сәлим хан телгә килде.

Йөзләре, тәннәре кара көйгән тоткыннар чылбырыннан Мөхәммәтгали берникадәр алга таба аерылып чыкты. Һәммәсе өчен дә җавапны шул тотты.

—Әгәренки синең «олуг шәфкатьлелегеңне» кабул кылсак, без үземезне—гөнаһлы, ә сине шәриф зат, дип таныган булыр идек. Иллә дә мәгәр син—залим хан, ә без—гаделлек вә азатлык бәрабәренә яуга чыккан вә гади халык хәтерендә бакый гомер буена изге булып калачак керсез инсаннармыз. Корыч сынар, әмма бөгелмәстер. Юк, без синең мәкер белән тулы бүләгеңне кабул кыла алмыйбыз, залим таҗдар. Хан көенә калтырап яшәгәнче, кол хәлендә елмаеп шәһит китү күпкә хәерлерәк.

Сәлим ханның муены, янаклары борчак белән чүкегәндәй кызарып һәм тимгелләнеп чыкты, йөзеннән нур качты. Тагын бер-ике минут шул рәвешчә узса, мөгаен, Сәлим хан үзенең курсыбаена «карлыгачлар» өстенә

ташланырга, аларны изәргә-сытарга әмер биреп өлгергән булыр иде. Ләкин менә шул арада хан янына Гази-Бәрәж белән элеккечә кап-кара җилән башлыкка төренгән Лачын Хисами килеп җитте. Һичнинди икеләнү-буйсыну белмәс утлы карашы белән текәлеп, Хисами сүз башлады.

—Болгарларны урыс кенәзләре, ушкуйлар, шәрекъ яклап килеп карлукъылар, аймыклар кырганы да инде хәттин ашкан. Шуларга өстәлеп син, бөекләрнен бөеге булган вәли хан да, үз борадәрләреннен канын коймасаң иде берүк?

Сәлим хан мона җавабында:

—Мин биш йөз гыйсъянчыга үлем җәзасы бирү хакында фәрман тараттым бит. Вәли хания фәрманы—аның анты да ләбаса ул, шуны анлыйсынмы?—дисә дә, Лачын Хисами җавапны бик тиз уйлап тапты:

—Ә синең фәрманыңа каршы килгән бәгъзе инсан да юк бит әле. Әнә тегендә тезелешеп торган өч меннән артык ушкуйның беренче биш йөзе синең өлешенә тигән әсирләрдер. Алар—синең колларың, мин алар турында әйтмим. Мәгәр шул ук өч мең эчендә мин хуҗа булачак янә биш йөз тоткын да бар бит әле. Менә шуларны мин сиңа бүләк итәм. Ул угры-гыйсъянчылар белән ни кыласың, анысы инде синең ихтыярың.

Үзен мәнге тоттырмас һәм асыл күнелен һичкемгә дә ачмас өрәк сыман йөргән Лачын Хисамидан курку-шөлләү хисе Сәлим ханга әле унбер-унике ел элек үк сенеп калган иде. Инде хәзер Хисами янәшәсенә таштай салкын йөзле Гази-Бәрәҗ дә килеп баскач, таҗ иясенең күнеленә тагын да зәһәррәк очкын кереп инде. Юк, иске чалгы йөзе сыман мең кат чарланган-игәүләнгән бу ике бәкнең сүзләрен инкарь итәргә, аларга битараф калырга һич ярамый иде. Ләкин таҗ иясе, ил башлыгы үзен юаш, күндәм холыклы, теләсә кем кубызына бии торган үшән мокыт итеп тә танытырга тиеш түгел. Әлеге бәкләрнең дә, шул ук гыйсъянчылар, уйсулыктагы ушкуйлар, аларны уратып баскан газиләрнең дә—һәммәсенең өнен алырга, бөтен мәмләкәтне өркетергә кирәк!..

Бер-ике минуттан соң Сәлим ханнан курсыбай башлыгы Атбасар тарафына ялгыз жайдак җилдәй очып узды. Янә ике-өч минут үтүгә курсыбайдагы яллы кыпчаклардан, башкортлардан торган меңлек ушкуйларның биш йөз кешелек бер нөгәрен калганнарыннан аерып ала башлады. Һични аңышмаган биш йөз ушкуй чирәм дала ягына да чыгып өлгермәде, курсыбай җәлладлары бер көтү бәбкә-чебешне буарга ташланган тилгән өере сыман бичара әсирләр өстенә ябырылды. Ушкуйларның кул-аяклары гына богауланып калмаган, алар әле унар-унар итеп бер-берсенә дә бәйләнгәннәр, качып китү яки каршылык күрсәтү турында уйлавы да мөмкин түгел иде. Курсыбайныкылар аларны утын әрдәнәсе урынына изде, тураклады. Ялан өстендә зынҗырларга эләккән кылыч тавышлары һәм әсирләрнең өзгәләнеп, ачыргаланып кычкырган әҗәл авазлары гына яңгырап торды.

—Җәллад!

—Залим!

—Кассап!

Әлеге әҗәл туен күзәтеп торган Мөхәммәтгали беренче минутта ук балбал шикелле тораташтай калган, ә дала өстендә биш йөз ушкуйның тавышы тынган чакта аның сагыздай кап-кара чәчләре бәс белән каплангандай чаларып чыккан иде...

Шул көнне үк кичен мөнадилар Сәлим ханның яңа фәрманын пайтәхет урамнары буйлап кычкыра-кычкыра игълан итеп йөрде:

—Биш йөз гыйсъянчының һәммәсен дә чит мәмләкәт базарларында кол итеп сатарга!

—Фетнә башлыгы Мөхәммәтгали хәзрәтне Алабуга урынындагы Шайтан каласына илтеп, манара диварларына зынҗырлап куярга!..

Икенче көнне «Шайтан бугазы» зинданы каршындагы ачык мәйданга халык иртә таңда ук һәм күп булып җыелды. Зиндан җәлладлары вакытны юри суздылар, алар халыкның сабырлык җуеп таралуына өметләнә иде, күрәсең.

Ләкин язгы кар суларын үз эченә тартып җыйган уйсулык шикелле зиндан мәйданы да халык белән торган саен ныграк тула барды.

Ниһаять, өйләдән соң авыр зынҗырларга уралган Мөхәммәтгалине иске генә бер олау үрәчәләре өстенә чыгарып утырттылар. Олауны баштан-аяк коралы усал җайдаклар чылбыры уратып алды. Шул чылбыр аша булса да халык үз күңелендәге әрну-газапларны әйтеп калырга ашыкты:

—Олуг кеше югалса, бөтен өй эче буп-буш кала бит ул. Без дә синсез ятим бала кеби интегермез, Гали...

—Шайтан каласына бикләп куйгач, Сәлим хан сине халык онытыр, дип хыяллана бугай. Ай-һай! Иләк белән генә Айны һич тә каплап булмый. Иншалла, синең якты нурың зинданнарны да ерып чыгар әле...

—Халык күтәргән кешене җиргә ташлау авыр ул. Безнең тәрәзәләремезгә дә кояш карамый калмас...

Инде мәйданнан чыгып барган чакта Мөхәммәтгали үзен озатып калучыларга ныклы тавыш белән мөрәҗәгать итте:

—Бүгенгә тикле җиһанда мин барча илдәшләрем өчен Мөхәммәтгали атлы борадәр-дуст идем. Ә залим хан гадел көрәшем өчен тоткын кылып гайре «олылагач», Давыт бабам төсле мин дә үземә «Кол» лякабен алам. Киләчәктә мин һәммәгез өчен Кол-Гали атлы чордаш кына булырмын. Кол-Га-ли! Онытмагыз шуны.

## Егерме беренче бәйләм

### 1

Тимучин кыят-нируннлыларның унөч мең тирмәсен, көтү-көтү малын атаулы туганы Җәмуга нойон хуҗа булган далаларга илтеп житкерде. Бу вакытта инде җиһанда кыш уртасы хөкем сөрә иде. Чирәмлек җирләрнең байтак өлешен каты боз элпәсе каплап киткәнгә күрә мал-туар йөртердәй уйсулык-инкүлекләр мәйданы шактый кимесә дә, чатҗиратлар аларны киң күңеллелек, җылы кочак һәм якты йөз күрсәтеп каршы алды. Тирмәләр тезәрләй, мал-туар туплардай кышлау җирләрне дә шундук бүлеп бирделәр.

Ә Җәмуга белән Тимучин исә тагын бергә, бу юлы һичнинди яуфәлән булмаган тыныч чакта килеп кушылуга аеруча канәгать, алар икесе тиң үзләре кичергән шатлык-сөенечне яшерергә җыенмыйлар иде. Көндезләре әле ауга йөреп, әле кабиләләре турында кайгырту белән үтсә, кышкы кич һәм төннәр шәфәкъ вакытындагы күләгәдәй озын; атаулы туганнар аларны күбесенчә җылы гапьләшү яки төрледән-төрле бәхәс эчендә янып уздырдылар. Мондый әңгәмә-бәхәсләр торган саен ялкынлырак, кызурак төс ала башлады һәм кайчакларда, хәтта, җинелчә чәкәләшүгә тикле үсеп житкәләде.

—Барча магул кабиләләрен бер йодрык сыман төйнәп тупларга җыенабыз икән, иң элек, без гади халыкны—карачуны үз ягыбызга аударырга тиеш,—дип, Җәмуга нойон һәрчак түбән катламны яклый торган булды.—Кара магулның ертык тирмәсеннән, агач арбасыннан, дүрт-биш елкы вә куйларыннан кала байлыгы юк аның. Шуна күрә алар хыянәтне белми, хуҗаларына карата тугры җанлы була. Әмер бирсә, ул хуҗасы өчен утка-суга керә. Ә менә бәкләр, сәүдәгәрләр, байлык туплап алган һөнәр осталары, меңбашлары—кыскасы, аксөякләр җил кайсы тарафка иссә, шуның уңаена бөгелүне, яраклашуны гына белә. Алар, күбесенчә, фәкать көчле бәк йә нойон канаты астына сыену җаен эзли. Бу хуҗасын яна көч килеп сыта икән, ул инде иртәгә үк тегесе ягына ава, аның аягына егыла. Аксөякләргә һичбер ышаныч юк, алар без таянырдай нигез була алмый.

—Юк инде, Җәмуга чәчән, бик нык ялгышасың,—дип, Тимучин аңа кабат-кабат каршы төшеп килде.—Атны йөгән илә идарә итәләр, камчы илә куалыйлар булыр. Көтүләрне кирәк якка борыр өчен бер чабан да

житә. Бүреләр, җәйрәннәр, елкыларның көтүләрен дә мәңге-мәңге сынар ата бүре, сынар тәкә яки сынар айгыр гына башлык булып йөри, калганнары исә бердәм буйсыналар. Инде хәзер бөтенләе белән капма-каршы яктан килеп күз атыйк. Чабан булган бәндә хәлдән тая йә булмаса чирләп егыла икән, көтүдәге маллар шундук таралып бетә дә, барс-бүреләргә ризык була. Ата бүрене яисә баш тәкәне ук очына алсаң, калганнары шундук куркып кача. Инде аңлыйсыңдыр булыр, бөтен нәрсә идарәдән тора. Бәс шулай икән, магулларны бергә җыйнаган чакта да иң яхшысы—дилбегә-йөгәннәр, ягъни бәк вә нойоннар белән эш итү. Аксөякләрне үз ягына түндерәсең икән, карачу ул, бичара, сукыр көчек сыман ана ияреп килә, хуҗасыннан калмый.

Җәмуга чигенү белми.

—Бүреләр, елкы-җәйрәннәр дөньясындагы хәлләр бөтенләй икенче ул, бу хакта бәхәсләшмим. Мәгәр карачу—томана сарык түгел. Ул үзе теләгән, үзе сайлаган хакимгә буйсынырга тиеш. Шуңа күрә мин бит хан вә хакимнәрне сайлап кую яклы. Карачуга аны көч илә буйсындырган, изгән-сыткан явыз хаким түгел, ә осталыгына, абруена карап үзе сайлаган хан күпкә кадерлерәк. Менә шул сәбәпле карачуларга булачак хан сайлау, магул халкының киләчәк язмышын хәл итү чорында бәк вә нойоннар, менбашлары вә башка аксөякләр белән бер үк дәрәҗәдә хокук бирү кирәк. Камчы гына күрсәтеп, йә гел өркетеп торсаң, бер генә чаптарга да ит вә җегәр инми. Атны һәрвакытта солы, арпа ашатып ипкә-сапка китерәләр. Ә аннары мин әле ханнарны гына түгел, бәлки бәк вә нойоннарны да сайлап кую яклы. Кабиләләр өстеннән идарә итүне бер кан булган өчен генә атадан—улга, улдан оныкка күчереп бару Тәңре үзе кушкан, дөрес гамәлмени? Ә бәлки, кабиләләрдә синнән-миннән дә сәләтлерәк, остарак, елгыррак юлбашчылар бардыр?

—Һе, кызык кеше син, Җәмуга борадәр,—дип, андый сүзләрдән соң Тимучин һәрвакытта ярсу әтәч сыман кабынуын белде.—Менә, минем атай бөртекләп чүпли-чүпли үзенең кул астына кырык меңгә якын тирмә җыйган иде. Нәрсә, тотсын да, көннәрдән-беркөнне ул гомер буе өйгән тырышлык-хәзинәсен алабутадан әремне дә аера белмәгән карачуга бүләк итсенмени? Өстәвенә, шушы тиклем көчне туплау өчен бармакка-бармак та сугып карамаган карачу мондый бүләкнең кадерен белә, аның асылын бәяли димени? Ул карачу, мокыт, андый бүләкне иртәгә үк суга салачак, таратып бетерәчәк бит. Юк инде, Җәмуга борадәр. Ул ханнар тәхете дә элгәрерәк елларда Көрән Бүредән—Бүрежигәнгә, Кабул бабамыздан Котул хакимгә юкка гына күчеп килмәгәндер. Бер кан, бер нәсел дәвамы булганга күрә алар хакимлекнең кадерен дә белгән, үзләренең яулары, батырлыклары белән магул ыруын да дан-шөһрәткә күмгән. Безгә менә шул Кабул-Котул оныкларының берсен хан тәхетенә кайтарырга кирәк. Монда инде томана карачуның бер кысылышы да юк. Ул, мина калса, тик кабилә бәкләре, нойоннар вә баһадирлар эше...

Моның ише бетмәс-төкәнмәс бәхәс-дәгъваләрнең, барыбер, кайчан да булса бер очы табылырга, чишелергә тиеш иде инде. Ә ул атаулы ике туган өчен һич тә көтелмәгәндә килеп чыкты.

Кыят, нирун кабиләләре арасында Тимучинның ерак бабалары булган Байшонкар сунарчы, Томавыл мәргән, Бәртән баһадир, Кабул ханны әллә никадәрле хатирәләр белән искә алу, шуларга бәйле рәвештә үзләренең бүгенге хакимнәренә мәдхия уку кебек чәй-мәҗлесләр инде күптән тамыр җәйгән иде. Менбашлары, сәүдәгәр, һөнәрчеләр Тимучин тирмәсенә ашка җыеламы, әллә аларны башка бер аксөяк үз учагы янына чакырамы—әңгәмә-җырулар гел бер тирәдәрәк әйләнә торган булды. Элек магул халкының батыр вә шөһрәтле хакимнәре булган. Хәзер дә халык арасында юлбашчы табылырга һәм ул барча магул кабиләләрен бер ояга берләштерергә тиеш. Алар бүген Тимучиннан да кыюрак вә лаеклырак баһадирны белми. Фәкать Тимучинның тәкъдиренә генә магул халкын бергә туплау бурычы язган һәм ул гына юлбашчы булырга кулай, лаек батыр.

Әйе, Котул хан вафатыннан соң юлбашчысыз калганнан бирле, утыз ел буена, иң ярлы карачу да магулларның бер гаилә булып яшәгән чорын сагынып сыкрана, бүген кабиләләрнен үзара яу йөреп бер-берен кырганы өчен йөрәге белән әрни һәм ул инде далада янгыр тамчысына сусаган гөл кебек яңа хаким, яңа әйдәүче табылуын көтеп тилмерә, яна, газаплана иде. Ә кыят-нируңлылар, әлбәттә инде, кичен ятса да, иртән торса да, хыялларында яна хаким итеп үзләренен бәген—Тимучинны күрде. Нәкъ менә шуңадыр аларның барча мәдхия-җырулары газиз бәк колагына таба юнәлтелгән һәм бу хәл Тимучинда горурлык, ышаныч, тәвәккәллек хисләрен арттыра иде.

Җәмуга Тимучин тирәсенә кунак булып килгән бер мәҗлестә соңгы араларда баһадирның якын ярдәмчесенә әверелгән Мохали-менбашы әңгәмә тезгәнен үз кулына алды һәм кыятларга тансык җайга-көйгә салды.

—Менә, без соңгы яудагы олуг җиңүдән соң Җәмуга нойон илә Тимучин баһадир тантана иткән үзәнлектә утырамыз. Магулларның актык хакиме—Котул хан да кырык-илле ел элек үзе яулаган җиңүләр хөрмәтенә әнә теге зирек, артыш агачлары ышыгында байтак туй үткәргән. Мәгәр утыз еллар элек кара татар ыруы изеп киткән дә, магулларның бердәмлеге-куәте әрдәнәләр өеме сыман җимерелгән шул. Әмма Мәнгелек Күк Тәнре үзе өчен газиз булган магул халкын барыбер ташламаган. Ул җиһанга безнең кабиләләремезне кабат үз туграсы янына тупларлык, халкын данга күмә-күмә олуг хан булырлык, дошманнарын изеп таркатырдай батыр бүләк иткән. Ул—Тимучин. Тик ул гына магул ыруына хан булырга хаклы. Мин, Мәңгелек Күк Тәнре белән гомер бакый бәйләнештә яши, аның сүзләреннән чыкмый торган Мохали-менбашы, Тимучин баһадирның тәкъдирен-киләчәген менә шулай күрәм. Әйдә, хан тәхетенә мен дә, җиһанга хуҗа бул, шанлы Тимучин батыр...

Кыят-нируңлылар өчен үтә тансык, сары майдай күңелгә ятышлы булса да, чатҗиратларны һәм аеруча аларның бәген кимсетә, гарьләндерә торган чәнечкеле сүзләр иде бу. Шуңа күрә аларны тынлап бетерүгә үк Җәмуга бәк урыныннан капылт сикереп торды. Ишекне бусагасы-түбе белән куптарырдай йолкып тышка томырылды. Артыннан Тимучин чыгып җиткән чакта Җәмуга инде иярлә атланып ята, йөзе-кыяфәте исә иске табак сыман изелгән һәм төссезләнгән иде.

—Сине монда хан итеп үк билгеләгәннәр икән, ә мин белмәдем дә,—дип тезеп китте ул, тешләрен усал шыгырдатып.—Бездәй фәкыйрьләргә олуг хан белән бер тирмәдә, алай гына да түгел, хәтта бер далада утыру килешмәстер. Шуңа күрә мин карачуларым белән ошбу Балакош үзәнлеген бүген үк ташлап китәм.

Тимучин аны тынычландырырга тырышып караса да, Җәмуга биреш-мәде. Ә артыш куаклары эченә кереп югалыр алдыннан, артына борылып, соңгы сүзен ыргытты:

—Тирмәләреңне җый да, ычкын. Сиңа шулай хәерлерәк булыр.

## 2

Шул ук елның җәендә Тимучин әле тагын, чин министры Чен-Сян үтенече буенча шәрекъ ягына барып, андагы солонг кабиләләрен[1] дә пыр туздырып, әллә ничаклы ганимәт һәм коллар җыеп кайтты. Бөркет сыман һаман-һаман ныграк канат җилпеп, югарыга күтәрелә барган баһадирның даны магул далалары буйлап торган саен тизрәк җәелә иде. Күз кергәндә Тимучин туграсы тирәли тезелеп баскан тирмәләрнең саны инде егерме меңгә җитте. Башка бәкләр канаты астында бу кадәрле көч юк, Тимучин хәзер магул кабиләләре арасында иң куәтле һәм иң хәтәр арысланга әверелгән иде.

«Адәм баласының бәхет капусы бер ачылса, аның кулына алган туфрагы

[1]Солонг кабиләләре—хәзерге кореялылар.

да алтын була»,—дигән сүзләр хактыр инде. Жиһанда янә әбиләр чуагы канат ярган гына иде, үзенең барча яраннарын, шулар белән бергә азамат яугирләр буларак дан алган урут һәм мангыт кабиләсендәге менәрләгән жайдакларны да ияртеп Балдак-Дала үзәнлегенә Алтын бәк килеп керде. Үзен дә кимсетмәде, артык сүз дә куертып тормады ул. Килүенең сәбәбен кыска гына итеп аңлатып бирде:

—Юлда адашкан сәйях далада унлап учак күрсә дә, шуларның яктырагы, көчлерәге янына бара бит ул. Чөнки якты учакның казаны да, гадәттә, олырак вә калжалырак була. Нә үкенеч, магул даласында бүген син элдергән уттан да яктырак вә көчлерәк кенә түгел, хәтта, үз янына ымсындыра алырлык та бүтән учак юк шул.

«Син үзеңнең бертуган энеләрең—Кучар вә Сачә бәкләр белән ниндидер майлы калжаны бүлешә алмагансың. Йә булмаса татар, найман, мәркет тарафыннан берәр нинди хәтәр сизгәнсең дә, туганнарыңны ташлап качкансың ич»,—дип, Тимучинның ярсып-мәсхәрәләп кычкырасы килде, әмма түзде. Чөнки Алтын бәк—магулларның соңгы хакиме Котул ханның улы, ә мондый көрәштәшнең үзенә никадәрле абруй китерәчәген һәм нинди куәтле терәк булачагын Тимучин, әлбәттә, яхшы аңлый иде. Ул мәржән-якут нурлы бәхет кошын эләктерүгә тиң мондый унайлы форсатны фәкать үз файдасына жигәргә исәпләде һәм тирмәсенә бертуган энеләре Билгүтай белән Хасар-мәргәнне ашыгыч чакыртып алды. Тимучинның йөзе кырыс һәм тәвәккәл иде.

—Кылган сыман анда-монда сибелгән магул кабиләләрен бер учмага жыяр вакыт килеп житте. Бүген далада Ясүгәйнекеләрдән дә куәтле вә дәһшәтлерәк бүтән кабилә юк.—Тимучин инде шактый шомарган нотыкчы иде, сукмактагы сикәлтәләрне оста сикереп үтте. Ә тавышы тамак төбеннән үк зынлап, вәкарь чыкты.—Тимерне кызу чагында сугып калу кирәк. Менә шул сәбәпле мин сезнең икегезне атайның энеләре, безнең гамужә агайлар Дәритай, Тайчу вә Канун бәкләр тарафына озатырга булдым. Кичекмәстән юлга чыгыгыз да, заманында безне, ятимнәрне, ташлап качкан ул сатлыклар каршында бил бөкмичә, горур сөйләшегез. Балдак-Далага кайтып баш исәләр, мин аларны кичерергә әзер. Иллә мәгәр тез чүкмиләр икән, үзләренә үпкәләсеннәр. Гамужә агайларга шуны аңлатыгыз. Ахырда үкенерлек вә егъларлык булмасыннар...

Билгүтай белән Хасар унбиш-егерме көн эчендә кире әйләнеп кайтты. Кыяфәтләре үк шат һәм кояшлы иде.

—Гамужә бәкләрнең өчесе дә сиңа итагать кыла, гафу үтенә, абый. Беренче кар төшкәнче үк алар барча-барча күремнәре илә синең канатыңа кайтып сыеначак.

Тимучин-хаким энеләренә шундук яңа фәрман житкерде:

—Сезгә ял итәргә туры килми инде, борадәрләр. Ятып торган дөянең авызына үлән үзе кермәс. Мин сезне хәзер Котул ханның угыллары Кучар белән Сачә бәкләр хозурына юллыйм. Үзегез белән биш мең жайдак алыгыз. Борнай бәкләр бүген көчнең кем ягында икәнлеген тоярлык вә камыш сабагыдай сынарлык та булсын. Мәгәр боларга безнең асыл максатыбызны ачып салмагыз. Менә, Дәритай, Тайчу, Канун вә Тимучин бәкләр барча кабилә башлыкларын корылтайга дәшә, алар анда Алтын бәкне магул ыруының яңа хакиме итеп куярга жыеналар бугай, дигән булыгыз. Тегеләрнең астына су йөгерсен, икесе тиң йокысыз калсын. Мәгәр аларга иснәнү вә төрле якка чапкын юллау өчен бик күп көннәр бирү ярамастыр. Шуңа күрә корылтай беренче кар төшүгә үк жыела, диегез. Һәр икесе юлда узыша-узыша килеп житәрлек булсын...

Тимучин әле үткән кышта гына үзенең атаулы борадәре булып саналган, әмма язын инде аны жәйләвеннән куган Жәмуга бәк янына да чапкыннар жибәреп карады. Ләкин илче-сәйях бәгырьгә шырпы сыман калалырдай жавап алып кайтты.

—Тимучин үзен бөтен магул ыруын сөзәрдәй үгез кеби күреп юкка хыяллана. Ул—гап-гади бер мүкләк, Мәңгелек Күк Тәңре аңа мөгез бирмәгән.

Магул бәкләре вә нойоннары арасында аның эчәгеләрен сөзеп агызырдай Җәмуга бар әле. Вакыт җиткәч менә шул Җәмуга карачулар сайлап куйган бөек хан булачак, магулларның бөтен кабиләсе фәкать аңа гына буйсыначак...

Тимучинга тешләрен шыгырдатып түзәргә һәм көтәргә генә калды.

### 3

Беренче кар ятуга Балдак-Дала үзәнлеге меңәрләгән-меңәрләгән тирмә белән тулды. Онон елгасы ярлары буйлап нигездә алты кабилә—кыят, нирун, урут, җүрҗән, мангыт, исут күремнәре тезелеп баскан иде. Ни гаҗәп, Тимучин чакыруы буенча җыелган бәкләрнең дә саны алты килеп чыкты. Дәритай, Тайчу, Канун бәкләр Ясүгәйнекеләр булып саналса, каршы як—Котул ханныкылар да өч һәм ул Алтын, Кучар, Сачә бәкләрнең корылтайда нинди мөгез китереп чыгарасын күзаллау ифрат авыр иде. Тимучин мондый халәтне көянтәле үлчәү белән чагыштырды һәм аны үзенең файдасына аудару өчен кулай гер булырдай яңа кунакларга өметләнде. Үзәнлек өстенә инде кар да байтак ятты, ләкин тайҗут, чатҗират, уранхай кабиләләреннән бәкләр, эре сәүдәгәрләр генә түгел, һич югы меңбашлар, һөнәр осталары булса да килеп өстәлмәде.

Алдан килешенгән көнне Балдак-Дала янындагы Бүрехан тавы итәгенә алты кабиләнең дә күрем башлыклары, базар тотучылар, һөнәрчеләр, сәрдәрләр, йөзбашлар, кам-шаманнар—кыскасы, барча аксөяк катлам вәкилләре тезелешеп утырды. Учак-казаннар тирәли җәелгән түгәрәкнең бер ягында Дәритай, Тайчу, Канун, ә капма-каршы якта Котул ханның уллары урын алды. Билгүтай, Хасар, Сүбүдәй, Җәбә, Бавырчы, Җәлмә, Мохали, Жучи, Чагатай һәм башка абруй ияләре—һәммәсе дә монда, фәкать йорт хуҗасы үзе, Тимучин баһадир гына һаман күренми иде. Ул бөтенләй дә көтелмәгән яктан—Бүрехан тавы өстеннән Мәңгелек Күк Тәңренең үзе тарафыннан фатиха алып төшүче серле-олуг пәйгамбәр кыяфәтендә пәйда булды. Тимучин кулларына тугыз койрыклы өр-яңа әләм тоткан, магулларның андыйны бөтенләй күргәне юк, җитмәсә баһадир үзе дә ак-караны күз чалымына да китереп карамыйча, вәкарь адымнар белән, түгәрәк тирәли тезелешкән кунаклар өстенә атлап килә иде. Кунаклар арасындагы сәүдәгәрләр, йөзбашлар, әлбәттә, урыннарыннан кубып Тимучин өчен юл ачарга мәҗбүр булды. Калган аксөякләр исә аю биетүне күзәткән сыман сәер әләм тарафына текәлде.

Ин очына, түбәсенә, бер учма ат кылы тагылган, үзе тугыз чук-койрыктан хасил ап-ак әләм иде бу. Әләм уртасына канатларын зәһәр җилпеп очкан шоңкар сурәте төшерелгән, ул тырнакларына нәни бер кош аскан. Ә шоңкарның карашы-кыяфәте исә сурәттәге килеш тә очкын, аяусызлык, дәһшәт бөркеп тора.

Тимучин шушы сәер әләмне түгәрәк мәйданның үзәгенә китереп кадады да, берникадәр вакыт буе тилмерткәннән соң гына, кабилә вәкилләренә мөрәҗәгать итте:

—И, сез, магул халкының тугры яугирләре! Сез бөек атамыз—Котул хан вафатыннан соң утыз ел буена тилгәннәрдән өркеп сибелешкән чебеш өере кеби төрле якка чәчелеп яшәдеңез. Явыз татар, мәркет, ангыт ырулары шул дәвердә сезне һаман саен карчыга кеби чукып, талап торды. Утыз ел эчендә нинди генә мәсхәрә вә җинелү кичермәдеңез. Инде, менә, магул кабиләләре дә яраларын өннәрендә килеш ялап тернәкләнгән үҗәт бүре балалары кеби савыгып, көрәеп килә. Сез магул кабиләләренең киләчәктә дә таралып вә япа-ялгыз көе хәят кыла алмасын, ниһаять, аңладыңыз. Иске бишмәт төсле таланган-өзгәләнгән кабиләләрне бер йодрыкка, бер ояга туплау нияте белән заманында Бүреҗигән, Томавыл мәргән, Байшоңкар бабаларыңыз тирмә томкан ошбу магул бишеге, магул учагы янына җыелдыңыз. Магул халкы бүген янә бөек Кабул хан, азамат Котул хан кеби юлбашчылар пәйда булуын көтә. Җиһанда бал кортлары, бүреләр, елкылар да ана корттан, ата бүредән, баш айгырдан аеры яшәмидер. Безгә дә магул

ыруы өчен бөек ата, якты маяк, гаярь яклаучы булырдай олуг ханымызны сайлап куярга вакыт. Ошбу ният белән мин һәммәнезне корылтайга дәштем. Шаять, инде ятим балалар булып таралмамыз...

Шушы сүзләрдән соң Тимучин түгәрәк читенә юнәлде, үзенен агалары Дәритай, Тайчу, Канун бәкләр янәшәсендә урын алды. Бүрехан тау итәгенә тынлык, хәтта, беркадәр шом инде. Үз-үзенә сүз-ук янгыры жыярга теләк белдергән нотыкчылар әлегә күренмәде.

Ниһаять, түгәрәк уртасына магул ыруының баш камы, заманында әле Котул ханның үзе белән бергә сәгадәт кылган Муенлык би чыкты. Биленә, муенына, түшенә юлбарыс, аю, кабан, бүре, чуртан кебек ерткыч җәнлек-балыкларның тешләрен тезеп каеш-муенсалар аскан, янакларына, ияге, мангаена сары, зәнгәр, кара төстәге әллә нинди сурәтләр сызгалап бетергән бу ап-ак чәчле кам үзенен килеш-килбәте белән үк сискәндерә һәм һәркемне мондагы инкүлекне онытып, Тәнрегә якынаерга мәҗбүр итә иде. Уртада янган учак тирәли сәер хәрәкәтләр ясап әйләнсә дә, ул һичнәрсәне әфсенләп маташмады, шулай да түгәрәкне бик тиз иярләп алды.

—Мин бүген төнлә Мәнгелек Күк Тәнре сараена инеп, анда Бүрежигән атамыздан алып Бәртән баһадирга тикле хәят сөргән алыс-алыс бабаларымызны күрдем. «Бүген магул ыруын җитәкләргә кем лаеклы?»—дигән утлы сөаль биргәч, алар озын бауга тигездән-тигез тугыз бәжра элде дә, шулар хозурына төбәп ук очырды. Яшендәй чатырдап вә ялтырап очкан ошбу укларның барчасы да бер җепкә тезелгән кеби әүвәл Котул хан бәжрасын әйләнеп узды, ә ахырда исә Ясүгәй оясына бөтерелеп төште. Шанлы бабаларымыз сызган якты сукмак изге вә ачыктыр. Бабаларымыз безгә олуг ханны Ясүгәй баһадирның угыллары арасыннан күтәрергә боера.

—Юк, олуг кам, чаптарын типкәләгән җайдак кеби куалама әле,—дип шулчагында янә Тимучин сүз алды.—Бабаларымыз очырган ул яшендәй уклар әүвәл Котул хан тирмәсенә төбәп юл алган бит. Менә, хәзер без бирегә туплаган алты кабилә исеменнән Котул ханның уртанчы угылы Кучар бәктән сорыйк. Син кырык-илле ел элгәре бөтен магул халкын бер казан хозурында, бер түбә астында туплап тоткан шанлы хан угылыдыр. Ата-бабаларымызның изге йоласы буенча тәхет сина тиеш. Әйдә, атан калдырган тезгенне кулларына ал да, магул халкының олуг ханы бул син.

Тимучин тарафыннан ясалган мондый гайре сәер тәкъдим Котул ханныкыларга аяз көнне яшьнәгән яшен сыман тәэсир итте бугай. Алар өч туган арасыннан кемне хан итеп күтәрү мөмкинлеген күз чалымына да китереп карамаган, бу хакта бөтенләй һичбер төрле фикер алышмаган иде. Кучар бәк исемен генә атап, өчесенен тин итәгенә утлы күмер ташлагач, Котул ханныкылар куырылып, исәнгерәп калды. Бер ата уллары булсалар да, болар арасыннан шушы мизгелдә үк зәһәр елан үткән, Ә Тимучин моны алдан ук чамалаган, тойган иде шул инде.

Өч бертуган арасыннан ин беренче булып Алтын бәк анга килде. Ләкин анын ярымпышылдап тезгән сүзләре магул аксөякләре тарафына түгел, ә үзенен энекәшләре колагына юнәлтелгән иде.

—Ошбу мәлдә ханлыкка йөз тоту безнен өчен көпә-көндез йолдызай күрү кеби үк гайре ят хыялдыр. Малай-шалай булмыйк, куәт Тимучин ягында. Монда җыелган күрем башлыкларының күпчелеге Тимучинның исемен яклаячак. Без буралкы ат кеби каршы торсак, Тимучин катилләр яллап булса да барча киртәләрне барыбер сындырачак. Безгә хәзер Тимучинны яклау күпкә отышлырак. Без аңа киртә булырдай көндәш атамасак, ул бүген хан тәхетенә инәр. Мәгәр мондый җинү өчен кемгә бурычлы булуын онытачак түгел. Сонра аны ятьмә эченә алып, үз кубызымызга биетергә дә була.

—Дөрес, дөрес,—дип энеләре аны хуплады да, Котул ханныкылар исеменнән хәзер Кучар бәк сүз катты:

—Муенлык кам бәян иткән күрәзәдә һичбер хата юктыр. Шанлы бабаларымыз укларын Ясүгәй тирмәсенә төбәп очырган, алар безгә Тимучин бәкне олуг хан итеп сайлап куярга кушкан. Без бабаларымыз фәрманыннан

читкә тайпылмыймыз вә Тимучинны ханлыкка күтәрүне хуплыймыз. Әйдә, Тимучин бәк, олуг ханымыз бул да, магул ыруын яңа яуларга, җиңүләргә иярт. Синең бихисап дошманнарыңа каршы орышларда без иң алда булырмыз...

—Бөтен ыру, барча халык өчен олуг хан итеп күтәрелгән һәрбер хаким үзенә яңа исем, яңа ләкаб сайларга тиешледер,—дип, абыйсының сүзләренә Сачә бәк кушылды.—Син үзеңә нинди ләкаб алырга булдың, Тимучин бәк?

Тимучин вакыйгалар агышын бу кадәр үк тиз, тау елгасы кебек җитез, шаулы булыр, дип уйламаган иде, күрәсең. Ул бермәлгә, хәтта, югалып та калды. Урыныннан кубып, түгәрәк уртасындагы серле әләм янәшәсенә чыгып баскач кына, ниһаять, ул авызын ачты.

—Моннан ары мин үземә «Чыңгыз» атын алам, ә ошбу әләм минем яу юлдашым, изге сүлдә булыр.

—Чыңгыз—ул бабаларымыз телендәге «куәтле», «җиңелмәс», «каһарман», дигән мәгънәдәге сүздер. Тимучин баһадирга мондый ләкаб үтә тач киләдер, бик кулай, бик хуп,—дип әүвәл Муенлык кам мөһер суккан иде, шуның артыннан ук инде бөтен кыят, нирун, мангыт кабиләләренең барча вәкилләре дәррәү эләктереп алды:

—Чыңгыз хан! Чыңгыз-хан! Чыңгызхан!..

Яңа хакимне әүвәл кыят-нирунлылар гына кулларында чөйсә, соңыннан алты кабиләнең дә иң абруйлы башлыклары, шуларга өстәп алты бәк тә ап-ак дөя йонынннан сугып ясалган киез келәм өстенә күтәрде. Ата-бабаларның бөтен йоласына туры китереп, бәк һәм юлбашчылар аны келәм өстенә күтәргән көенчә, түгәрәк уртасында янган дәү учак тирәли тугыз тапкыр әйләндереп үтте. Аннары хакимне, анадан-тума калдырып, ап-ак дөяләрдән савылган җып-җылы, чип-чиста сөт белән янә тугыз мәртәбә башыннан аягына тикле коендырдылар. Өс-башына алтын-көмеш җепләр белән нәкышьләп чигелгән затлы җилән, чит-читенә мәрҗән асылташлар тезелгән төлке бүрек киеп алгач кына, яңа хаким үзенең яран-колчураларына мөрәҗәгать итте:

—И, сез, магул кабиләләре чәчелмәсен, таралмасын өчен көч вә мәдәт түккән дусларым, иптәшләрем! Менә без дә бүген янә бердәм вә чигенү белмәс халыкка әвереләдек. Инде киләчәктә дә барча дошманнарымыз өстеннән җиңү генә кылып, бүтән халыклар янәшәсендә үземезгә лаек вә тиеш булган урынны алсак иде. Һәммәнез тарафыннан сайлап куелган уртак хан буларак, мин сезне фәкать җиңү вә ганимәт вәгъдә иткән яу һәм орышларга гына алып барырмын. Дошман кулыннан алынган гүзәл канизәкләрнең, мал-туарның, байлык-нигъмәтнең дә барчасы уртак булыр, мин беренезне дә нахакка рәнҗетмәмен. Мин ата-бабаларымыз хәят-мәгыйшәт кылган ошбу оя-бишекләрнең берсен туздырмамын, алар нигезләгән сукмак вә йолалардан читкә тайпылмамын. И, сез, Бүреҗигән атамызның азамат угыллары! Магул халкы үр артыннан үрләр, биектән-биек тау-кыялар яулый-яулый, күрше ырулар өстенә лачын-шоңкар булып күтәрелсә иде!..

Балдак-Дала үзәнлегендә шул кичтә үк ким дигәндә бер ай буена сузылачак тантана, туй башланды. Үзәнлекне әледән-әле уянып хәбәр биргән вулканныкы сыман күкрәү авазлары тетрәндереп, сискәндереп торды:

—Чыңгызхан! Чыңгызхан!

*Беренче китап тәмам*

Чаллы каласы,
*1995—1998 еллар.*

ШИГЪРИЯТ



## Салисә Гәрәева

### АЛМАГАЧТАН АЛМА ТӨШТЕ...

#### И, Тормыш!

И, Тормыш!
Һәр мизгелеңне
Бал, ширбәт итеп эчәм!
Моң тулы, шигърият тулы
Иртәм, көндезем, кичем!..

Яфраклар—минем сердәшем,
Мохитем—серле урман.
Бу—Урал-тау, бу—Идел-йорт,
Мин янып яши торган!..

Юлларым илтә Иделгә,
Тау, урман, сулар кичеп.
Җирдә тудым, җирдә яшим,
Галәмнәр тынын эчеп.

Тау, урман, сулар кичеп...

#### Җиңү көне

Сугыш тынгач, хәрабәләр калка.
Исәннәрдә кинәт батыр арта.
Тол хатыннар
урман кисеп кайта,—
иңдә пычкы, билбавында—балта.

Сугыш тынгач, гел батырлар арта.
Хәерчелек һәм ятимлек кенә
дәшми-тынмый ишекләргә килә,—
ярты телем сала кесәсенә...

Сугыш тынгач,
гел батырлар арта—
истәлекләр
атыш, шартлау тулы.
Җиңү килде!
Тол хатыннар аны
алып килде,—
кемнәр белә шуны?!.

Сугыш тынгач,
бөтен Россияне
ярып, яңгырады елау өне:
кемгә—күтәрмәслек олы кайгы,
кемгә шатлык иде
Җиңү көне!..

## Тагын бер көз

Тагын бер Көз—яфракларын
Сарыга һәм алга манды!—
Кояшның ал янгынында
Ягымлы бер җәем янды!..

Акты сулар алга таба,
Акты еллар... артка таба!
Якты гомер елгаларын
Тугыз баллы давыл кага...

Тик соң инде—җилкәннәрем
Ул давылның корбаныдыр!—
Якты өмет белән генә
Җирдә яши торганмындыр!..

Яфрак арты яфрак оча,
Көн артыннан йөгерә Төн...
Хыялларым—җәйге болыт,
Өметләрем—зәңгәр төтен!..

Күзләремнең ак каены
Яфракларын суга коя.
Ләкин язлар киләчәген
Белә күңел, күңел тоя!..

***

Бер Ходаем күпме гомер биргән?—
Соңгы чиген аның кем белә?
Якты көннең һәр сәгате саен
Йөрәгемнән җырлар түгелә...

Яңгыр яуган көзге тын кичләрдә,
Җиләс җилнең тоеп агышын,
Җылы яңгыр итеп, кара төнгә
Тапшырдым мин йөрәк сагышын!..

Көнгә калсын якты тойгыларым,
Төнгә китсен уйлы-моңлысы!
... Әзме, күпме гомер бирелгәндер—
Җырларымда бөтен тормышым!..

## Бер алманың яртысы

Бер алманың төшле яртысы ул,
Уникенең төгәл алтысы!
Тәкъдире шул: йортка ямьнәр биреп,
Гаилә корып, айдай балкыйсы!..

Кушкаенның нәкъ бер гүзәл пары:
Кәүсәләре үскән үрелеп.
Яка уемыннан ике алманың
Ярымшары тора күренеп.

Бер йөрәкнең ярты бүлеме ул—
Кан юллары бергә тоташкан.
Гүзәл хатын. Әмма ялгыз яши,—
Йөрәгенә хәсрәт-ут ашкан.

Ай очына кунган нурлы йолдыз—
Айсыз ничек гомер итсен ул?!
Күккә илткән Аккош юлларыннан
Ник берүзе—ялгыз китсен ул?

Ярымшардан төгәл бөтенлеккә
Омтыла ул, белми үләрен.
Сизми шушы төгәл парлык өчен
Бар бәхете белән түләрен!..

## Көзге алма

Көзге алмагачтан алма төште.
Кызыл битен җылы җиргә куйды.
Газиз җирнең татлы җимешенә
Ана кочагыдай җылы куены...

Картайды да кеше, дөнья куйды.
Тәкъдир белән бетте авыр уены.
Әҗәлнең, аһ, зәһәр икән угы,
Салкын икән кара җирнең куены!..

## Шагыйрә һәм сүзләр

Төннәр буе шигырь тыңлый колаклар.
Шагыйрьләрем талантлы һәм тыйнаклар!
Шигъри өннәр эчеп, җаным тирбәлә,—
Тирбәтешә аны Пушкин, Блоклар!..

Тукай килә, өзелгән кылы белән.
Туфан килә, шагыйрьләр юлы белән.
Сүзләремне—моңны, сызлануларны
Мин, Салисә, язам үз кулым белән...

Яңгырый сүзләр—алкын моң ташкыннары!
Күз алдымда шагыйрь, чәчән сыннары...
... Ашкындырып, сокландырып, колакта—
Музыкадай, шигъри сүзләр чыңлавы!..

## Үз—үземә, читтән карап

Эче тулы сихри дөнья аның,
Сихри дөнья сыймый җанына;
Тыелмаган моңнар, дәртләр белән
Узып бара көзләр ягына!..

Кирәкмәгән чакта ояла ул,
Кеше көлгән чакта моңая,
Кеше торып басса—иелә ул,
Кеше иелгәндә—турая.

Сәгать буе күзәтергә әзер
Кырмысканың йөкләр ташуын,
Яз да, җәй дә, көз дә туймый карый
Туган-үскән яклар басуын...

Бар дөньясын онытып, гашыйк була,
Килешүләр белми нәфрәте.
Шатлыклары күзләренә чыга,
Күкрәгендә сыза хәсрәте!

Дөнья-ахирәт алдашмаска дигән
Вәгъдә асларында туган ул.
Нурдан җитез, үлән кебек юаш,
Учак кебек кайнар булган ул,—

Гел шигырьдән генә торган—ул!..

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә бары тик машинкада басылган кульязмаларның беренче нөсхәләре генә кабул ителә. Әсәрләр **210 х 297** лы форматтагы ак кәгазьгә кара төстәге тасма аша ике интервал калдырып басылырга тиеш.

Бер биттә иң күбе—**30** юл, һәр юлда—бары тик **60** (сүз араларын да исәпләп) тамга була.

Кәгазь битендә сулдан—**25** мм, өстән—**20** мм, уң яктан—**10** мм, астан **25** мм чиста ара калдырыла.

Әсәрнең исеме һәм бүлек исемнәре төп тексттан астан да, өстән дә өчәр юл белән аерыла.

Кызыл юл өч хәреф урыны кадәр бушлык белән ясала.

Күләме ун биттән арткан кульязмалар ике нөсхәдә җибәрелергә тиеш.

Әсәр компьютер ярдәмендә җыелган очракта, мөмкинлегегез булса, дискетын алып килү сорала.

Редколлегия таләпләренә җавап бирә алмаган һәм шунлыктан журналда басылмаячак кульязмалар анализланмый, рецензияләнми, авторга кире кайтарылмый.

Бүтән басмаларда дөнья күргән әсәрләр кабул ителми.

*Редакция*



# Илдус Гыйләҗев

## ИҢ ЗУР КУАНЫЧ

### Казан көзе

Төтен катыш юеш асфальт исе
Урамнардан җанга күчәнә.
Әллә нинди авыр тойгы биләп,
Баш әйләнә, фикер күшегә.
Унбише шул бүген—октябрьнең,—
Сагыш кына бу көн китерә.
Хәтта агачлар да шушы көнгә
Яфракларын коеп бетерә...
Тартыналар бугай күренергә
Яшәү төсе кунган күлмәктән.
Казанда көз һәрчак моңсу була,
Үкенечләр ургый күкрәктән.
Бәйсезлегем минем югалган көн...
Еллар арты еллар үтәләр.
Тамагымда тора кайнар төен,
Яфрак коеп елый юкәләр...

### Тукай мәйданында

*Бер горурлык хисе яна миндә,*
*Эчтән бөреп яна битләрдә.*
*Сөйләр идем аны дөньядагы*
*Барлык-барлык парламентларда.*

Сибгат Хәким

Тукай мәйданында басып торам,
Казан каласының үзәгендә.
Җанны биләп алган шатлыгымның
Очкыннары балкый күзләремдә.
Күпме көткән җылы урын бит бу,
Авыр чакта килеп сыенырга.
Насыйп булсын барлык төбәкләрдән
Милләттәшләр бергә җыелырга.
Безгә тиеш гүзәл мәйданнарның,
Олы эшнең әле башы гына.
Бар да булыр! Каршы тора алсак
Таркаулык һәм мәкер басымына...
Тукай мәйданында басып торам,

Татар бәгыренең үзәгендә.
Баш югары, сулыш иркен монда,
Өмет уты балкый күзләремдә...

## Ирексез дулкын

Урта диңгез дулкыннары
Гүләп, шаулап торса да,
Океанга чыга алмый,
Кыршауда ул, кыршауда.
Татарстан—көчле дулкын,
Бик кечкенә булса да...
Океанга җитәр иде,
Уртада шул, уртада...

## Алардан булмас

*КПСС Азнакай шәһәр комитетының*
*соңгы беренче сәркатибе Н. Мозаффаровка*

Яшисезме Сез дә, минем кебек,
Үкенечле уйлар саркытып.
Сез беренче, мин икенче идек,
Булып калдык... соңгы сәркатип.
Фирка җыйган гөнаһ, сагыш, каргыш,
Авып төште безнең өсләргә.
Тарих таптап үтеп китте шулай,
Җәрәхәтләр сызлый, нишләргә?
Без үстергән «яңа» җитәкчеләр
Үзебезне йөртә типкәләп.
Бөтен җирдә шулар, элеккеләр,
Алым шул ук—таптау, төрткәләү.
Ул фирканың әллә табигате,
Тәгълиматы шундый идеме?
Әллә исәнме ул, үзгәрмичә,
Яңа битлек кенә кидеме?
Илне дә бит бүлеп бетерделәр,
Кемгә байлык, кемгә шымытыр.
Халык һаман түзә, бер кузгалса,
Җәһәннәмгә, беләм, ыргытыр.
Бер фиркада тордык шулар белән,
Кайтып-кайтып шуңа үкенәм.
Без соңгылар... әмма ил алдында
Үзем башлап гафу үтенәм...

## Яраткач...

«Чыгып китмә,—диде ана,—
Беләсең бит, холкы начар.
Бер төнәгәч җитмәгәнме,
Төзәлми ул, кыйнар, эчәр».
Кызы тагын тыңламады,

Тыяр көч юк иде аны.
Бәйләп куеп булмый ла шул...
Үксеп елап калды ана.
Үзе уйлый: «Минем булып
Минем сүзне салгач аска...»
... Ул да шулай эшләр иде,
Яшьлегенә кайта калса...

## Хурлык!

Үз халкыңны үзең кырдыруның
Гөнаһ икәнлеген беләләр.
Беләләр дә... шул ук эшләр өчен
Рәсәйдә... орден бирәләр.
Нинди хурлык! Шуны алалар...
Күкрәкләренә тагалар...

## Рәнҗү

Өч йөз елдан артык испаннарны
Басып торган гарәп-маврлар
Гранада шәһәре эргәсендә
Мәчет-кирмән салып калдырган.
Диварлары, суы, бакчалары...
Җир өстендә оҗмах өлгесе.
Бер могҗиза инде карап торсаң,
Осталыкның иң зур билгесе.
Инквизиторлар иле югыйсә,
Фашистлар да күпме таптаган.
Кирмән исән... әллә гыйбрәт өчен
Еллар аны безгә саклаган.
Бездә дә бит булган мәчет-кирмән,
Урын сайлаган кем ялгышкан?
... Нигә дучар иттең, әй, Ходаем,
Болгарымны башка язмышка?!

## Шикчел хуҗа

Әйтерсең лә миннән башка калса,
Хуҗалыкның чите кителә.
Кунакка да чыгып керә алмый
Көнләп-көнләп гомер сүтелә:
«Абзый өйдә юкта...»—диярләр,
Эскертләрне кыек өярләр.
Өрлекләрне ялгыш куярлар.
Нәсел үгезләрен суярлар...
Әйтерсең лә миннән башка барса,
Бу дөньяның яме бетәчәк.
Әллә ниткән шикчел бәндә булдым...
Минсез камил булмас киләчәк:
«Сөя белә иде...»—димәсләр,
Ятимнәргә хәер бирмәсләр.
Гомер кыскалыгын күрмәсләр,
Уйнап-көлеп яши белмәсләр...

## Эзләп чыгабызмы?

Кешелекнең хәтер агышында
Аңлады да даны какшасын,
Черек сөякләрен җыеп кайтып,
Күмде урыс соңгы патшасын,
Сиксән елдан артык вакыт элек
Ваз кичсә дә үзе тәхеттән,
Патшаның да һәрбер кеше сыман
Хакы бардыр соңгы бәхеткә.
Ул бит әле, түгел илнең генә,
Баш милләтнең рухи шәүләсе.
Халкы затлы булса, күмелмичә
Аунап ятмас патша гәүдәсе.
Кемдер әйтер:—Син үзеңне кара,
Тикшергәнче кеше хәлләрен.
... Сөякләрен эзләп чыгабызмы,
Кайда ята, татар, ханнарың?..

## Өч терәү

*Марсель Галиев һәм*
*Нур Әхмәдиевкә*

Бер үк елда туган малайлар без,
Бер үк яктан, бер үк төбәктән.
Гамәлләребез дә шундый охшаш—
Хис дулкыны кайный йөрәктә.
Чатыртауга карап өч ягыннан,
Өч хыялый, өскә үрләдек.
Шуңа микән, җиңел яуландылар
Яшәешнең башка үрләре.
Хис кимесә, имеш куәт кайта,
Өч каләмне Тауга сөядек.
Туган якны, Чатыртавы белән,
Горурланып һәрчак сөйләдек.
Өч терәүле җисем аумый, диләр.
Ул каләмнәр әле торамы?
Тау ишелер, аның берсенә дә
Кагылмагыз... миннән сорамый...

## Иң зур куаныч

Гади генә үтеп бара гомер,
Сәламәтлек кенә үтендек.
Зур кәнәфи эзләп йөгермәдек,
Мал карадык, иген үстердек.
Туган телне йөрттек байрак итеп,
Гаиләгә ят сүз кермәде.
Саф миллилек булды теләгебез,
Икейөзле булып йөрмәдек.
Өч кыз һәм бер малай-ул үстердек,
Оныклар да туды, юаныч.
Икебездән унбиш татар кала,
Шушы безнең иң зур куаныч...

# Чәчмә әсәрләр



## Нурулла Гариф

# МИН СЕЗНЕҢ АРАДА ЯШӘДЕМ

ЭССЕ

*Фәндә вакытны секундлар, минутлар, сәгатьләр, тәүлекләр һәм ахыр килеп... гасырлар белән үлчиләр. Кеше гомере дә еллар хисабы белән санала. Мин моңа ышанмыйм да, моның белән ризалашмыйм да. Чөнки кыз-кыркын, ханымнар гына түгел, ничә яшь дип сораганны таякка таянган бабаң да яратмас. Яшен искә төшерсәң, үпкәләмәсә дә, артыңнан күңеле сызланып калыр. Кеше гомере узган еллары белән түгел, күргән-белгәне, кичергән кайгы-шатлыклары, күңелен биләгән уй-хисләре белән үлчәнергә тиештер ул.*

*Дөньясын, галәм киңлекләрен дә чакрымнарга салып исәплиләр. Ә кеше дөньясын, күңел киңлекләрен нинди берәмлекләрдә үлчисе? Заманасының кая барганын белер өчен дә әллә нинди югары уку йортлары бетерергә, очсыз-кырыйсыз статистик саннарга чумып, аларны санар өчен компьютерларны җәфалап торырга кирәкми. Әлеге тизлек, юнәлешне күрсәтүче җиһазлар уйлап табылмаган әле. Инде чамалыйсың килсә, урамга чыгып яшьләр белән аралаш, балаларыңның нәрсә сөйләшкәнен, аларны нәрсә кызыксындырганын тыңла. Ә алар, күптәннән синең белән минем кебек уйламыйлар инде. Мин әле моны начар да, яхшы да димим. Бу өлкәдә дә һәркемнең үз үлчәве, үз эше. Тик шулай да юкка янып, хиссез-төссез узган яшь гомерләре барыбер жәл. Һәрберебезнең күңелендә еш кына, кеше ни өчен яши дигән, төгәл җавап бирә алмаслык мәңгелек сораулар туа. Бу сорауны үземә дә еш бирәм дә акланырлык сәбәпләр эзлим. Үзең соң ни өчен яшисең: ник килдең дә дөньясына, ни калдырып, кая китеп барышың?*

*Хәер, бу сорауны үзеңә дә, читләргә дә бирү килешмәс. Беркем дә үзе теләп килми, кайчан киләсен дә, китәсен дә белми. Ә менә дөньясына ни калдырдың дигән сорауны кеше алдына еш куярга була әле. Татар әйтеме бу урында: ул үстер, йорт төзе, агач утырт дип искәртер. Тик бүгенге катлаулы дөньясында тынычланыр өчен болары гына җитәрме? Агачын утыртып, йортын төзеп бирүче дәүләт, тудырган улыңны да тартып алып, тамырсыз калдырып, дөньяга ник килгәнеңне дә, кем икәнлегеңне дә онытырмасмы? Менә монысы чынга ашарга мөмкин, шуңа куркып, көрәшергә тырышып кычкыруым да әле бу.*

*Без авылда тудык.* Татар авылы тормыш авырлыгыннан сыгылып төшсә дә, тамырларының исән вакыты әле. Кыр капкалары аумаган, мәчетләрнең манаралары киселеп, азан тавышы янгырамаса да, күңеленнән иман нуры юкка чыкмаган чак. Яз житсә уен жирләрендә учак яна, тирә-якка гармун моны таратып, түгәрәктә кызлары әйләнә. Авыл тирәсендәге әрәмәлекләр каз көтүе һәм аларны саклаучы бала-чага белән тулган. Татар авылы әле егылып эчми. Кибет тирәсен саклаган өч-дүрт авыл агаеның да нормасы көненә илле-йөз граммнан артмый. Авылда әле ирсез бала да тапмыйлар, тыкрык саен кияүдән кайтучылар да юк. Егет-жилән дә өйләнмичә кырыкка житми. Үзара ызгыш-талашлар да күп түгел. Кыскасы, авыл яхшы күрә, аек акылдан уйлый, юк-бар сүз-чүпне дә читкә чыгарып түкми әле.

Шулай да татар авылы өстендә заман болытлары куерган, татарның соңгы терәге булган авылны ничек төртеп аударасы, таркатып, юкка чыгарасы инде билгеле. Без генә бу турыда әле белмибез. Әмма мәсьәлә Мәскәүдә уйланылган инде. Татар язмышын хәл иткән кәгазьләргә кул куелган, алар бары Суслов кабинетында фәрман биргәнне генә көтеп яталар. Һөжүм берничә юнәлештә алып барылырга тиеш. Талап, ачыктырып, утсыз-газсыз калдырып, тундырып та бетереп булмаган татар авылын шәһәргә авыштырып сыегайтырга, мәктәпләрне тирә-яктагы урыс авылларында гына калдырып, укуны урыс теленә күчерергә һәм эчертергә кирәк. Эчертергә, исертергә һәм юк итәргә. Себер халыкларында сыналган адым бу юлы да үз нәтижәсен бирми калмас. Барысын да төгәл үтәрләр. Дөрес, эчертер өчен бары авыл саен кибетләре, гастроном-ресторannары гына төзелмәс. Аларын төзегәч анда шикәр-писугын да, конфет-прәннигең дә кайтартырга туры киләчәк бит. Кибете булгач эш урыны да була, халыкка акчасын да түләргә кирәк. Ничек эчертә башларга килгәндә, милли тамырына балта чапкан халыкның башка чарасы калмас инде. Анысына гына башлары житәр, үзләре жаен табар.

*Без авылда үстек.* Татар тамырының соңгысына балта белән кизәнгән вакыт, безнең балачакка туры килде. Яланаяклы, әле утын агачыннан аз гына калкурак булсак та, бозау арканлау, каз көтүләр, куяннарга үлән эзләп кеше бакчаларын урау, ерак чишмәдән бөгелә-сыгыла су ташулар барысы да безнең өстә иде. Татарларның кыска буйлы, киң күкрәкле булуын, тамырдан нык чыгуларын галимнәрнең антропологик тән төзелеше, яки борынгы ата-бабаларының ат өстендә йөрүләре белән генә аңлаткан фәнни фәлсәфәләре дөрес түгел ул. Балачактан авыр күтәреп, эшләп үскәнгә дә буйсыз калдык без. Шуңа күрә тәнебез дә нык, көчебез дә бар. Баш күтәреп шул турыда уйланырга вакытыбыз гына юк. Татарның акылы да шул сәбәпле төштән соң аңың. Әзрәк уйланып шәһәргә таючылары булды булуын. Тик рәхәт тормыш тапканнардырмы, монысын әйтүе кыен. Татар булып яшәү кайда җиңел соң?

Гел эш дигәч тә, уйнамадык та түгел, жаен тапкаладык анысы. Кояш чыгып аз гына кыздыра башлауга, казларны көтүләре белән су буена куып төшерәбез дә, кичәдән ком тутырып калдырган тишек галушларны эзләп табабыз. Безнең хыялда алар шунда ук комбайн-тракторларга, машиналарга әйләнә. Трактор, машиналар белән уйнау, арба тартып үскәннән ул. Трамвай-троллейбусларны, очкычларны күреп, шулар белән женләнеп, гәжит-журналларны актарып, китаплар арасында кайнашып үссәк, без башка белемгә, уеннарга тартылмас идекмени? Бабайлар тартып үскән бу уфалланы без дә гомер буе тартып йөрмәбез бит. Без башка юлдан китәчәкбез... Уенның тәме казлар тавышыннан бүленә. Күршедә генә яшәп тә тыныша алмаган ата казлар белән ни эшләргә инде? Күрше малайлары белән сугышмыйча, матур гына уйный идек бит әле...

Суда рәхәтләнеп ята алмасагыз, әнә лапаста ятыгыз. Һәркем үз казын бүлеп алып, өйгә юнәлә. Тамак ачканлыгы искә төшә. Кибеткә ипи кайтыр вакыт житкән. Күнелдә бер курку, бүген дә ипиесез

калмабызмы? Ипи алып кайту, әни кушып калдырган эшнен иң зурысы, иң авыры.

*Алтмышынчы еллар азагы.* Авыл халкының, арыш-бодаен үзе иксә дә, ипи пешерерлек оны юк. Кибетендә дә, районында да юк. Юк дип бар ул, сатуда юк. Фәрман бер, он килеш бер грамм да сатасы түгел. Колхозның он тарта торган тегермәне бар, анысына да рөхсәт юк. Менә шундый баш житмәслек катлаулы мәсьәлә. Дөрес, кибеткә кеше башына ике йөз граммнан ипи кайта кайтуын. Анысы да ярты авылга житми. Әллә авылда яшәүче халыкның санын белмиләр, әллә башкасы. Әле булганын да иртүк чират алып, көне буе саклыйсы. Ипи чиратында күрше-күршене, туган-туганны белми. Сугыш вакыты да түгел югыйсә. Ник болай жәфаланганнарына, дөресрәге жафалауларына беркемнең дә жавабы юк. Бәлкем булыр иде, сорау бирүчесе юк. Кыюларын утызынчы елларда ук жыеп алып бетергәннәр. Котылып калганнары—телсез. Жавап бар, ул Мәскәүдә, теге Суслов кабинетындагы папкада. Әнә, күрше Шомбыт маржаларына жан рәхәте. Аларның үз пекарнялары. Ак ипи генә пешерәләр. Башка авылларга ипи сату тыела. Ә үзләренә күпме аласылары килә. Безнең күрше әби шуна күрә алар турында сөйләгәндә: берсеннән-берсе сары, берсеннән-берсе юан маржалар дип сүз кыстыра. Ак ипи белән салы ашаганга гына икән ул. Аларны кара ипи дә ашап туймаган кара-чутырлы ябык татар апаннары белән чагыштырып булмый инде. Без, әйтерсең лә, башка илдә яшибез.

Кибет тирәсендә көндәгечә сабан туендагыдай халык. Ипи әле кайтып кына килә, халык инде бер аягын жиргә терәгән килеш һөжүмгә әзер. Без малайлар beләбез, иртән әниләр алып куйган чират белән безгә барыбер ипи житмәячәк. Кемнең әбисе бар, ул малайларга жинелрәк әле. Менә ипине сата башладылар. Әле генә дөнья, бер-берсенең хәл-әхвәл, туганлыкларын барлашып утырган халыкның аны таралды. Хәзер инде әби-бабасын, бар нәселен мактасаң да сине беркем дә ишетмәячәк. Ярты авылга сузылган чират катлана-катлана тарая бара. Без беләбез, тиздән ул бөгелеп килеп, ипи алып кайткан атны әйләндереп алачак. Аннан инде чират дигән нәрсәнең эзе дә калмый. Ат та сизенеп як-ягына башын айкап пырхылдый. Бер ыргылыш. Инде без, ипи сатучы Мисбах абыйның артында. Хәзер иң зур бәхет Мисбах абыйның очраклы борылганда, жае килеп, нәкъ синең акчанны алгач киләчәк. Кара брезент астындагы ипиләр күзгә күренеп кими. Шулчак кайсыдыр чаярагы атның корсагына очлы әйбер белән төртеп куя. Авыртудан алга ыргылган ат ипи чиратын артта калдырып ике-өч метрлап алга уза. Без, арба алдында тезләнгән бериш малай, Мисбах абыйны аркасыннан кочып кына арба астында калу куркынычыннан котылабыз. Чират кабат бутала. Алдагылар артта, арттагылар алда хәзер. Без дә Мисбах абыйны яннан урыйбыз. Менә ул бәхет! Акча Мисбах абый кулында. Ах! Ул-бу була күреп, дөньясы гына бетмәсә иде. Тагын бер мизгелдән жылы ипи инде минем кулда. Тиз арада арба астына сикерәм дә кемнәрнендер аяк, бот араларыннан ирекка, урам якка атылып чыгам. Мин беләм, әни әле генә колхоз эшеннән төшке ашка кайткан. Бу жылы йомшак ипине күрсә, дөньясында аннан да бәхетле кеше булмаячак. Табынга, ипи янына мин бөтен чоланны актарып та таба алмаган тагын әллә ниләр чыгачак әле. Әйттем бит мин сезгә кеше гомере еллар белән исәпләнми дип. Әни белән минем бу шатлыклы мизгелләрне күпме фәнни елларга чагыштырып үлчәп булыр иде икән? Бу чорлардан утыз еллар вакыт узгач та каткан ипидән, әнә шул вакыттагы ипинен жылысын тоям әле мин. Нигә ул суынмаган? Кая монда фән, нигә эшләми ул физика законнары?!

*Күршеләр.* Аларны сайлап алмыйлар. Ызгышырга сәбәпләре бихисап булса да, алар авыл жирендә начар да булмыйлар. Күршеләр дигәндә минем күнелгә беренче булып, авыл машина-тракторсыз булмаса да, һәрчак үз кул көче белән генә яшәгән мәрхүм Хәпиз абый килә. Аннан

соң балаларга сүз белән генә түгел үз гомерендә бер генә тапкыр шаярып бармак та янамаган Зыятдин абый.

Без үскәндә утыз-кырык яшьлардәге бу агайлар, дөньяның бар авырлыгын үз җилкәләрендә тартучы ир-атлар иде. Бүгенге көндә инде үзебез шул яшьтә. Ә аларның исән калганнары—таякка таянган мәчет картлары.

Элек күршеләр бер-берсенә кич утырырга йөрешәләр иде. Хатын-кыз бияләй, шәл бәйли. Ирләр җеп аера, базар оегы сүтә. Бала-чага, киресенчә, кемнәрнең өендә аулак—шунда чаба. Уйнаган уеннары да качышлы, яисә күз бәйләш кебекләре. Бар дөнья хәбәрләре, авыл гайбәтләре шунда тарала. Хәзер генә ул һәркем үз өендә бикләнеп, карашын телевизорга текәгән. Бер-берсе белән урамга чыкканда гына күрешәләр. Заманасы башка шул. Бүген исә, көндәлектә генә түгел, туйларда да савыт-саба, чынаяк-чокыр кебек әйберләрне сорап керәсе дә, йомышка йөгертерлек бала-чагасы да юк.

Без үскәндә халык күпкә бердәм, бер-берсенең ярдәменә мохтаҗ иде. Үзебез дә шул калыптан чыктык исә. Тик безнең буында бу тойгылар аз инде. Очрашулар да сабан туйларына, яисә башка очраклыкка бәйле. Анысында да авыз ерып, шатланышып исәнләшәбез, яшь чакларны искә төшергәндә, бала чактагы кебек ихлас булабыз да, бүгенгесен искә төшереп барлаганда, арада ниндидер күзгә күренмәгән пәрдә туа. Элек барыбыз да бер үлчәүдә идек. Хәзер тормыш-язмышлар, яшәү шартлары төрлечә. Әмма озак, иркенләп сөйләшеп утырырга вакыт тими. Йә хатын чакыра, йә балалар чабудан тарта дигәндәй. Дөньясы начар бит... үзебез шундый булганга. Саубуллашып китәргә ашыгабыз. Җан күршеләр белән әле кабат тагын кайчан күрешелер?

*Әбиләр.* Без үскәндә алар сиксән-туксанга житкәч тә чабып йөреп, көтмәгәндә генә мәңгелек йортка китеп баралар иде. Көне буе эшләгәннән соң йөреп, кичләрен капка төбендә дисбе тартып, дини китаплар укучы, ак яулыклы бу әбиләрне без мәңгегә югалтуыбызны аңламый да калдык. Ярата идек без аларны. Кулларыннан өлешкә тигән шикәр-конфетлар, йөзем, өрек җимешләре, аларның төшләре дә, өч-биш тиенлек бакыр акчалары да, безгә күп шатлыклы мизгелләр бүләк итте. Бисмиллаларын әйтеп, йомшак куллары һаман да баш түбәләребезне сыйпый кебек. Еллар узып, без үсә төшкән саен, инде башкалар әби булгач, карашлар үзгәрде. Болары башка, революциядән соң туып, совет хакимияте күрсәткәннәрнең ачысын да, төчесен дә татып үсүчеләр. Гореф-гадәтләр югалган, әхлак тапталган вакыт. Бу әбиләрнең таяклары сыртка күп төшеп, Аллаһ исеменнән каргышлары да еш яуды безгә. Әниләр биргән хаерне дә кертергә курка идек. Үзебез дә шук, шуклыгыбыз да зыянны күп салгандыр, күрәмсең. Шулай да заманасының иң авыр чагында, татар авылының рухын саклап, шул таянып йөргән таяклары аша да безне деңгә кертеп, тәрбия, җан җылысы биреп киткән бу әби-бабайларга һәрчак хаердогада без. Без үскәндәге әбиләр бала-чаганы яратып, киләчәккә өмет багласалар, бүгенгеләре, киресенчә, куркып, инде болар үсеп житкәч нәрсә күрсәтер дип өметсезләнә.

Бүгенге көндә авылдагы ак әбиләрнең аклыгы, күбесенчә башларындагы ак яулыкларында гына. Сынмаган, сыгылмаган, аклык-сафлыкларын саклаучылар бик сирәк. Инде алар җылысыннан да мәхрүм калсаң, ни эшләрсең син, татар авылы?!

*Авылдашлар.* Аларның тамырларын барлый башласаң, бары да бишалты буын арасында туганлашып бетәрләр. Бу берлекнең чишмә башы, унтугызынчы гасыр уртасында Тәтеш өязенең Иске Сала авылыннан тирә-якта бүленмичә калган кысан бушлыкка килеп төпләнүчеләргә тоташыр. Атамасы да шуңа бәйле (Околоток) Яңа Сала. Безнең бабайлар бу якларда килгән халык. Авылның үзенчәлеге зиратында да саклана. Бүгенге көнгәчә андагы каберләр имән казыклардагы тамгалар белән чуарланган. Тирә-яктагы дистәләрчә башка авылларда мондый йоланы

тапмассын. Араларында биш төрлесе еш очрый. Килгән унбер гаиләнең төпләнеп калган бишесенеке алар. Тау ягыннан күченеп килүчеләр–кыпчаклар. Аларның антропологиясе, тамгалары да кыпчакларга хас. Татар язмышы кайда да бер инде ул. Физик кыерсытылу, кимсетелүләр генә җитмәгән, күнеленә дә кагылалар. Берәүләр аларның килү сәбәбен урман, җир җитмәү сәбәбе белән аңлатса, икенчеләре көчләп чукындыру сәясәте белән бәйлиләр. Ни сәбәптән булса да гуып-үсеп, ата-бабанны җирләгән нигездән тамырларың белән кубарылып китүе җиңел булмагандыр. Өстәвенә кырыс еллар, беркемне дә, беркайда да көтеп тормый. Яңа урында да бары да тыныч түгел. Бер яктан "Тәтеш хәерчеләре" дип үзеннеке кимсетсә, икенче яктан шул ук Шомбыт урыслары бимазалый.

Безнең бик борынгы бабаларыбыз–дала халкы. Бер фасылдан икенчесенә алышынып торган табигать, үзләре уйлап тапкан арба тәгәрмәчләре генә түгел, авыр язмышлар да бөек дала буйлап куып йөрткән аларны. Инде кабат үзебездә дә шул язмыш. Бүгенге көндә авылда туып, үз дөньясын ачкан халыкның анда чиреге генә булса да торамы икән? Язмышлар гына түгел, үткәндәге ялгышлар, татарга хас булган таркаулык та дулкын кебек бәрә-бәрә куа безне...

Элекке Тәтеш өязендәге Иске Сала турында шул чорның тарихи язмалары гына искәртә. Инде киләчәктә янасының язмышы ничек язылыр?

*Туганнар.* Аларның арасында төрлесе була: туганы да, чәчкәне дә. Туганнарың барлап, яратып чәчелгәннәре өчен борчылып, җан атып яшәп яту әле. Кызганыч, югалтулар да зур шул.

Тирә-яктагы татар авыллары, җиләк җыйсалар да, шәл бәйләсәләр дә сатыр өчен Чистай базарына чабалар. Чулман буендагы Кызыл Яр кичүенә урман аша, унбиш чакрым юл. Күрше-күләннәр арасында юлдаш табылмаса, әнигә ияреп, шәһәргә бару бәхете кабат миңа төшә. Безнең анда урнашып торырга, кирәк булса кунып калырга туганнар да бар. Килүгә, әни кыз туганын ияртеп югары базарга менеп китә. Ә аның ике-өч яшькә кечерәк малаена күз-колак булу минем өстә. Тик бер уңайсызлыгы бар: ул юньләп татарча, мин урысча белмим. Аңлаша алмыйбыз. Шунлыктан уен да ялганмый. Шәһәр баласы һавалырак шул, чарасыз калган Радик ике куллап күземә ком чәчә. Кунак булу тыйнаклыгы тәэсир иткәндерме, әллә гомеремдә беренче күргән уенчык машинамы, уйнавымны дәвам итәм. Бераздан Радик та миңа кушыла.

Базарчыларның юлы уңган. Озак та узмый, өйдән әйберләрен күтәреп апасы белән әни чыга. Китәр мизгелләр якыная. Азрак дуслаша төшкән Радик белән ни әйтергә белмичә бер-беребезгә карашып торабыз. Якын кешесен югалткандай, безнең арттан урам беткәнчегә чаклы:–"Китмә малайка, китмә малайка",–дип җылап чабачак әле ул.

Безнең авылда гомер дә Радик атлы малай булмады. Татарча белмәүчеләр генә түгел, телсезләре дә тумады. Чистайда күп тапкырлар булсам да, миндә зур тәэсирләр калдырган Радикны башка очратмадым. Алар шәһәрнең икенче ягына күчеп киткәннәр иде.

Тарих белән кызыксынып, Чистайдан биш чакрым ераклыктагы болгар шәһәре Җукәтауда күп еллар тикшеренү эшләрендә катнашырга туры килде. Элек юкка гаҗәпләнгәнмен, үз телен белмәүче Радиклар белән Чистай тулы икән. Аларның берсе минем туганым. Язмышына ниләр язылган булды икән синең, малайка. Җан тартмаса да кан тарта бит... Кабат очрашырга иде, бәлкем бу юлы аңлаша да алырбыз.

*Дин.* Авыл белән бергә барлыкка килеп, беренче тапкыр 1871 елда искә алынган мәчетнең 1934 елда манарасы җимертелә. Без белгәндә клуб иде ул. Тау астындагы мәдрәсәсенең дә урын-нигезләре беленеп тора. Авылның беренче мәктәбе дә шунда ачылган. Олы кешеләр үзләренең кечкенә чакта анда латинча укулары турында сөйлиләр. Каршы яктагы бушлыкны да хәзергәчә мулла йорты урыны дип ишетеп беләбез. Бу авыл хәтере.

Авыл картлары, мәчетне тартып алсалар да, төшенкелеккә бирелми. Бу чорлардан дистәләрчә ел узуга да карамастан, җомга намазына безнең күрше әби йортына җыелалар иде. Ураза, корбан гаетләре дә алар оештыруында уза. Кичтән үк колхозның берәр буш амбары яисә бәрәнге саклау урыны җыештырылып куела. Җомга намазларыннан аерым буларак монда авылның бар ирләре дә җыелыр. Мәктәптән калып, әтиләргә ияреп гаеткә бару безнең өчен дә зур бәйрәм. Кичтән үк сөйләшеп куябыз да, иртән бер-беребезне барлыйбыз. Бергә булгач күнеллерәк, әрләүләре дә куркытмый. Амбар почмагында бала-чага сыярлык урын кала ла ул. Бердәм булып барыбыз да бер кыйблага багабыз. Кешелектә төрле булган авыл ирләре дә, бер тәндәй булып, сәҗдәгә китә... Хәтер почмагында бер уй да пәйдә була,–өйдә әнинең бәйрәм коймагы да пешкәндер инде.

Без намазга басып, белгәннәрне укып йөрмәсәк тә, бөтенләй бисмилласыз да түгел идек. Җомга вакытын белеп, шул арада үзебез дә шау-шулы уеннардан тыелып үстек. Өйдә олылар ураза тотып, намазга басып көн күрде. Шуңа да кечкенәдән күңелгә сенеп калган моңлы азан тавышы янгыраганда бүген дә күңелләрне уйнатып, күзләрне яшьләтә. Без динле төбәктә, әмма дини тәрбиясезлектә үстек. Әнинең китапларындагы серле язмаларны карап, аның пышылдап укыган догаларын сәгатьләр буе тынларга риза. Бала күңеле киң бит ул. Бит саен үзгәргән тамгаларның мәгънәсен сорап, икенче көнне үк ачкан берен әйтеп бирә алырлык өйрәнгән идем. Әмма тагын да ныграк кызыксына башлагач, әни борчылып,–"Улым, боларны белүнең сезгә кирәге чыкмас инде"– дип китабын алып, яшереп куйды. Ул үзе укымышлы муллалар нәселеннән. Күптән түгел генә вафат булган апасы да Казакъстандагы Гурьев шәһәренең остабикәсе иде. Бәлкем үз туганнарына төшкән каһәрле язмыштан йолып каласы килгәндер. Әнинең бу кырыслыгы, бала күңеленә каршы төшү сере, бүгенгәчә аңлый алмаган иң катлаулы табышмагым минем.

*Һәр авылның үз чикләре була.* Алар табигать яисә кеше тарафыннан билгеләнә. Авылыбызның як-ягында ике җенле нарат бар. Күпме куркыныч, шомлы хәлләр, күренешләр сөйләнелгән алар турында. Күрәмсең, шуңа да авыл арасындагы җенле нарат яныннан узганда, үзеннән-үзе балачак халәтенә төшелеп, ихтыярсыздан, иреннәр белгән догаларны пышылдый. Әби-бабайлар чорыннан ук калып, инде картаеп беткән җен, кабат яшь кыз булып, муеннарга сарылыр, яисә ак сакаллы карт булып каршыга килеп басар төсле.

Авылга алып кайтучы юлдан узганда гаскәриләрнекеке кебек, баш үзеннән-үзе унга борыла. Күзләрдә кызыксыну катыш курку. Ә анда, ике елга арасында үскән җил-давылларга, бөтен табигатькә ялгызы каршы торып, кырыкка бөтерелгән нарат агачы. Нинди генә булсаң да рәхмәтлемен мин сиңа, үзең каршы алган һәр юлчыңны уйландырасың син. Синең аркада без әле дә әби-бабаларыбыз кичергән хисләрне татыйбыз.

Шулай да күңелдә булган бер борчылу да бар. Юк, сиңа каршы берәү дә балтасын күтәрмәс. Тик шул ук рухта безнең балаларыбызга да тәрбия кыларга гомерең җитәрме синең? Сорауны бирәм дә уйга калам. Авыл тирәсендә бүгенге балалар куркырлык нинди генә җен-шайтаннары калды икән?

*Кыек тау.* Ике тау арасындагы үзәнлеккә сыенган авылны ачы Себер җилләреннән саклаучы ул. Ә безнең өчен әлегә бар дөньясында да аннан биек тау юк. Чөнки анда барган да юк, аннан биеген күргән дә юк. Күпме генә агач башларына менеп карасак та, әлегә һавада йөзүче болытларның чиге һаман шунда өзелә. Дөнья зурлыгы тирә-яктагы күршеләр, кибет белән йорт аралыгында гына әле. Авыл чикләре кыр капкалары белән тәмамлана. Күз күременең бер ягы караңгы урман булса, калганнары–иксез-чиксез басулар.

Кечкенә чак гомернең иң гөнаһсыз, иң рәхәт, тыныч чаклары икән. Татар авылының гасырлар буе бер тел, бер иманда кайнаган заманы.

Дөньясы әле бозылмаган: сугыш, кан коюлар да ишетелми. Чөнки әле авылда радиосы, телевизоры да юк. Иң курыкканыбыз—бер Ходай. Аннан авылның кыр пләвәе белән пожарный. Соңгыларыннан курыксак та тоттырган юк әлегә. Менә әрмиядән генә кайтыйк әле, үзегез беренче килеп күрешерсез...

Әмма үсәсе, дөньяны танып, газиз халкың иннәренә төшкән ачы язмышларны күреп беләсе, бу авырлыкларны да үз сыртыңда гомер буе йөртәсе алда әле. Әлегә басу читеннән соң башланган дөнья безне әллә урта, әллә таш гасырда калдырып, каядыр чаба гына. Башкалар инде галәм кораблары, ис-акылны алырлык акылга ия компьютерлар ясап яталар. Без генә бу турыда әлегә берни дә белмибез. Безнең өчен тагын да зуррак югалтулар китерәчәк вакыт та алда әле.

*Гореф-гадәтләр.* Әйткәнемчә, без әле авыл халкының азмы-күпме татар калыбыннан чыкмаган заманнарда үстек. Яз житеп, калкулыкларда жирләр чыгуга аларда кичкә чаклы бала-чаганың чыр-чуы тынмый иде. Ут ягу, язгы ташуларда утлы көймәләр жибәрү эшләре, әйтерсең лә, безгә йөкләтелгән. Сугыш уеннары да яз житкәч башлана. Һәр малайда төелгән жиз торбага бөгелгән кадак белән суктыручы шартлаткыч пугач-мылтык. Олыракларда аның тагын да дәһшәтлесе. Анысы катырак шартлый, шуна күрә куркынычырак та. Бу мылтыкны кесәгә тыгып йөрү дә егетлек. Яз көне пожарник яисә олырак мужикларның малай-шалайларны тентеп, кесәсеннән мылтык эзләве гадәти хәл. Безнең авторитет күтәрелә генә, әйтерсең лә гестапо үзе тикшерә. Безме соң инде алар табырлык итеп кенә яшерүчеләр? Бу уен, шартлауларның югары ноктасы беренче, тугызынчы майларга туры килеп, кинәт кенә бетә иде. Беренче май бигрәк тә күтелгән бәйрәм. Дөнья эшчеләренең үз хакларын даулауда әлегә эшебез юк безнең. Әмма Беренче май гасырлардан-гасырларга, мәжүсилек чорыннан ук дәвам иткән олылар өчен—сабан туе, без бала-чагаларга йомырка жыю бәйрәме. Ел буена көтеп алынган бу көндә бары да елның уңышлы килүен теләп бала-чаганың күңелен күрергә тырыша. Буләге буялган йомырка—жан яралуның серле бер йомгагы. Кичтән йомырка буяп куймаучылар авыл саен берничә генә булыр. Алары да алдан ук акланып, кунакка барасыбыз бар иде дип күбесенчә өендә бикләнеп ятучылар. Укытучы халкы кисәтүле булып, бу бәйрәмнән искелек калдыгы күрсә дә читтә кала алмый. Үз балалары да әти-әнисенең укытучы булганына гаепле түгел бит инде. Бары да безнең арага кереп буталалар. Ә безгә, укырга да кермәгәннәргә, бары да тигез, күңелгә курку да кереп сеңмәгән әле.

Йомырка бәйрәме—балалар өчен язның иң беренче бәйрәме. Безнең чордан тагын да элегрәк аның үзенчәлекле башка йолаларын да үтәгәннәр. Көне дә апрель ахыры, май башлары арасында язның кайчан, ничек килүенә бәйле булган. Кырга чыгарга бер-ике көн кала уза ул сабан туйлары. Бәйрәм ат белән авыл буйлап йөреп, әрәпә әйтүдән башлана. Һәр авылның үз такмаклары: "Бүген әрәпә иртәгә сабан туе, абыстайлар, тәтәйләр бирер безгә күкәйләр". Тирә-яктагы татар авылларында соңрак була торган жыеннан үзгә, бары бер көнне генә уза ул. Ялгышып кабат керелсә дә борып чыгару юк. Әниләр тегеп биргән киндер капчыкка барыбер конфет, печенье булса да төшми калмый. Олылар сөйләве буенча заманнарның иң авыр чакларында да тукталмаган бу бәйрәм. Утызынчы елларда, налог жыючылар тавыкның йомырка салганын көтеп йөргән чакта да, арыш оныннан шакмаклы төшләр пешереп, балаларга таратканнар.

Тамагы туеп, күңеле булган бала-чага, яшьләр соңрак урман хозурына тарала. Анда учак ягалар, жыр-биюләр башлана. Һәрхәлдә без үскәндә шулай иде.

Бәйрәмгә бәйле башка хатирәләр дә күп. Ел саен ураза вакытында кемнең озын тәнәфестә ашамаганын тикшерү генә житмәгән, апрельнең соңгы атнасында ук беренче май бәйрәмендә йомырка жыярга ярамаганлыгын кисәтеп жибәрделәр. Дөрес, ул куркытулар мәктәптән кайтканда

ук коелып калды. Майда өч көн ял, аңынчы онытырлар әле... Ә дүртенче майда беренче дәрес алдыннан ук линейка җыйдылар. Директор үзләренә үк кирәргә батырчылык иткән өч-дүрт кечкенә баланы линейка каршына чыгарып бастырды. Торалар тегеләр геройлар кебек. Берлинны алганнармыни! Ә башкалар үзләрен күрмәгәнгә шат. Тик кенә басып торсалар ярыйсы да бит. Әмма геройларның котырта торгач түземлеге бетте. Нигә ул көлә, без бит йомырканы бергә җыйдык. Ә шулаймы? Әйдә, чык! Бала-чага бер-берсен күрсәтә-күрсәтә каршы якка чыгып бетте. Линейканың каршында, укытучылар арасында гаепле кешеләр кебек директорның ике баласы гына калды. Хәзер инде бар мәктәп алардан көлә. Мин шунда директорның тәүге тапкыр уңайсыз хәлгә калып, кызаруын күрдем. Кеше баласын гына мәктәп каршында хурлавы җиңел ул. Директор ык-мык килде дә линейканы таратты. Шуннан соң беренче майда йомырка җыймаска дигән кисәтүнең башка булганын хәтерләмим.

Бәйрәм бүгенге көндә дә дәвам итә. Авылдан чыкканнар бары да кечкенә балаларын йомырка бәйрәменә алып кайтырга тырышалар. Кечкенә чакларын исләренә төшереп, үз балаларына да авыл йолаларын күрсәтәселәре килә, күрәмсең. Дөрес, балалар капчыгына йомырка урынына хәзер чәйни торган сагызлар күбрәк коела. Әллә тавыклары йомырка салмый, әллә балалары ашамый. Заманалары үзгә булгач, бәлкем, җан яралуның сере дә ачылгандыр. Мин үзем кешенең йомыркадан түгел, сагыздан яралу мөмкинлегенә күбрәк ышанам. Үзегез дә уйлап карагыз әле, бу дөньяда сагыз кебек очсыз, чәйнәлүчән, изелеп-сузылып, сыгылып-бөгелеп төрле формаларга керүче, ябышкак, буш куыктай өрелеп шартлаучы кешегә охшаш башка тагын нинди хайван бар соң?

Гореф-гадәтләр авылларда гына сакланса да, аларның да күбесен югарыдан килгән фәрман буенча баш-аяк бутап бетергәннәр, яисә онытырга мәҗбүр иткәннәр. Мин кечкенә чакта язгы чәчүләр тәмамланганнан соң буласы бәйрәмне сабан туе түгел, ә җыен дип кенә ишетеп белә идем. Кайда ничектер, бездә ашлыкны сука белән чәчмиләр. Җыен—җыелу сүзеннән бит ул. Чәчүләр бетеп, печәнгә төшкәнче халык эштән берара буш була. Менә шунда туганнар бер җыелып, яшьләр күңел ачып аралашып алганнар. Ә җыен сүзен хәзер урысчага тәрҗемә итеп карагыз әле. Куркыныч булып китмәдеме? Бу сезгә теге “праздник плуга” гына түгел инде. Татарлар җыелгач ни була соң? Моны теге Суслов кабинетына җыелучы “олы” агаңнар яхшы белә. Җыелмыйча да мөстәкыйльлек сорый алар. Ә җыелсалар сорап та тормаячак, тартып кына алачак. Әнә үзләре дә, ничек, татар барда—хәтәр бар, диме әле?

Җыен бәйрәменә бәйле үз хатирә-елларым да бар. Нәкъ шул көнне беренче тапкыр үҗәтләнеп, яланаяк, канап беткән тез башларым белән елый-елый булса да авылдан чыгып дөнья күрергә насыйп булган икән миңа.

Биш-алты яшьләр тирәсе. Өйдә әти белән бабай тирә-якка данлыклы Бөкәш җыенына җыенып йөриләр.

—Мине дә алып барыгыз—дим.

Бала сүзенә колак салучы да юк. Чыгып йөгердем болар артыннан. Күрше Котдус абый инде машинасын кабызган, кузовы да яртылаш басып баручылар белән тулы. Машина тирәсендә елап йөрим. Ниһаять, Котдус абый чыкты. Мине күрде дә:

—Ни эшләп бу баланы алып бармыйсыз?—ди.

Әти:

—Котыртма—дип әрли. Миңа исә:—Бар улым, киенеп чык, алып барам,—ди.

Шаяруларын белмәсәм дә, алдашуларын гына аңларга баш җитә. Күп тә үтмәде, машина кузгалды. Мин дә машина артыннан йөгерәм. Юлдагы кешеләрне туктап утыртканда куып та җитә язам үзен. Тик ул тагын кузгала, минем җир акырып елап чабу кабат дәвам итә. Борылышларда юл юнәлешен үзгәрткән арада тузан арасыннан чыгып күренеп тә

киткәлим, ә боларның барысын да Котдус абый ут йотып машина көзгесеннән күзәтеп бара икән. Авылны чыгып киттек. Инде хыялдагы кыек тау да яртылаш артта калды. Миннән инде күз яше дә, акырган тавыш та чыкмый. Үҗәтлектән башка барысы да чыгып беткән. Машина кыек тау артына качам дигәндә генә тукталып калды. Кабинадан атылып чыккан Котдус абый кузовтагыларга кулларын бутый-бутый нидер кычкыра. Ул арада мин дә килеп житеп, тузан да кабат басылды. Соңгы сүзләре мина да ишетелә:

–Шушы баланы алып бармасагыз, ант итеп әйтәм, үзем бармасам бармыйм, сезне дә алып бармыйм! Төшегез машинадан!

Күршеләрнең ялварулы карашлары әти белән бабайга юнәлгән. Шулчак бабай:

–Әйдә, улым, минем белән йөрерсең,–дип ризалашты.

Машинага кемнәр очыртып кына меңгезгәнен хәтерләмим дә инде. Шулай итеп, ертык күлмәк-ыштаннар белән, башаяк тузанга баткан килеш, аның каравы дөньямның иң биек тавыннан машинага утырып, татарның иң олуг бәйрәменә–җыеңга юл тоттым. Кыек таудан соң башланган яңа дөньяның әллә ни артык кызыгын күрмәдем. Шул ук урман-кырлар, бер-берсенә охшаш авыллар. Әллә шул чорлардагы шатлы-гым зур булып, бар хис-хатирәләремне басып киткән, белмәссең. Аның каравы бәйрәмнең хатирәләре кичә генә булгандай истә калган. Минем бабайны анда барысы да таныйлар, үзләре килеп ике куллап күрешәләр. Шул исәптән минем дә аркамнан сөеп тишек кесәләремә тәм-томнар салырга тырышалар иде. Бабай белән йөрү минем өчен бик файдалы булды. Аннан алып кайткан күчтәнәчләр белән атна буе тукландым әле мин.

Элегрәк җыенда берәр ялан аяклы кечкенә бала күрсәм, кулына бер уч акча салырмын дип хыяллана идем. Бүгенге көнемдә бәйрәмгә чәчәктәй киенеп килгән бала-чаганы күреп сөенәм дә, акылым белән Ходайдан элекке хыялларымның тормышка ашмавын сорыйм.

Билгесез, әмма күреп беләсе килгән дөньяма икенче тапкыр әнигә ияреп чыктым. Туганнарының хәлен белеп кайтырга барган көннәренең берендә, олыга санап, үзенә иптәшкә алды. Абыйсының балалары да минем чамада булгач, аралашып, туганлашып та калсыннар, дигәндер. Моныңчы апайга елмая иде бу бәхет. Җәйнең озын көннәре булса да көтүдән дә алдан кузгалдык. Йокы килү кулларны йодрыклатып, күзләрне ышкыта. Нигә болай иртә кузгалуның сәбәбе дә билгесез. Шулай да ризасызлык юк. Чөнки кырык ишетеп, бер булып та күрә алмыйча калган элекке район аша да үтәчәкбез икән. Кызыл Йолдыз районы бетеп, Балык Бистәсенә кушканнарына әллә ни гомер узмаса да, Бөкәшкә баруны районга дип сөйләшкән чак. Кыек тауга күтәрелеп, аз гына баргач та күз алдында тагын бер биек тау пәйдә булды. Әлеге тауның итәгендә яткан авылның атамасы да Биектау икән. Ана чаклы Көчек, тагын да элгәре Балхуҗа исемендә булган ул. Миндә, бу таудан да биегрәк тау бармы икән, дигән уй туды. Бу турыда әнидән сорашкач:

–Булырга тиеш улым, Ходайның рәхмәте иксез-чиксез аның,–дигәне истә калган.

Әни алдамас, ул бит төннәрен карт әбиләрдән әллә нинди борынгы калын китаплар алып чыгып укый.

Тирә-яктагы элекке Нугай юлы буйлап энҗе-мәрҗәннәрдәй тезелгән татар авыллары гасырлар буена үзара туганлашып беткәннәр. Әнинең туган авылы да безнең авылдан унөч чакрым ераклыкта урнашкан. Хатын-кызларда туганлык хисләре күпкә көчлерәк була икән. Әни дә туганнары арасыннан исән калган бердәнбер абыйсы янына кимендә айга бер тапкыр булса да барып кайтыр.–"Кыз туганың хәлен белүнең савабы үлчәп бетерә алмаслык",–дип кабатларга яраткан абыйсы да кимен куймас, ай дигәндә салкынга, яңгырлы пычрак көнгә дә карамый килеп чыгар иде. Мина алар бер-берсенең хәлен кем күбрәк белешә дип ярышканнар кебек. Бу аралашу, якын туганлык җепләре безгә, аларның балаларына

да күчте. Тик еш очрашуга килгәндә һаман да шул заманасының җүнсезлеге. Безнең хәл белешүләр күбесенчә бер-беребезгә йомыш төшүгә кайтып кала шул...

Иртән чыгуның сәбәбе әнинең туган авылына барып җиткәнче юлда очраган дистәгә якын авылларга керә бару. Һәр авылда аның яшьлек дуслары, тормыш юлын бергә үткән таныш-белешләре, чыбык очына тиклә аралашкан туганнары. Һәрберсенә кергән саен чәй эчәрлек конфет, әби-бабайларга унбиш-егерме тиенлек хәер калдыра барып безнең сәфәр көне буена сузылачак. Дөрес, өйдә калдырылган юл хәере урамга чыккач озатып калучылар башымны сыйпаганнан соң минем кесәгә күчә. Баланы сөендереп—"Шәфкатьле бул улым"—дип күнеленә изгелек орлыклары салу хәернең тагын да зуррагы икән.

Районны күрәм, кесә тулы вак акча булганлыктан, тирә-якның иң зур кибетенә керәм дигән хыяллар тормышка ашмады. Район дигәнең мин күргән авыллардан күпкә зур булып, безгә аның бер читеннән генә узарга язган икән. Аның каравы киләчәктә, яшәүнең олы бер мәгънәсенә кайтып калачак Ханнар каласын күрдем. Аның турында әнидән ишетеп, күп тапкырлар кызыксынганга минем күз алдында ул районнан да зур, ап-акка төрелгән биек манаралар белән тулган ташкала иде. Әмма әнием күрсәткән җирдә бары текә тау башындагы тирән чокырлар, биек үрләр һәм алардан соң башланган калатау өсте атамасындагы такыр кыр башлары гына күренде. Минем аңыма әле кешеләрнең безгә чаклы да яшәгәнлеге, урманнарның шәһәргә, шәһәрләрнең кырга әйләнеп калуы соңрак киләчәк. Дөньясы кинәйгән саен, аңларга теләү дә арта, әмма, ачы язмышларны күреп күнелләр катылана, кешеләр кырыслана икән. Чаллы каласын күргәннән бирле мине дөньяның зурлыгы гына түгел, борынгылыгы да кызыксындыра башлады...

*Тарих*. Безнең халыкның тарихи тамырларын нигәдер җиденчесигезенче гасырларда Азау диңгезе буйларыннан килгән болгар кабиләләре белән генә бәйлиләр. Ә аңынчы әйтерсең лә төркиләрнең Идел буенда эзләре дә булмаган. Бу төбәктә бары фин-угор, балт халыклары гына яшәгән дип аңлаталар. Соңрак, үз ялганнарына үзләре ышанып, славяннарның бер кабиләләре дә яшәгән дигән теория кертә башладылар. Чит халыкларның яулап алган җирләрен үзләренеке дип ышандырырга кирәк бит. Рәсәй тарихы кысаларыннан чыга алмаган үзебезнең тарихчыларны кимсетү түгел бу. Мөмкинчелек тууга алар үзләренең бүгенге кыю, әмма күптәннән дөрес булган фикерләре белән чыга башладылар. Бу җәһәттән минем дә үз фикерем бар. Бу җирлектә төрки кабиләләр безнең эрага чаклы мең еллар элек тә яшәгән. Аларның эзләре адым саен. Мәсәлән, иң борынгы кабиләнең берсе "бура" культурасы белән аерымлана. Алар үз мәетләрен җиргә агачтан бура бурап индерә торган булганнар. Ә кайсыгызның безнең халыкта "Төшендә бура күрсән—өеннән мәет чыга"—дигән юрауны ишеткәне юк. Ә мондый юрау тагы кайсы халыкта бар? Безнең халыкка гасырлар кичеп геннарга күчкән куркудан керә бу төшләр. Анда үлем китергән ин зур кайгы, тетрәнүләрдән язылган ул. Бүгенге көндә геннардагы үзгәрешләр физик үзгәрүләр белән генә бәйләнә. Киләчәктә аннан тарихи информациядә алып булачагына шик юк. Кемнең каян килеп, кемгә әверелгәнен беләселәр алда әле.

... 1183 елның җәй башы. Өметле язның шифалы янгырларына ияреп Болгар иле өстенә шомлы хәбәрләре дә килә. Биләргә—Олуг шәһәргә каршы яу булып кабат урыс кенәзлекләре берләшеп юлга чыккан. Инде дуслашканда, "колмак суга батканчы, таш судан калыкканчы дошманлашмаска" дип сүз дә беркетелгән, Болгар ханының уртанчы кызы Ханәкә Суздаль кенәзе улына ярәшелгән дә. Котыртучысы бармы, әллә берәр алдан уйланган мәкерле эш йөртәләрме бу урыслар, белмәссең. Уйланырга, илчеләр җибәрергә ара юк. Олуг шәһәрне җимерсәләр Бөек Болгар иле юкка чыгачак. Ә бер җил тараткан кабат җыеп кара син. Көл-күмеренен бөртеген да тапмассың. Авыл-биләмәләр, арба тәгәрмәче астында изелгән

үлән кебек кенә авып калачак. Биләргә ярдәм кирәк!

Имеш-мимешләргә уралып, Чулман алды гөр килә. Урыслар инде Чулман каршындагы Ак Иделгә кереп, Исәт утравына килеп туктаган. Йөзгә якын жил каекларындагы субасарлары каршы ярга чыгып урнашкан. Биләргә туры юлдан ким дигәндә көн ярымлык юл кала.

Болгар халкы төрле ыруг, биләмәләргә бүленсә дә бер тамырга тоташкан. "Бүленгәнне бүре, аерылганны аю ашар" мәкале дә гасырлардан килгән бердәмлекне аңлата. Чулман буйларының Биләргә каршы ягындагы болгарларның Чаллы, Тәмте, Саба һәм Күл кабиләләре Олуг шәһәрне якларга бердәм кузгалды. Субасарларның Идел белән төшеп уңга түгел, сулга туктап үз биләмәләрендә ут белән айкап узулары да бар иде. Биләр каршы тора алмаса, кайтканда сугылып китүләре дә мөмкин. Тәүлек арасында биш меңнән артык сугышчы җыелды. Кыска төннең карангылыгыннан файдаланып шул ук төндә көймәләргә төялеп Исәткә юнәлделәр. Утрауның әйләнә тирәсе учаклар белән тулган. Әмма алар дошман хәйләсен яхшы белә. Болай да бүленеп калган гаскәрнең кече өлеше генә утрауда. Калганнары каекларын саклый. Йөздән артык кеше сыйдырышлы бушап калган каеклар судан колач буе күтәрелгән. Шунлыктан аларга ун-унбиш кеше сыйдырышлы көймәләрдән һөҗүм итүе уңайсыз. Ә менә утраудагыларын иркенләп туздырып була әле. Сугыш кыска һәм нәтиҗәле булды. Урысларның утраудан качып котылганнары үлемнәрен судан таптылар...

Милли китапханәнең ябыласын белгертеп кыңгырау шалтырый. Ипатьев елъязмасындагы соңгы юлларга күз салам. "Идоше булгаре и убиша сына Изослава... острове Исады всего их пяти тысяша их лодьях. Болгаре те из городов, называемые Челмата, Собокуляне, Тямтюзе... "

Урыс яуларыннан соң да иркенләп тынычлыкта калырга язмаган икән. Күп гомерләр дә үтмәс, көньяк даланы инләп килгән монгол яулары болгар иленең үзәген, шәһәр, авылларын көл-күмергә калдырып китеп барыр. Аларның зәхмәтеннән, кабат Чулманның аръягындагы кара урманнарга ышыкланып Тәмте, Саба, Чаллы төбәкләре генә исән калыр. Бу якларның табигате кырыс. Җир-суы да артык уңдырышлы түгел. Шулай да җан тынычлыгына ни җитә соң? Сугыштан соң бу төбәкләргә күченеп килүчеләр арта. Калалар ныгый, зурая. Олы авыллар калага әверелә. Чаллы шәһәрендә дә тормыш кайный. Кремль тирәсе өченче саклану үре белән әйләндереп алына. Икенчесен биегәйтеп, беренчесенең бураларын күтәртеп, таш нигез түшиләр. Шәһәр тирәсендә тагын бер бистә барлыкка килә. Янындагы базарда дөньясының чиксезлеген белгертеп, чит ил сәүдәгәрләре кайнаша. Алар колак ишетмәгән ят телдә сөйләшеп, гомер күрмәгән мал сата. Алтын Урда дәүләтенең ныгып чәчәк аткан дәвере бу. Бик тиздән сәүдәгәрләр илләренә кайтып, тирәякның шәһәрләре, табигатенең гүзәллеге турында сөйләп, бар Аурупага хәбәр таратачак.

Безгә бу турыда Италиядә сакланган борынгы хариталар (1367) искәртә. Алар Венециядә яшәп дөнья гизгән абыйлы-энеле сәүдәгәр Пицциганилар тарафыннан эшләнгән. Без аларда Чаллы шәһәре белән бергә як-ягында бары 25-30 чакрымда гына урнашкан Кирмән белән Җукәтауны да күрәбез. Бу борынгы Чаллы төбәгенә караган соңгы тарихи табышлар түгел әле.

Туган төбәгебез, Чаллы шәһәре заманында бар Европага билгеле булса, бүгенге көндә алар безне белү түгел, Татарстан белән Казакъстанны да бутыйлар. Үткәндәге бөеклек дәрәҗәсенә менү өчен тагын күпме вакыт кирәк булыр безгә...

Әни белән барыр юлыбызның яртысы узылган инде. Кояшның кыздыруы соңгы ноктасына җиткән. Кунактан-кунакка йөреп, баллы әйберне күп ашаганлыктан карын су сорый. Уңайсызланып кына:

—Әни тагын кайсы өйгә керәбез, су эчәсем килә—дим.

Чаллы авылында ул башка кунакка кереп тормый. Урамда очраган апаларның бары да таныш аңа. Аздан да күнеле була торган әнинең йөзе елмаюлы:

—Улым, тиздән Хәлфә бабаңның чишмәсенә житәбез. Азрак сабыр ит. Изге чишмәдән су эчсәң шифасы да булыр—дип мине өметләндерә. Минем бу изге чишмә турында әнидән дә, туган абыйдан да күп тапкырлар ишеткәнем, үзләре белән алып килгән суны эчкәнем дә бар инде. Зур могжиза көткәндәй, эчәсе килүемне онытып, әни артыннан теркелдим.

Чаллыны чыккач сулга каерабыз. Хәлфә бабай чишмәсеннән эчкән су бар арыганны бетерә. Аннан зират кырына чүгәләп барлык мәетләр рухына дога кылабыз. Юлда әнинең Хәлфә бабай турында сөйләгәннәре онытылмас булып күңелемә сеңә...

*Хәлфә бабай.* Бу исем—халык күңелендә сакланган ихтирам билгесе. Без аның тулы исемен Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслиминең "Тәварихы Болгария" китабыннан күрәбез: "Чаллы авылыннан чыккан Идрис бине Зөлмөхәммәт".

Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, "Суфый Ишмөхәммәт үлгәннән соң (1589 еллар тирәсе) 20 еллап вакыт узгач, Идрис хәлфә Болгар, Тубылгы, Казан һәм Сембер җирләренә халык арасында дин гыйлеме таратырга җибәрелә". Шулай ук аның Уфа якларында да халыкка хезмәт итүе мәгълүм. Ләкин "Тәварихы Болгария" (Болгар тарихы) китабында еллар исәбенә бәйләп һәм дә мәсьәләнең Шиһабетдин Мәрҗани тарафыннан тикшерелүен искә алып, Хәлфә бабайның яшәү дәвере соңрак чорга—XVII гасыр урталары—XVIII гасыр башына, төгәлрәк килсәк, 1645-1710 елларга каравын фараз кылырга мөмкин. "Тәварихы Болгария" китабында бәян ителгәнчә, Идрис Зөлмөхәммәт улы Хафиз әүлия укымышлы, зур белемгә ия булган. Ул Яркандагы шәех Батулла мәдрәсәсендә тыңлаучы булып, 15 ел буе суфыйчылык кагыйдәләрен өйрәнгән. Бу мәдрәсәләрдә укучы мөридләргә дин дәресләре белән беррәттән дөньяви фәннәр дә укытылган. Урта Азиянең Мәшрәб, Аллаяр Суфый кебек танылган шагыйрьләре дә шушы чорда яшәгән. Хәлфә бабайның алар белән бер силсиләдә, суфыйлык һәм дәрвишлеккә бәйле туганлык һәм бердәмлек оешмасында торуы тарихта билгеле. Бу турыда мөдәррис, галим һәм язучы Таҗетдин Ялчыгол (1768-1838) үзенең дини-дидактик әсәре "Рисаләи газизә" китабында (1796 елда тәмам) сөйли: "Аллаяр (1630-1721) Бәйтуллага (кагъбә) зиярәт кылыр өчен Болгар йортына килеп, Казан каласында тукталып торган һәм ул замандагы Болгарның бер камил суфые Идрис Хафиз белән очрашып күрешкән."

Идрис хәлфәнең халыкка хезмәтен, аңа карата үскән ихтирамны, аның турында бәян ителгәннәрне күз алдына китерү һәм фикерләү өчен суфыйлык, дәрвишлекнең мәгънәсен аңларга кирәк. Суфыйчылык һәм дәрвишлек—ул ислам динендә булган үзенчәлекле агым. Аңа күндәмлек, тормыш авырлыгыннан һәм мәшәкатьләреннән читләшеп хыялый тормышта яшәү, ахирәт һәм киләчәкне күзаллау хас. Суфыйчылык 8-9 гасырларда түбән катламда торучы мөселманнарның хокукый һәм милек тигезсезлегенә, байларның комсызлыгына каршы булган хәрәкәт буларак барлыкка килә. Чиктән ашкан мохтаҗлык, авырлыклар гади халыкны уйланырга, бу хәлдән котылу юлларын эзләргә мәҗбүр итә.

Төрки халыклар арасында суфыйларның туганлык җепләре Хуҗа Баһаветдин Нәкышбәнди (1318-1389) исеме белән бәйле. Ул үзенең дәвамын "төрки" Әхмәт Ясәви (?-1166) мәктәбеннән алып аны тулыландыра. Нәкышбәнди тарикате (юнәлеше) XVI-XVII гасырларда Урта Азиядә, XYII-нче гасырлардан XX-нче гасырларның 30 елларына (Вәисевчеләр хәрәкәте) чаклы Идел буенда актив эшчәнлек алып бара. Ә Төркия аркылы XIX-нчы гасырда Кавказга үтеп кергән Нәкышбәнди тарикате Шамилгә урыс баскынчакларына каршы алып барылган сугышларда идеологик нигез буларак хезмәт итә. Бу тарикатнең төп өлеше буларак зикр әйтү (хәтер яңарту, Аллаһны искә алу) каралган. Бу

туганлыкка кергән бар суфыйлар да төрле юнәлештә хәрәкәт итәләр. Әмма алар Аллаһ, ислам юлыннан читләшми, аның канаты астында хөкүмәткә каршы ризасызлык күрсәтәләр. Сонрак феодализм дәверендә суфыйчылык шулай ук шәһәрдәге һөнәрчеләр, авыл жирендәге игенчеләр арасында милли һәм дини изүгә корылган тәртипләргә каршылык күрсәтүнең бер чагылышы буларак барлыкка килә. Шуңа күрә мондый агым бигрәк тә болгар-татар халкы өчен газаплы чор булган XVII-XVIII гасырлар чигендә халыкның теләгенә туры килә һәм кабул ителә.

Әлеге дәвердә Идел-Җаек буйларында элекке милли изүгә колониаль изү дә өстәлә. Бу авырлыклардан чыгу юлын эзләү дини һәм суфыйчылык карашларының кабат җанлануына китерә. Шул ук вакытта бу төбәктә халыкның түбән катламына ислам диненен тагын да тирәнрәк үтеп керүе күзәтелә. Православие руханиларының кешеләрне фикерләүдән тыйган бер заманда суфыйчылык асылда фәлсәфи фикерләүнең бердәнбер мөмкинчелек чарасы булып кала.

Суфыйларның тирән белеменә, фәлсәфи карашларына сокланып, авыруларны дәвалау мөмкинлекләрен күреп, халык аларны изгеләштерә. Дәрвишләр кырыс шартларда яшәп, үз көчләре белән көн күрәләр. Алар биргән хәер-садаканы да бары бер көнлек алып, "Аллаһ үзенең рәхмәтеннән аермас, яна көн туу белән ризыгын бирер", дип ышаналар. Дәрвишләр—дөнья ләззәтләреннән һәм байлыкларыннан ваз кичеп, тыелып яшәүчеләр. Без яшәгән бу фани кешелек дөньясы алар тарафыннан "Явызлык һәм гөнаһлар белән тулы җәмгыять" дип аңлатыла. Шуңа да ислам дине төрле мәхрүмлекләргә түзәргә чакыра, һәм бу зур батырлык буларак аңлатыла. Шунлыктан, ислам диненә чын күңелдән бирелгән Хәлфә бабай да халык тарафыннан Әүлия (Аллаһка якын торучы, аның арадашчысы, изге), "Аллаһ кодрәте белән могҗиза тудыручы" буларак кабул ителә.

Хәлфә бабайның халык телендә сакланып калган күп кенә әйтемнәре суфыйларга хас шигъри юлларны хәтерләтә. Аның тарафыннан күзалланган "бөтен кырларны тимер пәрәвәз оялары чорнап алыр, күктә тимер кошлар очса, җирдә тимер атлар йөрер"-дигән сүзләрен раслап бүгенге көндә Чаллы төбәген электр, телефон линияләре уратып алган. Күк-җирендә очкыч-машиналар хәрәкәт итә. Хәлфә бабайның әйтеп калдырган сүзләре буенча, имеш, ахыр заман алдыннан:—Биек-биек йортлар, йорт тулы җиһаз булыр, һәм дә шуның тынычлыгы булмас. Ахыр заман алдыннан хатын-кыз чәч белән уйнар, кырда чәчәк бетәр, ә хатын-кыз чәчәк кебек йөрер. Чаллы белән Котлы Бөкәш авыллары бергә кушылыр...

Юлыбыз каршыдагы Мәмле Казаклар Чаллысын читләтеп, болынга борыла. Әнинең авылына туры юл бу. Читтә калган авылда аның туганнары тагын да күп. Алар хәлен ул иркенләп кайту юлында беләчәк. Болын ягына әнине тизрәк барып җитәргә ымсындырган Чураш авылы тау башында бар матурлыгы белән күренеп тора. Әнинең генә түгел, үземнең дә туган, кендек каным тамган авыл икән бу. Барып җитеп чәй эчкәннән соң әни кулыма кучтәнәч тоттырып мине кендек әбием янына алып менеп: "Вәсби апа, кара әле бу егет таныш түгелме сина"—дип шаяртачак. Чурашка кунакка беренче килүем булса да, әбинең мине икенче күрүе икән инде. Мин бу авылда әнием кунакка килгәч туып кайтканмын. Вәсби әби мине Чурашка килгән саен кунакка менәрлек, беренче очрашу тойгыларын гомер буена искә калдырырлык итеп сөеп, сыйлап төшерәчәк. Ах! Белгән дә бит инде бу әбиләр халкы, бала күңелен ничек җәлеп итәргә.

Болынны чыгып җитәрәк әни кабат сукмактан сулга тайпыла. Хәлфә бабай турында ишеткәннәремнән айный алмаган килеш сүзсез генә артыннан иярәм. Кечерәк кенә тауны менгәч каршыда өч кабер ташы пәйдә була. Алар серле дога сүзләре белән сырланган. Аларны әни дә укый алмый. Ул мондый ташларның дөньсына бары изгелек эшләгәннәргә

генә куелганлыгын искәртә. Ташлардагы язуларның серлелеге мине озак еллар буе озата барачак әле...

Бу ташлар (1528-1532) Казан ханлыгы чорына карый. Алар Казаклар Чаллысын урталай бүлеп аккан изге чишмә суларының Мәшләк елгасына кушылган җиргә урнашкан. Борынгы чорда бу тирәдә Мәмле Чаллысы авылы, ә чишмә тирәсендә Чаллы ханнарының утары, җәйге биләмәләре булган. Югары катлам кешеләре үлгән очракта да гади халыктан аерым урынга җирләнгән. Әлеге кабер ташлары бу фикерне исбатлый.

Таштагы язмалар суфыйчылык әйтемнәре белән сугарылган. Аларның як-ягында шигъри юллар: "Күрәмен дөньяны үтеп баручан җимерелү хәлендә, шул килеш бер төрле тормас ул мәңгегә". Менә биш гасырга якын әлеге ташлар кешелек дөньясын: "Һәрбер җан иясе үлем ачысын татыр, аннан Безгә (Аллаһка) әйләнеп кайтыр"—дип кисәтеп тора. Пәйгамбәребез (Ана Аллаһның сәламе булсын) әйтеп калдырган сүзләрдә зур мәгънә ята: "Бу дөнья ул—бер сәгатьлек кенә, аны Аллага буйсынуда дога кылып үткәр". "Ошбу дөнья ахирәткә бара торган юлда бер иген кыры гына" дип уелган таштагы хәдис юллары да без яшәгән чорга аваздаш...

Әйе, тормыш югалтулардан тора. Дөньяга килү, кайда, ничек яшәп китү очраклыкка бәйле. Татар халкы аны язмыш дияр. Еллар-кичерешләр кабат балачактагы хатирәләргә ташлый. Авылда кайгылы хәбәр. Тракторчы абый үлгән. Хатыны—әнинең иптәш кызы. Әнигә ияреп кайгыларын уртаклашырга барабыз. Без килеп кергәндә дүрт урындыкта олыдан кече дүрт малай үксеп елый. Каршыларындагы караватта өстенә ак җәймә җәелгән килеш әтиләре ята. Әтиләренең үлеме, ир баланың иңнәренә авыр йөк булып төшеп, гомер буе озата барачак күренеш...

Кеше кайгысы кичкә чаклы. Күпме гомер узгандыр, үзебездән бер-бер артлы өч мәет чыкты. Бабай, әби. Әбинең кырыгын уздырганның икенче көнендә әни. Гомер буе искә төшкән саен, күңелләрне өшетеп, күз алдында кино кебек әйләнәчәк авыр тойгылар. Берьюлы өй дә, күңел дә бушап калды. Туганнан бирле аңларга теләгән дөньясына да караш үзгәрде.

Әмма югалтуларның башка төрләре дә була икән. Минем апалы-энеле ике бертуганның белә торып, исән килеш бер-берсенә карашып соңгы тапкыр саубуллашканнарын күргән булды. Ике карашта да чарасызлык, җиңелү, язмышка буйсыну. Күзләрендә яшь. Арадагыларының берсендә яше-картына карамастан килә торган әлеге төзәлмәслек чир, икенчесендә читкә кияүгә чыккан хатын-кыз язмышына уралган дөнья мәшәкате. Соңгы минутларны сурәтләргә сүзем җитми... Мин бу карашларга түзә алмый чыгып киттем.

Без—дөньясына вакытлыча гына килеп, күреп шул вакытта яшәүнең мәгънәсен эзләп, әмма таба алмыйча китәселәр. Һәр кешегә киләчәк үлем—дөньясының бердәнбер гаделлеге, бөек хакыйкате. Тик барын да акыл белән кабул иткәч, яшәүнең тәме бетеп, гайрәт чигә шул.

Барган бер җиремдә мөмкинчелек туугa шул авылның зиратын барып карарга тырышам. Халыкның бар рухи байлыгы шунда тупланган сыман. Төгәл хаклык зиратта диючеләрне аз гына төзәтеп узасым килә. Җирнең өске ягында да шул ук хаксызлык гомер сөрә әле. Аскы ягынданиләр булып ятадыр, анысын белмим, барганнарының кайтып сөйләгәне юк. Каберләргә куелган чардуган, ташлар төрлечә. Хәзер авыл зиратларында да татар түрәләре, эшмәкәрләренә куелган кызыл, кара, күксел һәм ак мәрмәрдән эшләнгән кабер ташлары еш очрый. Аларда борынгы кабер ташларындагы фәлсәфи сүзләрне күрмәссен. Ә кирәк иде. Һич югында: "Ул үзе өчен генә яшәде", "Монда үз гомерендә фәлән сум акча җыя алган эшмәкәр ята", яисә "Бу мәрхүм үзе белән тиенен дә алып китә алмады"—дип язарга иде. Бу сүзләр үзләрен "мәңгегә" килгән кебек хис итүчеләргә тәэсир итми калмас.

Казанның татар зиратындагы ташларны укыганда милләт күгендәге

күренекле кешеләр искә төшеп, күнел алар хөрмәтенә дога сүзләрен кабатлый. Халык күнеленә яхшылык белән керер өчен әллә ни күп байлык кирәкми дә югыйсә. Авыллар зиратында йөргәндә андагы меңнәрчә сумнарга төшереп ясатылган ташка караганда, без исәннәргә, гади ташка:— "Бу ходай бәндәсе авылда мәчет төзеде", "Авыл чишмәсен төзәтте", яисә "Авыл тарихын бастыруда ярдәм итте"—дип язылганнары күпкә кадерлерәк. Бу яхшылыкларны эшләр өчен әлеге мәрмәр ташларнын ярты бәясе дә житәр иде...

*Без дә мәктәптә укыдык...* Беренче сыйныфка кергәндә утыз өч бала идек. Анда да, туган көнем беренче сентябрьгә туры килгәнлектәнме, әни сораганга каршы килмичә, авырыксынып кына алдылар үземне. Чөнки укучынын бергә артык булуы, болай да артыгы белән тыгыз бүлмәгә тагын бер парта кертеп урнаштыру белән бәйле иде. Әмма әнинен: "Бераз йөргәч туеп китәр әле, бар иптәшләре дә баргач бик күнелсезләнә бит"—дигәне дә һәм шуна ышанып каршы килмәүче, беренче укытучым Сания апамның өметләре дә тормышка ашырга бер елдан сон гына язган икән. Чөнки икенче елны мәктәпкә килгәндә бүлмәбез иркенәеп киткән, парталар саны да бергә кимегән иде. Бу вакыйга мәктәп өчен генә түгел, авыл өчен дә зур яналык булды. Монын сәбәбе, әти-әниләренең гади эшчеләр булуына да карамастан, бергә уйнап үскән күрше малаенын авылдан ерак булмаган урыс мәктәбенә кабат беренче сыйныфка күчүендә иде.

Әлеге хәлдән сон, бу билгесез яналыкка юл ярган Рафиска игътибар артты. Хәер, үзе дә үзгәрде ул. Уеннарга катнашмый, көне-төне дәрес өстендә утыра торган булды. Укудан да без уйнап туйганда гына кайтып житә иде. Бер тапкыр үзен көлемсерәп озатып калгач, ә сез өйнен урысча ничек булганын беләсезме сон дип сораганы хәтердә калган. Аны гына белмәскә: "Дум" дип жавап бирдек без бердәм. Ә юк шул белмәдегез "Ызба" диде ул борылып та тормастан. Безнен урысчабыз тагын бер сүзгә артты.

Рафис акрынлап бездән читләшә, сөйләшкәндә дә без анлап бетермәгән сүзләр кыстыруы белән гажәпләндерә иде. Уенчыларны бүлүдән башлаган санамышлары да урысча булганлыктан, уенга хәрәм кертә дип үзебез дә аны санатмый башладык. Күрше урыс авылыннан адашып килеп кергән дунгызларга утырып йөрү уеннарында да катнашмый башлады ул. Күрмәгән нәрсә түгел янәсе. Шулай да жәйге каникулларда үзгәреп, кабат тулысынча безнен калыпка кереп бетә иде.

Тагын бер ел узып китте. Икенче елда ул инде ялгыз түгел иде. Әлеге урыс авылында эшләүчеләрнен дә кайберләре, үзләренең балаларын урысчага укырга күчерделәр. Акрынлап урысча уку модага әйләнде.

Дүртенче сыйныфта уку бүлмәбез тагын да иркенәеп китте. Бу елны сыйныфта иң яхшы укучы тагын ике күрше малаебыз урысча укуга күчкән. Иптәш малайларга ияреп төшәргә үземнен дә теләгем зур иде, ләкин әниемнен рөхсәте булмады. Фәлсәфәсе бер,—без анлап житкермәгән урыс калыбына күчмә әле. Без урысча укымадык, алардан ким яшәмибез. Киез итек басканда кулланган агач калыптан башканы белмәүче безләргә моны анлау сәер иде. Әмма бу юлы да, әни дигәнчә булырга язмаган икән. Бер атна укып, икенчесенә күчкәндә мәктәбебез директоры керәшен Иван Федорович мине—Син яхшы укыйсын, "монда әрәм булып йөрмә"—дип, атына утыртып Шомбыт мәктәбенә укырга алып төшеп китте. Безнен өчен авылда мәктәп директорыннан да зур кеше булмаганлыктан, әнинен рөхсәт итмәве дә онытылган. Директор хәтле директор белән янәшә утырып, урыс мәктәбенә таба билгесезлеккә атлау үзе бер олуг мажара иде. Әмма мәктәпкә төшкәч директор артыннан озак тагылып йөрергә насыйп булмаган икән. Бер-ике кеше белән нидер сөйләшеп анлашкач, мине бер сыйныф бүлмәсенә кертеп утырттылар. Бәхетемә каршы, бу ят билгесезлектә мина озак башымны иеп як-ягыма карарга куркып утырырга туры килмәде. Дәрес бетәргә

ун-унбиш минутлап кына вакыт калган булган икән.

Татар мәктәбенә китеп, урыс мәктәбеннән әйләнеп кайтканчы әнигә дә бу хәбәр ирешеп, аның да ризалыгы алынган иде. Һәрхәлдә, мина ул ябык чырай күрсәтмәде.

Алдагы көндә утырган урын, үз урыным булып чыкмады. Сыйныфтагы укучылар саны парсыз булганлыктан, мине кабат яңа партага бер ялгызымны утырттылар. Аның каравы алдымда утыручылар өч ел бергә укыган иптәш малайларым иде. Яңа жирдә укуның бары бер уңайлыгы булды. Өч ай буена безнең янга килеп тә карамадылар, дәрестә сорамадылар диярлек. Бары математикадан гына өйгә тикшерүне бездән башлыйлар иде. Хәер ул математиканы белү өчен урыс телен белү кирәкми дә икән ләбаса! Беренче көннән үк беренчелекне кулга алып, мәктәпне бетергәнчегә чаклы чикләвек урынына ваттык без аны. Шунлыктан урыс балалары, балга жыелган чебен кебек, иртә таңнан безне көтеп ала торган булып киттеләр. Үзебез дә югалып калмадык. Алар математикадан кучергәндә, урыс теленнән бирелгән язмаларның жөмлә-сүзләрен урыннарыннан алыштыра-алыштыра дәфтәргә күчерә идек. “Нам, татарам и так пойдет” дигән фәлсәфәдән чыгып карау ярады. Урыс теле укытучысы бездән разый калып, “Икенче юлы болай итегез” дип нәрсәдер аңлатырга тырышканы хәтердә калган.

Шулай итеп беренче чирек тә узып китте. Көндәлектә ник бер дүртле булсын, математика, хезмәт, рәсем һәм физкультура ишеләре биш, ә калганнары өч. Хәер, бу билгеләрнең уртаклыгы безне әле мәктәпнең соңгы елларына чаклы озата киләчәк.

1971 нче елның көзе. Каникулдан соң килгән атнаның беренче ял көнендә үк мәктәп, янып, көлгә калды. Ох ул шатланулар! Яңа мәктәпне төзеп бетергәнче укымыйбыз икән,–дип бер беребез белән хәбәрләшеп сөенешүләр. Әмма заманнары нинди иде соң? Икенче көнне үк барыбер укымыйбыз дигән фәлсәфә белән бары мәктәпнең көл-күмерен генә карап менәргә дип без сумкасыз төшүчеләрне күнелсез хәбәр көткән икән. Мәктәп урынына элекке авыл советы бинасы бер төн эчендә үк уку бүлмәсе хәленә китерелгән һәм ул житмәсә без гел курку белән караган чиркәүнең төбенә үк урнашкан иде. Мәктәп яну шатлыгы безгә үзенең тагын бер уңайсызлыгын алып килде. Яныбыздагы үз, татар мәктәбенең кадерен белмичә күрше авылга бер сәгать алдан чыгып киту өстенә тагын ярты сәгать вакыт кушылды.

Дөрес, ул ярты сәгать вакытны барыбер артыгы белән чыгардык без. Урыс авылын аркылы чыгу безнең өчен бер зур батырлык сораган вакыт. Шунлыктан барыбыз бергә жыелып беткәч кенә анда төшеп, иң ашыгып йөргән урыныбыз да шул чиркәү тавы тирәсе генә булды. Шуңа күрә сулышка кабып керелгәч ике-өч дәрес узылса да укытучылар хәлгә керәләр иде.

Акрынлап ипи-тозлык сүзләр аңлап декабрь дә килеп житте. Бездән дә “да”, “нет”, “здрачте” кебегерәк сүзләр чыга башлады. Дөрес, тагын да батыраеп китеп авыз да ачылган иде. Әмма ул бүгенгә кадәр мәзәк урынына сөйләргә калган хәл белән тәмамланды. Уку бүлмәсеннән чыгып килгәндә кайсыныңдыр кесәсеннән төшеп калган бияләенә тап булдым. Яхшылык эшләргә теләп, бияләйне күтәрдем дә, “чья рубашка потерял” дип коридорга оран салдым. “Рукавица” белән “рубашканы” бутаганмын икән. Яртысы басып көлсә, көлә алмаганнары егылып калды. Мин дә ярыйсы гына сабак алдым. Моннан ары башыгыз тәгәрәп ятса да дәшми узып китәрмен!

Әмма дөнья гел без дигәнчә бармый шул. Бер айлап та үтмәде, тагын күнелгә тигән хәл булды. Шомбыт кибетләрен урап йөреп, кабат чиркәү тавын йөгереп менеп соңга калган көннәрнең берендә, укытучының түземлеге бетте:

–Зачем сюда пришел–дип кат-кат сорап бәйләнде. Шунда түзмәдем, бар урысча белгәнемне эшкә жигеп:

–Иван Пидероч привез–дидем.

Укучы балаларның көлүе, укытучы апамның кызаруы хәлне җиңеләйтте. Әмма күрше малайлары белән шул көнне үк бер мәзәк булып авылга менгән иде бу хәл. Ә бит бары бер сүз "учится" дип кенә әйтәсе калган.

Бер ел эчендә мәктәпне янадан төзеп, кайту юлы кабат якынайды. Ләкин алда яңа унайсызлыклар көткән икән. Бишенче сыйныф башында тарихтан татар-монгол явы турында үтә башладык. Тарихтан укыткан маржа апа артыгын тырышканмы, китабында шулай язылган булгандырмы, әмма бу дәресләрдән соң урыс малайларының безгә булган карашы үзгәрде. Мәктәптән икенче сменадан кайтканда алар безнең каршыга чыгып мыскыллап озата торган булып калдылар. Көннәрнең берендә аларның берсе кулын да уйнатып алды. Бер-ике тапкыр түзеп торып та, каршы алулар дәвамлы булгач, без дә бер нәтиҗәгә киллек. Ял көнне тимерчедә җыелып көне буе пычак ясадык. Безгә ярдәмгә авыл аша йөрүче Чаллыбаш авылы малайлары да кушылды. Бу эшләрнең башында торган, арабыздагы иң шугы Илфатның пычагы сумкасына яткырып та сыймас булды. Икенче көнне каршыга кабат Рязәнь урамы малайлары чыккач, пычагын да беренче чыгарып, каршыларына ул басты. Өч-дүрт адымнар артта, кесәдәге пычакларның сабын учлап без торабыз. Үзебез елар хәлгә житсәк тә, ни белән бетәр дип көтәбез. Артка чигенү юк, кем кача, шуны үзебез тотып кыйнаячагыбыз турында сүз беркетеп куелган. Биш минутлар чамасы сүзсез, бер-беребезгә карашып торгач, урыс малайлары һаман да без әлегәчә аңлап җиткермәгән телдә нидер сөйләшеп, кире борылып кайтып киттеләр. Алар китеп күздән югалгач, әле иртәгә дә кирәк булыр дип без дә, пычакларны юл читендәге агач төбенә күмеп, авылга юнәлдек. Акылда иртәге өчен азрак курку булса да, күңелдә җиңү шатлыгы иде. Әмма пычакларның башка кирәге чыкмады. Икенче көнне бу турыда бөтен мәктәп шау килеп, бездән көлсәләр дә, бу очракның җиңүчеләре без, ә үзебез арасында чын батыры Илфат иде. Кушаматы "ипи" булса да, эшләгәне ипи бәһәсеннән ким булмады аның. Башка безнең юлга каршы чыкмадылар. Дөрес, бу турыда беренче сменада укучы бездән олырак малайлар да белеп алып, шул көнне үк Рязәнь урамы малайларының койрыкларын кысканнар иде. Тагын бер-ике елдан Шомбыт мәктәбе яртылаш тирә-як авыллардан килгән татар балалары белән тулды. Үзебез дә бердәм булып, артык масайганнарына каршы бергә-бер чыга торган булдык. Шомбыт малайлары өчен бу куркуның иң зурысы иде....

Мин әлеге хәлләрне бу чорлардан егерме биш еллап вакыт узгач искә төшереп утырам. Авылда татарча, Шомбытка төшеп урысча укыганнарның язмышын барлап, чагыштырып карыйм. Бүгенге көнгәчә булып узган үзгәрешләр гәҗәпләндерә. Урыс мәктәбенә татар балаларының иң яхшы укыганнарын гына сайлап төшергәннәр. Шунлыктан анда укучыларның барысы да югары техник уку йортларын бетерделәр. Әлеге очрак урыс мәктәбенең абруен күтәрү өчен эшләнгән. Ә авыл мәктәбендә укырга калганнар барысы да диярлек авыл хуҗалыгында, яисә завод-фабрикаларда эшли. Бу мәктәптән татар халкының тарихына, теленә һәм мәдәниятенә хезмәт итәрлек ник бер хезмәткәр чыксын. Без барыбыз да татар тамырын бетерүгә юл торткан сәясәтнең корбаннары булганбыз икән.

Ә беренче сыйныфка утыз өч укучы бирә алган Яна Сала авылының мәктәбе беткәнгә дә унбиш еллап вакыт узган инде. Бүгенге көндә аның урынын, ялгыз үсеп утырган каен агачлары белән Ленин һәйкәле урынында калган ком аралаш кирпеч калдыклары гына искәртә.

Шомбыт мәктәбе бүгенгәчә эшли. Хәзер анда укучы урыс балаларын бармак белән генә санарлык. Тәнәфес вакытында йөргәндә дә урыс теле сирәк ишетелә, гәрчә укытулары һаман урыс телендә генә булса да. Сәясәт җилләренең үзгәрүенә дә карамастан, тирә-як авыллардагы татар балаларын урыслаштыру өчен көйләнгән бу "җил тегермәне" бүген дә

элекке унаена әйләнә әле. Анда һаман урыс көенә татар телен тарталар...

Һәрчак хәрәкәттәге тарих тәгәрмәче төпкеленнән акрын гына татар кояшы да чыга сыман. Тик аның беренче нурлары гына кайчан күренер...

*Укытучыларыбыз.* Алар турында да җылы сүземне әйтәсем килә. Укытучыларыбыз кешелекле, үз эшләренә җаны-тәне белән бирелгән кешеләр иде. Дөрес үткән белән бүгенгене чагыштырып, аларның нинди кысаларда эшләгәннәрен аңлап була. Шулай да алар булган бар җан җылысын безгә бирергә тырышты. Ә башкасы сәясәт белән уралган иде.

Завод эшчесе үз эш урынында иртәнге сигездән кичке бишкә чаклы бикләнеп торса, укытучының тозагы тәүлек буена сузылыр. Яшәү, эшләү шарты да бар дөньясының күзәтүе астында. Нәтиҗәсе сугыш чорындагы кебек: дәрес планыннан уңга, сулга бер адым китү—үлем белән бер. Хаталансаң, гайбәтеңне җыелыш саен, авыл буе сатарлар. Мин аларның сабырлыгына сокланам, шул түземлекләре аша килгән хөрмәткә шатланам.

Элек укытучылыкка очраклы кеше килмәгән, килсә дә, эшли алмагандыр. Алар арасында нинди генә укымышлы, талантлы кешеләр юк иде. Андыйлары партия, комсомол эшенә тартылып, талантларына үсәргә мөмкинчелек бирелмәде. Күбесе шул җыелышлардан соң уздырылган банкетларда эчүгә сабышып юкка чыктылар. Укытучы халкының күңеле нечкә шул. Үзе кебек эчкерсез бала күңеленнән аерсаң, озак яши алмый.

Без хыялыйлар илендә яшәдек. Укытучыларыбыз безне шул хыял дингезендә йөзәргә өйрәтте. Яхшы теләктән алар безне наданнар дип әрли-әрли надан калдырдылар. Безнең өметле киләчәк—гадел тормыш тудырырга тиешле коммунизм белән бәйле иде. Шунлыктан, кырыс тормышлардан чыгу юлларын күрсәтмичә, авыр шартларда үз-үзебезне якларга өйрәтмәделәр. Бүгенге түрәләрне милиция, закон яклый. Безнең яшәү, өмет-шатлыгы кабат сугыш чорыннан соң әниләр кебек: "Аллага шөкер базымда бәрәңгем бар" дип шатлануга кайтып кала. Оныкларыбызга яхшы тормыш килер дигән әби-бабаларыбыз хыялы кабат мираж кебек ике-өч буын алга күчә. Бүгенге көндә үзебез шул өмет белән яшибез.

Шунысы кызык. Кемнәр генә булырга өндәмәде безне укытучыларыбыз. Үз һөнәрләрен генә тәкъдим итмәделәр. Сәбәбе, укучыларының киләчәктә үзләре кебек кол хәленә төшүләрен теләмәүдән дип уйлыйм. Бу фикергә үземнең дистә елдан артык мәктәп системасында эшләвем этәрә.

Без үскән саен дөнья үзгәрде. Олылар сүзе белән әйткәндә, бозылды ул. Ат арбасы гына сыярлык урам-тыкрыкларны башта МТЗ, ДТ-75 тракторлары тавышы күмсә, соңрак аларга авыл өйләреннән дә биегрәк Т-150, К-700 үкереп керде. Авылны урыс зиратына охшатып тәре баганалы радио, телевизор антенналары басып китте. Аларның саны арткан саен, авыл тынлыкка күмелеп, капка төбенә чыгып аралашкан, дөнья, туган-тумача, авылдашларының хәлләрен уртаклашкан утыргычлар бушап калды. Гасырлар буена катып калган татар авылы күзгә күренеп үзгәрде. Уенҗырлы кичәләрдәге дәртле бию көйләрен, моңлы вальсларны барабан тавышлары, экзотик хәрәкәтләр алыштырды.

Дөнья авылны бозды, соңрак без—дөньясын. Кинлеге яртышар метрга җиткән клёш балаклар белән анда тезелгән урыс акчаларын чыңлатып яшьләр дөньясының бар пычрагын себерде. Күп тә үтмәс, авыл кагыйдәләренә буйсынырга теләмәгән яшьләр, туган авылларының киләчәген өметсезлеккә ташлап, шәһәргә үк китеп барырлар.

Безне авылдан элекке заманнардагы кебек көчләп сөрмәделәр. Авылдан ник киттек соң? Кешечә яшисе килгәнгә. Җаны, рухы тапталганнарны күреп, шул халәттә калмас өчен!

Көзнең бер көнендә әни эштән соң гына, борчулы кайтты да, берара озак кына урындыкта башын иеп утырды. Әнине мондый халәттә

беренче күргәнгә, без, балалар, шым булдык. Бераз вакыт узгач анын почмакка кереп: "Юктыр син Ходам, булсан безне шул чаклы авыр сынауларга ташламас, аз гына булса да җинеллек биреп, дөньясына хаклык индерер иден" дип такмаклап үкси-үкси җылаганын хәтерлим. Азрак тынычлангач, тәүбәгә килеп тәһарәтен алды. Көндәгенә караганда намазын да күбрәк укыды, сәҗдәсендә дә озагырак торды кебек тоелды мина. Намаздан сон үзлегенә кайтты. Әйтерсең лә дөньясына, авыл халкын коллыкта тоткан бар түрәләренә күнелендә бер генә үпкә-ачуы да калмаган иде. Кич белән башка хатыннар кебек чөгендер басуыннан маллар өчен җыйган чүп үләнен дә барып алмады. Ә икенче көнне башланган янгырлар нәтиҗәсендә үләне генә түгел, бөтен кыры белән калды ул чөгендер. Шул ук көзне үз эшчеләреннән басуынын чүп үләнен дә күпсенгән колхоз управы Гәверләне (Гаврилов) эшеннән алдылар. Беркатлы халык чөгендер өчен икән дип үзара пышын-пышын сөйләшсә, сонрак анын колхоз кассасыннан халыкнын анына да сыя алмаган чаклы акча урлавы билгеле булды.

Бу чорда авылнын ярты малай-шалае "Үскәч кем буласың?"— дигәнгә "Гәверлә булам" дия иде. Гәверлә булу, машинада гына йөрү, бушка ашау, кабина ишеген ачып кемгә генә аты-юлы белән кычкырсан да хаклы булу иде. Авылны зар елаткан Гәверләләр ана чаклы да булган, аннан сон да булдылар. Гәверләләрне яратмаучы буын без. Сүзем юк, нәчәлстванын да төрлесе бардыр. Әмма бүгенге акылым белән әйтә алам: Алар арасында кеше хакына кермичә яшәгәне булмый!

Кеше хакына керү гөнаһнын ин зурысы. Әни бу сүзне еш кабатлаганга, безнен анга ул дога урынына сенде. Кеше хакы. Кеше хакы белән төзелгән колхоз-совхозлар, башка халыклар хисабына төзелгән Рәсәй дәүләте. Алар шуна кешелексез, хәерче. Киләчәкләре дә өметсез аларнын. Кеше хакы үзенне тотмаса, нәселенә кереп, анын каргышы оныкларына төшәчәк. Кеше хакы өчен генә борчылып йөрү түгел, үз хакымны да даулау әле бу.

Менә шуңа күрә киттек без авылдан. Әлегәчә шуна кайтмыйбыз да.

Һәр ир бала үз мин-минлеге белән туа. Аларнын елау, киреләнүләре дә үзенчә. Үсә төшкәч, ул мин-минлек төрле кызыксынуларга әйләнә. Тамчы тама-тама ташны тишә дигәндәй, тырыш авыл баласына шул сәләтенә бәйле үҗәтлеген үстерергә аз гына җай бирсән дә, кемнәр генә чыкмас иде бездән. Юк шул. Бер яктан авыл үз тәрбиясенен тыйнаклыгы, икенче яктан дөньянын кая барганын билгеләгән вакыты, карангылык пәрдәсе белән капланган. Дөрес, аны ертып, шәһәргә китүчеләре дә булды. Тик бу югары белем алучы асыл егетләрдән татар кебек йөзләгән милләтләрнең киләчәген буып торучы КГБ, МВД, урыс армиясе көчен арттыручы роботлар ясадылар. Мәскәү тирәсендәге фәнни шәһәрчекләрдә эшләп, яңа корал уйлап табучы, галәм кинлекләрен яуларга өлеш кертүчеләр дә чыкты безнең арадан. Белегез, бүгенгәчә җир тирәли әйләнүче космик кораблар татар белеменә таянып оча. Шул җайланмалар ярдәмендә татар акылын таркатып, урыс телендә дистәләрчә радиотелеканаллар эшли. Алар киләчәктә дә татар халкынын Рәсәйдән башка яши алмаслык итеп милли анын суыралар. Егетләрнең үз язмышлары да халкынныкы белән аваздаш. Чит җирләрдә ят яр табып, аларнын нәселләре үзләре ясаган ачышлары—атом төшеннән дә тизрәк таркалды.

Авылда калганнарынын мин-минлеге трактор, машина буйсындырудан ары китмәде. Алар эшләп тапкан мал белән күпме гасыр инде ярты Рәсәй халкы җан асрый. Безнен мин-минлек кеше атына утырып шунын җырын көйләүгә кайтып калды шул. Эх! Үз арбаң булмагач, ни хәл итмәк кирәк сон?

*Армия.* Без дә булдык анда. Күрмәгәннен күрәсе килә, ди бит. Бүгенге акылым әлек булса ике аягымнын берсен дә атламаган булыр

идем дә. Ә ул чакта горурлык иде ул. Авыл кызлары да солдаттан кайтканнарга гына карый. Җырларын да: "Әллә каян күренеп тора, солдатта булган диләр" дип сузалар. Тәрбияли белгәннәр дә инде! Кая бару, кемгә хезмәт итү, кем дәүләтен яклау ул турыда уйланулар юк. Һаман шул гомер бетмәс күрше хакын хаклап йөрү инде.

Без әле, ярый, унсигез яшь тулуга китеп бардык. Аңынчы Казан тулай торакларында әниләрсез бер ел иркенлектә яшәп, мендәр атышып уйнап калдык. Шуңа аерылышуның әлләни авырлыгы да тоелмады. Ә дөнья күрми, жылы өйдән китүчеләр күпме булды? Сыкрангандыр җаннар. Безнең белән комисия үтеп йөргән 25-26 яшьлек абыйларны күрсәгез иде әле сез. Армиягә дә бара алмый, өйләнә дә алмый. Аларга күпкә авыррак. Бүгенге көндә сыер сатып, армиядән котылып калучылар белән чагыштырганда, бәлкем, кеше ышанмаслык та булып тоелыр. Әмма безнең белән йөрүче ике абыйның берсе армиягә барыр өчен комиссиядә утыручы майорга биш кило бал, икенчесе каклаган каз алып килгән иде.

Армиягә безне Казаннан алып киттеләр. Авылдан китүчеләр белән чагыштырганда тагын бер унайлык, комиссия үткәрмичә кире борып кайтармыйлар. Күпме авыл егетләре шуның аркасында унайсызлык кичерде. Ике елга, "йә кайтырмын, йә кайтмамын" дип бер жырлап, бер елап бар туганнарың, авылдашларың белән саубуллашканнан соң ике көннән кайтып кер әле. Кабат очрашканда оятыңнан кая барып керер тишек тапмассың. Безгә көлке, барын да шаяруга борабыз. Аналар күңеле ниләр генә кичермәгәндер? Һәр ата-ананың үз баласын армиягә кеше рәтендә, зурлап озатасы килә. Армиягә китү туйлар уздырудан ким булмаган заманнар. Өстәлләр аракыдан сыгылып тора. Табын тирәсендә әле 18 яшь тә тулмаган авыл яшьләре: кызлары да, егетләре дә. Һәр яхшы теләк өчен берне кабып куярга кирәк. Кем авылдашының исән кайтуын теләмәсен инде? Әнә шулай акрынлап авыл яшьләрен эчәргә өйрәттеләр. Ә бер тәмен татып карагач, теләк кабат уяна бит ул... Икенче көнендә инде буш шешәләр клуб артында тәгәрәп калдылар.

Егерменче гасырның кояшы баткан дәвердә халыклар акрын гына уяна. Рәсәй үлемен якынайтып, без–татарлар да уйланабыз. Бүгенге көндә яшьләрнең булдыклыгы армиядән котылып калуы белән үлчәнә. Шулай да Рәсәй армиясе һаман халыкларны коллыкта тоту өчен җан тартыша әле. Бүгенге заман империяләре озаграк яшәп, акрынрак таркала. Ни эшләмәк кирәк, фән-техника заманы шул.

*Авыл көтүе.* Авылның бер күрсәткече. Мал-туарның баш санына карап авылның хәл-әхвәлләре, киләчәктәге язмышы турында да күп нәрсәләр сөйләп булыр иде. Көтү көткәндә башта әллә нинди уй-фикерләр туа. Мәсәлән, нигә аны мал-туарны ашату, саклау түгел, ә көтү дигәннәр. Бәләкәй чакта без аны өйгә кайту вакытын көтү белән бәйли идек. Инде менә үсеп житкәч көтү сүзенә бәйле үзебез дә дөнья көтәбез...

Кояш әле күтәрелә генә. Иртәнге салкын. Ыштан балаклары чыкка манчылып юешләнгән инде. Кояшы да иренеп кенә чыга. Бик озак күтәреләчәк әле ул. Ә батканчы гомер узып китәрдәй булыр. Вакыт уздырырга яраган чыбыркысы да, юешләнгәч шартламый бит аның. Мукшы болынын инләп авылның үзенә якынлашабыз. Унлап ялгыз калган йорт арасындагы бер мунчадан төтен күтәрелә. Бар авылга хуҗа булып, җәен Мәскәү хәтле жирдән кайтып яшәүче "Палкауник" кушаматы алган урыс картының йорты ул. Пенсиягә чыгып, гомеренең соңгы көннәрен туган җирендә көтүе. Соңгы могикан.

Мукшы Чаллысы атамасындагы бу авыл 1724 елда үзендә яшәгән 41 ир кешесе белән искә алына. Элекке татар авылы. 1780 еллар азагында бу унайлы урыннарга урыслар килеп урнашкач, татарларның бер өлеше акрынлап Яңа Салага күченә, соңрак икенче өлеше 1914 елда Яңа авылга нигез салалар. Татар тамырын искәртеп, урыс авылына терәлеп торган зиратка бүгенгәчә үлгәннәрне жирлиләр. Хан заманнан ук билгеле Лаеш кичүе, Уракчы, Чаллы башы авыллары аша борынгы Чаллыга үткән юл

өстенә утырган бу авыл.

Урыслар яшәгән заманда авылга якынлашу түгел, бер башы белән үз авылыбызга терәлеп торган болынына да аяк басарга ярамаган. Хәзер исә авыл эчендә көтү йөри. Туган нигезләреннән тирә-ягын тетрәтеп торган Ягүр карт, Әләксә дәдәйләр чыгар кебек. Тик вакыт кешегә буйсынмый шул. Алары гына түгел, күпкә зуррак Түләге дә бетеп, заманында өч йөз йорты булган Шомбыты да ярым татарлашкан инде.

Көтү көткән җирләрдән көне буе зират һәм ана орынып торган үле авылның унлап ярым җимерек йорты күренеп торыр. Без калкулыктан калкулыкка күчәбез. Үзәнлектәге сыер, сарык көтүендә үзебез көтүче булсак, дөньясында үзебез дә шул халәттә. Дөнья катлы-катлы бит ул. Безгә карап безнен көтүчеләребез ни уйлый икән. Хәер, алар да шул ук язмыш буйсынуындадыр. Мал-туар да төрле-төрле. Төскә дә, холыкка да. Нәкъ үзебез, Рәсәй халкы инде. Берәүләре мыштым гына чемченеп йөрсә, икенчеләре гел уҗым ягына каерыр. Кичен берәүләре тамагы туйганнан әвеш-тәвеш килеп кайтса, икенчеләре көне буе ашап та тамаклары туймаганга җир акырыр.

Фани дөнья—көтү. Мәңгелеге зиратта. Бер караганда яшәүнен мәгънәсе бик гади дә кебек. Дөньясына кеше буларак сыналырга килгәч, абзарындагы сарык яисә күрше халкында яшәүче дуңгыз дәрәҗәсенә төшеп китмисе иде. Яшәү мәгънәсе—кеше хакына кагылмыйча, үз хакынны гына хаклап, кешечә китү түгелме икән?

Шулай да хаклымын дип акыл өйрәтергә тырышуым түгел. Дөньясын аңлар, танып белер өчен зур дәрәҗәле уку йортлары бетереп, көн-төн китапханәләрдә генә казынып яту аз. Ара-тирә шифаханәләрдә йөреп, авыр хәлдәге кешеләрнең хәлен белешергә, зиратларга барып кабер тынлыгына колак салырга кирәк. Базар, вокзал хәерчеләрен күзәтеп, май баскан түрәләрнең үзара сөйләшүләренә игътибарны юнәлтү дә аңбелем өстәми калмас.

*Безнең университетлар.* Һәркем үз университетын бетерә дигәндәй без дә укыдык анда. Элек бердәнбер иде ул. Ленин исемендәгесе һәм физмат факультеты. Керү өчен дә борчылыр урын юк. Бердәнбер фәлсәфә, "Без кешедән кимме әллә?". Физика, математикадан нәрсә сорасалар да җавап әзер. Беренче имтиханны бишкә бирергә өмет зур, икесеннән кимендә тугыз бал җыярга була. Калганы өчен борчыласы юк—кулда бишле билгеләре белән генә чуарланган аттестат. Ул елларда югары уку йортына керергә өмет иткән, урысчасы такыр татар баласының бердәнбер ышанычы. Мондый аттестатсыз булсаң, урыс теленнән сочинение язасы бар. Безгәме инде ул, андый киртәләрне уза алу?

Булдыра алмасак мактанмыйбыз да аны! Беренче имтихан физикадан. Биш! Алдан ук белеп торам, мин инде студент. Дөрес, күңелдә әлләни шатлык юк. Күңеленне алдан ышандырып куйгач шулай була икән ул. Университетның текә баскычларында тезелеп баскан тәкәббер карашлы шәһәр яшьләре алдыннан горур гына атлап беренче катка төшәм. Күбесен соңгы тапкыр күрәм, чөнки бер урынга өч кеше. Монда шундый закон "йә—син, йә—сине". Казан бит бу. Монда, авылдагы кебек, күрше күләннәргә дә, якын туган-тумача, җан дусларга да таянып булмый. Шул, акчаң күп булса гына инде.

Беренче сентябрь дә килеп житте. Кәеф яхшы: бәйрәм өстенә бәйрәм. Бүген туган көнем, университетка укырга барам. Тирә-ягымда кояштай балкып минем кебекләр йөренә. Бер ишләре инде җинелчә генә танышып, төрле төркемнәргә дә бүленеп өлгергәннәр. Бер почмакта үзләренә игътибар җәлеп итеп, кызлар чыркылдаша. Күп тә узмады, әлеге күренешкә буталчык кертеп, нәрсәдер шыгырдап алды. Лекциягә керергә чакыручы кыңгырау тавышы икән. Беренче дәрес. Минә музыка уйнар кебек. Кереп тулдык. Астан өскә таба өстәлләр тезелеп киткән. Бер ише алгы урыннарда калса, күбесе арткы рәтләргә, биеккәрәк омтылды.

Менә бер заман укытучы чыгып, тактага нидер яза да башлады. Ә

тавыш тынмый. Барысы да ниндидер тантана, үзләренең шушындый зур уку йортына керүләре белән котлауларын көтә... Әмма котлау сүзе озак көттермәде, укытучының: "Күләгәдә урын алдыгызмы, хәзер инде шуның өчен укып бетерә алганчы көрәшегез" дигән тавышы яңгырый...

Залда утыручыларның әле берсе дә биш-алты елга сузылачак уку елы эчендә, сиксән алты студентның бары егерме тугызы гына (алары да күбесенчә авыл баласы) диплом алып чыгасын, укытучы кисәткән көрәшнең авыр, бик авыр булачагын белми иде.

Шәһәрнен үз акылы, үз тормышы. Авылча яшәп булмый анда. Киләсең, күрәсең, яраклашасың. Ошамаса әйберләреңне җыясың да кабат авылыңа юл тотасың. Башка чара юк. Шәһәрдә бары да табигый, бүреләр генә яши торган урмандагы кебек.

Авылдан килүчеләрне шәһәр төрлечә ымсындыра. Берәүләр һушларын җыя алмый кибет-базарларында йөри, икенчеләренең аңын кинотеатрлар ала. Биек таш йортларга бикләнеп, "Аллага шөкер газы, суы үзендә"—дип шөкерана кылып ятучылары да күп. Белемгә тартылучыларын милли китапханә әсир итә. Яшь чакларны искә төшереп, хәзер дә аның залларында адашып йөрергә яратам. Кечкенәдән тынгы бирмәгән сорауларыма җавапны да биредә таптым.

XV гасыр башы. Татар башкаласы Сарай хәрабәләр эчендә. Идел буенда тарткалашулардан җан инри. Кайгы бер килсә, ялгыз гына йөрми бит ул. Үзара тыныша алмаган бертуганнардан әйтерсең лә Ходай үзе йөз чөергән. Инде ничә ел корылык килеп, ачлык, төрле чирләр адәм башларын кыра. Үзенне мәңгелеккә килгән кебек хис итсәң, гомер ахыры тизрәк килә шул. Алтын Урда таркалган, урталыкта калган Нугай татарлары бер-берсенә баш бирмәс ун йортка бүленгән. Аларның бер ише әле күпме генә гомер элек чәчәк аткан шәһәр хәрабәләре арасын инләп көтү көтә. Икенчеләрен тормыш кытлыгы борынгы болгар җирләренә китергән. Алары да Чулман кичә. Бу якларның кырыс табигатендә бары утрак тормыш белән генә яшәп була шул. Ә аның өчен урман кирәк. Нугай халкының бер өлеше тел-тамырлары уртак казанлылар арасында төпләнеп кала. Алар күчеп килгән җирләр, Мишә елгасы буйлары. Казан арты, Чаллы төбәге халкы белән чуарлана. Соңрак берара әле ул далача фикерләгән нугайлар йогынтысында да калып, киләчәктә булачак ызгыш-талашларга да бер җирлек калдырачак...

1549 ел. Чаллы кирмәненең көл-күмере белән җил шаяра. 1552 ел. Казан кан эчендә. Татар җирләрен болгатып, һәрчак хәрәкәттәге дөнья тетрәнә. Казан язмышына битараф калган Нугай бәкләре кабат берләшә. Бу юлы урысларга каршы. 1553 елда Казанның көндәше Чаллы ныгытмалары яңадан торгызыла. Нугай даласыннан хан итеп Йосыф мирзаның улы, Сөембикәнең энесе Гали Әкрәмне чакыралар. Кяферләрнең мәкере билгеле. Тиздән аларның канлы куллары Нугай җирләренә дә сузылачак. Әмма соңга калып килгән акыл белән кара көчләрне җиңәрлек түгел инде. 1556 елның язы. Көттереп килгән кыштан соң, катлам-катлам көл белән ашланган туфрактан баш калкытучы яшеллеккә кабат Чаллы кирмәненең дөрләп янган саклану буралары ава...

Шәһәрләренең ныклыгы татар халкын саклап кала алмаган. Ә иман ныклыгына, халкының бердәмлегенә кайчан ирешелер? Каршыбызда 20 гасырның соңгы елы. Әзме-күпме татарны саклап калган вакытта үзгәрә. Өметләре генә акланырмы?

Татар халкы язмышы әйтерсең лә тулысынча Чаллы төбәге тарихында чагылыш таба. 1774 ел. Июль башы. Татар халкы җае чыгуга үз дәүләтен кайтаруга өмет тотып кабат баш күтәрә. Чистай кичүе аша Чаллы төбәгенә үз яраннары белән Бәхтияр Канкаев чыккан. Аңа ярдәм кирәк. Тирә-як авыллар халкы бүгенгәчә "Бәхтияр үзәне" дип йөртелгән Көчек (Биектау) авылы янындагы болынлыкка агыла. Җыенда Бәхтиярне бердәм хуплаган

300 дән артык ир-атның йөзгә якыны, шул ук көнне походный старшина, крәшен татары Герасим Сабаев житәкчелегендә Чистай кичүен сакларга китә. Анда аларга Көчек авылы кешесе Токтамышев Мәһди житәкчелек итә. Пугачев явының төп көчләре дә алар ярдәмендә Чулманны кичә. Калган ирләрнен бер өлеше авылларда сакта калса, икенче өлеше, йөз башы Туктар Юзкәй житәкчелегендә, хәзерге Балык Бистәсе жирләрендә көч туплап, хәрәкәт итә.

Баш күтәрүчеләр Казанны алып, урыс гаскәренә күп зыян салсалар да, өстәмә килгән дошман көчләренә юлыгып жиңеләләр. Күбесе авылларга тарала. Күп тә үтми, аларны эзәрлекләп урман ягыннан Кала тау өстенә, ике менле жәза отряды килеп урнаша. Бу отряд килгән юл халык телендә бүгенгәчә "казаклар юлы" атамасында йөри. Чаллы кирмәне каршындагы үзәнлеккә дә урыс явы кереп тула. Алар баш күтәрүчеләрнен мөмкинлекләрен чикләп Чистай кичүен ябалар. Баш күтәрүчеләр камалышта кала. Кабат азатлыкка, татар дәүләтен торгызырга омтылган Чаллы төбәге халкының әсир төшкән азамат ир-атлары кирмән каршындагы үзәнлектә жәзалап үтерелә.

1920 елларда кирмән каршындагы бу үзәнлек янында Казаклар авылында яшәгән Гали бай тарафыннан су тегермәне төзелә. Үзәнлектән балчык алганда жир катламыннан бик күп кеше сөякләре, кылыч-сөңге, шул чорга караган утлы кораллар чыга. Актарылган тарих... жәберләнгән милләт, дөньясын үзгәртергә омтылган язмышлар. Алар тагын күпме озата барыр безне?

Кабат китапханәдә утырганнар искә төшә. Чаллы төбәгендә чыккан 1938-41 елларга караган "Кызыл Йолдыз" гәжитләрен актарам. Тарихтан сабак алырлык вакыйгалар күп сакланган анда. Революция, колхозлашу чорларында искелекне юкка чыгарырга чәчрәп чыккан авыл активистларының күплегенә исем-акылым китә... Нинди генә чаралар үткәрмәгән дә, нинди генә союз-берләшмәләр төземәгән алар. Арада ин кыюы "Сугышчан Алласызлар союзы". Шуның нәтижәсендә Биектау (Көчек), Ямаш, Күгәрчен һәм төбәктәге башка авылларда мәчетләр тартып алынып, клубка әйләндерелгән. Гәжит саен дин әһелләренә, авылның иманын саклап калырга тырышучы халык вәкилләренә яла ягу. Соныннан чарасы да күреләчәк. Кайсын-кая таркатып, ин жинел котылганын да кимендә ун ел төрмәгә утыртачаклар. Бу гәжит битләреннән бүгенге көндә күпләр үз әби-бабаларының язмышын белә ала. Бары яла ягучылары гына билгесез. Аноним хатлар "күрүче", "белүче", "элемтәче", "хәбәрче" һәм башка шуңа охшаш имзалар белән тамгаланган.

Бүгенге көндә безгә милләтнең үсеш юлында тагын да биегрәк үрләр яулау, хыяллану урынында, гасыр башындагы милли үсеш дәрәжәсенә житү мөмкинлеге турында уйланырга кала. Кая ул элекке дәрт, көч? Нигә бүген, милләтнен әхләкый яшәешенә мөмкинлекләр туган заманда, авылның тавышы элеккечә көчле яңгырамый? Нәрсә булды безгә?!

... 1985 ел башы. Университат залларының почмагында сөйләнгән сүзләрнен тавышы артып, кызу бәхәсләргә әйләнгән вакыт. Фәнни коммунизм серләренә төшенеп, укытучылар белән бәхәскә дә керелә. Ә алар, тәнәфес вакытларында тәмәке төтененә күмелеп башкачарак фикер йөртсәләр дә жавап-лекцияләрен һаман да элеккечә үткәрә. Тамагынны телең белән туендыргач, авызга хужа булырга туры килә шул. Кемнен ашаган табагына төкергәне бар. Аннан, дөньясының кая барып чыгасын кем белгән әле. Үзебез дә артык бәхәскә кермибез. Безнен дә имтиханнар биреп, диплом аласы бар. Вакыт агышы, кешенен ни уйлап, сөйләнүенә генә карамый ул. Кемне нәрсә кызыксындыра бит әле. Хокуксыз калган "олы абый" "жид"ларны сүгә. Ә безгә, авыл малайларына, шул "кимсетелгәннәр" дәрәжәсенә житү дә чынга ашмас хыял булып кала бирә.

Дүрт гасырдан артык дәүләтсез калган халыкның, бары тамак ягын

гына кайгыртудан ары әлләни алга киткәне юк. Язмыш үзен дә ашатырга, башкаларнын да тамагын туйдырырга мәҗбүр иткән аны. Шунлыктан үткәне белән киләчәге турында уйлар вакыты да юк, теләге дә күренми.

Безнең халыкка читләргә охшап яшәргә тырышу хас. Һәрхәлдә, бүгенге язмышы башкаларга бәйле. Җитмәсә, вакыт та зур тизлек белән, татар яшәешенә яңа киртәләр тудырып, дөньясын үзгәртә. Соңгы дистә елларда булып узган үзгәрешләрдән ис китәрлек. Яңа төр видеотехника, санаклар тирә-ягыбызны урап алган. Бүген алардан башка тормыш алып баруны күзаллавы кыен инде. Бу яңалык-үзгәрешләргә, бер уйлаганда, шатланырлык, икенче караштан, куркыныч та. Без үскәндә бердәнбер белем чыганагы, матурлык дөньясының көзгесе китап иде. Ә хәзерге тәрбия, белем бирүчеләре дә шул ук җиде ят җирдән килүчеләр. Элек без бала-чаганы куркытып үстергән җен-шайтаннары да шулар кебек.

Бүгенге көндә олы яшьтәгеләр "Дөньясы кая барып чыгар икән, яшьләр бик азынды" дип зарлана. Заман үзгәргән саен буыннар арасында каршылык туа. Әллә без яраклашабыз, әллә заманасы үзгәрә. Дөньясының казанында кайнап, яшьләр үзгәрсә, ата-аналары үткәннәре белән үз дөньяларында кала бирә. Каршылыкның башка төрлесе, өметләндергәне дә бар. Көннән көн яшьләр иманга килә, картлары тузына. Хәер, киресенчә булганда, буын саен бары да кирегә барып дөньясы да бетәр иде. Үткәннәрнең тәрбиясе шундый булган күрәсең, җитмеш ел тәрбияләнгәне, ике-өч елда гына тәртәдән чыкмас иде.

Татар халкы дөньяның бөеклегенә дә менгән, упкынына да төшкән милләт. Без бер яктан хисле, түземсез. Икенче карашка бездән дә сабырлары табылырмы икән? Кабат дөньясы, яшәеш өчен мөмкинлекләр тудырып, татар язмышын вакыт агышында сыный... Үзебез генә тормыш авырлыкларыннан тураеп, бүгенге халәтебездән котылып өлгерербезме?

Шул өметле киләчәккә йөз тотып, кайчандыр тормыш кайнаган борынгы Чаллы шәһәре үзәгендә басып торам. Анда үткәннәрне искә төшереп, балчык үрләргә кысылып җил улый. Аяк астында, шул чорның кайгы-шатлыкларын искәртеп, савыт-саба ватыклары шыгырдый. Тагын да астарак, катлам-катлам җирдә безнең укылмаган тарих ята.

Чаллы төбәгендә бүген дә тормыш дәвам итә. Без—шул үткәннәрнең варис-оныклары. Чаллы шәһәрчеге—ата-бабаларыбыз нигезе. Тирә-ягындагы зиратлар—мәңгелек йортлары. Күпме кан, күз яшьләре түгелгән бу урында. Әйтерсең лә бары кайгылырдан гына торган дөнья бар нәфрәтен безнең халыкка юнәлткән. Ихтыярсыздан Хәлфә бабайның халык телендә сакланып калган сүзләре искә төшә: "Кала тауны Хан корды, тирә ягы яу булды, тездән ары кан булды..."

Үткәннәрдән кабат чынбарлыкка кайтам. Каршымдагы тарихи урын актарылган, җимерелгән. Изге чишмәләре ләм белән капланган. Чүп баскан зиратларында көтү йөри. Тирә-ягында, тарих катламнарын изеп, заман техникасы үкерә. Әйтерсең лә вакыт безгә, кеше гомере чикле, дөнья малы җыеп бетерерлек түгеллеген искәртә. Бүгенге көндә бабаларыбыз нигез-йорты бездән игътибар, кадер-хөрмәт һәм хәер-дога көтә. Тик ис-акылына килеп, гыйбрәт алучылары гына табылырмы?

Кешене вакыт сайлый һәм ул яшәүнең һәр мизгелендә сынала. Мин сезнең арада яшәдем. Уй-теләкләрем, өмет хыялларым да шул хакта. Яшәү мәгънәсенең хакыйкате бер булса да, барыр юллары төрлечә аның. Уйланучылары да булмый калмас әле.

Серлелеге белән мәңгелек хакыйкатькә дәгъвә иткән дөнья бит бу!

*1999 ел.*

# ШИГЪРИЯТ



## Фәрит Габдерәхим

### ТАТАРГА ДА БӘЙРӘМ КИЛМИ КАЛМАС

**Һәркемнең бар...**

Һәркемнең бар үз мәсләге, гаме,—
Кемгә кирәк акча, кемгә—дан.
Мин матурлык эзләп йөрим әле
Ямьсезләнеп беткән дөньядан...

**Шулай яратылганмын**

Шулай яратылганмын—мин
Үтә каты бәгырьле.
Уала җанга бәрелеп
Дошманнарым җәбере.

Шулай яратылганмын—мин
Үтә йомшак бәгырьле.
Җанны парә-парә телә
Дусларымның җәбере.

**Соңлаганбыз**

Үзебездән артта калганбыз:
Бик-бик соңлап колак салганбыз
Бабайларның әйткән сүзенә:
«Барсаң гына алга, гел алга,
Барып җитеп була үзеңә».

## Телем өчен...

Телем өчен,—
телем-телем телеп,—
Бәгыремне утка яктылар.
Тел сатканнар,
акча чутларга дип,
Йөгерешеп килде яктыга.

## Шагыйрьнеке иде

Урман акланында яшь шагыйрьнең
Йөрәгенә төзәп аттылар.
Күмеп тормадылар. Погонлылар
Дәртле бер җыр җырлап кайттылар.
Ул дәртле җыр шагыйрьнеке иде...

## Татар яңгыры

Күк чалт аяз иде моңа кадәр,
Килә болыт—көттек күпмеләр...
Дымлы җилләр китерделәр хәбәр:
Мичкәсендә суы күп, диләр.

Рәхмәт яусын! Яңгыр дулап яуды,
Чиләкләрдән койган шикелле.
Ә иртәсен көйгән җиргә аудык:
Яңгырыбыз булган... селтеле.

## Уяу саклыйлар

Тарихыбыз упкын төпләрендә,
Ә упкыннар шундый тирәннәр.
Саклый аны, үтә уяу саклый
Инде күптән үлгән тираннар.

## Ялвару

Ялварамын: ашыкмачы, зинһар...
Бер-бер артлы, әнә, тезелгән
Күпме эшләр. Гафу сорыйсым бар:
Бик еш үпкәләдем көзгегә.

Бар әле, бар ыштыр битлеләрнең
Ыштырларын утка атасым.
Туган телне саткан мөртәтләрнең—
Сатлыкларның сатыйм атасын!

Бар әле, бар безне бүлгәләгән
Калын диварларны ватасым.
Ничә гасыр төзәтүне көтә
Бабайларның олы хатасы.

Оныкларны тапмасыннар эзләп,
Иблисләрне кирәк бәйләргә.
Татарга да бәйрәм килми калмас,
Шигырь язасым бар бәйрәмгә.

Ялварамын: ашыкмачы, әҗәл!

*Башкортостан. Арыслан авылы.*



# Рәшит Шиһап

## Мәхәббәт көче

Балачагым...
—Бүре Хәсән кичә күрше авылдан
Маржа Мариягә өйләнгән!..
Шушы хәбәр яшен ташы кебек,
Кереп-чыгып йөрде өйләрдән.
—«Бүрелегән» иткән,—диде картлар,—
Гел дә качкан икән иманы...
Ике денле кайнар мәхәббәттән
Йөз чөерде авыл урамы.
Шаһаб мулла күккә кулын сузды:
—Йа Ходаем, афәт яудырма!
Күгебезне хәсрәт капламасын,
Урыс көннәренә калдырма!
Менә бер көн Мария аңа килде,
Татарчалап әйтте—шартлатып:
—Үз динеңә күчер әле, бабай?!.
Мулла калды шунда шаккатып.
—Вәгъдә бирәм, балаларымны да
Үстерермен татар иттереп.
Сайлабрак тор матур исемнәр дә,
Куштырырмын сиңа китереп.
Ул Мәрфуга булды шул вакыттан,
Хәсәнгә дә булды—кояшы.
Авыр чакларында төп терәге,
Тормыш сукмагында—юлдашы.
Кызыксынды аннан авыл халкы:
—Каян беләсең син безнеңчә?
Ә Мария әйтте:
—Хәсәнне мин үлеп яратамын,
Шуңа өйрәндем дә сезнеңчә!

## Матурлык—мәңгелек

Искиткеч бу дөнья! Барсы матур анда:
Урман-кыры, суы, һавасы...
Юлга чыксаң офыкларга тарта,
Гел барасы килә, барасы.

Әнә күбәләктәй карлар ява,
Энҗеләр күк куна җилкәңә.
Ак мендәрдәй ап-ак болыт агыла,
Аннан кояш чыга иртәңә.
Язлар килә кошлар канатында,
Бар табигать сихри моңнарда.
Җәйләр, көзләрнең дә хозурлыгы
Сыеп беталмаслык җырларга.
Шуңа күрә
Тормышымда бары садәлеккә,
Камиллеккә идем башымны.
Омтылышы шундый булганнарга
Бүләк иттем якут ташымны.
Ләкин, дөнья, матурлыгыңа мин
Артыграк, ахры, кызыктым:
Зәвыклары түбән җаннарыңның
Базарына килеп юлыктым.
Рух кыйбласын акча иткәннәрнең
Мәнсезлеге тиде теңкәгә.
Сәүдә itelә гүзәллекләр белән,
Сатыла акыл алтын тәңкәгә.
Замананың кыргый заты тота
Матурлык дип сузган кулыңны...
Дөнья ул куласа,
Андыйны бер баса,
Диеп әйтү бүген урынлы!
Ни булса да, дөнья шау чәчәктә,
Тирә-якта нинди ямьлелек!
Рухи бушлар вакытлыча яши,
Ә матурлык җирдә—мәңгелек!

## Үз башына төшмәсә

Карт сөйләде сугыш елларында
Әсирлектә күргән газабын.
Ә оныгы
Исе китмәгәндәй торып китте
Тыңлап бетермичә азагын.
Ышанмады.
Бабасының йөрәк җәрәхәте,
Тәне сызлауларын тоймады.
Кәнфит кенә ашап үскәнгәме,
Андый әрнеш уена сыймады...
Әфган тауларында үзенең кулын
Кысты әсирлекнең богавы.
Менә шунда белде—бабасының
Ул чак җаны ничек елавын...

*Татар хикәяләре хәзинәсеннән*

**Фатих Әмирхан**

# МИЛЛӘТ ТӘРӘКЪКЫЙ ИТТЕРҮ

(ЕГЕРМЕНЧЕ ГАСЫРНЫҢ ӘҮВӘЛГЕ ЕЛЛАРЫ)

## 1

Хөсәен ысулы җәдидә мәдрәсәләреннән берсенең иң яна фикерле шәкерте һәм мәдрәсәнең могтәбәр вә тырыш гакаидханнарыннан берсе иде. Ул күптән мәдрәсәләрнең мантыйк оясы булуыннан зарлана һәм күптән үк тәфсир, хәдис вә фөнүне җәдидә кирәклегенә ышана иде. Үзенә фикердәш дип уйлаган шәкертләр белән тугры килгәндә, милләтнең артта калуы тугрысында сүз ачылса, Хөсәен, мотлакан, ул фикергә иштирак итә һәм бу бәланең мәдрәсәләремездә тәфсир, хәдис вә сиярен-нәби укылмаганлыктан һәм мөселманнарның үзара иттифак тормаганлыкларыннан килгәнен бер дә генә дә шөбһә итмичә сөйли иде.

Хөсәен заһири тормышында да башка шәкертләрдән аерыла иде. Мәсәлән, мәдрәсә низамына мохалиф икәнчелегенә карамыйча, ул озын казаки кими, бәлки озынрак кына, татар киемчесе теккән пиджак киеп йөри һәм «эре»рәк мәҗлесләргә барырга туры килгәндә дип саклап тота торган катыргы якага да малик, вә чәче дә, башкаларныкыннан озынлыгы өстенә, кәләпүштән бертөрле купшы булып күренеп тора иде.

Хөсәен яна чыккан рисаләләрнең һәрберсен укый һәм менә инде икенче ел «Тәрҗе-ман»ның да мөштәрие иде. Моның өстенә ул зыялылар мәҗлесеннән дә калмый: Сәгыйть казыйның Казанга һәр килүендә номерасына барып күрешә вә яна фикерләр тыңлап кайта вә, боларның нәтиҗәсе уларак, тәфсир вә хәдискә көннән-көн ихлаclана вә иттихадның кирәклегенә ныклап ышана бара иде.

Хөсәен һәрбер үзе шикелле милләтнең нидән тәрәкъкые терәлеп торганлыгын белгән кешеләргә бу вакытта, ягъни «заманымыз—заманы тәрәкъкый» булган вакытта, эшкә тотынуны фарыз дип белгәнлектән, үзе дә эш башларга карар бирде. Анынча, хәзер мөселманнарны иттифакка китерер өчен, мотлакан, җәмгыятьләр ясарга вә шул васита белән берләштерергә кирәк; шуннан соң тәрәкъкый булачак иде. Ул да үзенең әүвәлге эшен җәмгыятьтән башларга беркетеп куйды да шәкертләр арасында янарак фикерле дип белгәннәренә сүз дә салгалаштыра башлады. Озак та узмады, Хөсәен алты кешелек бер җәмгыятьне булдырды. Җәмгыятьнең мәҗлесе киләсе пәнҗешәмбедә «Сарай» номерларының берсендә булачак вә алты әгъзаның һәрберсе мәҗлескә бирәр мәкалә яхуд, үзләре сүзенчә, нотык хәзерләп барачак булдылар.

## 2

Пәнҗешәмбе көн, сәгать ике тулганда, Хөсәен килеп, «Сарай» номерасыннан берсен ишгаль дә иткән иде. Ул бу көн үзенең милләт тәрәкъкый иттерү юлындагы әүвәлге хезмәтенең җимешләрен күрәчәк булганга, үз-үзенә бөтенләй тәгаҗҗебсез кала алмады. Анынча, бу җәмгыять, бер дә шиксез бик

тиз арада зураеп, милләтне бик күп тәрәкъкый иттерәчәк вә бик зур эшләр эшләячәк иде. Менә җәмгыятьнең ике әгъзасы—Йосыф һәм Мөхәммәтҗан да килделәр. Боларның әүвәлгесе үзенчә бик нәфис вә күп мәгънәле шигырьләр язучы «шагыйрь» вә икенчесе дә һәр яңа мәсьәләләргә аять, хәдистән җавап эзли торган «тәрәкъкый пәрвәр мөдәкъкыйк» иде. Номер ишегеннән кергәндә, боларның йөзләренә чыккан җитдият вә фәхер шулкадәр зур иде ки, Англия лордлар палатасының рәисе дә, бәлки, ул хосусы белән болардан уздыра алмас иде.

Болар һәр икесе сыңар куллап кына Хөсәен белән килеп күрештеләр һәм, бүлмәдә бер дә ят кеше юк икәнлегенә тәмам ышангач, баш киемнәрен салып, ялашбаш калдылар һәм, арлы-бирле йөренә-йөренә, җәмгыятьнең файдасы хакында сөйләштеләр. Болар арасында Йосыф, ни сәбәп беләндер, үз-үзеннән бик риза шикелле күренә: шатлык белән тирләп, маңлаен еш-еш сөртә, борынын тарта һәм язып килгән шигырьләр кәгазен кесәсеннән чыгара башлап, янадан урынына куя иде. Җәмгыятьнең калган өч әгъзасы да килделәр. Боларның арасында озын гына буйлы, озынча битле саргылт мишәр һәммәсеннән картрак вә, үз уенча, һәммәсеннән гакыллы вә галимрәк иде. Шуңар күрә дә җәмгыятьтән үзенә вә фикеренә хосусый ихтирам көтә иде.

Шәкертләр, озак уйлап тормыйча, алты прибор һәм унсигез пәрәмәч китерергә куштылар. Вә үзләре, әүвәл коридорны тәфтиш итеп кереп, ишекне бикләп эшкә керештеләр.

## 3

Мәҗлеснең башында Хөсәен үзенең өч көннән бирле тырышып хәзерләгәне нотыкны басып сөйләде. Нотык бик озын, тәкрарларын ташлап, кыскарак әйткәндә, шушы мәфһүмнән гыйбарәт иде: «Милләтемез артка калган, әмма руслар вә башка милләтләр тәрәкъкый иткәннәр, милләтнең артка калуына сәбәп, Коръән вә хәдис буенча йөрмичә, «Вә әгътәсыйму бихәблиллаһи җәмиган вә лә тәфәррәку» аяте кәримәсенә буйсынмаганлык. Менә башка милләтләр, мәсәлән, япуннар иттифак аркасында никадәр бәхетле булганнар. Әмма без, мөселманнар, Коръәндә бөтен гыйлем бар икәнен вә әүвәл дә мөселманнар бөтен җир йөзенә гыйлем чәчкәннәрен онытып, аларны башка милләтләргә биреп, үземез иттифаксызланып бу хәлгә калган. Хәзер милләтне тәрәкъкый иттерү, мотлакан, җәмгыятьләр васитасы белән генә мөмкин, җәмгыятьләр булып, иттифак булса, һәммә нәрсә житешәчәк. Шуңар күрә һәр мөселманга иттифак вә иттихад фарыз. Менә бу җәмгыять тә шул фарызны өстән төшерер өчен кирәк». Моннан соң Хөсәен җәмгыятькә рәис сайлауны гарыз итәргә уйласа да, теге мишәрнең сайланасы киләчәк вә, сайланмаса, җәмгыятьтән чыгачак, ләкин сайланса, бик үз сүзле кеше булганлыктан, күп уңгайсызлыкларга сәбәп булачак икәнлеген уйлап, хәзергә рәис сайламыйча, сәркәтиб кенә сайлап торырга гарыз итте. Мишәр һәм Мөхәммәтҗан әфәнделәр һәр икесе дә, мөтәрәкъкый милләтләрдә җәмгыять рәиссез булмый икәнчелеген сөйләп, сайларга тиешлеген дәгъва кылсалар да, Хөсәен Сәгыйть казыйның бервакыт: «Аурупадагы җәмгыятьләр һәммәсе рәиссез булалар»,—дип сөйләгәнлеген дәлил тотып, боларны илзам итте. Катиблеккә Хөсәен сайланды.

Моннан соң җәмгыятькә исем бирү мәсьәләсе кузгалды. Йосыф—«Багыйсе тәрәкъкый», Мөхәммәтҗан—«Әл-мөэмине кәл-бөньяни яшәдде бәгъзаһу бәгъзан», Хөсәен—«Әл-иттихад» исемнәрен гарыз иттеләр.

Мона кадәр тик торган мишәр әфәнде урыныннан торып вә бик ышанычлы сурәттә «Әл-горвәтел-вөска» исемен бирергә кирәк икәнчелеген сөйләде. Дәлилләре дә куәтсез түгел иде. Әүвәлән, ислам философларыннан Җамалетдин әл-Әфгани үз китабына кушкан исем. Саниян, бу исем, Коръәннән алынганга күрә, һәрбер мөэмин-мөселманга гам. Салисән, матур. Ләкин Хөсәен ни өчендер бу дәлилләрне хисапка алмыйча, «Әл-иттихад» кушарга кирәк дигән дәгъвасында дәвам итә иде. Хәер, ул да бөтенләй дәлилсез түгел иде, ул кәнеж төрекләрнең җәмгыятьләре һәрвакыт шундый «Иттифак», «Иттихад» дигән шикелле исемнәрдә була икәнен

сөйләде. Җәмгыятьнең дә Мөхәммәтҗан белән мишәрдән башка әгъзалары Хәсәен тарафына күчеп, «Әл-иттихад» исеме кабул ителде.

Нәүбәт мәкаләләр укырга килеп җитте. Әгъзалар бер-берсен, «син әүвәлдә», «мин соныннан» дип, берникадәр кысташканнан соң, Мөхәммәтҗан, фахиранә генә кесәсеннән зур табаклы кәгазь чыгарып, тамагын кырып, бераз үзен төзәткәләп укырга тотынды:

«Хәмед вә салаваттан соң, диямез ки, безнең мөселман милләте, артта калып, тәрәкъкый итмәгәндер, чөнки пәйгамбәр әфәндемез галәйһиссалаваты вәссәламның сөннәтләрен аяк астка таптадылар»,—дип башланган бу мәкаләдә милләт тәрәкъкый өчен кирәк нәрсәләр аять, хәдис белән исбат ителгән иде. Бу мәкаләдә «таләбел-гыйльми фаризатен», «отләбель-гыйльмә вә ләү биссыйни» хәдисләре, иттихад фарызлыгын күрсәтә торган аятьләр һәм ысулы калимәнең балалар өчен бик зарарлы, хәтта тәҗвид бу тарикта бөтенләй укытылмый икәнлеге, вәхаләнки Җәзиридә: «Вәл-әхзе биттәҗвиди хәтмен ляземен, мән ләм йөҗәүвидел-Коръәнә фәһүә асимен», дигән икәнчелеге һәммәсе бар иде.

Мөхәммәтҗан укып бетергәч, җәмгыять әгъзаларының җөмләсенә бердән татлы гына карап та торды; анынча, бу мәкаләдән соң инде милләткә, бер дә төртелеп тормыйча, алга тәгәрәп китәргә генә калган иде. Моннан соң укырга мишәр әфәндегә гарыз итсәләр дә, ул, язган нәрсәсе бик мөһим булганлыктан, бөтенрәк хиссият калдырыр өчен, үзенең иң ахырдан укыячак икәнен сөйләде.

Нәүбәт Госсам әфәндегә иде. Госсам әфәнде, күп төрек романнары укыган бик тәрәкъкый пәрвәр вә «мәгълүматлы» кеше булып, инша куәсенең дә зурлыгы белән мәгъруф шәкертләрдән берсе иде. Госсам әфәнде нотыкны башлар алдыннан бер мәртәбә әгъзаларның йөзләренә карап алды да тиз заманда бөтен җәмгыять моның бу кадәр әдәби язганлыгына исләре китәрлеген аллан белгән шикелле, көшлек тавыш белән укырга тотынды:

«Җәмгыятьләр нәя лязем? Җәмгыятьләр бәни бәшәрнең тоткасы вә һәр милләтнең багыйсе тәрәкъкый вә тәгалиедер. Бөтен көррәи әрыздә нәкадәр мөтәрәкъкый милләтләр варса, һәпсе җәмгыятьләр васитасилә тәрәкъкый итмешләрдер. Бакыныз, әфәнделәр, миләле саирә нәсел тәрәкъкый итмештер. Күз уңымыздагы кечек Япуния кыйтгасы шу җәмгыятьләр васитасилә шу бөек чин милләтен зир вә зәбәр итте...»—дип башланган бу мәкаләдә милләтнең бөтен тәрәкъкые шул җәмгыятьләргә генә туктап тора; бурлар, шушындый җәмгыятьләр ясап, Англияне җиңгәнлекләре, шул җәмгыятьләр аркасында Франциядә никадәр мәгариф барлыгы, хәтта Америка фәтех итүчеләр дә шул җәмгыятьләр аркасында фәтех иткәнлекләре күрсәтелгән; һәм, әүвәлдә, шушындый кечкенә-кечкенә җәмгыятьләр ясап, аннан соң, шул җәмгыятьләрнең берничәсе бергәләшеп, зуррак җәмгыять ясап, вә ила гайрен-ниһая бара торгач, бөтен мөселманнарның бер җәмгыятькә җыелулары тиеш икәнчелеге «исбат» ителгән иде.

Җәмгыятьтә мәкаләләр тугрысында мөхакәмә булмаса да, Госсам бу мәкаләнең җәмгыять әгъзаларын хәйран калдырырга тиеш икәнчелегендә бер дә шөбһә итми вә шунар күрә әгъзаларның әле берсе, әле берсенә: «Нишләттем, яхшы иттем бит!»—дигән шикелле итеп карый иде. Хәер, бу караш бөтенләй җавапсыз калмады, мишәр әфәнде дә анар: «Син роман күп укыганга әдәби язсаң, менә минем мәкаләдә нинди тәхкыйклар бар икәнен күреп торырсың!»—дигән шикелле итеп, озак карап торды. Ләкин болар бер-берсен аңлашмадылар. Шунар күрә «милләте исламның иттифак вә иттихады» бозылмый кала алды.

Моннан соң укырга Йосыфка гарыз итсәләр дә, ул укыячак нәрсәсенең шигырь икәнлеген, шунар күрә дә иң ахырдан укылуы муафикъ икәнен сөйләп, имтинаг итте.

Теләсә вә теләмәсә дә, мишәр әфәндегә укырга лязем булды. Бу әфәнде озын буйлы вә кин җилкәле кеше булып, шул хасиятләренең калерен үзе белә иде. Шунар күрә дә ул укыр алдыннан, хазирунга карап, кечкенә генә бер мәзәк (мөзах) тә ясап алды.

—Мин дә басып укер идем дә, барегезгә дә башләрегезне сузып карәргә кирәк булыр дип куркәм, хи, хи, хи...

«Әлхәмде лиллаһи раббил-галәмин вә саллаллаһе галә сәйедил-мөрсәлин,

әмма бәгъдә, и җәмәгате мөслимин, белегез вә агяһ улыңыз ки, безнең бу диярдә миссионерлар заһир улыптыр...»—дип башланган бу озын «нотык»та миссионерларны Коръән кәрим, хәдис һәм Сәгыйть әфәнде рәддияләреннән алынган дәлилләр белән бик каты илзам иткән иде. «Нотык»та мишәр әфәнде, дәһриләрдән дә бик каты көлеп, аларны да бик каты илзам итте. Мәкаләдә, дәһриләргә хитаб итеп, болай ди:

«И мәлгун дәһриләр, әгәр сезгә бер мән: «Бу көн мин балта остасыннан башка, үз-үзеннән ясалган кимә күрдем»,—дисә, сез ышанмыйсыз. Бәс, ничек итеп, шушы җир вә күкләрне бер санигъдан башка вөҗүдкә килгән дисез?» Мәкаләнең бу җиренә җиткәч, мишәр әфәнде, галәбә иткән бер гаскәр башлыгының ифтихары белән бераз туктап, хазирунга карап та торды. Моннан соң да инсафка килмәгән дәһриләрнең моганид икәнчелегенә ул бик каты ышанган иде. Мәкаләнең ахыры тагы да житди вә тагы да гүзәл иде:

«Әгәр дә алар һаман шулай безнең дингә каршы торсалар, шунчалаен алла белән ямин итәм ки, җирләре вә күкләре яратты, безгә дияре исламга Һиҗрәт фарыздыр!»—дип тәмам була иде.

Мөхәммәтҗан әфәнде, мәкалә тәмам булуга, чыдый алмады:

—Бәрәкәаллаһ, афәрин!—дип кычкырып та җибәрде.

Мишәр әфәнде дә эченнән генә: «Ля йәгърифе зәвилфазлы илля зәвир»,—дип уйлап, тамак кырып, яулыгы белән маңлаен сөртеп, калган ярты пәрәмәчен ашарга тотынды.

Хәзер нәүбәт Йосыфка житте. Ул шигырьнең никадәр әһәмиятле икәнчелеген яхшы белә иде вә шуңар күрә нәсерләр укылган формада гына укылуын җаиз күрми иде. Акрын гына бүлмәнең уртасына килде, аякларын ике яккарак каратып басты һәм хосусый бер гайрәт белән укырга кереште:

«И безнең йоклап яткан милләтемез!
Уйган инде, житәр вакыт—сискәнермез.
Уйганмасан, җәһаләт битлеген киеп,
Җаргычланыр, һәлак булып, битләремез»,—

дип башланган бу озын касыйдә милләтне тәрәккъый итәргә бик кыстаган иде. Ахыры тагы да «гүзәл» бетә иде:

«И мөселман, уйган инде, уйган, уйган,
Инша алла, тәрәккъый булыр кидешемез!»

Шигырь укылып тәмам булгач, «Әл-иттихад» әгъзалары төрле яктан: «Афәрин!»—дип кычкырдылар. Йосыф та үзенең «милли шагыйрь» булып китүеннән хосусый ләззәтләнде.

Моннан соң җәмгыять, бу кыйммәтле «әдәбият тәзкирәләрен» җир йөзендә ила ямый кыямәти бакый итәр өчен, «Тәрҗеман» газетасына җибәреп бастырырга карар бирде. Киләчәк җыелышуга Мөхәммәтҗан вә мишәр әфәнделәр үзләренең «Бәян эс-сәнә»не тәрҗемә итеп китерәчәкләрен сөйләп, сөенче алып куйдылар.

## 4

Сәгать дүрт тулу сәбәпле, шәкертләргә таралырга да вакыт житкән иде. «Әл-иттихад»чылар, половой белән хисап күреп, унберешәр тиен акча түләп, икешәр-икешәр чыгып китә башладылар. Мишәр вә Мөхәммәтҗан әфәнделәр, коридорда очраган школьникларга карап вә аларны дәһрилекләре өчен кызганып, хәзер генә укылган мишәр әфәнденең мәкаләсен боларга укытсаң, никадәр савап булыр иде бит, дип уйлыйлар; Госсам әфәнде дә, әгәр мөселманнар җәмгыятьләр ясасалар, хәзер тәрәккъый итәрләр иде бит, дип ышана. Хөсәен әфәнде дә юлда очраган ямщикларны иттихад кирәклеген белмәгән өчен кызгана вә һәммәсе бергә бу җәмгыятьтән соң милләт тәрәккъый итә башлар инде дип игътикад итәләр иде.

*1908*

## Хикәядәге кайбер төшенчәләргә һәм сүзләргә анлатмалар

Тәрәкъкый иттерү—алга җибәрү.
Иштирак итә—кушыла.
Сиярен-нәби—Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормыш юлы.
Иттифак тормаганлыкларыннан—бер сүздә булмаганлыкларыннан.
Заһири—тышкы.
Низамына мохалиф—тәртипләренә каршы килү.
Иттихад—бер фикердә булып эш итү.
Тәгажжебсез—гаҗәпләнмичә.
Мөдәкъкыйк—тикшеренүче, җентекләүче.
Фәхер—горурлык.
Мәфһүм—эчтәлек.
Гарыз итәргә—тәкъдим итәргә.
Илзам итте—бәхәстә җиңде.
«Әл-иттихад»—«Берлек».
«Әл-горвәтел-вөска»—«Ышанычлы таяныч».
Гам—уртак.
Кәнеж (гәнеж)—яшь.
Фахирәнә—эре.
Тарик—ысул.
Җөмләсенә—һәммәсенә.
Вәхаләнки—чынлыкта.
Көшлек—кыланчык.
Бәни бәшәр—адәм балалары.
Шу чин—шул Кытай.
Зир вә зәбәр итте—тар-мар итте, җиңде.
Фәтех—ачу.
Вә ила гайрен-ниһая—һәм шулай чиксез.
Мөхакәмә—фикер алышу.
Тәхкыйклар—бик җентекләп тикше-ренүләр, хакыйкать ачулар.
Имтинаг итте—баш тартты.
Хазирунга—шундагыларга.
Бәгъдә—аннары.
Диярдә—тирәдә, җирдә.
Рәддияләреннән—каршы язылган мәкаләләреннән.
Илзам иткән—кире каккан.
Галәбә иткән—җиңгән.
Ифтихары—масаюы.
Моганид—кире беткән дошманнар.
Имин—ант.
«Ля йәгърифе зәвилфазлы илля зәвир»—«акыллы кешене акыллылар гына таныйлар».
Җаиз—яраклы.
Җәһаләт—наданлык.
Касыйдә—ода.
Кидешемез—барышыбыз.
«Әдәбият тәзкирәләрен...»—«Әдәбият ядкярләрен...»
Игътикад итәләр—ышаналар.
Гакаидхан—«Гакаид» китабын—ислам дине канунннарын анлаткан гарәпчә дәреслекне—уку сыйныфындагы шәкерт.
Бурлар...—көньяк Африкадагы бер халык.

## ИСКӘРМӘ

Күренекле прозаик һәм публицист Фатих Әмирханның (1886—1926) «Гарәфә көн төшемдә» исемле беренче хикәясе 1907 елда «Әл-ислах» газетасында басыла. Моннан соңгы басмасында ук (1909) «көн» сүзе «кич» сүзенә алыштырыла, һәм әдип аны «Хыялый хикәя» дип атый. 1908—1909 елларда ул инде мәшһүр «Фәтхулла хәзрәт» исемле сатирик әсәрен яза.

Аның күпсанлы хикәяләре, роман-повестьлары башка телләргә тәрҗемә ителде, китаплар булып еш кына басылды. Татарстан китап нәшрияты 1984—1986 елларда, язучының тууына йөз ел тулу уңаеннан, аның дүрт томлыгын чыгарды. Бу томнар—Ф. Әмирханның тулырак җыелмасы, һәм беренче томны гел хикәяләр генә тәшкил итә. Бай мираслы әдипнең әлек басылмаган яки соңгырак китапларына кертелмәгән хикәяләре, үткен публицистик әсәрләре соңгы елларда дөнья күрде.

Фатих Әмирхан—татар әдәбиятында кыска хикәя жанрын башлап җибәрүчеләрнең, бу төр әдәбиятның ныклы нигезен салучы-өюче олпат язучыларыбызның беренчеләреннән. Ул, гомумән, күп мәсьәләләрне иҗатында башлап күтәрә. Егерменче гасырда хикәя жанрының үсешен күзәткәндә очраган бер нәрсәгә игътибар итик.

Мәҗит Гафуриның «Хан кызы Алтынчәч» исемле (1914) һәм Нәҗип Думавиның «Болгар кызы Тойгы туташ» исемле (1915) әкияткә тартым хикәяләре бар. Болар укучыларыбызга таныш, алар икесе бергә аерым китап булып та ике тапкыр (1919 һәм 1921 елларда) чыккан. Әйе, халкыбыз тарихын әдәби калыпка салуда кайбер әдипләр әкияти тасвирлау ысулын (әлбәттә, сәбәпләре бардыр) сайлыйлар. Һәм, без белгәнчә, моны хикәя жанрында Ф. Әмирхан башлый—аның «Халык кызлары» исемле хикәясе 1912 елда языла.

Мондый алым әдәбиятыбызда соңрак та күренә. Танылган әдип Әхмәт Фәйзинең 1948 елда иҗат ителгән «Аучы Мәргән белән Болан кыз әкияте»ндә дә (әсәр беренче тапкыр 1960 елда гына басыла) тарихыбыз чагыла. Инде шунысын да әйтик, хәзер дә тарихи хикәяләр языла, ягъни Фатих Әмирхан башлангычы дәвам итә. Соңгы елларда, бу темага, мәсәлән, Ләис Зөлкарнәй («Кыргын»), Ркаил Зәйдулла («Шаһгали»), Туфан Миңнуллин («Әби патша һәм татар кызлары») бергәйле хикәяләрен укучыларга ирештерделәр.

Фатих Әмирханның иҗаты һәм тормышы турында әдәбият шактый бай. Арада аның иҗатын үтә тискәре бәяләүләр дә бар. Г. Толымбайның «Фатих Әмирхан» дигән китабы—менә мисал. Безнеңчә, Ф. Әмирхан турында җентекле хезмәтләрне галимнәр Мөхәммәт Гайнуллин, Ибраһим Нуруллин һәм Равил Әмирхан яздылар.

...«Милләт тәрәкъкый иттеру» хикәясенең—ул классик әдибебез дүрт томлыгының беренче китабыннан алынды—исеме астына Ф. Әмирхан «(Егерменче гасырның әүвәлге еллары)» дип куйган. Ә бит милләтне «алга җибәрү»дә гасыр башындагыча—хикәядә сурәтләнгәнчә—гамәл кылучылар гасыр ахырында да бар лабаса! Атаклы язучыбыз кисәтүенә колак салмаганбыз була түгелме соң? Кызганыч...

*Әсәрне журналда бастыруга* **Мәгъсум ХУҖИН** *әзерләде*

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

Хәтерегездә булса, 75 ел эчендә чыккан барлык нөсхәләрне дә редакциябездә булдыру максаты белән, үзегездә сакланган «Безнең юл», «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты» басмаларының элегрәк елларда чыккан саннарын җибәрүегезне үтенеп берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән идек. Сезнең ярдәм белән архивыбыз тулыланып бетте дияргә була. Шулай да кайбер саннар һаман җитеп бетми әле. Болар:

**1966—1 сан, 1963 —8 сан, 1954 —12 сан, 1942—11, 12 саннар, 1934—1, 5 саннар һәм «Безнең юл» (1922—1930), «Атака» (1930—1933) журналлары.**

Сездә бу саннар сакланган булса, редакциягә юлласагыз иде! Бу изге гамәлне бәхилләтер өчен, журналга бушка яздыру яки бүтән формада хак түләү юлларын редакция үз өстенә ала.

Безнең адрес: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 йорт, «Казан утлары» журналы редакциясе. Хәбәрләшү өчен секретариат телефоны: 43—56—12.*

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Рецензияләр конкурсы*

## ЯКТЫ ҖИРЛЕКТӘГЕ ҺӘЛАКӘТ

Хикәя жанры хакында, анын бүгенге хәле, киләчәге турында матбугатта да, төрле җыелыш-киңәшмәләрдә дә сүзләр еш кына кузгалып тора, бу төр әсәрләрнең бик кирәклеге, әһәмияте искәртелә, шулай да сәнгатьчә камил хикәяләрнең әле җитәрлек язылмавы, оста хикәячеләрнең әдәбиятка берән-сәрән, әллә нигә бер генә килүе икърар ителә. Моның үзенең сәбәпләре бар, әлбәттә. Шуларның аеруча мөһиме: кул яссуы хәтле тар мәйданда калку характерлы, җанлы образ иҗат итүнең, бер балкыш мизгелендә укучының хисләренә көчле йогынты ясардай картина тудыруның кыенлыгында булса кирәк. Бу каршылыкны сирәк әдипләр генә уңышлы хәл итәләр. Бәс шулай икән, офыкта иҗатның тансык татлы җимеше—әйбәт хикәя—пәйда булу белән аңа игътибар юнәлтү, серенә төшенергә тырышу, күркәмлеге, хикмәте нәрсәдә икәнен ачыклау, кыскасы, әтрафлы эстетик анализ ясау таләп ителә. Моны әдәби тәнкыйтьнең мөһим бер вазифасы дип санарга була.

Мәгъсүм Хуҗин—бөтен иҗат юлында шушы җыйнак һәм шул ук вакытта ифрат катлаулы, үзсүзле жанрга риясыз тугрылык саклаган, бу өлкәдә бай тәҗрибә туплаган, күзгә күренерлек нәтиҗәләргә ирешкән сирәк әдипләрнең берсе дер. Ул әлеге жанрны илаһи югарылыкта күрергә тели, «әдәбиятның күгендә—хикәя!» дигән караштa тора, шушы хасияте белән аны хәтта сүз сәнгатенең башка төрләреннән аерып та куя, «әдәбиятта хикәя иң өстене» *(М. Хуҗин. Ерактагы кыялар.—К.: Татар. кит. нәшр., 1990, 7 б.)* дигән катгый фикергә килә.

Кече күләмле жанрда М. Хуҗин инсан хәятының бик гыйбрәтле, тирән мәгънәле төбәкләрен, адәм баласы холкының төрле якларын, кәеф-халәтенең күп төсмерләрен сурәтләп күрсәтте. Аның әсәрләрендә без җанны назлый торган, нурланып балкыган күренешләр, мөнәсәбәтләр җылылыгы белән дә, кискен драматизм, сагыш, күңел китеклеге, бәндә рухының ярлылана, тупаслана, коргаксый төшүе белән дә очрашабыз. Әмма, ни генә тасвирланмасын, аның хикәяләрендә тоташ моң агыла. Еллар үткән саен бу моң яктыра, тирәнәя, нәфисләнә бара. Шундыйрак хәлне Ә. Еники болай аңлата: Яхшы хикәянең,—ди ул,—«ничектер үзенә генә хас эчке бер сулышы, җаны була. Моны язучының хикәягә салган настроениесе дип тә атарга була» *(Ә. Еники. Хикәя турында.—Китапта: Язучылык хезмәте турында.—К.: Татар. кит. нәшр., 1958, 172-173 б. б.)* М. Хуҗин аны әсәрнең кояшы дип саный, һәр хикәянең үз кояшы була, ул бөтен галәмне—әсәрне яктырта, дип расли. М. Хуҗин хикәяләренең моңы Ә. Еники әсәрләренекенә дә, И. Гази, Ф. Хөсни, Р. Төхфәтуллинныкына да охшамаган. Шул ук вакытта ниндидер аваздашлык, таныш аһәңнәр дә ишетелеп калгандай була аларда,—боларның һәммәсе дә классик традицияләрдә иҗат ителгәннәр.

«Казан утлары» журналының 1999 елгы алтынчы санында М. Хуҗинның «Каңгый иләндә» дигән яңа хикәясе басылып чыкты. Аны әдипнең хикәя өлкәсендәге казанышларының логик дәвамы һәм шул ук вакытта яңа бер ачышы, галәтилектән күпмедер калкыбрак торган әсәр дип карарга була. Монда язмыш, туган җир кадере

мәсьәләсе күтәрелә. Болай әйткәндә шактый гомум кебек күренсә дә, әсәрдә ул бик үзенчәлекле, тәэсирле яктыртыла. Вакыйга 1927 елда башланып китә. Әсәрнең үзәгендә Хәялинең хәл-әхвәле бәян ителә. Ул—чыра юанлыгыдай ябык бер малай: «куллары тиредән дә сөяктән генә торадыр...» Әнә шуның бер ел элек әтисе вафат булган. Әнисе Дәрига кулында өч бала торып кала: энесенә—дүрт, монысына—алты, апасына—сигез яшь. Ачлы-туклы яшәп бик бетеренгәч, әнисе, чарасызлыктан, төпчекне үз янында калдырып, Хәяли белән апасы Дөррияне балалыкка бирмәкче була.

Һәм менә боларның капка төбенә тарантаска җигелгән озын торыклы, «күккә тиярдәй» биек дугалы, тәзек, яхшы дирбияле күк ат килеп туктый. Хуҗалары, күрәсең, хәлле кешеләр булса кирәк. Ир белән хатынның—Хуҗанур һәм Мөсәгыйдәнең—Хәялине уллыкка алырга килүләре икән. Хикәянең нигезенә, шулай итеп, тойгыга турыдан-туры йогынты ясардай, күңел кылларына кагылып узардай ситуация салынган. Ләкин, аңа карап, автор сентименталь рухта хикәяләүне кирәксенмәгән. Ул бик җыйнак, ләкин шулай да халәтне нечкә төсмерләтердәй мәгънәле детальләр белән эш итә. Психологик сурәтләр нигездә сабыйның тормыш-көнкүреше, мохиты үзгәрү белән бәйләнгән. Иң әүвәл, үтә чандыр малайны күреп, Хуҗанур күңелендә: «синең өчен килдек микәнни?» дигән сорау туа. Бу мәсьәләдә әдип Хәялине үтә сизгер күңелле итеп сурәтли:

«Агайның мондый халәтен малай сизде—аңышты. Ул, агайның әйтелмәгән соравына турыдан җавап кайтарырга теләп, үзен олыларча тотып:

—Менә шундый инде мин,—диде.—Сез мине алырга килгән булырсыз.—Малайның тавышында каушау юк иде, шулай да аның:—Алсагыз...—дип сузуында шөбһә беленеп алды».

Әсәрдән аңлашылганча, Хәяли инде үзенең язмышы белән килешкән. Хәлнең кай тирәдә икәнен яхшы белә. Ул үз гаиләсенең моңсу тарихын Хуҗанур белән Мөсәгыйдәгә олыларча сабырлык белән сөйләп бирә. Шул ук вакытта агайның үз карарын әле һаман төгәл белдермәве, фикерен тәгаенләмәгән булуы Мөсәгыйдә белән Хәялине сискәндереп җибәрә. Бала янына килеп утырганда Мөсәгыйдәнең бөтен гәүдәсе бизгәк тоткандагыдай калтырап тора. Малай да каушап кала. «Шулай да, Мөсәгыйдәнең йомшак кулы аркасына тиеп алгач, тынычланды, шул мәл хатынның дерелдәвен дә бетерде». Очрашу, «дипломатик сөйләшү» барышындагы халәт әнә шундый штрихларда белдерелә.

Элегрәк иҗат ителгән байтак хикәяләрендәге кебек, монда да әдип рухи-интеллектуаль яссылыкта хикәяли. Ул фәкыйрьлектә ачлы-туклы көн күргән бу малайның рухи бай, пакь күңелле, инсафлы булуына басым ясый. Хикәянең башында ук укучының дикъкате Хәяли кулындагы «карындык тышлы әфтияк»кә юнәлтелә. Кечкенә хикәядә ошбу деталь биш тапкыр телгә алына. Хәяли мәдрәсәгә кергәнче үк, күрше хәзрәт кызыннан өйрәнеп, язу таный башлаган, инде юкарак унсигез китап укып чыгарга өлгергән. Бу гамәлне ул изге эштән саный, чистарынып, тәһарәт алып кына укырга керешә. Шуның белән бергә баланың фикер сөрешендә алфавитның үзгәрү ихтималына хафалану да сизелә.

Әсәрдән беленүенчә, малайның китапка һәвәслеге, сабыр-салмак фикер йөртүе, фәлсәфи нәтиҗәләр чыгарып куюы, кечкенәдән акыл утырткан булуы, күркәм холкы олылар күңеленә хуш килә. Ябыклык исә—вакытлы күренеш, кырыс тормыш шартларының гына нәтиҗәсе ул.

Хикәянең башында соңгы сүзне, тәртип буенча, гаилә башы Хуҗанур әйтер кебек күренә иде. Ләкин асылда хәлиткеч карарны абзый түгел, Мөсәгыйдә кабул итә,—капма-каршы якка күчешләр әсәрдә хәтсез урын ала. Катлаулы яшәештәге үзгәрүчәнлекнең сәнгатьчә чагылышы буларак, аларның тискәре якка борылыш икәнлеге хикәядә сизелми дә, сюжет җебенә каршылыклар берлегенең үрелеше гадәти, табигый хәл буларак кабул ителә.

«—Карале... ни ...—һәм, ниһаять:—Әтисе, дим,—дип әйтеп салды ул,—нигә утырасың соң син?! Бар әле, атка су эчереп мен. Инешне уздык кына, кайда икәнен беләсең, ашарына сал аннары». Бу сүзләрдә Мөсәгыйдә, бала белән ялгыз калып, икәүдән-икәү, күзгә-күз карашып сөйләшергә, эч серләрен бушатырга, шик-шөбһәләренә җавап табарга җыена икән дип аңларга да була. Ләкин көткән акланмый. Хикәядә ялгыз гәпләшүнең бер кәлимәсе дә китерелми. Ни өчен? Күрәсең, нәкъ менә шушы мизгелдә Мөсәгыйдә күңеленә кинәт яңа бер фикер килә, ул ныклы ышаныч

булып өлгерә: артык сүз куертып, сораштырып та торасы юк, аның өчен инде мәсьәлә хәл ителгән. Автор раславынча, Мөсәгыйдә белән бала баштан ук бер-берсен үз итешәләр. Сюжет барышы дәвамында Мөсәгыйдә берничә мәртәбә сабыйны алдына утыртып сөяргә укталып ала. Тик әчке бер кыенсыну, әле килешеп бетмәс дип санау гына аны тыеп тора. Ул инде шунда ук көчтәнәчләрне алып керү, баланы киендерү, тарантас башына утыртып, юк, алдына утыртып алып кайту турындагы сүзләргә көчә, хатын-кыз психологиясенә ярашлы рәвештә салмак, талгын агымга кискен бер дулкын килеп керә. Шулай да Хәяли бер теләген, шартын белдерүне кирәк таба, «сез мине уллылыкка алсагыз, хәзрәттән дә ризалык сорый күрегез», ди.

Очрашу, танышу күренешен тасвирлау шуның белән тәгәлләнә. Моннан соң аларның бик еракка, таулар иленә, Каңгый жиренә күчеп китүләре хәбәр ителә. Моны сюжетның табигый бер юнәлештә барышы, туры сызык буенча хәрәкәт итүе дип карап булмый. Бу—асылда бер халәттән икенче халәткә күчеш. Борынгы греклар мондый борылышларны «перипетия» дигән сүз белән билгеләп йөрткәннәр. Кискен борылышлар белән эш итү әдиптән зур осталык таләп итә, укучыны ышандырырлык итеп сәнгатьчә ныклы нигезләүне, дәлилләүне сорый. М. Хужин, күрәсез, перипетия таләпләреннән курыкмаган. Алай гына да түгел, ул борылыш белән кыскалыкны үзара яраштыруга, берләштерүгә ирешкән.

Хикәя әлеге таулы төбәкнең исеме белән, «Каңгый илендә» дип аталган, ягъни бу исем шул аймактагы мәгыйшәтне хикәяләүне вәгъдә итә, ул әсәр композициясенең төп өлешен алып торырга, үзеген тәшкил итәргә тиеш кебек күренә. Ләкин гаҗәп хәл: таулар илендәге хәяттән әсәрдә бер генә күренеш тә тасвир кылынмый. М. Хужин монда Каңгый илендәге яшәешнең бәгъзе нәтиҗәләрен генә күрсәтә. Нәтиҗә мондый. Утыз биш елдан соң Хәялиләр гаиләсе авылга ике машина белән кайтып төшә. Алдагысын—Хәяли, арттагысын—олы улы йөртә. Беренчесенә—Хуҗанур белән Мөсәгыйдә, икенчесенә Хәялинең хатыны белән балалары утырган.

Дәрига улының зур кеше булганлыгына чиксез куана, «улыкаем, пруфиссор ук булып життенме?»—ди. Ана кеше сүзен бер нәрсә турында башлый да, каударланып, икенче сукмакка кереп китә. Әсәрдә әлеге сорау җавапсыз кала. Хәялинең профессор булуы расланмый да, кире дә кагылмый. Ләкин сорауның куелу кадәресе дә, җавап алынмаган хәлдә дә, персонаж сурәтенә билгеле бер мәгълүмат өстәп җибәрә. Әгәр дә малайның бик яшьли зиһенле булуын, китап яратуын искә алсак, зур галим булып житешүе дә гаҗәп тоелмас. Моны Хәяли үзе кешеләрнең бер-берсенә ярдәм кулы сузуы нәтиҗәсе дип бәяли. Шул ук вакытта биредә кинрәк мәгънә дә аңлашыла, Каңгый иленең ятимгә рухи үсәргә юл куйганлыгы сизелә. Көнкүреш шартлары да начардан булмаска тиеш.

Әсәрдән күренүенчә, Хәялинең авылда, әнисе янында калган энесе алты почмаклы, калай түбәле таза йорт житкергән. Кунаклар кайткач, ул үз машинасында Дөррия апасы гаиләсен алып килергә дип чыгып китә.

Бу инде, күрәсез, хикәя башындагы үтә фәкыйрь, сүрән яшәеш түгел. Һәммәсенең дә тормышы тулы көйләнгән. Автор, шулай итеп, әниләреннән аерылып, чит кешеләр кулында үскән балаларның да ахырда муллыкка тиенүләре, житешле дөнья корулары хакында күтәренке рухлы хикәя язарга ниятләгән икән, дип уйларга була.

Хәяли әнисенең исеме—Дәрига. Бу сүз «Ни аяныч!»дигәнне аңлата. Аның мәгънәсе бу очракта әле хикәянең эчтәлеге белән бәйләнмәгән кебек тә тоела. Чөнки әлегә андый үкенечле хәл күренми.

Әмма әсәргә тагын кискен борылыш, бу юлы инде трагик нәтиҗәле вакыйга килеп керә.

Дәрига, улының зур кеше булуына куанып, «монда калсаң, тирес арасында гомерең узар иде»,—дип куя. Хәяли, бәрәңге бакчасына чыккач, чыннан да, әскерттәй өелгән тирес өеме күрә,—төпчек малайның мал-туар ишле, ахрысы. Шул чак әнисенең әлеге «тирес арасында гомерең узар иде» дигән сүзләре исенә төшә, бу сүзләр аның башына күсәк белән тондыргандай тәэсир итә.

«Тиресләребез арасында яшәү Каңгый иле рәхәтлекләреннән шәбрәк, мең тапкыр шәбрәк!—дип уйлады Хәяли.

Нәкъ шул мәлдә Хәялинең йөрәген куәтле кыскыч сытты...» Хәялинең җансыз гәүдәсе әлеге әскерттәй тирескә авып төшә.

Нәрсәне аңлата бу финал? Автор үзе моны шәрехләмәгән. Укучының уй

йөртүенә, фараз кылуына калдырган. Зур кеше булгач, рәтле тормышка ирешкәч кенә персонаж күнеленә канәгатьсезлек килеп керүе, йөрәгенең сызлый башлавы укучыны уйландыра, әлбәттә, анда төп сәбәпне белү теләге тудыра. Укучыда актив уй хәрәкәте кузгату—әсәрнең сәнгатьчә көчен күрсәтә торган бер мөһим билге ул. Уйландыргач, хикәянең масштабы да шактый киңәя, мәгънәви тирәнлеге арта төшә.

Бу урында аеруча шигъри стильгә хас булган бер үзенчәлекнең хикәягә килеп керүе хакында да әйтеп китәргә кирәк. Сәбәпнең ачылмавы, тәфсилләп ачыктырылмавы, фараз кылырга урын калдыру, күпмедер гомумиләштерелгән сурәт белән эш итү—бу шигъри сөйләмгә, лирик тасвирга хас сыйфат. Автор, димәк, эпик төрдә тезмә сөйләм мөмкинлекләрен дә файдаланган булып чыга.

Дөресен әйткәндә, тышкы иминлек ноктасыннан гына караганда, икенче кисәкнең әлеге финалны кире кагуы, аның белән килешмәү, карышу ихтималы да бар шикелле. Ләкин хикмәт шунда ки, хикәянең бөтен төзелеше, логикасы эчке драмага юнәлгән. Бик кыска гына мизгелдә Хәяли күнеленнән үтеп киткән чагыштыру матди житешлек, дәрәҗә файдасына булып чыкмый. Хәяли Кангый илендәге рәхәтлекләрне бөтенләй исәпкә алмый. Үз ягыбызда гомер кичерүне теге рәхәтлекләрдән күп тапкыр өстен куя.

Әсәрдән безгә мәгълүм булганы—иң әүвәл Хәялинең әнисе назыннан, жылы карашыннан мәхрүм калуы. Ул туган жиреннән, аның жанга якын хозурлыгыннан, милләтеннән аерыла, утыз биш ел аларны күрмичә, сагынып гомер кичерә. Әнисе белән сөйләшкәндә Хәяли «бүз бала Кангый иленнән кыз ала» дигән мәкальне әйтеп жибәрә. Киленне ул әнә шул Кангый иленнән алып кайткан. Әсәрдә киленнең дә, балаларының да авылда сөйләшкәннәре ишетелми. Алар бәлки татарча бөтенләй белми дә торганнардыр.

Бер урында автор Хәялинең «уй йөртү сәләте кечкенәдән үк акылы көченә буйсына иде»,—ди. Димәк ул сагышларын тышка чыгармаска тырышып яшәгән. Һәммәсен эченә жыя килгән, һәм алар, йөрәк сызлавы рәвешендә, ниһаять, тишелер хәлгә житкән. Шулай булмаса, ул тиресләребез арасында, ягъни туган туфракта яшәү Кангый иле рәхәтлекләреннән мең тапкыр шәбрәк димәс иде. Тышкы иминлек астында эчке бер тирән әрнү, сызлану яткан булуы мөмкин. Акыл көченә буйсынып фикер йөртү сәләте исә Хәялине һич тә хистән мәхрүм итми. Чөнки акыл белән эш итү һәм тойгы-кичерешләр тирәнлеге—алар үзара сыешмый торган хасиятләр түгел.

Хәяли женазасында, автор тасвирлавынча, иң нык Хужанур карт ачыргалана. «Улым, безне нигә ялгыз калдырдың...—дип өзгәләнә ул.—Хәялием, әнием белән мин бәхеттән мәхрүм бит инде... Ятим-ятимә бит инде без...» Бу сүзләрдә акыллы, игелекле Хәялине үз баласы кебек ихлас ярату да, чит жирләрдә ялгыз, ятим калу хәсрәтеннән шомлану да ишетелә. Картлар өчен Хәяли бәлки иң ышанычлы таяныч, терәк кенә түгел, Кангый илендә туган телдә сөйләшердәй бердән-бер кеше дә булгандыр. Хәзер менә ул да юк. Шушы мизгелдә жирсү хисе Хужанурның да йөрәген бәлки телеп, чәнчеп узгандыр.

М. Хужин хикәяләренең күпчелегендә финал шактый тәэсирле итеп бирелә. Биредә дә әдип туган якны сагыну тойгысын фажигале коллизия аркылы зур художество көче белән сурәтләп күрсәтә алган. Асылда бөтен хикәя шушы финал өчен язылган. Чөнки тәүге юллардан ук әдип шушы кайгылы чишелешкә таба бара. Сюжет хәрәкәте дәвамында жыелып килгән эстетик жегәр әсәрнең азагында аеруча ачык сизелә. Биредә инде «Дәрига» исеменең дә мәгънәсе башкача яңгырый, кинәт язмышның үкенечле, аяныч ягы ачылып китә.

Хикәядә фольклорда еш очрый*торган өч саны берничә мәртәбә кабатлана: Хәялиләр авылдан өчәү чыгып китәләр, һәр персонаж гаиләсендә—өчәр бала, Дәриганың ике малаенда өч машина. Дөррия тәрбиягә алган әнисен дә, бианасын да якын күрә, үз итә, «мин бәхетле—минем өч әнием бар, дип мактанып та куйгалый ул». Бу саннарның эстетик мәгънәсе, әсәрдәге төгәл вазифасы төгәл төсмерләнми. Ә менә композициянең өч кисәктән оешканлыгы ачык күренә. Боларның өчесендә—өч төрле аһәң. Контрастлылык эффекты аеруча соңгы ике бүлекчәдә анык чагыла. Әдип фажигане якты фонда бәян итүне мәгъкуль күргән, шуның белән чишелешнең тәэсир куәтен бик нык көчәйтеп жибәргән. Биредә перипетия, борылыш мәгънәви мөһим эстетик алым буларак файдаланылган. Финал Кангый илендәге яшәешнең нәтижәсе итеп бирелгән. Әсәрнең «Кангый илендә» дип аталуы да әнә шуннан килә.

Сорау туарга мөмкин: хакыйкатькә төшенгәч, сюжетның тагын яна борылыш алу ихтималы булмаганмы, ягъни Хәялинен үз ягында калуы, психологик бушануы, эчке сызланудан арынуы табигыйрак килеп чыкмас идеме? Юк, ул мәсьәләне хәл итми. Алай иткәндә, хатыны, балалары үзләренең җирлегеннән аерылалар, яна драма бөреләнә.

Күпчелек хикәяләрдә гадәттә бер эпизод тасвирланучан була, әсәрне шул үзәк оештыра, хикәя ингә дә, буйга да әлеге бер күренеш белән чикләнә. Икенче берләрендә озын гына тормыш юлы да яктыртылырга мөмкин. Ләкин бу очракта да хикәя повестька күчми, үз табигатен, үз йөзен төгәл саклап кала. Ягъни анда бер үзәк вакыйга гына җентекле тасвирлана да, тормыш юлындагы калган күренешләр штрихлар белән генә рәсемләнә. «Кангый илендә» әсәре әнә шундый икенче төр хикәяләр рәтенә керә. Биредә тәүге очрашу күренеше генә тәфсилле бәян ителгән, калганнары турында җыйнак кына әйтеп кителгән. Монда кыскалык сонгы чиккә җиткерелгән. Һәр сүз исәптә. Автор кайчак башлаган җөмләсен дә төгәлләп куймый, алга таба нинди сүз киләсе контекстта болай да аңлашыла дип саный. Үзләренә таба чит ат борылуын шәйләп алгач, малай аптырап кала: «Без кунак чакырмадык ла. Әй, кунак чакыру, ди, үзебезгә ашарга да...» Җөмлә шуның белән бетә. Ләкин шуннан соң нинди сүз яки сүзләр ялганасы бик ачык беленеп тора: «үзебезгә дә юк әле» яки «үзебезгә ашарга да такы-токы гына әле» рәвешендә ул җөмлә. Шул ук вакытта синтаксик конструкциянең киселеп, өзелеп калуы сәнгатьчә аклана да. Малайның уе тарантастагы кешеләргә юнәлә: кемнәр булыр болар? Шулай итеп, бер очракта башланган җөмлә дә төгәлләнми кала, ә икенче вакытта исә әфтияк детале биш мәртәбә искә алына. Ләкин моны стиль чуарлыгы, эзлексезлек дип карап булмый. Чөнки тегесе дә, монысы да хикәянең сәнгатьчел куәтен, эстетик энергиясен формалаштыруга хезмәт итә. Күп кенә контраст төсләрдән үрелгән булса да, хикәягә стиль бөтенлеге, бердәмлеге хас.

Биредә юл асты мәгънәләренә саллы вазифа йөкләнә. Менә Дәрига кызын асрамага тапшыру өчен ике авыл арасындагы басу чигенә килгән. Ул елый-елый кызының кулын булачак әнисенең кулына тоттыра. Кыз белән аның яна әнисе юлның теге ягына чыгалар. Шул чак «Дәрига Дөрриягә кулын сузды, Дөррия ике куллап Дәригага сузылды. Ләкин юл киң үк иде, сузылган куллар бер-берсенә җитмәделәр». Хикмәт, әлбәттә, ат юлының кинлегендә түгел. Ул—М. Хуҗин тарафыннан табылган бер поэтик чара гына. Ә мәсьәлә—аяусыз, мәрхәмәтсез язмышның ана белән сабыйны аеруында. Әлеге конкрет вакыйга—куллар тоташмау детале—бик зур фаҗигаи хәлне аңлата. Бу хикәядә сурәтләр җыйнаклыгы мөһим эстетик категория дәрәҗәсенә күтәрелгән. Шуның нәтиҗәсендә тыгыз тәнле, нык мускуллы әсәр туган.

Шул ук вакытта кыскалыкның астыртын, мәкерле хасияте булуын да искәртеп үтәргә кирәк. Куллана белми куллансан, аның сине схематизмга китереп чыгаруы да бар. Хикәя җыйнаклыгы—ул очар кош җыйнаклыгы. Кош никадәр генә кечкенә булмасын, Ходай аңа, гәүдәсенә карап, нормаль яшәр өчен зарури бөтен әгъзаларны да биргән. «Кангый илендә» хикәясен, әнә, М. Хуҗин өч ел язган. Анда ул иҗади осталыгын, талантын бер фокуска җыйган, жанрның мөмкинлекләрен тулы файдаланган. Шуңа да әсәре биеккә, еракка очардай кош булып дөньяга килгән. Хикәянең кояшы исә туган якка, милләткә булган мәхәббәт хисенең олылыгын, тирәнлеген көчле сурәтләүдә күренә. Монсу булса да, асылы белән якты әсәр иҗат ителгән.

«Ерактагы кыялар» китабына язган кереш сүзендә әдип болай ди: «Ибраһим Газиның «Тургай картаямы икән?», Мирсәй Әмирнең «Мөстәкыйм карт йокысы», Фатих Хөснинең «Сөйләнмәгән хикәя» һәм Әмирхан Еникинең «Матурлык» исемле хикәяләренә сокланам. Иң югары шурлектәге бу әсәрләр янында мин тагын Аяз Гыйләҗевның «Тәрәзәләр», Газиз Мөхәммәтшиннең «Ике әби бәрәнге ала», Фаил Шәфигуллинның «Солдатлар кайта» дигән хикәяләрен дә тотам». Әнә шундыйларны үрнәк итеп куя М. Хуҗин. Ул матбугатта да бүгенге укучыларга татар хикәяләре хәзинәсеннән иң әйбәтләрен сайлап алып тәкъдим итә, журналда бастырып чыгаруны оештыра. Болар сүз остасының әдәби зәвыгын билгеләп кенә калмыйлар, аның нинди югарылыкка карап иҗат итүен, әсәрләргә карата таләбен дә күрсәтәләр. М. Хуҗин әнә шул байлыкка, дөнья классикасы казанышларына таянып яза.

**Фәрит ХАТИПОВ**
*филология фәннәре докторы.*

# ХАТАЛАР ДА БУЛМАСА...

Рафаил Газизов исеме соңгы еллар матбугатында еш күренә. Әлбәттә, әдәбият мәйданында күренгән яңа исемнәргә башта беркадәр сагаебрак карыйсың. Кем ул? Нәрсә турында яза?.. Инде әлеге авторның күптән түгел генә дөнья күргән «Кичер, кичерә алсаң» *(«Татар китабы» нәшрияты, Казан, 1998)* хикәяләр җыентыгы кулыма килеп кергәч, аны кызыксынып укып чыктым. Р. Газизов кечкенә-кечкенә генә хикәяләрендә авыл тормышын, төрле язмышларны ачып бирергә омтыла. Аның геройлары—гади авыл кешеләре. Хикәяләрдә, кечкенә генә детальләр ярдәмендә, авыл яшәеше, кешеләре шактый киң планда чагыла. Тискәре яктан күрсәтелгән персонажлар да байтак. Бусы да табигый. Шуна күрә авторның әсәрләре тормышчан, геройлары, ничек бар, шулай тасвирланган.

Р. Газизов үз хикәяләрендә төрле һөнәр ияләренә, төрле чорларга мөрәҗәгать итә. Аерым әсәрләрендә үткән белән бүгенгене бәйләп, чагыштырып карарга да омтыла. Менә «Җинүчеләр» хикәясе. Ул беренче карашка әллә ни зур проблема, идея дә күтәрмәгән шикелле. Сюжет та гади генә. Яз көне, әле сугыштан кайтып, өйләнешүләренә берничә генә ай үткән ике яшь гаилә—Гарәфетдин белән Нуридә һәм Шәкүр белән Хөснури сыерларына ашатырга салам эзләп басуга чыгалар. Менә шушы эпизодта геройларның бер-берсенә булган мөнәсәбәте, дуслыгы ачыла да инде. Эчкерсез ярдәм итү, игелек эшләү кебек күренешләр югала барган бүгенге көндә әлеге геройлар үрнәк булып торырлык. Хикәя азагында автор бу күршеләрнең Варшава, Прага, Берлинны алып, авылга җинүчеләр булып кайтуларын ассызыклый. Ягъни, сугыш вакытындагы җиңү белән менә шушы көнге язгы ташу алдыннан, зур авырлыклар белән булса да исән-сау салам алып кайтучыларның җиңүләре арасында параллель үткәрелә. Авторның әйтергә теләгән төп идея-фикере дә шунда ачыла кебек. Автор дуслыкның сугыш вакытында гына түгел, тыныч тормыш агышында да бик кирәк һәм алыштыргысыз булуын күрсәтә, безне һәр эштә ярдәм, тату булырга чакыра.

«Кашыклар» хикәясендә дә шуңа охшашрак проблема. Сугыш чоры авылының тормыш-көнкүрешен тасвирлаганда автор кеше күңеленең матурлыгын, изгелеген катлаулы вакыйгалар, уйлап чыгарылган каршылыклар эчендә түгел, ә бәлки Р. Газизовка хас булганча, гади, тормышчан хәл-әхвәлләрдә ача. Сугыш чоры кешеләре яшәешен автор гади бер детальгә—агач кашыкларга—бәйли. Хикәядә чынбарлык һәм хыял беркадәр каршы да куела кебек. Ә төп фикер, унбишләп хатын-кыз белән Ташлы авылына чәчүлек орлыкка җибәрелгән Мәгъсумбикәнең кибет киштәсендә «матур, ялтыравыклы» агач кашыкларны күргәч туган хыяллары, кечкенә генә куанычлары, һәм тирә-юньдәге кешеләрнең мона мөнәсәбәте белән бәйле. Алда карап үтелгән хикәядәгечә, биредә дә дуслык, бер-береңә ярдәм итү кебек сыйфатлар үрнәк итеп, үзәккә куела. Вандовка авылы марҗаларының бу хатыннарга мөнәсәбәтен ачканда да автор әлеге принципка таянып, уңышлы сәнгать чаралары ярдәмендә эш итә.

Авыл кешеләрендә буыннан-буынга күчеп килгән матурлыкны, аларның гадилеген, шаянлыгын һәм уңганлыгын мактау белән бергә, әлбәттә, автор тормышыбызда яшәп килгән аерым тискәре күренешләр турында да яза. Әдәп, әхлак, экология проблемаларын күтәрә. Хыянәт, әләк, яхшылыкка—явызлык эшләү кебек күренешләрнең авыр нәтиҗәләрен күрсәтә. Бу китаптагы «Гаян абый хат укый», «Кил, килештер», «Куян бәлеше», «Җәбир», «Куштан», «Игенче», «Өй өмәсе», «Богзай» кебек әсәрләр шуңа мисал була ала.

«Куян бәлеше» уңышлы гына язылган. Биредә автор авылның күзгә әллә ни ташланып тормый торган ваклыкларын да тотып ала һәм күрсәтә алган. Төп фикер исә табигатьнең пычрануы, юкка чыга баруы турындагы борчулар белән бәйле. Дөрес, биредә вакыйгалар агышы, геройларның бирелеше уңаеннан беркадәр уйланырлык, автор белән бәхәскә керерлек урыннар бар шикелле. Чөнки Дәүләтхан кебек табигатьне яраткан, аның юкка чыга баруына борчылган герой, тереклекне тагын да корытырга—ауга чыгарга—җөрьәт итмәс иде кебек. Нәкъ менә шушы урында автор үзе дә, үз-үзенә беркадәр каршы килә шикелле.

Китапка кертелгән әсәрләрнең иң уңышлысы һәм күләмлесе ул, әлбәттә,

«Кичер, кичерә алсан...» хикәясе. Төп герой Барый образы аша автор бүгенге көн өчен аеруча әһәмиятле мәсьәлә—мәрхәмәтлелек, кешелеклелек проблемасын күтәрә.

Унтугыз яшеннән аягы яраланып, сугыштан инвалид булып кайткан Барый беркадәр Р. Төхвәтуллинның «Авылдашым Нәби» повесте героен да хәтерләтә. Әйе, Нәби дә, Барый да—чын күңелдән тормышны, кешеләрне яратучы геройлар. Әлеге ярату аларга башкаларга карата игътибарлы, игелекле булырга ярдәм итә. Озак еллар тимерчелектә эшләгән Барый, Нәби кебек үк, карт-корыларга, сугыш вакытында ирләрен, балаларын югалткан мохтаж гаиләләргә ярдәм итәргә омтыла. Әмма Барыйның үзенчәлекле ягы да бар, ул принцип кешесе: бары тик саф күңелле, гадел һәм намуслы кешеләргә-гаиләләргә генә ярдәм итүне үзенә максат иткән. Бу—геройның ачучы төп сыйфат. «Ә шулай да әшәке кешегә бармыйм. Әшәке кеше белән әйбәт кешенең аермасы саклансын. Әнә, Гайшә апа бар, кеше әләкли, кайсы гайбәт сатып йөри...»—ди ул.

Барый образын автор бөтен катлаулылыгы, каршылыгы белән ача алган. Беренче карашка беркатлы булып күренгән бу персонаж күңелендә шактый авыр яра ята икән. Озак еллар ялгыз яшәп картайган сугыш инвалиды чын кичерешләрен, рухи йөзен башкаларга күрсәтми икән. Яшерүнең, әлбәттә, сәбәбе бер генә—кешеләрнең мәрхәмәтсезлеге.

Дистә еллар дәвамында ялгыз яшәве, яшь ханым һәм туташларның аны өенә озатып төрлечә шаярулары, тормыш кирәк-яракларына үтә сакчыл карашы һ. б. авылда гайбәт чыганагына әверелгән һәм бу геройны рәнжеткән. Әлеге вакыйгаларны биргәндә Р. Газизовны чын мәгънәсендә каләм остасы итеп танийсың. Автор Барыйның кичерешләрен бары бер тапкыр, бары бер вакыйгада гына тасвирлый. Шулай булса да, кеше бөтен барлыгы, фаҗигасе белән ачыла: «Барый абыйның капка төбендә, такта дөбердәтеп, берничә ирдәүкә кыз көлешә иде, чираттагы «маймыллар», чираттагы күңел ачу. Барый абый капканы бикләп кереп тайган, хәзер көлеп ятадыр...

Барый абый идәнгә капланып үкси-үкси елый. Аның үзәк өзгеч тавышы тәрәзә пыялаларына бәрелеп сулкылдый. Мин үз күземә үзем ышанмыйча читкә сикердем. Ялгыш күрмәдемме, дип янадан тәрәзәдән үрелдем.

Дөрес икән, җилкәләре сикерә, әнә хәзер көзән җыерган кебек калтырана башлады һәм йөзен тәрәзә ягына борып тынып калды. Бу йөздә мең еллык кайгы-хәсрәт бар иде.

Табигатьне, чисталыкны яраткан, намуслылыкны үзенә юлдаш иткән Барый башкалардан да шуны таләп итә. Әмма... Зарифа карчыкның сараен төзәткәндә салкын тидереп, авырып урын өстенә егылган Барыйның, медпунктка хәбәр ителгән булса да, берәү дә килеп хәлен белми. Кешеләрнең бер-берсенә битарафлыгы Барыйның үлеменә дә сәбәпче була. Шәфкатьле бер җан, шулай итеп кичереп булмаслык шәфкатьсезлек белән очраша.

Хикәядә Р. Газизов берничә мәртәбә «Ни өчен шулай мәрхәмәтсез икән бу кешеләр?», «Авыл көн дә урамнарында чылтырап йөрүче көмеш кыңгыравын югалтканын аңлар микән?» кебек риторик сораулар куя. Укучыларга турыдан-туры мөрәҗәгать итү бүгенге тормыш, бер-беренә булган мөнәсәбәт турында житди уйланырга мәҗбүр итә.

Р. Газизов хикәяләренең теле гади һәм шул ук вакытта—үзенчәлекле. Автор кызыклы чагыштырулар, гипербола, эпитет, җанландырулар, сынландыру, лирик чигенешләр белән оста эш итә, образларны тудыруда уңышлы алымнар куллана. Мәсәлән, «Богзай» хикәясендә төп геройларның берсе булган Сәлим Сәйфулласын ачуны автор, аның тышкы кыяфәтен бирү белән башлап җибәрә: «...Бүрек колакчыннарын өскә бөтереп куйган, чишеп җибәрелгән яңа фуфайкасыннан җылы күкрәкчә, бумажи күлмәк күренә, күлмәкнең якасындагы ак сәдәп ут яктысында җем-җем итә, хатын-кыз муенсасы таккан диярсең. Фуфайка итәгеннән яңа кара чалбар сузылган, ул Сәлимечнең клубка беренче тапкыр киеп чыккан яңа итегенә кереп югала...» Алга таба, әлеге төс-кыяфәткә туры килеп торган үзенчәлекле характер сыйфатлары да ачыла башлый: «...Сәлим Сәйфулласы дөбердәп урыныннан төште.—Аның кайда яшәгәнен дә белмәгәч, ничу анда изеп утырырга,—дип.—Әйе, эке, п-у!—дип йөрәген басар өчен тәмәке тартырга чыгып китте. ... Үзе кебек атчыны кешеләр алдына бастырып сорау алуны аның сабырсыз йөрәге күтәрә алмый иде». Гадилек бөркелеп торган, туры сүзле, үзенә генә хас сөйләшү рәвешле әлеге геройга укучының игътибарын җәлеп итә, яраттыра.

Р. Газизовның хикәяләре нигездә гади, җыйнак, уңышлы эшләнгән. Әмма, аерым әсәрләрнең сюжетын, вакыйгалар агышын бирүдә әле беркадәр уйланасы урыннар бар кебек. Кайбер хикәяләрендә, мәсәлән, автор бер вакыйга турында сөйли башлый да, кинәт тукталып, икенчегә күчә. Нәтиҗәдә, хикәяләрнең сюжет бөтенлеге югала, әсәр аңлау өчен катлаулана. Мисал өчен, «Куян бәлеше» андагы төп герой Дәүләтханның ауга чыгып китүе белән башланып китә. Алга таба вакыйгалар үстерелә башлый. Дәүләтханның күзәтүләре, уй-теләкләре белән беррәттән, хикәягә Бануттинең мәчесе Җанкай белән сөйләшү вакыйгасы да кертелә. Әлеге күренеш игътибарны читкә юнәлтә. Вакыйга ничектер яңа кулмәккә кирәксездән салынган ямаулык кебегрәк тәэсир калдыра. Шуның өстенә, Банутти бик теләп Фирая киленнең уңганлыгы, булганлыгы, аның бала табу йортына китүе турында сүз алып бара да, каяндыр тагын Разия килене турында сөйли башлый. Шушы урында укучыда шик туа: әбинең ике килене булып, икесе дә бала алып кайтырга җыенамы, әллә инде сүз һаман да бер героиня турында гына барамы? Мондый аңлашылмау очрагы «Куштан» хикәясендә дә күзгә ташлана.

«Точка Хуҗасы» хикәясе дә төп геройны ачу, вакыйгаларны эзлекле тасвирлау юнәлешендә тиешле дәрәҗәдә эшләнеп бетмәгән. Бу герой төрле әсәрләрдә кабатланып һаман тулылана бара. Аерым вакыйгалар агышында укучы тарафыннан яратылып өлгергән Точка Хуҗасы, ни хикмәт, үз исеме-кушаматы белән аталган хикәядә ачылып бетә алмый, ягъни ул тулы эшләнелеп беткән образны тәшкил итми. Инде алда әйтелгәнчә, биредә геройга бәйле вакыйгалар, үсеш-үзгәрешләр дә эзлекле рәвештә бирелсә, хикәя күпкә уңышлырак булыр иде. Әлеге хәл авторның «Рәхимша абый», «Завхоз» хикәяләрендә дә кабатлана. Р. Газизов биредә дә геройларның аерым сыйфатларын бирү белән генә чикләнә, тулы, җанлы әдәби образ тудыруга ирешеп житә алмый кебек. Бу хикәяләрдә әдәбият өчен яңа сүз, яңа фикер бирелгән дип исбатлавы да, күтәрелгән төп идеяне ассызыклавы да шактый кыен.

Хикәяләрдә күпчелек геройлар кушамат белән бирелгән. Бу аларга үзенчәлекле төс бирә. Чөнки мәгълүм ки, авылларда кушаматсыз кешене табу шактый кыен. Геройларның үзләренә генә хас сөйләм теле дә бар: автор әдәби телдә кулланылмый торган сүзләр белән (аерым очракларда рус сүзләре дә кулланып) аларның характер сыйфатларын, сөйләшү-аралашу манераларын ачарга омтыла. Мондый алым, әлбәттә, яшәргә хаклы. Әмма хикәяләргә гел бу юнәлештә генә халыкчанлык төсе бирергә омтылу үзен акламый.

Р. Газизов хикәяләрендә, сирәк булса да, авыр, аңлаешсыз җөмләләр—хәтта стилистик хаталар да очрый. Мисалга түбәндәге җөмләләрне китерергә мөмкин: «Имән төбенә кырмыскалар килеп менгән», «Политикадан Рәхимша эшне мәйданның иң биек жиреннән урын алудан башлады». «Күршеләр» хикәясендә исә автор үз-үзенә каршы килә. Баштарак «Китте шуннан игълан ителмәгән сугыш» дисә дә, бераздан, ни өчендер, фикерен үзгәртеп «Җәй буе бара игълан ителгән сугыш» дип яза. «Монысы Харисның бахтыр булып эшләвенә ишарә», дигән җөмлә дә аңлашылмый. «Бахтыр»—«вахтер» дигән сүзме, әллә автор башка фикер әйтергә теләгәнме? Алай икән, бәлки, аңлатма бирергә кирәк булгандыр?

«Җанының кайнар тирәнлегендә кибеп парга әйләнмичә калган, күзләре аша кысылып чыккан бүгенге газапларның соңгы яшь тамчылары да, Марья түтинең «Ах!» дип тирән көрсенеп карап торуы да һәм бу ап-ак чәчле марҗа түтинең үзенең дә кулына яшьләр тамуын да, бу яшьләрнең беркайчан да идәнгә төшеп житә алмасын да инде ул белми иде, чөнки Марья түтинең яргаланып беткән кулындагы ярыкларны тутыру өчен дә шактый күз яше кирәк иде шул». Бу озын җөмләдәге мәгънәне, әлбәттә, башкачарак та бирергә мөмкин булыр иде, чөнки татар телендә да-дә кисәкчәләреннән тыш та бәйләүче чаралар байтак бит. «Иреннән үз хуҗалыгына ни кызык, (казык) ни бүрәнә, дигәндәй», «Вандовка марҗаларыннан (моржаларыннан) төтен чыга» кебек җөмләләр дә, әдәби шаяруларга әйбәт нигез булырга мөмкин.

Китапта еш җибәрелгән орфографик хаталар: авысын да авасын, мәсәлә, берике, тавышгауга, җиләкҗимеш һ. б., пунктуацион хаталар да күңелдә уңай тәэсир калдырмый. Болар, әлбәттә, «Татар китабы» нәшриятының да дәрәҗәсен төшерә.

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

## *Мәдәният тарихы*

**Фәрит Галимуллин**

# «ИСЛАМ ИМПЕРАТОРЫ»—РӘШИТ КАЗЫЙ

*«Җиһел сәякле сәяхәтче», «тарихи кыңгыравык», «Рәшид казый», «Габдерәшид хәзрәт», «Рәшид бабай», «Ислам императоры Рәшид», «кызыклы карт»—болар барысы да бер кешегә төрле галимнәр, язучылар, публицистлар тарафыннан бирелгән исемнәр; алар арасында, безнең карашка, иң мөһимнәре—«көрәшче» һәм «шәхес» дигәннәре. Әмма шунысы әһәмиятле, кешене төрле уңай эпитетлар ярдәмендә әнә шулай шәхес дип танышлар икән, димәк, ул, һичшиксез, үзеннән соңгы буыннарның да игътибарына лаеклы була. Хәзер инде бу кызыклы көрәшче-шәхеснең исемен дә әйтеп китәргә кирәктер. Ул—Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимов. Тулы исеме Габдерәшит булса да, алга таба без аны, традициягә ияреп, Рәшит Ибраһимов дип атарбыз. Элекке чор русча документларда исем Абдрашид рәвешендә язылган, ләкин халыкта ул—Рәшит исеме астында күбрәк билгеле. Икенчедән, исемне инициал итеп биргәндә (ягъни Г. Ибраһимов рәвешендә язганда), Габдерәшит Ибраһимовны Галимҗан Ибраһимов белән бутауга юл кала, бу—төрле аңлашылмаучылыкларга да китерергә мөмкин. Кыскасы—Рәшит Ибраһимов.*

*Соңгы вакытта Р. Ибраһимовка игътибар арта бара. Аның исеме гасыр башы татар тарихына багышланган хезмәтләрдә лаеклы урынын ала башлады. Р. Ибраһимовка багышланган мәкаләләрдән аның үзе исән вакытта язылганнары аеруча игътибарга лаек. Болардан Галимҗан Ибраһимовның «Тарихи кыңгыравык өзелде» дигән мәкаләсе аерата дикъкатьне тарта. Аның язылу сәбәбе дә кызыклы... 1922 елда дөнья матбугатында Р. Ибраһимов үлгән дигән хәбәр тарала. Әлеге хәбәр Татарстанга да килеп җитә. «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елгы февраль (46) санында буржуаз журналист Р. Ибраһимов белән шагыйрь Вакыйф Җәлалнең, янәсе, Ташкент вокзалында үлүләре турында бер хәбәр басылып чыга. Шул уңай белән Галимҗан Ибраһимов әлеге гәзитнең 1 март (51) санында Р. Ибраһимов хакында махсус мәкаләсен бастыра. Дөрес, аңа кадәр дә, 1920 елда ук Гатаулла Исхакыйның рөшди (урта) мәктәп-мәдрәсәләр өчен язылган «Әдәбият юллары» исемле дәреслегендә дә «Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов» дигән мәкалә басылган иде*[1]*.*


*Моннан соң Р. Ибраһимовның исеме вакытлы матбугат һәм басма китап битләреннән югала диярлек (сирәк кенә күренгән очракта да, ул гел тискәре яктан телгә алына иде). Нәкъ менә Р. Ибраһимов эшчәнлеге белән бәйле өлкәне һәм дәверне өйрәнүгә багышланган хезмәтләрдә дә аның исеме аталмаска тырышылды. Моңа мисал итеп М. Гайнуллинның 1983 елда чыккан «Татарская литература и публицистика (нач. XX в.)», Р. Г. Әмирхановның 1988 елда дөнья күргән «Татарская демократическая печать (1905-1907 гг.)» кебек хезмәтләрне күрсәтү дә җитә.*

*Яңадан бу күренекле шәхесебезнең исеме, безнең матбугатта 1990 елда гына искә алына башлады. 1990 елда «Казан утлары» журналының декабрь санында*

---

[1] Исхакый Гатаулла. Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов /*К.У.—1990.—№ 12.—180 б.*/

*Ж. Миңнуллин һәм Р. Мәрдәнов тарафыннан хәзерге әдәби телгә күчерелеп һәм матбугатка әзерләнеп, Гатаулла Исхакыйның «Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов» исемле мәкаләсе басылып чыга. Бер ай вакыт узгач, 1991 елда «Идел» журналының беренче санында Т. Әйдинең «Габдерәшид Ибраһимов» исемле публицистик мәкаләсе дөнья күрә. Бу хезмәттә Р. Ибраһимовның тормыш юлы тасвирлана һәм аңа тискәре мөнәсәбәт тууның, исеме онытылуының сәбәпләре турында да фикерләр әйтелә. 1992 елда «Мирас» журналында (8 сан) М. Мәһдиевнең «Тарихи кыңгыравык» дип аталган мәкаләсе басылып чыга. 1994 елда «Казан утлары»нда (5 сан) М. Госмановның «Котсыз еллар кайтавазы» исемле мәкаләсендә Риза казый Фәхретдиннең егерменче елларда төрле зыялыларга язылган хатлары, шул исәптән 1926 елның 7 мартында Р. Ибраһимовка җибәрелгән хаты һәм аның язылу тарихы тасвирлана.*




*«Себерияле мәшһүр сәяхәтче Габдерәшит Ибраһим» китабының тышлыгы*

*Р. Ибраһимовка багышланган хезмәтләр чит илләрдә дә дөнья күрә. Мәсәлән, 1997 елда Төркиядә И. Төрекуглы тарафыннан «Себерияле мәшһүр сәяхәтче Габдерәшит Ибраһим» исемле китап басылып чыга.*

*Ләкин бу хезмәт-мәкаләләр Р. Ибраһимовны өйрәнүгә нокта куймыйлар, ә киресенчә, яңа эзләнүләргә этәргеч булып торалар. Чөнки без югарыда атап киткән хезмәтләрдә күп кенә каршылыклар очрый. Мәсәлән, бер хезмәттә Р. Ибраһимовның туу елы дип 1850 ел, икенчесендә 1853, өченчесендә 1857 ел күрсәтелә, аның тормыш юлы, эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар арасында да төгәлсезлекләр очрый.*

*Шулай итеп, бу хезмәтнең максаты— Р. Ибраһимовның тормыш юлын, булган мәгълүматларга таянып, кыскача булса да, мөмкин кадәр дөресрәк яктырту. Шулай ук «Миръат» альманахы, «Дәүре галәм» сәяхәтнамәсе, «Автономия» дигән мәкаләләр циклын да исәпкә алып, аның сәяси карашларын, иҗтимагый эшчәнлек юнәлешләрен берникадәр ачыклау да күз уңында тотыла.*

## Рәшит Ибраһимовның тәрҗемәи хәле


Рәшит Ибраһимовның тәрҗемәи хәле турында мәгълүматлар шактый. Ләкин алар шул ук дәрәҗәдә буталчык та.

Рәшит Гомәр улы Ибраһимов, «Тәрҗемәи хәлем» исемле китабында үзе күрсәткәнчә, 1857 елның 23 апрелендә, Тубыл губернасының Тара өязендә дөньяга килә. Ибтидаи, ягъни башлангыч белемне Тарага якын урыс авылында ала. М. Мәһдиев исә, Р. Ибраһимовны тумышы буенча Бохарадан, ди. Дөрес, Себер татарлары арасында шундый төркем булган, аларны «бохаралылар» дип йөрткәннәр. Әмма аларны үзбәк яки таҗик дип карау дөрес булмас, шулай ук Р. Ибраһимов үзе дә Бохарадан килмәгән. «Бохаралылар» дигән атама Р. Ибраһимовның XVII-XVIII йөзләрдә Урта Азия якларыннан күчеп килгән ата-бабаларына бирелгән (Ибраһимов Р. Сибирия мөселманнары *//Миръат:—1903.—№ 17.—20-22 б.*). Соңгы дәвер бохаралыларның татарлашкан булулары, бу мәсьәләнең белгечләре күрсәткәнчә, инде шик тудырмый[1].

---

[1]Валиев Ф. Западно-Сибирские татары во второй половине XIX - начале XX вв.: Ист.—этногр., очерки.—Татар. кн. изд., 1980.—232 с.

Укырга-язарга өйрәнгәч, Рәшитне Казан артындагы (хәзерге Арча районы) Кышкар мәдрәсәсенә җибәрәләр. Монда ул егерме яшенә кадәр шәкерт була. Берникадәр белем туплаганнан соң, иптәш шәкертләре белән Урта Азия якларында, казакълар арасында белем таратып йөри, «кардәш халык балаларын хәреф танырга өйрәтә, олысын-кечесен дини һәм әхлакый тәрбияләүгә көчен сала, бер үк вакытта үзлегеннән укуын, тормыш тәҗрибәсен арттыруын дәвам итә»[1]. Шулай йөреп, бераз акча туплагач, туган җирләренә кайта, әмма монда озак тормый, гыйлемгә тартылган күңеле аны сәяхәткә чакыра. Ул 1877 елда, Истанбул аша Хиҗазга[2] сәфәр итеп, Мәдинә шәһәренә килеп урнаша. Монда дүрт ел буе ислам дине нигезләрен өйрәнүне дәвам итә, галимнәр, төрле илләрнең хаҗилары, фикер ияләре белән аралаша. 1881 елда яңадан Истанбулга барып, шунда төрек җәмгыятенең алдынгы вәкилләре белән таныша. Бирүдә ул мәдрәсәләрдә уку-укыту методикасын, программаларны үзгәртергә, дөньяви фәннәр укытырга кирәклеген аңлый, шул фикерләр белән туган иленә кайта. Тиз арада Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Ризаэтдин Фәхретдиннәр белән элемтәгә керә.



*Рәшит Ибраһим кызы Фәүзия Тогрул һәм шәкертләре белән. Токио.*

1892 елда Р. Ибраһимов Уфадагы Духовный собраниегә казыйлык хезмәтенә чакырыла. Мөфти Солтанов хаҗ сәфәренә киткәндә, аның вазыйфаларын үтәп тора[3]. Ел ярым казый булып торганнан соң, ягъни 1894 елда, ул, казыйлыктан китеп, Истанбулга бара. Монда ул Русия мөселманнарының милли-сәяси хәл-әхвәлләрен анализлаган, киләчәген фараз иткән, Диния нәзарәтенең хәлен, идарә формасын, аны үзгәртеп кору зарурлыгын аңлаткан «Чулпан йолдызы» дигән китап яза. Галимҗан Ибраһимов бу китапка мондый бәя бирә: «Чулпан йолдызы» исемендә тәртипсез, ләкин самодержавиягә каршы көрәш агитациясе белән җанып язылган китабын 95 нче елларда Стамбулда бастырып таратты. Бу татар дөньясының беренче эмигрантының беренче эмигрант әсәре. Бишенче ел революциясенә чаклы аңлы татарлар арасында, полиция ишетмәсен дип, колактан-колакка сөйләп, яшереп берберенә биреп укылган бердәнбер әсәрдер»[4].

1896 елда тагын Тарага кайтып, 1897-1900 елларда Р. Ибраһимов беренче ерак сәяхәтенә чыга. Истанбулдан Мисырга, Фәләстин һәм Хиҗазга бара, аннары Франциягә юнәлә, Италия, Австрия, Сербия, Болгария җирләрен узгач, ул Көньяк Русия аша Кавказга, аннан Каспий диңгезе яры буйлап Бохарага, Төркестан аша Җидесу өлкәсенә аяк баса, Себер кәрван юлы белән туган җире Тарага әйләнеп кайта. 1899 елда Петербургка барып, татарча гәзит чыгарырга омтыла. Ләкин моңа рөхсәт бирелми һәм Р. Ибраһимов «Миръат» (Көзге) исемле альманахны бастыра башлый. 1900-1903 елларда татарлар арасында көндәлек матбугат вазифасын үтәгән бердәнбер басма шул «Миръат» альманахы була. «Миръат»ның бары 22 саны гына чыгып кала. Анда яктыртылган мәсьәләләрнең чикләре бик киң һәм шул елларда «Миръат»ның

[1] Әйди Т. Габдерәшид Ибраһим /*Идел.— 1991. —№ 1.—30 б.*/

[2] Хиҗаз - Гарәбстанның көнбатышында Кызыл диңгез буендагы бер өлкә (башкаласы Мәккә шәһәре).

[3] Исхакый Гатаулла. Күрс.мәкалә—180 б.

[4] Ибраһимов Г. Әсәрләр. 8 томда, 7 т. /*Тарихи хезмәтләр 1911-1927.*/—Казан: Таткитнәшр., 1984. —267—268 бб.

бердәнбер даими чыга торган альманах булуын искә алсак, аның яшь буынны тәрбияләүдә, ана кызыклы мәгълүматлар бирүдәге әһәмиятен танымый булмый. М. Мәһдиев язуынча, Р. Ибраһимовның «Миръат»ы татар яшьләре өчен 1905 елга кадәр «өстәл китабы» булып тора.

Беренче рус инкыйлабы вакыйгаларыннан соң Р. Ибраһимов Петербургта үз басмаханәсен булдыра. 1905-1907 елларда «Өлфәт» (Дуслык) исемле татарча гәзит һәм «Әт-тилмиз» (Шәкерт) дигән гарәп телендә журнал чыгара башлый. «Өлфәт» гәзите тиз арада татар укучылары арасында дан казана һәм аның тиражы заманы өчен рекордлы санга житә—дүрт мең данә булып чыга. Әмма гәзит озак яши алмый, ел ярымнан соң хөкүмәт тарафыннан туктатыла. «Әт-тилмиз» дә тиздән ябыла. Шуннан соң «Өлфәт» урынына «Нәҗат» исемле җыентык-мәҗмуга чыгара башласа да, ул да бер-ике сан чыгып, шулай ук хөкүмәт тарафыннан ябыла. Шул елларда Рәшит казый үзенең бөтен карашларын мәйданга куйган «Автономия» дигән әсәрен яза. «Рәшит хәзрәтнең бу әсәре хәзерге көндә (1920 еллар—Ф. Г.) «федерация» ди торган барыбызның да сүз башы иде. Рәшит хәзрәт шул фикерне шундый кысык—Николай заманында ук чыгарган иде (ләкин ул заманда ул фикерне көлке генә санадылар)», дип яза аның турында Гатаулла Исхакый.

Р. Ибраһимов 1905 елгы инкыйлаб дулкынында милләттәшләрен оештыруга зур өлеш кертә. Ул рус кадетлары партиясендә төрки халыклар вәкиле вазифасын үти, «Мөселман иттифакы» партиясен оештыруда башлап йөри, аның корылтайларын үткәрүгә куп көч сала, партия идарәсе рәисе итеп сайлана.



*Рәшит Ибраһим балалары белән.*

Реакция дәвере башланып, гәзит-журналлар ябылгач, Р. Ибраһимов, басмаханәсен сатып, 1907 елның ахырында янә сәяхәткә чыгып китә, башта ул Көнбатыш Төркестан, Сәмәрканд, Бохара шәһәре һәм Җидесу өлкәсе аркылы туган ягына әйләнеп кайта. Монда ул озак тормый, гаиләсен Казанга алып килеп урнаштыра да, 1908 елның сентябрендә яңадан сәяхәткә китеп бара, юлда күргәннәрен яза, шулай итеп «Исламият дөньясы» яки «Дәүре-галәм» исемле сәяхәтнамәсе барлыкка килә. Әлеге әсәр берьюлы ике телдә—Казанда «Бәянел-хак» һәм Истанбулда «Сираты Мөстакыйм» гәзитләрендә басылып чыга. Шул хезмәте аша Р. Ибраһимов туган илендә һәм Төркиядә генә түгел, аннан ерак тарафларда да мәшһүр сәяхәтче булып таныла.

Р. Ибраһимов Япониядә 6-7 ай сәяхәт итә. Бу ил аны үзенең тиз арада көчәеп китүе белән кызыксындыра. Р. Ибраһимов монда да төрки халыклар, ислам дине турында мәгълүматлар бирергә тырыша. Хәтта мөселманлыкка өндәве дә монда артык ризасызлык тудырмый—японнарның кайберәүләре ислам динен кабул да итәләр. Әдип «Азия гекай», ягъни «Азияне саклау көче» дип исемләнгән мөселман җәмгыятенә нигез сала һәм аның башлыгы итеп мөселманлыкка күчкән, Әбубәкер исемен алган мәшһүр япон дипломаты Оһараны сайлап куя[1].

---
[1] Әйди Т. Күрс. мәкалә—32 б.

Р. Ибраһимов Төркиядә «Яшь төрекләр» хәрәкәте тарафдары була... Инде өлкән яшьтә булуына карамастан, Африкада һәм Балканда кабынып киткән сугышларда төрек гаскәрләренә рух бирер өчен бер фронттан икенчесенә бара. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Германиягә, Австриягә әсир төшкән мөселманнарны кайгыртырга керешә һәм аларның байтагын Төркиягә алып кайтуга ирешә. 1917 елда Истанбулдан, конференциягә дип, Стокгольмга чыгып китә. Монда бөтендөнья сугышын туктату мәсьәләсе каралырга тиеш була. Әмма төрле сәбәпләр аркасында конференция булмый[1]. Русиядә инкыйлаб башлангач, Р. Ибраһимов янадан туган җирләренә кайта. Якташы, сәнгать фәннәре докторы Мидхәт Булатов хәтерләвенчә, Тубылда һәм башка шәһәрләрдә, авылларда митинглар җыеп, татарларны тизрәк уяныргга, колония богауларын өзәргә, ирек яуларга чакырып кайнар нотыклар сөйли.

1922 елда, югарыда әйтелгәнчә, дөнья матбугатында: Р. Ибраһимов вафат булды дигән ялгыш хәбәр тарала. Исән Р. Ибраһимов Кытай чиге аша үтеп, Көнчыгыш Төркестанга барып чыга, уйгырлар, казакълар, татарлар арасында милли көрәшкә чакыру агитациясен алып бара.

Күпмедер вакыттан соң ул янадан Төркиягә күчеп китә. 1930-1931 елларда хаҗга барып кайта. 1933 елны, Истанбулдан чыгып, 1934 елда янә Японияге барып житә. Шунда ул үзе оештырган «Азия гекай» җәмгыятен җанландырырга керешә. Тырышлыгы бушка китми, Һиндстан, Малайзия, Индонезиядә аның эшчәнлеге кин яклау таба: бу илләрнең мөселманнары икенче бөтендөнья сугышында милли бәйсезлеккә ирешүдә мөһим адым ясыйлар.

Гомеренең соңгы елларында Р. Ибраһимов имам вазыйфасын башкара, үз эшен дәвам итәрлек шәкертләр тәрбияли. Ул 1944 елның 31 августында дөнья куя, кабере Токиода.

Р. Ибраһимовның «Мантыйк» тәрҗемәсе, «Чулпан йолдызы», «Галәме Ислам», «Әл-котбе әш-шимали», «Мең дә бер хәдис» тәрҗемәсе, «Тәрҗемәи хәлем», «Мохтәсәре тарихе гомуми», «Һәркемгә кирәк», «Вөҗдан мөхакәмәсе», «Мең өч сәнәлек назыйрә», «Гыйлме хале тыйбби», «Собах садыйк», «Доронкинга рәддия» һ. б. кебек гыйльми һәм әдәби әсәрләре бар. Әмма Р. Ибраһимов гыйльми һәм әдәби эшчәнлеккә караганда, сәяси эшләрне өстен күргән иде. Сәяси эшләрдә әйтәсе сүзен һич курыкмый әйткән, язган, сөйләгән. Менә шул сыйфаты өчен аны югары бәяләгәннәр, зурлаганнар. Безнең дә аны зур хәрефтән Шәхес дип атарга тулы хокукыбыз бар.

---

[1] Мәһдиев М. Тарихи кыңгыравык... / *Мирас.— 1992.— № 8.— 82 б.*/

*Җиңүнең 55 еллыгына*

## Зәет Мәҗитов

# ЙӨРӘК АША УЗДЫ СУГЫШ...

Еллар үтә тора. Ватан сугышы дип исемләнгән, Советлар империясенең барлык халыкларына хисапсыз афәтләр, кан һәм күз яшьләре китергән олы сугышның тәмамлануына да илле биш ел тулып килә. Билгеле, инде хәзер сугыш өермәсе алып килгән хәрабәләр дә, тән җәрәхәтләре дә онытыла төшкәндер... Ихтимал, җиңү шатлыгы да инде моннан илле еллар элек кичергән дәрәҗәдә түгелдер. Аннары, ул кайгы-шатлыкларны үзләре кичергән кешеләрнең дә күбесе инде дөньяда юк бит.

Әмма шул елларның онытылмый, җуелмый, тузмый торган, сугыш мәхшәрен генә түгел, миллионлаган кешеләрнең җанын, йөрәк тибешен мәңгелеккә беркетеп калдырган шаһитлар бар. Әйе, алар күп! Алар—карлы-бозлы, ут-ялкынлы окопларда, землянкаларда иҗат ителгән шигырьләр. Беләм, безнен хәзерге Ходай каһәрләгән заманда ул бәһаләп бетергесез хәзинәләрне дә этеп-төртеп йөртүчеләр юк түгел. Ләкин чын җәүһәргә-көмешкә—тутык-тап иярәмени?

Тутык-тап төшми торган рухи хәзинәләрне иҗат итүдә, әлбәттә, фашизм чумасына каршы көрәшкә күтәрелгән бөтен дөнья халыкларының иң атаклы язучылары һәм шагыйрьләре дә, композиторлары һәм рәссамнары да, артистлары һәм сүз осталары да катнашты. Кояшның кояш булып калуы өчен, Ирек һәм Киләчәк өчен каннарын һәм җаннарын кызганмый көрәшүчеләр сафында алгы рәтләргә баскан татар шагыйре бүген дә калку сыны белән пьедесталда тора. Юк, мин биредә татар шагыйре дип Муса Җәлил яки Фатих Кәрим кебек аерым исемнәрне генә әйтмим, сугыш елларындагы татар шигъриятен тудырган барлык шагыйрьләребезнең җыелма сынын күз алдында тотам. Олы сын бу, бөек Шигърият сыны!

«Фронт сызыгындагы сугышчының көне ничек үтсә, минем дә көнем шулай үтә. Кай вакытларда шундый янарга-пешәргә туры килә, гимнастеркалар тозланып ката. Шул шартларда табылган вакытны иҗатка багышлыйм»—дип язды Фатих Кәрим фронттан җибәргән бер хатында. Тозланып каткан гимнастерка кесәсендә йөргән блокнотларга язылган шигырьләр йөрәк каны белән сугарылган, шуңа күрә халыкның үз сүзенә әверелгән мәңге тутыкмас җәүһәрләр иде. Халыкның үз сүзе булып, йөрәк авазы белән яңгырау—сугыш чоры шигъриятенең төп һәм иң күркәм сыйфаты. Шигърият баштарак фашизмга каршы бердәм күтәрелергә чакырган декларация рәвешендәрәк булса да, алга таба ул гаҗәеп олы җанлы, шигъри мөмкинлекләрнең бөтен төсләре һәм аһәңнәре белән балкыган югары сәнгатькә әверелә, ил азатлыгы өчен көрәшүче миллионнарның рухи дөньясын үзенә сыйдырган бөек шигърият булып күтәрелә. Шагыйрьнең йөрәк канына манчып язылган ялкынлы сүзе тиз арада укучыларның, окопташларның да йөрәгенә барып ирешә, көч бирүче рухи юлдашка әйләнә.

Әйе, шигъри сүзнең абруе искиткеч зур иде. Хәтта меннәрчә гади кешеләрнең фронтка язган һәм фронттан алган хатларында да җыр һәм шигырь зур урын биләде. Тагын шуны бүген шатланып әйтәсе килә: сугыш китергән кәгазь кытлыгы шартларында да Татарстан китап нәшрияты күп санлы шигырь китаплары чыгарып бүген дә мактауга лаек эш башкарды. Утлы елларда чыккан шигырь китаплары арасында Муса Җәлилнең «Тупчы анты», Салих Батталның «Илем—анам», Әхмәт Исхакның «Ант», Фатих Кәримнең «Моң һәм көч», «Мәхәббәт һәм нәфрәт», Шәрәф Мөдәррискең «Тупчы Ваһап» , Әхмәт Фәйзинең «Давыл җырлары», Әхмәт Ерикәйнең

«Казан сөйли», Кави Нәҗминен «Атакага», Мәхмүт Максудның «Үч һәм нәләт жыры», Нур Баянның «Өч бөркет», Шәйхи Маннурның «Җинүчеләргә сәлам» кебек җыентыклары бар. Шигырь төрле фронтларда татар телендә чыккан фронт газеталарында, сугыш елларында да чыгудан туктамаган бердәнбер әдәби журналыбыз «Совет әдәбияты» битләрендә бик теләп бастырылды. Бу игътибар татар шигъриятенең көчле тавышын ерак ишеттерергә ярдәм итте, аның яңа шигъри биеклеккә күтәрелүенә җирлек булды. Әмма татар поэзиясенең гөрләп үсүенә китергән төп чыганак, әлбәттә, халкыбызның рухи халәте белән бәйле иде.

Шуңа күрә дә шигырьләрдә лирик герой, әсәрдән әсәргә төрле яклары белән ачыла барып, бай рухи дөньялы, тирән кичерешле, кешелекле һәм олы ихтыярлы татар кешесе булып күз алдына баса.

Татар шагыйрьләре төрлесе төрле фронтта сугышып, солдат тормышының күп якларын шигъри сурәтләделәр. Ул әсәрләргә карап татар солдаты үткән фронт юлларын гаять ачык күз алдына китерергә һәм күрергә мөмкин.

Теге яки бу шигъри әсәрнең кайчан, кайда, нинди шартларда язылуын белү, әлбәттә, кызыклы. Менә, мәсәлән, Ш. Маннурның «Еллар моңы» җыентыгындагы шигырьләр үткән юл. «Нинди төннәр» шигыре—май, 42 ел, Брянск фронты, «Балама»—август, 42 ел, «Чәчәкләр һәм снарядлар»—Белев, 1942 ел, «Көтеп алган шатлык»—Калинин фронты, октябрь, 42 ел, «Кояш байшына»—февраль, 44 ел, Островляне авылы, «Җиңү балдагы»—август, 1944, Көнбатыш Белоруссия—Литва, «Язмыш мине кая чөерсә дә»—ноябрь, 45 ел, Лихтенһоген, «Торасың син күзләремә карап»—март, 45, К. Пруссия, «Янасың син»—апрель, 1945, Кенигсберг һәм, ниһаять, «Май төне»—9 май, 45 ел, Гроссбау, дип күрсәтелгән. Шул формада «паспортлау» сугыш беткәнче дәвам иткән.

Яки менә Ш. Мөдәрриснең «Җыр үткән юл» җыентыгындагы кайбер шигырьләрнең паспортына күз салыйк.

«Үстем синең юмарт кулларыңда»—Казан, февраль, 1942; «Күп булса да йөрәк ялкыннарым»—Свердловск, июнь, 1942; «Туган халык, берек батыр сафка»—Сталинск, июль, 1942; «Омтыл, иптәш, һаман көнбатышка»—Төньяк-көнбатыш фронт, июль, 1942; «Хат яз, диген»—Селигер күле, декабрь, 1942 һ. б.

Шул рәвешчә солдат-шагыйрь үткән юл төрле шагыйрьләр тарафыннан тудырылган монументаль юлъязма һәм елъязма шигърият булып тарихка керде.

Сугыш чоры татар шигъриятенең төп сыйфатлары турында сөйләгәндә тагын шуны истә тотарга тиешбез: ул үзенең тирән тамырлары белән татар халкының фронтта һәм тылда күрсәткән батырлыкларына тоташа. Гасырлар буе азатлык өчен көрәшкән татар халкы Бөек Ватан сугышы елларында үзенең батыр һәм фидакарь халык икәнен уннарча мәртәбә арттырып раслады.

«Совет халкы,—дип язды маршал Конев,—гадел, азатлык сугышы алыр бара, моны аңлау сугышта геройлар тудыра. Геройлык масса төсендәге күренешкә әйләнде. Татарстанда туган сугышчылар да арсланнар кебек сугышалар.»

Маршал Р. Малиновский исә болай диде: «Мин, карт солдат буларак, сугыш кырларында татар сугышчыларын һәм офицерларын күп күрдем һәм аларның сугышта какшамас ныклык күрсәтүләренә һәм корыч ихтыярларына һәрвакыт сокланып киләм. Советлар Союзының бәйсезлеге өчен алып барыла торган бөек көрәшебездә татар халкы үзенең сугыш эшендә чыдам һәм батыр солдатлары белән бөтен армиябез каршында хөрмәт казанды.»

«Советлар Татарстаны,—дип язды маршал Л. Говоров,—немец-фашист илбасарларга каршы чын патриотларча кыюлык һәм фидакарьлек белән көрәшкән фронтовик уллары белән горурланырга хаклы.»

Татар халкының гасырлардан килә торган батырлык традициясендә тәрбияләнгән шагыйрьләр сугыш кырларындагы көрәшчеләрнең йөрәгенә тиз юл таптылар, солдатның күңел түрендә саклаңган уй һәм хисләрне дә, аның дошманга каршы көрәштә үзен ничек тотуын да бөтен йөрәкләре белән сизделәр, күңел күзләре белән күрделәр. Шуңа күрә солдат йөрәгендәге моңны һәм сагынуны да, шатлык һәм җорлыкны да гаҗәеп көч белән әйтеп бирделәр.

Беренче шигырьләр сугыш башланган көнне үк язылды. «Кызыл Татарстан» газетасының 24 июнь санында аларның берничәсе басылып та чыкты. Әхмәт Фәйзинең «Һәркем үзенең көчен барласын», Гадел Кутуйның «Коммунизм өчен»,

Кави Нәҗминең «Фашизмга үлем», Салих Батталның «Хаклык бездә! Җиңү безнеке!» шигырьләре иде алар.

Фашистлар башлап җибәргән сугыш беренче әсәрләрдә илебезнең тыныч тормышына каршы куела.

Завод моржаларын алсулатып
Аткан чакта сызылып алсу тан,
Көндәгечә тыныч хезмәт белән
Шаулаганда безнең киң Ватан,
Көндәгечә колхоз кырларында
Башланганда шундый кызу эш
Котырган эт—Гитлер безгә каршы
Сугыш ачты. Ләкин бу сугыш
Үз башына булыр ул этнең,

- дип язды Кави Нәҗми «Фашизмга үлем» шигырендә.

Шагыйрьләр беравыздан фашизмның явыз ие барып чыкмаячагы, безнең хак эшебезнең җиңәчәге турында җырлыйлар. Бу әсәрләр, чыннан да, халыкны бердәмлеккә чакырды, изге көрәшкә күтәрелергә өндәде:

Сугышка, иптәшләр, сугышка!
Халыклар, басыгыз сафларга!

*(Ә. Ерикәй, «Сугышка, иптәшләр!»)*

Беренче чор әсәрләренә хас аһәңнең иң көчлесе—ант сүзе. Муса Җәлил «Тупчы анты» шигырендә дошманга булган тирән нәфрәтне халыкның җанлы сөйләм телендәге каһәрләү сүзләре белән белдерә:

Ялкын телең белән әйт Гитлерга
Хөкеменне, тубым, үкереп,
Хәшәрәтнең битенә бу халыктан
Булсын соңгы утлы төкерек.

Тупчы үз ядрәсен фашист көтүен теткәләп очыручы яшен итәргә ант бирә. Һәм бу бик табигый, ләкин гаҗәеп зур ныклык белән әйтелгән ант булып яңгырый. Ант сүзе, сугышның беренче айларында яңгырый башлап, 1942—1943 елларга тагын да көчәя. Ф. Кәримнең 1942 елгы «Ант» шигыре—шуның матур үрнәге.

Көчле яңгыраган аһәңнең икенчесе—дошманга каршы изге көрәшкә киткәндәге саубуллашуны сурәтләү. Ш. Маннурның «Саубуллашу җыры», Г. Кутуйның «Озату җыры», М. Садриның «Саубуллашу җыры», Ә. Исхакның «Озату», «Сугышчылар җыры», К. Нәҗминең «Озату» шигырьләрендә бу аһәң гаять көчле булды. Болар арасыннан К. Нәҗминең «Озату» шигыре халык җырына әйләнеп китә. Шигырь инде чын мәгънәсендә дошманга каршы көрәш коралына тиңләшә. Шигырьнең олы көрәшкә чыгуын гәүдәләндереп М. Җәлил «Әйдә, җырым» шигырендә:

Җырым, синдә минем гәүдәләнде
Илне сөйгән йөрәк тибешем,
Җырым иде антым:
Яшәсәм дә,
Үлсәм дә тик туган ил өчен!—

дип белдерә. Җыр—шагыйрьнең анты. Аның җыры халык назы белән сугарылган һәм җимешләнгән. Аның җыры—туган җирнең чишмәсе төсле. Фашистлар шушы җыр иленә басып кергәннәр. Шуңа күрә:

Җырым утын корыч сөңге итеп
Мин күтәрдем хәзер кулыма.


Шул елларда күтәрелеп чыккан һәм тиздән күренекле шагыйрь булып танылып киткән Шәрәф Мөдәррис тә җырның сугышчан көченә зур әһәмият бирә. 1941 елгы «Башланды» шигырендә ул үз җыры алдына зур таләпләр куя:

Эх, сөйлә, жыр, фронт хакыйкатен,
Көнебезнен чорга тиңлеген,
Йөз ел белән—эпос вакыйгасын,
Ун сүз белән—роман киңлеген.

Жыр фронт хакыйкатен чагылдырырга, сугыш чорының бөтен вакыйгаларына үтеп керергә, аны тирән һәм тулы итеп гәүдәләндерергә тиеш.

Шулай итеп сугышның беренче көннәрендә үк поэзия зур жаваплылык тойгысы белән сугарылды. Бу яктан ул публицистика белән тиңләште.

Менә инде 1942 елның хәвефле язы да үтеп бара... Фашистларның тәкәббер шапырынуларын Мәскәү янында беренче тапкыр хурлыкка калдырган, безнең һөжүмнәр сүрелгән вакыт бу. Көньяк фронтта, Сталинград һәм Кавказ юнәлешендә гитлерчылар кабат инициатива яулауга ирешә. Куркыныч яңадан куера. Һәркемгә ачык: сугыш әле озакка сузылачак, сугыш әле яңа корбаннар сорый.


*Фатих Кәримнең фронтта язылган «Газиз әнкәй» шигыренең кульязмасы*

Шушы көннәрдән—1942 елның май-июнь айларыннан—поэзиянең сугыш чоры үсешендәге икенче баскыч башлана. Шигырьләр күп төрләнә, тармаклана. Үзәк урынга фронт вакыйгалары һәм солдатның дошман белән бугазга-бугаз килешкән жирдәге батырлыгы, уе-хисе калкып чыга. Фронт тормышы (нәкъ менә тормышы) бөтен тулылыгы, драматизмы, катлаулылыгы һәм авырлыгы белән чагыла башлый. Шунысы әһәмиятле: бу үзгәреш, яңа сыйфат сикереше аерым шагыйрьләр ижаты өчен генә хас булмыйча татар шигъриятенең төп осталарына тулысынча хас. Тагын шуны аерып әйтәсем килә: сугыш башында әледән-әле телгә алынган Сталин исеме шигырьләрдән бөтенләй диярлек төшеп кала. Шигърият шәхес культы өрәгеннән арына. Бу, һичшиксез, зур казаныш. Моабит тоткынлыгында ялкынлы шигырьләр язучы Муса Жәлилдән башлап давыллы сугыш юлларын кулына корал тотып узган Фатих Кәрим, фронтның төрле шартларында язган Гадел Кутуй, Әхмәт Фәйзи, Шәйхи Маннур, Шәрәф Мөдәррис, Әхмәт Ерикәй, Гали Хужиев, Сибгат Хәким, Әхмәт Исхак һ. б. шагыйрьләр ижатында инде бу исемне очратуы кыен.

Фатих Кәримнең «Соңгы тапкыр карыйм Иделгә» шигыре (1942, март), мәсәлән, татар поэзиясенең сугыш чорындагы яңа сүзе, публицистик декларациянең, фикерләрне турыдан-туры, «кычкырып әйтүнең» гомерен кыскарткан шигырьләрнең берсе иде.

Соңгы тапкыр карыйм Иделгә,
Соңгы тапкыр күрим акканын,
Бәлки бик тиз кире кайтмамын,
Сакланыр ул бары күңелдә.

Яз килүенә ышану, кыр казлары, иркен болыннар, назлы аккош моңы турында искә алулар шигырьдә газиз туган жир рәсемен тудыра. «Кыр казлары язын кайткан кебек без дә кайтырбыз». Жиңүгә, кайтуга ышаныч шундый сурәтле телгә күчә.

1942 ел язында Ф. Кәрим, солдатның фронтка китүен сурәтләгән берничә шигырьдән соң, фронт вакыйгаларын, солдатның сугыштагы хисләрен гәүдәләндерүгә багышланган шигырьләр язуга күчә. «Дусларга» шигырендә үк инде без шагыйрь белән фронт эченә килеп керәбез:

Артта калды куе, киң урманнар,
Тау, елгалар, шәһәр, авыллар...
Тәтәп торган кырның окоплары
Серле генә каршы алдылар.

Шушы юллардан бөек сугышның Ф. Кәрим каләме белән язылган шигъри елъязмасы башлана. «Бездә яздыр» шигырендә ул ике дөньяны: немецлар таптаган жирләрне һәм Туган илебезнең тыныч жирләрен чагыштыра:

Бездә хәзер ямьле яздыр, иркәм,
Көн кояшлы,төннәр айлыдыр,
Идел буендагы бакчаларда
Сыерчыклар ярсып сайрыйдыр.

Ф. Кәримнең шигъри сиземләү, сурәткә эчке мәгънә салу көченә сокланмый калу мөмкин түгел. Идел буендагы сыерчыклар «ярсып сайрыйдыр», ә фашистлар таптаган жирләрдә «күңел өчен бер генә кош та юк».

Төрле фронтларда сугышып йөрүче һәм ижат итүче шагыйрьләрне бер уртак сыйфат берләштерә: алар барысы да ялкынлы сүзнең бүген, хаклык өчен сугышучыларга кирәклеген, аның бөтен йөрәк белән, чын иптәшләрчә әйтелгән сүз икәнен беләләр.

Алыйк Шәйхи Маннур шигырьләрен. Сугыш вакыйгаларында актив катнашкан, күп фронт юлларын үткән Ш. Маннурның төп герое—фронтовик, ил азатлыгы өчен сугышып йөрүче. Бу лирик геройның уй һәм фикерләре шагыйрьнең сугыш елларында ниләр өчен борчылып, ниләр өчен шатланып, ниләр кичереп йөрүен дә төшенергә мөмкинлек бирә. 1942 елның августында язылган «Балама» шигырендә, мәсәлән, ул бала йөзендә чәчәк кебек нәфис, назлы, саклауга һәм сөюгә мохтаж иң кадерле зат күрә.

Шуңа да аңа балалар кадерле, чәчәкләр якын, жирдәге һәр тереклек изге. Дошманнын ерткычлыкларына нәфрәт көче мәхәббәтнең дә олылыгы белән бәйле. Лирик герой өчен изге булган нәрсәләр—халык өчен дә изге. Балаларны сурәтләгәндә шагыйрьнең тавышы да йомшак, нәфис яңгыраш ала, күңел нечкәргәндә чыга торган күкрәк тавышына әверелә:

Ерак юллар буйлап үткән чакта
Кошлар тавышын тыңлап барсам да,
Бөреләнеп, яна чәчәк аткан
Яшь гөлләрне өзеп алсам да,—
Искә төшә кинәт бәгърем-балам,
Күз алдыма килә елмаеп.
Сагынып уйлап, ялгыз жырлап алам,
Чәчәкләргә карап, моңаеп.

Дошманга нәфрәт хисләрен белдерүче ачулы сүзләр дә, ялангач лозунг рәвешендә булмыйча, сөйгән баласын сагынучы солдатнын жан ачысы булып яңгырый:

Мин кайтырмын, балам, тиздән-тиздән,
Син көтеп тор сагынып үткәнне,—
Сөрик кенә изге жиребездән
Каһәр суккан шашкан этләрне.

Шигырьдә зур гуманистик фикер олы хис белән берләшкән. Бер үк вакытта хиснең драматизмы да тирәнәя.

Туган илдән куып дошман көчен
Мин кайтырмын, гөлем, сау булсам,
Син корал тот һәм ал үткән үчен,—
Мин сугышта әгәр егылсам.

Дошманнан гадел үч алучы кешенең эчке дөньясын төрле яклап ачу—поэзиянең казанышы. Шагыйрь-солдат күзләре окопташларынын тормышындагы һәр адымны искәреп, һәр батырлыкны күңеленә теркәп бара иде. Шуңа күрә дә окоп поэзиясе—ул барыннан да элек солдат поэзиясе, солдат батырлыгының кыйммәтле шигъри эпопеясы.

Шагыйрьләр совет сугышчысы йөзендә бөтен жаны-тәне белән тормышка, туган жиргә, дөньяга, яшь буынның тууына, кояш чыгуына, тын күлләрдә йөзгән аккошларга гашыйк олы жанлы һәм нечкә күңелле, әмма кирәк чагында ир йөрәкле һәм сабыр була торган, салкын үлемнең үзеннән дә курыкмаган кешенең реаль,

табигый образын сурәтләделәр.

Ф. Кәрим әле 1942 елның язгы айларында ук «Дусларга» шигырендә: «Сугыш сугыш инде, рәхимсезлек ия булып йөри күнелгә», дип язды. Әмма бу рәхимсезлек совет солдатының тупаслануы, кыргыйлануы дигән сүз түгел иде. Киресенчә, бу хис солдатның көн саен, сәгать саен үлем белән күзгә-күз очрашып торуына карамастан, каушамавын, ил каршындагы бурычын үтәүдә нык торуын күрсәтә иде. Ш. Мөдәрриснең 1942 елгы «Парчалар» циклыннан бер шигырьгә күз салыйк:

Күп булса да йөрәк ялкыннарым,
Чит-ят жиргә чәчәр жылым юк.
Үтсәм дә мин кургаш янгырларын,
Сыкранырга туган жырым юк!

Күп гаять тә йөрәк түрләремдә
Дус ишемә рәхим-шәфкатем,—
Ялкын булып ярсый күкрәгемдә
Дошманнарга каршы нәфрәтем.

Парчаның шушы строфасы «күнеленә рәхимсезлек ия булып йөргән» солдатның нәкъ менә «гаять тә күп рәхим-шәфкатьле» кеше икәнлеген ача да. Кайсы гына шагыйрьнең бу елларда язылган нинди генә шигырен алма, шушы олы кешелек хисе гәүдәләнер. Шигырьләрдә солдатның бөтен рухи дөньясы ачыла. Солдатны без хәзер дошманга каршы һөжүмгә ташланганда да, землянкада авыр сугыштан соң ял иткәндә дә, туган жирен, анда калган сөекле кешеләрен сагынып жырлаганда да, моңайганда һәм шатланганда да, шикләнүле уйларга батып йөрәге әрнегәндә дә күрәбез.




*Муса Җәлилнең Моабит төрмәсендә ясаган куен дәфтәрләреннән берсенең тышлыгы*

Солдат образын иң тулы ачкан шагыйрь татар поэзиясендә, һичшиксез, Ф. Кәрим булды. Аның лирик герое тормыш турында, яшәү һәм үлем турында, гомумән, кешенең яшәү мәгънәсе турында тирән уйлана, фәлсәфи югарылыктан торып фикер йөртә. Әгәр бу чорда Ф. Кәрим лирикасы барыннан да элек кай ягы белән аерылып торды дип сорасалар, икеләнмичә, интим хиснең, шагыйрь кичерешләренең һәм фикерләренең бөтен ил йөрәк тибеше белән берләшүе, дип жавап биреп булыр иде. Ф. Кәрим аеруча «Тимер һәм тимерче» балладасында, табигый—конкрет сурәтләүне гомумиләштерүче, эреләндерүче сыйфатлар белән оста берләштереп, солдатның калку сынлы образын бирүгә ирешә.

1942—1943 еллар поэзиясендә фронт вакыйгаларын һәм, гомумән, сугышта була торган күп төрле хәлләрне, күп төрле очракларны, көтелмәгән очрашу яки аерылуларны, разведкада күргәннәрне, һәлак булган кадерле иптәшләр белән саубуллашуларны һ. б. сурәтләү гаять киң колач ала.

Ш. Мөдәрриснең «Таныш кунак» (1942), «Землянкада», «Сукыр лампа» (1943), С. Хәкимнең «Хат» (1942), «Дуслар», «Иртән», «Урман», (1943), Ә. Исхакның «Ал гитараңны, сенел» (1943), Ш. Маннурның «Ял минутларында», «Йөрәк типкән саен дәшәм аңа», «Солдат моңнары» (1943), Ә. Ерикәйнең «Утыр, дускай, әзрәк серләшербез» (1943), Бари Рәхмәтнең «Сәлам хаты» (1943), Ә. Фәйзинең «Вагонда», «Фронт юлында» (1943) шигырьләре һәм башка күп санлы әсәрләр шундыйлардан иде.

Оригиналь һәм таләпчән шагыйрьләрнең берсе Әхмәт Фәйзи «Алдыбызда, дуслар, биеклек» (1942) дип башланган лирик шигырендә сугышчы «мин»нең яшәү һәм үлем, батырлык һәм куркаклык, тугрылык һәм нәфрәт турындагы карашларын үзәккә куя. Шунысы әһәмиятле: бу карашлар декларация булып яңгырамыйлар, алар «мин»нең кичерешләренә манчылган.

Чигенәм икән, миңа харам булсын
Ашым, суым, һавам—бөтенесе,
Чигенәм икән, минем газиз улым
Атасының йөзенә төкерсен!

Сугышны башыннан ахырына кадәр кичеп чыккан фронтовик-шагыйрь Гали Хуҗи шигырьләрендә дә:

Солдат булып кулга корал алдым,
Куркынычта илем язмышы,—
Һәр кайгыдан өстен шушы кайгым,
Һәр кайгыдан авыр һәм ачы,—

дип фикер йөртүче, Ватан язмышы хәл ителгәндә намус һәм җаваплылыкны байрак итеп яшәүче сугышчы—лирик герой образы үзәктә тора. Г. Хуҗиев шигырьләрен бергә җыеп укыганда, сугыш барган урыннар да, лирик герой—солдатның бу шигырьдәге хисләре нинди шартларда тууы да шактый тулы күз алдына килә. Моны шигырьләрнең астына куеп барган географик адреслар да тулыландыра. Барыннан да элек бу геройның татар халкы вәкиле, Идел буйларында үскән һәм яшәгән кеше булуын әйтергә кирәк.

Туып-үскән алтын бишегем син,
Җимешен, суын татлы;
Киләчәгем, өмет-сөенечем син,
Кояшың җылы, якты,—
*(«Туган җир»).*

дип мөрәҗәгать итә ул туган җиренә

Туган җир һәм Идел—икесе бер. «Идел, Идел» шигыренең соңгы строфасы лирик геройның Идел баласы булуын гаять җылы, шигъри яктан көчле итеп күрсәтә:

Минем хәзер синең язмышыңны,
Уйламаган көнем юк;
Кайтарырбыз язгы агышыңны,
Кояш шаһит, Идел—йорт!

Г. Хуҗиев шигырьләренә үзенчәлекле лирик яңгыраш бирә торган якның тагын берсе—һәр шигырьдә диярлек тылда калган сөйгән кешеләрне сагынып искә алу.

Уйна, дустым, гармуныңны,
Күңел дәрткә күмелсен,
Сагынуымның, януымның
Ялкыннары сүрелсен—

кебек юлларда («Гармун», 1942) бу хисләр халык җырларындагыча чын җылылык белән бирелә. Ләкин бу моң, бу сагыну һич тә өметсезләнеп өзгәләнү түгел. Моң—Г. Хуҗиев шигырьләрендә (һәм гомумән башка шагыйрьләр иҗатында да) туган җиргә булган мәхәббәт белән бәйле. Моң—солдатның кешелекле җанын, рухи байлыгын күрсәтүче тирән хис. Шуңа күрә дә:

Кемдә моң бар синдәгечә,
Синдә туган җир моңы,—

дигән юллар оптимистик рухта яңгырыйлар.

Шагыйрьләр кешелекнең явыз дошманына каршы көрәшүче саф һәм олы йөрәкле солдатның «вак сыйфатларына», «йомшак якларына» да күз сала. Кешене һәр яктан кеше буларак күрсәтү тенденциясе үзәк юнәлешкә әйләнә. Мин биредә сугыш елларында Ерак Көнчыгышта хәрби очучы булып хезмәт иткән С. Батталның поэзиясен күздә тотам. Шагыйрь, әйтерсең лә теманы үзегеннән түгел, ниндидер читкә чыгып торган җебеннән ача башлый. Һәм һәрвакыт ул җитди теманың да бер «кызыклы ягын» таба белә. «Казармада төн», «Юл капчыгы», «Берлинга һөҗүм», «Шинель», «Иптәшләрнең берсе хат яза», «Солдат хаты» шигырьләренең кайсын алып

карасам да, С. Баттал стиленең шушы ягын—теманы кызыклы бер яктан ачуын күрәм кебек. Менә «Юл капчыгы» шигыре:

Юл капчыгы сатып алдым
Бер магазинга кереп,
Чөнки тормыш юлда үтә
Чегән тормышы кебек.

Шигырь шундый «вак кына» бер мәсьәлә турында сөйләүдән башлана да әкренләп капчыкның «хикмәте» ачыла:

Күп юл үттем, капчыгыма
Каты сухари төяп.
Һәм тутырып кайткаладым
Якыннарыма бүләк.

«Ул капчыкта Арзамас суганнары, өзелеп сөю хатлары, биләүсәләр булып уза», ләкин, «Өзлексез төшми йөри тик шигырь дәфтәрем генә».

«Капчык башыннан үткән тарих» лирик геройның гомер юлын күз алдына бастыра, һәм:

Тагын юлга җыенамын,
Капчыгым тулып килә:
Үткән юлларыма карыйм—
Гомерем узып килә,—

«Капчык тарихыннан» үтелгән гомер турында сагынулы хисләр белән тулы җитди уйлану калкып чыга:

Кайтырмын әле дошманны
Сөйгән илемнән куып;
Авыр поход тузаннарын
Көмеш Иделдә юып.

Ләкин С. Баттал шигырьне шушы төп фикерне белдерүче строфа белән тәмамламый. Лирик герой монологының гомуми агышына яраштырып йомгаклаучы строфа китерә:

Кайтырмын. Юл капчыгымны
Әнием ямар әле;
Данлы юллар истәлеге
Булыр ул, ярар әле!

Юмор белән янәшә «капчык төбендә» сугышчы—шагыйрь йөрәге тибә, тормышка гашыйк, яшәү мәгънәсе турында җитди уйланучы кеше күңеле сурәтләнә. Бераз елмая төшеп сурәтләнгән юл капчыгы образы, фронт поэзиясендә урын алган каска, шинель, котелок кебек сүрәтләр белән бергә, солдатны табигый һәм җанлы итеп гәүдәләндерергә ярдәм итә.

Шушындый тирән гомумиләштерү ясаучы ассоциацияне без Ш. Маннурның сугыш елларында язылган иң уңышлы әсәрләреннән берсе—«Чәчәкләр һәм снарядлар» шигырендә очратабыз.

...Снарядлар төягән бер машина, яңгыр үткән юлдан килгәндә, үзән уртасына кереп бата. Ничек кенә шофер тирләсә дә, йөк кузгалмый, юлга түшәргә якын тирәдә һичнәрсә юк.

Хикәяләү бик гади, бернинди ялтырап торган сурәтләү чарасы кулланылмый кебек:

Тик бер оя шомырт, матурланып,
Ап-ак чәчәк белән киенгән.
Исертерлек хуш исләре аның
Бөтен үзән буйлап сибелгән.

Шау чәчәктә утыручы шомыртның гүзәллеге шоферны билэп ала:

Шул шомыртка таба китте егет,
Кузгалды аның нечкә хисләре

Һәм, гомерендә әүвәл күргән кебек,
Чәчәкләрне йотылып иснәде.
Исерде ул язның саф исеннән,
Гашыйк егет кебек сөйләнде...
Аерылалмый шомырт тирәсеннән,
Әллә ничә тапкыр әйләнде.

Шушы кыска мизгел, солдатның бер мәлгә чәчәкләргә гашыйк булып әсәрләнеп калуы аның олы кешелеклелеген, нечкә хисле күңелен укучы йөрәгендә уелып калырлык сурәт итеп җанландыра. Шушы бер мизгелдә солдатның философиясе дә, сугышларда йөреп сагыш белән тулган йөрәге дә күренә.

Сөйләнгән вакыйганың финалы драмадан гыйбарәт:

Әйләнде дә...
балта белән кырып,
Илтеп салды шиннар астына...
Һәм газ бирде, ике күзен йомып,
Карамаска теләп алдына.

Чәчәкләрне шытырдатып изеп,
Чыгып китте авыр машина...
Снарядлар өлгерделәр килеп
Һәм яудылар дошман башына.

Әйе, зур сугыш бара шул! Сугыш машинасы кешенең иң нәфис хисләренә ябырылган. Җину хакына, олы хакыйкать һәм якты хисләр хакына чәчәктәй гомерләрне корбан итәргә туры килә.




*Бер төркем фронтовик әдипләр. Алгы рәттә (сулдан уңга): Мөхәммәт Садри, Атилла Расих, Госман Бакиров, Сибгат Хәким, Нури Арслан, Әхмәт Исхак. Урта рәттә: Габдулла Шәрәфи, Хәй Вахит, Зәйни Шаһиморат, Нур Гайсин, Хатип Госман, Әхмәт Булатов. Арткы рәттә: Геннадий Паушкин, Әбрар Шамин, Сафа Сабиров, Мәҗит Рафиков, Ибраһим Нуруллин, Мария Елизарова, Нәби Дәүли, Тихон Журавлев.*

Солдат йөрәгенең олылыгын, хис тирәнлеген сокландыргыч шигъри көч белән гәүдәләндергән әсәрләр арасында мәхәббәт һәм сагыну турындагы шигырьләр бик күп. Чыннан да, Көнбатышка таба ераграк киткән саен солдат-шагыйрь күңелендә Туган җирне, анда калган кадерле кешеләрне сагыну хисе ялкынланып үсә. Сугышның инде бетеп килүен тою ул сагынуны искиткеч тирәнәйтә. Тизрәк туган җиргә, дуслар, туганнар янына кайтасы килә. Сөю, сагыну, тиздән житәчәк кавышу көннәре турында уйлану 1944—1945 еллар шигъриятендә мәхәббәт лирикасының күрелмәгәнчә чәчәк атуына китерде. Җиңү шатлыгын, дошманга нәфрәт ярсуын, сугыш фаҗигаләрен сурәтләгән ялкынлы әсәрләр белән бергә шигырь җыентыкларында, газета-журналларда тирән хисле, гаҗәеп нәфис моңлы мәхәббәт шигырьләре янәшә басыла иде. Болар сугышта сынау кичергән мәхәббәт һәм тугрылык көчен, ил кешеләренең иң саф, иң нәфис тойгыларга бай булуын раслаучы шигъри көзге иде. «Мәңгелек мәхәббәт китабына» дулкынландыргыч яңа сәхифәләр күп өстәлде һәм алар бүген дә төссезләнмиләр, чөнки иң тирән күңел серләрен җанландыралар.

Татар шигъриятендәге мәхәббәт һәм сагыну лирикасы аерым шагыйрьләрнең шәхси кичерешләрен чагылдырган интим әсәрләр җыелмасы гына түгел. Лирик герой мәхәббәтне дә, ил алдындагы олы бурычын да, чит җирләрне фашизм тырнагыннан коткаруны да бердәй дәрәҗәдә намус эше итеп карый. Шуңа күрә мәхәббәт шигыре белән иҗтимагый-политик мәсьәләләргә караган шигырьләр арасында сизелерлек аерма да юк төсле. Киресенчә, Туган илгә мәхәббәт һәм шәхси мәхәббәт, туган җирне сагыну белән сөйгән кешеләрне сагыну бер-береннән аерылгысыз. Сугыш чоры татар шигъриятенең өр-яңа һәм күркәм казанышы иде бу. Лирикабызның бу сыйфаты елдан-ел үсә бара, лиризм 1942-1943 елларда аеруча көчәеп, 1944-1945 елларда җиңү шатлыгы аһәңнәре белән бергә һәм бердәй яңгырый. Нур Баянның «Илем, сиңа» (1944) шигырендәге солдат, мәсәлән, Венгрия болыннарында ак чәчәкләр үпкән кызларның каш сикертүен күргәндә үз илен, үз Татарстанын, аның эшчән кызларын сагына:

Әллә дөнья шулай күренә микән
Бу йөрәкне сагыш басканга?
Карпат кыясына утырып җырлыйм,
Татарстан, йөрәгем янганга.

Туган илгә мәхәббәт, интим мәхәббәт кебек үк, көчле һәм тирән:

Бер ил дә юк безнең илебез күк,
Бер кайда юк матур кыз-кыркын,
Мин, валлаһи, чит ил кызларыннан
Су сорамас идем бер йотым.

Н. Баян шигырендәге сурәтләр Г. Кутуйның «Туган ил» шигыре белән авазлаш. Шагыйрь, «И туган ил, и матур ил, калдың бездән еракта» дип, Туган илен өзелеп сагына. Ул иленең шифалы һаваларын, учакларын, бәйрәмнәрен, «бер караудә гашыйк иткән зифа буйлы кызларын» уйлый. Сагындырган туган җиренең Г. Кутуйдагы сурәтләнеше халык җырындагыча нәфис һәм саф буяулар белән, чын шигъри музыкальлек белән бирелә. Сугышка кадәрге поэзиядә, мәсәлән:

Искә төшә кышкы көннәр,
Җем-җем иткән карларын,
Һәр аш саен кул күтәреп
Дога кылган картларын,—

кебек юлларны гайре табигый сурәтләү дип карарлар иде. Хәзер исә ул шагыйрь күңеленең нечкәрүен, хисләрнең тирәнлеген, сагынуның көчен күрсәтүче уңышлы сурәткә әверелә. Шигырьдә һәр сурәт кадерле Туган илнең гүзәллекләрен күрсәтә: «Киткән чакта эчкән суың тәме авызда минем», «И туган ил, и матур ил, Нур күмә калаларын».

Туган җир, туган туфрак, сөйгән яр, еракта сугышып йөрүче улына изге теләкләр теләп аның исән кайтуын көтүче ана, әтисен сагынып көтүче бала сурәтләре шигырьдә үрелеп баралар, гаҗәеп ягымлы аһәңнәр, нәфис бизәкләр белән биреләләр. Шулай итеп тыл һәм фронтның берлеге күңелләр берлеге белән беркетелә. Сугыш

башында, алда күргәнебезчә, озату һәм саубуллашу жыры булып яңгыраган бу аһәң сугыш барышында өзлексез көчәя, шигъри яктан бик тә тирәнәя, камилләшә һәм сугыш ахырына таба чын сәнгатьчә жырланган үзәк мотивларның берсенә әверелә. Әйтелгәннәрне мин сугышка кадәрге поэзиядә күзәтелгән «Мәхәббәт лирикасын кыерсыту» шаукымыннан хәзер тулысынча арынган М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Исхак, Г. Кутуй кебек танылган шагыйрьләр иҗатыннан да, Ш. Мөдәррис, Гиз-эль Габид, Н. Арсланов, З. Мансур кебек әле яшь буын вәкилләреннән дә дистәләрчә мисал белән раслый алыр идем. Хәзергә Ш. Мөдәррискә генә тукталам. Аның «Хат яз, диген» шигырендә лирик герой «сөеклесенең чәчен, күзен, битен үпкән җилдән:

> «Әй, гүзәл кыз, сәлам, йокың качыр,
> Иркәң жырын тыңла, тор!»—диген;
> «Сугышларда ул бер корыч батыр,
> Күнеләңдә ләкин моң!»—диген,—

дип үтенә.

Өлкәнрәк кешеләр хәтерлидер, бер заман тәнкыйтьтә моң сүзен гаеплиләр иде. Ләкин Ш. Мөдәррис ул сүзләрдән курыкмый. Аның сурәтләвендәге солдатның сугышлардагы батырлыгына моң комачауламый. Аның «Минем моңым» (1943), «Сөеклемнең алтын балдагы» (1944) кебек шигырьләрендә туган жиргә һәм андагы сөйгән ярга мәхәббәтнең, сагынуның солдатка көч бирүче моң булуы турында сүз бара.

Тирән сагыну һәм мәхәббәт хисләре белән сугарылган «Туган авыл» шигырендә Ш. Мөдәррис «Сагынмасам, чәчеп моңнарымны, мин бу кадәр эчтән янаммы»— дип туган почмагын, туган учак, туган анасын искә төшерә. Ләкин солдатның сагынуы көчсез, тар бер шәхси сагыш түгел. Аның йөрәгендә туган ил, туган авыл, ягымлы ана, бала, сөйгән яр, тыныч тормыш кебек изге сурәтләр сагыну тудыра. Шуңа күрә мин мәхәббәт һәм сагыну моңнары сугыш чоры татар лирикасының куәтен арттыручы зарури аһәңнәр булды дип саныйм.

... Без жиңдек. Бу жиңүдә бөтен халкыбыз белән бер рух, бер жан булып яшәгән һәм көрәшкән әдәбият-сәнгать кешеләренең дә өлеше зур иде. Татар шагыйрьләре, күргәнебезчә, явыз дошманга каршы көрәш сафына беренчеләрдән булып бастылар. Изге жирләребез туфрагына аларның да йөрәк каны тамды. Дошманның үз оясында тиңдәшсез гражданлык батырлыгы эшләп һәлак булган Муса Җәлилдән алып олы яу кырында тагын күп шагыйрьләребез башын салды. Алар арасында Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян, Демьян Фәтхи, Хәбра Рахман, Мифтах Вәдүт, Исхак Закиров, Касыйм Вахит, Әгъзәм Камал, Шамил Гәрәй, Мансур Гаяз, Исмәгыйль Шәфиев кебек күп талантларның якты исемнәре бар... Ә Абдулла Алиш, Рәхим Саттар, Гайнан Курмаш, Хәйретдин Мөҗәйләр, Җәлил шикелле үк, дошман тарафыннан җәзалап үтерелде.

Поэзия сугышта үзенең күп солдатларын югалтты, шагыйрьләр сафы сирәгәйде. Ләкин ул сугыштан жиңүче солдат кебек чыныгып чыкты. Бөек Ватан сугышы чорында бөтен татар әдәбияте, шул исәптән татар поэзиясе дә, яңа югарылыкка күтәрелде, бөек мәхәббәт һәм фашизмга ачы нәфрәт жыры булып яңгырады. Илебез өчен иң авыр елларда, Гитлер Германиясенең кара тәреле яуларына каршы көрәшкән солдатның ярсып типкән кайнар йөрәге ачылды. Бүген горурланып әйтә алабыз: шигърияттебез ул чакта халыкчан поэзиягә әверелде. Поэзиянең сугыш алды еллары белән чагыштырганда күпкә тирәнрәк булган халыкчанлашуы Ватан сугышы чорында зур казаныш булды.

Татар поэзиясе, үзенең сугышчан бурычын намус белән үтәгән солдат шикелле, зур иҗади фидакарьлек күрсәтте. Поэзия халыкның олы йөрәген бөтен дөньяга күрсәткән рухи көзге булды. Шуңа күрә утлы елларда язылган, чын шигъри ялкын белән сугарылган күп әсәрләр бүген дә тулы көчкә яңгырыйлар, төсләрен жуймыйлар. Ватан сугышы чоры поэзиясенең күркәм традицияләре бүген дә яши, көрәшә, яңа буын шагыйрьләр тарафыннан үстерелә.

*Сәнгать*

# БАЛЕТНЫҢ ШИГЪРИ ТЫЛСЫМЫ

## Король балеты патшасы

Интернет дөньяга хәбәр салган:
—Балет биючеләре һәм бу гүзәл сәнгатькә гашыйк затлар! «Ковент-Гарден» театры директоры кәнәфиендә кемне күрәсегез килә?

Лондонга фикер-теләкләр ташкын булып агыла. Төрле кыйтгалардан меңләгән җавап, меңләгән фикер килә. Анализ ясыйлар. Бу уңайдан мөнәсәбәтен белдергән кешеләрнең 37,7 проценты татар биючесе Ирек Мөхәммәтов исемен атый. Житәкче кәнәфиенә дәгъва тотучы күренекле шәхесләрнең бүтәннәре Иректән ике мәртәбә чамасы ким тавыш җыя.

Әйе, 1999 елның җәендә бу вакыйга балет дөньясын әнә шулай кузгатып, сискәндереп алган иде.

«Ковент-Гарден»га яңа директор быел ел ахырында куелачак. Асыл затларны яд итә белүче инглизләр, шөт, балет җәмәгатьчелеге фикеренә колак салмый калмаслар. Аннары Мөхәммәтов үзе дә мона каршы булмастыр, мөгаен. Яшь бара бит. Казанга кайткач, мин аның киләчәк планнарына бәйле кылларын чиертеп караган идем. Мона каршы Ирек Мөхәммәтов: «Мин—биюче, дөнья мине балетта таныды. Продюсер яисә директор була алырмын, дип уйлыйм. Балетмейстерлык минем кулдан килә торган эш түгел. Моның өчен балет сәнгате дөньясын бүтән төрле күрә белергә һәм аңа башка төрле талант кирәк. Миндә андый сәләт тә, сыйфат та юк»,—дигән иде ул чакта. Яңа гасырга кергәндә, өченче меңъеллыкны башлаганда теләге тормышка ашсын иде аның. Татар халкы мона шат булыр иде. Моның белән горурланыр иде.

Форсаттан файдаланып, «Ковент-Гарден»ның нинди рәк язмышлы театр икәнен ачыклап китик әле. Егерменче йөз уртасында дөньяның балет сәнгатендә өч мәктәп хакимлек итә башлый: русларныкы, французларныкы һәм итальяннарныкы. Гасыр ахырына таба Италия операсын да, балетын да дөнья дәрәҗәсендә тота алмый. Итальяннар балеты конкуренциягә түзми таркала. Моннан инглизләр бик оста файдаланалар.

«Ковент-Гарден»ның дөньяда иң зиннәтле һәм иң затлы театрга әйләнүе болай башлана. 1961 елның 17 июнендә 23 яшьлек Рудольф Нуриев, СССР гражданы булудан баш тартып, Франциядә кала. Бу хәл Ленинградның Киров исемендәге театры труппасы Париждан Лондонга очарга җыенганда аэропортта була. Шушы вакыйга тирәсендә шау-шу барган чакта Рудольф инглиз балетының йолдызы Марго Фонтейн белән таныша. Балерина Лондонда балет бию буенча Король академиясе башында тора. Фонтейн Рудольфне академиядә 2 ноябрьдә булачак гала-концертта катнашырга чакыра. Нуриев, әлбәттә, мона ризалык бирә. Татар егете Скрябин музыкасына язылган «Трагедия поэмасы»нда биеп бөтен Лондонны таң калдыра. Ниндидер шашкын, әкәмәт чыгыш була ул. Фантастика! Танылган хореограф Фредерик Аштон бу манзарадан тәмам «исерә». Аның карары катгый: Нуриев Король балеты труппасында булырга тиеш, фәкать ул гына дөньяны гаҗәпләндерерлек балет спектакльләрендә биергә сәләтле! Рудольф ярты елга Лондонга күчеп килә. Алар Марго Фонтейн белән сәхнәдә кеше күзе күреп ышанмаслык могҗизалар тудыралар. Итальяннар балеты таркалган бер чорда Нуриев катнашында «Ковент-Гарден» менә шулай дан-шөһрәт яулап туа. Шушы тиңдәшсез пар өчен Ашот үзенең иң гүзәл балет спектакльләреннән саналган «Маргарита һәм Арман»ны махсус куярга мәҗбүр була. Биюче маэстролар анда бөек композитор Лист

музыкасының тирәнлеген һәм нечкә назын үзләренчә, балет хәрәкәтләре ярдәмендә ачалар. Киемнәр Рудольф зәвыгыннан чыгып тегелә һәм бу спектакльгә яңа төсмер өсти, аның бизәлешен баета. Аннары «Гамлет прелюдияләре». 1976 елда «Ковент-Гарден»да аның бөтендөнья премьерасы була. Король театрының даны шушы балет белән балкый. Шулай да Нуриев—Фонтейн дуэтының дөньяны шаккаттырган спектакле булып Чайковскийның «Аккош күле» балеты исәпләнә. Ул дөньяның иң атаклы театрлары сәхнәләрендә күрсәтелә, татар һәм инглиз парының таҗ спектакле булып тарихка кереп кала. Венада «Аккош күле» тәмамлангач, тамашачы балет талантларына «үз спектаклен» күрсәтә: аягүрә басып 40 минут дәвамында туктаусыз кул чаба, шушы вакыт эчендә пәрдә 89 мәртәбә ачылып ябыла!!! Театр сәнгатенең бер генә төре дә мондый хәлне күргәне булмаган, ул Гиннес китабына театрларда кул чабу рекорды булып теркәлгән. Нуриевның «Ковент-Гарден»ны данга күмгән тагын бер гамәлен әйтеп үтим әле. Венаның шул ук опера театрында ул Чайковскийның «Йокыга талган гүзәл»ен сәхнәгә куя. Нуриевның режиссер буларак та таланты ачыла. Бу спектакльне кую 2 миллион долларга төшә һәм бүгенге көнгә кадәр ул дөньяда иң күп чыгым тотып күрсәтелгән балет булып санала.

Король балетының триумф-тантанасын Рудольф Нуриев әнә шулай тәэмин итә һәм чын мәгънәсендә аның биюче патшасы булып таныла.

Рудольф Нуриевның биюен киноларда гына күргәнем бар иде. Шулай да барлык чорларның даһи биючесе белән очрашып сөйләшү бәхете тәтеде үземә. Ул болай булды. Гомеренең соңгы елларында мәшһүр биюче дирижерлык итүгә күчте һәм сәнгатьнең бу өлкәсендә дә талантының зурлыгын раслады. 1992 елның маенда Казанга кайткан иде. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрында 21 май кичендә Чайковскийның «Щелкунчик» спектакле куелды. Оркестрга Рудольф Нуриев дирижерлык итте. Ул кичтә безнең театр нур белән тулды, һәр тараф балет бию патшасы сәнгатенең ялкынлы һәм сүнмәс-сүрелмәс нуры белән балкый иде. Әнисе Фәридә ханым туган җирдә татар тамашачысы белән очрашкан кунак артист моңа гаять шат иде. Икенче көнне Нуриев журналистлар белән очрашты. Җәлил театрында ел саен үтә башлаган халыкара классик балет фестивален үз исеме белән атарга рөхсәт бирде.

Матбугат конференциясендә һәм аннан соң да мин аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать иткән идем һәм җавапларын куен дәфтәремә теркәп куйдым.

—Димәк, Рудольф әфәнде, биюне ташладым, дисез инде. Кайчан булды бу хәл?

—Сигез ай чамасы элек.

—Ә дирижерлык эше белән шөгыльләнүегез ничек башланды?

—Язмыш үз кулында бит. Йә өйдә утырасың, йә талантыңны башка юнәлештә сынап карыйсың. Мин дирижерлык эшен сайладым. Бервакыт Парижда «Гранд-Опера»да биегәндә атаклы дирижер Герберт фон Караян белән сөйләшеп утырган идек. «Син, Рудольф, дирижер булырга тиешсең, дирижерлар биючеләрдән озаграк яшиләр»,—дип шаярткан иде ул әлеге әңгәмә вакытында.

**(Юраганы юш килде шул. Нуриев Казаннан киткәндә бераз авырыбрак тора иде һәм шуннан соң озак та яшәмәде. 1993 елның 6 гыйнварында Парижда аның йөрәге тибүдән туктады).**

Король балетының янә икенче бер патшасы да татар егете—Ирек Мөхәммәтов. Ул 1960 елның 8 мартында Казанда Рәшидә һәм Җәүдәт Мөхәммәтовлар гаиләсендә икенче малай, төпчек бала булып туа. Әнисе—укытучы, әтисе—инженер. Биш яшеннән Казанның Ленин районындагы Пионерлар йортына, хореография түгәрәгенә йөри. 1967-1970 елларда Казанның 122 нче мәктәбендә укый. Ун яшеннән—Мәскәү, Академия хореография училищесы. Аны тәмамлагач, 1978-1981 елларда Мәскәү классик балет ансамбле солисты. 1981-1998 елларда ССР Союзының Зур театрында бии һәм шул дәвердә дөньякүләм дан алып таныла. 1981 елда балет артистларының Мәскәүдә үткәрелгән IV халыкара фестивалендә Гран-при бүләген ала. Анда 23 илдән 126 биюче катнашкан була.

1990 ел җәендә Ирек Мөхәммәтов Лондонга күчеп китә һәм «Ковент-Гарден»да баш солист булып бии башлый. Шушы уңайдан аның иҗатындагы кайбер истәлекле вакыйгаларны хәтергә төшереп үтү урынлы булыр кебек. 1986 елда аңа РСФСРның атказанган артисты исеме бирелә. Совет илендә Ирекнең хезмәтенә бирелгән иң зур бәя менә шул. 1986 һәм 1990 елларда Лоуренс Оливье призына ия була, монысы—балетта дөнья күләмендәге иң дәрәҗәле бүләк. 1988 елда Ирек Мөхәммәтов

Ганс Христиан Андерсен призын ала һәм аңа дөнья балетынын ин оста биючесе дигән исем бирелә. 1992 елда елнын ин шәп биючесе булып таныла. 1996 елда ЮНЕСКОнын «Бенуа де ля данс» призы белән бүләкләнә.

1991 елда данлы якташыбыз Лондонда «Ирек Мөхәммәтов һәм К» компаниясен оештыра, анын сәнгати житәкчесе була. Ирек Жир шарындагы балет биючеләренен иң атаклыларын Лондонга жыя. «Отелло», «Диана һәм Актеон» балет спектакльләрен куя. Шунын белән ул дөнья тамашачысына балет сәнгатенең бөтен гүзәллеген ачып бирә, аны сокландырып, гажәп-хәйран калдыра!



*Ирек Мөхәммәтов репетиция вакытында.*

Менә кем ул безнең татар егете Ирек Мөхәммәтов!

Мин анын белән үземә кирәк кадәр яхшы таныш. Әти-әнисе, абыйсы, гаиләсе белән дә аралашырга туры килде. Ирек 1997 елнын 14 октябрендә кабаттан Казан жиренә аяк басты. Бу анын Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театры сәхнәсендә беренче мәртәбә биергә кайтуы иде. Ул гаиләсе белән Казанда ун көн яшәде. Мөхәммәтовларны каршы алдым, озатып калдым, Ирек биегән өч спектакльне дә карадым, Олы Ачасырга да бардым.

Электровоз үзе артыннан елан кебек сузылган вагоннарны йөгертә-йөгертә, станциядән-станциягә сәлам биреп, Татарстанга якынлаша. Мәскәүдән килгәндә, Төрләмә—туган ягыбыз чигендә соңгы станция. Төрләмәдән Олы Ачасыр да кул сузымында гына. Ул авыл Ирекнең күнел түрендә аерым бер кадер-хөрмәт белән саклана. Анда әнисе туып үскән. Ирекнең балачагындагы күп кенә хатирәләре дә Олы Ачасыр белән бәйле. Казанда укыганда да, Мәскәүдә яшәгәндә дә ел саен җәйге каникулларда кайта торган булган ул әнисе авылына. Наил абыйсы белән урманга жиләккә, елгага балыкка йөрүләре әле дә исендә. Тагын бер атнадан Мөхәммәтовлар бөтен гаиләләре белән Казаннан Олы Ачасырга кайтачаклар: Ирек белән Машанын никахын яңартырга, татарча авыл туе ясарга...

Сагындырылган... Әти-әни, туганнар, мәктәптә укыган дуслар... Туган жирдә, туган калада соңгы күрешүләргә быел җәй 15 ел үткән ич. Зур театрда биегән, дөнья күләмендә танылган чагында кайткан иде ул Казанга. Хатыны белән аерылган. Людмила Кудрявцева Зур театрда бии иде. Монда ул Пермь хореография училищесын тәмамлап килде. Ирек—балачактан ук Мәскәү кешесе. Матур гына гаилә корып җибәрә алмыйлар, балалары да булмый. Шулай никах өзелә.

Рәшидә ханым белән Җәүдәт әфәнде биш ел элек Лондонга барып кайтканнар иде. Бер ай торалар. Ул чакта әле Чулпанга (кызларының урысча исеме Александра, балаларының паспортларына ике исем язылган) ике яшь кенә тулып килгән була. Хәзер Рәсүлнең дә (Җәүдәт абыйның әтисе хөрмәтенә шулай атаганнар, урысча исеме Максим) шундый чагы. Мөхәммәтовлар Казанда балаларына татарча исемнәре белән генә эндәштеләр.



*Лондон кунакларын Казан тимер юл вокзалында каршы алу күренеше.*

Борынгы Казаныбыз да Ирегең сагынган. Вокзал халык белән тулы. Рәшидә апаның кулындагы подноста талкыш-кәләвә. 10 яшьлек Иректе Мәскәүгә укырга озатканда да Рәшидә апа улын вокзалда талкыш-кәләвә белән сыйлаган булган. Мөхәммәтовлар утырган поезд перронга иртәнге тугызда килеп туктады. Ирек Казанга Президент Минтимер Шәймиевнең шәхси кунагы булып кайтса да, каршы алучылар арасында югары дәрәҗәле житәкчеләр юк иде. Ипи-тозын, чәкчәген, чәчәген дә туганнары гына бирде. Милли киемнәр киеп кадерле кунакларны каршылый торган зифа буйлы сылу кызларыбыз, түбәтәйле егетләребез кайда иде соң? Монысы, журналистлардан бигрәк, балет сөюче тамашачыларга анлашылмады. Без татарны дөньяга танытучы бөек шәхесләрне менә шулай бәялибез инде. Культурабыз, интеллектыбыз шундый. Болары һич кенә дә милли горефгадәтләребезгә, татарның кунакчыллыгына хас түгел иде, әлбәттә.

Туган ягына аяк басуга бер мөһим нәрсә ачыкланды: киләчәк планнар турында фикер алышканда Ирек сүзен саф татарча «Алла боерса», дип башлады. Шунысын да әйтеп куйыйм. Олы Ачасырда ул гел татарча гына сөйләште. Матбугат конференциясенең берсендә кайсыдыр журналист:

—Татарча беләсезме?—дип сораган иде.

Маэстроның җавабы бик җитди һәм катгый булды.

—Минем әти-әнием татар, алар теле минем туган телем. Лондонга күчкәч, ярты елда инглизчә чиста сөйләшергә өйрәндем. Әти-әни белән ике-өч көн татарча сөйләшик әле. Аннан соң татарча бирелгән сорауларга гына җавап бирәчәкмен...

Олы Ачасырга без 22 октябрьдә барып төштек. Иртән, нәкъ Лондондагы кебек, күе томан төшкән иде, юлга чыккач көзге салкын яңгыр яварга тотынды һәм ул кичкә кадәр дәвам итте. Кунакларны алып кайтырга Зеленодол районы һәм шәһәре хакимиятенең мәдәният бүлеге мөдире, яшь һәм чибәр, әдәпле егет Рамил Гобәйдуллин килгән иде. Рәшидә ханым, Җәүдәт әфәнде авылга шулай зурлап кайтуны кадерле бәйрәмгә тиңлиләр, дәрәҗәгә санныйлар. Элек килешеп куйганча, мин Ирек белән бер машинага утырам. Маша каенанасы һәм каенатасы белән бергә баралар.

Олы Ачасырга килеп житкәнне сизми дә калганбыз. Авыл читендәге халыкны күрсәгез иде. Бөтен районнан җыелганнар. Барысының да татарның бөек биючесен—Иректе һәм аның хатынын якыннан күреп каласылары килә. Авылның уңган кызлары автобуста кунак киленнең аякларына ак сарык йонынннан бәйләнгән

оекбашлар кидерәләр, резин итекләр бирәләр. Маржа кызы менә шушы минутларда үзенең кем икәнен танытты! Безнең машинага кереп утырды да , жылы оекбашларын салып, үз куллары белән ире аякларына кидереп куйды.

—Синең аяклар жылыда булырга тиеш. Бик күп биисең бар әле. Тунмасыннар,салкын тидерә күрмә,—дип мәгънәле һәм саф мөселманча гамәле белән халыкны шаккаттырды.

Машаның янә бер акыллы эшен әйтеп үтим әле. Мәчеткә кергәндә, кияү белән киленгә тәһарәт алырга куштылар. Ирек аякларын юганда комган белән суны Маша үзе салып торды. Мөселман кануннарын белә икән киленкәй!

Авылга кергәндә каршыбызга ялкын кебек яшь кызлар һәм яшь егетләр чыга. Көн шактый салкын булуга да карамастан, алар жәйге жинел киемнәрдән генә. Үзләре чибәр, өс-башлары шундый матур, шундый зәвыклы, күзләр камаша. Ерактан кайткан кунакларыбыз ни әйтергә белми каушап калдылар бугай, шулай да Ирек күңел түреннән чыккан рәхмәт хисләрен әйтмичә китәргә ярамавын тиз абайлап алды.

—Мин—Жир шарының буен буйлаган, инен инләгән кеше. Әмма мондый гажәеп матур тамашаны, мондый ихлас кунакчыллыкны, мондый ачык йөзләрне, мондый иркен күңеллелекне беркайда да күргәнем булмады. Менә фәкать татар халкы гына сәләтле, моны тик минем милләттәшләрем генә булдыра ала,—дип жиргә кадәр башын иде.

Маша бу эчкерсез манзарага хәйран калды, таң калды. Аның күзләреннән терекөмеш бөртекләре тәгәри иде. Иренең нинди унган халык улы булуына чиксез горурланудан, шатланудан чыккан күз яшьләре иде алар.

Авылга кергәч, беренче булып туктаган жиребез—мәчет. Менә кайда икән әле авылга кайтуның төп сәбәбе , сере. Югарыда әйткәнемчә, тәһарәтләнгәч, кияүнең башына ука белән чигелгән затлы түбәтәй кидерделәр. Машага татарча итеп шәльяулык яптырдылар. Мәчеттә һәркем Ислам дине кануннарына буйсына. Кунакларыбыз да авыл картлары һәм Габбас хәзрәт Вәлиуллин алдына килеп тезләнәләр. Аннары аякларын бөкләп утыралар. Хәзрәт никах укый.

Мин Ирек белән Машаның бик яшьли гыйшык-мыйшык уйнап йөргән чакларын Жәудәт абыйдан ишетеп белә идем. Бу хакта Машаның үз авызыннан ишетәсем килеп йөри иде. Жае чыкты ләбаса! Башны жүләргә салам.

—Маша, Ирекка гыйшык тотып йөрүеңне сер итеп саклагансың, диләр. Чынлапмы?

—Без балет мәктәбендә бер класста укыдык. Бер-беребезне күргәндә мина—12, Ирекка 14 яшь иде. Ул мина мәхәббәт хатлары яза башлады. Балалык жүләрлеге булгандыр инде. Ирекне кире кактым. Зур театрда эшли башлагач, ул өйләнде, мин кияүгә чыктым. Күрәсез, икебезнең дә гаилә тормышыбыз җайланып китмәде. Ходай безнең чәчләребезне теге чакта ук бәйләп куйган икән. Мәктәп мәхәббәтенә 15 ел узгач, без яңадан очраштык. Бу юлы ныклы гаилә корырга карар иттек. Мин биюемне ташладым, балага уздым. Ирек минем балалар үстерүемне теләде һәм без Англиягә киттек. Менә шулай мин хужабикәгә һәм балалар тәрбияләүче анага әвереллем. Димәк, безнең балалык мәхәббәтебез сүнмәгән, ул яңа ялкын белән кабынды. Ирекне беренче тапкыр кире боруым өчен үземне һаман гафу итә алмыйм. Ул—гаиләдә менә дигән хужа, мәхәббәтне саклый белә торган булдыклы ир, балаларына яхшы ата,—дип куанып сөйләде мина Олы Ачасырда Маша.

Ирекнең Машага хөрмәте искиткеч зур икәнлеге әллә кайдан сизелеп тора.

—Балаларыбыз бәхете хакына биюдәге талантын корбан итте. Мондый асыл сыйфат хатын-кызның, бигрәк тә сәнгатьтәгеләрнең, һәркайсына да бирелмәгән,—ди Ирек.—Без гаиләбез белән бәхетле. Ижатымда Маша иң гадел тәнкыйтьче. Чөнки мин сәхнәдә балетның иң гади хәрәкәтләрен дә ясый белмәгән хәсрәт тәнкыйтьчеләрнең фикерләре белән беркайчан да килешмим.

Олы Ачасырда туй башланганчы, Лондоннан кайткан кунакларга татар авылының тормышы, гореф-гадәтләре белән танышу мөмкинлекләре тудырырга тырыштылар. Урамда кәжәләр йөри иде. Менә Маша битараф түгел икән. Шулчак киленебез:

—Сөт бирәләрме? Мин кәжә сөтен үлеп яратам,—дип әйтеп салды.

Безнең халык тапкыр. Күз алдында савып бирделәр.

Әлбәттә, кунакларга кияү мунчасы да ягылган иде. Вакыт тар. Рәхәтен татый

алмадылар. Аның каравы мәктәптә укучылар белән очрашу, алар иҗаты белән танышу гомергә онытылмаслык тәэсир калдырды. Ирек тә, Маша да авыл тормышын онытканнар. Моны яшерми сөйләделәр. Тора-бара зал җыр-бию мәйданы булып китте. Авыл егетләре баян тарта. Кызлар биергә чыга. Галия Шәйхуллина Ирек абыйсын татар көенә татарча биергә чакыра. Типтерә генә бит балет бию остасы. Казанда пионерлар сараенда татарча биергә өйрәткәннәрен онытмаган. Балаларга балет бию турында мавыктыргыч итеп сөйли, биеп күрсәтә. Бу очрашуның иң истәлекле минутлары шулар. Ирек Казанда «Баядерка» балетында киеп биегән туфлиен мәктәпкә бүләк итеп калдырды. Мәктәп тарихы кенәгәсенә теләкләре биюченең үз кулы белән языла: **«Кадерле якташлар, өлкәннәр һәм балалар! Шундый җылы һәм эчкерсез каршылавыгыз өчен чиксез зур рәхмәтебезне белдерәбез. Фәкать татар биюләре, татар җырлары, татар музыкасы, татар шигырьләре белән генә сез татар халкының зурлыгын раслап, рухын саклап һәм тагын да күтәреп тора аласыз. Һәр адымыгызда уңышлар һәм сәламәтлек юлдаш булсын!**

*Ирек МӨХӘММӘТОВ, 22 октябрь, 1997 ел».*

Кичкә кадәр дәвам иткән туй мәҗлесе ни тора?! Милли ризыкларның ниндиләрен генә пешермәгән авыл осталары. Ин беренче чиратта кияү пилмәненнән авыз итәргә кирәк. Каз бәлеше, гөбәдия, тутырган тавык, түшкә-түшкә каз, өчпочмак, ит пәрәмәче, бәрәңге пәрәмәче, кыстыбый, төче коймак, кабартма, бавырсак, чәкчәк... Ризыкларны һич кенә дә санап бетерерлек түгел иде.

—Менә татар табыны нинди була икән ул,—дип таң кала Лондон кунаклары.

—Бер рәссам да ясый алмыйдыр боларны!

Ирекнең берсеннән-берсе тәмле аш-су пешергән останы күрәсе килде. Асия Борһанова икән ул. Кунаклар, аш-су остасының фоторәсемен сый-нигъмәтләре янында төшереп, Лондонда инглизләргә күрсәтү өчен алып киттеләр.

Өстәл яныннан торып киткәч, Машадан сорыйм:

—Тәэсирләрегез ничегрәк?

—Сөйләп аңлатырлык түгел. Татар кухнясына тиң бүтән кухня юктыр дөньяда. Сез миңа татар ризыклары турында альбом-китап бүләк иттегез ич әле. Анда һәр аш-суны әзерләү рецептлары бирелгән. Мин үзем дә кухняда рәхәтләнеп әвәрә килеп йөрим. Лондонда инглизләрне татар ашлары белән сыйлармын,—ди килен.

—Алла боерса дип әйт,—ди Ирек.

Тагын бер туй бар икән бит әле. Анысын Рәшидә ханымның туганнары өендә әзерләгәннәр. Кереп чыкмый булмый. Югыйсә, үпкәләүләре бар...

Олы Ачасырга булган сәяхәтебезгә Ирек менә болайрак нәтиҗә ясады:

—Репетицияләрдә, спектакльләрдә мин үземә кирәгеннән артык таләпчән, балет классларында шәкертләремә каты куллы. Әмма тормышта мин бик йомшак табигатьле кеше. Сәхнә минем өчен—дәва, дару. Театр ишеген ябып, машинага кереп утыргач, бөтенесен онытам. Өемдә гаиләм белән иркенләп, рәхәтләнеп ял итәргә яратам. Ялым, әйткәнемчә, театрдан чыгып китүгә башлана.

## Фәрештәләр канатларын биреп торадыр аңа

Мин балетны ихлас күңелемнән бирелеп яратам. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театрына кырык биш ел инде даими йөрим. Таныш театр, таныш зал, таныш сәхнә, таныш кешеләр. Нишләптер, күңел ниндидер тылсымлы хисләр, мәҗаралы тойгылар белән тулган. Сәхнә һәм зал ниндидер сер томанына чумган. Әйе, әйе, бу шулай һәм мондый хәл бүген бик табигый. Бүген үзе туган кала театры сәхнәсендә гомерендә беренче мәртәбә Ирек Мөхәммәтов бии. Лондондагы Король балетының иң атаклы, иң талантлы артисты, гаярь якташыбыз казандашлар алдында имтихан тота.

Бүген француз композиторы Адольф Аданның «Жизель» балеты күрсәтелә. Ирек бу әсәрне драмалы мәхәббәт белән сугарылган булуы өчен ярата икән. Ул төп герой граф Альберт партиясен башкара. Артист балетның драматизм киеренкелеген бөтен нечкәлекләре белән тоя, героеның эчке тормышын аңлый. Граф крәстиян кызы Жизельгә гашыйк. Героиня ролендә Казан артисты Елена Щеглова. Сылу кызга мәхәббәт һәм соклану Альберт-Ирекнең көләч йөзендә балкый, Жизельнең

драмасын кичерү аның кайгыга баткан йөзендә чагыла, Альбертның дулкынлануларын, борчылу-үкенүләрен Ирек мимика аша тамашачы күңеленә сала. Альберт-Ирек сәхнәгә атылып чыгу белән зал, хисләрен тыеп тора алмый, алкышларга күмелә. Тамашачының үз улына мәхәббәте, аның таланты алдында баш июе шул кул чабулар өермәсендә чагыла. Әфарин Ирек! Артистыбыз гүя жирдә түгел, күктә, фәрештәләр биреп торган канатлар белән очына-очына бии. Кайчакларда ул канатларын җәеп бер ноктада асылынып калган кош сыман булып китә. Тамашачы бу галәмәтне үз күзләре белән күреп биюченең виртуозлыгына шаккатып утыра.

Мөхәммәтовның рухы, аның һәвәслеге, әйтерсең, бөтен труппага күчкән. Жизель—Елена аккош төсле йомшак басып бии. Башка артистлары да, Ирекнең үзе кебек, каз мамыгыдай җиңел бүген, һәммәсенә дә яңа канатлар үсеп чыккан диярсең! Хәтта Медет Тугумбаев дирижерлык иткән оркестр музыкантлары да, талант ихтыярына буйсынып, бүтәнчәрәк дәртләнеп, вә хисләнеп уйныйлар.

Театрда Мөхәммәтов нуры балкый, сәхнә һәм зал бөек артист яктылыгына күмелгән. Монда Сихри Рух, Сихри Көч, Галиҗәнап Осталык тантана итә. Боларны сүзләр белән генә аңлатып, сурәтләп бирергә мөмкин түгел.

Пәрдә ябыла. Чү, бигрәк тиз бетте түгелме соң әле бу спектакль?! Яшен яшьнәп ялтырап киткән шикелле генә булды бит бу бәхетле минутлар. Шулай шул: чын талантлар сәнгатен беркайчан да күреп туеп булмый. Ирек, «Жизель»дә биегән артистлар белән сәхнәгә кабат-кабат чыгып, үтә дә җылы каршылаулары өчен тамашачылар алдында башын идәнгә тигәнче ия-ия мең-миллион рәхмәтен белдерә. Аның саен алкышлар көчәя бара. Чәчәкләр кочакка сыймый. Ирек гаять зур әдәплелек, саклык белән чәчәкләрне артистларның аяк астына китереп сала. Моның үз мәгънәсе бар: спектакльнең бүгенге уңышын сез тәэмин иттегез, барасы юлларыгыз чәчәкләргә күмелсен!

Тамашачылар сәхнә белән аерыла алмыйча таң калып басып тора. Нишләмәк кирәк, хис-тойгылар никадәр генә көчле булмасын, барыбер аерылырга кирәк.

Мин аның белән пәрдә артында янә очрашам. Ул, дулкынланудан һәм арудан еш-еш сулап, су сорап тамагын чылатып ала.

—Спектакль алдыннан болай ук көчле дулкынланганым юк иде. Моны табигый хәл дип саныйм. Үзем туган шәһәрдә, туган халкым алдында беренче мәртәбә биим ич. Мин партнерларым биюеннән бик канәгать. Үзем исә Казанда бар булган осталыгымны күрсәтергә тырыштым. Тамашачылар мине аңлады булса кирәк. Бу халәт аларның йөзләрендә чагыла иде,—ди ул эчкерсез горурлык хисе белән.

—Ирек, ни өчен чәчәкләрне беренче булып хатының, балаларың кулыннан алдың? Әллә моның берәр сере бармы?

—Йолам, гадәтем шундый. Сере бик гади. Сәхнәдәге халәтемне алардан да яхшырак берәү дә аңлый алмый. Һәр хәрәкәтемне алар гына дөрес бәяли. Уңышлысын да, бик үк килеп җитмәгән җирләрен дә күземә карап әйтәләр. Үзара аңлашу, хөрмәт шулай эчкерсез була.

Бу кичтә мин Ирекне татарның икенче бер бөек улы Илһам Шакиров белән таныштырдым.

—Таныш бул, Ирек, Татар Шаляпины,—дим мин ике бөек артистның танышуына сөенеп.

Талантлы егетләребез дустанә кочаклаштылар. Илһам күңеле тулуын яшермәде.

—Биюенне караганда күземнән яшь килә,—диде җырчы биючегә.

—Ни өчен икән?

—Татарның бөек биючесе Ирек белән горурланудандыр, мөгаен!..

Бу үзе бер олуг мәгънәгә ия күренеш иде!

Быелның 2 гыйнвар кичендә телевидениенең «Культура» каналы искиткеч нечкә зәвыклы тапшыру күрсәтте. Ул балетка һәм балетмейстер Джордж Баланчинга (чын исем-фамилиясе Георгий Баланчивадзе, 1904-1983 елларда яшәгән) багышланган иде. Ул СССРда туып, совет балет мәктәбендә укыган. Гомеренең яртысын АКШта үткәрә. Сугыштан соң Американың балет мәктәбенә нигез сала. Аннары «Нью-Йорк сити балле»ны оештыра һәм бу балет труппасының сәнгать җитәкчесе була. Кыскасы, Джордж Баланчин—балетмейстер буларак дөнья күләмендә билгеле шәхес. Телевидениедән күрсәтелгән тапшыру Америкада төшерелгән. Аның авторлары—американнар. Алар Рудольф Нуриев белән Ирек Мөхәммәтовның балетмейстер Баланчин сәнгатенә йогынты ясау серләрен дә ачарга омтылалар. Бөек

талантларыбызның «Жизель»дә—граф Альберт, «Баядерка»да—Солор, «Дон Кихот»та Базиль булып бию күренешләрен күрсәтеп алдылар. Татар биючеләренең башкалардан аерылып торган үзенчәлек-өстенлекләрен күрүне тамашачының үз карамагына тапшырдылар. Шул рәвешле балетның бүтән йолдызлары белән чагыштырып карау мөмкинлеге туды. Безнекеләр—тиңдәшсез!.. Рудольф та, Ирек тә композиторның, либретто авторының, балетмейстерның уй-ниятләрен, теләк-фикерләрен бию алымнары ярдәмендә гаять осталык белән гәүдәләндерәләр. Аларның сәхнәгә һәр чыгуы инде беркайчан да кабатланмас искиткеч вакыйга, дөнья балеты тарихында тулы бер дәвергә тиң икән. Тапшыру авторлары телефильм сюжетына менә шушы фикерне кызыл җеп итеп салганнар. Шул мизгелдә Рудольф Нуриевның васыять төсендә язып калдырган сүзләре искә төште: «Юк, мин бөтенләй үлмәм. Балет сәхнәсендә биюче артист күңелендә, тузан бөртеге хәтле генә булса да, минем бер өлешчегем яшәр». Бию даһиенең бөек сүзләре!

Ул тапшыруда мин тагын бер татар биючесенең исем-фамилиясен ишетеп калдым. Хәер, аның үзен Нуриевның классик балет фестивалендә Казанда да күргәнем бар иде. Илгиз Галимуллин ул, Россиянең атказанган артисты, халыкара конкурслар лауреаты. Хәзер Токио балетында бии. Казанда ул шул ук «Дон Кихот»та Базиль иде. Илгизнең Базилен карагач, бу образ татар биючеләре өчен генә иҗат ителгәнме әллә, дип горурланып та куйган идем. Әйтергә кирәк, алар әлеге геройны өчесе өч төрле ача. Бу үзе үк зур казаныш лабаса.

Ирекнең Казандагы спектакльләренә кайтыйк әле. Людвиг Минкусның «Баядерка» балетында ул шундый итеп бии ки, Солорның бар шатлыгын, бар кайгы-сагышын, бар моңын—бию хәрәкәтләре һәм мимика аша аңлатып бирә. Әйе, балет сәнгатенең бик тә хикмәтле, серле төре, әмма Ирек тылсымлы биюе белән тамашачыны аның мажараларына, тылсымнарына төшендерү, сихерли-сихерли әсир итү кодрәтенә ия артист.



*Ирек Мөхәммәтов интервью бирә.*

«Баядерка» балетында Ирек тиңдәшсез иде. Белгечләр әйтүенчә биючегә талантын тулырак ачу өчен нәкъ менә «Баядерка» балетында бөтен мөмкинлекләр дә бар. Индуслар тормышын сурәтләгән-тасвирлаган балетның исеме үк шуңа ишарәли. Баксаң, Баядерка сүзенең татарча мәгънәсе биюче дигәнне аңлата икән. Баядерка—Дини бәйрәмнәрдә халыкның күңелен ачучы, күтәрүче биюче кыз. Никия ролендә—Мәскәүдән, Зур театрдан килгән балерина Елена Князькова. Кунак кызы биюен мин Чайковскийның «Йокыга талган гүзәл» балетында да күргән идем. Бүген—Никия-Еленаның осталыгы бөтенләй бүтән югы белән ялтырап китте, ул—чәчәктән-чәчәккә очып кунган күбәләк кебек җинел, җилбәзәк, шаян. Ә Ирек талантының көче партнерларын рухландыра белүдә дә «күзгә күренеп», сизелеп тора. Моны Елена Князькова үзе дә әйтеп бирде:

—Ирек белән «Баядерка»да биюем тәмле бер төш кенә булды ул. Аның янында биеп йөрүем белән мин бик тә бәхетлемен. Мондый мөмкинлек тудырган өчен Җәлил театрына рәхмәтемнең чиге юк.

Заманында театрыбызның күренекле биючесе булган Нинель Юлтыева спектакльдән соң соклануын тыеп тора алмады:

—Ирек, балет әкияте бетте!

—Әкият тәмам, әмма тормыш дәвам итә. Алла боерса, без Казанда тагын очрашырбыз әле, Нинель ханым!—дип кочаклап алды Ирек Казан артистын.

Чех композиторы Людвиг Минкус (кайбер чыганакларда аның милләте поляк дип күрсәтелгән) икенче балетын язганда испаннарның бөек язучысы Мигель Сервантес иҗатына мөрәҗәгать итә. «Дон Кихот»та Ирек-Базиль «Жизель» һәм «Баядерка» спектакльләрендә ачып бетерә алмаган сыйфатларын күрсәтергә алына. Ачыграк итеп әйткәндә, балет биюенең тамашачы күзенә бәрелеп тормаган техникасын

ача. Пируэтны Ирек кебек ясаучы—бер аяк очында басып бөтерчек шикелле тиз әйләнүче осталар юк! Рудольф Нуриев кына шулай житез иде, диләр белгечләр. Ирекнең әйләнеп торуына күз иярми. Анда ниндидер сихерле, тылсымлы көч бар. Ул кичтә Жәлил театрында Ирекнең биюен күргәннәрне гомер буена онытырлык түгел. Базиль-Ирек һәм Китри-Елена шулай мавыгып, шулай бирелеп биилэр, гүя ки икесе бер жан-образ булып берләшә. «Дон Кихот»та да Мөхәммәтов белән Князькова беренче мәртәбә очрашалар, әмма, шуна да карамастан, ирексездән бу ике асыл зат биюләре белән сәхнәдә бер-берсен тәмам тулыландыру, сәләтләрен ачу өчен туганнардыр, дип уйлап куясың. «Баядерка»да алар безнең йөрәкләрдә индусларның мәхәббәт ялкынын кабыздылар, «Дон Кихот»та испаннарның темпераментлы гыйшык утын дөрләттеләр.

«Дон Кихот»ны караган кич Казан тамашачысы өчен иң зәвыклы, нәзакатьле балет сәнгате бәйрәме булгандыр, мөгаен. Ирек рухы спектакльдә катнашучы артистларны гына канатландырып калмады, сәхнәгә дә, декорацияләргә дә бүтәнчә «жан керткән» шикелле булып тоелды. Театрда бар да Ирекка ияреп бии: жанлылар да жансызлар да! Бу татар егете биюенең тантанасы иде, триумфы иде! Тагын бер кат, йөз кат, мең кат әфарин, Ирек!

Сәхнәгә спектакльдә биючеләр барысы да чыгып баскач, чәчәкләр яңгыры ява башлады. Хөкүмәт ложасыннан күз явын алырлык, күзләрне камаштырырлык зур букет төшерделәр. Монысы—Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең һәм аның хәләл жефете Сәкинә ханымның истәлек бүләге иде. Зал аягүрә торып басты, шуннан китте алкышлар! Юри генә сәгатемә карап тордым. Кул чабулар туктаусыз унбер минут ярым дәвам итте. Казанның тамаша залларында әлегә кадәр мондый хәлнең булганы юк иде әле!

## Президентларның да кадерле кунагы

Мәгълүм ки, чын сәнгать әһелләренең бик сирәге генә сәясәт белән саташып китә. Бер атна инде төрле хәлләрдә аның белән көненә ике-өч мәртәбә очрашып сөйләшәм, сәясәткә кагылышлы ник бер кәлимә сүз чыксын. Шулай да, жаен туры китереп, Ирекнең кылларын чиртеп карарга булдым.

—Быел жәй Казанга Людмила Зыкина килгән иде,—дим мин Ирекнең «телен чишәргә» тырышып.—Матбугат конференциясендә ана Борис Ельцинга мөнәсәбәте турында сорау бирдек. «Былтыр Россия президентын сайларга әзерлек чорында Виктор Черномырдин мөрәжәгать итте,—диеп жавап бирде Людмила Георгиевна.—Ельцинны пропагандалавымны сорый. Мин, Россия гражданы буларак, мона каршы килмәдем. Концертларымда Ельцин файдасына сөйләдем. Әмма ач калган очракта да, мин президенттан бер телем ипи дә сорамаячакмын. Яклау өчен, сыеныр өчен мине яраткан халкым бар...»

—Америкадан кайтып килешли Ельцинның Ирландия аэропортында унайсыз хәлдә калуын хәтерли торгансыздыр,—дип әсәрләнеп китте Ирек.—Шул көнелсез вакыйгадан соң, аның, сәясәтче буларак, Бөекбританиядә абруе бик нык төште, дәрәжәсе калмады. Президент булып сайлану өчен Көнбатышның сина карата әйбәт мөнәсәбәте кирәк. Россия Президенты аппаратыннан мина мөрәжәгать иттеләр. Туган-үскән илемне көлке итәсем килмәде. Ил, халык хакын хаклап Борис Николаевич файдасына сүзләр әйтергә туры килде. Гади халык сәнгать әһелләре сүзенә колак сала. Зыкина хаклы. Аның белән килешәм: Ходай Тәгалә зур власте булган кешеләр кулына калдырмасын...

Бөекләрнең сәясәткә, сәясәтчеләргә карашы менә шундый. Зур житәкчеләрнең акыл белән эш итә торганнары сәнгать эшлеклеләренә ихтирамлы һәм игътибарлы мөнәсәбәттә була беләләр. Алар дипломатия теле белән бик күп нәрсәне күздә тотып сөйләшәләр.

Мин әлеге мисалларны очраклы рәвештә генә китермәдем. Тирәнрәк, киңрәк фикер йөртик әле. Шекспир исемен телгә алганда, бөек драматургның әсәрләрен генә күздә тотмыйбыз бит. Шекспир—Бөекбритания, инглизләр; Гюго—Франция, французлар; Паганини—Италия, итальяннар; Сервантес—Испания, испаннар; Гете—Германия, немецлар тормышы. Бах, Штраус, Безе, Россини, Чайковский, Рахманинов, Верди...

Татарның шундый шәхесләре бармы соң? Әлбәттә бар, хәтта күп тә. Исемнәрен ишетүгә Татарстан, татарлар гына түгел, СССР дигән бөек державаны, Россияне дөньяга таныта торган бөек талант ияләре күз алдына килә. Академик Роальд Сәгъдиев—XX гасыр космос фәненең корифее, АКШта яшәп, иҗат итеп ята. Композитор Суфия Гобәйдуллина Германиядә киләсе гасыр, киләсе меңъеллык музыкасын иҗат итеп үзен дөньяга танытты.

Яңа гасырда яшәячәк буынга музыканы Альфред Шнитка язып калдырмады. Татарның данлы кызы Суфия йөрәгеннән чыга ул сихри моң, кодрәтле музыка. Моның шулай икәнен бөек музыкант Ростропович та таныды һәм исбат итте. Ул 1999 елгы дөнья концерт сезонын Гобәйдуллинаның яңа әсәрләрен уйнап башлаган иде. Шушы программасы белән әле дә булса дөнья гизеп йөри.

Ирек Мөхәммәтов турында язганда боларны телгә алуның нигә кирәге булган әле дип уйлаучылар табылыр бәлкем. Кирәк, бик кирәк. Безнең зур-зур түрәләребез АКШка, Англиягә, Германиягә көне-сәгате белән барып кайталар. Әмма шушы бөек шәхесләр белән аларның ник берсе очрашып сөйләшсен? Үзебез һаман дөньяда татарны, Татарстанны аз беләләр, дип зарланып елап йөрибез. Танытучы, белдерүче шәхесләр—Роалдьләр, Суфиялар, Ирекләр... Безгә Америкада татарның атаклы кешеләреннән җәмгыять оештырырга вакыт җитте инде. Казан консерваториясен тәмамлап американга кияүгә чыккан Халидә Хәйретдинова шунда яшәп шөһрәт казанып ята. Хатын-кызлар арасында Паганини дәрәҗәсендәге скрипкачыбыз Зариус Шәехморзаеваның кызы Елена Бушкова да Штатларда. Скрипкада әнисеннән ким сызгыртмый, диләр. Анда бит татар каны. Зариусның улы Евгений Бушков, әнисе кебек үк, Бельгиядә Королева Елизавета исемендәге иң дәрәҗәле конкурс лауреаты. Австриядә гомер кичерә. Диана Яфарова дигән милләттәшебез Санкт-Петербургта яшәсә дә Парижда француз балаларын укыта. Рахманинов исемендәге Париж консерваториясенең профессоры, Казанга концерт бирергә килгәч, Президентыбыз Минтимер Шәймиев белән чәй эчеп утырды. Теләк-фикерләрен әйтте. Әмма алар чәй белән юылып агып киттеләр. Бу кызыбызны Парижга алып килү өчен Президент Ширак үзе самолет җибәрә. Казанда телгә дә алганыбыз юк. Бушлай концертлар бирергә вәгъдә итеп киткән иде. Шулай булгач, Татарстанны дөнья шәп белә алмый. Татарстанны дөнья күләмендә танытучы шәхесләрне, иң башта үзебезгә танырга кирәк!

1988 елның мартында Ирекнең Америкада гастрольләре була. Илнең иң



*Ирек Мөхәммәтов белән хатыны Мария Леонидовнаны Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев кабул итте.*

йогынтылы газитләренен битләрендә Мөхәммәтов портретлары басылып чыга. Телевидениенең һәр каналында Ирек, СССР Зур театрының беренче номерлы солисты. Ул чакта Америкада Рейган президент. Хатыны белән «Жизель» балетын карарга бара.

—Нигә шулай ялкынланып, очып бии әле бу егет?—дип кызыксына Рейган.

—Иртәгә туган көне, шул рухландыра торгандыр,—диләр кинәшчеләре.

Рейган—утә сизгер дипломат, хәйләкәр. 8 мартта—Ирек Мөхәммәтовның туган көнендә—Ак йортта бу бөек биюче хөрмәтенә аш мәҗлесе уткәрә. Американың дәүләт эшлеклеләре алдында үз илләренә гастрольләргә килүе өчен рәхмәт әйтеп кулын кыса, таланты алдында башын ия, истәлеккә фотога төшәләр. Америка Президенты Ирекне шушы мәҗлестән соң онытмый, фотолар артына, теге мәҗлесне телгә алып, үз кулы белән теләкләрен язып җибәрә. Ак йортның иҗтимагый эшләр буенча секретаре Линда Фолкнер Мөхәммәтовка, очрашуда бәхетле минутлар бүләк иткән өчен, рәхмәт әйтеп, СССРга хат җибәрә. Фотолар да килә.

Җәлил театрында Ирек Мөхәммәтовның тормышына һәм иҗатына багышланган күргәзмәнең бер бүлеге Ак йорттагы мәҗлес турында иде.

Әйе, Америка талантларны таный белә. Чөнки анда талантлар өчен, сәнгать өчен социализм иле дә, милләт тә юк икәнен яхшы аңлыйлар. Сәнгать—Җир шарындагы барлык халыклар өчен дә уртак.

Мәгълүм булганча, Ирек туган-үскән каласына Минтимер Шәймиев чакыруы буенча кайтты. Юл газаплары чигеп, Президентыбызның Казан Кремлендә Ирек Җәүдәт улы белән Мария Леонидовнаны кабул итүе бик табигый хәл иде. Минтимер Шәрипович зур кунаклар каршына кулына зур чәчәк бәйләме тотып чыкты. Аннары гөбәдия, чәкчәк, бавырсак, кош теле, өрек җимеше һәм кара җимеш белән чәй эчә-эчә әңгәмә башланып китте. Президент кунаклар белән тормышлары, татар сәнгате турында сәгатьтән артык иркенләп сөйләшеп утырды. Ирек Англиядә татар сәнгатен пропагандалау өчен татар фольклоры, «Шүрәле» балеты төшерелгән фильмнар кирәклеген искәртте. Бу шушы бүлмәдә сөйләшүдән узмады бугай. Ирекнең әбыйсы Наилдән сораган идем. Шулайрак әйтте. Тууына 40 ел тулу уңаеннан Лондонда бронзадан Мөхәммәтовның биегән чагын сурәтләгән һәйкәлен коялар икән. Очрашу истәлеге итеп Ирек Минтимер Шәриповичка аның бүлмәгә куела торган кечкенә вариантын бүләк итте.

Президент кунакларга Татарстан белән бәйле махсус бүләкләр әзерләгән.

—Монысы милли читегебез,—диде Президент Машага аяк киемнәрен сузып.—Арча осталары тегә. Шыгыр-шыгыр басып, Лондон урамнары буйлап бер үтегез әле. Инглизләр татарлар осталыгын күрсен.

Читекләр теләсә кайсы илнең күргәзмәләрен, кибетләрен бизәрлек дәрәҗәдә, бик тә зәвыклы итеп чигелгән иде, әлбәттә. Икенче бер матур тартмага Казан Кремленең пыяладан эшләнгән макеты салынган. Аның капкачын ачкач, Татарстан Гимны яңгырый. Казанны, Татарстанны, анда булган очрашуларны искә төшереп тору өчен моннан да кулай бүләк була алмастыр!

Болар—үз йортыңны бизи торган бүләкләр. Англия халкына Татарстан сәнгате турында сөйләүче фильмнар булганда, әлбәттә, комачауламас иде. Ирек әле картаймаган, биюен туктатканда да даны тиз генә югалмас. Шәт, монысы да искә алыныр.

Ирек Мөхәммәтовның Җәлил театрында биюенә өч ел тулып килә. Бергә балет спектакленә килгән саен теге чактагы хисләр, кичерешләр, тойгылар, фикерләр, тәэсирләр яңара. Эчендә җаның булганда, ул кичәләрдәге бәхетле минутларны оныту, олы талант сәнгатеннән аерылу мөмкин нәрсә түгел. Ирек Мөхәммәтов—үз сәнгатендә шагыйрь ул, дөньядагы барлык милләт халыкларына аңлаешлы телдә иҗат итүче балет биюләре шагыйре! Талантлы шагыйрьнең талантлы шигыре һәрчак күңел түрендә йөри. Ирек биюе дә шулай!

**Мәгъсүм ГӘРӘЕВ**
*гыйнвар, 2000 ел*

*Әдәбият тарихына*

# ОНЫТЫЛГАН ӘДИП КАСЫЙМ БИККОЛ

Дөнья цивилизациясе тарихы шуны раслый: халыклар үзләренең үсеш юлында эволюция өчен гаять мөһим булган этапны—Ренессанс, Яңарыш этабын үтәләр. Бу дәвердә әдәбият-сәнгать чәчәк ату чорын кичерә, милли җирлектә олы талантлар, мәшһүр шәхесләр үсеп җитешә. Европалылар урта гасырларда узган мондый Яңарыш дәвере, мәгълүм тарихи сәбәпләр аркасында, татарларга соңрак, XIX гасыр ахырында килә һәм XX йөз башында үзенең югары үсешенә ирешә. Гасыр башында татар Сүз сәнгате өлкәсендә каләм тибрәткән 800 ләп исемне атый алыр идек. Табигый, иҗат активлыгы ягыннан алар бер дәрәҗәдә түгел. Бу исемнәр арасында үз заманында ук (1911-1918 еллар) татар әдипләреннән беренче булып 18 китаптан гыйбарәт әсәрләр җыелмасын чыгарырга өлгергән әдип Гаяз Исхакый (1878-1954) да, үзе исән вакытында бер генә җыентыгы да дөнья күрмәгән шагыйрь Дәрдмәнд (1859-1921) тә бар. Әмма икесе дә хаклы рәвештә татар әдәбиятының классиклары булып исәпләнәләр, рухи мирасыбызның «алтын фондын» тәшкил итәләр.

Бу җәһәттән, әдәбият фәнендә игътибар нәкъ менә шул даирәдәге әдипләребезгә юнәлтелеп, чорның милли-мәдәни хәрәкәте нигездә алар иҗаты аша өйрәнелде. Әлеге исемнәр һәрберебезгә билгеле, иҗатлары таныш. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Галиәсгар һәм Шәриф Камаллар, Г. Ибраһимов... Бу күркәм затлар мохитына соңгы вакытта шаулап, даулап Гаяз Исхакыйның мәһабәт фигурасы килеп керде. Зарыгып көткән мирасның ымсындыргыч көче шулкадәр тансык тоелды булса кирәк, җөмлә төзергә сәләтле һәркем каләм тотып әдип иҗатын сөрүне үзенең изге бурычы итеп санады.

Шул ук вакытта милли әдәбиятны үз дөньясы итеп таныган, әмма олы тәхеткә дәгъва кылмый яшәгән никадәр иҗат әһелләребез бар бит әле безнең?! Алтын тамырлары ерак гасырларга береккән әдәбият тоташ бөек шәхесләрдән генә тора алмый. Уйлану өчен табигатьтән бер сурәт-мисал: урман ни өчен гомер бакый матурлыгы белән үзенә тарта? Ни сере, тылсымы бар аның? Чөнки анда мәгърур имәннәре, гаскәр кеби чыршы-наратлары белән янәшә җыйнак кына балкып утырган куаклары, тыйнак кына хушлык бөркүче үлән-чәчәкләре бар—шуларның бергәлегеннән, бердәмлегеннән күңелләрне җәлеп итүче Матурлык галиҗәнапләре туа. Имәннәрен генә сайлап калдырган урман ул инде урман түгел. Кеше кулы белән булдырылган ясалма паркны хәтерләтә башлый ул. Табигатьтә бер нәрсә дә артык түгел—һәрберсенең үз яме, үз матурлыгы.

Юк, Тукайлар үз бөеклекләре белән башка әдипләрне күләгәләмиләр, киресенчә, тыйнак, җыйнак иҗатлар иннәрендә күтәреп мәшһүр шәхесләрне әдәбиятта моңарчы ирешелмәгән киң, якты дөньяга алып чыгалар.

Тукайлар заманы әдәбиятының үзенчәлекле сәхифәсен тәшкил иткән Касыйм Бикколов (Касыйм Биккулов, Касыйм Бикколь) әсәрләре игътибардан читтәрәк кала килгән, әмма һичшиксез өйрәнелергә һәм тәкъдир ителергә тиешле иҗат буларак бездән дикъкать сорый.

Үз гомерендә ике дистәгә якын китап бастырган Касыйм Бикколов хакында, кызганычка каршы, без бик аз беләбез. Ә бит Касыйм Бикколов—татар әдәбиятында «Төркестан» (1908) исемле беренче тарихи роман иҗат иткән, гасыр башында ук (1904) балалар өчен саф татар телендә язылган уку әсбабы «Нәмүнәи тәрәкъкый» («Прогресс үрнәкләре») китабын төзеп бастырган әдип бит!

Касыйм Бикколов тормышына кагылышлы хәзергә билгеле булган фактлар өчен әдипнең Мәскәү каласында яшәүче оныгы сынаучы инженер Рәсим әфәнде Бикаловка һәм язучының авылдашы үзешчән тарихчы Наил Төхфәтулловка рәхмәтлебез.

Касыйм Җамалетдин улы Бикколов 1868 елда Сембер губернасының Буа өязе Суыксу волосте (хәзерге бүленеш буенча Татарстан республикасының Буа районы) Яңа Тинчәле авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Әдип «Яңа Тинчәле вә аның тарихы» дигән кульязма хезмәтендә үзенең шәҗәрәсен дә китерә. Бу нәсел агачы татар дөньясына күренекле дин әһелләрен, мәгърифәт өлкәсендә актив катнашкан шәхесләрне бүләк иткән.



Әлеге нәселдән Габделлатыйф хәзрәт үз вакытында тирә-юньгә мәгълүм мөдәррис-укытучы булган. Аның улы—Касыйм Бикколовның әтисе—Җамалетдин хәзрәтнең (1831-1914) даны тагын да еракларга китә. Атаклы Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсендә белем алган Җамалетдин Бикколов берара шунда ук дәресләр дә бирә. Гомумән, Җамалетдин хәзрәт заманының бик алдынгы, гыйлемле, укыту системасын үзгәртүгә, аңа шул чор өчен бик зур вакыйга исәпләнгән яңалыклар кертүгә җиң сызганып катнашкан шәхес булган. Аның үлеме мөнәсәбәте белән «Кояш» газетасының 1914 елгы 8 декабрь санында некролог бирелә. Һәм анда Җамалетдин Бикколов үз заманына караганда иртәрәк дөньяга килгән куәт иясе иде, дип күрсәтелә. 22 яшендә үз авылына имам булып билгеләнеп, 60 елдан артык мәгърифәт юлында хезмәт иткән Җамалетдин хәзрәт иҗат эше белән дә шөгыльләнгән. Нәсел ягыннан Мәрҗанигә кардәшлеге дә булган Җ. Бикколов күренекле мәгърифәтче хакында гарәпчә әсәр язган. Некрологта шулай ук аның тарихка кагылышлы кульязма хезмәтләре булганлыгы турында да әйтелгән. Дөньяда бар булсалар, кайларда, кай тарафларда, кемнәр кулында өнсез яталар икән соң ул тарихи мирасыбызның газиз ядкарьләре?

Шушы нәселдән, Касыйм Бикколовның бертуган энесе Ибраһим (1884-1938)—педагог, көчле журналист буларак мәгълүм. Галимҗан Ибраһимов аның матбугаттагы чыгышларын уңай бәяли һәм И. Бикколов язмаларында «табигый бер юл сизелә ки, ул да—Казан хәятының эченә кереп, ул хакта фикер сөйләү түгел, бәлки шул хәятны фактлар аркылы ачу» бар дип раслый.

Күренә ки, Касыйм Бикколов зыялы, мәгърифәтле гаиләдә дөньяга килә һәм бу мохит ахыр чиктә аның әдип-мөгаллим, реформатор дин эшлеклесе булып тәрбияләнүендә төп рольне уйный.

К. Бикколовның туган елы турында ике төрле фараз бар. Әдипнең каберенә куелган ташта туган-үлгән еллары итеп 1870-1937 саннары сугылган. Ә күренекле галим Миркасыйм ага Госманов «Каурый каләм эзеннән» (1994) исемле китабында Касыйм хәзрәтнең кульязма «Яңа Тинчәле вә аның тарихы» исемле хезмәтенә анализ ясаганда туган елы итеп 1868 датасын күрсәтә.

... Башлангыч белемне авылда әтисеннән алганнан соң, Касыйм Бикколов Казан мәдрәсәләренең берсендә укый. Аны тәмамлап, мөгаллимлек хокукына ия булгач, Әстерхан төбәгендәге Киләче исемле татар авылында балалар укытырга керешә. Бирелә тупланган тәҗрибәсе нигезендә Касыйм мөгаллим беренче әсәре—«Нәмүнәи тәрәкъкый» исемле уку китабын яза. Китапка Санкт-Петербург Цензура комитеты тарафыннан 1903 елның 24 июнендә рөхсәт бирелә һәм ул 1904 елда Казанда дөнья күрә. (Китапның титул битендә К. Бикколов үзен Киләче мәдрәсәсе мөгаллиме булуын ачык күрсәтә.)

Күпмедер вакыттан соң (1905-1907 еллар), инде шактый олыгайган Җамалетдин хәзрәт Касыймны авылга чакыртып ала һәм үзе урынына мулла итеп куя. (Касыймның энесе Ибраһим журналистлык һәм педагоглык юлын өстен күреп, дин әһеле булудан баш тарта.)

Гомеренең байтак өлешен туган авылы Яңа Тинчәледә мулла булып торган

К. Бикколов бер үк вакытта иҗат эше белән дә шөгыльләнә: китаплары бер-бер артлы чыга тора. 1904-1918 еллар арасында аның ике дистәгә якын китабы дөнья күрә.

Октябрь вакыйгаларыннан соң К. Бикколов тормышында берсеннән-берсе хәтәррәк сикәлтәләр, куркынычлы борылышлар башлана. Егерменче еллар уртасыннан дингә мөнәсәбәттә көчәя барган кысулар, китапларын бастыру мөмкинлеге бетү актив тормыш белән яшәгән имам вә әдипне бик тә яман, авыр тормышка дучар итәләр. Әрнү-рәнҗешен эчкә йота-йота К. Бикколов шатлыгының да, кайгысының да шаһиты булган каләменә тотына. Шушы шартларда «Яна Тинчәле вә аның тарихы» исемле хезмәт дөньяга килә. Кульъязмада сакланган бу әсәр 1926 елда язылып беткән. Анда Яна Тинчәле тарихы белән беррәттән, авылдагы төп нәселләрнең шәҗәрәләре турында да кызыклы материаллар китерелә. Менә шушы әсәре өчен генә дә Яна Тинчәле халкы әдипкә рәхмәтле булырга тиешләрдер. Бу саллы хезмәт татар халкы тарихын өйрәнүдә дә кыйммәтле чыганак була ала. Хөрмәтле галимнәребез М. Госманов, М. Әхмәтҗанов та бу хезмәткә югары бәя бирәләр.

Туган авылы тарихына багышланган язмалары К. Бикколовның соңгы әсәре иде... Ил тарихындагы дәһшәтле, болгавыр вакыйгалар Касыйм хәзрәт гаиләсен дә чорнап алып, ахыр чиктә аны тәмам чәчеп, туздырып ташлый.

Утызынчы еллар башында Касыйм Бикколов кулга алына. Әйтүләренә караганда, ул гарәп алфавитын бетереп, латинга күчүгә каршы чыга. Шул хакта югары органнарга үз фикерен дәлилләгән язмасын да тапшыра. Әдәбият дөньясында актив тормыш белән яшәгән Касыйм Бикколов бу хәлнең рухи, мәдәни мохитта нинди өзеклек барлыкка китерәчәген, яшь буынны менәр ел буе тупланып килгән тарихи мирастан аерачагын яхшы аңлагандыр. Әлбәттә, кешене рухы сындырылган мескен кол хәлендә тотарга күнеккән тоталитар режим бу рәвешле шәхес бунтына ничек түзеп торсын ди?! Касыйм хәзрәт кулга алынып, Казанга озатыла. Гаиләсе Себергә сөрелә... Мөгаен, бик күп корбаннар кебек үк, Касыйм хәзрәт Бикколов та төрмә диварлары артында хәбәрсез юкка чыккан булыр иде. Әмма бер кыйпылчык бәхет аның гомеренә калган икән әле. Казан төрмәсендә сорау алган ОГПУ вәкиле Касыйм мөгаллимнең Киләче авылында укыткан укучысы булып чыга... Шуның ярдәме белән, Касыйм хәзрәт бер ел чамасы төрмәдә утырганнан соң, күздән югалып торсын дигән теләк белән булса кирәк, Уфа ягына озатыла. Бераздан аңа гаиләсе белән туган төбәгенә кайтып егылу насыйп була. Әмма дөньяның кыенын житәрлек кичергән, тормышның ачы тәҗрибәсен шактый туплаган Касыйм хәзрәт күңеле белән сизә: бу болганчык заманда исән-сау котылу вакытлыча гына, фамилияң кара исемлеккә бер эләккән икән...

Шуна да Касыйм Бикколов иң әүвәл гаиләсен афәтле язмыштан аралау ниятеннән мөмкин хәтле ераккарак җибәрү хәстәренә керешә. Нәтиҗәдә, укымышлы нәселдән чыгып, татар милләтен агартучы, үстерүче булырга тиешле асыл гаилә балаларын заман җилләре Рәсәй масштабы буенча дөнья чите дип әйтерлек җиргә—Төрекмәнстанның Чаржау шәһәренә илтеп ташлый. Кайбер эш-йомышлары булыпмы, әллә инде ата-бабалары гомер иткән, җирләнгән туфрактан тамырларын өзеп бөтенләйгә чит-ят төбәккә кузгалып китү авырлыгыннан бераз сабыр итәргә уйлапмы, башка сәбәптәндерме—ни булса да була, Касыйм хәзрәт гаиләсе белән үк юлга кузгала алмый. Алда очрашырга, кушылырга вәгъдәләр дә куелган булгандыр, әмма инде аңа башка беркайчан да кабат газиз гаиләсе белән күрешергә насыйп булмый. Яше дә олыгаеп килгән, аннан битәр нахакка рәнҗетелүләрдән, эзәрлекләүләрдән, төрмә-сөрген газапларыннан рухы арган татар милләтенең зыялы улы, заманының билгеле укымышлысы, мөдәррисе, язучысы Касыйм Җамалетдин улы Бикколов 1937 елның 21 июнендә вафат була... Бу якты дөнья белән хушлашканда аның тоташ җәрәхәтләрдән торган җанында бер сөенеч бөртеге дә булгандыр әле дип ышанасы килә: ни дисәң дә ата-бабасы күмелгән зиратка озатыла бит ул...

Касыйм Бикколов иҗаты XX йөз башы татар әдәби-мәдәни тормышының үзенчәлекле бер сәхифәсен тәшкил итә дидем. Бу чынлап та шулай. К. Бикколов иҗаты гомум әдәби хәрәкәтне аңларга, аерым тармакларының ни рәвешле үсү,

үзгәрү процессы кичерүләрен төшенергә мөмкинлек бирә.

К. Бикколов—әдәбиятыбыз тарихында күп төрле юнәлешләрдә нәтиҗәле эшләп, мәгълүм эз калдырган әдипләрдән. Татар дөньясында аның исеме ин әүвәл дәреслек характерындагы китаплар авторы буларак күренә башлый. («Нәмүнәи тәрәкъкый», «Гайне әт-тәрәкъкый», Г. Госманов белән берлектә әзерләнгән «Балаларга кыйраәт» һ. б.). Бу уку китаплары йөгерек теле, үтемле гыйбарәләре, эчтәлекле төзелеше белән игътибарны җәлеп итәләр. Касыйм Бикколов, укытучы буларак, бала психологиясен яхшы анлап эш итә, нәни күнелләргә хуш килә торган темаларны сайларга тырыша. Кыска-кыска гыйбрәтле, кызыклы хәлләр, табигать күренешләре, таныл-белүгә хезмәт итүче хикәятләр, әхлак темасына кагылышлы шигырьләр белән бергә үрелеп, бала хыялында гаҗәеп бер дөнья тудыралар. К. Бикколов балалар белән үз кеше булып әнгәмә кора белә, тирә-юньгә сабыйлар күзе белән карап, кичерешләрен кәгазьгә күчерә ала. «Нәмүнәи тәрәкъкый» китабындагы «Арыш» һәм «Богдай» («Бодай») шигырьләрен генә алыйк. Биредә һәр авыл баласына таныш, газиз тема-сурәтләр:

И арышым, арышым, синдә бәнем табышым.
Синдән башка юкдыр бәнем бу дөньяда тормышым.

Яки инде түбәндәге:

И богдаем, богдаем, бирде сине Ходаем,
Башын тулып үсеп йитсән, үзем килеп ураем.
Алтын синен сакалын, көмеш синен саламын,
Хода сине бирсен диеп яхшы йиргә саламын...—

кебек юллар аркылы нарасый күнелләрне тәрбияләү дәресләре бара...

К. Бикколов иҗатынын икенче тармагын дин дәресләре, ислам кануннары һәм тарихы буенча язылган хезмәтләр тәшкил итәләр. «Канун вә низам», «Тарихы әнбия», «Тарихы ислам» кебек китаплар шушы юнәлеш җимешләре.

Өченче тармакны, әлбәттә инде, әдипнең матур әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеге алып тора. Шунысы игътибарга лаек, К. Бикколов татар әдипләреннән беренче булып тарихи темага мөрәҗәгать итә һәм прозасы аркылы үзенчәлекле яктыртылуына ирешә. Инде 1904 елда басылган «Нәмүнәи тәрәкъкый» исемле уку китабы ахырына әдип «Әсирлек хикәяте» исемле кыйссасын урнаштыра. Сонрак бу әсәр «Төркестан» романынын нигезенә ята.

Роман үзәгенә XIX йөзнең икенче яртысында Урта Азиянең Россия тарафыннан басып алыну вакыйгалары салынган. Бикколовнын тарихи материаллардан иркен һәм белеп файдаланганлыгы анлашыла: Ташкент, Сәмәрканд, һ. б. шәһәрләрнең яулану даталары документаль дөрес күрсәтелә. Рус отрядлары белән әмир гаскәрләренең бәрелеше, сугышның характеры, халыкларнын үзара конфликты язучы каләме белән объектив тасвирлана, җанлы, ышандыргыч картиналарда сурәтләнә.

Рус армиясенең чагыштырмача тиз арада Урта Азияне яулап алу сәбәпләрен К. Бикколов икътисади һәм сәяси яктан нигезле ачып бирә. Җинелү сәбәпләреннән берсе итеп автор ханлыклар арасында бердәмлек булмауны, үзара мәгънәсез ызгыш-талашларны саный. «Үзара сугыш дошман илә сугыштан яманрак»,—ди язучы һәм бу талашлар вакытында хисапсыз күп мәдрәсәләрнен җимерелүенә, китапларнын, китапханәләрнен яндырылуына, аеруча гөнаһсыз сабыйларнын һәлак булуларына ачынуын белдерә.

К. Бикколовнын янә бер зур тарихи темага алынуы мәгълүм. «Гайне әт-тәрәкъкый» (1907) әсәренен титул битендә «Казакъ мәгыйшәте» исемле роман язылып, китап ахырына урнаштырылуы хәбәр ителә. Китапта үзе ул исә («Кыныгр эш кырык елдан сонра беленер») дигән исем белән аталган. Эчтәлеге белән танышканнан сон шундый тәэсир кала: бу автор тарафыннан язарга уйлаган зур әсәрнен беренче, яки бер варианты булган булса кирәк. Әсәрнен үзәгендә казакълар белән калмыклар арасындагы элек-электән үк килгән җир, территория өчен бара торган киеренке мөнәсәбәтләр ята. Ике халыкнын да потенциаль көчен, гайрәт-куәтен күрсәтә торган баһадирлары да бар. Казакъларда ул Куандык, ә калмыкларда Микян дигән шәхесләр. Төрле эреле-ваклы конфликтлар ахыр чиктә ике якнын

да олы яуга әзерләнүенә алып килә. Әмма вакыйгалар шунда туктап калалар: язучы, калмыклар ягыннан куәтле яу килүен белгән казакъларның Җаек аръягына күченеп китүләрен әйтә дә, ахырда аларның туй йолаларын тасвирлау белән чикләнә. К. Бикколов бу темага кайтып кабат эшләргә уйлагандырмы, хәзер инде бу хакта фикер йөртү кыен, һәрхәлдә «Казакъ мәгыйшәте» исемле мөстәкыйль әсәрнең язылу-язылмавы турында мәгълүматлар юк.

Үзе дә заманының алдынгы карашлы мөгаллиме, мөдәррисе буларак, К. Бикколов нигездә мәктәп-мәдрәсә тормышы турында яза, алдынгы карашлы укытучыларны хуплап, иске фикерле бәндәләрне тәнкыйтьләп чыга. Аның күпчелек әсәрләрендә («Ат караклары», «Сабирҗан агай», «Алтынбай агай» «Хаҗи» һ. б.) тискәре типлар булып гадәттә мулла-мәзиннәр алына. Һәм моны үзе хәзрәт булган кеше яза бит әле! Указлы мулла, дин әһеле яза! Әсәрләреннән чыгып караганда Касыйм Бикколовның, һичшиксез, яңалык тарафдары, укыту, тәрбия өлкәсендә реформатор буларак чыгыш ясаган татар зыялысы икәнлеге аңлашыла. Ачыклап китик, муллаларны тәнкыйть итү әле ул дингә тискәре мөнәсәбәттә булу дигән сүз түгел. Киресенчә, К. Бикколов дин исеменнән йөреп тә үз хәлләрен генә кайгырткан, халыкны алдап яшәгән адәмнәрнең чын йөзләрен ачуны максат итеп куя. Бу хәлне ислам динен әнә шундый сорыкортлардан чистарту нияте дип тә аңларга кирәк. Бикколов дин юнәлешендәге һәртөрле буталчык карашларны бер тәртипкә салуга үзеннән өлеш керткән хәзрәт тә бит әле. Аның «муллалар өчен һәрвакыт белергә тиеш булган» кагыйдәләр һәм законнар җыелмасыннан гыйбарәт «Канун вә низам» китабы шушы эшчәнлек нәтиҗәсе.

Гомумән, иҗаты ягыннан Касыйм Бикколов «сугышчан» мулла буларак характерлана. «Алтынбай агай» повестенда ул җәдитчеләрне, ягъни яңалык тарафдарларын яклап, надан ишаннарны, «мин туры юл күрсәтүче» дип авылдан-авылга каз, үрдәк ашап йөрүчеләрне камчылый.

«Ат караклары» әсәрендә хәлфә булган булып, мәдрәсәдән мәдрәсәгә йөри-йөри кесә калынайту максаты белән генә яшәгән һәм ахыр чиктә, оятсызлыкның аргы ягына чыгып, ат урлауга кадәр барып җиткән типлардан ачы көлә.

«Сабирҗан агай» повестенда ачлык афәтенә дучар булган ярлы халыкның юк кына бәягә соңгы терлеген, имана җирен сатып алып байлык туплаучыларга нәфрәтен белдерә. Бу бәндәләрнең үзләрен аклау максатыннан «ишан хәзрәтнең хәер-догасы белән баедык» дип мактануларын күрсәтеп, автор, акча хакына мондый кыланмышларга фатиха бирүчеләрнең икейөзлелеген фаш итә.

Ә инде халыкка ихлас хезмәт итәргә алынган алдынгы карашлы укытучы-мөгаллимне сурәтләгәндә Бикколов якты буяуларны кызганмый. Үз героена сокланып та, ана зур өметләр баглап та, рәхәт бер күтәренкелек белән яза ул мондый очракта. Бу җәһәттән «Алтынбай агай» әсәрендәге Шакир мөгаллим образы дикъкатькә лаек. Шакир килгәнче авыл халкы бик фәкыйрьлектә яши, мескен бер тормышта иза чигә. Сәбәп нидә? Баксаң, халык бик надан, үз хәлен бер дә кайгырта белми, шуңа да ярлылыкның чигенә житә язган икән. Байлар исә халыкны алдап рәхәт күрә: бурычка бер пот ашлык бирәләр дә, өч пот итеп түләтәләр. «Ник баемасын Алтынбайлар!»—ди автор ачынып. Шакир мөгаллим беренче эше итеп әнә шул күңелсез яшәү шартларын үзгәртергә алына. «Гыйлем вә белүгә бар куәтегезне сарыф итеп, ... наданлык бәласеннән котылырга, кәсеп, һөнәр, эшлелек, ирлек, тырышлык сыйфатлары илә үзебезне зиннәтләргә кирәк»,—ди ул халыкка мөрәҗәгатендә. Шакир иң әүвәл сүз сөйләүче генә түгел, ә практик эшчәнлеге белән үрнәк булучы кеше итеп тасвирлана. Халык аңа ышанып, ихластан иярә һәм тиз арада, исәп-хисап белән эш итү, бик нык тырышу нәтиҗәсендә, әйбәт кенә баеп та китә. Ул гына да түгел. Яңа К... карьясе хәтта башка авылларга үрнәк булып, даны бөтен Рәсәй мөселманнары арасына тарала. Аңлашыла ки, әсәрдә вакыйгалар авторның хыялы, ул күрергә теләгән авыл картинасы белән үрелеп баралар. Повесть беренче чиратта, укучыны үз хәле турында уйланырга чакыра, әсәрдәге образлардан үрнәк яки гыйбрәт алырга өнди. Әйтергә кирәк, «Алтынбай агай» повесте, заманы өчен актуаль мәсьәләләр күтәргәнгә, шул чор укучысын битараф калдырмаган. Моны әсәрнең бер нөсхәсе артына төрле кул белән язылган түбәндәге искәрмәләр дә раслый:

«Браво, бис, браво! Күп рәхмәт синең Шакир меллага!»

«Явыз Алтынбайга ләгънәт, тырыш, яхшы Шакир меллага рәхмәт».

Касыйм Бикколов гомере буе авылда яшәгәнгә күрә, крестьян тормышын бөтен нечкәлекләренә кадәр белеп яза. Ана вакыйгаларны да, геройларны да уйлап чыгарырга кирәк түгел. Ул шулар арасында гомер итә, авыл кешесенең куанычы да, кайгы-хәсрәте дә ана таныш, үз. Әгәр авыл тормышында вакыйгалар була икән, язучы өчен дә бу шәхси фаҗига. Мондый куркыныч хәлләрнең берсе—ачлык афәте. Татар крестьянының аянычлы язмышын тасвирлаучы «Сабирҗан агай» повесте әнә шул, чыннан да, тарихта булган шомлы вакыйгаларга нигезләнгән иде. Китапның титул битендә үк искәртелгәнчә, әсәр «1906 сәнәдә булган ачлыкны тасвир кыйлуга» багышланган. Ачлык афәтенең куркыныч көч белән якынаюын тойган татар әдипләре үз вакытында ук халыкны уяу булырга чакырып чаң сукканнар иде. Моны ин беренчеләрдән булып вакыйгалар агышына гаять сизгер булган Гаяз Исхакый искәртте. Ул «Таң йолдызы» газетасының 1906 ел 12 сентябрь санында «Ачлык башланды» исемле мәкаләсен урнаштыра һәм әйтә: «... әллә ничә еллардан бирле ачлы-туклы килгән авыл халкы бөтенләй ач калып, бер кисәк икмәксез утыра башлады. ... Бездә шул ачлыклардан, әллә никадәр авырулар күбәеп, бөтен Русияне бертуктамаенча әүвәле юк һәм ахыры юк булган ачлык каплап алмакчы була».

Мондый куркынычлы дәһшәт җәмәгатьчелекне тирән борчуга сала, уйланырга, бу хәлдән котылуның төрле юлларын эзләргә мәҗбүр итә. Мисал өчен «Казан мөхбире» газетасы (1906 ел, 10 ноябрь) шундый белдерү бастыра: Габдулла хәзрәт Апанай ачларга ярдәм итү тугрысында кинәшер өчен мәҗлес ясарга сорап полицмейстрга заявление бирде. Мәҗлес 11 нче ноябрь кич 7 сәгатьтә «Болгар» залында булачактыр».

Татар әдәбияты да бу кара, фаҗигале вакыйгаларны читләтеп узмый. М. Гафуриның «Ачлык ел яки сатлык кыз», Я. Вәлинең «Ачлык кушты», һәм ниһаять, К. Бикколовның мәгълүм «Сабирҗан агай» әсәрләре шушы эчтәлеккә нигезләнгән иҗат үрнәкләре иделәр.

Касыйм Бикколов Сабирҗан карт образы аша социаль контрастлы авыл картинасын сурәтли. Халыкның мохтаҗлыгыннан, чарасызлыгыннан файдаланып мал туплаучы байларга, куштаннарга тирән нәфрәтен белдерә.

Сабирҗан агайның үлеме сурәтләнгән җанөшеткеч картинада үзләрен дин тоткасы дип санаган бәндәләр чын сурәтләре белән укучы алдына басалар. Әхлак, иман дигән төшенчәләрне таптап, бу типлар мәрхүм өстендә үк сәдака өчен тавыш куптаралар, ямьсез талаш чыгаралар.

Бер авыл крестьянының фаҗигале язмышын сурәтләргә алынган язучы шул чор татар тормышының кырыс картинасын ачуга һәм реаль образлар аша яктыртылуына ирешә. Бикколовның бу әсәре халык тормышында мондый афәтләр кабатланмасын дип кешелекне уяу булырга чакыру, шомлы хәлләрнең беренче чаткылары күренүгә үк чаң сугып хәбәр ителергә тиешлеген искәртү иде.

... 1997 елның җәендә юллар мине Яна Тинчәлегә алып килделәр. Авыл зиратының кыл уртасында урнашкан кабер янында озак басып тордым мин. Татар зыялысы, мөдәррис, язучы Касыйм Җамалетдин улы Бикколов кабере иде ул. Хәтердә әллә ничек кенә мәгълүм шигырь юллары янарды: «Үлгәннәрнең каберен бел, исәннәрнең кадерен бел!» Күнелдә исә бу сүзләр берләштеләр, кушылдылар да бер җөмләгә әверелеп колагымда чынлап алдылар: «Үлгәннәрнең кадерен бел!» Соңгысын әллә зират читендәге вакыт узу белән уалган, язулары җуелып бетә язган борынгы ташлар, әллә кисәк кенә көчәеп киткән җил, әллә әдип кабере өстендәге мәһабәт тирәк яфраклары пышылдады...

**Фәрит БӘШИР,**
*филология фәннәре кандидаты.*

*Хәтер*

# ҮЗ КЫЙБЛАСЫН ТАПКАН ШӘХЕС

Язучы Хәсән Сарьян бабаларыбызның ел хисабынча елкы елында, кучкар йолдызлыгы баш калкыткан көннәрдә дөньяга килгән (1930 ел, 24 март). Шуңа күрәдер, аңа ат-елкыдай хезмәт итү, тырышлык һәм зирәклек хас булды. Әйе, Ходай аны сәләттән, уңганлыктан мәхрүм итмәгән иде: ни-нәрсәгә тотынса да жиренә житкереп эшли—барысын да булдыра ала торган ир затларның берсе иде ул. Уфа педагогия институтын янарак кына тәмамлаган һәм янарак кына өйләнгән жәендә ул туган авылында ике катлы өй күтәреп куя. Кайчандыр илен-жирен ташлап чит илгә качарга мәжбүр ителгән бабасы йорты үрнәгендә, ата-баба төсе итеп!

Без якыннан танышып, аралашып киткән бер вакытта, 1963 елның жәендә аның ишле гаиләсенә (әдип өч ул үстерә иде) Бутлеров урамындагы бер иске агач йортта бик таушалган фатир биргәннәр иде. Элек анда чирек гасыр чамасы олуг әдибебез Мирсәй Әмир гаиләсе яшәгән. Аннан соң Нури ага Арслан икеөч кыш торып алган иде. Баскыч-балконнары жимерелеп төшкән әнә шул өйне Сарьян жәй буе сипләде, төзекләндерде, идән һәм баскычларын алыштырды, элек келәт урынына файдаланылган бүлмәләрне киңәйтеп, тәрәзәләр уеп, торакны өч бүлмәле иркен фатир рәвешенә китерде. Балта-пычкыларын кулдан төшермәстән үк беренче зур әсәре булган «Әткәм һөнәре» повестен язарга утырды. Ул әсәрне укучылар һәм каләмдәшләре бик хуплап кабул иткәннәр иде.

Сарьян беренче хикәяләрен педагогия институтында укыган елларында яза башлаган. Аның беренче кечерәк хикәяләр тупламасы 1955 елда Казанда басылып чыккан, ә аерым хикәя һәм мәкаләләре Башкортстан вакытлы матбугатында урын алган.

Зирәклеге, эшчәнлеге һәм киң мәгълүматлы булуы нәтижәсендә ул тиз арада олы каләмдәшләре дә таныган әдип һәм галим булып житеште. (Ул Бөре педагогия училищесын, аннары Уфа педагогия институтын кызыл дипломга тәмамлаган, училищеда укыганда ук тел гыйлеменә аерата әһәмият биргән.)

Хәсән Сарьянның 1990 елда нәшер ителгән «Нокталы өтер» китабына остазы, күренекле әдип Әмирхан ага Еники бик тирән эчтәлекле кереш сүз язган иде. Аны ул яшь каләмдәшенең исеменә багышлап башлап жибәрә, «Сарьян» дигән жыйнак, матур исем белән ул әдәбиятка керде», ди. Совет чоры өчен мондый ятрак исемне татар баласына кем кушкан соң? Әйе, милли тарихыбызга, киләчәккә мөнәсәбәттә фикердәшем һәм ижатта остазым булган Сарьянның исемендә үк ниндидер серлелек бар иде шул. Янача тормыш корырга керешкән күпчелек татар гаиләләрендә «Лерон, Вил, Марсель, Эрнест»лар тупырдашып туып торган бер заманда аңа ата-анасы борынгылык—төркилек чалымнарын саклаучы бер исем кушканнар. Бу очракта инде, әлбәттә, мулла-мәзин нәселеннән булган Мәдхижамал апа фикере өстенлек иткәндер. Әйе, ата-анасы аны, берничә кыз баладан соң туган тансык ир затын, борынгы бабаларыбыз мисалында алтынга тиңләп, Сарыжан (Башкортстан ягы язылышында Сарьян) дип атаганнар. Рәсми документларда ул Хәсәнов Сарьян Салихжан улы йөрде. Әдәбият дөньясында Хәсән Сарьян иде, шунлыктан якыннан белмәгән кайберәүләр аңа еш кына Хәсән ага дип тә дәшәрләр иде.

Алты яшеннән ятимлек михнәтләрен кичергән бала ул. Колхозга үз тегермәне белән кергән Салихжан ул чор тормыш-көнкүрешен күнеле белән кабул итеп бетермәгән булса кирәк. Яна түрәләрнен берсе белән ачыктан-ачык сөйләшүдән соң аны йөрәк өянәге кара гүргә алып киткән. Мәрхүм Сарьян соңгы вакытларда:

«Атам мәңгелеккә киткән кырык сигез яшь бусагасын узсам, инәй кебек озак яшәячәкмен», дип сөйләр иде. Язмыштыр инде, ул чикне уза алмады, нәкъ шул яшьтә йөрәк өянәге тотып, якты дөнья белән саубуллашты Сарьян. Шуннан алдарак бер җәйдә туксан яшенә житеп килүче «инәе» Мәдхиҗамал апа аларда кунак булып киткән иде. Безнең бакча карлыганын чәй касәсенә салып болгатыр иде дә: «Безнең Агыйдел буе карагаты татлырак шул. Сезнең ком күп монда», дип әйтеп куяр иде...

«Бер ананың биш улы» әсәрен төгәлләп, «Казан утлары» мөхәррире кулына тапшырганнан соң, 1978 елның җәй урталарында Сарьян ике-өч атна чамасы туган якларында булып кайтты. «Элекке кайтуларда житешә алмаган күрше авылларда да, жиде чакрымдагы базар авылында да булдым. Бала вакытта ул базарга еш йөрелде; Агыйдел болыннарыннан җиләк-җимешне солдат котелокларына тутырыр идек тә, ялантәпи тыпырдашып, шул базарга йөгерер идек», дип сөйләгәне хәтеремдә.



*Әдипнең соңгы фотосурәтләреннән (1978 ел, февраль). Уңнан: Хәсән Сарьян, Лирон Хәмидуллин, Фирүзә Еникеева—Хәсәнова.*

Алдагы әсәрен язып бетерербетермәстән үк ул «Җәза» исемле повесть язарга керешкән иде. Балачак хатирәләренә, атасы язмышына кагылышлырак бер әсәр иде ул. Агыйдел буйларына, балачак эзләрен саклаган Иске Аю авылына да шул хатирәләрне яңартыр өчен дип кайткан иде. Казанга кайтып, өстәл янына утыру белән үк шул повестен яңабаштан эшләргә кереште. Аның төзелеш-сюжетын да, исемен дә үзгәртте. «Егет язмышы» повесте Сарьян вафатыннан соң ике ел узгач кына басылып чыкты. «Җәза» повестеннан анда язучының балачак эзләрен саклаган, авылдан бер читтәрәк торган тегермән тасвиры да, явызларча чәнчеп үтерелгән бер гайрәтле ир образы гына калган иде. Явызларча үлем белән үтерелгән шул ир язмышы минем күз алдыма Салихҗан Хәсәнов язмышын китереп бастыра. Гәрчә аны без белән чәнчеп түгел, сүз белән чәнчеп үтергән булсалар да. Әйе, Сарьянның ул соңгы повесте әнә шул фаҗигале язмышка багышлап иҗат ителгән. Тик аны әлегә бик аз кеше генә белә. Ул заманда аны башкачарак бәян итү, һәркемгә дә аңлаешлырак итеп бирү мөмкин түгел иде. «Җәза»ның караламалары сакланган очракта, аның шулай иҗенлеген аңлау кыен түгел. Аннан соң инде Сарьян иҗаты белән кызыксынучы кешегә Әмирхан абыйның алда телгә алынган сүз башында китерелгән кайбер сәеррәк җөмләләр дә аңлашылыр дип беләм. Әмирхан ага яза: «Талантлы, дәртле, энергияле, кулыннан һәртөрле эш килүенә карамастан, Сарьянның җаны бервакытта да тыныч була алмады, ниндидер бер канәгатьсезлек—әллә үзеннән, әллә тормыштан—аның бәгърен гел кимерде дә торды».

«Әткәм һөнәре» басылып чыккан көннәрдә (1966) Сарьянның икенче зур әсәре—«Нокталы өтер» повесте дә язылып бетү дәрәҗәсендә иде. Дөрес, «Нокталы өтер»не ул күпкә алданрак яза башлаган, тик, басылып чыгачак әсәренең «оеткысы» алданрак өлгерү сәбәпледер, мөгаен, аны берничә елга читкәрәк куеп торган иде. «Нокталы өтер»нең эчтәлеге—Сарьянның Башкорт университетында татар теле һәм әдәбиятыннан укытып йөргән көннәренә бәйле вакыйгаларга корылган. Ул әсәрнең уңай һәм тискәре геройларының чалымнары шул дәвер галим-укытучылары тормышыннан алынган. Рухланып иҗат ителгән, нигездә татар теленең үз халәтенчә яшәеше өчен нәни көрәш мәйданы булырак тәсмерләнгән ул әсәр соңрак авторына бик күп күңелсезлекләр китерде. Бу әсәрнең язмышы—Сарьянга иң авыр тәэсир иткән, җан әрнүен кузгаткан нәрсә булды.

Башта әсәрне нәшрият та, әдәби журнал редакциясе дә хуплап кабул

иттеләр шикелле. Һәрхәлдә, ул 1968 ел урталарында китап рәвешен алачак иде. Нәшрият житәкчелеге апрельнең соңгы көннәрендә кульязманы типографиягә тапшырырга әзерләгән, барлык имзалар куелган, мөһерләр сугылган була. (1990 елда чыгачак китапка мин шул элекке мөһерле кульязманы тапшырдым.) Ләкин Сарьян исән вакытта ул әсәр дөнья күрмәде. Аны тоткарладылар.

Сарьянның 60 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә дусларыннан берсе: «аны КГБ эзәрлекләде, обком түрәләре яратмады, шулар аның бер китабын чыгармадылар», дип сөйләде. Ул атаган оешмаларның каләмдәшемне эзәрлекләү-эзәрлекләмәүләрен тәгаен белмим. Үзеннән: «Эзәрлеклиләр мине» дип, берәр дәлил китереп сөйләгәнен ишеткәнем булмады. Ара-тирә шикләнгәләгән чаклары да булгандыр. Мәгәр, «Нокталы өтер» язмышында әлеге оешмаларның катнашы юктыр дип уйлыйм. Ул китапны чыгармаска дигән карар шул елның март аенда гына сайланган Язучылар берлеге идарәсендә кабул ителде. Көн тәртибенә кертелмәгән ул мәсьәлә үзеннән-үзе калыкты дисәм дә ялгышмамдыр. Хискә бирелүчәнрәк бер өлкән шагыйребез сүз башлап: «Сарьян безнең галимнәребезне мыскыллап язган китап чыгарырга йөри. Телче галимнәребез бармак белән генә санарлык. Ул китапны чыгармаска кирәк», диде. Аның фикерен хуплаучылар булды. Шулай итеп иҗатчының төн йокылары исәбенә язылган бер хезмәте сызып ташланды.



*Татарстан Язучылар берлегендә «Идел» альманахы эшен тикшерүдә катнашучылардан бер төркем. Сулдан: альманах мөхәррире Х. Сарьян, Ә. Баян, берлек идарәсе рәисе З. Нури, М. Маликова, Х. Халиков, Б. Камал, Г. Латыйп, Р. Әхмәтҗан. 1973 ел.*

Шушы вакыйгадан соң Сарьян байтак еллар күләмлерәк әсәр өстендә эшли алмады. Рецензия-тәкъдимнәр, кечерәк күләмле мәкаләләр язуга күчте. Газета битләрендә һәм радио тапшыруларында татар теленең көндәлек кулланышына багышланган очерк-язмалары күренгәләде. (Аның каләмдәшләренең иҗатын барлап, тел, стиль җәһәтеннән үрнәк төзәтмәләр тәкъдим итеп язган мәкаләләренең саны гына да ике йөздән артык.) Ул очерк-мәкаләләрнең бер өлеше 1977 елда басылып чыккан «Уеңны уйдырып сал» китабында урын алган. Дөрес, ул да китап нәшрияты планлаштырган күләмнән кимрәк булып чыкты. Ана кермәгән (рецензент хупламаган) берничә мәкалә, шул исәптән башка беркайда басылмаганнары да мәрхүмнең гаиләсендә, шул исемдәге папкада сакланалар. Кульязмалары арасында шулай ук берничә кыскарак хикәясе дә бар.

Дөрес, шушы ун еллык аралыгында да ул күләмлерәк әсәр язудан бөтенләй ук тынып тормады. Бөре педучилищесында укыган елларында һәвәскәр сукыр артислар төркеменен администраторы булып йөргән дәверне чагылдырган кызыклы повестенын караламасы эшләнеп беткән диярлек, ана, мәрхүм үзе әйтмешли, «ит кундырып чыгасы» гына калган иде. «Җәза» повестен тәгәлләүдән сон ук шуна тотынасы иде. Икенче зур әсәре—ата-бабалары язмышына багышланган зур романына керәчәк кайбер бүлек-өземтәләрне дә ул кайта-кайта язып куйгалар иде. Казан артындагы Масра авылыннан Агыйдел буйларына күчеп утырган ерак бабасы Гәрәйгә багышланган кайбер бүлекләрне дус-иш алдында кычкырып укуы да хәтеремдә. Ул өзекләр язылган зур форматлы калын «амбар кенәгәсе» дә Фирүзә ханымда саклана торгандыр.

Кин җәмәгатьчелек тарафыннан хупланып кабул ителгән «Бер ананын биш улы» повесте әдипнен торгынлык кризисын кичергәннән сон иҗади активлыкка аяк басу үрнәге булды. 1977 елда ул әсәр «Казан утлары» журналында басылып чыкты. Шуннан сон китап нәшриятына тәкъдим ителде. Нәшрият үтенече белән кулъязманы укып анализлау һәм тәкъдим итү бурычы күренекле әдип, әдәбият мәйданына Сарьян белән бер чордарак аяк баскан, бүгенге халык язучысы Аяз Гыйлажевка тапшырылган булган. Менә минем кулда нәшрият архивыннан алынган шул тәкъдим-рецензия язмасы. Укучы хөкеменә шуннан берничә җөмлә китереп китәм. Аяз Гыйлажевнын үзенә һәм каләмдәшләренә карата бик тә таләпчән булуын һәркем белә булыр. (Вакыт-вакыт ул өметне акламаган каләмдәшләренә карата кискен-кискен тәнкыйть сүзләрен кешенен күзенә карап та әйткәли.) Рецензиясенен баш өлешен ул болай башлаган: «Сонгы вакытларда Хәсән Сарьянны берникадәр пассивлыкта гаепли башлаган идек. Хәрәкәт пассивлыгында түгел, фикер пассивлыгында... Ничектер, фикер кузгатырлык әсәр язмый йөрде егет. Һич кирәкмәскә, һаман шул «Нокталы өтер»ен күтәреп килгәләде. Ләкин талантлы кеше турында ашыгып нәтиҗә ясарга кирәкми икән. Менә «Казан утлары»нда «Бер ананын биш улы» басылды. Сонгы ике-өч елда журналда басылган бердәнбер жанлы, тере, мавыгып укыла торган повесть шул булды дисәк тә ялгышмабыз» (апрель, 1978 ел).

«Һаман шул «Нокталы өтер»не күтәреп килгәләде» дигән җөмләгә карата гына анлатма биреп китү кирәктер. Сарьян ул әсәрен бик нык үзгәртеп, янабаштан эшләгән иде. Шул сонгы вариантын журналга тәкъдим иткәнлеге мәгълүм. Әсәрнен исемен үзгәртсә, мөгаен, журналда басылган да булыр иде. Үзгәртергә теләмәде...

Ятимлек кыерсытылуларын татып үскән, кайбер олы каләмдәшләренен гаделсез гамәлләрен тоеп яшәгән Сарьян дустыбыз иҗади күтәрелеш кичергән бер мәлдә арабыздан китте. Бик тә үкенечле хәл. 1978 елнын 21 сентябрендә без аны, кырык сигез яшьлек гаярь ир затын, җир куенына индердек... «Бер ананын биш улы» китабы анын вафатыннан сон, 1979 елда басылып чыкты.

**Лирон ХӘМИДУЛЛИН**

*Фатих Кәриминең тууына 130 ел*

# ЯҢА МӘДӘНИЯТЫБЫЗНЫҢ «БАШ КОНСТРУКТОРЫ»

Фатих Кәрими—талантлы халкыбызның иң сәләтле, киң колачлы, эшлекле улларыннан берсе. Ул—остаз-педагог, язучы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, журналист... Һәр юнәлештә кабатланмас нәтиҗәләргә ирешкән, халкы һәм замандашлары алдында, зур абруй казанган мәшһүр кешеләрдән. Әйе, Фатих Кәрими һәрбер эшендә, «беренчеләрдән» дигән билгеләмә алырлык, халыклар тарихында сирәк очрый торган бәхетле язмышлы, инициативалы шәхес.

Фатих Гыйльман улы Кәримов 1870 елның 30 мартында, хәзерге Әлмәт районының Миңлебай авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Гыйльман ахун—үз заманының алдынгы кешесе, Бөгелмә өязендә җәдитчелек мәктәп-мәгариф системасын яңартуны башлап җибәрүче һәм җитәкләүче кешеләрдән була. Яңа мәктәпләр өчен яңа дәреслек китаплары төзи һәм үзе дә яза башлый. Фатих башта әтисенең Миңлебай авылындагы мәктәбендә, аннары унбер ел Чистайның мәшһүр Закир ишан Камалов мәдрәсәсендә белем ала. 1892 елда Төркиягә китеп, Истанбулның Мөлкия югары мәктәбен тәмамлый. Төркиядән яңа мәктәп системасы һәм яңа төрек әдәбияты белән якыннан таныша. 1896 елда Ф. Кәримине Ялта шәһәре читендәге «Дара күй» авылы мәктәбенә укытучы итеп чакыралар. Ф. Кәрими—җәдитчелек хәрәкәтен яңа баскычка, массакүләм күренешкә әйләндергән буын вәкиле. Кырымда татар җәдитчелек хәрәкәтенең башлап йөрүчеләреннән берсе булган Исмәгыйль Гаспралы белән аралаша. Кырымда яшәгәндә әдипнең язучылык хезмәте башланып китә. Беренче әсәрләре белән үк ул шул чордагы татар әдәбиятының иң алдынгы сафына баса. Әдәбиятның якын киләчәктә үсеп китәчәк тема, материал, структураларын билгели, яңа реалистик әдәбиятыбызның офыкларын киңәйтә. Темасы, материалы, образлары, эшләнү үзенчәлекләре ягыннан караганда, «Мирза кызы Фатыйма» повесте аның Кырымда язган беренче әсәре булырга охшый (1901 елда «Заман календаре»ндәге басмасында һәм 1907 елда аерым китап итеп чыгарылганда да язылган елы күрсәтелмәгән). Повесть морзалар тормышыннан алып язылган. Соңыннан бу тема Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» (1912) һәм С. Җәлалның «Дим буенда» (1913) романнарында да яктыртыла. 1897 елда Ф. Кәрими әдәбиятыбызда «табигать балалары» темасын башлаган һәм бу юнәлештәге әсәрләрнең иң камилләреннән берсе булган «Салих бабайның өйләнүе» хикәясен яза.

Әдип укытучы булып Кырымга киткән елда Оренбург бае Гани Хөсәенов, батырчылык итеп, яңа (җәдит) мәгариф челтәрен татар, башкорт, казакъ халыклары тормышында массакүләм күренешкә әйләндерү эшенә алына. Каргалыда, җизнәсе мәдрәсәсендә, җәдитче укытучылар әзерләү курслары оештыра. Бу курсларга татарлар яши торган төбәкләрдәге күренекле мәдрәсәләрдән өлкән сыйныф шәкертләрен укырга чакыра. Аларның юл хаҗәтләрен һәм уку дәверендә материал тәэмин итүне үз өстенә ала. Янача укытырга өйрәнгән укытучыларны татарлар яши торган барлык төбәкләргә тарата, аларга хезмәтләре өчен хак түләүне оештыра. Каргалы курслары беренче елларда янача хәреф таныту ысулын гына өйрәтә. Алга таба исә дүрт сыйныфлы башлангыч мәктәп укытучыларын әзерләү сорала. Бу эшне оештыру өчен яхшы әзерлекле белгеч кирәк була. 1898 елда Гани Хөсәенов менә шул эшкә Фатих Кәримине чакырып кайтара. Гани бай кулында материал тәэмин итү эше генә калып, курсның укытучылар әзерләү бурычлары тулысынча Фатих Кәрими өстенә төшә: ул татарлар яши торган бөтен төбәкләрдә яңа, җәдит мәгариф челтәре оештыру эшенең баш җитәкчесенә әйләнә. Бу очракта шунысын искәртеп узу урынлы булыр: әлеге хәрәкәт башка кардәш халыкларда аерым очрак

дәрәҗәсеннән узмаган. Гани бай Хөсәенов һәм Фатих Кәриминен тырышлыклары нәтиҗәсендә, җәдитчелек татар мәгариф челтәрендә әйләп баручы юнәлешкә әйләнә. Шунын җирлегендә татар халкы үзенен үсешендә башка кардәш халыклардан алга китә. Яна татар әдәбияты һәм матбугат үсешенә уңай йогынты ясарлык әзерлекле көчләр шул нигездә барлыкка килә. Фатих Кәрими үзе дә яна мәгариф челтәрен төзү эшен әдәби иҗат белән бәйләп бара. Бу чорда язган уңышлы әсәрләреннән «Шәкерт илә студент», «Җиһангир мәхдүмнен авыл мәдрәсәсендә укуы» (1898) повестьларын, «Нуретдин хәлфә» (1900) хикәясен күрсәтергә мөмкин. Заман таләпләренә җавап бирмәгән иске (кадим) мәктәпләрне, андагы тәртипләрне әдип эче сатира белән камчылый. Бу тема да, беренче башлап, Фатих Кәрими әсәрләрендә шундый актуальлеккә һәм үткенлеккә күтәрелә. Шуннан сон, 1917 елларга кадәр, мәдрәсә тормышы әдәбиятта ин шаулы темаларнын берсе булып кала. Закир Һадинын «Яна әсхабе кәһәф», Гаяз Исхакыйнын «Тормышмы бу?», «Мулла бабай» романнарында күренекле урын тоткан мәдрәсә-шәкертләр тормышы күренешләре Фатих Кәриминен бу өлкәдә нинди үткер күзле булуын шактый калку искәртәләр.



Беренче карашка, Фатих Кәриминен биографиясе бернинди чайкалу киеренкелекләренә юлыкмаган кебек, ул—укый, эшли, яналыкка тартыла. Ә яналыклар аяк астыннан чыгып кына тора: Гани бай (алтын табучы Рәмиевләр катнашында) Оренбургта татарча китап нәшрияты ачмакчы була. Шул ниятен тормышка ашыру өчен ул 1899 елда Фатих Кәримине Мәскәүгә нәшрият эшенә өйрәнергә җибәрә. Фатих Кәриминен этисе Гыйльман Кәримов исеменә матбугат сатып алалар. Шулай итеп, әдип Оренбургта татар китапларын бастыру эшен башлап җибәрә: зур эш, халык мәдәни хәрәкәтендә күренекле вакыйга була бу. 1906 елда Уральск шәһәрендә чыга башлаган «Фикер», «Әлгасрелҗәдит», «Уклар» кебек басмалар да баштарак Фатих Кәрими басмаханәсендә басылганнар. Әдәбият өлкәсендәге мондый янарышларны ул үзе «табып ала», әдәбият тормышында кайда, нинди яналык житлеккәнен башкалардан күпкә алдарак күргән, аны бөтен нечкәлекләренә кадәр анлый алган. Төрекөмеш кебек тере-житез әдип кадими мәдрәсәләрне сатира утына тотып, әдәбиятта яна кинлекләргә омтыла, хатын-кыз проблемасын яна, заманча хәл иту эшенә алына. 1899 елда төрек язучысы Шәмсетдин Самибәкнен «Хатыннар» китабын тәржемә итә һәм Оренбургта бастырып чыгара. Аннан сон «Хатыннар вазаифе» һәм «Белгеч кыз», «Телсез хатын» тәржемә әсәрләре дөнья күрә. Болар әдип эзләнүләренен житдилеген искәртеп торалар. Ниһаять, иҗатында яна зур казаныш булган, әмма әдип мирасыннан төшеп калган, онытылган «Кайнана» повесте мәйданга килә (1902). Бу әсәр—яшьләр арасындагы иреклә яна мөнәсәбәтләр шигърияте. 1902 елдагы беренче басмасынын кереш сүзендә ул аны тәржемә әсәр дип тәкъдим итә: бер гәзиттә шул әсәрне очраткан да, имеш, тәржемәсен әзерләп бастырасы иткән. Әмма авторынын кемлеген, нинди телдән, кайдан алынганлыгын күрсәтми. Әсәрнен яна басмасы чыккач, «Вакыт» газитендә басылган «Китап игъланы»нда («Вакыт», 1907, Т 308, 22 апрель) һәм 1913 елдагы яна игъланда («Вакыт», 19 июнь) Фатих Кәрими әсәре дип ачык билгеләп үтелә. Әмма бу гүзәл әсәр, төрле тышкы сәбәпләр нәтиҗәсендә, әдип мирасыннан кисеп ташланган, онытылган. Һичкайчан ул анын әсәрләре исемлегендә үзенә тиешле урынны ала алмаган. Хәлбуки, татар гаиләсендәге үзара мөнәсәбәтләр темасы да, «табигать балалары», иске мәдрәсәләр кебек үк яна татар әдәбиятынын терәк баганасы булып торган «Кайнана» повесте да Фатих Кәриминен генә түгел, гомумән гасыр башы татар әдәбиятынын уңышы булып саналырга хаклы.

1899 елда әдип тормышында житди бер борылыш була—ул Шакир Рәмиевкә иптәш һәм тәржемәче буларак, Европа илләре буйлап зур сәяхәттә катнаша. Алар, 1899 елнын 15 февралендә Оренбургтан кузгалалар. Мәскәүдә—8 көн, Петербургта—10 көн, Берлинда—8 көн, Германиянен төрле шәһәрләрендә—8 көн, Брюссельдә—9 көн, Парижда—13 көн булалар һәм һәр җирдә музейларны, күргәзмәләрне карап йөриләр, мәдәни, технологик казанышлар белән танышалар. Алдынгы җәмәгатьчелек вәкилләре белән очрашалар. Төньяк Италия, Австрия, Венгрияне гизеп, Истанбул шәһәре аша июньдә

генә туган шәһәрләренә әйләнеп кайталар. Шул сәфәр материаллары нигезендә Фатих Кәрими «Аурупа сәяхәтнамәсе» дигән әсәрен яза. Әсәр 1902 елда Петрбургта Бораганский матбагасында басылып чыга. Язучы буларак, Фатих Кәримине әдәби хикәяләүнен хикәя, повесть кебек гадәти, тотрыклы бер калыпка салынган беллетристик формалары гына канәгатьләндерә алмый, ул сәфәр хатирәләре нигезендә әдәбиятыбызнын уникаль, яна матур казанышын гәүдәләндергән әсәр ижат итә. Сәяхәт язмалары сәяхәтнамә өлгесендә язылган, әмма сәяхәт биредә хикәяләүгә сылтау гына, хикәяләү юнәлешенен пунктиры гына. Автор үзенен максатына яраклы материалларны гына игътибар үзәгенә ала. Әсәрдә сәяхәт язмалары—сәяхәтнамәләр өчен үзенчәлекле булган, табигый-географик сурәтләүләрнен тарихи-этнографик экскурсларнын эзе дә юк. Әйе, бу әсәр гади традицион юнәлешендәге сәяхәтнамә генә түгел. Әдип сәяхәт материалларын анда бөтенләй башка максатларда файдалана. Анлашылса кирәк, монарчы язылган әсәрләрендә ул яналыкны һәм анын зарурлыгын негатив планда, искелекнен ни дәрәжәдә яраксыз, мәгънәсез, зарарлы булуын күрсәтү аша билгеләсә, «Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәрендә исә, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, киләчәккә барунын, чын тәрәккыятнен тарихи расланган, конкрет юнәлешен, анын уңдырышлы перспективасын тасвирлый. Ул укучыларын ана илтүче яна идеал-омтылышлар, яна ымсынулар, яна карашлар, яна белемнәр, яна сәләтләр системасы белән таныштыра. Үзе һәм Шакир әфәнде мисалында шул максатларны кыйбла һәм яшәү рәвеше иткән ватандашлары барлыгын искәртә. «Аурупа сәяхәтнамәсе» шул рәвешчә яна татар әдәбиятынын идеологик-мәгънәви мөмкинлекләрен яна югарылыкка күтәрә, анын колачын, офыкларын киңәйтеп җибәрә. 1904 елда басылып чыккан, шул ук калыпта язылган «Кырымга сәяхәт» әсәрендә ул үзенен бу казанышын тагын кабатлый: татар тормышындагы янарыш каршылыкларын һәм уңышларын гәүдәләндереп күрсәтә. Башка алдынгы язучылар да бу төр гомумиләштерү-сурәтләү мөмкинлекләрен шунда ук күреп алалар һәм үз ижат үсешләрендә файдаланалар. Әйтик, Гаяз Исхакый 1904 елда шундый ук гадәти булмаган «Ике йөз елдан сон инкыйраз» дигән әсәр бастыра. Күрәсен, Исмәгыйль Гаспралы да үзенен «Дарессәлам мөселманнары» дигән утопик әсәрен шул фактлар тәэсирендә янабаштан, зурайтып эшләп бастырырга мәжбүр булган. Морзалар, «табигать балалары», иске мәдрәсәләр дөньясы, ханымнар даирәсен тасвирлауга, «сәяхәтнамә»ләрендәге гадәти булмаган сәнгатьле гомумиләштерү-типлаштыруларга—яна татар әдәбияты үсешенен магистраль юлын тәшкил иткән юнәлешләргә, башлап, Фатих Кәрими эз сала, бу темаларны сурәтләүнен гомуми принципларын формалаштыра. Бүгенге әдәбиятта инде бөтенләйгә игътибарга алынмый торган шундый казанышларын күз алдында тотып, Фатих Кәримине (аз да түгел, күп тә түгел!) яна татар әдәбиятынын «баш конструкторы» дип атау дөрес булыр иде.

1905 ел революциясе әдәбиятта көчләр нисбәтен төптән үзгәртә. Әдәби мәйдан яна буыннар, яшь көчләр кулына күчә. Гаяз Исхакый ижаты яна биеклеккә күтәрелә. Әдәбият-сәнгатьтә дөнья (Аурупа) стандартларына якынаю әдәбиятнын яна үлчәменә әйләнә. Шул рәвешле чор һәм заман таләбен халкынын һәм татар әдәбиятынын нигез проблемалары белән органик бердәмлеккә китерүдә янадан-яна нәтижәләргә ирешкән Гаяз Исхакый әдәбиятта баш яугир була бара. 1905 елдан сон ижат итә башлаган Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимжан Ибраһимов кебек яшьләр мәйданны үз кулларына алалар. Фатих Кәрими әдәби хәятнен бу ярышында катнашмый, ул күләгәдәрәк кала бара кебек. Дөрес, башкарак өлкәләрдә,—сәяси хәрәкәттә һәм газитчелек өлкәсендә,—ул олы талантына лаеклы урын табып, халкы тәрәккыятенен алгы сафында кала алган. Алай гына да түгел, бу өлкәләрдәге тәжрибәләрен һәм казанышларын әдәбиятнын житлегеп килгән яна мөмкинлекләре белән берләштереп, теге «конструкторлык» миссиясен 1917 ел революцияләре көннәренә кадәр дәвам иттерә алган. Беренче Дәүләт Думасында (1906) Мөселман фракциясе оештырылгач, Фатих Кәрими сәяси кинәшче вазифасында Петербургка эшкә чакырыла. Өч ай да яши алмый, Дума таркатыла, куып таратыла. Шул Дума фракциясендә эшләү тәжрибәсе нигезендә, Фатих Кәрими «Хыялмы, хакыйкатьме?» (1907) дигән повесть яза. Татар әдәбияты өчен өр-яна мохит—дәүләт думасы эшчәнлеге, татар депутатынын колоритлы образы, Дума жыелышлары үткәрелә торган Таврия сарае, депутатларнын эшләү һәм яшәү ритмы һ. б. шундый эпизодлар шул чор татар әдәбиятында бөтенләй яна күренеш була. «Депутат» темасы шуннан сон әдәбиятыбызда (Фатих Кәримидә билгеләнгән чикләрдә) Ш. Камалнын шул исемдәге хикәясендә генә кабатлана.

1906 елнын 21 февраленнән Оренбургта «Вакыт» исемле татарча газит чыгарыла башлый. Оештырыла башлаган көннәреннән алып, 1917 елнын азакларына кадәр, Фатих

Кәрими бу газитнен алмашсыз редакторы була. Газитнен халкыбыз тормышында ин игътибарлы басмага әйләнүендә Фатих Кәрими тырышлыгы, булдыклылыгы бәхәссез, хәлиткеч роль уйнаган. Балкан сугышы (Төркиянең Балкан илләре белән бәрелеше) башлангач, 1912 елның 1 ноябрендә, «Вакыт» газитенең хәбәрчесе сыйфатында, Фатих Кәрими Төркиягә китә (1913 елның 18 мартында гына Оренбургка әйләнеп кайта). Төркиядәге хәлләрне күзәтүләре, тикшерүләре, шул хакта уйланулары турында «Вакыт» газитенә (һәм өлешчә «Шура» журналына) ул хатлар җибәреп тора. Бу язмалар шунда ук газит битләрендә басыла да баралар. Туган иленә әйләнеп кайткач та әдип аларны «Истанбул мәктүпләре» исемендә зур китап итеп (450 б.) әзерләп бастыра. Билгеле булганча, Балкан сугышы Госманлы (төрек) империясенең җимерелүенә китерде. Госманлы империясенең җимерелүе исә яна заманның бөек империяләре (Австро-Венгрия, Герман империяләре, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, Британия һәм Француз колониаль империяләре, безнен көннәрдә—Россия империясе—СССР) җимерелү, таркалу процессын башлап җибәрде. «Истанбул мәктүпләре»ндә Фатих Кәрими империянең җимерелү халәтен, механизмын, социаль алшартларын сурәтләп бирде. Китап—сугыш хәбәрләре дә түгел, хатлар, газит мәкаләләре дә түгел. Әйткәнебезчә, бер темалы, конкрет материал нигезендә, монументаль тарихи процессны анализлаган уникаль әсәр. Ул яна әдәбиятта «яна конструкция» үрнәге булган. Фатих Кәрими иҗатына игътибарлы үтә сизгер Галимҗан Ибраһимов (морзалар тормышы, «табигать балалары» темаларын гына искә төшерик) «Безнен көннәр» һәм «Казакъ кызы» романнарында «Истанбул мәктүпләре»ндә күтәрелгән проблематиканы беллетристика яссылыгына күчерә. Кызганыч, бүгенге укучы (һәм әдәбият фәнебез дә) Фатих Кәриминең мәҗбүри оныттырылган «Истанбул мәктүпләре»н дә, аның проблематикасын да инде бөтенләй белми.

Юк, 1905 елдан соң да әдип әдәбияттан газиткә, сәясәткә китмәгән, сәясәттә дә, газиттә дә әдәбиятчы булып калган. Матбугатта очраклы рәвештә генә күзгә чалынган хәбәрләрдә дә аның гомеренең азагына кадәр актив иҗат иткәнлеге ачык күренә. Ул хәтта драматургиягә, балалар әдәбиятына да үзеннән өлеш кертә. «Вакыт» газитәсендә (1917 ел, 1 март, N 2185) Оренбургның «яшүсмер вә укучы балалары өчен» махсус Фатих Кәрими әсәре буенча «Салих бабай өйләнә « спектакле куелганлыгы турында хәбәр бар. Революциядән соң да әдипнең халкына актив хезмәт күрсәтергә теләп яшәгәнлеген күрәбез. Әмма «Вакыт», «Шура»ларны ябып, яна хакимият аны матбугаттан мәхрүм итә. Совет матбугаты битләрендә андый «буржуаз» әдипләрне якын җибәрмәскә мәш киләләр. Ә ул «ишектән кусан, тәрәзәдән үтмәкче»: үзенең дәреслек китапларын бастыра. Тәрҗемә өлкәсенә күчеп, В. Бартольдның «Төркестан тарихы» китабын татарчага тәрҗемә итә һәм Мәскәүдә, Бохара халык мәгарифе нәшриятында бастырып чыгара (1924). Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романын урысчага тәрҗемә итеп, Мәскәүнең ГИХЛ басмасына тапшыра. «Буржуаз» шәүләсе йогудан куркып, Галимҗан Ибраһимов бу тәрҗемәдән баш тарта (Гөлсем Мөхәммәдева, «Олы юл», 233 б.). 30 еллар башында аның замандашлары һәм үз заманасы турында истәлекләр китабы язып, басмага тапшырганлыгы турында да хәбәр бар. Хәбәр бар, әмма басма юк. Кульязма үзе дә юкка чыгарылган. Хәзер гоманларга гына кала: чорының мәдәни-әдәби хәрәкәте үзәгендә кайнаган шәхес киләчәккә күпме яна хәбәрләр тапшыра алган булыр иде. Әмма татар яшәеше мәдәни кыйммәтләрне күбәйтүгә түгел, юкка чыгару дулкынына корылган шул.

Талант һәм фаҗига... Күп очракта бу төшенчәләр янәшә йөри. Фатих Кәриминең язмышы да аянычлы тәмамлана. Картаюны, вакланүны, сүрелүне белмәгән иҗат тоталитар режим өчен куркыныч күренеш. 1937 елда Фатих Кәриминең бу тынгысызлыгына чик куела. Әдип кулга алына. Бер ай эчендә «тикшерү», «хөкем кәмите» эвәләп, төрек шпионы дигән нахак гаеп нигезендә аны шундук атып үтерәләр. Исеме әдәбияттан, татар халкы мәдәнияте тарихыннан сызып ташлана. 1957 елда реабелитацияләнгәннән соң да ул берничә әсәре белән югары уку йортлары татар әдәбияты курсларына гына кайтарыла. Фатих Кәрими иҗатын мәдәниятебез тормышыннан читләштерү үзе ук шомлы күренеш, олы югалту ул. Габдулла Тукай, Фатих Әмирханнар үрнәгендә (һәм күләмендә) аның күп томлыгын яшәешебезгә кайтару—әдәбиятыбызның колачын хисапсыз киңәйтер, җирлеген, тамырларын тирәнәйтер иде.

**Мәсгуд ГАЙНЕТДИН,**
*филология фәннәре кандидаты.*

**Китап күзәту**

# QURAY MOŅI QAYTA...

Tatar muzıkasın uqıtu ɵçen xəzer hɵnəri muzıkal' belem birü ɵlkəsendə yaņa əsbaplarğa, dəreslekləŗgə şaqtıy ğına qıtlıq tudı. Həm ənə şul qıtlıqnı beterü maqsatında küp kenə fidaqər canlı muzıkantlar qatnaşında ber matur xərəkət tə başlanıp kitte. Min biredə məktəplər, urta həm yuğarı uqu yortları ɵçen dəreslekler buldırunı küzdə totam. Bu eştə başlanğıç sıynıf məğəllimnərennən alıp konservatoriə professorlarına xətle qatnaşa. Mədəniət ministrlığı qarşındağı metodik kabinet (citəkçese—N. B. Arşinova) isə bu yünəleştə yaņa niətlər həm inisiativalar tuuğa, alarnı ğəməlgə aşıruda bulışa.

Menə şunıņ işe urtaq tırışlıqlar nəticəsendə soņğı yıllarda yegermedən artıq qullanma bastırıp çığarıldı. Alar arasında S. Rəimovanıņ «Tatar muzıkası sol'fedjio dəreslərendə», «Bittən uqu ɵçen xrestomatiə», «R. Yaxin. Fortepiano ɵçen yazılğan əsərlər» (ɵç çığarılış), V. Dulat-Alinıņ «Tatar muzıkal' ədəbiətı» həm başqalar bar. Yuğarıda sanap kitelgən ələge bik qəderle həm tansıq kitaplarğa küptən tügel tağın ber qullanma kilep ɵstəlde. Qazan şəhəre mədəniət idarəseneņ 3 nçe muzıka məktəbe direktorı İldus Almazof tɵzegən «Qurayda uynaw sabaq-ları» digən kitap basılıp çıqtı.

Bu—quray ɵçen maxsus tɵzelgən həm kamilləşterelgən berençe qullanma. Elekkerək yıllarda bezdə qurayğa bik ük iğtibar yuq ide. Ul səxnədə də sirək kürende, anda da xalıq uyın qoralları ansamble belən bergə genə. Ə xəzer muzıka məktəplərendə, uçilişçelarda həm xətta konservatoriədə də, başqa tınlı uyın qoralları belən bergə qurayda da uynarğa ɵyrətələr.

Əye, bügen quraynı iņ kiņ taralğan uyın qorallarınnan berse disək, hiç tə yalğış bulmastır, mɵğayın. Ul muzıka məktəplərendə bigrək tə iğtibar üzəgendə tora. Ələge qullanmanı tɵzep çığaruçı İldus əfənde Almazof isə bu yünəleştə aktiv eş oyıştıruçı bularaq tanıldı. Quray—tərki xalıqlar arasında milli uyın qoralı bularaq ğayət tə kiņ taralğan. Elekke zamannarda ul qura digən üsemlektən ozınlığı 45-100 sm çaması itep eşləngən, altı urında tişege də bulğan. Soņğı yıllarda inde anı tɵrle materialdan yasıy başladılar. Bezneņ kɵnnərdə Qazan qurayınıņ ostası bulıp kompozitor İfrat Xisamof sanala. Bez süz alıp bara torğan kitapnıņ avtorı aņa üzeneņ kiņəşləre ɵçen rəxməten də belderə.

Kereş süzendə İ. Almazof uquçını bu instrumentnıņ qısqaça tarixı belən tanıştıra, şaqtıy qızıqlı məğlümat birə, xəzerge quraynıņ mɵmkinleklərenə tuqtala.

Ə inde kitapnıņ tɵp eleşenə küçsək, berençe bülektə—qurayda uynıy başlawnıņ tɵwge adımnarı, künegü-künekmələr bəyan itelə. İkençe bülektə yalğız quray ɵçen xalıq moņnarı birelə. Ɵçençe bülek quray həm fortepiano ɵçen eşkərtmələr təqdim itə h. b. Hər bülek «ğadidən—qatlawlığa» prinsibı buyınça tɵzelgən həm, avtor fikerençə, qurayğa ɵyrənü waqıtında ələge bülеklərdəge materiallarnı yənəşə də qullanırğa mɵmkin.

Tağın şunısı da mɵhim: biredə təqdim itelgən eşkərtmələrne, əsərlərne fleyta, gaboy, klarnet, bırğı işe bütən uyın qoralları ɵçen də bik rəxətlənep faydalanırğa bula.

Uquçıbız inde sizgənder, aņlağandır—bu qullanma tatar telendə basılıp çıqqan. Şuņa kürə moņarçı xalıqara terminnar bularaq qına qullanılğan muzıkal' atamalarnıņ tatarça tərceмələre də biredə bik unışlı faydalanılğan.

Mondıy əybət kitaplar basılğaç, xəzer inde bezneņ kompozitorlarıbız da quray ɵçen yaņa matur kɵylər icat itərlər həm bigrək tə balalarıbıznı, yəş buınnı estetik tərbiələwdə, milli ruxqa yaqınaytuda üz ɵleşləren kübrək kertərlər dip ışanabız.

**Tənzilə ARSLANOVA,**
*səngət fənnəre kandidatı.*

# Укучы сүзе

* * *

Хөрмәтле редакция!


“Туксанынчы еллар әдәбияты” дигән сөйләшү миндә бик уңай тәэсир калдырды. Ул һәм журнал укучылар, һәм язучылар өчен файдалы булгандыр, дип ышанам. Шул уңайдан кайбер фикерләремне Сезгә дә язып җибәрергә булдым.

Туксанынчы еллар татар әдәбиятының уңай сыйфаты—әсәр геройларының гел ап-ак яки гел кап-кара итеп сурәтләнмәвендә. Алар эзләнәләр, ялгышалар, үз гамәлләренә тәнкыйть күзлегеннән карый беләләр. Шулай да еш кына татар прозасындагы байтак татар кешеләренен, уңай геройларның татар әдәбиятыннан һәм сәнгатеннән, татар теленнән куәт ала алмауларына гаҗәпкә каласың.

Азатлыкны матур кәгазьгә төреп бирерләр дип көтеп торган кешеләр тәрбияләүче, аракы эчүне, тәмәке тартуны рекламалаучы әсәрләрнең поты бер тиен булды, шулай булып калыр да. Әллә нинди әйбәт экономик шартлар тудырганда да халык андый кибәк, буш әсәрләрне укымаячак, андый әсәрләргә омтылмаячак.

**Җәүдәт ХӨСӘЕНОВ,**
*Кукмара районы.*

* * *



Хөрмәтле Флүс Латыйфи әфәнде!*

Сезне барчабыз җандан хөрмәт вә сәламнәребез берлән тәбрик итәмез яңа 2000 ел вә киләчәк мөбарәк “гаед фытыр” бәйрәме берлән. Мөбарәк булсын!

Бу олуг көннәремез хәерле сәгатьтә килгән булып Сезгә, барчагызга тулы исәнлек, тыныч, рәхәт тормышлар эчендә яшәп, кәтелмәгән шатлыклар күреп, каршы алырга Аллаһ насыйп итсен дип чын күңелемездән теләп каламыз. Амин!

“Казан утлары”ның 5 вә 6 (1999 ел) саннарында басылган романыгызда, исемнәр үзгәртелгән булса да, анда мине дә күз каршыгызга китергәнгә күрә, Сезгә чын йөрәктән рәхмәтләремне белдерәм. Аллаһы Тәгалә Сезгә озын-озын гомерләр яшәргә насыйп итсен дигән догада калам. Бик-бик зур рәхмәт Сезгә.

Хөрмәт вә сәламнәребез берлән, эшләрегездә тулы уңышлыклар теләп:

**Әмруллаһ—Шәмсенур АГИ вә балаларымыз.**
*Нью-Йорк.*
22/XII-1999.

* * *

Исәнмесез, Марат Әмирханович!

Сезне ихлас күңелдән яңа әсәрегез “Тәкъдир” романы (К. У. № 10,11-1999) белән тәбрик итәбез. Ул тормышның үзе. Ул тормыш ваклыкларыннан өстен торырга, гомернең һәр мизгеленең кадерен белергә, якыннарыңа игътибарлы һәм мәрхәмәтле булырга өнди. Романның китап булып дөнья күрүен генә көтәргә кала.

**Дания Сөярбаева-Рәупова,**
**Марсель РӘУПОВ.**
*Баулы.*

---

*Хатта автор стилистикасы сакланды.

## Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча дәүләт комиссиясе турында Россия Федерациясе хөкүмәте

# КАРАРЫ

**2000 ел, 28 гыйнвар, № 79, Мәскәү шәһәре**
**Россия Федерациясе хөкүмәте карар бирә:**

Россия Федерациясе Президентының «Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында»гы 1999 ел, 1 сентябрь, 1141 нче Указы нигезендә (Собрание законодательств Российской Федерации, 1999, № 36, ст. 4382) төзелгән Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча дәүләт комиссиясе турындагы положениене һәм аның составын расларга.

Күрсәтелгән дәүләт комиссиясенә Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлекнең төзелергә һәм реконструкцияләнергә тиешле корылмалары, күләмнәре һәм финанслау чыганаклары, күрсәтелгән программасы проектын эшләп, 2000 елның августына Россия Федерациясе хөкүмәтенә тапшырырга.

**Россия Федерациясе Хөкүмәте рәисе**
**В. ПУТИН.**

### Казан шәһәренә нигез салынуның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча дәүләт комиссиясе

**Путин В.В** —Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе *(комиссия рәисе)*.
**Матвиенко В. И** —Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе урынбасары *(комиссия рәисе урынбасары)*.
**Миңнеханов Р. Н.**—Татарстан Республикасы Премьер-министры *(комиссия рәисе урынбасары)*.
**Блохин А. В.**—Россия Федерациясенең Федерация һәм милләтләр эшләре министры.
**Ванин М. В.**—Россия ГТКсы рәисе.
**Газизуллин Ф. Р**—Россия Федерациясе дәүләт милке министры.
**Геращенко В. В.**—Россия Банкы Рәисе *(килештерү буенча)*.
**Егоров В. К.**—Россия Федерациясе мәдәният министры.
**Иванов И. С.**—Россия Федерациясе тышкы эшләр министры.
**Иванюженков Б. В.**—Россия Федерация физкультура, спорт һәм туризм министры.
**Исхаков К. Ш.**—Халык депутатларының Казан Советы рәисе, Казан шәһәре хакимияте башлыгы *(килештерү буенча)*.
**Коренев Н. Г.**—Россия Федерациясе Хөкүмәте аппаратының региональ үсеш департаменты башлыгы урынбасары *(комиссия сәркатибе)*.
**Кудрин А. Л.**—Россия Федерациясе финанс министрының беренче урынбасары.
**Лесин М. Ю.**—Россия Федерациясенең матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм аралашу чаралары министры.
**Мөхәммәтшин Ф. М.**—Россия Федерациясе Хөкүмәте аппаратының федераль җыелыш, иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәләр белән элемтә департаменты башлыгы.
**Пиотровский М. Б**—Дәүләт Эрмитажы директоры *(килештерү буенча)*.
**Починок А. П.**—Россия Федерациясенең салым һәм җыемнар министры.
**Рушайло В. Б.**—Россия Федерациясенең эчке эшләр министры.
**Самохвалов А. Ф.**—Россия Федерациясенең икътисад министры.
**Таль Г. К.**—Россиянең ФСФО җитәкчесе.
**Франк С. О.**—Россия Федерациясенең транспорт министры.
**Фурсенко А. А.**—Россия Фәннәр академиясенең тарих бүлеге академик-сәркатибе *(килештерү буенча)*.
**Хәсәнов М. Х.**—Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты *(килештерү буенча)*.
**Церетели З. К.**—Россия Федерациясе сәнгать академиясе президенты *(килештерү буенча)*.
**Шамузафаров А. Ш.**—Россиянең Госстрой рәисе.

## «Казан утлары» журналының баш мөхәрриренә

*Бик күп халык вәкилләре һәм җәмәгать оешмаларының мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты 1552 елда Казанны саклаганда һәлак булган каһарманнар истәлегенә багышлап һәйкәл төзү турында үткән ел 93 номерлы карар кабул итте.*

*Шушы карарны үтәү нигезеннән, һәйкәлне төзү өчен махсус фонд оештырылды. Фондның төп максаты—бу һәйкәлне кору өчен төрле чыганаклардан акча җыю.*

*Фонд исеменнән, аның максатлары һәм бурычлары хакында, Сезнең журнал битләреннән укучыларыгызга мәгълүмат бирүне үтенеп сорыйбыз. Сезнең тарафтан мондый ярдәмне бу изге эшкә Сезнең хәйрия дип санар идек.*

**1552 елда Казанны саклаганда һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл төзү фонды**

## Хөрмәтле туганнар! Мөхтәрәм җәмәгать!

Белгәнебезчә, моннан 447 ел элек, канлы бәрелешләрдән соң, Казан ханлыгы дәүләт буларак яшәүдән туктап, рус дәүләтенә кушылды. Казан өчен барган аяусыз көрәштә һәр ике яктан да бик күп сугышчылар һәлак булды.

Шәһәрне яулап алганда үлгән рус сугышчыларына 1823 елда һәйкәл салынды. Башкалабызны яклап шәһит киткән бабаларыбыз истәлегенә исә гади генә таш та куелмады. Ләкин халык хәтерендә аларның фидакарьлеге һәрвакыт кадерләп сакланып килде.

Ниһаять, шул хәтерне һәйкәл итеп сынландыру вакыты килеп җитте. Бик күп халык вәкилләре һәм җәмәгать оешмаларынын мөрәҗәгатен искә алып, Татарстан Республикасынын Министрлар Кабинеты 1552 елда Казанны саклаганда һәлак булган каһарманнар истәлегенә багышлап һәйкәл төзү турында үткән елның 26 февралендә карар кабул итте.

Шушы карарны үтәү йөзеннән, һәйкәлне төзү өчен, махсус фонд оештырылды. Бүгенге көндә ул фонд рәсми рәвештә теркәлеп, үзенен эшен башлап җибәрде.

Булачак һәйкәлнен проектына конкурс игълан ителде. Берничә проект инде жюри тарафыннан карап тикшерелде дә.

Һәйкәл 2000 елда төзелеп бетәр дип уйлыйбыз.

Төзелешне тизләтү өчен, әлбәттә инде, финанс чыгымнары кирәк. Һәйкәл халык хәтеренен символы булганга, анын чыгымнарын да җәмәгать белән күтәрербез дип өметләнәбез. Бу изге эштә һәрберебез дә хәлдән килгәнчә катнашырбыз дип ышанабыз. Оешмалар, предприятияләр дә читтә калмас дип уйлыйбыз.

Казанны яклап һәлак булучыларга һәйкәл кую мәсьәләсе күтәрелгәч, заманында төрле бәхәсләр дә булып алды. Бу турыда бүген дә берничә сүз әйтеп китәргә кирәктер.

Һәйкәлнен зарурлыгына шик белдерүчеләр бар. Берәүләр, җинелүебез хөрмәтенә һәйкәл төзү урынлы булырмы, дисә, икенчеләр, ул һәйкәл ике милләт арасында каршылык тудырмасмы дип борчылалар.

Безнен уебызча, андый шикләнүләргә нигез юк. Төзеләчәк һәйкәл халык хәтере символы булып, анын янына килүчеләрне уйландырыр. Үткәнебез, бүгенгебез, киләчәгебез турында уйланып күпсанлы корбаннар бирмичә тату яшәүнең серенә төшенергә тырышырбыз. Һәр сугыш халык хәтерендә фаҗига булып саклана. Сугышны халыклар түгел, канга сусаган хәкимнәр башлый. Халык ул сугышларда корбан гына була.

Килер заман, кешеләр төрле низагларны кан коеп сугышмыйча, акыл белән чишәргә өйрәнерләр. Дөнья белән идарә итәргә җыенучы тиран хәкимнәрнең нәфесләренә чик куя белерләр. Бөтен халыкларны тигез итеп күргән җир анабыз берәү генә. Аны кан белән сугару зур гөнаһ икәнен аңлар кешеләр.

Казансу елгасының бер ярында Казанны яклаучыларга һәйкәл торса, икенче ягында Казанны алганда үлгән рус сугышчыларына куелган һәйкәл бер-берсенә карашып сүзсез генә сөйләшерләр, аңлашырлар, татулыкка юл эзләрләр.

Безнен фонд рус сугышчылары истәлегенә салынган һәйкәлне төзекләндерүне дә күздә тота. Ул эшкә дә үз өлешләрен кертүчеләр булыр дип уйлыйбыз.

Хәерле сәгатьтә эшкә тотыныйк, җәмәгать!

**Туфан МИҢНУЛЛИН,**
*Фонд рәисе, драматург, Дәүләт Советы депутаты.*

## *Иҗтимагый—мәдәни тормышыбыздан*

### ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

4 февральдә язучыларның Тукай клубында ел йомгагына багышланган традицион җыелыш булды. Җыелышны Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Фоат Галимуллин ачты һәм алып барды. Язучылар аягүрә басып, бу чорда мәрхүм булган каләмдәшләрен искә алдылар.

Аннан соң Язучылар берлегенә яңа кабул ителгәннәргә язучы таныклыгы тапшырылды. Җыенда исемле премияләргә лаек булучы язучылар игълан ителде.

Язучы, тәнкыйтьче Рифат Сверигин—проза, Владимир Корчагин—рус язучылары иҗаты, Марс Шабаев—публицистика, Рафис Корбан—балалар әдәбияты, Галимҗан Гыйльманов тәнкыйть турында докладлар белән чыктылар.

Тыңланган докладлар буенча фикер алышуларда Харрас Әюп, Саимә Ибраһимова, Нәҗибә Сафина, Рифә Рахман, Лена Шагыйрьҗан, Вахит Имамов, Рабит Батулла, Айдар Хәлим, Туфан Миңнуллин, Госман Садә, Ркаил Зәйдулла һ. б. катнашты.

### АКСАКАЛЛАР ФИКЕРЕ

Татарстан Аксакаллар шурасы Дәүләт Думасына белдерү җибәрде. Анда болай диелә: «Татарстан Республикасы һәм татар халкының Аксакаллар Шурасы сугыш чыккан очракта Россиягә атом-төш коралын беренче кулланырга мөмкинлек бирә торган яңа хәрби доктрина турындагы мәгълүматка бәйле рәвештә Федерациянең күпмилләтле халыкларының язмышы өчен тирән борчылуын белдерә. Аксакаллар Шурасының бу белдерүен Дәүләт Думасы депутатларына, Федерация Советы әгъзаларына, Президент вазифаларын башкаручыга һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенә житкерүләрен үтенә».

### «ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ» БӘЙРӘМЕ

«Казан» милли мәдәният үзәгендә «Татарстан яшьләре» газетасының беренче саны чыгуга 80 ел тулуга багышланган тантана булды. Республикабызда нәшер ителә торган иң күп тиражлы газетаның юбилеенда Татарстан Югары Советы Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары И. К. Хәйруллин, Югары Совет Рәисе урынбасары Р. М. Миңнуллин, ТР матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм аралашу чаралары министры З. Р. Вәлиева, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Р. А. Ратникова газетаның төрле еллардагы мөхәррирләре, авторлары, матбугат һәм мәгълүмат чаралары житәкчеләре, әдәбият-сәнгать әһелләре катнашты.

### ШАЛЯПИН ФЕСТИВАЛЕ

4 февральдә Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры сәхнәсендә Шаляпин исемендәге халыкара фестиваль ачылды. Бу инде унтугызынчы фестиваль. Һәр елдагыча Казан кешеләре һәм шәһәр кунаклары Россиянең иң яхшы җырчылары белән очраштылар.

### ТАТАР-ИНФОРМГА БҮЛӘК

Татар-Информ мәгълүмат агентлыгы «Русия халыкларын рухи яктан яңарту» номинациясендә 1999 ел өчен Русия Журналистлары берлеге бүләге лауреаты булды.

### «СӨЕМБИКӘ»ДӘ ЯҢА ХУҖАБИКӘ

«Сөембикә» журналының элекке баш мөхәррире Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллова Дәүләт Советына даими эшкә күчү сәбәпле, баш мөхәррир итеп Фирая Равил кызы Бәдретдинова билгеләнде.

Ф. Р. Бәдретдинова моңарчы «Таһир—Зөһрә» газетасының һәм «Салават күпере» журналының баш мөхәррир урынбасары булып эшләде. Яңа житәкчене 7 февраль көнне коллективка матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм аралашу чаралары министры Зилә Вәлиева тәкъдим итте.

## НӘШРИЯТ ИСЕМЕН ҮЗГӘРТТЕ

«Идел-пресс»—Татарстан газета-журналлар нәшрияты хәзер шулай атала. Элекке Татарстан газета-журналлар нәшриятының исемен үзгәртү зарурлыгын полиграфия-нәшрият комплексы җитәкчелеге болай анлата: күпкырлы нәшрият эшчәнлегендә яна тактик якын килүләр таләп итетә. Идел буендагы шушы зур полиграфия предприятиесе эшлекле партнерларын алга таба нәтиҗәле хезмәттәшлеккә чакыра.

## САЛЛЫ БАСМАНЫҢ ЯҢА САНЫ

«Гасырлар авазы—Эхо веков» журналының чираттагы саны (3/4 1999) дөнья күрде.

Басманың күп өлеше Казан тарихына багышланган. Шәһәргә нигез салынган елны ачыклау эшләре, борынгы архитектура, элекке чорда китап басу турындагы язмалар һәм гыйбрәтле архив документлары урын алган.

## ТОРГЫЗУ ЮЛЫНДА

Екатеринбург (элекке Свердловск) 30 нчы елларда татар мәдәният үзәкләренең берсе булган. Анда татар-башкорт язучылары оешмасы эшләгән. «Социализм юлы» газите («Күмер өчен», «Урал кочегаркасы», «Уралның ударнигы» дигән кушымталары белән), яшьләр, балалар өчен «Алга», «Алмашчы» газитләре, «Зур Урал төзегәндә», «Мәгариф эшләре», «Уралда мәгариф» журнал-бюллетеньнәре, «Шәпи агай» исемле юмористик журнал һәм башка басмалар чыккан.

Быел шәһәрдә «Урал тау» исемле татарча газит чыга башлады.

## ЯЗУЧЫЛАР БӘЙРӘМЕ

С. Садыйкова исемендәге концертлар залында 25 язучыны берләштергән Чаллы Язучылар оешмасы төзелүгә 20 ел тулу уңаеннан тантаналы кичә булды.

Анда Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин, танылган әдипләребез Туфан Миннуллин, Разил Вәлиев, Роберт Миннуллин, Шәмсия Җиһангирова, күрше тирә-як районнарда яшәп иҗат итүче язучы һәм шагыйрьләр катнашты. Кичә барышында Чаллы язучылар оешмасы рәисе Вахит Имамовка һәм барлык әдипләргә җылы котлау сүзләре, бүләкләр тапшырылды, аларның эшчәнлегенә уңай бәя бирелде.

Шәһәр хакимияте башлыгының мәдәният эшләре буенча урынбасары Ф. Мостафина язучылар оешмасына мәрнын котлау юлламасын тапшырды һәм хакимиятнең тел һәм мәдәниятне үстерү фондыннан ай саен 5 мең сум акча күчерелеп торачагын белдерде.

## ЯҢА ӘГЪЗАЛАР

26 гыйнварда булып үткән Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышында танылган публицист-тарихчы, Татарстан архив идарәсе башлыгы Дамир Шәрәфетдинов, биш китап авторы, республика хастаханәсе табибы Нәкыйп Каштанов, яшь прозаик Марианна Валишева һәм Балык Бистәсе районы газетасы мөхәррире Вәзыйх Фатыйхов берлек әгъзалары итеп кабул ителде.

## ӘДИП КИЧӘСЕ

28 январьда Татарстан язучыларының Г. Тукай клубында күренекле язучы Барлас Камаловның 70 яшьлек юбилее уңаеннан әдәби-музыкаль кичә узды. Аңа кадәр аның иҗат кичәләре Буа районы үзәгендә, аның гомере, язмышына бәйле шул төбәктәге тирә-юнь авылларда булган иде инде.

## ОСТАХАНӘЛӘРДӘ

25 гыйнвар көнне Язучылар берлегенең Тукай клубында проза остаханәсе утырышы үткәрелде. Анда республикабызда чыга торган журналларда дөнья күргән проза әсәрләре турында сөйләшү булды.

«Сөембикә» журналында басылган проза әсәрләренә язучы Марат Әмирханов күзәтү ясады. «Идел» журналындагы проза әсәрләре һәм журналның бу жанрны үстерүдәге хезмәтләре хакында Рафикъ Юныс сөйләде. «Чаян» журналы турында шагыйрь Зөлфәт чыгыш ясап, үткер һәм таләпләргә җавап бирердәй чын хикәяләр аз булуын искәртте. «Ялкын» журналыннан Фәйрүзә Мөслимова бүгенге яшүсмерләр, балалар тормышын белеп, аңлап язылган әсәрләр азлыгын әйтте. «Язучылар күбрәк үз балачак хатирәләрен язалар»,—диде ул.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Президенты Указы белән Казан дәүләт педагогика университетының татар әдәбияты кафедрасы профессоры, Язучылар берлеге әгъзасы **Фәрит Миргалим улы Хатыйповка** «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# ГҮЗӘЛЛЕК МӘҖНҮНЕ

Мәскәүле татар рәссамы Мансур Саттар—бүгенге гүзәллек идеалларына ерак юллар аша килгән шәхес. 1948 елда Казанда туып, Уфада белем алган Мансурның иҗаты 1970 еллар башында, сәнгатьтә индустрия шаукымнары, патриотик илгизәрлек, яңа җирләр, поляр утраулар, Сахалин-Камчаткаларның кырыс гүзәллеген тасвирлау стихиясе хөкем сөргән чакта ачылып китте. Романтик аһәңнәр, экзотик төньяк балкышы, бозлы алып-кыялар, илаһи айсберглар, гейзерлар, Диксон манзаралары индерелгән серле тукымалары белән 1980—1988 елларда ул Казан тамашачысын бер тетрәтеп киткән иде инде. Аның Америка пионерларын хәтерләткән ковбой стиле—биек кунычлы итекләр, киң эшләпә, күн киемнәр һәм, гомумән, ниндидер, гадәти, профан тормыш белән канәгатьләнмәү, ерак сәяхәтләр белән хыяллану, эзтабарлык хисе—болар барысы да әсәрләрендә ачык чагылган иде.

Һәм менә көннәрдән бер көнне әлеге рәссам имиджын үзгәртер, көчле ихтыярлы, бәхет эзләүче азгын жилкуардан—хатын-кыз гүзәллеген алга сөрүче талгын шагыйрьгә әйләнер, дигән уй башка да килми иде...

Соңгы күргәзмәләренең географиясе гаҗәпләндергеч киң һәм гыйбрәтле аның: Мәскәү, Штутгарт, Хельсинки, Лиекса, Стокгольм, Мюнхен, Женева, Рейкьявик... Иҗатының профессиональ югарылыгы, нәфислеге һәм илаһилыгы белән Мансур Саттар көнбатыш сәнгать сөючеләренең йөрәген яулап алды. Рәсәй һәм чит илләрдә нәкъ менә гүзәллек мәҗнүне, мәхәббәт корбаны һәм аның шәрекъчә татлы вә сизгер иҗатчысы абруен йөртә ул. Аның хатын-кыз портретларыннан гыйбарәт булган, XX гасыр башына хас эстетлык, кием-салым, жест-мимикаларны, эчке тирәнлек-тотнаклыкны кабат кайтарган әсәрләренең исеме дә элеккечә сагынулы, шигъри интонацияле: «Якты өметләр образы», «Узган гомер белән очрашу» һ. б...

Күрәсең, хыял ташкыны рәссамны җилләр-илләр, ком-чүлләр, ерак шәһәрләр, борынгы мәдәниятләр арасында шактый исертеп йөртеп, ахыр чиктә кеше гүзәллеге, хатын-кызның ихлас матурлыгы хакындагы уйлар кодрәтенә алып кергән. Шушы дулкыннар тамашасында—«Җәүһәрләр утравы» (1993), «Кеше яшәми торган әкияти утрау» (1993) кебек әсәрләргә алмаш буларак, «Ак киемле кыз» (1993) һәм тышлыкның беренче битендәге «Татар гүзәле» (1994) әсәрләре туган.

Бары тик кара-көмеш карандаш белән сынландырылган бу зифа сын чын мәгънәсендә ләззәтле рухи тормыш белән яшәгән, тышкы гүзәллеге белән бер микъдарда эчке дөньясы да кайнап-балкып торган, укымышлы татар хатын-кыз зыялыларының гомумиләштерелгән портреты булып кабул ителә... Монда нечкә чалымнар, үтә күренмәле яссылыклар, китап-каләм сыман әсбаплар да—үзенә бер рухият, илаһият... Гасырлар төбеннән килгән татар хатын-кыз кальбенең XX гасыр гүзәллек канатларында эретелгән чагылышы. Асыллык, шигърият...

**Розалина ШАҺИЕВА,**
*сәнгать белгече.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Барлас Камалов



# ХУШЛАШУ СҮЗЕ

Республикабызның киң җәмәгатьчелеге авыр кайгы кичерә. Шушы елның 16 февралендә 91 яшендә талантлы әдип, кабатланмас каләм остасы, чорыбызның мәшһүр шәхесе **ӘМИРХАН ЕНИКИ** вафат булды.

Әмирхан Еники (Әмирхан Нигъмәтҗан улы Еникеев) 1909 елның 17 февралендә элеккеге Уфа губернасының Бәләбәй өязендә Яңа Каргалы авылында туган. Булачак язучының балалык һәм мәктәп еллары исә Дәүләкән авылында уза.

Яшьтән әдәбият, иҗат эше белән кызыксынган Ә. Еники 1925 елның җәендә Казанга килә һәм бер елдан соң Казан университеты каршындагы рабфакка укырга керә. Шул чор көндәлек матбугатында аның әдәби парчалары һәм хикәяләре еш күренә башлый.

Ә. Еники, үзенчәлекле язучы буларак, нигездә, сугыш вакытында һәм шуннан соңгы елларда формалаша. Аның «Бала», «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз», «Мәк чәчәге», «Кунакчыл дошман», «Тауларга карап», «Кем җырлады?» кебек хикәяләре татар психологик прозасын яңа биеклеккә күтәрде. Илленче-житмешенче елларда әдип тагын да зуррак иҗади уңышларга ирешә. Язучының «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге», «Йөрәк сере», «Рәшә», «Вөҗдан» «Без солдатлар идек» повестьлары, «Гөләндәм туташ хатирәсе» романы, «Ялгызлык», «Туган туфрак», «Матурлык», «Төнге тамчылар», «Коръән хафиз», «Әйтелмәгән васыять», «Тынычлану» кебек хикәяләре, кешеләр арасында төрле катлаулы мөнәсәбәтләрне реалистик рухта яктыртуы һәм заманны борчыган проблемаларны кыю рәвештә күтәрүе белән бергә, сәнгатьчә камил эшләнүләре җәһәтеннән дә татар әдәбиятының олы казанышлары булып санала.

Әдипнең иҗатында юмор-сатира, әдәби тәнкыйть, очерк, публицистика, мемуар әсәрләр һәм тәрҗемәләр дә зур урын биләп тора. Ул А. Островский, М. Бубеннов, К. Паустовский, О. Гончар, Э. Казакевич, Ч. Айтматов кебек танылган әдипләрнең әсәрләрен һәм күп кенә халыкларның әкиятләрен татар теленә тәрҗемә итте. Үзенең дә күп кенә әсәрләре рус, төрек, инглиз һәм башка телләрдә дөнья күрде.

Ә. Еники халкыбызның акылын, зирәклеген, намусын гәүдәләндергән олуг әдипләребезнең берсе иде. Күпкырлы талант иясе буларак, әдип үзенең әсәрләрендә фәлсәфи үткенлек, психологик тирәнлек, алдан күрүчәнлек, сәнгати камиллек белән әхлакый-этик мәсьәләләрне кыю күтәрде, әдәбиятыбыз-сәнгатебез үсешен гомеренең соңгы көннәренә кадәр тирәнтен кайгыртып яшәде. Ул тормышның үзәгендә кайнап, халкыбызның абруйлы асыл затына әверелде.

Ә. Еникинең күпьеллык намуслы хезмәте ил-халык тарафыннан югары бәяләнде. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнде. 1984 елда аның «Юлчы» исемле хикәяләр җыентыгы һәм русча «Повести и рассказы» дигән китабы өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Ул «Татарстанның халык язучысы» дигән шәрәфле исемгә лаек булды.

XX гасыр татар әдәбияты, иҗтимагый-эстетик фикер үсешенә бинибая зур өлеш керткән Әмирхан ага Еникинең якты истәлеге күңелләрдә мәңге сакланыр, аның бөек әсәрләре сөекле язучыбызны халкыбызның үлемсез шәхесе итеп, иленнән, халкыннан аермый яшәтер, киләчәк дәверләргә илтер.

**М. Ш. Шәймиев, Р. Н. Миңнеханов, Ф.Х. Мөхәммәтшин, Ә. С. Гобәйдуллин, И.К. Хәйруллин, Р. М. Миңнуллин, К. Ш. Исхаков, И. Г. Тарханов, З. Р. Вәлиева, Ф. Г. Галимуллин, Г. А. Ахунов, Ш. Г. Галиев, А. М. Гыйләҗев, Р. Г. Фәйзуллин, Н. С. Фәттах, И. Г. Юзеев.**

Индекс 73210



Барлас Камалов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)